ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

ЗНАМЕНИТЫЕ ЛИЧНОСТИ



# Галимҗан ИБРАҺИМОВ



**Г. Ибраһимовның әнисе Бибихәсәнә абыстай (1862–1921)**




**Сулдан уңга: Г. Ибраһимов, абзасы Шакирҗан, Ш. Әхмәдиев. Казан, 1910**



**Г. Ибраһимов. Киев, 1912–1913**



**Г. Ибраһимов. Киев, 1913**



Г. Ибраһимов. Казан, 1913



Г. Ибраһимов (уңда), Х. Еникеев төрмәдән чыгарылганнан соң. Киев, 1913




Г. Ибраһимов (беренче рәттә сулдан икенче) «Галия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре белән. Уфа, 1916



**Г. Ибраһимов (икенче рәттә сулдан икенче) «Галия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре һәм шәкертләре белән. Уфа, 1916**



**«Галия» мәдрәсәсендә тән хәрәкәте дәресе**



**Г. Ибраһимов (икенче рәттә уңнан өченче) татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләү, аларның белемнәрен күтәрү курслары мөгаллимнәре һәм тыңлаучылары белән. Уфа, 1917**



**Г. Ибраһимов (беренче рәттә уңнан өченче) татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләү, аларның белемнәрен күтәрү курслары мөгаллимнәре һәм тыңлаучылары белән. Уфа, 1917**



Г. Ибраһимов аклар тылында йөреп кайтканнан соң. 1919



**Г. Ибраһимов (икенче рәттә сулдан өченче) фикердәшләре белән. Уфа, 1917**




**Г. Ибраһимов (беренче рәттә сулдан алтынчы) Татар театрының 20 еллык бәйрәме уңае белән тантаналы утырышның президиумында. Казан, 1925**



Г. Ибраһимов (беренче рәттә сулдан дүртенче) Гыйльми үзәк әгъзалары белән. Казан, 1926



Г. Ибраһимов (сулда) Ш. Әхмәдиев белән. Ялта, 1928



Г. Мөхәммәдова улы Рөстәм белән. Ялта, 1928



**Г. Ибраһимов (икенче рәттә уртада) бер төркем татар зыялылары белән. Ялта, 1929**



**Г. Ибраһимов (сулдан икенче) гаиләсе һәм М. Таһиров белән. Ялта, 1929**



**Г. Ибраһимов. Ялта, 1929**



Г. Ибраһимов (уңнан беренче) дуслары белән. Ялта, 1930



Г. Ибраһимов (сулдан икенче) хатыны һәм кардәшләре белән. Ялта, 1930



**Г. Ибраһимов (уңнан икенче) хатыны Г. Мөхәммәдова һәм татар зыялылары белән. Ялта, 1931**



**Г. Ибраһимов туганнан туган сеңлесе Җ. Тулунгузина белән. Ялта, 1932**



**Сулдан уңга: Г. Ибраһимов, баскан (?), М. Бикбулатов, Г. Насыйров, М. Гафури. Ялта, 1932**



**Сулдан уңга: Г. Ибраһимов, М. Гафури, М. Бикбулатов. Ялта, 1932**



Г. Ибраһимов. Ялта, 1932



**Уңнан сулга: Г. Ибраһимов, Г. Алпаров. Ялта, 1932**



**Г. Ибраһимов (уртада), хатыны Х. Фәтхуллина, Ш. Камал (сулдан беренче), К. Тинчурин (сулдан дүртенче), Г. Нигъмәти. Ялта, 1936**



**Г. Ибраһимовның соңгы фотоларыннан берсе…**



Г. Ибраһимов туып үскән Солтанморат авылы күренеше



Г. Ибраһимов туган йорт нигезе. Я. Чанышев фотосы. 1963



**Г. Ибраһимов укыган һәм укыткан «Галия» мәдрәсәсе бинасы. Ә. Мансуров фотосы. 1962**



**Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсендә эшләгән елларында яшәгән йорт. Уфа, хәзерге Свердлов урамы, 86. Ә. Мансуров фотосы. 1962**



Г. Ибраһимов «Галия» мәдрәсәсендә эшләгән елларында яшәгән йорт. Уфа, Электрический переулок, 7.  Ә. Мансуров фотосы. 1962



Г. Ибраһимов нигезләгән «Ирек» газетасы редакциясе урнашкан «Сарай» номерлары бинасы. Уфа, хәзерге Пушкин урамы, 92. Ә. Мансуров фотосы, 1962



**Г. Ибраһимов Казанда 1922 елларда яшәгән йорт. Хәзерге К. Насыйри урамы, 10. 2010**



**Г. Ибраһимов Казанда 1925–1927 елларда яшәгән йорт. Хәзерге Мөштәри урамы, 33. А. Такташ фотосы, 1966**



Г. Ибраһимов
Ялтада 1927–1936
елларда яшәгән йорт.
Халтурин урамы, 5



Г. Ибраһимов Ялтада 1936–1937 елларда яшәгән йорт.
Боткинская урамы, 23

# *Галимҗан Ибраһимовка мөнәсәбәтле кайбер документлардан үрнәкләр*



ТЫУЫУ ТУРАҺЫНДА ТАНЫКЛЫК

СВИДЕТЕЛЬСТВО О РОЖДЕНИИ

«Повторное»

Гр. Ибрагимов, Галимзян Гирфанович

тыуған 26/II-1887 г.

родился(лась) Двадцать шестого февраля тысяча восемьсот восемьдесят седьмого г.

Баланың тыуған ере: кала, ауыл

Место рождения ребенка: город, селение дер. Султанмуратово

район Аургазинск.

өлкә, край

область, край

республика Баш. АССР.

тыуыу тураһындағы граждандар хәле актарын язы[у] кенәгәһендә был тыуыу тураһында

о чем в книге записей актов гражданского состояния о рождении

1887 йылдың февр. айының 26 числоһында

года месяца числа

№ менән тейешле язма яһалды.

произведена соответствующая запись за № 6.

АТА-ӘСӘҺЕ:

РОДИТЕЛИ:

Атаһы

Отец Ибрагимов Гирфан Нурмухаметович

милләте

национальность татар

Әсәһе

Мать Ибрагимова Бибихасана Зайдулловна

милләте

национальность татарка

Теркәү урыны

Место регистрации Султанмуратовск. выд. Аургазинск. бюро ЗАГС

Бирелеү вакыты

Дата выдачи 14. марта 1969 г.

III-АО № 107878



АВТОБИОГРАФИЯ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА.

I.

Родился в 1887 г. в деревне СУЛТАНМУРАТОВО б. Уфим. г. Стерлитамак, Уршакминской волости.

По происхождению крестьянин.

До 20-ти летнего возраста сам каждое лето работал как обыкновенный крестьянин (во время летних каникул). После некоторого перерыва, во время войны, когда братья были взяты на войну опять вернулся к этой работе.

Отец – человек духовного звания, но к концу своей жизни бросил этот сан и жил только как хлебороб. Хозяйство его по размеру было чисто середняцкого типа.

2.

Учился:

I – в деревне, в татарском "Мектебе".

2 – в сельской, начальной русской школе.

3 – с II до I3 лет в Оренбурге в мусульманском "Медресе" старого типа, откуда был изгнан за "вольнодумство" за новаторский образ мышления.



ПОСТАНОВЛЕНІЕ.

1913 г. Апреля ... 18 дня, въ г. Кіевѣ, Начальникъ Кіевскаго Губернскаго Жандармскаго Управленія Полковникъ Шредель, имѣя свѣдѣнія, внушающія основательныя подозрѣнія о принадлежности Крестьянина Уфимской губерніи ..... Галимжана Гирфановича Ибрагимова къ противоправительственному сообществу и руководствуясь 21 ст. Положенія о Государственной охранѣ, ВЫСОЧАЙШЕ утвержденнаго 14 августа 1881 г. ПОСТАНОВИЛЪ: поименованнаго Галимжана Ибрагимова .. подвергнуть личному предварительному задержанію въ Кіевской тюрьмѣ впредь до разъясненія дѣла, о чемъ сообщить Кіевскому Губернатору; копію сего постановленія препроводить Прокурору Кіевскаго Окружнаго Суда и въ мѣсто заключенія, объявивъ это постановленіе съ подпиской на семъ же, задержанному

Полковникъ Шредель

Постановленіе это мнѣ объявлено "19" Апреля .. 1913 г.

Галимзянъ Ибрагимовъ



НАЧАЛЬНИКЪ
КІЕВСКАГО
ГУБЕРНСКАГО
ЖАНДАРМСКАГО
УПРАВЛЕНІЯ.

2 Апрѣля 1914 г.
№ 843
г. Кіевъ.

По 9 дѣлопроизводству.

Вслѣдствіе предложенія Департамента Полиціи отъ 25 минувшаго Марта за № 168739 и въ дополненіе донесеній Начальника Казанскаго Губернскаго Жандармскаго Управленія и Начальника Жандармскаго Управленія города Одессы отъ 15 февраля сего года [№-неизвѣстенъ] и 28 минувшаго марта за № 1251, доношу Вашему Превосходительству, что секретарь мусульманскаго журнала "Аңъ" - Галимджанъ-Алимзянъ Гирфановъ ИБРАГИМОВЪ 15 февраля сего года прибылъ изъ города Казани въ г. Кіевъ и былъ встрѣченъ на вокзалѣ наружнымъ наблюденіемъ у коего онъ проходилъ подъ кличкой "Интеллигентный".

Съ вокзала наблюдаемый Ибрагимовъ былъ проведенъ въ домъ № 130 по Жилянской улицѣ въ меблированныя комнаты "Москва", а на слѣдующій день 16-го того же февраля Ибрагимовъ снялъ комнату въ домѣ № 55 по Львовской улицѣ, гдѣ и проживалъ до выѣзда въ г. Одессу.

Учрежденное за Ибрагимовымъ наружное наблюденіе отмѣтило посѣщеніе имъ библіотекъ, почты и рестора-

ДИРЕКТОРУ ДЕПАРТАМЕНТА ПОЛИЦІИ

НАЧАЛЬНИКЪ
УФИМСКАГО
ГУБЕРНСКАГО
ЖАНДАРМСКАГО
УПРАВЛЕНІЯ.

15 Октября 1914 года.

№ 8067

г. УФА.

Секретно. 96

В дополненіе записки моей отъ 18 Сентября сего года за № 7306 сообщаю, что упоминаемый въ таковой Галимджанъ ИБРАГИМОВЪ-2-го сего Октября выбылъ на жительство въ городъ Казань.

Генералъ-Маіоръ

Начальнику КАЗАНСКАГО Губернскаго Жандармскаго Управленія

---

НАЧАЛЬНИКЪ
КАЗАНСКАГО
Губернскаго
ЖАНДАРМСКАГО
УПРАВЛЕНІЯ.

„12" іюня 1914 г.

№ [redacted]

г. Казань.

По 9-му Дѣлопроизводству.

1 ІЮН 1914
вход. № 18674

Въ дополненіе донесенія Начальника Уфимскаго Губернскаго Жандармскаго Управленія Господину Директору Департамента Полиціи отъ 3 сего іюня за № 141, доношу Департаменту Полиціи, что авторомъ совершенно-секретнаго документа за № 124, приложеннаго къ сказанному донесенію, является Галимджанъ Ибрагимовъ, проживающій нынѣ въ гор. Сухумѣ, о коемъ было донесено мною Департаменту 15 февраля текущаго года за № 115.

Упоминаемый въ документѣ "Ваталъ" – сотрудникъ Казанской газеты "Йулдузъ" /редакторъ-издатель ея Гадый Максудовъ, братъ бывшаго члена Государственной Думы 3-го созыва Сатретдина Максудова/ Абдулбарей Баталовъ. По имѣющимся у меня агентурнымъ свѣдѣніямъ онъ панисламистъ. По тѣмъ же свѣдѣніямъ Баталовъ недавно выѣхалъ въ Сарапулъ для присутствованія на совѣщаніи общественныхъ дѣятелей Вятской и Пермской губерній по поводу происходящаго нынѣ въ С.Петербургѣ мусульманскаго съѣзда, съорганизованнаго председателемъ думской мусуль-

ВЪ ДЕПАРТАМЕНТЪ ПОЛИЦІИ.

Казань　　　　　　　　　　　　　Ячейка № 12

50

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

Ц. К. Р. К. П.
СТАТИСТИЧЕСКИЙ ОТДЕЛ.

*Пролетарии всех стран, соединяйтесь!*

# ВСЕРОССИЙСКАЯ ПЕРЕПИСЬ

Бланк „А" ЧЛЕНОВ РОССИЙСКОЙ КОММУН. ПАРТИИ (Б-ов).

№ 7

## 1922 года.

1. Местонахождение ячейки: гор./сел. Казань уезд/волость ______ губ./область ______

2. Наименование предприятия (учрежд., воинск. часть), при котором организована ячейка 6-ая Государственная Типография

3. Наименование парторганизации, выдавшей билет Забулачно-Плетеневский Район № 652205

4. Фамилия Ибрагимов 5. Имя и отчество Галимджан Гирфанович

6. Пол: муж. 7. Возраст: родился в 1888 году; число исполнившихся лет: 33 лет.

8. Разговорный язык татарский 9. На каких языках, кроме того, свободно говорите: русский турецкий

10. а) Имеете ли какие-либо религиозные верования (убеждения?) (да, нет) какие именно: никаких

б) Если Вы неверующий, то с какого возраста: с 16 лет.

11. Число членов семьи при спрашиваемом (не включая его самого): иждивенцев: 1; работников: 0

12. Образование: а) грамотный ли (да, нет): да б) если учились или учитесь, то укажите:

### Таблица I. Образовательный ценз.

| | Тип учебных заведений (2-х кл. земское; 4-х кл. городское; проф.-техн. школа; вечерние курсы авто-дела; авиационные курсы; гимназия; университет; партшкола). Внешкольное образование отмечается словами „самоучка", „домашнее". | Сколько лет учились. | Окончили ли школу (да, нет, вышел из такого-то класса, учусь). |
|---|---|---|---|
| | 13 | 14 | 15 |
| а | Начальная русская школа 3х год. исп. курсом; Восточная Мусульманская стар. типа с 7 годичн. курсом; | 3; 7; 3 | да; да; не оконч. |
| б | Высшая Мусульманская Восточная нового типа с 4х г. курсом. | | |
| в | Университет Истор. Филологич. вольно-слушатель с 4х годичн. курсом | 1 | не окончил |

16. Если имеете желание учиться, то чему именно (грамоте, наукам, искусствам, ремеслам—каким именно): нет

### Таблица II. Социальное и национальное происхождение.

| Отношение к опрашиваемому. | Основная профессия или занятия, должность, чин. | Положение в промысле (хозяин с наемными рабочими; хозяин-одиночка; наемный рабочий; лицо „свободной" профессии; домохоз.; домашн. хозяйка). | Национальность. |
|---|---|---|---|
| 17 | 18 | 19 | 20 |
| 1. Дед (с отцовск. стор.) | Землепашец | владелец 5-6 десятин земли | Татарин |
| 2. Отец | то-же | владелец 5-6 десят. земли | Татарин |
| 3. Мать | домашн. хозяйство | домашняя хозяйка | Татарка |

21. С какого возраста живете своим трудом: с 13 лет; по найму или в своем хозяйстве (подчеркните).

22. а) Основная профессия и специальность до 1917 года: Журналист, педагог и писатель

б) Сколько лет работали по этой профессии: 17

23. Основной источник средств к существованию до 1914 года: Заработок в 1914—1917 г. тоже.

### Таблица III. Рабочий и служебный стаж с 1917 г. до настоящего опроса.

| Период работы. | Место работы: Наименование предприятия, (учреждения, воинской части), где работал не менее 3-х месяцев и где работает в настоящий момент. | Место работы: Город или губерния. | Род занятий. | По найму, выборам, назначению. | Продолжительность работы. С какого и по какое время: Месяц, год. | Месяц, год. | Итого работы: Лет. | Мес. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 24 | 25 | 26 | 27 | 28 | 29 | 30 | 31 | 32 |
| А) С 1917 г. до времени вступления на постоянную должность. | а. Парт. Газ. Ирык | Уфа | Редактор | выб. | 1917 III | 1917 XII | | 9 |
| | б. Цен. Мусульман. Комис. | Петроград | Зам. Комиссара и редак. газет. | по назнач. | 1918 I | 1918 IX | | 8 |
| | в. Хутор Науч. Областъ | Казань | Писарь | | 1918 X | 1922 I | | |
| | г. | | | | | | | |
| | д. | | | | | | | |
| Б) В момент опроса. | а. Центральное Бюро | Казань | Член Колл. | выб. | 1919 IV | 1921 IV | 2 | |
| | б. Камвостпоко Госиздат. | | | | | | | |



Этра юк

1927. 21.06.

1

# Факультетская Терапевтическая Клиника № 193

## КАЗАНСКОГО УНИВЕРСИТЕТА.

Поступил 19 21/III 27 **Diarium** Выбыл 19 21/IV 27

Фамилия, имя и отчество Ибрагимов. Гасим.

Возраст 40 л. Семейное положение жен. Национальность мисуль.

Занятие ______ Образование средн.

Местожительство Кошлевс. ул. № 33 кв. 6.

Диагноз: Tuberculosis III п. [illegible]

Ординатор Гамков. Куратор

1) Анамнез и суб'ективные жалобы: Б-ной поступил в клинику в тяжелом состоянии после бывшего повторного легочного кровотечения, установленного врачами. — Ввиду тяжелого состояния больного — сведения о нем даны его женой.

— В настоящее время больной очень слаб, у него имеется [illegible] кашель с выделением кровяных сгустков темно-красного цвета.

— Заболел 17-го марта с/г. среди относительного здоровья, во время пребывания на деловом собрании. — Во время разговора больного со своим соседом — у него открылось обильное кровотечение, при чем выделилось почти полных [illegible] кружки крови. Кровь [illegible], пенистая. — Б-ной быстро был доставлен в домашнюю обстановку. 19-го марта вечером — кровотечение возобновилось. Кол-во выделившейся крови равнялось 1/2 стакану. На следующий день, 20 марта, снова имело место кровотечение с выделением 1½–2 стаканов крови. — Т° вечером 18 марта повысилась до 39,5° вечером 19/III дошла до 40,1° и в последние дни пребывания дома ниже 39° не опускалась.

— Б-ной очень ослабел, совершенно потерял аппетит. Отмечается отсутствие [illegible] — запора. — В последние дни — сильная слабость, бессонница, небольшой кашель с выделением [illegible] сгустков крови, потеря аппетита, [illegible] общее состояние.

— За две недели перед [illegible] наступлением заболевания у б-го был [illegible] [illegible] кашель с выделением окрашенной кровью мокроты.

— О перенесенных в детстве, а равно и в более зрелом возрасте заболеваниях — подробных сведений жена дать не может.

— Б-ной давно болеет „грудью" — давно врачи у б-го нашли туберкулез. — В 1921 г. — б-ой был по поводу своего туберкулеза



# ГРАМОТА

ГЕРОЮ ТРУДА

гр. ИБРАГИМОВУ Галимджану Гирфановичу

Президиум Всероссийского Центрального Исполнительного Комитета, отмечая Вашу выдающуюся и исключительно полезную деятельность в области социально-культурного развития татарских трудящихся масс, выразившуюся в создании классических произведений татарской художественной литературы, в издании специальных трудов по изучению классовой борьбы и революционного движения среди татар, а также учитывая Вашу активную общественную работу, — награждает Вас званием Героя Труда.

Председатель Всероссийского Центрального Исполнительного Комитета

И. о. Секретаря Всероссийского Центрального Исполнительного Комитета

Москва, Кремль.
11 ноября 1932 года.
№ 118






قەدىرلىك جۇدى جان سەردەر، شىبرەشتان،

شۇنى مەن كۆپ ئەسلەيمەن سەنىڭ سۆزلىرىڭ ئەمەسمۇ؟ تۆت ئوتتىنچى:
شۇ ئەتكەن ھالىڭلار، مەدادىيار، غالىب تېشىم، ئۈزلىگىدە مابار ئالىم، مېنى
ئۇزاق يادىدا يالقۇن رەسىم ھامان تىغلىق بېرىپ، سىنىپ بېرىدىن بېرى
ۋە ياپچىق ئالىپ، بىر مەشقۇلىنى ياسا بۇ ئەمەل ۋە ئىشتىم. سىز بىلەن ئاقىل
ھازىرلاردىن ئالغان رەسىملەر بىلەن بىللە بۇ نالە ئەتتىم ئۈچ
كالامى دارۋى دېگەن سىزگە بۇ ھالەتنى شۇ ئۆزۈم ئېتتىم.
جېنىم، . . . بىر نالە ئەتتىم مىڭ 15، 20 كۈندە بىر ئاي يالقۇن
تۇرادا. شۇ كۈنى دوكتۇر ئالىپ كۆپ سۆزلىدى، بۇ دارۇ يالقۇندا
سىپ كېتتى. ۋاجان كۆڭلۈمنى ياغلىدى. سىز بىلەن ھەممە ھەققىدە ئاڭلاڭ
سىز بىلەن دەم شۇل.
ئاللا سۆزى ئالغان رەسىم ئاۋال دارۋى تۆتلەر ۋە مەكتەپ
ئۆتكەن بەكلىك. يۇسۇپ دەل شۇل 10، 15 دە كۆپ بولۇپ تۇرادا.
سىز بىر ئۇچرىغان بولسا زور ئادەم ئەمەس، قىلىپ سىزگە تۇرادا
ئىشىدۇ، شۇ ۋەقەدە، ئىشىنىڭ ئۆز ئىشىنى بىر ياساپ، بىلىپ دەپ بوۋاقتا
ئالىپ ياشغان ئالىم ۋە گۆش ئىشلىرىنى تۈگەتتىم. ئىشلەپ بۇ نالە بىلەن ئاتا ھەزرەتى
سۆزلەرنى، بۇ مەلەسا بېرىلگەن ياشقا چۈشكەن ھازىر بار ئۆز بېرىپ!
تىنىدە ئىشلەپ سەرى بىر يىل: ئالىمجان — بالىتى 3 يىل مىنۇن 9

P.S. ۋە دوست سېلىپ جاۋاب بېرىشىڭىز ئىمكان بولسا، 10، 15 جۇمە، ماي ھەر قەدەملىرىڭ
جىسمانى، مەكتەپچىلەر ئۈستىدە ئۆز تىنچلىقىڭىز: ؟.

Qədrle Məçit abzьj !

Xatlarьꞑnь yz vaqtьnda alƣan idem, xəlemneꞑ bik avьr çaqь kəjfemneꞑ nacar konnəre ide. Şuꞑa kyrə çavabьm kicekte.

Bolnitsada 3½ aj jattьm, əmma zur nətiçə bulmadь. Xəzer hər kon doktor kilep davalap jɵri, qalƣan barlьq məşƣələtem — 1 ojƣa, xatьnьm ɵstenə tɵşə inde.

Yzem əle haman jatudamьn. Tik çylmьzlьqda jɵrəsterem: ozьn jaza almьjm, ƣafu it.

Səlamətlek teləp qalam:

Ƣalimçan

19 24/V 34

Jalta



"УТВЕРЖДАЮ":
НАРКОМ ВНУТРЕННИХ ДЕЛ АТССР
Капитан Гос.Безопасн.- (АЛМАЗОВ)

" " Августа 1937 года.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

1937 года, августа "25" дня, Я, Начальник 3 отделения 4-го отдела УГБ НКВД ТР - Мл.Лейтенант Гос.Безопасности [illegible], рассмотрев следственное дело за № 3434 по обвинению ГАФУРОВА, [illegible], [illegible] и других в преступлениях, предусмотренном 58-10 ч.1 и 58-11 ст.ст. УК РСФСР -

НАШЕЛ:

Имеющимся материалом с достаточной полнотой уличается ИБРАГИМОВ Галимзян в том, что он в 1920 году примкнул к к/р. националистической группе, так называемых "левых" в Татнарторганизации, а в 1926 г. с определенной частью этой группы вошел в к/р. троцкистско-националистическую организацию, в которой играл роль одного из руководителей вплоть до последнего времени, проводя практическую к/р. работу на культурно-идеологическом фронте, т.е. в преступлении, предусмотренном 58-10 ч.1 и 58-11 ст.ст. УК РСФСР.

Принимая во внимание, что пребывание на свободе Галимзяна ИБРАГИМОВА, в интересах следствия, невозможно, руководствуясь 145 и 158 ст.ст. УПК -

ПОСТАНОВИЛ:

Мерой пресечения для ИБРАГИМОВА Галимзяна, 1887 года рождения, сына муллы, уроженца дер. Султан-Муратово, Стерлитамакского района, Башкирской АССР, члена ВКП(б), по профессии писателя, татарина, проживающего в городе Ялте, Крымской АССР, - избрать содержание под стражей.

Командировать в г. Ялту спецконвой для доставления ИБРАГИМОВА в город Казань.

Просить санкцию Прокурора на арест.

НАЧ.3 от-ния 4 отд. УГБ НКВД ТР
Мл.Лейтенант Гос.Безоп. (подпись) ([illegible])

"СОГЛАСЕН":
НАЧАЛЬНИК 4 отдела УГБ НКВД ТР
Капитан Гос.Безопасности- (подпись) ([illegible])



С. С. С. Р.
Народный Комиссариат Внутренних Дел СССР
НКВД по ТАТАРСКОЙ АССР.

ОРДЕР № 122

Выдан 25 Августа 1937 г.
Действителен ... суток
Сотруднику [illegible]
тов. Курбанову
Вам поручается произвести обыск и арест гр. Ибрагимова Галимзяна
проживающего гор. Ялта Крымской АССР

Всем органам Советской власти и гражданам СССР надлежит оказывать законное содействие предъявителю ордера, при исполнении им возложенных на него поручений.

Нарком Внудел АТССР
Нач. 2-го отдела (подпись)



РАСПИСКА

Арестован с материалами обыска согласно протокола обыска сдал Ибрагимова Галимзяна
принял
« 29/VIII » 1937 г.
(подпись)



«УТВЕРЖДАЮ»
29 Августа 1937 г.
ВРИД. НАЧ. ЯГО НКВД-
Лейтенант госбезопас...

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
(об избрании меры пресечения и предъявления обвинения)

Город Ялта 1937 г. Августа «29» дня

Я, Опер. Упол. [illegible] КУРБАНОВ (должность и фамилия) отд-ния 4 отд. УГБ НКВД ТАССР отдела Управления Государственной Безопасности УНКВД Крыма

рассмотрев следственный материал по делу № ... и приняв во внимание, что гр. ИБРАГИМОВ ГАЛИМЗЯН 1887 г. рож. сын муллы урож. дер. Султан-Муратово Стерли...
по професии писатель, т...

достаточно изобличается в т...
листической группе, так ...
а в 1925 г. с определен...
троцкистско-националис...
го из руководителей в п...
контр. революционную раб...
в преступлении предусмот...



ПОСТАНОВИЛ:
гр. ИБРАГИМОВА ГАЛИМЬЗЯНА привлечь в качестве обвиняемого по ст. ст. 58-10 ч. 1 и 58-11 УК, мерой пресечения способов уклонения от следствия и суда избрать содержание под стражей при Симферопольской тюрьме по 2-й категории для дальнейшего этапирования спец конвоем в гор. Казань.

П/О Уполномоченный 4 отдела УГБ НКВД ТАССР (подпись)

«СОГЛАСЕН» Нач. Отделения

Настоящее постановление мне об'явлено « » 193 г.
Подпись обвиняемого



"УТВЕРЖДАЮ":

НАЧАЛЬНИК 4 отдела УГБ НКВД ТР
Капитан Гос.Безопасн.- (ВЕВЕРС)

"21" октября 1937 года.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

1937 года, октября 21 дня. Я, вриц.Нач.1 от-ния 4 отдела УГБ НКВД ТР - Лейтенант Г/Б. ГРИШЕЧКИН, рассмотрев следдело № 3389 на ИБРАГИМОВА Галимджана, содержащегося под стражей в Казанской тюрьме № 1 и принимая во внимание, что в интересах следствия содержание ИБРАГИМОВА под стражей будет целесообразным во внутреннем изоляторе НКВД ТР, а поэтому -

ПОСТАНОВИЛ:

ИБРАГИМОВА Галимджана для дальнейшего содержания под стражей из Казанской тюрьмы № 1 перевести во внутренний изолятор НКВД ТР.

Копию настоящего постановления для исполнения направить Коменданту НКВД ТР и Нач.Казанской тюрьмы № 1.

Врид.Нач.1 от-ния 4отд.УГБ
Лейтенант г/б (ГРИШЕЧКИН)



Акт № 3

от 21/I-1938 г. Мы нижеподписавшиеся врач Олз Маврина, лекпом Байкеев и старший надзиратель Петров, составили настоящий акт в том, что [illegible] Ибрагимов Галимзян 50 лет, прибывший из Казанской тюрьмы № 1 21/X 37 г. — умер 21/I 38 г. от туберкулеза легких и туберкулезного плеврита.

КАЗАНСКАЯ ТЮРЬМА № 1

бе-2. 206 219

ВЫПИСКА ИЗ ПОСТАНОВЛЕНИЯ

Следственного отдела КГБ при СМ ТАССР от 24/IX-1955г.

## П О С Т А Н О В Л Е Н И Е

24 сентября 1955 года, гор.Казань.

Зам.начальника следственного отдела КГБ при СМ ТАССР майор АМИНОВ,рассмотрев материалы архивно-следственного дела № 19816 по обвинению ИБРАГИМОВА Галимзяна Гирфановича, 1887 года рождения,урож.дер.Султан Муратово,Стерлитамакского района,БАССР, по профессии писателя,к моменту ареста лечившегося в гор.Ялте и материалы дополнительной проверки по настоящему делу,

Н А Ш Е Л:

ИБРАГИМОВ Г.Г. арестован 29 августа 1937 года НКВД ТАССР в гор.Ялте и этапирован в гор.Казань.

Находясь в заключении,ИБРАГИМОВ Г.Г. 21 января 1938г. умер, поэтому в июне 1938 года настоящее дело производством было прекращено.

Учитывая,что в процессе дополнительной проверки никаких объективных данных о принадлежности ИБРАГИМОВА к антисоветской организации и проведении им вражеской деятельност не установлено,руководствуясь ст.4 п.5 УПК РСФСР,

П О С Т А Н О В И Л:

Следственное производство по настоящему делу прекратить за отсутствием в действиях ИБРАГИМОВА состава преступления.

Копию настоящего постановления направить Прокурору Татарской АССР.

ЗАМ НАЧ.СЛЕДОТДЕЛА КГБ при СМ
ТАССР - майор
( АМИНОВ )

" УТВЕРЖДАЮ "

ПРЕДСЕДАТЕЛЬ КГБ при СМ ТАССР
П о л к о в н и к
( СЕМЕНОВ )
24 сентября 1955 года.

Выписка верна: СОТРУДНИК ОТД.КГБ
Кузьмин
( КУЗЬМИН )

"21" мая 1962 года.

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ – ДОКУМЕНТЛАРДА

## 1 том

Автобиографияләре, әдәби әсәрләреннән,
гыйльми хезмәтләреннән үрнәкләр, совет чорына кадәрге
һәм совет чоры документлары

Казан
«Җыен» нәшрияты
2020

ББК 83.3(2Рос=Тат)
И13

*Редколлегия:*
Р. И. Вәлиев, М. Б. Галиев, Х. Й. Миңнегулов, И. Г. Һадиев,
Ф. М. Рәфыйков, Ф. Ш. Сафиуллин

*Фәнни мөхәррир:*
Җәүдәт Миңнуллин,
тарих фәннәре кандидаты

*Төзүче:*
Рәмил Исламов,
филология фәннәре докторы

*Бәяләүче:*
Хатыйп Миңнегулов,
филология фәннәре докторы, профессор

И13 **Галимҗан Ибраһимов – документларда: 2 томда** / Төзүче: Р. Ф. Исламов, филология фәннәре докторы. – Казан: Җыен, 2020. – 1 т.: Автобиографияләре, әдәби әсәрләреннән, гыйльми хезмәтләреннән үрнәкләр, совет чорына кадәрге һәм совет чоры документлары. – 688 б. («Шәхесләребез» сериясендә)
ISBN 978-5-902783-48-0

Ике томлы хезмәтнең беренче томына татар әдәбияты классигы, галим, педагог, публицист, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Хезмәт Батыры Г. Ибраһимовның (1887–1938) автобиографияләре, кайбер әдәби әсәрләреннән һәм гыйльми хезмәтләреннән үрнәкләр; совет чорына кадәрге документлар (жандармерия, Учредительный собраниегә сайлау документлары, хатлар, белдерүләр, мөрәҗәгатьләр, хәбәрләр, автографлар, котлаулар); совет чоры документлары (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Гыйльми үзәк документлары), хәбәрләр, белдерүләр тупланды. Биредә урын алган документларның күбесе беренче мәртәбә һәм оригиналда китерелә.

Китап әдипнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүче киң гавамга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-902783-48-0

© «Җыен» фонды, 2020
© Р. Ф. Исламов, төзү, 2020

## Галимҗан Ибраһимов — документларда: өйрәнелү тарихы

I

Галимҗан Ибраһимов хакында документлар, аерым алганда аның хатлары, көндәлек матбугат битләрендә үзе исән вакытта ук дөнья күрә башлый. Язучы һәм әдәбият галиме Гомәр Толымбай (1900–1939) «Кызыл Татарстан» газетасының 1927 елгы 4 декабрь[1], «Безнең юл» журналының 1927 елгы 12 нче[2] саннарында әдипнең Ялтадан язган кайбер хатларын бастыра. Аларда язучының егерме еллык хезмәт юбилеена бәйле мәсьәләләр күтәрелә.

Уфада татар телендә нәшер ителгән «Коммуна» (хәзерге «Кызыл таң») газетасының 1933 елгы 22 октябрь санында Г. Ибраһимовның Башкортстан педагогия институты тел-әдәбият бүлегенең өченче курс студентлары Афзал Кудаш (1912–1981), Зәйнәп Зөбәирова (1905–1980), Зәкиҗан Локмановларга (1912–1959) юллаган хаты «Кайбер әдәби мәсьәләләр» исеме белән дөнья күрә[3].

Әдипнең тормышы һәм иҗаты турында сакланып калган документларны системалы итеп туплау эше ул акланганнан соң башлана[4]. «Совет әдәбияты» журналы редакциясе 1956 елда аның

---

[1] Толымбайский Г. Галимҗан Ибраһимовның хатыннан (Карт марксис[т] әдибебез Галимҗан иптәш Ибраһимов юбәләйе мәсьәләсе күтәрелгәч миңа язган хатыннан) / Г. Толымбайский // Кызыл Татарстан.– 1927.– 4 дек.

[2] Толымбайский Г. Галимҗан Ибраһимовның хатыннан / Г. Толымбайский // Безнең юл.– 1927.– № 12.– Б. 32–33.

[3] İbrahimof Ƣ. Qajber ədəbi məs’ələlər (Başqrtstan pedagogiə institutь 3 nce kurьs tel-ədəbiat bylege studentlarь ismennən Loqmanof, Zөbəjerova həm Əfzal Qudaşoflar tarafnnan jazlƣan xatqa çəvap) / Ƣ. İbrahimof // Kommuna.– 1933.– 22 okt.

[4] Г. Ибраһимовны аклау эшенең ничек башлануы хакында тулырак кара: Еники Ә. Әдипнең терелеп кайтуы / Ә. Еники // Казан утлары.– 1966.– № 11.– Б. 100–111.

1930–1935 елларда язучы Кави Нәҗмигә (1901–1957), шагыйрь Әхмәт Ерикәйгә (1902–1967), язучы һәм тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмовага (1901–1978) язган унбер хатын һәм бер телеграммасын бастыра[1].

Журнал редакциясе, алга таба да бу юнәлештә эшне максатчан дәвам иттереп, 1957 елда әдипнең тууына 70 ел тулу уңае белән, аның 1913–1932 елларда язучылар Хөсни Кәримгә (1887–1965), Фатыйх Әмирханга (1886–1926), шагыйрь Мәҗит Гафурига (1880–1934) язган хатларын бастырып чыгара[2].

«Совет Татарстаны» газетасының 1957 елгы 12 март санында[3], «Совет әдәбияты» журналының шул ук елгы 3 нче санында[4], «Язучылык хезмәте турында»[5] дигән китапта Г. Ибраһимовның Башпедвуз студентларына язган мәгълүм хаты кыскартылып урнаштырыла.

Әйтелгән хатлар шул ук елда Х. Хөсәенова тәрҗемәсендә һәм язучы Афзал Шамов (1901–1990) шәрехләре белән «Дружба народов» журналының 5 нче санында рус телендә дөнья күрә[6].

Узган гасырның 60 нчы елларында, Г. Ибраһимовның тууына 75 ел тулган вакытта, аның иҗат мирасын барлау, туплау өчен Татарстан Язучылар берлеге каршында А. Шамов рәислегендә махсус комиссия төзелә. Бу хакта «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында шулай диелә: «Г. Ибраһимовның хатлары, төрле эшләр буенча язган запискалары, аның әдәби-иҗтимагый эшләрен характерлый торган документлар һәм әдип турындагы истәлекләр бер үзәккә тупланырга тиеш. Шуңа күрә без кулларында Г. Ибраһимовның кулъязмалары, хатлары, запискалары, рәсемнәре һәм аңа бәйләнешле башка документлар булган кешеләрнең андый әйберләрне һәм үзләренең әдип турындагы истәлекләрен язучының әдәби мирасы комиссиясенә җибәрүләрен яисә бу турыда комиссиягә хәбәр итүләрен үтенәбез (Комиссиянең председателе язучы Афзал Шамов).

[1] Галимҗан Ибраһимов хатлары // Совет әдәбияты.– 1956.– № 10.– Б. 75–78.

[2] Ибраһимов хатлары // Совет әдәбияты.– 1957.– № 3.– Б. 49–62.

[3] Кайбер әдәби мәсьәләләр // Совет Татарстаны.– 1957.– 12 март.

[4] Ибраһимов хатлары // Совет әдәбияты.– 1957.– № 3.– Б. 49–62.

[5] Ибраһимов Г. Кайбер әдәби мәсьәләләр / Г. Ибраһимов // Язучылык хезмәте турында / Төзүчесе Зәки Нури.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.– Б. 121–125.

[6] Галимджан Ибрагимов. Письма к друзьям // Дружба народов.– 1957.– № 5.– С. 170–179.

Комиссиянең адресы: Казань, Баумана, 19, Дом печати, Союз писателей Татарии, Шамову Афзалу»[1].

Журналның шул ук санында Г. Ибраһимовның 1914–1936 елларда Х. Кәримгә, Зәйнәп Кәримовага (Х. Кәримнең хатыны; 1909–1995), язучы, драматург, тәрҗемәче, нашир Әхмәтгәрәй Хәсәнигә (1883–1933), журналист, партия һәм җәмәгать эшлеклесе Газыйм Касыймовка (1891–1941), М. Гафурига, К. Нәҗмигә һәм С. Әдһәмовага, туганнан туган кардәше (әтиләре Гыйрфан белән Вилдан бертуган) Мохтар Ибраһимовка (1885–1969), журналист һәм ул чакта «Коммуна» газетасының баш мөхәррире Мөхәммәт Бикбулатовка (1899–1961), Татарстан совет Язучылары берлегенә язган 21 хаты А. Шамов тарафыннан әзерләнеп бастырыла[2].

«Социалистик Татарстан» газетасы 1962 елгы 14 март санында Г. Ибраһимовның 1922 елның 2 августында Г. Касыймовка язган хаты дөнья күрә[3]. Хатны башкорт теленә тәрҗемә итеп «Ағиҙел» журналының 1962 елгы 5 нче санында бастырган әдәбиятчы А. Кудаш газетада бирелгән текстта кайбер хаталар, шәрехләрдә төгәлсезлекләр булуын күрсәтә[4].

«Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 9 нчы санында Г. Ибраһимов белән Кәрим Тинчурин (1887–1938) 1936 елда бер-берсенә язган ике хат басылып чыга[5]. Аларның ул вакытта К. Тинчуринның хатыны Заһидә Тинчуринада (1877–1988) саклануылары хакында хәбәр ителә.

Редакция 1963 елда Г. Ибраһимовның вафатына 25 ел тулу уңаеннан янә укучыларга мөрәҗәгать итеп, әдипнең мирасын туплау юнәлешендә махсус комиссия белән элемтәдә булып эш итәргә чакыра. Шул ук санда язучының 1913–1932 елларда педагог, нашир һәм язучы, журналист Фатыйх Кәримигә (1870–1943), М. Гафурига, партия эшлеклесе Сибгатулла Гафуровка (1888–1938), Татарстан Республикасы Мәгариф халык комиссариатына, М. Бикбулатовка язган хатлары, М. Ибраһимовка автографы, М. Ибраһимовның «Туганым турында», педагог Хәбиб

---

[1] Язучы, галим һәм көрәшче // Совет әдәбияты.– 1962.– № 3.– Б. 92.

[2] Язучы, галим һәм көрәшче…– Б. 95–108.

[3] Хатлардан // Соц. Татарстан.– 1962.– 14 март.

[4] Ҡудаш А. Ғалимьян Ибраһимовтың яңы табылған хаты / А. Ҡудаш // Ағиҙел.– 1962.– № 5.– Б. 79.

[5] Галимҗан Ибраһимов белән Кәрим Тинчурин хатлары // Совет әдәбияты.– 1962.– № 9.– Б. 135–136.

Зәйнинең (1890–1967) «Кайбер хатирәләр», педагог һәм журналист Каюм Мостакаевның (1885–1974) «Галимҗан Ибраһимов Киевтә», нәшрият эшчесе Батыр Гозәеровның (1896–1983) «Хәтердә калганнар» дигән истәлекләре А. Шамов тарафыннан әзерләнеп бастырыла[1].

ТАССР Үзәк дәүләт архивының өлкән фәнни хезмәткәре Н. Таҗетдиновның 1964 елда дөнья күргән мәкаләсе Г. Ибраһимовка бәйле матбугаттагы язмаларга, Татарстан Үзәк дәүләт, КПСС Өлкә комитеты партархивларында саклангән, Казан, Киев губерна жандармерия идарәсе документларына багышланган[2].

1965 елда «Социалистик Татарстан» газетасы Г. Ибраһимовның 1933 елда ВКП(б) Үзәк Комитетында эшләгән әдәбият галиме, тәнкыйтьче Валерий Кирпотинга (1898–1997), Совет Язучылары берлеген оештыру комитетында эшләгән язучы А. А. Фалевка (1901–1956), Дәүләт матур әдәбият нәшрияты хезмәткәре Николай Накоряковка (1881–1970), сәркятип Александра Рябининага (1897–1977)[3] язган хатларын татар теленә тәрҗемә итеп бастыра[4].

Әдәбият белгече Нил Юзиев (1931–1996) 1965 елда Мәскәүдә әдәбият һәм сәнгать Үзәк дәүләт архивында Г. Ибраһимовның 1932–1936 елларда Дәүләт матур әдәбият нәшрияты директоры Н. Накоряковка, оешма идарәсенә, хезмәткәрләре Ә. Ерикәйгә, Б. Чернякка (1898–1955), А. Рябининага, Е. Мозольковка (1909–1969), Әсәдуллаевка язган хатларын, телеграммаларын табып ала һәм аларны татар теленә тәрҗемә итеп, искәрмәләр белән «Казан утлары» журналының 7 нче санында бастырып чыгара[5].

1966 елда әдәбиятчы Октябрь Кадыйров матбугатта Г. Ибраһимовның 1915 елда «Гасыр» нәшрияты хуҗасы, «Аң» журналының нашире һәм мөхәррире Ә. Хәсәнигә язган хатын искәрмәләр һәм аңлатмалар белән бастырып чыгара[6]. Хат исә

---

[1] Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр, хатлар (Үлүенә 25 ел тулуы уңае белән) // Совет әдәбияты.– 1963.– № 1.– Б. 107–136.

[2] Таҗетдинов Н. Галимҗан Ибраһимов жандарм күзәтүе астында / Н. Таҗетдинов // Совет әдәбияты.– 1964.– № 11.– Б. 122–126.

[3] Соңыннан редакция җитәкчесе була.

[4] Галимҗан Ибраһимов хаты // Соц. Татарстан.– 1965.– 4 июль.

[5] Галимҗан Ибраһимов. Нәшриятка хатлар // Казан утлары.– 1965.– № 7.– Б. 133–143.

[6] Галимҗан Ибраһимовның яңа табылган хаты // Казан утлары.– 1966.– № 12.– Б. 124–125.

адресатның хатыны, әйтелгән басманың җаваплы сәркятибе булып эшләгән Зәйнәп Хәсәниядә (1887–1967) саклanган.

Уфа губерна жандарм идарәсенең Г. Ибраһимовка бәйле документларның Башкортстан Үзәк Дәүләт архивында саклanган кайберләре әдәбият галиме Үзбәк Гыймадиев (1920–1987) мәкаләсендә чагылыш тапкан[1]. Алар галимнең икенче хезмәтендә дә урын алган[2].

А. Шамов әдипнең үзе тарафыннан 1929 елда рус телендә язган һәм ул вакытта КПССның Татарстан Өлкә комитеты партия архивында саклanган автобиографиясен татар теленә тәрҗемә итеп, искәрмәләр, аңлатмалар белән 1967 елда «Казан утлары» журналында бастырып чыгара[3].

Г. Ибраһимов хакында истәлекләр шулай ук әдипнең тормышын, иҗат мирасын өйрәнүдә кыйммәтле чыганак булып тора. Чөнки аларда тарихи документларны дәлилли яки дөресли, кайбер билгеле булмаган фактлар искә алынган мәгълүмат табарга мөмкин. Матбугатта дөнья күргән аерым истәлекләр хакында бераз әйтелгән иде. Шулай да аларның иң элгәргеләреннән берсе, ягъни М. Бикбулатов тарафыннан «Әҙәби Башҡортостан» журналында 1957 елда басылуын[4] искә төшереп үтү урынлы булыр. Аннан соң Б. Гозәеров[5], Гайшә Шәрипова (1906–1966)[6], З. Кәримова[7] тарафыннан укучыларга җиткерелгән истәлекләр дә бу юнәлештә зур кызыксыну уята.

Тарихчылар Риф Хәйретдинов (1935–2007), Миркасыйм Госманов (1934–2010), язучылар А. Шамов, С. Әдһәмова, филолог Гөлчәчәк Әдһәмова (1927–2016) 1967 елда матбугатта Г. Ибра-

[1] Ғимаҙиев Ү. Ғалимйән Ибраһимов жандарм күҙәтеүе аҫтында (Ғалимйән Ибраһимовтың тыуыуына 80 йыл тулыу алдынан) / Ү. Ғимаҙиев // Ағиҙел.– 1966.– № 12.– Б. 72–75.

[2] Ғимаҙиев Ү. Талант һәм хеҙмәт: (Ғалимьян Ибраһимов ижады тураһында әҙәби-публицистик мәҡәләләр) / Ү. Ғимаҙиев.– Өфө: Башҡорт. кит. нәшр., 1982.– Б. 20–29.

[3] Галимҗан Ибраһимов. Автобиография // Казан утлары.– 1967.– № 2.– Б. 4–26.

[4] Бикбулат М. Ғәлимьян Ибраһимов. Иҫтә ҡалғандарҙан / М. Бикбулат // Әҙәби Башҡортостан.– 1957.– № 7.– Б. 57–63.

[5] Ғөзәиров Б. Хәтерҙә ҡалғандарҙан / Б. Ғөзәиров // Ағиҙел.– 1961.– № 7.– Б. 74–76.

[6] Шәрипова Г. Көндәлек битләреннән / Г. Шәрипова // Казан утлары.– 1967.– № 3.– Б. 129–131.

[7] Кәримова З. Ул безнең якын дустыбыз иде / З. Кәримова // Казан утлары.– 1967.– № 3.– Б. 134–141.

һимовның Әстерхан хәрби мөселман комиссариатына, Милләтләр эше буенча Халык комиссариатына, Үзәк Татар-Башкорт комиссариатына, Үзәк Бюрога җибәргән телеграммаларын, тарихчы, филолог, шәркыятьче, академик Василий Бартольдка (1869–1930), журналист, халык мәгарифе эшлеклесе Габдулла Гыйсмәтигә (1883–1938), әдәбият белгече Пётр Коганга (1872–1932), К. Нәҗмигә, кырымтатар телендә нәшер ителгән «Большевик ёлы» журналының редколлегия әгъзасы Якуп Мусанифка (1900–1937) язган хатларын бастырып чыгаралар[1].

Әдипнең икенче хатыны Гөлсем Мөхәммәдованың (1903–1988)[2] 1972 елда «Казан утлары» журналында «Киев вакыйгасы» дигән күләмле мәкаләсе дөнья күрә[3]. Ул тулысы белән архив материалларына нигезләнеп язылган һәм Г. Ибраһимовның Киевтә яшәгән чорына бәйле шактый мәсьәләләр ачыкланган.

1975 елда Г. Шәрипованың[4] кызы Асия Поцелуйко әнисенең шәхси архивында сакланып калган Г. Ибраһимовның хатларын, телеграммасын, ике фотосын, бер килешү кәгазен һәм «Безнең көннәр» романының автор кулы белән төзәтелгән ике нөсхәсен Татар дәүләт (хәзерге Татарстан Республикасы Милли) музеена тапшыра. Шулардан егерме алты хат һәм ике телеграмма әдәбият галиме Мансур Хәсәнов (1930–2010) һәм тел белгече Искәндәр Абдуллин (1935–1992) тарафыннан «Казан утлары» журналының 12 нче санында бастырылган[5].

---

[1] Әдипнең телеграммалары, яңа хатлары // Казан утлары.– 1967.– № 3.– Б. 142–145.

[2] *Әдипнең икенче хатыны Гөлсем Мөхәммәдованың (1903–1988)* – Өммегөлсем Давыт кызы Мөхәммәдова, әдип белән 1924–1933 елларда яши. Ә беренче хатыны Мәстүрә Гыйльман кызы Фәйзуллина (? – 1978) булганлыгын әйтеп үтү дә урынлы булыр. Алар 1919 елларда өйләнешкәннәр. М. Фәйзуллина партия һәм хөкүмәт органнарында эшләгән, соңыннан шәхес культы газапларын кичергән. Тарих фәннәре кандидаты Тәэминә Биктимирова эзләнүләреннән күренгәнчә, аның партия билетында фамилиясе Ибраһимова булып язылган.

[3] Мөхәммәдова Г. Киев вакыйгасы / Г. Мөхәммәдова // Казан утлары.– 1972.– № 8.– Б. 133–151.

[4] *Г. Шәрипова* – Гайшә Габделхәмит кызы Шәрипова (1906–1966), тәрҗемәче, 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, язучы, «Семья Гафура» романы авторы; драматург, публицист Гафур Коләхмәтовның (1881–1918) бертуган апасы Шәмсекамәр (1880–1936) һәм аның ире Габделхәмитнең (? – 1936) кызы.

[5] Хәсәнов М., Абдуллин И. Әдипнең яңа табылган хатлары / М. Хәсәнов, И. Абдуллин // Казан утлары.– 1976.– № 12.– Б. 137–149.

И. Абдуллин соңыннан Алматы шәһәренә эш сәфәре белән баргач, Казакъстан Дәүләт архивында Г. Ибраһимовның Г. Шәриповага язган янә бер хатын табып ала һәм аны матбугатта игълан итә[1].

Г. Ибраһимовның тууына 100 тулу уңае белән Г. Мөхәммәдова әдипнең 1918 елда Ленинга язган хатын[2], А. Шамов Киев жандармерия документларын, укытучы Вәсфи Гыйльмияровка (1893–1978) һәм Ташкентта «Белем йорты»нда ачылган татар бүлегендә укучы яшьләргә автографларын, Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинатына, РКП(б)ның Татарстан Өлкә комитетына, Гәжур[3] мөдире Сәлах (Сәлахетдин) Атнагуловка (1893–1938), ВКП(б) әгъзаларын һәм кандидатларын тикшерү Үзәк комиссиясенә, К. Нәҗмигә, Татарстан республикасы Өлкә контроль комиссиясенә, ВКП(б) Үзәк контроль комиссиясенә, Татарстан Өлкә комитеты секретариатына Абдуллинга[4], ВКП(б) Үзәк Комитетының Татарстандагы вәкаләтле вәкиле янындагы партколлегиягә[5]; әдәбиятчы Фатыйма Ибраһимова (1928–2016) әдипнең педагог, журналист Хәлим Искәндәровка (1888–1958) һәм Татарстан Мәгариф халык комиссары Мөхәммәт Таһировка (1895–1929)[6] язган хатларын әзерләп бастыралар; Марсель Әхмәтҗанов язучының Газиз Гобәйдуллинга автограф белән бүләк иткән «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (Казан, 1922) дигән китабы табылуы хакында яза[7].

---

[1] Абдуллин И. Әдипнең тагын бер хаты / И. Абдуллин // Казан утлары.– 1977.– № 3.– Б. 162–163.

[2] Мөхәммәдова Г. Г. Ибраһимовның В. И. Ленин белән очрашуына бәйле документлар / Г. Мөхәммәдова // Казан утлары.– 1987.– № 3.– Б. 64.

[3] *Гәжур* – 1925 елның 25 сентябрендә Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты каршында ачылган газета-журнал нәшрияты. 1925–1927 елларда Татарстанда барлык газета-журналларны әзерләп бастыру шушы нәшрият аша үтә. 1927 елның 7 мартында Татгиз составыннан К. Якуб исемендәге полиграфия комбинаты чыгарылып, Гәжур аңа кушыла һәм Татиздат дип атала башлый.

[4] *Абдуллинга* – Бари Абдулла улы Абдуллин (1899–1937), дәүләт эшлеклесе; ул вакытта ВКП(б)ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре була. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[5] Кадерле ядкарьләр. Галимҗан Ибраһимов биографиясенә материаллар // Казан утлары.– 1987.– № 3.– Б. 66–77.

[6] Г. Ибраһимовның яңа табылган хатлары // Казан утлары.– 1987.– № 3.– Б. 78–80.

[7] Әхмәтҗанов М. Галимҗан Ибраһимовның автографлы китабы / М. Әхмәтҗанов // Казан утлары.– 1987.– № 3.– Б. 81.

Ф. Ибраһимова 1990 елда нәшер ителгән «Язучы биографиясенә яңа чыганаклар» дигән җыентыкта Г. Ибраһимовның ул вакытта Казан университетының медицина факультеты студенты Хәнәфи (Мөхәммәтхәнәфи) Кайбышевка (1890–?)[1], ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты секретаре Иван Морозовка (1888–1957) һәм пропаганда бүлеге мөдире Миңлегәрәй Сәгыйдуллинга (1900–1937), М. Таһировка язган хатларын бай шәрехләмәләр белән бастыра[2].

Г. Ибраһимовның хатлары турында күп кенә истәлекләрдә дә телгә алына. Мәсәлән, әдипнең бертуган энесе Хәкимҗан (1895–1957) абзыйсыннан тиз арада Ялтага килеп җитүен үтенгән хат алуын яза. Бу аның өченче хатыны Хәдичә Әпсәләмова-Фәткуллина (1893–1967)[3] белән яши башлаган вакыты була. Соңыннан ул Хәдичә белән 1949 елга кадәр хат алышып торганлыгын да белдерә[4].

Педагог Каюм Мостакаев (1885–1974) Г. Ибраһимов белән хатлар алышып торуы хакында болай ди: «1911 елның азагына таба җибәргән хатларында Галимҗан үзенең «Яшь йөрәкләр» романы өстендә эшләвен һәм аны якын арада тәмам итеп, Орскийның китап сәүдәгәре Әхмәт Исхакыйга биреп бастыру уенда икәнен, аның белән инде бу хакта килешкәнлеген яза иде»[5]. Ул 1912 елда Киевтә укытучылык урыны барлыгын белдереп аңа хат яза. Г. Ибраһимов җавап хатында юл чыгымнарыннан тыш, өс-баш киемнәре алуны да истә тотып янә акча җибәрүен үтенә.

---

[1] Аның «Теоретик» дигән кушамат белән яшертен рәвештә жандармериядә хезмәттә булганлыгы ачыклана.

[2] Ибраһимова Ф. Галимҗан Ибраһимовның берничә хаты / Ф. Ибраһимова // Язучы биографиясенә яңа чыганаклар / Редколлегия: Ә. Х. Алиева (төзүче), З. З. Рәмиев, Н. Г. Юзиев (җаваплы редактор). – Казан, 1990. – Б. 48–62.

[3] *... өченче хатыны Хәдичә Әпсәләмова-Фәткуллина (1893–1967)* – Хәдичә Мөхәммәт кызы Әпсәләмова-Фәткуллина, әдипнең 1924–1933 елларда икенче хатыны булган Өммегөлсем Мөхәммәдова ташлап киткәннән соң, 1934 елның 12 мартыннан рәсми язылышта 1937 елга, ягъни язучы кулга алынганга кадәр Г. Ибраһимов белән яши.

[4] 1957 елның 13 мартында Г. Ибраһимовның туганнары Шакирҗан һәм Хәким Ибраһимовлар белән үткәрелгән беседаның стенограммасы (татар телендә) // Галимҗан Ибраһимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / Автор-составитель М. Х. Ибрагимов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 170–171.

[5] Мостакаев К. Киевта / К. Мостакаев // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төзүчесе Рөстәм Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Б. 78.

Г. Ибраһимов, Киев төрмәсеннән чыгарылып, Казанга кайткач та, К. Мостакаевка хат язып торган. Шуларның берсендә ул болай дип белдерә: «Каюм, Киевтагы хәятымның шулай очлануына аз гына да кайгырмыйм. Андагы эшләр, утырып чыгу минем өчен бер мәктәп булды. Дөресен әйткәндә, файдалы мәктәп. Күзем ачыла төште. Күп нәрсәне һәм кешеләрне дөресрәк күрә, дөресрәк таный башладым...»[1].

Журналист Сәгыйть Фәйзуллин (1899–1975) үзенең истәлегендә Г. Ибраһимовның философия буенча яңарак чыккан бер китапны Ялтада таба алмавыннан зарланып, кайтышлый Мәскәүдән яки Казаннан шул китапны табып җибәрүне үтенүен, китапны алгач, рәхмәт әйтеп хат күндерүен яза[2].

Әдәбият белгече Җамал Вәзиева (1907–1989) шундый фактны китерә: «Кырымга барып урнашкач, Насыйх абыйларга озын һәм тәфсилләп язылган хатлары килде. Хат Гөлсем апа кулы белән язылган иде. Без аны җыелышып укыдык. Аннан Галимҗан абыйның хәле һаман да авыр икәнлеге аңлашылды»[3].

Ул вакытларда Җ. Вәзиева доцент Насыйх Мөхетдиновның (1892–1937 яки 1943) сәркятибе булып эшли. Алар Г. Ибраһимов белән хәзерге Мөштәри урамындагы (элекке Комлев урамы, 33 нче йорт) йортта яшиләр.

Г. Ибраһимовның Оренбургта мәдрәсә шәриге, журналист, җәмәгать эшлеклесе Шәһит Әхмәдиев (1888–1930) истәлегендә китерелгәнчә, әдип аңарга Гульрипшидан 1926 елның 29 ноябрендә язган хатында шундый юллар бар: «Беләсең, Шәһит, без синең белән 12 яшьтән, Оренбургта яланаяк чабучы малай чактан башлап хәзергәчә күп план кордык. Моның байтагы тормышта гамәлгә дә куелды инде. Ләкин бөтенесен тәмамлау безгә насыйп булмас. Алдагы буын, бәлки, безнең балалар, үзебез уйлап та ирешә алмаганнарны тормышта чынлап күрерләр. Шул өметләр эченнән карап, мин балага бик шатландым...[4]

---

[1] Мостакаев К. Киевта... – Б. 87.

[2] Фәйзуллин С. Юл күрсәтүчем / С. Фәйзуллин // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төзүчесе Рөстәм Акъегет.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.– Б. 248.

[3] Вәзиева Җ. Зур язучы турында кечкенә хатирә / Җ. Вәзиева // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төзүчесе Рөстәм Акъегет.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.– Б. 264.

[4] *... мин балага бик шатландым...* – Г. Ибраһимов Гульрипшида вакытта 1926 елның 5 ноябрендә улы Рөстәм туа. Сүз шул хакта бара.

Минем авыру шундый инде. Даими сакланырга, даими дәваланырга кирәк. Шулай иткәндә бераз, бәлки, гомер итеп булыр. Ләкин, туган, шулай да иртә ватты мине дөнья... Гадәттән тыш авыр көрәшләр минем ун еллар буенча бертуктаусыз бара. Шул ватмый хәле дә юк. Адәм гомере шулай инде: дөньяга килсәң, планның бер өлешен үтисең, тәмамлауны башкаларга тапшырып китәсең. Шулай да, Шәһит, акрынлык белән булса да, бер егерме ел гомер кирәк әле. Саклансак, моңа да ирешербез»[1].

Шагыйрь Максуд Сөндекле (1904–1981) 1930 елларда Донбасста эшләгән вакытында Г. Ибраһимов белән хатлар алышып торган. Әмма ул аларны саклап кала алмавына тирән борчылу белдереп болай ди: «Ләкин, зур үкенечкә каршы, 1937–1938 елларның хәвеф-хәтәрле көннәрендә кулымдагы кыйммәтле тарихи хатларны котырган күзләрдән ераграк яшереп кала белмәдем»[2]. Шулай да аның истәлегендә Г. Ибраһимов хатларыннан китергән өзекләрдә әдипнең шул вакытларда эшчеләр арасыннан әдәбиятка килүчеләр турында кызыклы фикерләре чагылыш тапкан: «Беркөнне минем исемгә әдиптән бик озын латин алфавиты белән язылган хат килеп төште. Галимҗан ага бу хатында, эшче ударникларны әдәбиятка чакыруның тарихи әһәмиятен аңлатып, безгә кыйммәтле киңәшләр бирде. Ул бу озын хатында: «Әдәбият бик җаваплы, нечкә һөнәр, ашыкмагыз, әдәбият түгәрәге оештырып, әсәрләрегезне бергәләп тикшерегез. Әдәбият теориясен өйрәнегез, укуны, өйрәнүне беренче планга куегыз»,– дип язган иде.

Икенче хатында Галимҗан ага безнең кайбер очерк, шигырьләрне чамалап кына мактап та җибәргән иде. Янәсе, шундый шәп әсәрләрне без генә – Донбасс шахталарында эшләп чыныккан кешеләр генә яза алабыз. Бу хатта ул: «Сез киләчәктә эшчеләр тормышыннан һәйбәт әсәрләр бирә алачаксыз»,– дигән иде. Шушы ук хатында: «Хәзергә Донбасс миңа иң якын, зур юл мәшәкате таләп итмәгән өлкәләрнең берсе. Насыйп булса, Донбасска барып сезнең белән очрашырга ниятем бар әле»,– дип язды. Ләкин авыру әдип Донбасс эшчеләре белән очрашырга

[1] Әхмәдиев Ш. Якын иптәш / Ш. Әхмәдиев // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төзүчесе Рөстәм Акъегет.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.– Б. 267–268.

[2] Сөндекле М. Яшьләрнең бөек остазы / М. Сөндекле // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төзүчесе Рөстәм Акъегет.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.– Б. 287.

булган теләген үти алмады. Безнең чакыруга җавап итеп язган хатында үзенең авыр кайгылы көннәр кичергәнен – бердәнбер баласы үлгәнлеген[1], шул сәбәпле сәламәтлегенең юлга чыгарга мөмкинлек бирмәве хакында хәбәр итте.

Донбасстагы бу әдәби хәрәкәтне берләштерү өчен Украинаның «Молодняк» дигән әдәби оешмасы янында татар секциясе төзелде. Галимҗан ага бу эшне бик мәгъкуль күреп, шатланып хат язды. Бу хатында: «Әсәрләрегезне җыентык итеп чыгарырга бик кирәк иде, Г. Галигә[2] мин язармын, бәләкәй булса да бер адым булыр, бу хакта секциядә уйлашыгыз әле»,– дигән иде».

1934 елда «Эшче»[3] газетасы мөхәррире иптәш Агишев, партиянең Үзәк Комитеты белән киңәшеп, мине Мәскәү янындагы күмер шахталарында эшләүче татар-башкорт шахтерлары өчен чыгачак «Мәскәү кочегаркасы»[4] дигән газетаның мөхәррире итеп җибәрде. Бу газетада эшләгән вакытта да мин Галимҗан ага Ибраһимов белән элемтәне өзмәдем. Ул миңа соңгы хатында Уфага яки Казанга күчеп, әдәбият осталары белән аралашып яшәргә, эшләргә, укырга киңәш биргән иде»[5].

Казакъ язучысы Сабит Муканов (1900–1973) Г. Ибраһимов белән хат алышып торганлыгын шулай искә ала: «Мин аңа, үземнең ихтирамымны белдереп, «Адашканнар» исемле романымны Кырым адресы белән җибәрдем һәм озакламыйча аңардан озын хат алдым»[6].

---

[1] *... бердәнбер баласы үлгәнлеген* – уллары Рөстәм 1931 елның 21 мартында йөрәк параличыннан вафат була.

[2] *Г. Гали* – Гомәр Гали (Гомр Билал улы Галиев, 1900–1954), язучы, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе. 1931 елдан Татарстан китап нәшриятының әдәби секторын, Татар пролетар язучылары ассоциациясен (ТАПП) җитәкли.

[3] *«Эшче»* – РКП(б)ның Үзәк һәм Казан комитетлары басма органы. 1918 елның 27 сентябреннән Казанда, шул ук елның 13 декабреннән Мәскәүдә, 1920 елның 2 февраленнән Казанда, 1921 елның 10 апреленнән 31 декабренә кадәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителгән. Барлыгы 2039 саны дөнья күрә.

[4] *«Мәскәү кочегаркасы»* – 1932 елның 16 сентябреннән 1933 елның 24 июненә кадәр Мәскәү өлкәсенең Донской эшчеләр посёлогында татар телендә нәшер ителгән атналык эшчеләр газетасы. ВКП(б)ның Мәскәү комитеты Мәскәү өлкәсе бюросы, күмер чыгаручылар профсоюзы өлкә комитеты һәм «Мәскәү-күмер» берләшмәсе басма органы. Барлыгы 38 саны дөнья күрә.

[5] Сөндекле М. Күрс. хезм.– Б. 287–289.

[6] Муканов С. Онытылмас хатирә / С. Муканов // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төзүчесе Рөстәм Акъегет.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.– Б. 336.

А. Шамов әдипнең күптомлыкларын чыгаруда катнашуы белән бәйле хатлашып торганлыгын болай тасвир итә: «Берничә көннән соң Галимҗан аганың миңа язган хаты килеп җитте. Чыннан да, ул миннән дүрт томлы «Сайланма әсәрләр»енә редактор булып, карап, бастырып чыгаруымны үтенгән иде.

Өченче том 1936 елның урталарында басылып чыкты. Матбугатка чыгу белән үк авторга иң яхшы кәгазьгә басылганнарын җибәрдек. Нәшриятка һәм миңа рәхмәт әйтеп язган хатында китапның басылышын, шулай ук тышкы күренешен ошатканлыгын әйткән иде»[1].

Язучы Мирсәй Әмир (1907—1980) үзенең истәлегендә Г. Ибраһимов хатыннан шундый өземтә китерә: «Агыйдел» повесте басылып чыккач (1936)[2], Г. Ибраһимов, мине зур иҗади уңышым белән котлап, үз исемемә махсус хат язып җибәрде. Ул анда повестьны бик ошатканлыгын әйткән, миңа яхшы теләкләр теләгән һәм искәрмә төсендә төп геройларымның берсенә Гаяз исеме бирүемне ошатмавын белдергән иде. Нигә шундый әйбәт образга әшәке кешенең исемен бирдең, дип сорау куйган иде. Һәм мөмкин булганда ул геройның исемен алыштырырга киңәш биргән иде (Ул, әлбәттә, үзенең килешмәс дошманы булган Гаяз Исхаковны[3] күздә тота иде). Мин аның бу сүзләре турында бик күп уйладым, шулай да героемның исемен алыштырырга кирәк тапмадым. Чөнки Гаяз исеме укучылар өчен бик табигый яңгырый, ул вакыттагы яшь буын Гаязны юньләп белми дә иде инде»[4].

Язучы Салих Баттал (1905—1995) Г. Ибраһимов белән хат алышуы хакында шулай искә ала: «Мин Гроховский «циркында» эшләгән чорда ул миңа ике мәртәбә хат җибәрде. Берсендә ул, берничә китап исемен атап, шуларны Мәскәү магазиннарыннан табып җибәрә алмассыңмы дип, яңалиф белән язган. Мин

[1] Шамов А. Күңелсез вакыйга / А. Шамов // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төзүчесе Рөстәм Акъегет.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.– Б. 339.

[2] Əmir M. Aƣidel (Artьqbikə). Ozьn xikəjə / M. Əmir.– Qazan: Tatgosizdat, 1936.– 258 b.

[3] *Гаяз Исхаков* – Гаяз Исхакый (Мөхәммәтгаяз Гыйләҗетдин улы Исхаков) (1878–1954), язучы, журналист, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе, татар милли-азатлык хәрәкәте лидерларыннан берсе.

[4] Әмир М. Гүзәл тойгылар уятучы әдип / М. Әмир // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төзүчесе Рөстәм Акъегет.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.– Б. 415.

ул китапларны таба алмадым. Икенче хатында ул: «Минем китапны син таныш кызларыңа укыткансың, бу бик кызык булды әле!» – дип язган иде.

Сүз аның русчага Шәрипова[1] тарафыннан тәрҗемә ителгән «Татарка» исемендә чыккан китабы турында бара[2]. Парашютчы кызлар миннән алып укыдылар да, аны бик яратып, зур эстетик ләззәт биргән өчен авторга рәхмәт язып, күмәк хат җибәрделәр»[3].

Г. Ибраһимовның туганы Марат Ибраһимов архив документларын туплап, әдип турында 2012 елда аерым китап бастырып чыгарды[4]. Анда аларның күбесенең фотокүчермәләре дә бирелгән. Шулай ук авторның үзенең карамагында булган материаллар да беренче мәртәбә анда урын алган.

Әдип хакында кайбер архив документлары соңгы елларда ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Академик үзәк хакында[5], «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар»[6] дигән җыентыкларда бастырылды.

Г. Ибраһимов турында материалларны эзләү һәм табылганнары белән көндәлек матбугатта укучыларга таныштыру юнәлешендә безнең тарафтан да берникадәр эш башкарылды. Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге мөдире булып эшләгән вакытымда, 2010 елның көз айларында, ме-

---

[1] *Шәрипова* – сүз Гайшә Шәрипова турында бара.

[2] Сүз аның русчага Г. Шәрипова тарафыннан тәрҗемә ителгән «Татарка» исемендә чыккан китабы турында бара: Ибрагимов Г. Татарка: Роман / Перевод с татарского Гайши Шариповой / Г. Ибрагимов.– М.: Гос. изд-во «Художественная литература», 1935.– 174 с.

[3] Баттал С. Г. Ибраһимов турында соңгы истәлекләр / С. Баттал // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төзүчесе Рөстәм Акъегет.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.– Б. 424–425.

[4] Галимҗан Ибраһимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / Автор-составитель М.Х. Ибрагимов.– Казань: Татар. кн. изд-во, 2012.– 336 с.

[5] Академический центр Наркомпроса ТАССР: документы и материалы / Составители: кандидат искусствоведения О.Л. Улемнова, Л.Ш. Давлетшина.– Казань: ИЯЛИ, 2015.– 224 с.

[6] Рухи мирас = Духовное наследие: поиски и открытия / Редколлегия: И.Г. Гумеров (руководитель проекта и ответственный редактор), М.И. Ахметзянов, З.З. Рамеев. Составители выпуска: Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова, Л.Ш. Давлетшина.– Казань: ИЯЛИ, 2017.– Вып. 3.– 336 с.

дицина фәннәре кандидаты Сәяр Әхмәров әдипнең медицина картасын тапшырган иде. Ул аны 1960 елларда Казанның Иске хастаханәсендә терапия кафедрасында ординатор чагында табып алган булган[1].

Максатчан эзләнүләребез нәтиҗәсендә Г. Ибраһимовның әлегә киң даирә укучыга билгеле булмаган автографлары да табылды[2]. Мәсәлән, аның яшь вакытта алдырган фотосының икенче ягына Киевтән 1913 елның март аенда язылган һәм бертуган Шакирҗан абзыйсына адресланган; әдип Уфада яшәгән вакытында алдырылган фотосының икенче ягына 1916 елның 20 декабрендә туганы Мотаһар Ибраһимовка (1893–1975) язылган; Колчак[3] тылыннан йөреп кайткач киемнәрен дә алыштырмый алдырылган фотосының икенче ягына яшьлек дусты, Солтанмораттан өч кенә чакрым ераклыктагы Әпсәләм авылы кешесе Габделәхмәт Сөләймановка (1885–1962) 1919 елның 3 сентябрендә язылганнары. Аларның төп нөсхәләре белән Казанда Әлфия апа Шамованың шәхси архивыннан таныштык.

«Тугры, гомуми, тигез, яшерен һәм мөтәнасиб сайлауга нигезләнгән Учредительный собрание» (Казан, 1917) дигән китапның 29 нчы битендә буш урында Г. Ибраһимов татар әдәбияты хадимнәренең Үзәк союзы рәисе буларак имза куйган. Ул чыганакны тарих фәннәре кандидаты, доцент Җәүдәт Миңнуллин (1953–2019) исән вакытында биреп торган иде.

Танылган археограф, тарихчы, шәхес культы корбаннарының берсе Сәидгаттар Вахидовка (Вахидига) (1887–1938) адресланган автограф Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» (М., 1924) дигән китабының титул битенә язылган. Төп нөсхәнең хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университеның Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәнең сирәк кулъязмалар һәм китаплар бүлегенең Шәрык бүлекчәсендә саклануын ачыкладык.

Г. Ибраһимовның «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясе исеменә адресланган автографы әдипнең «Татарлар арасында ре-

---

[1] Исламов Р. Әдипнең медицина картасы табылды / Р. Исламов // Мәд. җомга.– 2011.– 25 февр.; *Шул ук* // Кызыл таң.– 2011.– 11 март.

[2] Исламов Р. Әдипнең автографлары: Галимҗан Ибраһимовның тууына 130 ел тулуны каршылап / Р. Исламов // Кызыл таң.– 2917.– 9, 16 февр.; // Мәд. җомга.– 2017.– 17, 22 февр.; Исламов Р. Әдипнең яңа автографы / Р. Исламов // Мәд. җомга.– 2017.– 17 февр.

[3] *Колчак* – Александр Васильевич Колчак (1874–1920), адмирал (1917), революциягә каршы хәрәкәт җитәкчеләреннән берсе.

волюция хәрәкәтләре. Беренче бүлек (1905)» (Казан, 1925) дигән китабының титул битенә язылган. Ул китапны Россия Фәннәр академиясе Федераль тикшеренү үзәге «Казан Гыйльми үзәге»нең Фәнни китапханәсендә таптык.

Бу китапның Г. Ибраһимов тарафыннан 1926 елда Бакуда Фәрид бәйгә язган автографлы икенче нөсхәсе Истанбул шәһәренең Бөекшәһәр бәләдиясендә (мэриясендә) Ататөрек исемендәге китапханәдә сакланганлыгы билгеле булды.

Язучының «Безнең көннәр» романының рус телендә чыгачак басмасы өчен Г. Шәриповага җибәрелгән автографлы фотосы (Ялта, 1932) хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Милли музеенда саклануын белдек.

Болардан тыш янә төрле кешеләрнең истәлекләрендә дә Г. Ибраһимовның автографлары хакында мәгълүмат китерелә. Мәсәлән, укытучы Гайнулла Ишбулатов (?–?) Уфадагы татар-башкорт педагогия техникумында укыган вакытында, әдәбият түгәрәге әгъзаларыннан 11–12 кеше җыелып, 1924 елның июнь аенда Казанга экскурсиягә килгәч, әдип янына керүләрен, шунда ул үзенең «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» исемле китабын әдәбият түгәрәгенә автограф белән бүләк итүен яза. Истәлек авторы белдергәнчә, Г. Ибраһимов соңыннан «Пролетариат әдәбияты нәрсәдә?» дигән китабын да автограф белән җибәрә.

Озак еллар мәгариф өлкәсендә эшләгән педагог Касыйм Гыйрфанов (1889–1968)[1] 1920 елның башында Чиләбедән Казанга китаплар алырга командировкага килә. Шул вакытта ул Г. Ибраһимов белән очраша һәм әдип аңа «Безнең көннәр» романын тегелеп һәм төпләнеп бетмгән килеш типографиядән алып кайтып, «Автордан Касыйм Гыйрфанов иптәшкә истәлек өчен» дип язып бүләк итә.

Х. Әпсәләмова-Фәткуллина Павлодарда укытучы булып эшләгәндә Г. Ибраһимов аңа «Яшь йөрәкләр» романын автографы белән җибәрүе хакында 1961 елның 24 июлендә язучы Локман Бадыйкшанга (1919–2015) сөйләп калдырган.

---

[1] Тулырак кара: Саламатова Г.Д. «Башҡорт аймағы» журналынан бер мәҡәлә / Г.Д. Саламатова // Востоковедение в Башкортостане: сборник статей, посвященных памяти члена-корреспондента Академии наук Республики Башкортостан, доктора филологических наук, профессора Ишмухамета Гильмутдиновича Галяутдинова / Составители: А.Г. Салихов, С.А. Искандарова. Редакторы: А.Г. Салихов (отв. ред.), С.А. Искандарова, Ш.В. Нафиков.– Вып. 1.– Уфа: ИИЯЛ УФИЦ РАН, 2018.– Б. 262–274.

Г. Ибраһимовның хатлары хакындагы мәсьәләгә дә аерым мәкалә багышладык[1]. Әдипнең тормышы һәм иҗат мирасы, аның өйрәнелү торышын шулай ук көндәлек матбугатта яктырткан идек[2].

Язучы Лирон Хәмидуллин болай яза: «Ө. Мөхәммәдова тарафыннан тупланган менә шундый хатлар, фотолар, документ күчермәләре калын-калын папкаларда әдибәнең өстәлендә өелеп торалар иде. Ул папкаларның хәзерге язмышы миңа билгесез»[3]. Казан шәһәренең элекке Ленин районының Восстания урамындагы 89 нчы татар мәктәбенең (хәзер Мәскәү районының Г. Ибраһимов исемендәге татар гимназиясе муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе) 1960 еллардан бирле аның директоры булып эшләгән Вазыйх Надриев 1990 елда аңа шулай сөйләгән: «Галимҗан Ибраһимовка багышлап утыз биш ел дәвамында тупланган истәлек язмаларын һәм фотоларны югалттык. Ике-өч ел элек. Илдә зур үзгәрешләр башлангач, аларны без шушында (Татарстан Язучылар берлегенә. – *Р. И.*) китереп биргән идек. Шуларны хәзер таба алмыйлар. Ул кыйммәтле истәлек язмаларын, фотоларны кем, кая куйган – белмиләр. Анда әдипне соңгы елларда карап, тәрбияләп торган соңгы хатыны Хәдичә апа Фәтхуллинаның истәлекләре дә бар иде. Ул истәлекләр башка беркайда да басылмады, бездә аның тулы нөсхәсе иде»[4].

Әдипнең хатлары һәм документлары Ф. Ибраһимова тарафыннан аерым том буларак төзелеп, 2000 елда нәшер ителде[5]. Галимә «Документлар ни сөйли?» дигән кереш мәкаләдә болай яза: «Китапта йөз туксан данә хат, телеграмма, автограф, автобиографияләр, йөз кырык өч исемдә документ урнаштырыл-

[1] Исламов Р. Әдипнең хатлары / Р. Исламов // Кызыл таң.– 2017.– 11 март; // Мәд. җомга.– 2017.– 17 март.

[2] Исламов Р. Әле аны өйрәнәсе дә өйрәнәсе: Галимҗан Ибраһимовның тууына 125 ел / Р. Исламов // Кызыл таң.– 2012.– 17 апр.; Исламов Р. Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр / Р. Исламов // Мәд. җомга.– 2013.– 13 сент.

[3] Хәмидуллин Л. Ак тапларны киметәсе иде… / Л. Хәмидуллин // Рухи мирас = Духовное наследие: поиски и открытия / Редколлегия: И. Г. Гумеров (руководитель проекта и ответственный редактор), М. И. Ахметзянов, З. З. Рамеев. Составители выпуска: Л. Ш. Гарипова, Г. М. Ханнанова, Л. Ш. Давлетшина.– Казань: ИЯЛИ, 2017.– Вып. 3.– Б. 303.

[4] Хәмидуллин Л. Күрс. хезм.– Б. 303.

[5] Галимҗан Ибраһимов: Хатлар һәм документлар / Җыентыкны төзүче, текст һәм аңлатмаларны әзерләүче Ибраһимова Ф. И.– Казан: Фикер, 2000.– 464 б.

ды. Әле бу соңгы чик түгел. Г. Ибраһимов – гигант фигура. Аңа бәйле шәхси кәгазьләрнең табылу ихтималы шик тудырмый. Гыйльми Үзәк рәисе булып эшләгәндә, аның җитәкчелегендә хәл ителгән мәсьәләләрне караган утырыш беркетмәләре генә Татарстан республикасы Милли архивында күпме? Үзләре бер җыентык булырлык. Бу китапка аларның әдәбиятка мөнәсәбәтле аз өлеше генә алынды. Автобиографияләре дә барысы да керәп бетмәде. Миңа Татарстан республикасы Дәүләт Иминлеген Саклау Комитеты архивына кереп, эзләнүләр алып барырга да рөхсәт булмады, үзләре биргән кайбер белешмәләр белән генә чикләнергә туры килде»[1].

Г. Ибраһимовка бәйле документларны барлау, туплау һәм аларны киң даирә укучыга җиткерү юнәлешендә башкарылган нәтиҗәле уңай күренешләр белән бергә, кызганыч ки, кайбер җитди төгәлсезлекләр һәм җитешсезлекләр дә шактый күзәтелә. Аларны төп нөсхәләре белән чагыштырып тикшерү барышында шулар ачыкланды: кайбер текстларны кыскарту, үзгәртү, текстологик яктан эшкәртүдә игътибарсызлык очраклары бар. Мәсәлән, әдипнең 1912 елның 13 декабрендә Киевтән Х. Кайбышевка язган хатның төп нөсхәсе сакланмаган. Ул Аерым жандармнар корпусы тарафыннан 1913 елның 3 маенда тентү буенча төзелгән 16 санлы беркетмәдә урнаштырылган. Хат рус теленә 15 нче Татар-улан полкы штабс-ротмистры А. Ф. фон-Трентовиус[2] тарафыннан тәрҗемә ителгән. Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томына ул янә татар теленә тәрҗемә итеп урнаштырылган.

Әдипнең Х. Кайбышевка 1913 елның 3 гыйнварында язган хаты нишләптер һаман ике хат буларак тәкъдим ителә.

Г. Ибраһимовның Киевтән 1913 елның 24 апрелендә Шәһит Әхмәдиев һәм журналист, тәрҗемәче Заһит (Заһидулла) Нуркинга (1888–1966), 1924 елның 19 июлендә Тарасова дигән кешегә, 1926 елның 25 августында Һади Такташка (1901–1931) рус телендә язган хатлары да моңа кадәр оригиналда дөнья күрмәде. Алай гына да түгел, Һ. Такташка 1927 елның 4 февралендә Заһидуллин имзасы белән язылган хат Г. Ибраһимовка нисбәт ителеп, әүвәл Һ. Такташ «Әсәрләр»енең 3 нче томын-

[1] Галимҗан Ибраһимов: Хатлар һәм документлар… – Б. 14.

[2] *А. Ф. фон-Трентовиус* – Александр Федорович фон-Трентовиус (1881–?), 15 нче Татар-улан полкы штабс-ротмистры, тәрҗемәче.

да[1], аннан күчерелеп Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томына[2] урнаштырылган.

Тагын бер мисал. «Мәгариф» журналының 1928 елгы 2 нче санында «Татар педагогия җәмгыяте»ндә дигән рубрикада «Юбилейга багышлау» аталышында шундый мәгълүмат китерелгән: «Татар педагогия җәмгыяте» идарәсе үзенең 28 нче декабрь утырышында Галимҗан иптәш Ибраһимовны җәмгыятьнең фәхри[3] әгъзасы итеп сайларга карар бирде.

Идарә җәмгыять янында оештырыла торган тел-әдәбият кабинетын Галимҗан иптәш исеменә атарга карар бирде»[4]. Ул Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында болай үзгәртеп бастырылган: *«Татар педагогия җәмгыяте» идарәсе үзенең 1927 елгы 28 декабрь утырышында, 20 еллык юбилее уңае белән, Галимҗан иптәш Ибраһимовны җәмгыятьнең фәхри әгъзасы итеп сайлады. Идарә җәмгыять янында оештырыла торган тел-әдәбият кабинетына Галимҗан иптәш исемен бирү турында карар кабул итте»*[5].

Мондый тискәре күренешләрне шул чор татар текстологиясе фәне үсеше белән бәйләп аңлату гына дөреслеккә туры килеп бетми.

## II

Җәмгыятьтәге үзгәрешләр, фәндәге казанышлар, табышлар Г. Ибраһимов хакында документларның яңа басмасын төзү зарурияттен барлыкка китерде.

Ике томлы бу җыентыкта барлыгы 710 документ (шуның 374 е беренче мәртәбә яки гамәлдәге татар хәрефләрендә һәм ориги-

---

[1] Такташ Һ. Әсәрләр: Өч томда / Томның әдәбият-сәнгать тәнкыйте, публицистика өлешен төзүче, текст һәм искәрмәләрен хәзерләүче Лена Гайнанова. Биографик материаллар, хатлар өлешен төзүче, текст һәм искәрмәләрен хәзерләүче Марсель Әхмәтҗанов / Һ. Такташ.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1983.– 3 т.: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, публицистика, биографик материаллар, хатлар.– Б. 371.

[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Тугыз томда / Җыентыкны төзүче, текст һәм аңлатмаларны әзерләүче Ибраһимова Ф. И. / Г. Ибраһимов.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.– 9 т.: Хатлар һәм документлар.– Б. 131.

[3] *Фәхри* – мактаулы.

[4] Юбилейга багышлау // Мәгариф.– 1928.– № 2.– Б. 100. Аннан соң гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында шактый үзгәртелеп бастырылган (Казан, 2000, б. 321). Текст журналдан алынды.

[5] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Тугыз томда / Җыентыкны төзүче, текст һәм аңлатмаларны әзерләүче Ибраһимова Ф. И. / Г. Ибраһимов.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.– 9 т.: Хатлар һәм документлар.– Б. 321.

налда беренче мәртәбә, хәзерге заманда басылган 264 документ оригиналлары буенча алынды) тупланган бу җыентыкның корылыш композициясе тематика һәм жанрлар буенча аерымланган шундый биш бүлектән төзелде: I. Автобиографияләр; II. Кайбер әдәби әсәрләреннән үрнәкләр («Алмачуар», «Табигать балалары» хикәяләре); III. Кайбер гыйльми хезмәтләреннән үрнәкләр («Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?»); IV. Совет чорына кадәрге документлар (Иҗтимагый-сәяси документлар: а) жандармерия документлары; б) Учредительный собраниегә сайлау документлары; хатлар; белдерүләр; мөрәҗәгатьләр; хәбәрләр; автографлар; котлаулар); V. Совет чоры документлары (Иҗтимагый-сәяси документлар; Татарстан Мәгариф халык комиссариаты документлары; Гыйльми үзәк документлары; хәбәрләр; белдерүләр; хатлар; телеграммалар; мөрәҗәгатьләр; автографлар; котлаулар; репрессия чоры документлары; аклау чоры документлары; шәхси тормышына караган документлар; исемен мәңгеләштерү документлары; тормышы һәм эшчәнлеге хроникасы; яшәгән фатирларының, кунакханәләрнең һәм ул булган йортларның исемлеге; яңа библиографиясе).

Болай аерымлау, инануыбызча, Г. Ибраһимовның тормышын, гыйльми-әдәби, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген логик эзлеклелектә тикшерергә, эволюцион тенденцияләрне тирәнрәк күзалларга, шәхесен киңрәк ачыкларга һәм гомуми бәяләмәне хәзерге заман таләпләре нигезендә дөрес билгеләргә ярдәм итә.

Эш барышында һәр документның чыганаклары яки хәзерге вакытта саклану урыннары күрсәтелеп, моңа кадәр кайда һәм кайчан дөнья күрүләре яки беренче (шулай ук гамәлдәге татар хәрефләрендә) мәртәбә бастырылулары хакында белдерелеп барылды. Биредә исемнәре теркәлгән кешеләрнең туган-үлгән еллары, һөнәрләре, башкарган вазифалары; күрсәтелгән көндәлек матбугат; тарихи, сәяси-иҗтимагый вакыйгалар хакында мәгълүмат мөмкин кадәр тулырак бирелергә тырышылды.

Документларда әдип һәм аның әтисе исемнәренең төрлечә язылышы күзәтелә. Мәсәлән, *Алимзян, Алимзан, Ализьян Гильфатович, Галинчан, Галитжан, Гирфандович, Галим, Галимжан, Галимджан, Галимжан-Алимзян, Галимзан, Галимзен, Галимчан, Галямзан, Герфанович, Гилимутан*. Башка кешеләрнең исемнәре белән дә шулай. Әйтик, *Шафи – Пафи, Кайбишев – Камбишев, Ханафи – Халафи, Мухамет-Ханафи, Умми-Гульсум – Уми-Гуль-*

*сум, Гульсюм* һ.б. Алар үзгәртелмәде, документларда ничек булса, шулай калдырылды.

Совет чорына кадәрге админстратив бүленешләрне совет чорындагыча итеп яки бөтенләй ялгыш күрсәтү очраклары да юк түгел. Мәсәлән, ТАССР Министрлар советы каршындагы Дәүләт иминлеге комитеты тикшерү бүлегендә төзелгән бер документта Г. Ибраһимовның туган урыны Баш[корт] АССРның Стәрлетамак районында (*Стерлитамакского района Баш. АССР*) дип күрсәтелсә, Г. Мөхәммәдова СССР Дәүләт иминлеге комитетына кулдан язган гаризасында Г. Ибраһимов Уфа өлкәсендә (*Уфимская область*) туган һәм кулга алыну ае *«сентябрь»* дип яза. Язучы дөньяга килгәндә бернинди өлкә дә, республика да, район да булмаган лабаса. Хәер, мондый төр төгәлсезлекләр хәзерге чор чыганакларында да күзәтелә[1].

Тагын бер моментка игътибарны юнәлтү сорала: бу җыентык тулы камиллеккә дәгъва итми, әлбәттә. Чөнки мәгълүм булып та, объектив сәбәпләр нәтиҗәсендә танышу мөмкинлеге булмаган чыганаклар бар, киләчәктә табылуы ихтимал булганнарын да истән чыгарырга ярамый.

## III

Эш барышында аерым мәсьәләләрне хәл итүдә күрсәткән ярдәмнәре өчен тарих фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университеты доценты Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллинга (1953–2019)[2], дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» директоры Илдар Фәрит улы Шәфыйковка, дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» фондларын баш саклаучы Римма Йосыф кызы Мәхмүтовага, Казанда яшәүче Әлфия Афзал кызы Шамовага,

---

[1] Эзләнеп тормыйча, «хәзерге фәлән республика» яки «хәзерге фәлән район» дип кенә күрсәтүне еш очратырга туры килә. Ә 1920–1930 еллардагы *кантон* административ-территориаль берәмлек бөтенләй диярлек искә алынмый башлады.

[2] Галим исән вакытында бу хезмәтне тикшереп, редакцияләп чыккан иде. Соңыннан кайбер материаллар ул төзегән «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З. С. Миннуллин; науч. ред.: Р. Р. Фахрутдинов, Р. Р. Хайрутдинов. – Казань: Заман, 2017. – Т. 1. – 520 с.» һәм аның автордашлыгында нәшер ителгән «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З. С. Миннуллин, Р. Д. Шарафиева; науч. ред.: Р. Р. Фахрутдинов, Р. Р. Хайрутдинов. – Казань: Заман, 2019. – Т. 2. – 496 с.» дигән җыентыклардан да алынды.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе директорының фән эшләре буенча урынбасары Ирек Габделхәй улы Һадивка, Татарстан Республикасы Милли музееның өлкән хезмәткәре Рәмзия Әсрар кызы Абзалинага, Татарстан Республикасы Милли музееның музей предметларын саклаучы Рәсүлә Нургаяз кызы Гайнетдиновага, Башкортстан Республикасы Милли архивы бүлек җитәкчесе Зөлфәр Габит улы Гатиятуллинга, Башкорт дәүләт университетының Стәрлетамак филиалы татар һәм чуваш филологиясе кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент Илсур Салихҗан улы Мансуровка, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Җиһангир улы Заһидуллинга, Башкортстан Республикасы Әхмәтзәки Вәлиди исемендәге милли китапханәнең кулъязмалар, сирәк басмалар бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент Флүр Шәрифулла улы Сибәгатовка, Россия Фәннәр академиясе Уфа федераль тикшеренүләр үзәгенең Тарих, тел һәм әдәбият институты кулъязмалар бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Әхәт Гобәй улы Салиховка, шул ук Институтның әдәбият белеме бүлеге фәнни хезмәткәре Салават Мирсадыйр улы Хөсәеновка ихлас рәхмәтләремне белдерүне мөкатдәс бурычым итеп саныйм.

*Рәмил Исламов*,
филология фәннәре докторы,
Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе

# I
# АВТОБИОГРАФИЯЛӘР

## 1921
## Автобиография Г. Г. Ибрагимова 1921 года[1]

Биография чл[ена] РКП(большевиков)
Галимджана Ибрагимова.

По социальному положению – крестьянин.

По профессии – журналист (писатель) и педагог.

Образование – высшее восточно-мусульманское.

Родился 1887 года в Уфим[ской] губ[ернии] в д[еревне] Султанмуратово[2].

Учился: до 12 лет в своей деревне[3], потом в Оренбурге[4] и окончил в Уфе высшее восточно-мусульманское учебное заведение[5].

[1] Төп нөсхә (кулдан язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (292 ф., 6 тасв., 51 эш, 44, 44 (икенче ягы), 45, 45 (икенче ягы) кәг.). Документ шулай расланган: «Ваше изложение подтверждаю. Член РКП с 1912 г[ода] № 649658 (*подпись неразборчива*)». Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Солтанморат авылы хәзерге вакытта Башкортстан Республикасы Авыргазы районында.

[3] *Учился: до 12 лет в своей деревне* – сүз Солтанморат авылында земство башлангыч рус мәктәбе хакында бара. Язлы-көзле, ягъни мәдрәсәдә укулар тәмамланып янә башланганчы, Г. Ибраһимов белән агасы бу мәктәптә дә укыйлар.

[4] *Учился: ... потом в Оренбурге* – Г. Ибраһимов Оренбургта 1 нче мәчет (хәзерге Левашев урамы, 12 йорт) каршындагы Вәли Хөсәенов (Мөхәммәтвәли Габделгани улы Хөсәенов, 1871–1933) мәдрәсәсендә 1899 елдан 1906 елның язына кадәр укый. Башта мәдрәсә чыгышы белән Стәрлетамак ягыннан булган Шакир хәзрәт (?–?) карамагында булып, аның вафатыннан соң В. Хөсәеновка күчә.

[5] *... окончил в Уфе высшее восточно-мусульманское учебное заведение* – 1906 елның көзендә Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә, 1908 елда чыгарыла.

*«Мәдрәсәи Галия» – Уфада педагог, дин белгече, җәмәгать эшлеклесе Зыяэддин хәзрәт әл-Кәмали (Пәрвәзетдин Камалетдин улы Зыятдинов (1873–1942) Уфа шәһәренең Нижгородка бистәсендә әүвәл Зариф мулла тарафыннан 1906 елда нигезләгән аскы каты таштан, өске каты агач мәчеттә, аннары 1907 елның 18 ноябрендә шул вакыттагы Большая Уфимская урамында кирпеч өч катлы бинада тантаналы ачылган югары дини уку йорты. Уку-укыту курсы якынча 30 фәннән торган. 1914 елдан музыка укытыла башлый. Анда Идел буеннан, Уралдан һәм Көнчыгыш Себердән, Урта Азиядән, Кавказдан, Кырымнан шәкертләр укыган. 1918 елда ябыла. 1919 елда мәдрәсә ир балалар өчен икенче баскыч гомуми белем*

Литературно-научное образование в Европейском смысле приобретено частной подготовкой и одну зиму был вольным слушателем Киевского университета (1912–1913).

Литературную работу начал (если не считать сотрудничество в подпольных листках) с 1908 года в газете «Эльислах»[1], органе революционной молодежи. С тех пор моя литературная деятельность безпрерывно шла в двух областях: 1) Художественной литературы и 2) учебно-педагогической.

В 1913 году сидел в Киевской тюрьме за подпольную работу среди студенчества[2], после освобождения из тюрьмы[3] находился под гласным надзором полиции до 1917 года.

---

*мәктәбе итеп үзгәртелә. 1920 елда ул ябыла. Хәзерге Чернышевский урамындагы 5 нче санлы бу бинада озак еллар М. Гафури исемендәге 15 нче санлы татар мәктәбе эшли. Бина яңадан мөселманнарга кайтарып бирелгәннән соң, 2002 елдан анда мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәтенең Р. Фәхретдинов исемендәге Россия ислам университеты эшли.*

[1] «*Эльислах*» – «Әлислах» – мөхәррире һәм нашире Вафа (Әхмәтфава) Гали улы Бәхтияров (1881–1960) булган һәм 1907–1909 елларда Казанда чыккан демократик яшьләр һәм алдынгы шәкертләрнең басма органы булган газета. Барлыгы 68 саны дөнья күргән.

[2] *В 1913 году сидел в Киевской тюрьме за подпольную работу среди студенчества* – Г. Ибраһимов элекке танышы, ул вакытта Киевтән ерак булмаган Казатин дигән авылда укытучы булып эшләгән Каюм Рәхим улы Мостакаев (1885–1974) булышлыгы белән 1912 елның көзендә Киевкә университетта укучы ике-өч татар студентына, өч-дүрт гимназисткага татар теле, әдәбияты һәм тагын берничә балага хәреф танытып, аларны укырга-язарга өйрәтү өчен килә. Бу эш Киев тимер юлында ресторан-вагоннар, вокзалда буфет тотучы Габдулла Максудов дигән кешенең үтенече белән була. Тиздән ул Изге Владимир университеты мөселман студентлары һәм курсисткалар белән танышып, аларның яшерен «Якташлык» җәмгыяте утырышларында катнаша башлый. 1913 елның 17 апрелендә Сона Абделхак кызы Ахундова (1893–?) квартирасында (Захарьевская, 17) бу җәмгыятьнең киңәшмәсе вакытында анда катнашучылар полиция тарафыннан кулга алына. 17 апрельдә, төнге сәгать 12 дә 30 минутта Г. Ибраһимов (ул киңәшмәдә булмый) фатирында (Степановская, 18) тентү ясалып, ул да кулга алына. Көндез аңардан сорау алу оештырыла, ә 19 апрельдә Киев төрмәсенә ябыла. 29 апрельдә аның кулга алыну көненнән исәпләп, төрмәдә тотылу вакыты тагын бер айга озайтыла.

[3] *…после освобождения из тюрьмы* – 1913 елның 13 июнендә Киев Изге Владимир университеты студентлары, «Якташлык җәмгыяте» әгъзалары Фирүзбәк Мехтихан оглы Ордубатский (1888–?), Җәмилбәк Исмаилбәк оглы Вәзиров (1888–?), Алибәк Касыймбәк оглы Алибәков (1878–?) белән бергә Г. Ибраһимов та гаепсез табылып, төрмәдән азат ителә. Ул шул ук көнне Киев губерна жандарм идарәсе башлыгына үзенең башта Казанга, аннан соң туган авылы Солтанморатка кайтып китәчәге хакында язмача белдерә.

Во время Февральской революции работал в Уфе, откуда был избран в члены Учредительное собрание[1], прибыл в Петроград.

Вместе с тов[арищами] большевиками и ЛСР[2] покинул Учредительное собрание, потом участвовал в третьем съезде Советов[3], откуда был избран в члены ВЦИК[4].

В январе 1918 года с тов[арищем] Вахитовым[5] организовал Цен[тральный] Мус[ульманский] Комиссариат при Совнаркоме[6].

В начале 1919 года по болезни переехал в Казань и продолжал свою революционно-литературную работу.

---

[1] *Учредительное собрание* – Бөтенруссия Учредительное собраниесе – 1918 елның 5 гыйнварында чакырылган халык вәкилләре җыелышы Петроградта, Таврия сараенда ачыла. Ләкин Совет хөкүмәтенең декретларын танымаганлыктан таратыла.

[2] *ЛСР (левые социалисты революционеры)* – сул социалист революционерлар (сул эсерлар) – XX йөз башында Россиядә төрле народниклык төркемнәренең берләшүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән фирка. Аларның программасында хосусый милеккә кагылмыйча, җирләрне крестьяннарга бүлеп бирү таләп итеlә. 1917 елның җәендә эсерларның сул канаты фиркадән аерылып чыга һәм декабрь аенда аерым сул эсерлар фиркасе оештыра.

[3] *... потом участвовал в третьем съезде Советов* – эшче, солдат депутатлары советларының 3 нче Бөтенроссия съезды 1918 елның 10–18 гыйнварында Петроградта була. Ул «Хезмәт иясе һәм эксплуатацияләнүче халыкларның хокуклар декларациясе»н кабул итә. Кара: История Советской Конституции в декретах и постановлениях Советского правительства 1917–1936. Составил С. Студеникин. Под ред. А. Алымова.– М.: ОГИЗ, 1936.– С. 55–56; Образование Башкирской Автономной Советской Социалистической Республики. Сборник документов и материалов. Под редакцией Б. Х. Юлдашбаева.– Уфа: Башкир. кн. изд-во, 1959.– С. 78–80.

[4] *...откуда был избран в члены ВЦИК* – әгъзалык билеты № 118.

[5] *Вахитов* – Мулланур Муллаҗан улы Вахитов (1885–1918), сәясәт эшлеклесе; 1918 елның 19 августында Казанда акгвардиячеләр тарафыннан атып үтерелә.

[6] *Цен[тральный] Мус[ульманский] Комиссариат при Совнаркоме* – 1918 елның 17 (30) гыйнварында Халык комиссарлары советының Декреты белән Милли эшләрне карый торган комиссариат каршында Үзәк мөселман комиссариаты оештырыла. Аның рәисе итеп М. Вахитов, ә урынбасарлары итеп Г. Ибраһимов һәм Шәриф Манатов (Шәрифҗан Әхмәтҗан улы Әхмәтҗанов, 1893–1936) билгеләнә.

Сталин җитәкчелегендәге Милләтләр эшләре буенча Халык Комиссариаты 1917 елның 25 октябрендә эшче һәм солдат депутатлары Советларының II Бөтенроссия съездында оештырыла. Бу хакта тулырак кара: Песикина Е. И. Народный Комиссариат по делам национальностей и его деятельность в 1917–1918 гг. Под ред. Д. И. Надточеева / Е. Н. Песикина.– М., 1950.– 155 с.

Комиссариат берничә мәртәбә исемен алыштыра: Эчке Русия мөселман эшләре комиссариаты, Үзәк Татар-башкорт комиссариаты, Үзәк мөселман комиссариаты.

Летом 1919 года по мандату Мусульман[ского] Бюро коммунистов был отправлен во время борьбы с Колчаком для подпольной работы в Сибирь, поработав около четырех месяцев возвращался через пятую дивизию в Казань.

С этого времени опять всецело ушел в литературную работу. Вместе с этими шла работа в периодической печати, главным образом как фельетонист и обозреватель научно-художественных книг.

В периоде Февральской революции был редактором газеты «Ирк»[1], органе татарских социалистов в Уфе. Дальнейшая работа в периодической печати: 1918 года в Петрограде организовал газету «Чулпан»[2], общий орган ЛСР и большевиков-татар, с 1919 года переехал в Казань и работал в газетах «Эш»[3], «Эшче»[4], органах ЦБНВ при ЦРКП большевиков и принял ближайщее участие в журнале «Кызыл Шарык»[5], органе ЦБКВ при ЦКРР. Параллельно с этими шла моя работа над своей трилогией «Безнен кюнляр»[6], первая часть которой (в размере 165 стр.) вышла в печати в 1920 г[оду] (первая часть этой трилогии революция пятого года, вторая – времена реакции, третья – Октябрьская революция).

Кроме этого закончил свой историко-теоретический труд под заглавием «Октябрьский переворот и диктатура пролетариата»[7].

[1] *«Ирк»* – «Ирек» – 1917 елның 21 сентябренә кадәр Г. Ибраһимов мөхәррирлегендә, Фатыйх Сәйфи-Казанлы (Мөхәммәтфатыйх Камалетдин улы Сәйфуллин) (1888–1937) наширлегендә Уфада чыккан халык, 16 санынннан татар социал-революционерлар газетасы.

[2] *«Чулпан»* – иҗтимагый-сәяси газета, Үзәк мөселман комиссариатының басма органы. 1918 елның 18 гыйнварыннан 1919 елның 21 мартына кадәр Петроградта (12 сан), 30 марттан Мәскәүдә (45 сан) чыга. Үзәк мөселман комиссариаты матбугат бүлеге Мәскәүдән Казанга күчерелгәч, «Чулпан» анда чыгучы «Эш» газетасы белән берләштерелә.

[3] *«Эш»* – Казан мөселман комиссариаты тарафыннан 1918–1920 елларда чыгарылган көндәлек сәяси, әдәби һәм иҗтимагый газета. Барлыгы 418 саны дөнья күргән.

[4] *«Эшче»* – РКП(б) Шәрык халыклары коммунист оешмалары Мәркәз бюросы тарафыннан 1918 елдан нәшер ителгән газета.

[5] *«Кызыл Шәрык»* – 1920–1921 елларда Казанда, 1922–1923 елларда Мәскәүдә нәшер ителгән икътисади-иҗтимагый, сәяси-гыйльми айлык журнал.

[6] *«Безнен кюнляр»* – роман 1919 елда нәшер ителә: Ибраһимов Г. Безнең көннәр: Роман / Г. Ибраһимов.– Казань: Лито-тип. т-ва «Умид», 1919.– 442 б.

[7] *«Октябрьская революция и диктатура пролетариата»* – сүз шушы хезмәте хакында бара: Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы (Револю-

Революционная работа: первые шаги в 1905–[190]6 годах среди шакирдов в виде митингов, собрании и организационные работы.

Хотя с 1918 года всюду открыто работал в глубоком контакте и единении по всем вопросам с тов[арищами] коммунистами, но формально вступил в РКП лишь 1920 года[1].

Принимая во внимание мои бывшие революционные работы, меня приняли со стажем с 1917 г[ода] 15 апреля[2].

Заканчивая свои заметки, считаю нужным сделать две оговорки: 1) все мои революционные работы до 1917 года не были под знаменем определенной какой-либо партией, а скорее носили общее – беспартийно-социалистического характера; 2) хотя я официально работал с 1917 года под именем ЛСР, но я состоял членом не общей партии, а автономной татаро-башкирской организации ЛСР.

Эта организация во всех практическо-тактических вопросах, вопреки ЦК ЛСР, работала в контакте с партией коммунистической, о чем может засвидетельствовать масса фактов.

Член РКП Галимджан Ибрагимов

---

циядә сыйнфый нигезләр – Милли тарих өчен материаллар – Бу бөек хәрәкәт эчендә татарлар, башкортлар). Мөхәррире: Галимҗан Ибраһимов. Бу хезмәт Шәрыкнең вакытсыз һәлак булган бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов хатирәсенә багышлана. Г. И.– Казан: Татар Социал Советлар Җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты, 1922.– 146 б.

[1] *…формально вступил в РКП лишь 1920 года* – 1920 елның 23 декабрендә Болак арты Пләтән район комитетының 12 нче санлы партия ячейкасында РКП (б) сафына кабул ителә.

[2] *Принимая во внимание мои бывшие революционные работы, меня приняли со стажем с 1917 г[ода] 15 апреля* – Г. Ибраһимов 1917 елның 15 нче апреленнән алып 1918 елның көзенә кадәр татар-башкорт сул эсерлар фиркасендә була. РКП(б)нең ул вакыттагы уставы башка фиркаләрдән большевиклар фиркасенә күчкән кешеләрнең партия стажын электәге фиркагә алыну вакытыннан башлап исәпләү мөмкинлеген биргән.

## 1924
## Автобиография Г. Г. Ибрагимова 1924 года[1]

январь 1924 г.

Копия

В ГПУ тов[арищу] Журавлеву

Автобиография
Ибрагимова Галимджана Гирфановича
члена Казанской организации РКП(б)

1

Родился в 1887 г[оду] в деревне Султанмуратово б[ывшей] Уфим[ской] г[убернии] Стерлитамак, Уршакминской вол[ости].

По происхождению крестьянин.

До 20-ти летнего возраста сам каждое лето работал как обыкновенный крестьянин (во время летних каникул). После некотрого перерыва, во время войны, когда братья были взяты на войну[2], опять вернулся к этой работе.

Отец[3] – человек духовного звания, но к концу своей жизни бросил этот сан и жил только как хлебороб. Хозяйство его по размеру было чисто середняцкого типа.

2

Учился:

1) в деревне в татарском «мектябе».

2) в сельской начальной русской школе.

---

[1] Күчермә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (15 ф., 6 тасв., 6367 эш, 70–74 (икенче ягы) кәг.). Беренче мәртәбә «Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых» дигән китапта бастырылган (Казан, 2012, б. 7–12). Текст күчермәдән алынды.

[2] *А*гасы Шакирҗанны (1880–1962) 1915 елның гыйнварында, энесе Габделхәкимне (1896–1957) җәй аенда Беренче Бөтендөнья сугышына алалар. Габделхәкимнең истәлекләреннән күренгәнчә (жандармерия документлары белән дә раслана), Г. Ибраһимов туган авылына февраль аенда авыру хәлендә кайта һәм бераздан аны хастаханәгә салалар: 1957 елның 13 мартында Г. Ибраһимовның туганнары Шакирҗан һәм Хәким Ибраһимовлар белән үткәрелгән беседаның стенограммасы (татар телендә) // Галимджан Ибрагимов: документы и факты; Галимджан Ибрагимов глазами молодых / Автор-составитель М. Х. Ибрагимов.– Казань: Татар. кн. изд-во, 2012.– С. 168.

[3] Гыйрфан Нурмөхәммәт улы Ибраһимов (1847–1913), муллалыгын 1907 елда ташлаган.

3) с 11 до 18 лет в Оренбурге в мусульманском «медресе» старого типа, откуда был изгнан за «вольнодумство» и за новаторский образ мышления.

4) В Уфе в т[ак] н[азываемом] высшем мусульманско-восточном учебном завед[ении] «Гали», откуда был исключен за анти-исламскую пропаганду и из-за своей книги против религии и Корана[1], рукопись которой до сих пор сохранилась у меня. В то время эта ученическая работа, конечно, не могла быть напечатана.

5) Потом совершенно разочеровавших от мусульманского-восточн[ого] учеб[ного] завед[ения] начал было готовится для поступления в русск. университет или институты; но по двум причинам не мог достигнуть этой своей цели: во-первых, я был лишен политической благонадежности, без чего меня не приняли бы, во-вторых, у меня не было никаких материальных средств, чтобы я мог систематически заниматься. И по этим обстоятельствам я был вынужден отказаться от русск[ого] выс[шего] учеб[ного] завед[едения] и предаваться всецело самообразованию, добывал себе кусок хлеба, то уроками, то журнальной работой, за которую мне платили в буквальном смысле гроши.

Приходилось долгие-долгие годы голодать и холодать, продолжая свое самообразование.

Профессия:

Я – профессионал журналист-литератор и преподаватель-лектор.

В татарской печати начал работать с 1908 года, в газете «Эль-Ислах» (в Казани) – органе революционной татарской молодежи – «шакирдов»,– где я поместил свой первый рассказ[2], описывающий борьбу татар. молодежи против старого порядка.

Во время суровой Столыпинской реакции[3] эта газета прекратила свое существование и мне пришлось работать в качест-

---

[1] *Г.* Ибраһимов «Коръән Алладанмы, түгелме?» дигән китап яза. Ләкин ул бастырылмый кала.

[2] «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән беренче хикәясенең бер өлеше «Әлислах» газетасының 1907 елгы 10, 17 октябрь, 5, 12, 19 ноябрь, 3 декабрь саннарында, дәвамы 1908 елгы 14, 21 гыйнвар, 9 февраль, 2 март, 3, 27 апрель, 19 май, 10, 17, 24 июнь, 2 июль саннарында басылып чыга.

[3] Пётр Аркадьевич Столыпин (1862–1911), рус дәүләт эшлеклесе. 1905–1907 елларда инкыйлапны бастыру белән җитәкчелек итә, хәрби кыр мәхкәмәләр эшчәнлеген һәм үлем җәзасын хуплый (асу җепләре аның исеме белән «Столыпин галстугы» дип атала башлый).

ве постороннего сотрудника (не штатного) как фельетониста и литературного критика в различных газетах и журналах, этим я зарабатывал себе кусок хлеба. Вместе с работой в прессе я начиная с 1900–10 г.г. начал выпускать свои труды отдельными книгами, главным образом по двум отраслям: 1) по разработке и научному исследованию тат[арского] языка и татарской словесности и истории татарской литературы; и 2) вторая область моей работы – эта художественная литература (бытовые рассказы, социальные романы и т.п.).

В области разработки татарского языка и литературы (кроме журнальных статей) мною до сих пор выпущено около шести-семи названий[1]. Некоторые из них вышел 5-м изданием.

Из художествен[ной] литературы до сих пор из моих работ напечатано около двадцати (20) названий[2], среди них есть труды

---

[1] Сүз шушы хезмәтләр хакында бара: Ибраһимов Г. Татар нәхүе. Наширләре: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе, Казан / Г. Ибраһимов.– Казань: Лито-тип. И.Н. Харитонова, 1911.– 74 б.; *Аныкы ук.* Татар сарыфы. Наширләре: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе, Казан / Г. Ибраһимов.– Казань: Лито-тип. И.Н. Харитонова, 1911.– 82 б.; *Аныкы ук.* Татар шагыйрьләре. Беренче бүлем. Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Габдулла Тукаев / Г. Ибраһимов.– Оренбургта «Вакыт» матбагасы, 1913.– 103 б.; *Аныкы ук.* Татар имлясы. Мәктәпләр өчен дәреслек. Беренче басма. Наширләре: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе Казанда / Г. Ибраһимов.– Лито-тип. И.Н. Харитонова, Казань, 1914.– 28 б.; *Аныкы ук.* Ибраһимов Г. вә Баттал Г. Яңа әдәбият: Дәреслек. Беренче басма. Наширләре: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе, Казан / Г. Ибраһимов вә Г. Баттал.– Казань: Лито-тип. И.Н. Харитонова, 1914.– 240 б.; *Аныкы ук.* Әдәбият дәресләре. Нашире: «Сабах» ширкәте. Казан, Уфа / Г. Ибраһимов.– Казань: Типо-лит. «Умид», 1916.– 148 б.; *Аныкы ук.* Татар телен ничек укытырга? (Телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә). Нашире: «Сабах» ширкәте. Казан, Уфа / Г. Ибраһимов.– Казань: Типо-лит. т-ва «Умид», 1916.– 90 б.; *Аныкы ук.* Тел сабаклары. Икенче китап (Гамәли имля – Иншага, сарыф, нәхүгә хәзерлек). Нашире: «Сабах» көтепханәсе, Казан / Г. Ибраһимов.– Казань: Лито-тип. т-ва «Умид», 1918.– 47 б.

[2] Сүз шушы әсәрләр хакында бара, ләкин алар 20 берәмлектән артык: Гыйшык корбаннары. Милли хикәя. Мөхәррире: Гыйрфанзадә.– Казань: Электро-тип. «Урнэк» [елы юк].– 45 б.; *Аныкы ук.* Татар хатыны ниләр күрми? 1 нче җөзэ. Ирләр сурәтендә йөргән хатын. Эстәрлетамак өязендә булган вакыйга. Ширкәте «Каләм» мәсарыфы илән басылды / Г. И.– Эстәрлетамак: Тип. т-ва «Нур», 1910.– 141 б.; *Аныкы ук.* Яз башы. Нашире: «Мәгариф» көтебханәсе / Г. Ибраһимов.– Изд-е т-ва «Маариф», 1910.– 16 б.; *Аныкы ук.* Диңгездә. «Шура»га дәреҗ ителгәннән соң аерым рисалә шәкелендә басылды / Г. Ибраһимов.– Оренбургта «Вакыт» матбагасы, 1911.– 25 б.; *Аныкы ук.* Йөз ел элек. «Шура»га дәреҗ ителгәннән соң аерым рисалә шәкелендә басылды / Г. Ибраһимов.– Оренбургта «Вакыт» матбагасы, 1911.– 35 б.;

в размере 500 (пятьсот страниц. Напр[имер] «Безнен кюнляр» из событий революции 1905 г[ода]; это было написано в 1914 г[оду], но по цензурным условиям вышло только после революции).

Начиная с 1917 г[ода] я начал работать еще в одной области, именно, в области истории, главным образом по истории РКП, революц[ионного] движения в России вообще, среди татар в особенности (До сих пор отдельной книгой вышла «Октябрьская революция и диктатура пролетариата» (Сборник имени Вахитова и др[угие])[1].

---

*Аныкы ук.* Яшьләр хәятыннан бер ләүхә. Мөхәррире: Галимҗан Ибраһимов. Беренче басылуы.– Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1911.– 32 б.; *Аныкы ук.* Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы. Табгы вә нәшере Әхмәджан Исхакый «Шәрык» көтебханәсе / Г. Ибраһимов.– Казань: Электро-тип. «Умид», 1912.– 50 б.; *Аныкы ук.* Карак мулла: Хикәя. Мөхәррире: Галимҗан Ибраһимов. Беренче басылуы.– Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1912.– 30 б.; *Аныкы ук.* Сөю-сәгадәт: Хикәя. Наширләре: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе, Казан / Г. Ибраһимов.– Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1912.– 24 б.; *Аныкы ук.* Яшь йөрәкләр. Нашире: Әхмәд әл-Исхакый «Шәрык» көтепханәсе / Г. Ибраһимов.– Казань: Электро-тип. «Умид», 1912.– 416 б.; *Аныкы ук.* Табигать балалары: Хикәя / Г. Ибраһимов // Альманах (Хикәя вә шигырьләр мәҗмугасы). Нашире: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе, Казан. Казанда «Мәгариф» матбагасы.– Казань: Электро-тип. «Маариф», 1915.– Б. 4–28; *Аныкы ук.* Мәрхүмнең дәфтәреннән // Караңгы төннәрдә / Г. Ибраһимов.– Казань: 6-я Гос. тип., 1920.– Б. 2–6.; *Аныкы ук.* Уты сүнгән җәһәннәм // Караңгы төннәрдә / Г. Ибраһимов.– Казань: 6-я Гос. тип., 1920.– Б. 7–17. *Аныкы ук.* Габдрахман Салихов // Караңгы төннәрдә / Г. Ибраһимов.– Казань: 6-я Гос. тип., 1920.– Б. 19–32.; *Аныкы ук.* Табигать балалары: Хикәя. Икенче басма. «Корылтай» нәшере Казанда / Г. Ибраһимов.– Казань: Электро-тип. «Миллят», 1920.– 24 б.; *Аныкы ук.* Көтүчеләр // Картлык көннәрендә.– Казань: Электро-тип. «Миллят», 1920.– Б. 4–23.; *Аныкы ук.* Карт ялчы // Картлык көннәрендә.– Казань: Электро-тип. «Миллят», 1920.– Б. 24–57.; *Аныкы ук.* Яңа кешеләр: Драма өч пәрдәдә (Вакыйга 1918–1919 нчы елларда Идел-Урал тупрагында) / Г. Ибраһимов.– Казанда «Өмид» матбагасы, 1920.– 60 б.; *Аныкы ук.* Алмачуар / Г. Ибраһимов.– Казан: Татар Социал Шуралар Җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты, 1922.– 43 б.; *Аныкы ук.* Кызыл чәчәкләр хикәясе (Без түбәннән күтәрелдек) / Г. Ибраһимов.– Казан: Социал Советлар Җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты, 1922.– 148 б.; *Аныкы ук.* Адәмнәр: Хикәя / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты нәшере, 1923.– 50 б.

[1] *С*үз шушы хезмәтләре хакында бара: Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы (Революциядә сыйнфый нигезләр – Милли тарих өчен материаллар – Бу бөек хәрәкәт эчендә татарлар, башкортлар). Мөхәррире: Галимҗан Ибраһимов. Бу хезмәт Шәрыкның вакытсыз һәлак булган бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов хатирәсенә багышлана. Г. И.– Казан: Татар Социал Советлар Җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты, 1922.– 146 б.; *Аныкы ук.* Ибраһимов Г. Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә. Татарстан өлкә коми-

5

В периодической печати, журналах и газетах работаю беспрерывно.

1917 году организовал в Уфе первую социалистическую газету «Ирк» и был ее редактором.

После слияния этой газеты с органом татарских солдат, под названием «Безнен Юл»[1] также был редактором этого нового органа. Когда мы с тов[арищем] покойным Вахитовым 1918 г[оду] в январе месяце начали работать в Петрограде в Центр[альном] Мус[усульманском] Комисс[ариате] при Наркомнаце, я организовал газ[ету] «Чулпан» и был фактическим редактором этого органа.

По переезду в Казань (конец 1918 г[ода]) беспрерывно работал, писал общественно-политич[еские] и научные статьи в коммунистич[ескх] газетах и журналах, издававшихся в Казани («Эш», «Эшче», «Красный Восток»[2], «Красная армия»[3], «Татарстан»[4], «Безнен Юл»[5], «Маариф»[6] и др[угие]).

---

теты коммунист яшьләр союзы нәшере / Г. Ибраһимов.– Казан: «Татарстан» матбагасы, 1922.– 42 б.

[1] *«Безнен Юл»* – «Безнең юл» – 1917–1918 елларда Уфада чыккан авыл халкы шурасы, татар социалист-революционерлар, мөселман гаскәри комитеты оешмасы газетасы. Барлыгы 36 саны дөнья күргән.

[2] *«Красный Восток»* – «Кызыл Шәрык».

[3] *«Красная армия»* – «Кызыл армия» – 1918–1921 елларда Мәскәүдә һәм Казанда Мәркәз мөселман хәрби коллегиясе тарафыннан чыгарылган сәяси, әдәби һәм иҗтимагый газета.

[4] *«Татарстан»* – 1922–1924 елларда Казанда Автономияле Татар Социал Советлар Җөмһүриятенең Мәркәз башкармасы һәм РКП(б)ның өлкә комитеты наширлегендә чыккан газета. Барлыгы 529 саны дөнья күргән. 1920–1922 елларда бастырылган «Татарстан хәбәрләре» газетасының дәвамы буларак нәшер ителә. Алга таба «Кызыл Татарстан» (1924–1951), «Совет Татарстаны» (1951–1960), «Социалистик Татарстан» (1960–1992) дип атала. 1992 елдан хәзерге вакытта – «Ватаным Татарстан».

[5] *«Безнен Юл»* – «Безнең юл» – 1922–1930 елларда Казанда нәшер ителгән гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый айлык журнал. Татарстан Социал Шуралар җөмһүрияте Мәркәз башкарма комитеты белән Халык комиссарлары советы нәшере. 1930–1932 елларда «Атака», 1933–1965 елларда «Совет әдәбияты» дип атала, 1966 елдан хәзерге вакытта – «Казан утлары».

[6] *«Маариф»* – «Мәгариф» – 1921–1936 елларда Казанда чыккан гыйльми педагогия журналы. Алга таба «Башлангыч мәктәп», «Совет мәктәбе» дип атала, хәзерге вакытта – «Мәгариф».

Последние годы работал, главным образом, над историей РКП и историей революционного движения среди татар.

6

Преподавательско-лекторская работа началась с 1914 г[ода][1], был в 1917–19 годах перырыв, потом в Казани эту работу опять возобновил лекциями на командных курсах, в Областных партшколах и в Тат[арском] Ком[мунистическом] Университете.

Предметы преподавания те же, над чем я работаю пером.

7

Партийная принадлежность и революционная работа

Партийный стаж мне дан с 15-го апреля 1917 года.

Главные моменты работы следующие:

1. В 1905 году работал среди молодежи, участвовал в подпольных шакирдовских кружках, в т[ак] н[азываемой] подпольной подпрессе.

2. Во время реакции 1912–13 годах был в Киеве, где принимал активное участие в подпольных организациях мусульман[ского] рев[олюционного] студенчества, за что был арестован и заключен в тюрьму (в одиночку) вместе со своими товарищами (кроме меня 16 человек).

После освобождения до февральской революции находился под гласным надзором полиции.

1. Во время февральской революции в Уфе был редактором лево-социалистичес[кой] газ[еты] и чл[еном] татаро-башкирской организации ЛСР интернационалистов, организатор и пропагандист среди рабоче-крестьянских и солдатских масс. Участвовал, как выборанный делегат в двух Всероссийских мусульманских съездах (первый в Москве в мае[2], второй в Казани в июле[3]), где организовал левое крыло съезда и вел борьбу с татарской националистической буржуазией, а также был делегатом всех губернских мусульманских съездов Уфы и организовал против буржуазии социалистическую фракцию (лев[ых] с[оциалис-

[1] *Преподавательско-лекторская работа началась с 1914 г[ода]* – дөреслеккә туры килеп бетми: укыту-лекторлык эшен ул 1915 елның көзендә «Галия» мәдрәсәсендә башлый.

[2] *…первый в Москве в мае* – Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае 1917 елның 1–11 маенда Мәскәүдә уза.

[3] *…второй в Казани в июле* – Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае 1917 елның 21 июль – 2 август көннәрендә Казанда уза.

тических] р[еволюционеров] и большевик[ов] всегда среди татар шли вместе и создали единый фронт) для борьбы против всяких буржуазно-националистических организаций, вроде «Милли шуро»[1], «Харби шуро»[2], «Милли идаре»[3], «Национальный парламент»[4] и т.д. (по этому вопросу имеются материалы очень подробные в татарской печати).

2. Во время октябрьского переворота был в Уфе. Там переворот совершился без капли крови по двум причинам: во-первых, буржуазия была слаба, не организована и не имела никакой военной силы вроде юнкерских школ и т.п. Во-вторых, громадное большинство местного гарнизона составляли татарские солдаты, которые до октября были подготовлены под лозунгом «Вся власть Советам», и уже это настроение выявлялось заранее на демонстрациях которые мы устраивали вместе с русскими большевиками.

Я лично все время и после переворота непосредственно работал в среде татарской солдатской массы как пропагандист,

---

[1] *«Милли шуро» – «Милли шура»* – Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае карары белән 1917 елның маенда Петроградта оештырыла. Милли шураның эшчәнлеге Совет хакимиятенең 1918 елның 22 май карары белән тыела.

[2] *«Харби шуро» – «Хәрби шура»* – мөселман гаскәриләренең югары сәяси оешмасы. Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае карары белән 1917 елның июлендә Казанда оештырыла. Рәисе – прапорщик Ильяс Сәетгәрәй улы Алкин (1895–1937). РСФСР Милләтләр эше халык комиссариатының 1918 елның 24 март Декреты белән Хәрби Шураның үзәк оешмасы, шул елның 24 апрель карары белән аның Мәскәү бүлеге, 22 май карары белән Милли Шура карамагындагы бүлеге бетерелә.

Бөтен тирә-якта дан тоткан ике алмачуар чабышкының анасы!!

Җитмәсә тагы карынында бер колын бар!

Бундый бер хәл һичкемнең башына сыя алмый. Безнең күрше карчык Фәтхия әби башкорт баһадирның үз күзе алдында ук:

– Балалар, бу эш хәерлегә булмас! Моның астында берәр хәйлә бардыр,– ди. Безнең кардәш Сафа карт та, ак сакалын сыйпап, бу сүзне куәтләп куя:

– Китапча итеп әйтсәң инде,– ди,– мин әйтәм, ди,– таштан су чыгар, усак агачы алма бирер, ди, Әбуҗәһел иманга килер; – әмма, ди, Әлемгол бай, ди, бу данлыклы бияне карынындагы колыны белән тиктән-тик Хафизга китереп бирмәс, монда берәр этлек юкмы икән, балалар,– ди...

Башкорт боларның һәммәсен тыныч кына тыңлап тора да, бераз елмаеп, кара күзләрен тагы ныграк җылтыратып, үзенең хәлен сөйләп бирә.

Ул сөйләгәч, халыкның аптыравы шатлыкка, хәер-догага әйләнә.

II

Безнең әткәй Мөхәммәтхафиз исемле булса кирәк. Буйга зурлыгы өчен аны Озын Хафиз дип йөртәләр.

Ул яшь чакта имән кебек таза, лачын кебек үткен, арыслан кебек гайрәтле булган, дип сөйлиләр. Тирә-якта теләсә сугышка булсын, теләсә көрәшкә булсын, аңа тиңдәш, охшаш чыкмаган. Иң зур Сабан туйларында да ул әллә кайлардан килгән данлыклы көрәшчеләрне шаяртып кына чөеп ташлый торган булган...

Менә бервакыт Чишмәдә зур Сабан туе ясала.

Асыл сөяк чабышкы атлар, үз тирәсендә исем казанган көрәшчеләр, шәп йөгерүче егетләр бу җыенга йөзәр чакрымнан киләләр – көч сынамакчылар, үзләрен күрсәтмәкче, дан алмакчылар.

Көрәш башлана.

Ни күрәсең? Хафизга кем чыдасын!

Безнең әткәй чыккан бер баһадирны аз-маз шаярта да чөеп үк ташлый.

Ахырдан килеп чыга ябык, чандыр бер кара башкорт.

Ике баһадир билләрен берәр тартып сыныйлар да, бер-берсенең сыртларына кулларын салган хәлдә, бөтен халыкның күзе астында, түгәрәк мәйданда әйләнәләр.

Йа Ходай! Бу ни эш?!

Кинәт данлыклы Хафиз тәгәрәп-тәгәрәп китә дә чалкан барып төшә!

Мәйдан гөж килә. Әткәйнең дустлары бу хурлыкка чыдый алмыйлар:

— Башкорт хәрәмләде, аяк чалды! — дип шау-шу күтәрәләр, яңадан көрәшергә чыгуны сорыйлар.

Ике як та риза була. Баһадирлар тагы түгәрәк мәйданда. Бөтен халык тагын, тыннарын да алмыйча, бу зур көрәшкә карап катканнар!

Ал аякларын бер-берсенең сыртларына салган арыслан белән юлбарыс кебек, ике ир каһарман ярты сәгать буенча, бер-берсенең билләреннән алган хәлдә, мәйданны урап йөриләр.

Тагы кинәттән, һич көтелмәгән бер секундта, башкорт каһарман сиздермәстән генә кысып ала да үзе җиргә ята, баш очыннан Хафиз баһадирны шундый көч белән селтәп җибәрә ки, ул, әллә кая барып, сул кулы өстенә бик каты егыла...

Халык шау-шу килә. Мәйдан кайный!

Безнең әткәй исә тиз генә бер якка чыга да Зариф остага кулын күрсәтә:

— Сынганмы, чыкканмы?

— Зарар юк, чыккан гына,— ди.

Мин ул вакыт бик бәләкәй идем, шулай да хәзерге кебек күз алдымда тора:

Сабан туе элеккечә шаулап калды, әткәй, күп баһадирларны җиңеп алган кызыл башлы сөлгеләр белән яшел чапанны бер як кулбашына асып, акрын гына кайтып китте. Мин аңар сүз дәшәргә курыктым; әллә тирләгәнгә, әллә ачуланганга, аның йөзе кара көйгән иде.

Ахрысы, бик гарьләнгәндер:

— Җитәр инде: заманында көрәштек, бусы— актыгы булыр! — диде.

Һәм сүзендә торды:

Шуннан соң Сабан туйларына аяк атламады (тик телләрдә генә аның баһадирлыкларын әкият итеп сөйләргә калды).

III

Аңа байтак заманнар үткән иде инде. Шулай да ул көннәр бөтен авылның хәтерендә иде. Шуңа күрә башкортның безнең әткәй белән көрәшеп, аны җиңүен сөйләгәндә:

— Без боларны беләбез...— дип тордылар.

Әлемгол, ачуланып, халыкка күз ташлый да:

– Шулаймы? Сез татарлар да боларны беләсезме? Әмма менә җиңүче башкортның йөрәгендә аннан соңниләр булганы сезнең төшегезгә дә кермәгәндер,– ди.

– Хафиз агакай,– ди,– мин сине екканда хәйлә ясадым... Үзеңә дә, карап торучыларга да сиздертмәстән, уң аягыңны бераз чалдым... Бу вакыт күңелемә бер шик килде. Шулай да үземне тыя алмадым,– ни булса, шул булыр, бәлки, бер юлга Ходай кичерер дидем дә шул хәрәмләвем аркасында сине баш аша чөйдем...

Күңел әүлия – диләр бит, дөрест сүз икән: Сабан туеннан кайтып та җитәм, түшәккә дә егылам: эчем бора, сул кабыргам астында нәрсәдер тырный, чәнчә башлый. Шуның белән өч ай акырып ятам, ашаганым – аш, эчкәнем – су булмый... Шул каты хәстә чагымда: «Бу авыру Хафизга каршы хәйлә эшләп, аны рәнҗетүдән килгәндер, терелсәм, бурлы биямне аңа дога кылдырырмын»,– дип нәзер әйткән идем.

Терелдем. Нәфес – шайтан бит: «Әй, ул татарның рәнҗеше төшәме соң!!» – дип уйладым. Бияне бирергә кызгандым.

Берничә ел үткәч, тагы шул хәстә: эчем бора, сул кабыргам астында нидер тырный, нидер чәнчә...

Һич түзәр хәлем калмады, бөтенләй аптырыйм. Шул вакыт әллә качан үлгән бабам үзенең зур ак сакалы, ак кәфене, ниндидер зур яшел таягы белән минем төшемә керә, миңа шелтәләп карый, ачулы тавыш белән:

– Ахмак бала: сиңа җан кыйбатмы, бурлы бия кыйбатмы? – ди. Үзе шунда ук гаиб була.

Терелсәм, бер көн кичекми илтеп бирәм,– дип тагы нәзер әйтәм... Күрәсез, мин терелдем. Менә нәзеремне үтим.

Картлар бөтенләй хәйран калдылар. Сафа бабай башкортның аркасыннан кага:

– Китапка язган кебек сөйлисең: этлеккә генә түгел, яхшы сүзгә дә синең акылың, телең итә икән,– ди.

Башкалар да рәхмәт укыйлар, яңадан чүгәләп дога кылалар.

– Хафизның бик авыр еллары иде. Угылы белән кызыннан да аерылган чагы иде; бурлы бия җиңел аягы белән килгән булсын! Бу йортка бәрәкәт китерсен! – диделәр.

Башкорт китә, картлар таралалар.

## IV

Картларның сүзе дөрест: безнең йортның, чынлап та, авыр еллары иде. Әткәй кебек зур, таза, баһадир, сылу абзамны нахак бәлагә эләктерделәр. Авылымызда бик череп беткән бер кара бай бар иде. Акчасы күп, имеш; күкрәкчә ясап, янында йөртә, имеш, дип сөйлилиләр аның хакында. Ул бай белән безнең әти арасында, ниндидер бер җир талашы сәбәбеннән, әллә качаннан бирле дошманлык бара иде. Кыш көне шул кара черегән байны, каядыр китеп барганда, урманга алып кергәннәр дә авылдан бер чакрым җирдә көпә-көндез суйганнар. Гөнаһ шомлыкка каршы, шунда ук бетерә алмаганнар. Өенә кайткач, үләр алдыннан, әзрәк һушына килеп, бөтенләй нахактан:

— Башкаларын танымадым... Берсе Озын Хафизның угылы Шәяхмәт иде...— дигән.

Абзыйны шул сәгатьтә үк богаулап алып китәләр. Хөкем була.

Әткәй, бу нахак бәладән коткарыйм дип, көн чаба, төн чаба. Бөтен авылда теге мәлгуньнең дошманлыктан гына әйткәнен беләләр. Әткәй, коткарам дип йөри торгач, актык атыннан, сыерыннан яза, абзыйны егерме елга каторгага хөкем итәләр... Без бөтенләй фәкыйрьлеккә калабыз...

Шул кайгы җитмәгән кебек, бердәнбер абыстай да түбән очның гармунчы Фәхригә ябышып чыга. Ул инде яшьтән үк бик башсыз кыз иде: аулак өй булса, биегән дә ул, җырлаган да ул, гармун тарткан да ул, егетләрне кертеп, аякларыннан түшәмгә асып мәсхәрә кылган да ул...

Шулар аркасында аты-чабы чыгу белән генә калмады, ул, әтинең: «Быел еллар авыр, бераз сабыр итик»,— дигәнен тыңламастан, Фәхри белән күрше авылга барганнар да никах укытып кайтканнар.

— Безгә фатыйха бирегез, без ирле-хатынлы булдык инде,— ди.

Әнкәй бик җылап карады: «Үз balaң бит, кич»,— диде. Әткәй:

— Егеткә сүзем юк, хәлле чагым булса, туйлап бирер идем; Гайния минем авыр елымны хәтергә алмады...— дип, аларны куып чыгарды.

Әнкәй һаман, сүз уңае саен күз яшьләрен сөртә-сөртә:

— Картым, ачуланмасаң, балаларны кунакка чакырыр идем,— дип ялына иде. Әмма әткәй үз сүзеннән кайтмый:

— Мин үлгәч чакырырсың! — дип кырт кисә иде...

Картларның «авыр ел» дигәне менә шулар иде.

Аларның догасы кабул булды. Башкорт биясе безнең йортка җиңел аягы белән килде һәм үзе белән безнең йортка бәрәкәт тә китерде: атсызлыктан газап чиккән әткәй бу — моңарчы муены камыт күрмәгән симез бияне ике көн эчендә җигәргә өйрәтте дә дөнья җимереп эшләргә тотынды. Һәм шундый бәрәкәт булды инде: көз көне безнең әткәй шул кәсептән, йөрүдән, игеннән җыелган акчага икенче ат та алды. Башкача да йорт-җирне байтак төзәтте. Без бурлы бия аркасында аякка бастык.

Әмма, әмма бу көз минем өчен зур кайгы булып төште.

Нә арба, нә чана вакытта әткәй, бурлы бияне җигеп, урманга барган иде. Кайтканда, елга аша чыкканда, таеп егылган да, бия колын салган.

Әле өч-дүрт айлык кына иде. Шулай да йон чыккан иде, ди. Үзе мәчедән зуррак иде, ди.

Буны ишеткәч, мин көн җыладым, төн җыладым; ничек җыламассың, бурлы бия бит ике алмачуар чабышкы биргән. Буаз дигәч, мин инде аның булачак колынын, әлбәттә, алмачуар дип, чабышкы дип башыма да утырткан, бөтен иптәшләргә дә мактанып беткән идем!

Шул каһәр төшкән тайгак юл мине мәхрүм итте бит!

Әнкәй җылаган өчен мине һаман орыша:

— Бу чаклы тиле булырсың икән,— ди,— тумаган тай өчен шулай җылыйлармыни? — ди.

Әткәй ачуланмый, ике өлкән баласының хәсрәтеннән соң бөтен йөрәген миңа баглаган булса кирәк, ул мине ярата, сүземне тыңлый, һәрвакыт иркәли:

— Җылама, балам,— ди...— Хәзер ике ат булды инде... Башкортка илтеп, алмачуар айгырдан чаптырырбыз да киләсе җәйгә бер дә җикмәбез...

Сиңа алмачуар тай булыр,— ди.

Мин җәйне, кышын гына түгел, хәтта атналар, көннәр үтүен дә бармак белән санап барам...

Кыш үтеп бара, шулай да бик күп көтәсе әле...

## V

Көткән көннәр якынлыйлар.

Бурлы бия буаз. Без хәзер аны җикмибез. Җиксәк тә, бик җиңелгә, якынга гына. Әнкәй аның өчен һаман сукрана:

— Ике атың бар өстеннән, нәрсә шул хәерче кебек лырт-лырт бер белән йөрисең?— ди.

Әткәй аны бер сүз белән туктата:

– Җә, куй шул сукрануыңны,– ди,– нигә,– ди,– баланы юкка җылатырга,– ди.

«Бала» дигәне мин булам.

Чыннан да, берәр авыр йөккә, ерак җиргә җигә башласалар, мин әткәйгә барып сыенам, иркәләнәм; ул минем күзләремдә мөлдерәп төшәргә-ташарга торган күз яшьләремне күрә дә, мыек астыннан көлеп, башымны сыйпый:

– Җә, син, Закир, юкка җылап барма... Ярар, җикмәбез,– ди.

Мин шатлыгымнан кая сикерергә урын тапмыйм. Көн буена аягым кая басканны белмим. Ни кушсалар, минуты белән эшлим.

Кайберәүләрнең бияләре кар эри башлагач та колынлады; язгы сабанга чыккач инде, авылда һәр йортта диярлек колыннар күренә торган булды.

Әнә алар нинди уйнаклап йөриләр. Әнкәләреннән аз гына калсалар, үзләренең яшь, көмеш тавышлары белән бөтен тауны, урманны яңгыратып кешниләр.

Их, качан минем колын да шулай булыр икән?!

Хәер, күп көттермәс инде: биянең эче калынайганнан-калыная бара. Сафа бабай әйтә, озакламас, колынлар инде, ди. Күз-колак була торырга кирәк, ди...

Малайлар мине һаман:

– Сөенчегә нәрсә бирәсең, Закир? – дип шаярталар.

Шауламагыз, бирәсе әйберем әллә качан әзерләнгән. Тик тизрәк тусын гына!!

Соңгы көннәрдә әткәй белән бик нык бәрелешү дә булып алды.

Колын итен бүреләр бик яраталар булса кирәк. Фәхриләрнең матур бер колыны бар иде. Төнлә шуны бүре яралаган, ди. Кичә шуны ишеткәч, әтидән сорамыйча-нитмичә, нукта[1] тоттым да йөгердем. Бияне яланда калдырырга ярамый. Кем белә, төнлә очрар да, колынны бүре ашап та китәр!

Бия ерак түгел икән. Тиз таптым. Тотар өчен икмәк катысы да алып барган идем. Элек ул, аз гына кул сузып чакырсаң, үзе үк килә торган иде... бу арада әллә ничек үзгәреп тора: юк-барга ачулана, якын барсаң, өстеңә йомылып килә.

Әле дә бардым. Икмәкне күрсәтеп чакырдым. Элекке кебек тоттыру кайда, пырх-пырх итеп, үзалдына холыксызланып, кы-

[1] Нукта – киң каештан эшләнгән авызлыксыз йөгән.

зып тора. Мин, аны тота алмый, җылап кайттым да әтигә ялына башладым:

– Колынлар чагы җиткән,– дим,– йортта гына асрыйк... Мин аны үзем карар идем,– дим.

Әти риза булмый:

– Ашатырга азык юк... бернәрсә дә булмас, шунда болында, елга буенда йөрсен,– ди.

Мин җыларга тотынам. Бүре куркынычын сөйлим.

Әти һаман үзенекендә тора:

– Акылсыз булма: авыл янындагы болынга бүре килми ул,– ди.– Йортта ашатырга җүнле нәрсә юк, монда тотсаң, колыны начар булыр,– ди...– Бик курыксаң, малайлар белән көндез каравыллап йөр, кич өйгә кайтарырсың,– ди.

Бияне яхшы ашатмасаң, колыны начар була, дигән сүз мине җинде. Мин башаяк риза булдым.

Тавык ояларыннан йомырка урладым. Яшереп куйган шырпыны алдым да, шуларга алдап, малайларны үзем белән елга буена, болынга, бия каравылларга алып китәргә әзерләнә башладым.

Көн матур. Язгы кояш нуры минем күзләремә карый; ул, ахрысы, минем шатлыкны сизәдер, бераз елмайган кебек тоела.

Йомырка белән шырпы барлыгын белгәч, малайлар сикерә-сикерә минем белән бия сакларга бармакчылар.

## VI

Мин бер атуда ике куянны алмак булам: бияне дә сакларга, балык та тотарга.

Балык дигәч, малайлар бары беравыздан Кондызлы күл[1] ягына тарталар:

– Анда каптырырга да әйбәт, менә дигән чуртаннар, алабугалар да эләгә...– диләр.

Фәхри малае Апуш күзләрен җылтырата-җылтырата сөйли башлый:

– Без өченче көн,– ди,– иртән, көтү киткәч, барган идек, кояш төшлеккә җиткәнче каптырдык... Галәви – утызны, мин егерме дүртне алдым... Арада беләк җуанлыгы кызылканатлар бар иде, бик зур бер җәен эләккән иде, җебем чыдамады – кармакны өзеп алып китте,– ди.

[1] Кондызлы күл – Солтанморат авылыннан ерак булмаган күл.

Боларны ишеткәч, башкаларның да күзләре кыза, барысы да риза булып, шул Кондызлы күл ягына йөгерергә торалар.

Кызылканатлар, җәеннәр дигәч, мин дә, үземне-үзем онытып, иптәшләргә кушыла язган идем, бүген-иртәгә колынларга торган бурлы бия хәтеремә килгәч, кинәт туктадым:

– Юк, мин анда бармыйм,– дим,– әйдәгез Өзән елгага[1] барыйк, анда да шәп каба,– дип, бурлы бия ягына тарта башладым.

Мин ялгыз идем.

Шулай да җиңдем: минем ак киез эшләпәгә тутырылган йомыркалар белән шырпыны исләренә төшергәч, малайлар риза булдылар. Шул ук Апуш:

– Кармакларны, селәүченнәр, икмәкләр, йомыркалар, шырпыларны алабыз да кыйбла якка, якты кояшка карап, болын буйлап Өзән елгага чабабыз...

---

Алабугамы, сазанмы эләгер, бөтенләй буш кайтырбызмы – миңа алары кыйбат түгел: минем бүген-иртәгә колынларга торган бурлы бия Өзән елга буенда, болынлыкта йөри. Әткәй аның муенына зур арканны бәйләгән дә тышауламый-нитми генә җибәргән. Арканның икенче башына кызыл калын дуга тагылган. Минем бөтен күңелем менә шул дугасын, арканын өстерәп, су буенда, таллар арасында акрын гына йөргән бурлы биядә.

Без авылдан чыкканда, көн матур, җил юк иде. Болында безне кошлар сайрап каршы алдылар. Минем булачак колынымның әнкәсе, без барып җиткәндә, Әчеле тамак ярында ашамый-нитми, башын түбәнгәрәк салып, тик кенә тора иде. Ул миңа нәрсәдер уйлый кебек тоелды. Малкаем, син ни турында уйлыйсың? Аны күргәч, малайлар мине үрти-үчекли башладылар. Берсе әйтә: айгыр булыр, ди; берсе: бия булыр, ди... Миңа барыбер, тик исән-сау гына күрергә язган булсын иде.

## VII

Безнең бия йөргән җиргә якын гына зур яту бар. Бу Әчеле тамакның түбән ягында, шуның белән янәшә генә. Монда өч яктан өч елга килеп кушыла. Болар кушылалар да ул җиргә чаклы кечкенә бер «кул» гына булып агып яткан Өзән елганы берьюлы зурайтып җибәрәләр. Боларның суларын үз эченә алгач, безнең Өзән елга киңәеп, тулып китә: әллә ничек олуг сыман булып, мәһабәт булып ага башлый.

[1] Өзән елга – Солтанморат авылы яныннан ага торган елга.

Яратам мин үзебезнең авылны! Бигрәк тә яратам авылның төньягын каплаган зур тауларны! Аңардан да бигрәк яратам шул таулар өстендә мең еллар буенча шаулап утырган зур карт урманны!!

Дөрест, бу урман хәзер безнеке түгел, аны әллә ничек итеп безнең кулдан бер бай тартып алган; хәзер безгә аннан бер чыбыркы сабын алырга да ярамый! Шулай булса да, бу урманның гөрләп утыруы, бигрәк тә аның язгы кузгалагы, көпшәсе, җәйге чәчәкләре, исәбе-хисабы булмаган җир җиләге, кура җиләкләре, карлыганнары, бигрәк тә күзге чикләвекләре минем күңелемне ул урманга тарталар, аны йөрәккә якын, бик якын, бик сөйкемле итәләр...

Бу урманнан да бигрәк, миңа шул өч яктан килеп төшкән «кул»ларның суларын үз эченә алгач, ярдан-ярга тулып аккан сабыр, мәһабәт Өзән елга буйлары әллә ничек кадерле тоелалар...

Беләсе иде, кайдан чыга, кайларга бара икән бу сулар!

Беләм, бик беләм: таулар, болыннар буйлап килеп, безнең авылның буеннан аккан бу елга – Өршәккә[1], Өршәк – Димгә[2], Дим – Ак Иделгә[3] коя.

Ак Идел кая барадыр – анысын бер Алла белә.

Тик бик күп дөнья гизгән Сафа бабай гына кайвакыт сөйләп куя: көз көне кошлар китә торган якта, ди, Әчтерхан дигән бер зур шәһәр – борынгы ханнар шәһәре[4] бар, ди, шуның аръягында, ди, гаҗәп зур бер диңгез бар[5], ди. Ак Идел, ди, бик күп авыл-

---

[1] Өршәк – Агыйделнең сулъяк кушылдыгы. Башкортстан Республикасы Стәрлебаш районы Югары Гөлем авылыннан өч километр көньяктан башланып, Стәрлебаш, Стәрлетамак, Авыргазы, Дәүләкән, Кырмыскалы, Чишмә, Уфа районнары җирләреннән ага.

[2] Дим – Агыйделнең сулъяк кушылдыгы. Башкортстан Республикасы Фёдоровка районындагы Стәрлебаш-Фёдоровка калкулыгыннан башланып, Бишбүләк, Миякә, Әлшәй, Дәүләкән, Чишмә, Уфа районнары җирләреннән ага.

[3] Ак Идел (Агыйдел) – Чулман елгасының сул кушылдыгы. Ул хәзерге Башкортстан Республикасындагы Учалы районына караган Яңа Хөсәен авылыннан дүрт километр ераклыктагы Әвәләк сыртының көньяк итәгеннән башланып, Учалы, Белорет, Бөрҗән, Мәләвез, Күгәрчен, Куергазы, Стәрлетамак, Ишембай, Гафури, Авыргазы, Кырмыскалы, Архангель, Иглин, Уфа, Благовещен, Бөре, Дүртөйле, Борай, Илеш, Краснокама районнары җирләреннән ага.

[4] Әчтерхан дигән бер зур шәһәр – борынгы ханнар шәһәре – хәзерге Әстерхан өлкәсенең башкаласы. Идел елгасының ике як ярына, дельтасының югары өлешенә урнашкан. Аның хакында беренче хәбәрләр 13 йөзгә карый.1459–1556 елларда Әстерхан ханлыгының төп шәһәре була.

[5] …шуның аръягында, ди, гаҗәп зур бер диңгез бар – Каспий диңгезе күз алдында тотыла.

лар, шәһәрләр, таулар, кара урманнар эченнән агып, айлар еллар буенча бара-бара да, ди, әнә шул олуг диңгезгә барып коя, ди; сез моннан бер йомычка салып җибәрсәгез, ди, ул. Ди Өршәкләр, Димнәр, Ак Иделләр буйлап агар-агар да әнә шул ерак диңгезгә барып төшәр, ди... Их, күрәсе иде ул диңгезләрне!!!

---

Мин әллә нинди уйлар белән бурлы бия тирәсендә, аңардан күземне ала алмый уралып йөргәндә, тегендә, яр башында балып каптырып йөргән малайлар миңа кычкыра башлыйлар:

– Закир, Закир, шырпы белән йомыркаларны китер, тизрәк ягабыз да көлдә пешерәбез,– диләр.

Кармакларны ташладылар; уйнап, шаярып, көрәшеп, янган ут тирәсендә йомыркалар пешүен саклыйлар.

Безнең яннан гына Өзән елга һаман ага да ага... Минем хәтеремә бабайның сүзе килде.

– Беләсеңме, Апуш,– дим.– Бу елга кая коя? – дим.

Ул бик усал нәрсә:

– Бер йомырка артык бирсәң, барын да сөйләп бирәм,– ди.

– Ярый,– дим,– бирермен.

Ул, юеш балчыкны йомарлап, әллә кайларга, күздән югалырлык итеп югары ыргыта да бармак белән санап көйләргә керешә:

– Өзән елганы күрәсеңме? – ди.– Күрсәң, карап тор, – ди... – Бу елга, – ди, – унике чакрым җиткәч, Өршәккә төшә, Өршәк Димгә кушыла, – ди... – Дим матур болыннар арасыннан бара-бара да Өфе дигән зур кала янында, әллә нинди биек таулар каршында, Ак Иделгә барып чыга,– ди...

Кемдер аның сүзен бүлә:

– Ак Идел кая бара?

Апуш тагы балчык йомарлый да, баш өстебездән очып барган торналарга төзәп, һавага очыра...

– Ак Иделме? – ди.– Ак Идел инде, – ди, – урманнар, таулар, калалар ашасыннан бара-бара да әчтерхан диңгезенә төшә,– ди.

Малайлар кычкырыша башлыйлар.

– Егет син, Апуш: ал бер йомырканы,– диләр.

Апуш биргәнне дә көтми, бер йомырканы миннән тартып ала да ашарга тотына.

Аяк астында бер зур йомычка ята иде, шуны алдым да, малайларга күрсәтеп:

– Әйтегез,– мин әйтәм,– Өзән елгага салып җибәрсәм, менә бу нәрсә шул кыйбла ягындагы ерак диңгезгә барып төшәрме, юкмы?..– дим. Йомычканы ярдан-ярга тулып аккан Өзән елганың киң күкрәгенә ташлыйм. Дулкыннар аны кочаклап алалар да, ашыктырып-ашыктырып, үзләре белән түбән таба алып китәләр.

Малайлар талашырга тотына.

Апуш:

– Тукталмас та, батмас та, диңгезгә барып төшәр,– ди...

Башкалары:

– Барып җитә алмас, су белән авыраеп батар яисә, читкә чыгып, камыш арасында туктар,– диләр.

---

Инде төш тә ауды...

Йомыркаларны ашап бетердек тә, кармакларны, балыкларны күтәреп, Өзән елга буйлап кайтырга чыктык. Малайлар: «Килү бушка китмәде»,– диештеләр. Унар-унбишәр балык алганнар. Арада зуррак чабаклар, алабугалар, кызылканатлар бар.

Мин, күздән югалганчы, биягә борылып, карый-карый бардым.

Ул һаман шул хәлендә: ашамый, урыныннан кузгалмый, башын бераз аскарак салган да тик кенә тора. Нидер уйлый, нидер уйлый.

Их, беләсе иде: нәрсә уйлый икән минем бурлы биям?!

VIII

Өйдә табак тутырып бәрәңге пешергәннәр. Мин эттән яман ачыкканмын икән. Күземә ак-кара күренмәде, каз йомыркасы зурлыгындагы бәрәңгене тозлап-тозлап, арыш икмәге белән бөгәргә тотындым.

Үзем авыз тулы көенчә бурлы бия турында туктамый һаман сөйлим.

Әнкәй бер көлә, бер ачулана:

– Сиңа, ахры, ат җене кагылгандыр, торсаң – шул, ятсаң – шул, бер белгәнең шул булды,– ди...

Мин, аның белән карулашырга уйлап, авызымны гына ачкан идем, түбән очның Фәхринең зур улы Сәппәр урам як тәрәзәдән баш тыкты да, ут чыккан кебек, акырып җибәрде:

– Закир! Закир! Сөенче! Бурлы бияң колынлады,– ди.

Ни эшләгәнемне белмим, әни, аптырап:

– Ай, бу бала харап була инде шул мал өчен! – дип, кычкырып калды, мин, ашъяулыклар, табаклы бәрәңгеләр өстеннән атылып, йортка чаптым.

Әткәй бакча буенда арба төзәтеп маташа иде. Туры аңа ташландым.

– Әткәй, әткәй, әйдә тизрәк, бия колынлаган,– дип акырам.

Гаҗәп яратам мин әткәйне! Ул әз генә дә ачуланмады, минем сүзне ишетү белән, урыныннан торды да коймага эленгән нуктаны алды:

– Кем әйтте, сөенче бирдеңме?

Ул арада капкадан Фәхри малае Сәппәр сөенче сорап килеп керде...

Минем, каз кавырсыннары, чүпрәкләр сатып, сөенчегә дип әзерләнгән алты тиен акчам бар иде. Карап та тормадым, яшергән җирдән тиз генә алдым да Фәхри малаена китереп тоттырдым.

Без әткәй белән Өзән елга буена колынны алырга киттек.

IX

Шәп маллар аякланып туа, диләр.

Ахрысы бу сүз дөрестер.

Без барып җиткәндә, колын үзенең әле бик ныгып бетә алмаган нечкә аяклары белән саклана-саклана басып йөри башлаган иде инде.

Бичаракаем, бик ачыгып туган, күрәсең: әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, әнкәсенең сөт белән тулып каткан имчәкләрен суырып азаплана.

Бу арада бурлы бия бик артык холыксызланып киткәнгә, мин аның янына барырга курыктым. Үзенең нуктасы белән аңа якын килә башлагач та, ул, баласын бирмәскә тырышкан ана арыслан кебек әллә нинди яшел тавыш белән чинап, әткәй өстенә ташланмакчы булды. Йомылып тешләргә, чыелдап, колынының әле бер, әле икенче ягында йөгереп тибәргә итеп карады.

Ләкин безнең әткәй курку дигәннең нәрсә икәнен белми. Маллар да аның болай икәнен аңлыйлар булса кирәк. Биянең дулавына – тешләргә, тибәргә омтылуына карамастан, әткәй туры барды да муенына нуктаны ташлады; алай-болай иткәнче, бурлы биянең башы калын нукта эченә кереп тә өлгерде. Мин аптырап, хәйран булып тик тордым. Шатландыммы, юкмы – белмим.

## X

Тик өйгә алып кайтып, бияне кое баганасына бәйләп куйгач кына, мин үз-үземә исәп бирә алырлык булдым.

Колын чыннан гаҗәеп бер нәрсә иде:

Аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар. Бәкәлләре озын, шундый нечкә, озын ки, бундыйлар тик чабышкы атларда гына була, диләр.

Әле яңа гына кибеп килә торган койрыгы белән ялы, әз генә, кыска гына булсалар да, озаклап үреп, кабартып ясаган җефәк бәйләме кебек үзеннән-үзе дулкынланып торалар. Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәк турыннан, бармак калынлыгы кара тасма кебек булып, койрыктан ялга җиткәнче, кара җефәк җон сузылган. Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын яра кашка – бу колынны, мең миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз итеп күрсәтәләр.

Бөтен гәүдәсе әйтерсең, Ходайның үз кулы белән, фирештәләрнең ярдәме белән тигезләп, матур итеп, коелып ясалган. Шундый сылу, шундый асыл сөяк булып яратылганнар.

Төсе хакында аптырап калдым. Кара түгел, күк дип тә булмый. Анасы кебек саф бурлы да түгел – ничектер, күгелҗем ак чәчәк төсе кебегрәк булып ялтырап тора.

Бер самавыр кайнарлык вакыт үтмәгәндер, йортка бала-чага җыела башлады. Бары да, авызларын ачып, хәйран булып, бу асыл сөяк колынга карап каталар.

Кайдандыр ишетеп, безнең Сафа бабай да сакалын җилбердәтеп килеп керде. Ул бөтен тирә-якка ат тану белән дан тоткан кеше.

– Йа Ходай, ни әйтер? – дип, мин аңа карап каттым.

Колынны күрүгә бабайның йөзе ачылды:

– Сөбханалла... Сөбханалла... Күз тимәсен... Бу колын да үзенең элекке ике агасына охшаган икән,– диде.

Дәшми-тынмый тагы бик озак карап торды да:

– Шулай, шулай! Янлышмыйм, бу да нәкъ агалары кебек...– диде.

Әти, миңа белдермичә генә, әллә качаннан кечкенә генә көмеш кыңгырау алып куйган икән. Әни кызыл тасма бирде.

Карт акрын гына, оста гына килеп, колынны кинәт кенә кочаклап алды да:

– Бисмилла... Сөбханалла. Яман күздән, эт-бүредән Ходай сакласын,– дип, догалар укый-укый, минем айгырымның муенына шул кызыл тасма белән кыңгырауны такты.

Тагы бераз читкәрәк китеп карады да әткәйгә:

– Беләсеңме, Хафиз, бу нәкъ агалары кебек булыр, төсе дә тиз арада алмачуарга әйләнер... Хәерле булсын, хәсрәтең зур иде, ике өлкән балаң хафасы сине бик картайткан иде, бурлы бия бу йортка җиңел аяк белән килде, бәрәкәт китерде,– диде.

Ике өлкән агасын хәтергә төшерү һәрвакыт безнең әткәйнең йөрәгенә авыр була; мондый чакта ничектер аның тавышы үзгәрә, сүзләре башкачарак чыга. Мин, аптырап, күзләрендә яшь юкмы дип, аңа карыйм.

Юк, ул җыламаган. Шулай да әсәрләнгән. Әллә нинди эчке тавыш белән:

– Сөйләмә инде, Сафа абзый, ул ике балам адәм түгел, лачыннар, арысланнар иде. Үзләре дә бәхетсез булды, минем дә вакытсыз чәчләремне агарттылар...– диде.

Бераз туктап торып:

– Язганы шулдыр инде... Менә бар өмет бу кечкенәсендә,– дип кушты.

Сафа бабай тагы, теләкләр теләп, колынны мактады да минем колагымнан шаярып тартты:

– Закир, бәхетең зур икән: башкортның бурлы биясе атаңны аякка бастырды, сиңа алмачуар колын бирде, бу колын ике агасы кебек асыл сөякләрдән... Күз тимәсен, бу да чабышкы булыр...– дип сөйләнә-сөйләнә чыгып китте.

Мин кая басканымны белмим. Бер көндә әллә ничаклы үскән кебек булдым:

Уенмыни?! Минем колыным бар. Ул айгыр! Төсе алмачуарга әйләнәчәк! Тирә-якта дан тоткан ике агасы кебек чабышкы булачак!

Әнә күреңез: ул ничек көмеш тавыш белән яңгыратып кешни! Ничек асыл сөякле гәүдәсе белән матурлап сикереп уйный!?

## XI

Шул көннән алып Алмачуар минем тормышымның үзәге була. Шатлыкларым, кайгыларым шуннан чыга, шуңа кайталар. Төшемдә шуны күреп саташам. Иртән торуга, киенмәстән, битемне юмастан, мин азбарга, Алмачуарны карарга, аның исәнлеген белергә йөгерәм.

Исән, бик исән!

Ул, әкияттәге баһадир кебек, ай үсәсен көн үсә, үзе көннән-көн матурлана, асыллана бара. Хәзер авылда аңа тел тидергән кеше юк. Һәркем аңа:

Күз тимәсен, сөбханалла! Бигрәк асыл сөяк нәрсә икән! Яхшы нәселдән шул!— дип кенә карыйлар.

Тирә-якта асыллыгы, сылулыгы белән генә түгел, тавышы, җиңел, җитез, килешле һәм акыллы уйнавы белән минем Алмачуарга тиңдәш булырлык бер колын күренми дә, ишетелми дә.

XII

Җәй, аның артыннан көз үтеп китә. Әллә нинди карлы, яңгырлы, болытлы чаклар килә. Мин иртәгә «Покрау» бәйрәме[1] дигән көндә ничектер иртәрәк уяндым, шулай да торырга иренеп ятам.

Кайдадыр кемнәрнендер нәрсә хакындадыр ашыгыч-ашыгыч сөйләшкәннәре ишетелә.

Нидәндер йөрәгем шу-у... итеп китте.

Колак салдым:

Әткәй белән әнкәй чаршау артында пыш-пыш сөйләшәләр. Тавышларында әллә ни бар: куркалармы, кайгыралармы, нәрсәдәндер, кемнәндер яшерергә телиләрме? Бернәрсә белмим.

Син аңа белдермәскә тырыш! Ишетәмсең? — диде дә әткәй, кулындагы арканын җилкәсенә салып, тиз генә чыгып китте.

Мин тагы курка төштем.

— Ни бар, әнкәй, ни бар?— дип, әнкәйнең итәгенә барып асылдым.

Юк, балам, бернәрсә дә юк... Сиңа торырга иртә әле, бар, ят... Менә мин мичкә ягам да белен пешерәм... Самавыр кайнагач, эссе беленгә уятырмын,— диде.

Күңелем тынычланмый, ятсам да, күземә йокы керми.

Әни мич алдында, чыж-пыж итеп, нидер кыздыра калды, мин аннан-моннан киендем дә урамга чыктым.

Каршыма Апуш килә:

— Их, малай, бәхетең бар икән... Исән калган бит,— ди.

Мин шашып киттем:

— Ни бар? Ни булган? Кем исән?

Апушның күзләре дүрт булды:

---

[1] Русларның Покров день дигәннәре. *Авт. иск.*

– Әй, тавык баш! Шуны да белмисеңме? Бүген тауга бер көтү бүре килгән. Дүрт колынның бугазын чәйнәп, каннарын эчкәннәр, үтереп киткәннәр... Синең Алмачуарың үлмәгән, тик азрак яраланган гына...– ди.

Башыма нидер сукты, телем тотлыкты, сүз әйтә алмый катып калдым.

Апуш, моны күргәч:

– Тиле, нәрсә торасың! Бар, йөгер! Әнә алып кайтып киләләр,– дип, түбән очка, күпергә таба күрсәтте...

Чыннан да, ул яктан бер көтү халык әллә ничаклы бияләр, тайлар, колыннар куып киләләр иде.

Үземне-үзем белмәдем, шул якка очтым.

Ни күрим?

Зур арбага безнең кола ат җигелгән: тәртә янына бурлы бия бәйләнгән, ул бертуктамый кешни, кайдадыр китәргә, ычкынырга газаплана...

Арба янында әткәй килә...

Якынрак баргач, тагы авыр хәл: минем Алмачуарым, аяк-кулы бәйләнеп, арбага салынган...

Ни эшлим – аптырадым. Каттым...

– Әткәй, безнең колынны да үтергәнмени! – дип, кычкырып җылап җибәрдем.

Әткәй, мине иркәләп, култыгына алды:

– Җылама, Закир... Дүрт колынны үтергәннәр... Безнеке исән... Тик азрак арткы ботыннан тешләгән генә... Шул ярадан кан күп акмасын дип кенә бәйләп арбага салдык,– диде...

## XIII

Яра тирән түгел икән. Минем бәхет җиңде: көн-төн карау аркасында, бер атна дигәндә, минем Алмачуарым бөтенләй элекке хәленә кайта алды. Тик аның уң ботында бер илле чаклы яра булып, бүренең ике теш эзе генә ак җонлы булып сузылып калды...

Алмачуарым белән бергә мин дә авырган – йокымны, ашауэчүемне югалткан идем. Ул, терелеп, уйный башлагач, мин дә анардан калышмадым.

Кыш шулай үтеп китте.

## XIV

Икенче яшькә чыкканда, бездә яз көне тайның ялын, койрыгын бөтенләй кыркалар: «кырыкмыш» ясыйлар. Мин алай ямьсез итеп боздырасым килмәде.

Маңлай чәчен күзенә төшмәслек кенә ясап, тип-тигез кистердем. Бу хәзер, алдан караганда, рус боярларының матур кызлары кебек күренеп тора. Ялны да башкалар кебек бөтенләй бетертмәдем: бер чирек кадәрлерәк калдырып, үзеннән-үзе дулкынланып, күперенеп тора торган итеп төзәттердем генә. Әнидән алып, ул ялга ике яклап чуклар, тасмалар тактым. Койрыкны да бүтән кешеләр кәбестә кучәне кебек, ялангач беләк кебек ямьсезләп кыралар. Моңа да якын җибәрмәдем: сөяктән түбән ягын гына кистеләр дә матурлап түгәрәкләделәр. Кырыкмыш тайлар, бигрәк тә язгы сабан өстендә, йолыккан карга кебек чырсыз булып йөриләр. Минем Алмачуарым исә кунакка барырга ясанган бояр егете кебек чибәр булды.

Мин моны Әпсәләм[1] байларының берсендә, этиләр ялланып урак урырга йөргән чакларында күргән идем. Шулай итик дип сөйләп биргәч, әти карышмады:

– Их, балам, көенечкә генә булмаса ярар иде синең бу кылануларың,– диде дә бөтенләй мин әйткәнчә эшләде.

Авылда минем тайның болай матур кыркылуын күргәч, малайлар таң-хәйранга калдылар... Алдагы елларда башкалар да шулай ясый башладылар.

XV

Җәй, көз, кыш үтә. Яз килә.

Минем Алмачуар өченчегә керә. Авылда бу яшькә җиткәч, тайларны «беренче сабанга керде» дип сөйлиләр. Акрынлап, җиңелчәләп җигә башлыйлар.

Мин үзем буңа якын китермәдем.

Безнең Алмачуардан башка ике атымыз бар. Бурлы бия быел кысыр калды. Ул бура кебек таза, калын булып симереп китте. Берүзе биш атның эшен эшләрлек. Кола айгыр да анардан күп калышмый.

Шулай булганга, әткәй дә, Алмачуарны юк-барга җигәргә дип, тел кузгатмый. Сафа бабайның: «Бу колын ике агасына охшаган, бу чабышкы булыр»,– дигән сүзен ул да онытмый булырга кирәк.

Ләкин гөлләр чәнечкесез булмый икән шул.

Гөнаһ шомлыкка каршы: «Тарыны йомшакка чәчсәң, чүп басып харап итә»,– дигән дә, әткәй Кысылдык башкортларыннан мәңге сабан-сука кермәгән бер җир, каты чирәм сатып алган.

---

[1] *Әпсәләм* – Солтанмораттан өч кенә чакрымдагы хәзерге Иске Әпсәләм дигән авыл.

Тимер сабанны чыдатырлык түгел — урыны-урыны белән ташлы, чыбыклы җирләре дә бар. Шуңа күрә әллә качаннан кузгалмый яткан авыр төрән сабанны тартып чыгаралар. Буны ике ат йөртә алмый. Дүрт, иң азында — нык, таза өч ат кирәк.

Үзара сөйләшкәннәр дә өченчегә Алмачуарны җигәргә булганнар. Моны ишеткәч, мин, җыларга җитешеп, әткәйгә бардым.

— Ни бар? Кем тиде? — ди.

— Берәү дә тимәде! Ник минем Алмачуарны сабанга җигәсез? — дидем дә түзә алмыйча җылап ук җибәрдем.

Минем тавышка әнкәй дә килеп керә.

Ул Алмачуарны миннән көнләшә булса кирәк. Качан гына шул турыда сүз чыкмасын, мине тиргәргә, каһәрләргә тотына. Әле дә әткәй ни барын сөйләп бетмәде, әнкәй, миңа каршы кызып, ачуланып китте:

— Фу, Илаһым,— ди,— нинди бәла-каза килгән дип торам... Бер тай өчен адәм шул чаклы акырыр икән,— ди...— Әллә аны гомер буена җикми асрар идеңме? Менә тилергән нәрсә?— ди...

Әткәй ачуланмый, кызмый, мине җуатырга тырыша:

— Чү! Закир, алай юк өчен җылап барма,— ди.— Бернәрсә дә булмас, без аны буразна яклап очка гына җигәрбез... Үзең ат куарсың... Карап кына йөртерсең,— ди...

Мин аның саен ярсыдым, аның саен җылый бирдем.

Ашарга чакырдылар — кермәдем. Самавыр кайнаган диделәр,— аңа да карамадым. Туктаусыз җыладым да җыладым; шулай җылый-җылый арып, эштән чыгып, бакча буендагы такта өстендә йоклап та калганмын.

---

Уянып китсәм, ишек алдында түшәктә ятам.

Төш ауган. Кояш түбәнәеп бара. Дөнья бик рәхәт кенә, талгын гына тора. Йортта бер кеше дә күренми. Сабаннар, арбалар да юк, капка тулы ачык тора. Сикереп тордым да азбарга йөгердем.

Барсам, ни күрим? Минем Алмачуарым, озын тезген белән бәйләнгән хәлдә, улакның бер башыннан икенче башына йөреп тора.

Ахрысы, сагынгандыр: мине күрүгә кешнәп үк җибәрде.

Телләребез сөйләмәсә дә, без бер-беребезне бик тирән аңлыйбыз. Мин килеп күрешүгә, ул шатланып ук китте; өстен, ял,

койрыгын тазартканда, йөзеннән сыйпаганда, айгырым бертуктаусыз иһи... иһи дип, йомшак кына кешнәп, иркәләнеп тора.

Улагын төзәттем, коега илтеп, су эчердем дә өйгә кердем.

Әнкәй ярым шелтә, ярым елмаю белән каршы алды:

– Җылак малай! Җиндең бит, ахрысы! Вилдан[1] абзыйларың да безнең белән бергә янәшә чирәм алганнар икән... шулар белән алмашлап сөрергә булдылар...– ди.

Шатлыгым йөрәгемнән тулып таша. Җир-күге, бөтен дөньясы минем шатлыгымнан һәммәсе бииләр кебек тоела.

Бүген әни яныннан китмәдем. Ни кушса, барын-барын тыңладым.

Утын керт, диде – аны керттем.

Каз бәбкәләрен Өзән елгага илтеп кайт, диде – аларны илттем.

Тавыклар йомырка салгандыр, ояларны кара, диде – аңа йөгердем.

Әткәйләр киткәндә, катык оеп җитмәгән, икмәк тә пешеп өлгермәгән; шуңа күрә азык алмый киткәннәр икән, аларга ашарга илтергә кирәк булды.

– Бар, Мохтарга[2] әйт,– диде,– аркылы агач белән тотарсыз да яланга икмәк белән катык илтеп кайтырсыз,– диде әнкәй.

Бер сүзенә карышмадым, тик:

– Мин үзем генә дә илтә алам, әнкәй,– дидем.

– Булдыра алмассың, катыкны түгеп әрәм итәрсең, икәү барыгыз,– дигәч, аңа да күндем.

Яланга баргач, безнекеләр янында сабан сөрә торган Апуш мине көлеп каршы алды:

– Ну, малай, эт икәнсең: җиңдең бит, Алмачуарны җиктермәдең бит,– ди.– Әйдә, бирешмә, Закир, чабышкы буласы асыл сөякне сабанга җигеп әрәм иттермә,– ди.

Бу юлга җиңүен җиңдем...

Әмма бу җиңүләр миңа байтак кыйбат төшкән чаклар да булды.

Мин берәр төрле карулаша башласам, тыңламасам, хәзер күз алдыма Алмачуарны китереп куялар.

---

[1] Вилдан – сүз Г. Ибраһимовның туганнан туган кардәше Вилдан Ибраһимов хакында барса кирәк (Вилдан Гыйрфанның бертуган энесе).

[2] Мохтар – сүз Вилдан улы Мохтар Ибраһимов (1885–1969) хакында барса кирәк.

– Бик күп сөйлән тагы! Алай бик каршылансаң, Алмачуарыңны тотарбыз да урманга җигәрбез,– дип куркыталар.

Буңа җавап кайтарырга сүзем булмый, телем киселә: үземне җиксеннәр, аңа риза, тик минем Алмачуарыма гына тимәсеннәр.

Тир-якта ат тану белән дан чыгарган Сафа бабай:

– Бу колын үзенең ике агасына охшар, алар кебек чабышкы булыр...– дигән иде. Хәзер инде һәммә кеше дә шулай юрыйлар.

Урманга, тауга-ташка, сабан-сукага җиксәң, ул ничек чаба алачак? Анарда нинди чабышкылык калачак?!

Ни булса булыр, авырга җиктермим, менәм, чабыштырам, чабарга өйрәтәм, тирә-якта беренче чабышкы ясыйм!

## XVI

Менә күптән көтелгән килеп җитте.

Бүген Сабан туе!

Андый-мондый гына түгел, тирә-якта бик сирәк була торганы,– бик зурысы, бик шәбе!

Данлыклы чабышкылар җыелалар. Атаклы көрәшчеләр киләләр. Исемле йөгерек ирләр бүген көчләрен сынашмакчылар.

Алмачуар белән минем өчен дә бүгенге көн, бәлки, гомергә бер генә килеп китә торган зур көннәрдәндер.

Айгырым сыналмаган түгел. Өченче яшенә чыккач та, менгегә өйрәттек. Шуннан бирле авылыбызда үзара ат ярыштырулар күп булды. Әйтәсе дә юк, һичкемнең аты минем Алмачуарга якын килмәде – кузгалып китү белән мин очам, башкалар күз күреме җир артта калалар.

Күрше авылларның атлары белән дә ярышкаладым. Болар арасында күп Сабан туйларында беренче, икенче килгәннәре дә бар иде. Алмачуар боларны да бик җиңел, бик уйнап уза иде.

Әмма, әмма бу Сабан туе башкарак.

Әллә кайдагы, тау эчендәге башкортлар дан тоткан чабышкылары белән килгәннәр, диләр. Араларында бер күк бияне бик мактап сөйлиләр, үткән ел Өфе каласында чаптырганда, бөтен атларны адәм көлкесенә калдырган, диләр.

Башкаларын уйламыйм да. Менә шул күк бия мине куркыта. Кайдан гына килеп чыкты икән соң ул гөнаһ шомлык нәрсә!

Әткәй белән Сафа бабай да минем хәлне бик аңлыйлар булса кирәк.

Чаба торган атны бөтенләй башкача хәзерләргә тиешле була икән: заманында күп чабышкы асраган Сафа карт, яз чыккач ук,

әткәйгә бунының юлларын өйрәтте: нәрсә ашатырга, ничек эчертергә, көн саен ничек аз-аз гына йөртеп кайтарырга – һәммәсен әйтеп бирде. Анын белән генә дә калмыйча, һәр көн диярлек үзе килә, карый, яңадан өйрәтеп китә.

Сабан туена бер атна калгач, бигрәк каты тотына башладылар. Печәннең корысын гына бирәбез, бүлеп-бүлеп солы салабыз, азлап-азлап апара суы эчерәбез... Әти иренми, көн-төн карый. Мин аңа ияреп йөрим. Ансыз да асыл сөяк булган Алмачуарым бу арада карап туйгысыз булып чибәрләнде. Ял, койрык җефәкләнеп, дулкынланып тора. Эч каеш белән тарттырган кебек, нечкәреп, тип-тигез булып эчкә тартылды... Буе тагы да озыная төшкән кебек күренә... Аяк атлаулары шундый җиңел инде, әйтерсең ул җиргә басмый, бәлки күзгә күренми торган канатлары белән очып кына бара.

Ул электән дә ашауга назлы иде. Ахрысы, ярыш көннәренең якынаюын сизәдер, үзен үзе бик артык саклый башлады... Шуның белән бергә аны тыюлар бик авырайды.

Мин башка һичбер малайны мендермим. Йөрергә чыкканда, һаман үзем менәм. Шул вакытларда кайда гына булса да, нинди генә булса да, атланып кына барырга кирәк чакта да, башка берәр ат, арттан килеп, уза башласа, тыеп тотармын дип уйлама, – авызыкны тешләп ала да канатланып оча гына!

Бер дә шик юк, Алмачуар тиз арада Сабан туе буласын белә, анда үзенең чабачагын да сизә һәм шуңа бик нык, бик нык хәзерләнә. Минем хәзерләнүем дә аныкыннан ким түгел.

Әткәй белән Сафа бабай, шаяртыпмы, чынлапмы, кайбер вакыт башка берәр малайны мендереп чаптыру турында сөйлиләр:

– Син яшьсең. Алмачуар да әле зур җирләрдә чабып өйрәнмәгән, – диләр.

Мин якын да килмим. Тагы әйтәләр, күзләрем яшәрә башлый.

Сафа бабай мине жуата:

– Ярар, балам, ярар. Ни күрсәң үзең күрерсең, узсаң да – үзең, уздырсаң да – үзең! – ди.

## XVII

Бүген бөтен авылның асты өскә килә. Әллә ничә йөзләп җегетләр ат менеп чыкканнар да, яшь киленле йортларга кереп, сөлге җыеп йөриләр. Малайлар, кайсы атта, кайсы җәяү, өйдән-өйгә йомырка сорарга чыкканнар. Аларга яшелле-кызыллы

буяуга буяп әзерләп куйганнар. Хатын-кыз бертуктаусыз кайный: киенәләр, ясаналар, буяналар, тырт-мырт өйдән өйгә йөгерәләр.

Башка Сабан туйларында мин дә шулар эчендә кайнаша идем. Бусында күңелем ул якка бармый.

Алмачуарның йөрәге түзми, баскан җирендә тора алмый. Мин аны менеп, берничә мәртәбә урап кердем. Яраулануы җитсен дим.

Сафа бабай әйтә: «Яраулануы килмәсә, иң шәп атлар да артта калалар»,– ди.

Камчының бик зәһәрен әзерләделәр. Аңа этидән beləзеккә эләрлек итеп элмәк куйдырдым. Өскә кызыл киҗеле күлмәкнең калынын кидем. Түбәтәй төшеп кала, диләр, чабарга барган малайларның күбе аны кими, башларына яулыкмы-ниме, бернәрсә генә бәйлиләр.

Мин дә, әнкәйнең сандык төпләрен актартып, бер яшел яулыгын эзләтеп алдым. Кызыл яулыкны яратмыйм. Минем ат чибәрлектә беренче: аңа атланган малай да начар күренмәсен дим.

## XVIII

Мәзин, өйлә намазына азан әйтергә дип, манарага менгән генә иде, тагы Сафа бабай килде:

– Атлар китәргә вакыт җитә, әйдәгез, мәйданга барыйк,– ди.

Йөрәгем суга, тәнем бераз калтырый, күкрәгем никтер кысып-кысып ала. Алмачуар миннән дә яманрак тынычсызлана.

Әти айгырны җитәкләде, мин аякны чишендем, чалбарны салдым да бер кулга камчы белән яшел яулыкны алдым.

Өчәүләп Җамали карт тыкрыгыннан туры мәйданга таба киттек.

Безнең авылның кояш батыш ягында зур киң бер сырт бар. Сабан туен һәрвакыт шунда ясыйлар.

Бер якта аллы-гөлле, кызыллы-яшелле чүпрәк диңгезе үз алдына дулкынланып тора... Болар хатын-кызлар. Икенче якта, бик куе булып, ирләр бер түгәрәк ясап оешканнар. Бунда көрәш барадыр. Болардан читтә бала-чага, карт-коры, сатучы-фәлән, ат, арба, белмим, әлләниләр кара болыт кебек бөтен сыртны каплап алганнар...

Бераз еракта, киртә буендарак, атлар йөреп тора.

Кайберенең өстендә яулыклы малай, кайберләрен икенче атка менгән кеше җитәкләп йөртә... Барының да эчләре суырыл-

ганнар. Бары да карап торырга сөлек кебек маллар. Болар – чабышкылар.

Без теге халык диңгезеннән сулга, шул чабышкылар йөргән якка таба киттек. Боларга якынайган саен, минем Алмачуарның сабырсызлыгы арта бара иде.

Ул арада мәйданнан Садыйк абзый атка атланып килеп чыкты. Кулында зур таяк, аның башына кызыл башлы сөлге элengән...

Ул чабышкыларга якынрак килде дә:

– Вакыт җитте, китә башлагыз, алдан китүчеләр Ялгыз каен янында көтәрләр,– дип кычкырды.

Мине Алмачуарга күтәреп мендерделәр. Яулыкны урадылар, кәләпүшне әткәйгә бирдем.

Башка сүз әйтмәделәр. Тик Сафа бабай гына:

– Башта бик каулама, аерманың бу ягына чыккач, кызганма, нык сук!! Берүк тезгенеңне иркен куй! Тарткалап баруны ярата торган мал түгел бу! – дип, кат-кат әйтеп калды.

Без, Ялгыз каенга карап, үзеннән-үзе очарга барган атларыбызны көч белән тыя-тыя киттек.

## XIX

Ялгыз каен бездән унбиш чакрым.

Башка елларда булса, җиде-сигез чакрымнан чаптыралар иде, быел, төрле илләрнең данлыклы атлары килгәнгә, шулай ерактан куйганнар, диләр. Ялгыз каенга ничек килеп җиткәнне белмим. Бу – бик артык газап булды. Әлбәттә, атлап кына барырга кирәк. Алмачуарны тыяр хәл юк. Алда яисә артта икенче бер ат күренсә, авызыкны тешләп ала да оча гына.

Мин барып җиткәндә, атларның күбесе андалар иде инде. Ерак китмичә, туктаусыз йөреп торалар.

Боларны күргәч, каушап калдым: берсеннән-берсе сылу, берсеннән-берсе асыл маллар. Өметем азаеп ук калды. Болар бит берсе дә Алмачуардан ким түгел!

Теге данлыклы Күк бия дә килеп җитте. Күрүгә шунардан күзләремне алмадым. Гаҗәп бер мал икән: кыска яллы, сирәк койрыклы, чандыр гәүдәле нәрсә. Очасы[1] тар, бер якка бераз чалыш, аркасы бераз бөкрерәк. Әмма күкрәк дигән бөтенләй арысланныкы – шундый киң, шундый нык күренә. Тезләре ике яккарак китеп тора, бәкәлләренә карагач, тагы хәйран калдым:

[1] Оча – арка ягында билдән түбәнге урын, бот төпләре; арт сан.

алар шундый озыннар ки, мин гомеремдә андыйны күргәнем юк. Күзләре зурлар,– уйнап, ялкынланып торалар.

Өстенә кечкенә, кап-кара, башы бөтенләй ялангач, кулына камчы тотып, бер башкорт малае менгән.

Кечкенә булса да, күп чапкан малайдыр, ахры: бер дә каушамый, атның холкын бик белгәнгә охшый.

Чабышкылар арасында иң тыныч торганы шул Күк бия иде.

Атлар килеп бетте, Садыйк абзый безне тезә башлады.

Бусы бик зур бәла икән: инде тигезләп тездем генә дигәндә, йә берәүнең аты, кузгалып, алга китеп бара, җә баскан урынында тора алмыйча, кире чигенә. Күп азаплардан соң тезеп җиткерде:

– Берәү, икәү, өчәү! Һайди, туганнар,– дип кычкырып та йибәрде.

Ул «һайдиның» «һ»сен әйтеп бетә алмагандыр, атлар, әйтерсең, канатланып очтылар.

Башкалар кая киткәннәрдер, узганнардырмы, артта калганнардырмы,– белә алмадым. Урыннан кузгалуга, без өч ат: мин, Күк бия, тагы бер җирән чабышкы, бер-беребезгә бәрелә язып, янәшә оча идек.

Аяклар җиргә тияме, әллә атлар яшерен канатлары белән һавадан баралармы – әле дә аерып җитә алмыйм. Агачлар, елгалар, зур-зур баткаклар – алда ничектер күзгә чалынырга өлгерә алмыйлар, без аларны яшен кебек үтеп тә киткән булабыз.

Аеркул дигән бер тайгак елга бар. Бу юлда иң куркыныч нәрсә шул, диләр иде...

Очкан кошлар кебек, без бер-беребезне таптап, узып, каулашып, ул баткаклы елгага өчәү килеп кердек, ләкин ярның янында Күк бия белән минем Алмачуар гына иде, өченче иптәш – җирән чабышкы, малае белән баштүбән шунда баткакка чумды булса кирәк...

Инде икәү ярышабыз...

Көчләр бик тигез: бервакыт аның аты чак кына арттан бара, ләкин тагы бер каулый, минем атның башы Күк бианең койрыгы янына кала.

Тагы бер баткак; минем башым әйләнә, үзем егылам кебек булам. Күңелгә шөбһә килә; күзне йомам да Алмачуарның ялларына тотынам. Ачсам, баткакны чыкканбыз, ләкин Күк бия миннән өч-дүрт сажин алдан оча...

Инде якынлыйбыз да, авылның манаралары күренгән кебек була.

Гайрәт белән бер тартам, камчы белән уңга-сулга җан ачуына сугам. Алмачуарым «эһ» дип суырып ала да, күз ачып йомганчы, Күк биянең алдына барып чыга...

Әнә авыл, әнә басу капкасы, менә сырт өстен каплаган кара болыт кузгала!!

Чабышкы ияләре безгә каршы ат өстендә киләләр.

Арада әткәй дә күренеп кала.

Һайди, Закир, тагы бер сук! Тагы бер! Тагы!

Һайди, Алмачуар, һайди, Күк бия! Һайди, Алмачуар, һайди, Күк бия! Һайди, Алмачуар! Һайди, Күк бия! Ике яклап безне каулыйлар... Кычкыралар, сугалар, шатланышалар.

Ләкин Алмачуар белән Күк бия бөтенләй диярлек янәшә киләләр.

Тагы бер тартып җибәрдем, тагы бер бөтен гайрәтем белән уңнан, сулдан сугам...

Алмачуар «эһ» дип бер суырып та ала, Күк бияне аршын ярым чамасы калдырып, мәйданга килеп тә керәбез...

Кара болыт икегә ярыла.

Күк биянең башы минем Алмачуарның кабыргасындарак булган хәлдә чикне дә узып китәбез!!

Шау-шу, тавыш, тапталыш! Әйтерсең мәхшәр көне!

Старостаның бер кулында яшел чапан – бусы беренче килгәнгә, икенче кулында зур сөлге – бусы икенче килгәнгә билгеләнгән. Туфан, шау-шу эчендә староста яңлышмы, ничектер чапанны Күк биягә сузды, минем Алмачуарның муенына сөлгене ташлады:

– Син икенче килдең бугай,– ди.

Ни эшләгәнемне белмәдем, күз алдым караңгыланды, камчы белән уратып-уратып старостаның йөзенә селтәдем дә, кызулык белән Күк биядән чапанны тартып алып, бу кара болыт эченнән чыгып, читкә киттем. Камчы тигәндерме, юкмы,– белмәдем...

Аны карап торырга вакыт та юк: чабып килгән атны туктатырга ярамавы һәркемгә билгеле бит!!

Ул арада Сафа бабай, әткәй, күршеләр килеп, минем ат башыннан кочаклап алдылар. Һәммәсе мактый, һәммәсе рәхмәт укый. Сафа бабай, кат-кат башымнан сыйпап:

– Егетсең, балам, йөземне хур итмәдең,– ди.

Әткәй Алмачуарны җитәкләп йөртә башлады. Мин, яулыкны ташлап, кәләпүш кидем дә кайнашып торган халык туфанына барып кердем.

Малайлар мине куркыта башладылар:

– Камчы белән сугып старостаның битен яргансың. Ну, бирер үзеңә дә кирәгеңне! – диештеләр.

Ул арада староста үзе дә килде. Йөзе чыннан да ярылган булса кирәк: ак яулык белән бер күзе ашасыннан бәйләнгән.

Мин аңардан курыкмадым, тик аптырап калдым.

Ул ачуланмады гына түгел, мине кочаклады, башымнан сыйпады да:

– Мин бала чакта үзем дә атка менеп күп чапкан кеше... Алдан килеп тә, икенченең бүләген бирсәләр, җан түзалмый аңа... Мин сиңа ачуланмыйм, аргансың. Бар кайт инде,– дип, миңа егерме тиенлек көмеш бирде.

Дөнья минеке иде. Бөтен тирә-якта дан тоткан Күк бияне узып килү Алмачуар өчен һичкемнең акылына килмәгән бер бәхет иде.

XX

Ләкин бу бәхет тиз арада бик артык авыр бәхетсезлеккә әйләнде. Белмим, атымны кызу каулап яндырганмынмы, белмим, килеп җиткәч, староста белән талашып, туктап тору харап иткәнме? – ни дә булса булган: Сабан туеның икенче көнендә Алмачуарым аякларына баса алмас булды, ашавыннан, эчүеннән калды.

Бичаракаем, адәмнән болай акыллырак күзләре белән һәркемгә мөлдерәп карап, бер атнага якын ыңгырашып ятты да җомга көн, иртә белән сәгать унда дөньядан үтте.

---

Алмачуар җан биргәндә мин аның баш очында идем. Җылый алмадым. Йөрәгем таш булып катты.

Шуннан соң дөньяда һичбер малга, һичбер әйбергә күңелем дә, күзем дә төшмәде: һичбер нәрсәне сөя алмадым.

Алмачуар минем йөрәгемдә: җиргә, күккә, адәмнәргә, бөтен нәрсәләргә булган мәхәббәтемне үзе белән бергә алып китте.

1922, февраль, Казан

## Табигать балалары[1]

Хикәя

1

Мин егерме бер яшьтәмен. Өч атым, ике сыерым, ун баш сарыгым бар. Үткән көз өйне дә сипләтеп, алты почмаклы ясаттым. Шуңар дип боярдан урман алган идем. Кыш буена утынын ягып рәхәтләндек. Аның өстәвенә, ваграк булса да, кырык җиде бүрәнәсе калды, насыйп булса, тагы бер-ике имән багана алып, киләсе көзгә капканы яңадан эшләтергә, кечерәк булса да, келәт салдырырга исәплим.

Аннан соң тик мунча кала – заманы белән анысы да булыр әле, Аллаһ боерса!

Авыл йирендә безнең кебекләрне «урта хәлле», «ару көн итә» дип сөйлиләр. Шуның өстенә үзең дә ялгыз булгач, син инде теләсә кемгә башкода йибәрсәң дә, сүзем кире кайтыр дип шикләнмисең. Җамалый карт тирә-якның ару адәмнәреннән инде. Ул да әле: «Бу Хафиз нигә өйләнми икән – көнитеше чибәр, үзе ялгыз, кем кызын соратса да бирерләр иде»,– дип, сөйләп торган. Аның үзенең Фәхринисасы бар, зур кызларын, бик байга бирәмез дип, күп кайнишле йортта череткәннәр иде, инде бусын ялгызрак йиргә бирергә исәпли, ди. Бөтенләй әйтеп бетермәсә дә, башкодага берәр зуррак кеше барганда, миңа бирергә уйлары юк түгел кебек, тел төпләреннән шул сизелә.

Фәхринисаның үзенең дә дәрте юк түгел бугай. Минем бер җиңги бар. Әллә нинди ярты акыл. Шаркылдык, җиңел холыклы бернәрсә шунда. Көз җитеп, иген-тару ындырга кердеме – ул миңа кыз димләргә тотына. Беркөн шулай ишектән үк шаркылдап көлеп керде дә, керү белән мине: өйләнмисең, әнкәңне киленсез картайтасың, дип әрләргә:

– Җә... Җә... Хафиз. Әллә син катынлыкка язылдыңмы?! Синең ише егетләр уллы-кызлы булып бетте инде... Бик күп торсаң...– дип, миңа тагы кыз димләргә кереште:

[1] Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов тарафыннан төзелеп, 1915 елда «Аң» журналы нәшерендә чыккан «Альманах»та (б. 1–28), аннан соң, шулай ук ул урта мәктәпләр, курслар, семинарияләр һәм мәдрәсәләр өчен төзегән һәм 1919 елда «Сабах» ширкәте нәшер иткән «Яңа әдәбият. Икенче китап»та «Печән чапканда» исеме белән өзеге (б. 47–50), 1920 елда «Корылтай» нәшерендә аерым китап булып (24 б.), «Сайланма әсәрләр»нең 1934 елда дөнья күргән 5 нче китабында (б. 29–47), 1957 елгы 1 нче томында (б.180–195), 1974 елгы 1 нче томында (б. 189–204) бастырыла. Текст 1920 елгы басмадан алынды һәм стиль үзенчәлекләре сакланды.

– Менә,– ди,– Шаһи картның алма кебек кызы бар. Эшкә дисәң – авылда бер. Үзе шундый сылу, шундый зифа – тиленке, бер кашык суга сал да җот... Ул өшәнчеге[1]-бирнәсе дисәң, адәм әйтеп, адәм бетермәс. Әйтәм бит, өеңә сыймас. Авылыңа сыймас... Беркөн Кәримәләрдә аулак өй булды. Унбишләп кыз бар иде... Төн буена егет сайладылар... Җамалыйның Фәхернисасы бик оятсыз нәрсә икән: «Кемгә кем?» уены башланып та җитми, Хафиз үземә, Хафизкәем үземә, дип, синең белән тиләргә тотына. Шулай да бичарага бер дә чыкмадың. Сине янәшә өч кат салдылар, син өчесендә дә Шаһи кызы Бибиәсмага чыктың... Фәхерниса, мескенкәй, бер дә чыкмагач моңаеп ук китте... Әйтәсе дә юк, Шаһинең Бибәсмасы белән синең – икегезнең чәчләреңез бәйләнгән инде... Тот та башкода йибәр. Быел иген унган... Бүрәнәң бар... Аңарчы капкаң белән келәтеңне эшләт тә башкода йибәр... Шаулатып туйга барырмыз... Безнең әткәйне яучыга йибәрерсең. Ул тотынса, булмый калмас, булыр, бар да булыр, синең күңелең, әнкәйнең килене булыр.

2

Җамалый картның бирергә исәбе юк түгел. Кызы Фәхерниса-ның да миндә дәрте бар икән, шулаен шулай да бит, минем күңелем ул якка бер дә генә тартмый шул.

Менә ничә ел инде без Бибиәсма белән йөрешәмез. Бөтен тир-якка исемемез таралды. Ничә рәт тотыла яздык. Ел саен картка яучы йибәрәм. Юк бит, насыйп түгелме, көне җитмиме, карт, кемне генә яучы итсәм дә, кире кайтара.

Егетен әйтер хәлем юк, дип әйтеп әйтә, ди, шулай булса да, дип әйтеп әйтә, ди... Ә үзе һаман бирми, мин инде адәм алдында хур булырлык егет түгел, мактанудан булмасын, Ходайга шөкер, дип әйтәм, буем, төсем яхшы, бар йирем таза-сау, Фәхри малае кебек кылый күз түгел, Бәдри кебек аксак түгел, эчеп-ашап та яман атым чыкканы юк. Өмәләрдә, кайбер кунак-төшем чорларында бер-икене кагып аласың икән – анысы инде адәм булган һәркемдә булыр.

Элгәре алай булмаган бугай; бу елларда инде берәүгә башкода килгәч, кызның атасы мәһәр ягын кайгыртса, анасы: «Кайнишле йир түгелме, кайнанасы усал түгелме?» – дип чәрелди башлый. Безнең әле ул ягы да Аллаһка шөкер: кайниш дигәннең заты да

[1] Өшәнчеге – бирнәсе.

юк, әнкәй усал кайнана булмас, ул, Аллаһ боерса, киленкәем, дип, аркасыннан кагып кына тотар.

Белмим шул, никтер бирми инде.

Мин читләтеп сораштырган идем. Чын булса, сөеп алган, сөеп барган – алар бәхетсез булалар, дип әйтә, имеш, ди; әнә, дип әйтеп әйтә, ди, Камали кызы белән Тимеркәй ниләр күрмәде, ничә ел йөреп, баш тартып чыкты, инде эт көнендә гомерләре үтә, дип әйтеп әйтә, ди.

Тимеркәй – минем иптәш. Мин аны яхшы беләм. Ничә ел йөреп тә, аталары риза булмагач, Камали кызы аңар ябышып чыккан иде. Кызык инде аларның көнитешләре... Катыны ирен кыйный. Ул вакыт Тимер, бер сүз әйтә алмыйча, башын салып, кыйнатып тора... Тагы бер карыйсың: Тимер катынын кыйный башлаган, чәченнән йолка, типкәли, тегесе шуңар бер сүз әйтми, карулашмый, мескен булып тора... Шулай бик еш сугышалар, канга батышалар... Бер-ике сәгать үтми, алар килешкәннәр, ике күгәрчен кебек гөрләшеп утыралар, кочаклашалар, үбешеп җылашалар, Ходай белсен, әллә нинди хәл инде аларның... Аларны сихырлаганнар, бозганнар, диләр. Шул сүз чындыр инде...

Тимер белән Маһи шулай да бит... Сөеп алган бар кеше дә ул көнгә төшмидер инде. Ходаем, Бибиәсма катының булса, аңар ничек итеп кул күтәрә алырсың...

3

Әсма белән беренче әйтешүемез әллә нигә бер дә минем исемнән чыкмый.

Иген бик артык уңган ел иде. Күршемез Бәдри карчыкның Ак Иделгә коя торган Күксу тамагында бөтен бер дисәтинә тарысы бар икән. Бичараның бәхетенә каршы, искиткеч килешкән, урыны-урыны белән шулчаклы озын үскән: җигүле ат керсә дугасы-нисе белән югалыр, башы дисәң, тагы буеннан да хәйран, әйтерсең үз авырлыгын күтәрә алмый, бөгелә-сыгыла утырган зур чуклар – шулай булып салынышып утыралар.

Карчык берүзе барып кыштырдап йөрегән булса да, бер дә киметә алмаган. Көз җитеп, каты кыраулар да ешая башлагач, ул, тарым әрәм булыр дип куркып, тиз арада урдырып бетерү өчен, кәҗә бәрәнен суйган да өмә ясаган.

Андый ятим карчыкларга бармый килештереп булмый инде. Шулай да минем эшем бик күп, үз ашлыгым да яланда, фәлән, дип, бер әйтүгә, азрак җилкәне кашырга уйлаган идем, акыллы

карчык икән, кемнәргә әйттең, кемнәр бара, дигәнгә каршы иң элек Әсма исемен телгә алды, шуннан соң мин дә «ярар, барырмын» дигәнемне үзем дә сизми калдым.

Якындагы борайга мал кереп бара, шуның көлтәсен ташып аласы бар иде, ул истән чыкты; очланмаган кибән бар иде, ул да шул яңгырга каршы очланмый, ябылмый калды.

Әсма диләр, Бибиәсма диләр; карчыклар, иркәм, дип аның аркасыннан кагалар; имеш, күргән егетләр аның йөзенә, зифа буена, аяк атлавына хәйран булып сөйлиләр. Йөрәгемдә күптән үк аңар дәртем булса да, моңарчы бер сүз әйтү түгел, җүнләп күрә дә алганым юк иде. Карчык: Әсма да бара, дигәч, бүген нидер булыр кебек тоелды; ул үзе дә мине якын күрәдер, үзе дә өмәдә мине күрергә өмет итәдер шикелле сизендем.

Мин, өмәчеләрдән соңгарак калып, үз атымны менеп кенә бардым. Йиргә йиткәндә, алар ат тугара башлаганнар иде. Егетләр арба тирәсендә азаплана, кайсылары ураклар чишә, берничәсе атлар арканлап маташа; кызлар, киленнәр, алардан бер яктарак солы чүмәләсе артына ышыкланып, тыштан киеп килгән күлмәкләрен, шәлләрен салалар иде. Килеп җитүгә, күзләрем шунда кадалды: Ходаем, нинди бәхет, Әсма минем караганны күрде, миңа ялт итеп карап алды. Ул гына түгел, чак кына сизелерлек каш та сикертеп куйды бугай. Егетләр һаман ат, арба тирәсендә шаяралар иде; алдан Фәрхи җиңги төште, аның артыннан яулыкны артка бәйләгән, ап-ак җиңсәләр кигән җиту кызлар, нидер сөйләшеп, пырхылдап көлешеп, йир башына таба киттеләр.

Катын-кыздан тугыз, ирләрдән унбер – барлыгы егерме кеше икән. Өмәдә ир җәмәгате – бик начар халык. Бигрәк тә катын-кыз белән бергә булса, алар бер дә җүнләп эшләмиләр. Әле дә кызлар барды, уртан буразнаның кыйбла як яртысын алып, урырга да тотындылар. Ә без әле һаман арба янында, уракларны башка куеп, кызлар тикшерә, кемнең шәле матур, кемнең борыны томшык, урагы яңа икәнен сөйләшә, кызлар турында үзләренә ишеттерерлек итеп гайбәтләр, мактаулар ата идек.

Фәрхи җиңги түзмәде:

– Әй, егетләр... сез унбер... без тугыз... без йирнең яртысын алдык... Үз өлешемезне бетерсәк, аң булыңыз, сезнекен бер генә дә кистермәбез... Кәҗәгә калсаңыз, ятыңызга[1] көч килмәсен...– дип кычкырды.

[1] Ятыңызга – оятыгызга.

Без җаваплашырга уйласак та, булдыра алмадык. Кызлар үзара нидер әйтешеп, шаркылдап көлештеләр дә, без шуның белән җиңелеп, тарыга килдек. Килеп тә җиттек, шул урта буразнаның катын-кыздан калган төньяк яртысын алып, югары таба куа да башладык. Егерме уракка кырык сажин киңлегендә алын. Тары озын, бик күп иеләсе түгел. Бил авыртмас... Син күр дә мин күр, йирне түбән баштан югары таба иңеннән-иңенә кырып кына барабыз.

Өмә дигәнең рәхәт инде, валлаһи! Бу бер дә эш түгел – уен да көлке, шаяру да котыру... Арада яхшы тавышлы, чапак телле[1] шаян егетләр бар. Алар кызларга, киленнәргә чәнчеп йибәрәләр; тегеннән тагы агулырак җаваплар килә; кай ара бик татау гына булып, бергә кушылып та көйләп алалар...

Йирнең уртасында суы кипкән күл бар, аның тирәсендә күбүк таллар яшәреп утыралар. Төшкәчә өмә шул таллыкка җитәргә тиеш иде. Малайларның, өйрә килә, дип кычкыруына башымны күтәрсәм, ни күрим: ни арада төш тә җиткән, ни арада без таллыкка якынаеп та калганбыз. Малайлар, өйрә килә, дип ялганлаган икән. Алар тагы шулай бер-ике кат алдадылар. Авыл ягына карадык, бернәрсә дә юк иде, кызып тагы ура башладык. Менә адәм хурлыгы, үзебез ирләр була торып, үзебез тегеләрдән ике урак артык була торып, кызлар чаклы эшли алмаганбыз, безнең алын чыгарга бер сажин бар әле, ә алар үзләренекен бетергәннәр дә безгә карап шаркылдашып көлеп торалар, кыюрак киленнәрдән берничәсе:

– Кәҗигеҗеҗе, кәҗигеҗе, геҗе... болар кайсы авыл кәҗәләре...– дип безне мыскылларга тотындылар... Берничәсе, тагы ныграк әрләндерү өчен, безнең янга килеп булышырга әйтә башлады. Мин түзмәдем, шул як буразнага якын иптәшкә:

– Кертмә шуларны, аякларын бастырма безнең якка! – дип кычкырдым...

Без дә кызып тотынып, бер-ике минутта алынны юк итеп ташладык. Малайлар тагы, өйрә килә, өйрә килә, дип акырырга тотындылар.

Инде бусы чын иде: өстләре ашъяулыклар белән ябулы гөбеләр, батманнар куелган, шуларны кочаклап ике малай, бер катын утырган зур ящик арба безнең йирнең үрге башына килеп тә туктады. Элгәре кызлар, киленнәр, алар артыннан без

[1] Чапак телле – оста телле.

уракларны атып бәрдек тә йир уртасындагы таллы күл аша шул арбага таба чабышып киттек.

Ни дияргә белмим инде, күңелемдә булганмы, үзем шуны эзләгәнменме, әллә Ходай үзе туры китергәнме – ни дә булса бар, мин, урагымны атып бәреп, таллык эченә барып кергән генә идем, искәрмәстән алдымда бер зифа буй күрдем: ул да Әсма булып чыкты; тагы кызуладым, тагы омтылдым да, шул зифа буйны тотып ала язып, артыннан:

– Әсма, Әсма, мин сине яратам!.– дип кычкырып йибәрдем.

Ул, ахры, кочаклап үбәргә итә дип уйлагандыр, артыннан җитә башлаганымны күрде дә, кыр кәҗәсе кебек кинәт сикереп янымнан юк булды. Мин яңадан аңа: «Сине яратам»,– дигәнмендер, ахры, шуңа каршы аның да үзенең көмеш тавышы белән:

– Мин дә! – дигәнен генә ишетеп калдым...

4

Миңа шуннан артыгы кирәкми дә иде. Шул көннән алып без аның белән йөрешә башладык, өч ел буена аңардан алган чигүле кульяулыкларның санын гына да бер Ходай үзе белсен инде...

Егет сайлау уенында мине өч кат салганнар. Мин өчесендә дә Әсмага чыкканмын. Фәрхи җиңги: «Сезнең чәчләрегез бәйләнгән»,– ди иде. Мин үзем дә эчемнән нидер сизәм, Ходай кушса, бергә булырмыз әле, дип өметләнә идем. Тик әнкәйне ризалату гына авыр иде.

Ул инде ярыйсук картайды да; ахрысы, аның кайнана булып түрдә утырасы, килен рәхәте күрәсе бик килә торгандыр; моны турыдан-туры әйтеп бетермәсә дә, сүз җае белән бик нык китереп-китереп чыгара.

Анага бер булганга, миңа солдат куркынычы юк иде. Минем кебек ялгызлар унҗиделәре керер-кермәс өйләнә башлый; әнә миңа яшьтәш Наманҗан Гыйлаҗиенең тиздән атка йөри башларлык малае да бар инде.

Аталары булган егетләрнең үзләреннән сорап тормыйлар: көне килсә, тоталар да бер төшкә башкода йибәрәләр; сизми дә каласың, дулатып туй җитә.

Ә мин үзем хуҗа. Без әнкәй белән болай да бик тату торамыз... Ул минем белән киңәшсез кыл да кыймылдатмый.

Шулай булса да хәл мөшкелләште инде. Әнкәйнең картаюы да бар, ул күңеленнән рәнҗидер, минем кебекләр түр башында килен хезмәте күреп утыра, мин әле һаман утын кертеп, идән

җуып йөрим, ди торгандыр. Агай-энеләрдән дә яхшы түгел, яшең егермеләрне үтеп, һаман өйләнмәгәч, алар минем өчен кызарып, гарьләнеп йөриләр бугай. Дошманнар да үземнең артымда:

– Хафиз бик өйләнер иде дә, аңар дигән кыз тумаган, ди, анасының карынында, ди әле... Хафизга тагы егерме ел көтәсе бар, ди әле...– дип көләләр икән...

Ни булса шул булыр, күбен көттем, азына чыдарга кирәк. Бер елга куян тиресе дә түзә, ди: киләсе көзгә чикле сабыр итим, тагы яучының бик майлы авызын йибәреп карармын... Анда да булмаса, белмим инде, ничек кенә...

5

Минем бәхет өмәдән китте. Бибиәсма белән йөрешә башлавыбыз да өмәдә булган иде, Ходай кушкач, эшнең ахыры да шунда килеп чыкты.

Менә печән җитте. Картлар, без печән өстендә ураза тоттык, дип сөйлиләр иде; әллә ни түгел икән, менә без дә печәнен дә җимереп барабыз, Тәңрегә дә (мактанудан булмасын тик) гөнаһлы булганыбыз юк әле.

Бу ел корырак корысын. Шулай да, язгы ташкын шәп булып, тугайда су озак яткангамы, печән ярыйсы килеште. Минем бәхеткә каршыдыр, инде Бибиәсманың атасы Шаһи бабай Ханбикә тугаендагы печәнлеген чабарга өмә иткән.

Эш бик тыгыз... Печәннең яртысы чабылмаган, әнә анда инде киң арыш басуы бөтенләй диярлек алтын сары булып дулкынланып утыра... Урагыңны ал да бүгеннән беләк сызганып урырга тотын! Менә күрерсең, печәнне чабып, кибән куярга өлгерә дә алмассың, гөрләп арыш урагына йөри башларлар. Эш бу чикле тыгылып килгән елларда кешегә өмәгә йөрү түгел, үз эшең өчен дә бер үзең кырыкка ярылырга җитәсең.

Шулай булса да Шаһи бабайның өмәсендә уникеләп чалгы булды. Ул – авылыбызның әйбәт картларыннан, аның Ибракаен солдатка алдылар, эш кулы ялгыз калды. Җитмәсә тагы, печән алдыннан гына менә дигән ике алашасын урлап киттеләр. Карап туйгысыз маллар иде, бөтен авыл кызганды үзләрен...

Мондый кеше өмә итсә, бик үк ялгыз булмаганнар сүз кайтарырга килештермиләр инде, өстәвенә аның Әсмасы да бар. Егетләр бабайның әйтеп беткәнен дә көтмиләр, барабыз-барабыз, дип атылып торалар.

6

Өмә, өмә диләр дә бит, уразада өмә дигәнең дә коры сүз генә шул. Бүтән чак булса, иртән майлы белен белән чәйләп, сыйлап озаталар, көндез симез итле өйрә итәләр. Ә уразада нәрсә?

Хәер, монда да сәхәрләре шәп булды булуын! Бибиәсма хәйран уңган бит... Кыз кеше инде, аңа бар да ак булсын, бар да пакь булсын, бар да ялтырап торсын... Чәйгә утырсаң, исең китәр: ашҗаулыгы нинди... самавары алтын кебек... чынаяк-саба дисеңме? – бар да уңган кыз кулы шул.

Мин кичтән чалгымны чүкеп әзерләп куйган идем. Сәхәр ашап бетүгә, яшьрәк егетләр чыктык та җиңгел кулдан ике арбага икешәр атны җигеп ташладык. Рәхәт соң шул сәхәр чаклары! Әллә ничек йөрәкләр киңәеп сулыйлар... Ул арада картлар да эчеп бетте. Ике арбага төялдек тә, атларны җен кебек дулаттырып, тау артыннан сызылып килгән таң белән бергә, авылдан киң яланга чыктык.

Таң сандугачлары сайраудан туктамаганнар иде әле; безне әллә кайдан-кая җәелеп яткан киң тугай чык суы белән энҗедәй ялтырап каршы алды.

Унике чалгы алды-артлы тезелешеп тугайны бер әйләнгәч, нуры белән балкылдап кояш та күтәрелде... Җаннар киңәеп үк киттеләр... Рәхәт соң, валлаһи, шундый чакларда киң тугайларда күкрәк киереп печән чабулар! Бөтен су буйларын яңгыратып, чалгыңны бер яныйсың, күкрәк киереп бер селтәп йибәрәсең дә, әйтерсең лә бөтен дөньясын җиңеп алдың инде!

7

Көн үтә аяз; күк әллә кая ерак иде, иртәнге салкында чабу егетләргә бәйрәм генә булса да, соңгы чәй вакытлары үтү белән кояш эсселәтә, кайберәүләрне йомшарта да башлады... Без һаман чабамыз; биттән, муеннан, аркалардан тир ага; күлмәкләр тәнгә ябышты... Барыбыз да беләкләрне сызганган, изүләрне ике якка аерып йибәргәнмез... Үзара сөйләшү бетте... Бу инде эсселек җиңә башлаган дигән сүз була... Күк йөзендә Тәңре хакы өчен дә бер кисәк болыт юк. Төш якынлый... Көн кыза башлый, кыза башлый... Кошлар, авызларын ачып, елга буйларына төшәләр... Балыклар, хәлсезләнеп, камыш төпләренә яталар, үләннәр, әлсерәп, башларын түбән иделәр – әйтерсең күк йөзе кызган тимергә әйләнде, түбәнәйде дә без шуның астында калдык; ул безнең баш өстемездә яндырып, миемезне кайнатып

тора... Инде чабу кая, тамырлар куырылды, ирен, авыз кипте. Тын алсаң, эчкә ялкын керә – шулчаклы киптек, ай бер тамчы су эчәргә яраса! Хәл кереп үк китәр иде! Юк инде, ансы булмас, бер без түгел, бөтен ил белән шулай.

Шаһи картның үзенең дә эсседән күзләре агарган. Ул:

– Җә, балалар, без бит сәхәрдән үк килгән идек, әле дә күп чаптык...

Инде кайтамыз дисәңез дә сүзем юк,– дигән иде, Кәрим карт бер дә якын килмәде:

– Нинди кайту әле ул,– ди...– Типсә тимер өзәрдәй унике егет килеп, бер шобага печәнне дә бетермәгәч, ул нигә ярый... Көн бераз сүрелгәнче күләгәдә ятырбыз да кичкә каршы бетереп кайтырмыз... Бу егетләр ике көн, ике төн тоташ чаптырсаң да сер бирмәсләр әле,– ди.

Без дә аның ягында булдык. Арба астына тал араларына киемнәр корып күләнкә ясадык та сузылышып яттык.

Көн кызганнан-кыза, йир, күк көйгәннән-көя бара– әйтерсең дөньяга җәһәннәмнән бер тишек ачылган да, безне шуның каршысына китереп куйганнар иде.

Күләгә корган булсак та, аның да рәте аз инде. Эссе хәлне бетерә, сусауга чыдар хәл юк,– шуның белән башыңны кая куярга белми азап эчендә ятканда, тегеннән Шаяхмәт белән Саткай әллә ниләр дип талаша-талаша сикерешеп тордылар да кулларына чалгыларын алдылар.

Болар ни котыра тагы дип, мин дә, кояшның көйдерүенә карамыйча, яланбаш торып алар янына бардым.

Кызык бу ике егетнең хәле!

Әптерәш картның Майбәдәрен Шаяхмәт алырга йөргән. Сафа карт аша сүз салдырып, бирергә чамаларын да белгән, тик мәһәр турында килешә алмый гына торалар икән. Әптерәш бер калын бишмәт, бер кадак чәй, ярты пот бал арттырырга сорый, боларның шуңар күнәселәре килми икән. Саткай кайдандыр шуны ишеткән дә, Хәйрулла картны башкодага йибәреп: «Ни сораса шуны сал, күпме салсаң да сал, тик Майбәдәрне ычкындырма»,– дигән. Хәйрулла барган да Әптерәшнең сораганыннан артык биргән, шунда ук егерме биш тәнкә акча чыгарып салып, кыз бүләген дә алып кайткан.

Шаяхмәт катынсыз калмады, Майбәдәр булмаса, анардан да шәбрәк Гыйльминурны алды, шулай да егет ул җиңелүнең гарьлеген гомергә оныта алмады. Менә ничә ел инде алар, кая

гына барсалар да, бер-берсенә аяк чалалар. Әле бүген дә, әллә нидән сүз китеп, Шаяхмәт Саткайны хурлый башлаган: «Азаккы әйләнгәндә, малайның маңкалары акты, тагы бер-ике атларга булса, аяктан егыла иде»,– дип көлгән...

Саткай сикереп торган да:

– Мин кояш батканчы чалгымны кулымнан төшермәскә могу!– дип кычкырган. Ул бик гайрәтләнгәндә шулай русча сүзләр кыстырырга ярата.

Шуннан телгә килешкәннәр; кеше үртәүдән кызык табучы Вәликәй: «Булмас, булмас»,– дип майга ут төртә башлаган.

Без торып баргач, тагы кызыштылар. Шаяхмәт:

– Сине йөз сажин калдырып килмәсәм, исемем Шаһиәхмәт булмасын,– дип күкрәк какты. Аңар каршы тегесе:

– Мине ике адым уза алсаң, туры атымны үзем нукталап кулыңа тоттырам,– дип, зур йомрыгы белән тәгәрмәчкә шундый каты сукты инде, агай, арба урыныннан кузгалды, аңар сөялгән чалгы ауды, корылган күләнкә йимерелде. Аның астында йоклаучылар, бу ни, бу ни дип, күзләрен тырный-тырный урыннарыннан калыктылар.

Кояш тыннарны куыра, бөтен тән эреп, тир булып агып китәргә баргандай тоела иде. Без яңадан күләнкәләргә кердек. Шаяхмәт белән Саткай чаң-чоң китереп берәр генә рәт чалгыларын яныдалар да гайрәт белән селти-селти чабып киттеләр.

Шобагада Саткай өсткә чыккан иде, ул алдан төште. Шаһи карт: «Балалар, көн бик аяусыз, үзегез уразаларсыз, янарсыз, юкка кызмаңыз»,– дисә дә файда булмады,– киттеләр.

Көчләре, чабарга осталыклары бертигезрәктер, тик Саткайның чалгысы бераз көйсез иде, мин аны янар дип бик курыктым. Җитмеш сажиннар бер-берсеннән күп калышмый бардылар. Саткай, ахрысы, хәл җыя баргандыр – болын уртасындагы зур таллыкларны үткәч кызулый төште; тагы бераз баргач, алдагының артыннан җитеп, юл бир, дип кычкырган, күрәсең. Бер-берсен тапташырдай булып бераз каулаштылар да, ахыры Шаяхмәт чыдый алмады, Саткайга алынны бирде; болынның аргы читенә чыккач, ул инде бөтенләй туктады, янармын дип курыктым, ди. Саткай сүзен итте, тукталмады; ул бик гарьчел нәрсә, үз дигәне булмаса, йир ярылса, йир астына керә торган егет.

Безгә башта уен иде, Шаяхмәт теше башта егылып калгач, борчыла башладык. Башкалар да уянды. Шаһи карт, ай, яшьлек, җүләрлек, нигә юк белән үзеңне харап итәргә, дип, егетләрне

шелтәли башлады. Шулай да егет әйткән сүзен аяк астына салмады, бер дә арымаган кеше кебек яңадан урап арба янына килеп җитте, аның күзләре күрми, теле көрмәкләнгән иде ахры: килеп тә җитте, киң иттереп, актык дигәндәй, бер селтәде, шуның белән чалгысы бер якка китте, үзе арба тәртәсенә егылып та төште.

Без аны сырып алдык. Йөзе буылып кара көйгән, бөтен тәненнән тир ага, теле чак сөйли иде.

– Су, су, янам... үләм...– диде.

Су китердек. Эчәрме дип уйлаган идек. Нык егет икән, эчмәде, җиңен юешләтеп, иренենә куйды да шуның белән йөзен каплады. Сулы чүпрәк бераз җиңеләйтте, ахры, безгә берәм-берәм карады да, әллә нинди авырулы тавыш белән:

– Берәрегез белмиме: миңа су керергә ярамасмы икән? – дип сорады.

Арада гыйлемрәк кеше Фәттах карт бар иде:

– Инде ул, туган, – диде, – яравын ярамый ул, – диде, – мин, – диде, – хәзрәтләрдән ишеткәнем бар, алар, – диде, – суга керсәң, ураза ачыла, дип әйтеп әйтәләр, – диде... – Шулай да, – диде, – хәлең бик авыр булса, балакай, – диде, – җан газиз, Аллаһ хәзрәте кичерер, ахырдан алтмыш көн каза кыйлырсың, – диде. – Бик авырайсаң, – диде, – керсәң дә ярар. Җан газиз, Аллаһ кичерер, ахырдан, – диде, – алтмыш көн каза кыйлырсың,– диде.

Без аны суга якынрак китердек тә, астына яңа гына чапкан печән түшәп, өстенә күләнкәлек ясадык. Чүпрәкне яңадан-яңа сулап, йөзенә, күкрәгенә каплый тордык. Суга кермәде, үзенең теле начар, сулышы тигезсез иде.

Шаһи карт бик куркынды булса кирәк:

– Монда бик артык эссе булыр, өйгә кайтсын, анда безнең кар базы бар – шунда чыпта җәярләр дә төшереп яткырырлар,– диде.

Якында гына, кигәвеннәрдән үзен кая куярга белми дулап, арканына уралып дүрт аягы бергә килеп беткән соры бия бар икән, шуны тиз генә җиктек тә Әсманың энесе (минем кайниш булыр, Ходай кушса) белән кайтарып җибәрдек.

Көн кызганнан-кыза бара, без, кояштан, сусаудан көеп, һаман арба астларында әлсерәп ятамыз...

8

Әнә Ак Иделнең югары башыннан йомшак мамык төсле апак бер болыт күтәрелде. Әнә тагы берсе... икенчесе... өченчесе –

менә бер-бер артлы күтәрелә торган шул ак болытлар, аналары янына җыелган аккош балалары кебек, теге иң элек күренгәннең янына җыела, аңар кушыла башладылар. Бер самавар кайнап чыгарлык та вакыт үтмәгәндер, алар тәмам бергә оештылар да, калын катлаулар ясап, яварга охшашлы күгелҗем-кара төскә керделәр.

Аз гына җил исте, болытлар безгә таба кузгалдылар да, эсседән көйгән киң болынны талгын күләгәләре белән рәхәтләндереп, бик аз гына сибәләп, кара урманга таба үттеләр.

Без болыт күрү белән ояларымыздан чыккан идек, сибәли башлагач та, аның тамчыларына күкрәк ачып, үләндә аунадык, аны меңрәхмәтләр белән озатып калдык.

Бер якта кояш, икенче якта болыт – шулай аяз яңгыр булды.

Аз сибәләде, шулай да яхшы булды; көн сүрелде, безгә тәмам хәл кереп, егетләр берәм-берәм терелә башладылар.

Кемдер яңа йокыдан уянган. Әле бөтенләй ачылып җитмәгән тавышы белән озын көйгә салып:

Ак Иделкәй алкын, суы салкын,
Дулкыннары кага салларга...–

дип сузды. Кемдер: «Кая, көн бик сүрелде, азрак капкалыйк та, чаба башлармыз»,– дигән иде, ул ураза икәнне оныткан, күрәсең. «Гыйлаҗи ашыйсың килдеме, мә икмәк белән катык»,– дип анардан көлештеләр.

Көн дә кичегеп килә иде инде, тордык та яңадан чаба башладык.

9

Бу Гыйлаҗи дигәнең эт нәрсә берүк! Балта тотып сәнәк очларга кулыннан килми, чалгы алса, адәм уңаена бара алмый. Иллә мәгәр тел дигәндә авызына Иблис төкергән инде! Яңгырдан соң ике буй белән килгәч, азрак тын алыйк дип Идел ярына тезелешеп утырган гына идек, янындагы Кәрим картка бөтенләй бер кирәкле нәрсә сөйләгән кеше төсле:

– Кәрим бабай, бу елда безнең Хафиз бик саргаеп бара бит әле... Ни булды икән бу егеткә? Сез күпне күргән кеше, берәр дәвасын белмисезме? – диде.

Мин катышмадым, янымда утырган Шаяхмәт, Шаһи картның үзенә дә ишеттерерлек итеп, минем колагыма:

– Шаһи бабай Әсмасын бирсә, көне белән терелер иде,– дип пышылдады.

Минем саргайганым юк. Суксам инҗәләрен сындырырлык тазалыгым бар. Моны тик сүз булсын дип лыгырдыйлар инде. Шулай да минем эчем нидер сизенгәндәй булды. Күзләремә икенче төс чыккандырмы, бер-ике иптәш: «Караңыз, Хафизга ни булды, күзләре белән җота бит үзегезне»,– диештеләр.

Мин һаман дәшмәдем.

Теге Гыйлаҗи, тагы башлап:

– Шаһи бабай, берәү, икәү, өчәү, дүртәү дип, өч йөзне санаганчы өстемдәге кием белән Иделнең әнә шул киң йиреннән аша йөзеп чыксам, Әсмаңны бирәсеңме? – диде. Гыйлаҗиның андый сүзе кирәк качанда була инде, карт ачуланмады, тик шаярыпмы, әллә үзе дә сизмичәме, әллә язмышына каршымы, агарынып, аягына басты да ят бер тавыш белән:

– Әсма да Әсма сезгә! Бер Әсманы ничәңезгә бирим?! Мона Кәрим карт белән ярышыңыз, ике әйләнгәнче аны кайсыңыз йир буе калдырса, Әсма шуныкы! – диде.

Кемдер: «Чынмы, бирәсеңме?» – дип кычкырды, мин, ни эшләгәнемне дә аңламыйча, сикереп тордым да бабайның кулыннан тоттым:

– Сүзеңнән кайтмыйсыңмы... Бирәсеңме?

Карт каушады, уеннан уймак чыгарын сизенде булса кирәк, бераз чигенде, бераз агарынды, шулай да киреләмәде:

– Әйткән сүз – аткан ук, дигән борынгылар, ал чалгыңны! – диде.

Кәрим карт үз гомерендә һичбер чалгыга алын бирмәде, диләр.

Бездән ерак түгел «Бүре баткан» байлары бар. Шулар элегрәк заманда ел саен печән чабарга көнлек чыгара, монда тирә-якның көчле ирләреннән, шәп егетләреннән йөзләп кеше була торган иде, ди. Башкаларга көнлек хакы илле тиен, бер тәнкә бирсәләр, алдан төшеп, шәп барыр, күп чаптырыр өчен Кәримне көненә икешәр сум белән алдыралар. Аны кунак кебек кадерләп йөретәләр икән. Аңар инде байтак еллар үткән. Ул чакта таза имәндәй ир булган Кәримнең инде сакалына чал кергән, картлык үзен күрсәтә башлаган. Шулай да ул әле һаман бездә беренче осталардан санала. Тирә-якта кемнең дә булса аны җиңгәне ишетелми.

Шаһи бабай: «Әйткән сүз – аткан ук, дигән борынгылар, ал чалгыңны!» – дип кычкыргач, иптәшләр мине сырып алды. Кайберләре мыек астыннан, кем белән ярыша бу бичара, дигән мыскыл көлүе белән елмаялар; берсе: «Җүләр булма, сине уздыргач

Кәрим буламыни ул»,– ди. Мин берсенә дә карамадым. Колагым сүз ишетми, күз алдым караңгылана бара иде.

Ходаем, үзең коткар, үзең ярдәм бир!

Карт үзе белән яшьтәш булып, уртасы бер илле генә калган чалгысын түндәк башына сабы белән кадады, чаң-чоң китереп бер-ике янып йибәрде, әллә нинди каушаулы тавыш белән:

– Һай егетләр... Мәдәт, йа Ходай! – дип бөтен су буен яңгыратып аваз салды да киң Идел болынының билгә җиткән яшел үләне эченнән әйтерсең үзеннән-үзе йөзеп китте.

Мин дә, каушап, калтырап чалгымны яныдым, калагымны оек кунычына тыктым да, Аллаһка тәвәккәлләп, картның артыннан төштем.

Башкалар Иделнең текә яры өстендә безнең болын буйлап ярышканны карап тора калдылар.

10

Бер әйләнгәнче карттан бер дә калышмый бардым. Каһарман Кәрим картайганмы, әллә Хафиздагы көч мең Кәримне таптап узарлык зурмы,– ни дә булса бардыр: яңадан Идел ярына килеп, икенче әйләнүгә кергәндә, карт йомшара, мин аның үкчәсенә басарга якынлый бара идем инде. Болынның урталыгына җиткәч, киерелеп бер-ике селтәдем дә, картның аяк яныннан кырып алып:

– Киселәсең, кал артка! – дип тавыш бирдем.

Карт тиз җиңелергә теләмәде, актык көче белән тагы берничә омтылып карады. Юк инде, ни эшләсә дә ул җиңелергә тиеш иде. Тагы киерелдем, тагы киң селтәп, картның аяк яныннан кырып алдым да, үзен таптап юк итәргә баргандай бер тавыш белән:

– Ташла чалгыңны! Бир миңа юл! – дип кычкырдым.

Шул тавышым үземә тагы гайрәт бирде, кан тамырларым тулды, көчем тәнемә сыймый башлады. Атаклы Кәримнең бу гайрәтемнән күкрәге тарайды булырга кирәк:

– Егет икәнсең, энем...– диде дә миңа алынны бирде.

Картка карамадым, аның минем артымнан киләме, юкмы икәнен дә белмәдем, кан тамырларым тулып таша, чалгы бер селтәүдә ярты дөньяны кырып төшерердәй бер гайрәт белән ала иде.

Тирә-якка атаклы Кәрим миннән күз күреме йир артта калып килде. Мине яр башындагы халык шаулап, кулга күтәреп каршы алды.

Шаһи бабай: «Ир ике сөйләмәс», – дигән иде, сүзендә торды: «Инде Ходайның кушуыдыр», – дип, миңа Әсманы бирде.

Безнең бәхеткә игеннәр яхшы үсте. Юлдаш күл буена чәчкән җир ярым солым бар иде, ул да бик уңды. Картның вәгъдәсен алгач та, келәт белән капканы эшләттем. Яшь кара айгырны хәзер өйдә генә асрыйм, солы күп, симерсен, дим; билгеле бит: кәләшкә йөрергә шәп ат кирәк. Иген-тару җыелып булгач, бөтен авылны шаулатып туй иттек.

Җәйне көтмәдем, мин ялгыз кеше дип, Әсманы кыш көне үк йортка төшердем.

Без бик яхшы торамыз. Бөтен авылда безне мактап сөйлиләр. Әнкәй дә бик шат. Инде озакламый бер баламыз да булачак.

Кичә төн буена йокламый Әсма белән шул турыда сөйләшеп яттык.

Мин әйтәм: кыз бала булсын да сиңа охшасын иде, дим. Әсма әйтә: ир булсын да сиңа охшасын иде, без аңар Тимербулат дип ат кушар идек, ди.

Ходай ни язган булса, шул булыр; ни генә булса да, саулыгы белән, бәхете белән тусын иде инде.

# III
# КАЙБЕР ГЫЙЛЬМИ ХЕЗМӘТЛӘРЕННӘН ҮРНӘКЛӘР

## Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?[1]

Мөхәррирдән

Пролетариат революциясе һәм социализм төзелеше эчендә милли мәдәниятләрнең, аеруча татар мәдәниятенең ничек барышы мәсьәләсе партия өчен дә, Татарстан Өлкә комитеты өчен дә, әлбәттә, күптән ачык иде, билгеле иде.

Ләкин шуңа карамастан, 1918–1920 нче елларда, милли җөмһүриятләрне төзүгә каршы барып, партия аңлавыннан аерылучылар булган кебек, аерым халыкларның, үз телләре нигезендә мәдәниятләрен үстерү, күтәрү турында да, партиянең, Татарстан оешмасының тоткан юлын әле һаман үзләштерә алмаучылар, татар мәдәниятенең үз теле нигезендә үсүенә, күтәрелүенә, аның киләчәгенә начар карап, башка мәдәниятләр эчендә йотылу, руслашу ягына авыучылар килеп чыктылар (урысчы Сәлах Атнагулов[2], Гомәр Әлмөхәмmәтов[3], Мортазин, латинчы Фатыйх Сәйфи[4], Хөснетдин Кәримов[5] кебекләр).

Менә шул уңай белән партия Татарстан Өлкә комитетының матбугат бүлеге тарафыннан киңәш ясалды. Татар активының иң мәсьүл[6] хезмәтчеләре катнашкан бу киңәш өч көн (1927 ел

---

[1] 1927 елда Казанда нәшер ителгән: Ибраһимов Г. Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? / Г. Ибраһимов. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1927. – 40 б. Аннан соң гамәлдәге татар хәрефләренә күчерелеп, «Казан утлары» журналының 1992 елгы 3 нче санында (б. 157–176), «Мәдәни җомга» газетасының 2018 елгы 26 гыйнвар, 2, 9, 22 февраль, 2 март саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Сәлах Атнагулов* – Сәлах (Сәлахетдин) Садри улы Атнагулов (1893–1937) – сәяси эшлекле, публицист, язучы. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[3] *Гомәр Әлмөхәмmәтов* – Гомәр Әлмөхәмmәтов (1895–1939) – җәмәгать эшлеклесе, журналист.

[4] *Фатыйх Сәйфи* – Фатыйх Сәйфи-Казанлы (Мөхәммәтфатыйх Камалетдин улы Сәйфуллин) (1888–1937) – язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Шәхес культы корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[5] *Хөснетдин Кәримов* – Хөсни Кәрим (Хөснетдин Минһаҗетдин улы Кәримов, 1887–1965) – язучы, педагог, җәмәгать эшлеклесе.

[6] *Мәсьүл* – җаваплы.

25 гыйнвар, 11 февраль, 15 февраль) дәвам итеп, һәр ике як үзләренең тезислары-докладлары белән чыктылар. Озак аңлашулар барды.

Нәтиҗәдә ачык яки капланмалы урыслашучылар бик нык җиңелделәр. Партия карарларының һәм ун еллык совет тәҗрибәсенең җимешләрен күз алдында тотып төзелгән тезис-доклад зур күпчелек белән нигез уларак кабул кылынды (бу якта 96% тавыш, тегеләргә 4% тавыш).

Кулыгыздагы әсәр менә шул тезис-докладымның үзгәртми чыгарылуыдыр.

Г. И.

1927–19 февраль – Казан.

## Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?

(1927 ел 25 гыйнварда В.К.П. (б) Татарстан Өлкә комитеты матбугат бүлегенең киңәйтелгән җыелышында тикшерелгән мәсьәлә уңае белән). В. И. Ленин мәкаләсеннән:

«Чуждо ли нам, великорусским сознательным пролетариям, чувство национальной гордости? Конечно, нет! Мы любим свой язык и свою родину, мы больше всего работаем над тем, чтобы ее трудящиеся массы (т.е. 9/10 ее населения) поднять до сознательной жизни демократов и социалистов».

И. В. Сталин сүзеннән: «Пролетарская по своему содержанию, национальная по форме – такова то общечеловеческая культура, к которой идет социализм».

Марксист профессор Покровскийдан[1]: «Культуру определяет язык, главнейшее и необходимейшее орудие культурной передачи,– орудие без которого культура просто немыслима».

### I
### Мәсьәләнең куелышы

1927 нче елның 25 гыйнвар җыелышы пролетариат революциясе һәм социализм эчендә аерым милли мәдәниятләрнең язмышлары турында хәзер бер дәрәҗәгә кадәрле гаҗәп тоелырлык хата фикерләрне мәйданга чыгарып куйды. Без бу мәсьәләдә революциянең юлы һәммә иптәшләр тарафыннан ачык үзләштерелгән дип уйлый идек. Һич булмаса, төп карашларда зур ялгышлар беткәндер дип ышана идек. Алай түгел икән әле: арада кайбер иптәшләрдә бик тирән адашулар, хәрби коммунизмнан калма зур саташулар бар икән әле; мәсәлән, берәүләр әйттеләр: «Татарның теленә, мәдәниятенә әһәмият бирмиләр, аны кирәксез түбән бер әйбер саныйлар. Урыслашу юлында баралар. Урыска йотылалар дип артык кайгырырга ярамый, бу – зәгыйфь мәдәниятне ташлап, зур мәдәнияткә кушылу дигән сүз генә. Моңа каршы көрәшү хаҗәт түгел. Курсларда, техникумнарда артта калган, өлгермәгән шәкертләр өчен ачылган вакытлы хәзерлек группаларның кыйммәте, әһәмияте, роле ни дәрәҗәдә булса, татар мәдәниятенең дә, татар теленең дә хәзер тарихи әһәмияте тормышта шулчаклы гынадыр», – диделәр. Икенче бер иптәш: «Татар теленең, татар мәдәниятенең хәзергә кирәге артта калган

[1] *Покровский* – Покровский Михаил Николаевич (1868–1932) – тарихчы, партия һәм совет эшлеклесе, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1929).

крәстиян массасын безнең дәрәҗәгә (урта тип, татар коммунис-[т]ы сөйли) күтәрү өчен генәдер. Югары мәктәпләрдә (вузларда) татар теле дип маташу – юкка баш авырттыру...» – ди. Өченче берсе әйтә: «Монда мәдәният дип һаман мәктәп, тел, әдәбият, сәнгать, гыйлем тирәсендә генә кайнашалар. Минемчә, культура дигән сүз – развитие производительных сил дигән сүз. Паровоз, электр, трактор – болар һәммә милләтләргә бер дәрәҗәдә кирәк нәрсәләр. Шуңа күрә, төп асылда милли татар мәдәнияте дип йөрергә күп урын да юк. Без бу хакта мәсьәләне ачык куярга тиешлебез: әгәр бер тел, бер мәдәният артта булса, халыкның хуҗалыкта күтәрелүенә киртә булып, бөяп туктатып торса, аны ташлап турыдан-туры югары мәдәнияткә кушылу чарасына керергә кирәк», – ди[1]. Бу өч иптәшкә башка тагы бер-ике иптәшнең шул югарыга охшаш фикере ычкынды. Докладчының да бу мәсьәләдә ачык билгеле карашы юклыгы күренде (тик соңыннан гына аның урыслашучылык ягында икәне бөтенләй ачылды).

Бу 20–30 кешелек бер җыелыштагыларныкы шулай. Болар үзләре шул агымны тиеш дип куәтләүчеләр. Әмма киң партиясезләр арасында сөйләшсәң, аларда буңа кушылу юк, бәлки, бөтен партия шулай карыйдыр, дип, куркынып сөйләүчеләр очраштыргалый. Аларның кайберләре әйтәләр: «Пролетариат революциясе интернационализм юлы белән бара. Аның максуды аерым милли мәдәниятләрне бетереп, уртак, гомуми, бәйнәлмиләл мәдәният тудырудыр. Хәзерге көндә гәрчә милли мәдәниятләргә юл бирелсә дә, ул вакытлы бер тактика гынадыр...» – диләр.

Кыскасы, бу хакта һәр ике якта тирән бер аңлашылмау бар. Кайбер ихлас күңелләр дә монда бер каршылык күрәләр: Имеш, бер яктан без интернационал максудлар өчен каты көрәш алып барабыз, икенче яктан советның, партиянең ярдәме белән бик күп аерым халыкларга милли мәдәниятләр тудырырга, үстерергә тулы ярдәм күрсәтәбез. Моның аркасында электән барлар зураеп, чәчәкләнеп китәләр, сүнгәннәр, басылганнар яңадан тереләп, күтәрелеп чыгалар. Бу – бер кулың белән ясаганны икенче кулың белән җимерү түгелме? Интернационалистның кайбере, милләтченең байтагы менә бу турыда шөбһәле карашлардан котыла алмый. Шул гомуми мәсьәлә эчендә аерым татарныкы да үзеннән-үзе килеп чыга: бу зур пролетариат хәрәкәте эчендә, бу интернационал дулкыны арасында, татар мәдәнияте язмышы ни булачак? Бу милли мәдәният нинди юл белән барачак? Үз ана те-

[1] «Югары мәдәният» сүзе алар телендә конкрет рус мәдәнияте иде. *Авт. иск.*

лендә, үз нигезендә, үз хаҗәтләренә хезмәт итүче татар мәдәнияте туктаусыз үсәр, зураер, халыкның тормышына яктылык бирер дәрәҗәгә җитәчәкме? Яки башкалар тарафыннан йотылачакмы? Юкса, кем йотар? Урысмы, чувашмы, немец, французмы? Әллә юкса, барлык мили хассиятләрдән саф төзелгән берәр бәйнәлмиләл гомуми мәдәният килеп чыгар да, шул йотармы? Без тарихның сукыр агышына бирелеп, кул кушырып карап торырга тиешме, әллә бу мәсьәләләрдә мәгълүм бер принцип буенча, тарихның бер якка таба үзгәрүе өчен билгеле бер план астында активист булып эшләргә тиешме? Безнең активистлыгыбыз, кайсы якка юнәлер – йотылуга, руслашуга, чувашлашуга, тизрәк йоттыругамы, әллә башкачамы?

Югаргы шөбһәле мәсьәлә эченнән менә шундый тармаклар килеп чыгадыр. Болар татар өчен генә түгел, әрмән, әзәрбәйҗан, үзбәк, казакъ, грузин, чуваш, украиналарның һәммәсенә уртак мәсьәләләр. Бу хакта хәтта русларда да шөбһә бар. Чөнки аларда да: «Рус халкы Коминтернның интернационал байрагына корбан ителә, милли рус мәдәнияте җимерелә, бетә»,– дип караучылар бар.

Димәк, мәсьәлә бер татарныкы гына түгел, киң гомуми мәсьәлә. Шуңа күрә моны үзенең бөтен киңлеге белән шул рәвештә карарга һәм шул гомуми җаваптан, аерым татарныкына килергә кирәк. Мәсьәлә болай куела:

– Интернационалист пролетариат хәрәкәте, пролетариат революциясе һәм социализм эчендә аерым мили мәдәниятләрнең язмышы ни булачак? Болар үзләренең мили төсләрен югалтачаклармы? Яки шул нигездә үскән хәлдә интернационал максудлар өчен хезмәт кылачаклармы?

– Болар эчендә татар мили мәдәнияте нишләр? Башкалар үскән, күтәрелгән хәлдә безнеке сүнеп калмасмы? Татар халкы моны үзе ташлап, башка берәр көчле мәдәниятә кушылу чарасын күрергә тиешле түгелме? Яки тарихның сукыр агымына буйсынып, ни булса, шул булыр тактикасын тотармы?

## II

## Яңа һәм иске тип мирзалар карашы

Партиянең XII нче съезды карарларыннан:

«В этих условиях разговоры о преимуществах русской культуры и выдвигание положения о неизбежности победы более высокой русской культуры над культурами более отсталых на-

родов (украинской, азербейджанской, узбекской, киргизской и пр.) являются ничем иным, как попыткой закрепить господство великорусской национальности».

Алда куелаган мәсьәләгә сүздә һәм гамәлдә берничә төрле җавап бар. Боларның берничәсе – иске һәм яңа тип мирзаларныкы (үз халкыннан мәдәни аерылган татар совет чиновникларыныкы).

Иске патшачылык заманының татар мирзалар һәркемгә мәгълүм: болар рус хөкүмәтенең чиновниклары иделәр. Ихлас күңел белән шуңа хезмәт кылдылар. Үзләренең сыйныфташлары иделәр. Дворяннары белән бергә, бер рәвештә тәрбияләнеп, рус мәдәнияте эчендә кайнап, татар халкыннан аерылып яшәделәр. Боларның бөтен көнкүрешләре рус мәдәниятенә, рус теленә баглы иде. Менә шул бытие татарның бу катлавында тик рус мәдәнияте аркасында гына яшәргә мөмкин, татар мәдәнияте юк, булса да кыйммәтсез, аны күтәреп, үстерергә тырышып маташу нәтиҗәсез эш дигән сознание тудырды. Болар татар телен белмиләр, аны кирәксенмиләр, татарның мәктәбе, әдәбияты, тарихы, тормышы болар өчен чит нәрсәләр иде.

Рус җәмәгатьчелеге, рус зыялысы, рус мәдәнияте эчендә кайнап яшәү сәбәпле, безнең хәзерге татар совет хезмәтчеләренең – чиновникларының бер өлешенә дә шул иске мирзалык чире вакытлыча кайтып йокты. Икенче төрле әйткәндә, бездә хәзер яңа тип мирзалар мәйданга килде.

Болар әйтәләр: татарның теле, әдәбияты руснықына караганда ярлы. Татар мәдәнияте рус мәдәниятеннән түбән, татар тормышы руснықыннан артта. Боларга үзеңне һәм халыкны баглау – аны тарихи үсүдән туктату була. Татар мәдәнияте барыбер күтәрелә, үсә алмас, ул рус мәдәнияте дулкынында эрер, йотылыр, диләр. Кайберәүләре ачык әйтә, икенчеләре теле белән әйтмәсә дә, бөтен гамәле белән шул юлда бара. Курсларда, мәктәпләрдә татар теленә әһәмият бирмәскә, аны иске заманның закон божий дәресләре кебек бер күңелсез мәҗбүрият кебек кенә карарга азапланучы кайбер татар егетләре менә шул дулкынның бер мисалыдыр. Бездә хәзер бу яңа мирзалар аерым бер катлау булып киләләр: болар татар әдәбиятын, татар матбугатын укымыйлар, татар телендә язарга белмиләр, моны үзләре өчен кимчелек дип тә карамыйлар, үзенең бу наданлыгын ул ниндидер эчке бер «мәдәни» мактану белән әйтеп куя. Балаларын, якыннарын, әлбәттә, рус мәктәбенә, рус балалар йортына, рус курс-

ларына бирәләр. Иске заманда татар мәктәбе начар булганга, бертөрле динче, милләтче катлау да балаларын рус мәктәпләренә кертәләр иде, ләкин алар һич булмаса, үзләре яки мөгаллим китертеп өйдә ана теле дәресләрен укыталар иде. Әмма безнең хәзерге «мирзалар» моны да эшләмиләр, үзләре, татар гәзитәсенә мәкалә бирергә туры килсә, аны русча яздырып җибәртәләр. Болар әгәр коры уйламаудан, хәзерлексезлектән генә килгән бер чир булса, чарасы җиңел булыр иде, ләкин 25 гыйнвар җыелышы боларның гади чир генә түгел икәнен, бәлки, аерым бер агым рәвешенә кереп барганын күрсәтте. Ягъни гамәли мирзалык үзенә нәзари[1] нигез эзли башлады.

Бу ике заманның ике тип мирзалыгының тамыры бер үк җиргә бара, ләкин язмышлары бөтенләй башка булачак:

Иске тип мирзалар руслаштыру, башка һәммә милләтләрне христиан великорус мәдәнияте эчендә йоту сәясәтен алып баручы пашачылыкның ялчылары иде. Татар хезмәт халкыннан мәдәни аерылган булучылык аларның чиновниклык карьералары өчен беренче шарт иде. Алар татар мәдәниятеннән ничаклы ерагайган булсалар, великоруслык мәдәниятенә сукырча табынып руслашуны ничаклы нык, тирән гамәлләштергән булсалар, шулчаклы уңай һәм уңышлы буладыр иде. Әгәр дә, бу татар мәдәниятеннән аерылу һәм урыслашуны чиркәүдә чукынып, муенына тавык аягы тагу дәрәҗәсенә җиткергән булса, ул иске мирзаның карьерасы тагы да ныграк тәэмин ителәдер иде.

Менә шуңар күрә дә татарның ул мирзалык катлавы берничә йөз еллар буенча үзләренең урыслашу фикерләрен саклап, гамәлдә урыслашып, сүздә бу хәлне рус мәдәниятенең югарылыгы белән аңлатып, бер дәрәҗәгә хәтле көчле хәлдә яшәп килделәр.

Әмма безнең революция чорында да мәйданга килеп чыккан ул яңа калыптагы мирзаларның – совет мирзаларының – хәле алай түгел: чөнки совет һәм партия һәр халыкның үз эченнән, шул милләтнең телен, әдәбиятын, гадәтен, тарихын, тормышын белгән хезмәтчеләр җитештерүне планга куйган. Бу хакта һәр җөмһүриятнең үз конференцияләрендә чыгарылган бик күп резолюцияләрдә ачык рәвештә бик күп мәртәбәләр әйтә барган кебек партиянең XII нче съездында милли мәсьәлә уңае белән чыгарылган карарга да күтәрелгән. Анда менә шул сүзләр бар:

---

[1] *Нәзари* – теоретик.

...Д – Органы национальных республик и областей строились по преимуществу из людей местных, знающих язык, быт, нравы и обычай соответствующих народов[1].

Күрәсез, советның, партиянең карашы, тоткан юлы бөтенләй башкача: үз халкыннан мәдәни ераклашкан чиновниклар түгел, бәлки, аның телен, әдәбиятын, гореф-гадәтен, тарихын, тормышын белгән хезмәтчеләр кирәк. Идарә тик шулар кулында гына булырга тиешле дип карала. Һәм бөтен сәясәт шуңар корыла. Бу сәясәтнең бер тармагы яшь буынны киләчәк хезмәткә хәзерләү мәсьәләсенә кайта: безнең мәктәпләребез, татар мәдәнияте белән нык таныш, нык багланышлы хезмәтчеләр хәзерләргә тиеш.

Шулай итеп бездә яңа тип мирзалар – урыслашкан татар совет чиновниклары киләчәктә йә акрынлап карьераларын, тәэсирләрен югалтырлар, йә татарның телен, әдәбиятын, тормышын өйрәнергә, татар халкы белән даими, мәдәни багланыш ясарга мәҗбүр булачаклар.

Бу – киләчәкнең мәҗбүри хәле. Ләкин хәзердә әле ул яңа тип урысчы надан «мирза» чиновниклар байтак киң урын тоталар әле. 25 гыйнвар җыелышы әнә шул яңа тип «мирзаларның» яки шулар фикрендәгеләрнең карашларын да тыңлап үтте. Болар да нәкъ иске заманның чын, тарихи мирзалары кебек үзләренең татар мәдәниятенә әһәмиятсез, өмитсез, имансыз карашларын урыс мәдәниятенең югарылыгы белән тигезләргә азапланалар. Боларча, татар мәдәниятеннән ваз кичеп, урыс мәдәнияте эчендә йотылу, шуңа кушылу мәсьәләсе гүя тарихның якындагы бер бурычы, имеш. Кыюраклары моны ачык әйтә, хәйләкәрләре эчләрендә яшеребрәк саклый.

Ләкин, һәрхәлдә, мирзалыкның бу яңа рәвеше, бездә хәзергә бар әле. Бу мәсьәләгә партиянең ничек карашы турында бу II нче бүлекнең башына китерелгән эпиграф ачык әйтә. Анда ак өстенә кара белән болай язылган:

– Бу шартлар эчендә урыс мәдәниятенең өстенлеге турында сөйләнүләр һәм украина, әзәрбәйҗан, үзбәк, казакъ һәм башка артта калган халыкларның түбән мәдәниятләрен, урысның югары (гали) мәдәниятенең җиңүе мәҗбүр икәнлеге турындагы сүзләр, великорус милләтенең хакимлеген тәэмин итәр өчен бер чара эзләүдән башка нәрсә түгелдер. Партиянең XII нче съезды

[1] Тәрҗемәләрнең тулы һәм дөрес булып-булмавы турында сүз кузгатып маташырга урын калдырмас өчен һәр урында турыдан-туры урысча оригиналлар үзләре китерелделәр. *Авт. иск.*

менә шулай дип әйтте. Бу – великорусларга карата әйтелә. Безнең чиновник татар «мирзалары» исә үзләре дә аңламастан әнә шул тирә-якны чолгап алган великоруслык «мәдәни» шовинизм тәэсиренә төшәләр.

III

И. В. Сталин сүзләреннән:

«Лозунг национальной культуры был лозунгом буржуазным, пока у власти стояла буржуазия, а консолидация наций происходила под эгидой буржуазных порядков. Лозунг национальной культуры стал лозунгом пролетарским, когда у власти стал пролетариат, а консолидация наций стала протекать под эгидой советской власти. Кто не понял этого принципиального различия двух различных обстановок, тот никогда не поймет ни ленинизма, ни существа национального вопроса с точки зрения ленинизма».

Икенче караш, иске һәм яңа тип милләтчеләрнеке.

Болар үзләренә нигез итеп, иске заманның идеологиясе дөньясында аерым бер мәктәп булып танылган мәшһүр принципны – «адәмнәр тарихы – милләтләрнең, гыйрыкларның (расаларның) үзара көрәшүеннән гыйбарәт» дигән нәзарияне алалар. Һәм әйтәләр: тарих – милләтләрнең үзара тартыш мәйданыннан башка нәрсә түгел, кем көчле, шул җиңә, җиңелгән изелә, йотыла. Башка милләтләр белән көрәш мәйданында җиңелеп югалмас өчен бердәнбер чара: көч, куәт җыярга тырышудыр. Мәдәният менә шул юлда бер корал. Изелеп тапталмас өчен мәдәнияттә өстен булу лязим[1], диләр. Бу хакта Хәнәфи Мозаффар әфәнде үзенең әле басылмаган бер китабында (дин, милләт мәсьәләләре) болай яза (1922): «Һәр милләт үз милләтен уздырырга тырыша, үз милли хосусиятләрен бөтен тәфсыйләте белән сакларга, тәрәккъый кыйлдырырга[2] иҗтиһад итә[3] иде. Куәтле милләтләр арасында көчле ярыш бара иде. Куәтле милләтләр зәгыйфь милләтләрне йотарга вә анлар хисабына үсәргә омтылалар. Вә анлар өстенә атылалар, анларны үзләренә савым сыер ясыйлар, вә анларны хайван урынында күрмичә җәберлиләр иде. Табигый, бу вакыйгаларны күреп торган, бу сәясәтнең золымы астында изелгән вә аның ачы газапларын татыган

[1] *Лязим* – тиеш.

[2] *Тәрәккъый кыйлдырырга* – алга җибәрергә.

[3] *Иҗтиһад итә* – тырыша.

зәгыйфь милләтләрдә дошманлык көчәя, мөдафәгасе[1] уяна, анларда милләтләрен, миллиятьләрен[2] саклау чараларына керәләр. Бөтен милли хосусиятләрен тәмам үткенлеге берлә ачып салып милләтләренең милли хисләрен кабарткан өстенә кабартырга тырышалар иде...»– ди.

Әгәр иске заманның бөтен милли матбугатын – бер татарныкын гына түгел, бөтен дөньяныкын – карасагыз, һәммәсендә сез, шул бер нәрсәне күрерсез. Алар һәммәсе тарихның үткәне, киләчәге тик милли көрәшләр каны эчендә булганлыгын, үләргә теләмәгән милләтләр бу көрәшкә хәзерләнү тиешлеген, бөтен тормыш шулай барганлыгын, шуңа күрә һәр милләт үзен бетерергә, йотарга, изәргә әзерләнеп яткан дошман милләтләр эчендә икәнен онытмаска кирәклекне, һәркайчан менә шул милли көрәш фронты астында торганлыгын ерлыйлар.

Безнең татарның да иске тип милләтчесе шулай иде. Тик пролетариат революциясе дулкыннары арасында бу хакта тирән бер үзгәреш булды. Совет эчендә милләтләрнең үзара талашлары бетте, элек бер-берен, гүя җәберләп, дошман күреп килгән халыклар урыс һәм үз милли буржуаларын куып яңа хәят башлагач, тыныч мәдәни төзелеш хәрәкәтенә бирелделәр. Менә бу хәл бик күпләрнең күзен ачты, мондый могҗизаның тик пролетариат революциясе аркасында гына була алганлыгын үз тәҗрибәләре белән кичергән киң бер катлау демократ милләтчеләрнең игътикадында[3] алмашу ясалды. Болар: милли азатлык, милли мәдәният тик советның, пролетариат диктатурасының канаты астында гына тәэмин кылынуы мөмкин икән дигән иманга килделәр. Һәм шуның буенча совет белән бергә вөҗдан теләгәнчә эшләп баралар. Әмма кечкенә бер туң катлау ихласлыкта болардан читтә калды; бу катлау уйлый: революция бер дулкын, ул килер дә китәр. Ләкин шулай да аңа каршы көрәшеп маташырга ярамый, киресенчә, совет белән килешеп, анардан милли азатлык, милли мәдәният өчен алырга мөмкин булган һәммә нәрсәне суырып калырга кирәк, дигән тактиканы тоталар. Болар: алда яңадан кузгалачак зур милли тартышлар, милли көрәшләр вакытында җиңеп чыгар өчен, пролетариат канаты астында мәдәниләнеп, хәзерләнеп азмы-күпме көч җыйыйк, диләр. Бөтен идеологияләре, бөтен төп игътикадлары, дөньяга милли, сыйнфый карашлары һәммәсе тәмам иске

[1] *Мөдафәгасе* – каршылык күрсәтүе.

[2] *Миллиятьләрен* – миллилекләрен.

[3] *Игътикадында* – ышануында.

тип милләтчеләрнеке нигезендә калган бу кечкенә шайка үзе бик акыллы баш булып кылана. Ләкин, берәүнең әйтүенчә, тактикалары – карта уеннарында алдашып, акча утарга азапланган принципсыз шуллерлар тактикасы булганга, совет белән бөтенләйгә кушылып, вөҗдан буенча эшләп килгән чын яңа киң катлау милли татар зыялысы ул акыллы башлар тирәсеннән китеп беттеләр. Югарыда куелган мәсьәләгә җавап эзләгәндә милләтчеләр арасыннан менә шул төрле катлауларны нык аерып йөртергә кирәк.

1) Чын иске тип милләтчеләр, шулай ук 2) игътикадында иске, әмма тактикасында «яңарган» кечкенә группа пролетариат революциясе эчендә милли мәсьәләнең чишелү рәвешен һаман да үзләштерә алмаучылар; болар: иске алпавыт, буржуа дәверенең хәзерге археология музейлары өчен калдырылган ватык-сыныкларыдыр. Әмма 3) хезмәт халкы эченнән чыккан өченче киң катлау, күптән газаплап, борчып килгән милли язмыш мәсьәләсен тик пролетариат революциясе аркасында гына халык өчен уңышлы рәвештә чишәргә мөмкинлек барлыгына нык игътикад иттеләр.

Димәк, монда интернационал пролетариат хәрәкәте эчендә милли мәдәниятнең үсә алуын аңламаучы – искечеләр һәм бөтен эшләре белән милли мәдәниятнең тик пролетариат революциясе аркасында гына үсүе тәэмин кылыначагына таянган яңачылар бер-береннән нык аерылалар. Бу соңгылар гамәлдә шулай барганнары хәлдә, болар эчендә, кайберәүләрнең, кайбервакыт: пролетариат революциясенең интернационализм нигезендәге лозунглары, принциплары белән милли мәдәниятләрне үстерү гамәле арасында бер каршылык юкмы икән, моның киләчәге ничек булыр икән дигән мәгънәгә охшашлы шөбһәләр очраштыргалап куя. Димәк, бу фронтта, гамәли эшкә нәзари нигез бирүгә тирән бар хаҗәт бар.

## IV

## 1

## Пролетариат юлы

Русия эшче социал-демократия партиясе эчендә милли мәсьәләдә бик зур каты талашлар булып килгәнлеге мәгълүм. Аерым оешмалардан Польша социал-демократлары вакыт-вакыт милли мохтарияткә[1] каршы күтәрелделәр. Люксембург[2] белән

---

[1] *Мохтарият* – бәйсезлек.

[2] *Люксембург* – Роза Люксембург (немецча Luxemburg, полякча Luksemburg)

Ленин арасында бу хакта өлкән полемикалар кичте. Урыслардан Пятаков[1], Бухарин[2] иптәшләр әле Октябрьдән соң, 1919 нчы елның партия съездларында шул иске каршылыкларны яңартып чыктылар.

Ләкин Ленин юлбашчылыгы астында бик күптән үк зур күпчелек белән бу мәсьәлә чишелә килде: II съезд (1903), 1913–14 нче елларда VIII нче съезд моның ачык моментлары иде. Октябрь революциясе булу белән бу хакта аерым декларацияләр игълан кылынып, конституциягә дә кертелде. Икенче яктан канлы гражданнар сугышы бетәр-бетмәс бу милли программа гамәлгә, тормышка керә – һәркайда милли җөмһүриятләр төзелә башлады.

Бу вакыт партия эчендә нәзари көрәш беткән, сүздә һәммәсе милли мохтарияткә буйсынганнар иде. Ләкин җирле халык күпчелек булган урыннарда аерым конкрет җөмһүрият мәсьәләсе күтәрелү белән гамәлдә моңар каршылык кузгалды. Каршылар ике гөруһ[3] иде: 1) урыс коммунистлары[4], 2) җирле халыкның үз коммунистларының сул канаты.

Татарда бу соңгыларның башында Гали Шамигулов[5] иптәш булды. Шуның буенча ул хәрәкәт шамигуловчылык дип аталды да. Болар, әлбәттә, татарда гына түгел иде, һәр халык эчендә үз коммунистларыннан бер гөруһ та, кайбер урыслар да аерым җөмһүрият төзүне интернационализмга каршы бару дип, милләтчелек дип уйладылар. Шул нигездә каты көрәшләр барды. Ләкин съездларның нәзари көрәшләрендә ленинизм җиңгән

(1871–1919) – немец, поляк һәм халыкара эшчеләр хәрәкәте эшлеклесе, поляк социал-демократиясе, Германия социал-демократиясендә һәм 2 нче Интернационалда сул-радикал агым теоретикларыннан һәм җитәкчеләреннән, Германиядә коммунистлар партиясен нигезләүчеләрнең берсе.

[1] *Пятаков* – Георгий (Юрий) Леонидович Пятаков (1890–1938) – совет һәм партия эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган (1988).

[2] *Бухарин* – Николай Иванович Бухарин (1888–1938) – сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1929). Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланаган (1988).

[3] *Гөруһ* – төркем.

[4] Татар җөмһүрияте төзүгә урыс коммунистларының ничек каршы барганлыгын ачык күрү өчен Ходорковский иптәшнең «Биш ел эчендә» атлы мәҗмугада (Казан, 1925) басылган хатирәләрен карарга кирәк (275–279 нчы битләрдә). *Авт. иск.*

[5] *Гали Шамигулов* – Гали Камалетдин улы Шамигулов (1890–1959) – дәүләт эшлеклесе.

кебек, гамәли совет төзелешендә дә ул өстен чыкты. Бер гөруһ урыслар белән үтә сул канат шамигуловчыларның каршылыкларына карамастан, милли җөмһүриятләр мәйданга килделәр.

Партиянең милли программасы шулай итеп гамәлгә куела башлады.

Димәк, мәсьәлә чишелде, ләкин бөтенләй түгел, бигрәк тә ачык сәяси булган ягы белән чишелде, әмма милли программаның мәдәни моментларына киләнсә, монда бетмәс-төгәнмәс аңлашылмаулар, хаталар әле һаман да бик күпләр. Партиянең милли программасын гамәлгә куюда милли җөмһүриятләргә каршы барганлыклары өчен урыс иптәшләр Ленин һәм Үзәк комитет тарафыннан бик нык орышылдылар. Шул сабакны бөтенләй онытмаганда, аннан соң милли программаның мәдәни моментлары һәммәсе сәяси яклар белән бөтенләй бәйланып беткәнгә күрә, алар хәзер сүздә ачык чыкмыйлар, чыгарга телмиләр дә. Чөнки тагын ялгышудан куркалар. Ләкин алар да милли мәдәниятләр мәсьәләсенә бик тирән шөбһә белән караучылар, гамәлдә һәр адәм саен киртә салучылар, әлбәттә, барлар. Болар теге вакыт милли җөмһүриятләрне интернационализмга каршы дип хыял кылалар, җөмһүриятне идарә кылырга җирле халыктан большевик көч табылмас, дип саташалар иде. Хәзер инде ул украина, үзбәк, казакъ, әзәрбәйҗан, татар, әрмән, грузин, чуваш халыкларының телләре, мәдәниятләре бик зәгыйфь бит, болар белән маташканчы югары бөек урыс мәдәниятенә кушылып китү – бу милләтләр өчен зур файдалы булмас идеме? дигән шөбһәдәләр.

Шундый шөбһәләр, хыяллар кайбер урыс иптәшләрдә булган кебек, җирле халыкның үз эченнән чыкканнарда да юк түгел. Бездә шамигуловчылар теге вак милли җөмһүрияткә каршы кузгалсалар, аның кирәгенә, файдасына, нәтиҗәле булуына ышанып җитмәсәләр, хәзер милли татар мәдәнияте дигәнгә шундый нык шөбһә белән, ышанмау белән карыйлар, ягъни сәяси шамигуловчылык артыннан мәдәни шамигуловчылык килә. Бу соңгының кешеләре дә, нигезләре дә, әлбәттә, башкалар, ләкин тамырлары бердер.

Без югарыда яңа һәм иске тип мирзалар аналогиясен йөрткән идек. Милли мәдәниятләргә әһәмиятсез караучылар үткән тарихта да булганын сөйләп, шуннан мисал алган идек. Хәзер күрәбез, бу агым үзенең икенче бер канаты, дөресе, тамыры белән шамигуловчылык хәрәкәтенә кайтадыр. Димәк, бу агым

ике чишмәдән су ала. Әмма болар бәхетсезрәк шартларга туры килделәр. Чөнки милли җөмһүриятләр төзү — үзе милли мәдәниятне нык нигезгә утырту, шуңа төпле туры юл ачу, дигән сүз иде.

Ләкин шулай булса да, бу агым җөмһүриятләрдә милли мәдәниятләрнең әһәмияте, кыйммәте күтәрелергә, үсәргә бик нык киртә булачаклар. Шуның өчен боларга каршы даими, озак көрәш куярга туры килми булмас. Моның бик ачык мисалы үткәндә дә күрелгән иде. Берничәсен хәтерлик.

1924 нче елның февралендә Мәскәүдә җөмһүриятләргә кермәгән татар-башкорт мәгариф эшчеләренең съезды булган иде. Шунда мәктәпләрдә ана теле мәсьәләсендә зур талаш чыкты, секция тарафыннан һәммә беренче баскыч татар мәктәпләрендә уку теле — ана теле дип тәкъдим кертелгән иде. Шуңа берничә иптәш[1] «сәнагать теле» кирәк дип каты каршы чыкылар. Алар әйтте: эшче төбәкләрдә татар теленең файдасы юк, анда беренче баскычларда ук уку теле — сәнагать теле — урыс теле булсын», диделәр. Без моңа каршы бик каты сугыш ачарга кат-кат полемика ясарга мәҗбүр булдык. Шуның аркасында гына ана телен үткәрә алдык. Шул ук съездның вәкилләреннән аерым бер киңәшмә ясалып, әдәби тел һәм атамалар тикшерелгән иде. Анда өч агым булды. Берәүләр искедәге кебек гарәпчәлекне саклауны якладылар, әмма берәүләр һичбер нәрсә белән чикләмәстән урыс сүзләренә капка ачуны тәкъдим кылдылар. Безгә бу мәсьәләдә бик күп көрәшкәннән соң дөрес тезисларга күпчелек җыярга мөмкинек булды[2].

Мин уйлыйм, моннан 3–4 ел элек кузгалган әнә шул кечкенә дулкыннар татар һәм урыс мәдәниятләре мәсьәләсендәге хәзерге талашларның ерак беренче кузгалышы иде. Хәзер ул киңрәк рәвештә үзен күрсәтә башлады: аерым кешеләрнең хатасыннан үтеп укучы яшьләрнең бер өлешенә дә бу чир йокты. Һәрбер начар йогышлы чир кебек урыслашу сәясәте чире дә тиз таралыр. Шуңа күрә ул мәсьәләне ачык куеп, аңа кискен җавап кирәк. Зарарлы хаталар белән көрәшергә кирәк. Көрәшнең беренче планында, әлбәттә, бу мәсьәлә дә пролетариатның тоткан юлын аңлатудан башланырга тиешле.

---

[1] Милли мәдәнияткә әһәмиятсез караучылар арасында хәзер аларның берсе бар. *Авт. иск.*

[2] Бу тезислар хәзер Гыйльми үзәк тарафыннан рәсми кабул кылынып гамәл өчен таратылдылар. *Авт. иск.*

## 2

Беренче баскыч мәктәпләрдә уку ана телендә булу кирәклеге мәсьәләсе турында хәзер ике сүз ишетелми. 24 нче елның Мәскәү съездында урыс телендә булсын дип чыгучылар Донбасска таянырга уйлаганнар иде. Аннан бирле үткән 3–4 ел эчендә Донбасстан, Уралдан, Себердән һәм татар эшчесе күпчелек булган башка һичбер җирдән үз ана телен ташларга дип күтәрелү күренмәде. Димәк, бу беренче нигез момент хәзер инде өзелгән.

Өлкәннәр арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү эшендә дә бераз аңлашылмаучылык бар иде. Кайбер урыннарда, бигрәк тә урыс күпчелеге эчендә калган эшчеләр арасында кайбер иптәшләр урыс телендә генә үткәрергә чамалыйлар иде. Хәзер ул да тынычланды. 1913–14 нче елларда, бигрәк тә сугыш чорында, Русиядә милләтчелекнең аеруча котырган заманы иде. Бу исереклек социал-демократиянең дә бер катлавын үз эченә алган иде. Менә шул заманда Владимир Ильич Ленин «О национальной гордости великороссов» исемендә бер мәкалә язды. Анда шул сүзләр бар иде:

«Без аңлы великорус пролетарийлары өчен милли горур[1] чит бер нәрсәме? Әлбәттә, түгел. Без үзебезнең телебезне, үзебезнең туган илебезне сөябез. Без башка һәр нәрсәдән артык үз туган илебездәге хезмәт массасы (ягъни андагы халыкның уннан тугыз өлешен) аңлы демократлар һәм социалистлар дәрәҗәсенә күтәрү өчен эшлибез».

Монда мәсьәлә партия программасы ягыннан бигрәк пролетариатның үз теленә, үз иленә карашы ачык бирелә. Арада аеруча мөһим моменты соңгысыдыр. Анда һәр революционерның, һәр коммунистның өстендәге бурыч, башлыча, үз илендә, үз халкының хезмәт массасы эчендә эшләү икәнен аңлата.

Без югарыда партиянең XII нче съезд карарларыннан берсен укып үттек (II бүлектә). Аның тәрҗемәсе болай:

«Милли җөмһүриятләрнең һәм өлкәләрнең органнары башлыча җирле халыклар эченнән чыгып, шуларның горефләрен, гадәтләрен, тормышларын, телләрен белгән кешеләрдән төзелергә тиешле».

Менә бу момент бер яктан милли җөмһүриятләрнең эшләрен башкаручылар – шул җирле халыкның үзеннән куелу гына җитмәвен, бәлки, бу кешеләр шул халыкның тормышы, гореф-гадәте, теле белән таныш булуларын лязим итә. Урыслашкан

[1] Гордость. *Авт. иск.*

«мирза» татар чиновниклары партия, совет өчен үзләренең милли җөмһүриятләрендә кыйммәтләрен бетерәләр. Икенче яктан моның белән мәктәп-тәрбия мәсьәләсендә төп бер принцип бирелә: мәктәпләр тормыш өчен кеше хәзерләргә тиеш. Бу халыклардан хәзерләнүчеләрдән йөзгә берсе, бәлки, башка милләтләр эчендә эшләргә китәр. Әмма калганнары, әлбәттә, үз илләрендә, үз милләтләре арасында эшләячәкләр. Мәктәп исә аларны югарыда күрсәтелгәнчә, үз теле, үз мәдәнияте белән сугарып чыгарырга бурычлы була. Ул һәм үзенең программасын шуңа карап төзәргә мәҗбүр. Беренче баскычлар да, икенче баскычлар да, техникумнар, курслар, институтлар һәм югары мәктәпләр дә партиянең-советның әнә шул принцибы буенча, үзләрен җирле тел, мәдәният белән тәрбияләнгән хезмәтчеләр чыгарырга – димәк, дәресләрне шуңа каратып куярга тиешле булалар.

Без бу китапның башында эпиграф рәвешендә мәшһүр маркcис[т] большевик профессор Покровскийның «Урыс мәдәнияте тарихы» дигән китабыннан бер сүзне китергән идек. Аның тәрҗемәсе болай була:

«Мәдәниятне аерып билгеләүче нәрсә һәм мәдәният алуда иң баш, иң кирәкле коралы – телдер. Бу тел коралыннан башка мәдәният һичбер төрле була да алмый» ди.

Октябрь революциясе менә бу якны бик нык ачып бирде. Милли телләрне үстерү, мили әдәбиятларга киң юл һәм зур ярдәм бирү, мили телләрдә гыйльми-сәяси, әдәби атамалар тудыру моментлары хәзер совет милли җөмһүриятләрендә дөньяның һичбер җирендә күрелмәгән рәвештә кайнап, җанланып китте. Гади вакытларда, бәлки, ничә ун еллар кирәк булачак өлкән эшләр хәзерге диктатура заманының рухы буенча, берничә ел эчендә мәйданга киләләр. Казагстанда, Татарстанда, Кырым һәм үзбәкләрдә аз бер заманда хисапсыз күп нәтиҗә алдылар. Мәдәни хәзерлеге, икътисады, куәте зуррак булганнар исә инде телләре, мәдәниятләре белән университетларгача барып тулдылар. Төрки җөмһүриятләрдән Әзәрбәйҗан үзендә университет ачып, аның Көнчыгыш факультетында төрки телдә лекция укуны гамәлгә куярга ирешде. Үзбәкстанның Ташкент университетында да Көнчыгыш факультеты ачылып, анда төрек[1] халыкларыннан беренче мәртәбә мөдәррисләр кертелеп, төрки телдә эш булганлыгы күрелде. Үзенең мәдәни хәзерлеге зур булган Грузия, санының азлыгына (миллионнан кимнәр) карамастан, бөтен аппаратлар-

[1] *Төрек* – төрки.

ны да һәм гыйлем йортларын да ана телендә куйды. Хәзер грузин профессоры грузин телендә университетта дәрес алып бара. Саны күп, гыйльми хәзерлеге югары булган Украина каты кул белән үз телен күтәрде. Университетларны украинлаштырды. Ул гына түгел, аз бер заман эчендә, пролетариат революциясенең ярдәме аркасында, украина телендә эшли торган Гыйльми академия мәйданга китерде. Болар шөбһәсез, пролетариат хәрәкәтенең милли мәдәниятләр үстерү юлында күрсәткән могҗизаларыннандыр.

## V

## Сталин формуласы

Дөньяның алтыдан бер өлешендә туктаусыз кайнап, үсеп торган бу милли мәдәниятләрне күз алдына китергәндә кайбер күңелләрдә шөбһәләр уйгана: интернационал максудлар өчен туган революция бөтенләй милли теләкләргә корал булып китмиме? Бу милли мәдәниятләрнең киләчәге ни булыр? Боларны киләчәктә гомуми мәдәнияткә кушу мәсьәләсе тагы зур бер комачау тудырмасмы?

Бу мәсҗәлә төрле фикер кешеләрендә төрлечә калыпланып чыга. Шуңа күрә бу хакта җавап кирәк. Минемчә, моңа иң ачык һәм тулы җавапны И. В. Сталин иптәш бирде. Көнчыгыш хезмәт халыклары университетында сөйләгән сүзендә ул болай диде[1]:

– Мин Көнчыгыш совет җөмһүриятләрендә милли мәдәниятләрне күтәрү турында әйткән идем. Ләкин милли мәдәният дигәне нәрсә ул? Милли мәдәният белән пролетариат мәдәниятен ничек бергә җыярга мөмкин? Ленин бит сугышка чаклы ук әйткән иде: «Бездә ике төрле мәдәният бар: берсе буржуазия мәдәнияте, икенчесе социализм мәдәнияте. Милли мәдәният дигән лозунгы – реакция лозунгысы. Буржуазия бу лозунгы белән хезмәт халык массасының аңын милләтчелек агуы белән зәһәрләргә тели», – дигән иде. Шулай булгач, милли мәдәният төзү, ана телендә курслар, мәктәпләр үстерү, җирле кешеләрдән кадр җитештерү кебек эшләрне социализм төзү белән, пролетариат мәдәнияте төзү белән ничек бергә сыйдырырга була? Монда үтеп чыга алмаслык каршылык юкмы? Әлбәттә, юк!!

Без – пролетариат мәдәнияте төзибез. Монда һич шик юк. Ләкин үзенең мөндәриҗәсе[2] буенча социализм нигезендә бул-

---

[1] «Правда», 1925, 22 май буенча алдым. Бу хакта аерым китап та бар, «Биш ел эчендә» китабында да бар (Казан, 1925. Комбинат басмасы). *Авт. иск.*

[2] *Мөндәриҗәсе* – эчтәлеге.

ган пролетариат мәдәнияте, социализм төзелешенә катнашкан төрле халыкларның тормышларында, телләрендә булган башкалыкларга карап, үзенең тышкы калыбында, шәкелендә бик төрлечә була: мөндәриҗәсе белән пролетариатча, форма буенча милли – менә социализм бара торган гомум адәм мәдәнияте шулай булачак. Пролетариат мәдәнияте милли мәдәниятне бетерми (юкка чыгармый), бәлки, аңа мөндәриҗә бирә. Шулай ук киресенчә, милли мәдәният пролетариат мәдәниятен бетерми (юкка чыгармый), бәлки, аңа форма бирә.

Шул ук төп фикерне ачуда дәвам итеп Сталин әйтә:

– Буржуазия властьта булып, халыкларның милләт булып оешулары аның канаты ясалган дәвердә милли мәдәният лозунгысы – буржуазия лозунгысы иде. Пролетариат властьны алып, халыкларның милләт булып оешулары совет канаты астында ясала башлагач, милли мәдәният лозунгысы – пролетариат лозунгысы булып әверелде. Ике дәвердә ике төрле хәл эчендә булган бу принцип аермасын аңламаган кеше – ленинизмны һичбер вакыт аңлый алмас, шулай ук ленинизм каршында милли мәсьәләнең үзәге ничек булганын да аңлый алмас.

Милли мәдәниятләр мәсьәләсендә оппортунистларның карашларын һәм социализм вакытында телләрнең ни хәлдә булачагын аңлату юлында Сталин бу рәвешле сөйли:

– Кайберәүләр (мәсәлән, Каутский[1]) социализм вакытында башка һәммә телләр бетеп, бөтен кешеләр өчен уртак булган бер телнең тууы турында сөйләнәләр. Мин мондый бөтен дөньяны эченә алган бер тел була алу нәзариясенә аз ышанам. Тәҗрибә, һәрхәлдә, бу нәзарияне куәтләп түгел, бәлки, моңа каршы сөйли. Моңа чаклы хәл шулай барды – социализм революциясе телләрнең санын киметмәде, бәлки, арттырды гына. Чөнки адәм дөньясының иң тирән яткан түбәнге катлауларын кузгату, боларны сәяси мәйданга күтәрү сәбәпле социализм революциясен аңа кадәрле бөтенләй мәгълүм булмаган яки аз мәгълүм булган милли телләрне яңа тормышка уйгатып чыгарадыр. Иске патшачылык заманында Русиядә илледән артык милләтләр һәм этнографик группалар бар дип кем уйлар иде? Октябрь революциясе иске богауларны өзде, мәйданга бик күп онытылган халыкларны чыгарды, шуның белән аларга яңа тормыш, яңа хәрәкәт бир-

[1] *Каутский* – Карл Каутский (Kautsky) (1854–1938) – Германия социал-демократиясенең һәм 2 нче Интернационалның лидерларыннан һәм теоретикларыннан берсе, центризм идеологы.

де. Хәзер Һиндстан турында бөтен бер милләт кебек сөйлиләр. Ләкин анда революция булса, мәйданга аңарчы (киң дөньяга) мәгълүм булмаган, ләкин үзләренең аерым мәдәниятләре белән яшәп килгән бик күп милләтләр, баш күтәреп, тарих мәйданына чыгарлар. Әгәр бу төрле милләтләрне пролетариат мәдәниятенә кушарга уйланылса, бу кушулар, ул милләтләрнең тормышларына, муафыйк[1] ясалган рәвештә генә булачагында шөбһәләнергә ярамый,– ди.

Бүрәт коммунистларының сөальләренә җавап итеп Сталин болай ди:

– Бүрәт[2] иптәшләр гомуми адәм мәдәнияте төзелгәндә аерым милләтләрнең ассимиляциясе (йотылуы) турында мәсьәлә куялар. Шөбһә юк, кайбер милләтләрнең йотылулары мөмкин, бәлки, йотылалар да. Андый процесслар элек тә бар иде. Ләкин кайбер милләтләрнең йотылу процессы башка милләтләрнең зур күпчелеге булып күтәрелүләренә каршы булмый, бәлки, шуны куәтли генә. Чөнки аерым берәүләрнең йотылуы милләтләрнең гомуми тәрәккъкый итүләренең нәтиҗәсенә башка нәрсә түгелләр. Менә бу безнең алдагы фикерләребезгә куәт кенә арттырадыр. Кайбер аерым милләтләрнең йотылу мөмкинлеге безгә шуны ачып бирә: гомумадәм өчен булган пролетариат мәдәнияте милли мәдәниятләрне җимерми-бетерми, бәлки, боларның булуын лязим итә һәм боларга яшәргә ризык бирә. Шулай ук милли мәдәниятләрдә гомумадәмнең пролетариат мәдәниятен бетерми-юкка чыгармый, бәлки, аны тутыра, аңа байлык арттыра гынадыр...– ди.

Сталин фикерләре аеруча шәрех теләмиләр. Монда һәммә мәсьәлә якты көн кебек ачык куелган. Шуларга ачык кискен җаваплар бирелгән: пролетариат революциясе милли мәдәниятләргә үсәргә киң мәйдан бирә. Социализм вакытында да милли мәдәниятләр бетмәячәкләр, баеп, зураеп күтәреләчәкләр: «милли» белән «пролетариат» мәдәниятләрен бер-беренә каршы куярга ярамый. Болар бер-беренә дошман түгел, болар бер-берен бетермиләр, бер-беренә каршы көрәш ачмыйлар, киресенчә, болар берен-берен тутыралар, бер-берен баеталар, боларның бер-беренә мөнәсәбәт рәвеше. Мөндәриҗәсе белән пролетариатча, әмма формасы белән милли булачак.

[1] *Муафыйк* – яраклы.

[2] Бурят. *Авт. иск.*

Бу формула турында озак тукталып торырга хаҗәт юк дип беләм. Моның мәгънәсе, аңлаешы һәм форма буенча милли булыр дигән сүздән морат[1] нәрсә икәнлеге, әлбәттә, һәркемгә ачык: халыклар үзләренең телләре, гореф-гадәтләре, тормышлары, тарихи язмышлары буенча бер-берләреннән тышкы калыпларда байтак аерылалар. Шуңа карап, аларның һәрберенең мәдәнияте, мәдәни хәрәкәте дә тышкы төстә үзенә башка аерым рәвештә гәүдәләнәләр. Мәсәлән, мәктәп, сәнгать, гыйлем, әдәбият – болар һәммәсе милләтнең үз телендә булырлар. Үз телендә киңәеп, тирәнәеп үсәрләр; үз зәүкына, үз хаҗәтләренә каратып туарлар, үз уңгай, аңлаешлы калыпларга салыныrлар, үз тормышы белән сугарылып, үзләренә аерым тарихи моментлары, тудырган мәсьәләләре юлында нык баглылар; ләкин болардагы мәдәни хәрәкәт һәм икътисади-сәяси куәт татардагыдан зәгыйфь, диярләр.

Урысның теле бик бай, әдәби, гыйльми теле бөтенләй эшләнгән һәм матур. Урыс әдәбияты дөньяның иң алдынгы әдәбиятларыннан санала. Урыс мәдәнияте безгә караганда бик күп, бик күп дәрәҗәдә югары. Соңгы ун ел исә, урыс әдәбиятына, урыс гыйлеменә, урыс мәдәниятенә бик көчле рәвештә пролетариат элементы кертеп, аеруча зур яңа кыйммәтләр арттырды. Бу югары (гали) мәдәният безгә якын булу гына түгел, һәммә яктан безне чолгап алган. Без аның эчендә диңгездәге бер атау кебек, уралып алганбыз, тарихи яктан караганда, мең еллар буенча бу мәдәнияткә күрше яшәдек, 3–4 йөз ел инде бөтенләй моның уртасында калдык. Бу мәдәният бик күп яктан безгә остаз була килде. Безнең яңаруыбыз, безнең әдәбиятыбыз, безнең гыйлемнәребез, безнең революция хәрәкәтләребез, һәммәсе бу урыс мәдәниятенең бик нык тәэсире һәм мөгаллимлеге астында үстеләр. Икътисади, сәяси яктан да без бөтенләй диярлек беректәнбез. Элементлары туктаусыз арта баралар, урыс мәдәнияте туктаусыз дулкыннар белән безгә керә, тула бара. Шулай булса? Шулай булса, татар өчен, үзенең иске колакчынын[2] утка ягып, бу яңаны кию файдалырак булачагы үзеннән-үзе ачык түгелме?

Татарның саны бик аз. Үзе бик таркау. Мәдәнияте урыс мәдәнияте белән чагыштырмас дәрәҗәдә түбән! Татарның әдәбияты, татарның театры, татарның мәктәбе, сәнгате, матбугаты – болар бит һәммәсе Мәскәүнеке белән үлчәштергәндә бөтенләй югалып

[1] *Морат* – максат.

[2] *Колакчынын* – колакчын бүреген мәгънәсендә.

калалар. Татарның хуҗалыгын, икътисадын тикшереп караучылар – якын киләчәктә бик тиз генә татар мәдәниятенең гөрләп үсеп тиз генә югары менеп җитүенә өмет ачмыйлар түгелме?

Бүрәт егетләре үз халыкларының мәдәниятләре турында күп уйлаганнар булса кирәк, Сталинга аерым хат язып, җавап сораулары шуны күрсәтә, әмма бездә бу әле нәзари рәвештә куелмаган, уйланып, тикшерелеп ачык юл сызылмаган, маяклар кадакланмаган.

Ләкин гамәлдә бу мәсьәләгә төрлечә җавап бирелә, төрле төркемнәр үзләренең кайбер эшләре белән моңа ничек җавап биргәнлекләрен күрсәтәләр.

Әһәмияте, роле аз булган бер төркем – фатализм иманындалар. Алар тарихның «сукыр» агышын барыбер үзгәртеп булмый дип бу хакта бертөрле активистлыктан ваз кичкәннәр, ни булса, шул булыр!

Икенче берәүләр, аңлап яки аңламастан, уйлап яки уйламастан, теләп яки теләмәстән бу зур мәсьәләдә тормышның кечкенә бер катлавында сизелгән агымга яталар. Тикшереп, гыйльми көтмәстән, бер нәтиҗәгә килүне көтмәстән, татар мәдәниятенең киләчәк язмышын җиңел кулдан чишеп ташлыйлар.

Техникумда татар малаеның «Әй, татарда нәрсә булсын, мин лутчы урысчага бирелим» дип, татар китабын атып бәрү вакыйгасы менә моның байтак очрый торган кечкенә тупас мисалларыннан берсе була алыр. Бик зур мәшәкать белән татар дәресләре кертелә алган Казан югары мәктәпләренең берендә (вузда) укучы шәп татар егете гыйлеме бик чамалы булган урыс теле мөгаллиме алдында тирләп, куркып, калтырап зачет биргәне хәлендә, квалификациясе буенча тегеннән өстен торган татар теле, әдәбияты укытучысы алдына барып зачет бирергә хурлануы, шуны «булса да, булмаса да ярый ла» дип каравы тагы шул бер нигезнең төрлечә күренүеннән башка нәрсә түгел. Кайбер татар егетенең үз теле, үз каләмен белмәвен кимчелеккә санамавы, татар әдәбиятын укымауны ниндидер бер «мәдәни» мактану белән сөйләнеп йөрүе кебек хәлләр дә шуның үрнәгедер. Татар редакциясенә бирәчәк мәкаләсен урыс телендә язып яки яздырып җибәрүе дә әнә шул аңлап яки аңламыйча дәвам кылган урыслашу нәмунәләреннән[1] бередер.

Татарның мәктәбе, татарның әдәбияты, татар телендәге гыйльми әсәрләре, татар театры һәм татар мәдәниятенең баш-

[1] *Нәмунәләреннән* – үрнәкләреннән.

ка күп тармаклары да татарның җилкуарлык бер нечкә катлавы алдында шундый бер хөрмәтсезлек белән каралалар; башка бик күп рәсми урыннарда да татар теле, татар мәдәнияте әле һаман эчке тирән мәгънәви кыйммәт һәм авторитет алмаганлыгын, монда нечкәләп тикшерсәк, урыс мәдәнияте алдында татарныкын кадерсезләү галәмәтләре очраганлыгын, әлбәттә, яшерергә ярамый. 25 гыйнвар җыелышында кайбер иптәшләр уйламыйрак ычкындырган сүзләрендә моның серләрен бераз ача да төшәдер.

Берәүнең:

– Татар теленең, татар мәдәниятенең кирәге – караңгы крәстиян массасын үз телендә агартып, безнең дәрәҗәгә күтәрү өчен генә, – дигән сүзе;

Икенче берәүнең:

– Татар теленең, мәдәниятенең роле, кыйммәте мәктәпләрдә артта калган группалар өчен ясала торган вакытлы хәзерлек группаларының кыйммәте, әһәмияте дәрәҗәсендә генәдер,– дигән фикере;

Өченче берәүнең:

– Татар мәдәниятенә әһәмият бирмәү һәм руслашу дигән нәрсә белән кешеләрне артык куркытырга урын юк. Моның мәгънәсе – зәгыйфь, кечкенә мәдәнияттән зур мәдәниятка кушылу дигән сүз генә,– дип ачыктан-ачык мәшһүр тарихи руслашу сәясәтен аерым бер нәзари нигезгә салуы.

Болар һәммәсе әнә шул татарның яңа тип мирзалары аерым бер дулкын – аерым агым рәвешендә гәүдәләнеп килгәнлеген күрсәтүче хәлләр булалар.

Димәк, безгә татар мәдәниятенә каршы үзенең сәлби[1] карашын ачык билгеләгән бер нечкә катлауның барлыгын бер факт итеп карарга туры килә. Бу бер як.

2

Ләкин татар хезмәт массасы, татар эчендәге мәдәни-иҗтимагый агым нинди юл белән бара? Революция һәм тормыш бөтенләй шул югаргы дулкындамы, әллә моңа каршымы?

Моннан 8–9 еллар элек үк революция дулкыны эчендә бер агым бөтен хәрәкәтне шул якка таба борып алып китәргә теләде. Җөмһүрият булсынмы, юкмы дигән мәсьәлә – менә шуның күләгәсе иде. Татар җөмһүрияте гәрчә ул вакыттагы талашларда, тик сәяси бер нәрсә кебек күренсә дә, асылда аерым милли җөмһүрият формасы билгеләнә иде. Чөнки җөмһүрият төзү

[1] *Сәлби* – кире.

димәк – милли татар мәдәниятенә төп нигез салмак, татар мәдәниятенең совет хуҗалыгы һәм икътисади нигезенә һәммә тармакларында эшләп баетып торучы бер машина кормак дигән сүз иде. Җөмһүрияткә каршы баручылар – аңлап яки аңламастан, уйлап яки уйламастан пролетариат революциясе эчендә татар мәдәниятенә юл куймау, татарның аерым мәдәниятле булуыннан бигрәк югары рус мәдәниятенә кушылып китүен яклаучылар иде.

Партия үзенең бу саташкан улларын акылга утыртты. Үзенең бөтен мәдәни-сәяси нәтиҗәләре белән берлектә җөмһүриятне төзеп бирде. Милли мәдәниятнең нигезләреннән берсен рәсмиләштерде. Элекке заманда татарның руслашуын, үз мәдәниятеннән ваз кичеп, рус мәдәнияте эченә йоту сәясәтен алып баручылар туры мәдәни яктан кысу белән тукталмадылар, бәлки, татарны милли мәдәниятнең нигезе булган хуҗалык-икътисад ягыннан да изәргә, зәгыйфьләтергә тырышалар иде.

Пролетариат революциясе милли мәдәнияткә ирек биреп, аңа җөмһүрият кебек рәсми нигез салу белән генә калмады, бу мәдәни хәрәкәтнең икътисади фундаменты һәм хуҗалыкның ныгуы турында да татар өчен бик күп ярдәмнәр ясады.

Революция аркасында татар крәстияненең җире артты. Моның белән мәдәни хәрәкәт нигезе – икътисады бер дәрәҗә күтәрелде, элек татар авыллары шәһәрләргә, зур елгаларга, тимер юлларга якын җирләрдән читкә, аз табышлы урыннарга сөрелгәннәр иде. Пролетариат хәзер бу зур тарихи җәбергә каршы чара күрү юлын тотты – татар крәстияннәренең бер өлеше Волгага, Казанга якын урыннарга, элекке мәшһүр кенәз Гагариннар[1], маркиз Поулуччи җирләренә күчерелә башланды. Хәзер ул

[1] …*кенәз Гагариннар* – тулырак кара: Большая Российская энциклопедия.– М.: Науч. изд-во «Большая Российская энциклопедия», 2006.– Т. 6: Восьмеричный путь – Германц. – С. 238–240.

туфракларда яңа үсеп чыккан Йолдызлар[1], Үрнәкләр[2], Нариман[3], Кызыл Байрак[4], Идел, Чулпан, Мулланур Вахитов[5], Кызыл Юл[6], Игенче[7], Берек[8], Маркс, Татарстан, Салкын Чишмә[9], Яңа Тор-

---

[1] *Йолдыз* – 1925 елда Кырлыбаш һәм Кази авылларыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантоны Тәмте волостена керә. 1927 нең 14 февраленнән – Тәмте, 1931 нең 20 сентябреннән – Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән – Тәмте, 1958 нең 16 июленнән – Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән – Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан – Югары Ослан районында.

[2] *Үрнәк* – 1920 елларның башында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Арча кантоны Ильин волостенда, 1927 нең 14 февраленнән – Воскресение, 1927 нең 1 августыннан – Казан, 1938 нең 4 августыннан – Юдино, 1958 нең 16 июленнән – Яшел Үзән районында.

[3] *Нариман* – 1924 елда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантоны Ташёвка волостена керә. 1927 нең 14 февраленнән – Тәмте, 1931 нең 20 сентябреннән – Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән – Тәмте, 1958 нең 16 июленнән – Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән – Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан районында.

[4] *Кызыл Байрак* – 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантоны Тәмте волостена, 1927 нең 14 февраленнән – Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән – Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән – Тәмте, 1958 нең 16 июленнән – Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән – Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан – Югары Ослан районында.

[5] *Мулланур Вахитов* – 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантонында, 1927 нең 14 февраленнән – Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән – Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән – Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан – Югары Ослан районында.

[6] *Кызыл Юл* – 1926 елда Югары Ложы һәм Кызыл Кадка авылларыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Токмак волостенда. 1930 ның 10 августыннан – Зәй, 1963 нең 1 февраленнән – Чаллы, 1972 нең 1 ноябернннән – Зәй районында.

[7] *Игенче* – 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Минзәлә кантоны Мысы-Чаллы волостена керә. 1930 ның 10 августыннан – Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән – Тукай районында.

[8] *Берек* – 1920 елларда ТАССРның Зөя кантоны составында нигез салына, 1927 нең 14 февраленнән – Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән – Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән – Тәмте, 1958 нең 16 июленнән – Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән – Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан районында.

[9] *Салкын Чишмә* – 1927 елда Олы Батрас авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Зәй волостенда. 1930 ның 10 августыннан – Акташ, 1944 нең 19 февраленнән – Ямаш, 1956 ның 7 декабереннән – Акташ, 1959 ның 26 мартыннан – Зәй, 1963 нең 1 февраленнән – Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән – Зәй районында.

мыш кебек татар авыллары – болар әнә шул киләчәк зур эшнең кечкенә башлангычлары булалар.

Күп басуга күчә башлау, татар авылына яңа культуралар, агрономнар, тракторлар килү, авыл кооперациясендә татарның нык катнашуы – болар һәммәсе татар авыл хуҗалыгында совет вакытында ныгаюны, димәк, мәдәният көчәюне күрсәтәләр. Элекке изелеп яшәү бетеп, татар крәстияненең авылда, волостьта, кантонда, губерна яки җөмһүрияттә, аннан үтеп бөтенсоюз күләмендәге зур совет съездларына активист буларак катнашуы, шөбһәсез, көчле мәдәни гамилләрдер[1]. Моны коры декларация дип уйларга ярамый. Бер ак сакаллы татар картының Мәскәүгә Бөтенрусия советлары съездына барып президиумда утыруы, әллә ничаклы гади татар крәстияннәренең шунда катнашулары – болар иске басылып, тапталып яшәгән татар хезмәт массасының активистлыгын, гайрәтен уятуда бик зур роль уйныйлар, болар мәдәни хәрәкәткә зур булышлык кылалар.

Электән татар эшче катлавы да аерым авыр хәлдә иде. Революция соңында аңа азмы-күпме үзенең квалификациясен күтәрергә, яшь буыннарны фабзауч аркылы хәзерләргә юл ачты. Совет партия эшләренә активист рәвешендә кушылу белән монда сәяси һәм мәдәни аң киңәюгә мәйдан булды. Бу хәлләр татар мәдәни хәрәкәтендә юлбашчы катлауның көнкүрешендә һәм хәзерлек ягында үсәргә ярдәм бирделәр. Хәзерге көндә эшче районнарында кызу мәдәни хәрәкәт гөж килеп кайный. Татар пролетарийлары, бигрәк тә яшьләре бу хәрәкәттә бик нык катнашалар. Монда һәммә нәрсә ана телендә бара.

Әгәр дә татарның интеллигенциясе хәленә килсәк, Октябрь аркасында бигрәк тә җөмһүрият сәбәбеннән монда тирән алмашу булды. Элек татар зыялысы үзенең зур күпчелегендә кем иде? Байның кәефенә карап яшәгән укытучы яки язучы иде. Дәүләт хезмәте белән тәэмин кылынганнар меңгә бер генә иде (аз-маз чиновник, юрист, доктор, берничә инженер).

Бу хәл аларның матди тормышларында тәэминсезлекләренә, җәмәгать хәрәкәтләрендә билгеле бер роль уйный алмауларына сәбәп була иде. Әмма хәзер татарларның барлык зыялы көче рәсми дәүләт механизмы эчендә иң кирәкле һәм тулы хокуклы элемент булып урын алды. Ул кәнсәләрия хезмәтчесеме, комиссармы, командирмы, язучымы, укытучымы, укучымы, партия аппаратында, хуҗалыкта, кооперациядә эшләүчеме, кыскасы,

[1] *Гамилләрдер* – сәбәпләрдер, факторлардыр.

кем генә булса да, ул хәзер үзенең профсоюзы, месткомы канаты астында, рәсми совет аппаратның рәсми декретлары белән тәэминле челтәрендә билгеле шартлар буенча, мәгълүм бурычны үтәп баручы бер куәт. Моның аркасында бездә электән килгән зыялы көчнең хезмәте канун эченә кереп, матди тәэмине рәсмиләште, ныгайды; шуның белән бергә пролетариат революциясе эчендә бу катлау бик зурайды, киңәйде һәм боларга һәртөрле курслар, яңадан хәзерләүләр белән үзләренең квалификацияләрен күтәрүгә киң мөкинлек туды. Болар – гөжләп, кайнап торган мәдәни куәтләргә әйләнделәр. Боларның аяк баскан тупраклары ныгыды.

(Хальбуки, элекке зыялы русның кысуыннан зарланып, елап йөргән бер кызганыч бәндә иде.) Шулай итеп татар мәдәни хәрәкәтендә зур роль уйнаячак бу өченче кыйммәтле катлау – революция соңында үзенең матди ягын ныгытты. Рәсми хокуклы, тәэминле бер көч булып, татар тормышында зур роль уйнарлык хәлгә таба юл алды.

Мәдәни хәрәкәтнең көчәюе яки түбәнәюе мәсьәләсендә болар – үзләренең куәтләрен бик нык сиздерәчәкләр.

Ләкин монда шуны тагын хәтердән чыгармаска кирәк.

Милли мәдәният дигәннән кәләпүш киеп, без өч йөз ел изелгән дип, хәсрәт еры ерлап йөрүне генә алу хата булачак. Шөбһә юк, милли мәдәниятнең төп элментлары эченә башлыча халыкның үз тормышыннан алып, үз теле нигезендә, үз хаҗәтләренә каратып, үзе тарафыннан иҗат кылынган кыйммәтләр керәчәкләр. Ләкин милли мәдәният чиген моның белән кыскарту бик зарарлы идеологизм булыр иде.

Дөньяда һичбер халык башкалар белән алмашудан башка яши алмый. Тик товар алмашу гына түгел, техника, гыйлем, сәнгать, һөнәр, тәҗрибә, гадәт, методлар алышу – мәдәни хәяттә беренче рольне уйнаучылардан була. Трактор хәзер бәйнәлмиләл бер техника җимеше. Ләкин аны татар авылына китереп, җир сөрерлек хәлдә кузгатып, шуның белән эш эшләү – менә бусы инде милли мәдәният хәзинәсенә яңа байлык арттыру була. Татарча гадәтләнү дип алыйк. Русчада навык диләр. Менә бу халыкның тормышында, хуҗалыгында бик зур роль уйный. Асылда бөтен тәрбия нигезе яшь буынга мәгълүм навыкларны үзләштерү максудына корыладыр. Матди тормышта моның зур кыйммәте бар. Татар эшчесенең мәгълүм квалификациясе, татар крәстияненең яңа техника белән хуҗалыкны алып бара белүе,

зыялының мәгълүм бер бабда мәгълүм бер дәрәҗәдә хәзерлекле булуы – болар һәммәсе милли мәдәният хәрәкәтендә кирәкле рольләрне уйныйлар. 25 гыйнвар җыелышында берәү әйтте: трактор, индустрия, паровоз – болар бәйнәлмиләл нәрсәләр, ди. Бу дөрес. Ләкин бөтенләйгә түгел: трактор бәйнәлмиләл берәр коллектив тарафыннан чыгарылганмы, әллә берәр милләттәнме? Ни өчен ул Чувашстанда түгел, америка милләтләрендә башлап ясалган? Чөнки ул милләтнең мәдәниятендә шуңа шартлар, хәзерлекләр булган. Тракторның чыгуына байтак еллар инде. Күп башка милләтләрнең крәстияннәре аны әллә кайчан үзләренең тормышларына керттеләр. Әмма татар крәстияне моны 3 елдан бирле генә ишетә башлады. Әле шуны китерергә, файдасын аңларга, йөртергә яңа өйрәнә. Димәк, техника, гыйлем, сәнгать бәйнәлмиләл хәзинә булса да, болардан файдалана белү – файдаланырга өйрәнә алу – менә бу навык һәм тәҗрибә – милли мәдәниятнең бер тармагы булып саналадыр, халык моны үзе тырышып, үзе теләп өйрәнергә-үзләштерергә тиешле. Менә шул мәгънә белән милләтнең һәртөрле специалистлары – милли мәдәният хәзинәсендә аерым кыйммәтләр булып урын алалар. Боларда мәдәни хәрәкәт гәүдәләнә, болар шуны ташучылар булалар. Менә бу яктан татар милли мәдәнияте, революция вакытында гадәттән тыш күп җимеш алды, татар эшче-крәстияннәре үз эчләреннән бу мәдәни гадәтләрне, мәдәни кыйммәтләрне ташучыларны җитештерде. Җөмһүрият төзү моңа гаҗәп бер тизлек һәм киңлек бирде. Безнең кебек революциягәчә дә татар мәдәни хәрәкәтендә эшләп килгән карт буын бу юлдагы уңышлы тизлекләргә кайбер вакыт хәйран булып гаҗәпсенеп карыйдыр.

Мәсәлән, татардан трес[т] башлыклары, заводларда, фабрикаларда билгеле бүлекләрне алып баручылар, татардан җөмһүрияттә генә түгел, бәлки, Русия үлчәвендә яхшы-яхшы админстратор, яхшы кооператор, тәҗрибәле урыслар яки яһүд белән бер дәрәҗәдә барган банк директоры, хәзерлекле командир, эшлекле комиссар, дөрес юлбашчылык кылучы партком секретаре, ячейка секретаре, акыллы комсомол, яңа заманча тәрбияле укытучы, марксис[т] язучы, материалис[т] тарихчы, пролетариат рухында сугарылган шагыйрь, әдип, яңа студент, революцияче артис[т], масса белән бәйләнешле профсоюз хезмәтчесе – менә болар һәммәсе бит мәдәниятнең җанлы кешеләрдә гәүдәләнгән кисәкләре, элементлары дигән сүз. Татар эчендә бу

гәүдәләнүләр, бу кисәкләр ничаклы күп булса, шулчаклы милли мәдәниятнең нигез шартлары нык утырган булачаклар.

Пролетариат революциясе үзенең зур хәрәкәтләре вакытында бер яктан шулай хезмәт халкы эченнән тартып чыгарып гамәли көрәш аркасында андый көчләрне үстерсә, икенче яктан төзелгән план буенча татардан гыйльми, мәдәни көчләр хәзерләү эше бик нык куелды, Казанның, Мәскәүнең, Ленинградның югары мәктәпләрендә байтак татарлар югары мәктәпләр янында гыйльми хезмәткә калдырылдылар. Болар эчендә татар мәдәни хәрәкәтендә, Татарстанның югары мәктәпләренә татар теле-әдәбиятын кертү эшендә аеруча рольләре булачак. Татар лингвистлары, филологлар үзләренең квалификацияләрен арттыру юлында эшләгән кебек докторлар, инженерлар, педагоглар, педалоглар[1], икътисадчылар, хуҗалыкчылар, агрономнар, техниклар, механиклар, физиклар, математикачылар бар. Бу эш хәзер инде СССР чигеннән үтте. Бу 1927 нче ел эчендә Татарстан җөмһүриятенең өч гыйльми хезмәтчесе заграницага озатачак. Кыскасы, татар мәдәниятенең җанлы нигезләрен, җанлы терәкләрен һәм юлбашчыларын хәзерләү, кадрны күбәйтү, күтәрү мәсьәләсе хәзер элекке кебек бездә кеше юк дип елап, гәзитәдә хәсрәт мәкаләсе язудан үтте. Дәүләтнең рәсми планнары буенча, эшкә гамәлгә кертелде. Әгәр бу планлы эшләребезне хәзерге рәвешендә дәвам иттерә алсак, без тагын өч елдан инде татарда байтак профессорлар күрәчәкбез.

Әгәр статистика теләүчеләр булса, без монда бер дә мәшәкатьсез милли татар мәдәнияте революция аркасында күпме эшләр кылганын мәктәпләр, техникумнар, рабфаклар, югары мәктәпләрдә татарлар, анда татар дәресләре ничек артып үсеп барганын цифрлар аркылы күрсәтә алыр идек. Ләкин болар һәркайчан басылып торганга[2], моны кирәксенмибез.

3

Без югарыда Покровский сүзенчә: тел – милли мәдәниятнең иң баш коралы икәнен күрдек. Революциягә кадәр татар теле һәркайдан куылган, хокуксыз бер нәрсә иде. Пролетариат диктатурасының каты хөкеме белән ул элекке коллыктан азат кылынды гына түгел, рәсми дәүләт теле булып әверелде. Ләкин

---

[1] *Педалогия* – психологиядә һәм педагогикада бала үсешенә биологик, социологик, психологик һәм башка мөнәсәбәтләрне берләштерү максаты куелган юнәлеш.

[2] Бу хакта аеруча тулы мәгълүмат «Биш ел эчендә» дигән зур мәҗмугада бар. Русча, татарча аерым чыкты. Казанда 1925 нче елда басылды. *Авт. иск.*

коры рәсмият аз иде. Аны чыннан да реаль бер көчкә әйләндерү лязим иде. Бу хакта башта күп шөбһә булды. Имансызлар, татар телен гамәлгә кую әнә шул яңлыш язылган вывескалардан үтмәс, диделәр. Бу хактагы беренче декрет (1921 ел, 25 июнь) бик курка-курка гына беренче адымны атлаган иде. Байтаклар һаман да моны кәгазьдә калыр дип уйладылар. «Тат» дигән көлке дә чыгарганнар иде. Ләкин революция үзенең принциплары белән шаярырга теләмәгәнен күрсәтте. 1925 нче елда инде, кичерелгән гадәттән тыш авыр ачлык фаҗигасенә карамастан, җөмһүриятнең биш елы тулганда түбәнге хәлне күрдек:

Татар авылларындагы советларда татар телендә кәнсәләрия эше түбәндәгечә:

| 1925 | 1924 | 1923 | 1922 |
|---|---|---|---|
| 85% | 80% | 50% | 20% |

Волбашкармаларда аппаратның миллиләшүе:

| 1925 | 1924 | 1923 | 1922 |
|---|---|---|---|
| 52% | 51,4% | 40,4% | 30,4% |

Бу татарлашу югары киткән саен кими, җөмһүриятнең үзәк наркоматларында әле хәзер дә канәгатьләнерлек дәрәҗәдә түгел. Ләкин бер нәрсә ачык: алда торган зур киртәләргә, хәзерлексезләргә карамастан, пролетариат революциясе үзенең программасын үткәрүдә туктаусызлык белән бара. Милли мәдәниятнең бер тармагы – админстарцияне миллиләштерү моменты туктаусыз үсә бара.

Без югары бер вакыйга күрдек: 1924 нче ел февраль аенда Мәскәүдә булган татар мәгариф эшчеләренең съездында бер төркем иптәшләр башлангыч татар мәктәпләрендә дәресләрнең ана телендә түгел, бәлки эшче районнарда рус телендә булуы кирәклекне алга сөрделәр. Без бик каты көрәш аркасында ул принципны җимерә алдык. Менә бу вакыйга җөмһүрияттә нык урнашып барган татар телен, һич булмаса читтә урыс теле белән алмаштыру өчен бер тартышып караулары иде – монда урыслашу программасы үзенә бер почмак алмакчы иде, булдыра алмады. Шуннан соң һичкемнең һичкайда татар мәктәбендә уку теленең ана теле булуына каршы сүз әйткәне ишетелмәде. Димәк, революциянең ул принцибы һәркайда хөкем алган иде. Җиңгән иде.

Русиянең бик күп җирләрендә дәүләт хисабына урта татар мәктәпләре яшиләр, боларда барган саен телне дә, дәресләрне дә, укытучыларны да татарлаштыру көчәя бара иде. Соңгы ике

ел эчендә элек тик исемдә генә татарныкы булган берничә техникум, бөтенләй татарлашып беттеләр.

Әле монда зур җитешмәгәнлекләр бар. Әле идеалдан ераграк, ләкин бер нәрсә факт – милли мәдәният революция аркасында урта мәктәпләрне бөтенләй үз элементы белән тутырып бара, көннән-көн үсә, тирәнәядер. Киләчәктә мәсьәлә тагы югарырак куелачак. Моның өчен Татарстан Өлкә комитетының 1926 нчы [ел] 13 декабрь карары аеруча шаһит булып чыкты. Анда башка күп төрле кирәк карарлар эчендә шул сүзләр бар[1]:

4 – профтехника мәктәпләрен, эшче факультетларын, югары тип техникум һәм курсларны тәмам итүчеләрнең укуны бетерүләре рус телен яхшы белүләре белән генә тәмам булмаганын, бәлки, татар телен белү – укуны бетерү өчен куелган төп шартлардан берсе итеп куелырга тиеш иәнен каты рәвештә тормышка үткәрергә. Тиешле булган мәктәпләрнең программаларына төзәтү-үзгәртүләр кертүне Өлкә комитетының агитация-пропаганда бүлеге белән Мәгариф халык комиссариатына тәкъдим итәргә.

Мәгариф халык комиссариаты татар телендә булмаган барлык уку программаларына татар теле кертү өчен кирәкле булган каты чараларны күрергә һәм бер ай вакыт эчендә карарны үтәр өчен күргән чараларын Өлкә комитетына хәбәр итәргә тиеш.

5 – Халык комиссарлары советы һәм Татарстан Үзәк башкарма комитетының фракциясенә татар телен эшкә ашыру чараларын үтәү өчен җирле бюджеттан акча бирүне көчәйтергә һәм шушы ук вакытта татарлардан эшчеләр әзерләү, татарча язу машиналары белән тәэмин итү, татар телен гамәлгә кую курсларының куелышын төзәтү һәм эшләрен яхшырту өчен милли фондтан бирелә торган акчаның арттырылуы турында үзәккә мөрәҗәгать итәргә кушарга...

Безнең күз алдыбызда Казанның ике югары мәктәбендә (ВПИ[2] белән ТКУ[3]) татар теле, татар әдәбияты, татар дәресләре урын алдылар. Бу, әлбәттә, беренче адым. Ләкин инде моннан үтеп – Казанның 125 ел яшәгән карт университетына татар теле керергә хәзерләнеп бара. Якын киләчәктә моны да күрәчәкбез.

Кыскасы, революция шаярырга теләми, үзенең принципларын каты кул белән гамәлгә куюда дәвам кыла. Дөрес, монда зур кимчелекләр, хаталар, кайбер вакыт акыллы баш имансыз Ме-

[1] «Кызыл Татарстан», 1926, 19 декабрь. *Авт. иск.*

[2] ВПИ– Восточно-педагогический институт.

[3] ТКУ– Татарский коммунистический университет.

фистофльләр[1] өчен көләргә материаллар да була торгандыр. Бар да. Ләкин дөньяның нинди зур хәрәкәте – бөтен, камил рәвештә тулы нәтиҗә биргәне бар. Һәркайда яңлышлар, уңышсызлыклар табигый. Безнең өчен бу милли мәдәният төзү хәрәкәтенең революциясе ярдәме аркасында туктаусыз баруы, барган саен зураю, тирәнәюе шулай итеп, моның вакытлы бер бизгәк яки вакытлы бер тактика гына түгел, бәлки, тормыш өчен кирәкле бер нигез итеп алынган булуыдыр.

Җиде еллык бу тәҗрибәдә бу эшкә җитди керешелгәнлек күренде, һәм татар хезмәт массасы үзенең шул тарихи бурычларын аңлап, белеп гамәлгә куйганлыгы ачылды. Русча әйткәндә, татар мәдәнияте бөтен мәгънәсе белән үзенең жизненность һәм жизнеспособностьларын күрсәтте. Вакытлы җил түгел, тормыш нигезеннән туган хәрәкәт.

4

Бу югарыда мәдәниятнең баш коралы – тел икәнен күргән идек. Бичара татар теле үзен саклауда, үзен үстерүдә дә зур мәшәкатьләр, газаплар кичерде. Иске замандагы мирзалар һәм муллалар карашы турында тукталмыйм; миссионерларның бу телгә һәм татар язуына ни дәрәҗәдә ачу белән карап бетерү өчен чаралар эзләгәненә кайта тормыйм. Патшачылык хөкүмәтенең мәшһүр руслаштыру сәясәте аркасында татар теленең нинди кысынкылыкларга төшүен сөйләргә дә керешә алмыйм.

Менә болар һәммәсе татар теленә киртә булдылар. Бердән аның таралуына, икенчедән үзенең үсүенә, эшләнүенә юл куймадылар. Югарыда без Октябрь революциясе соңында татар теленең рәсми хокуклы дәүләт теле булганын күрдек. Гамәлгә керүен дә тикшердек. Әгәр без бу телнең, бу мәдәни коралның үзенең эшләнүенә килсәк, бу бездә тик Насыйри[2] бабайдан гына башлана. Әмма революциядән соң бу эшләнү бик зур адымнар белән алга атлап, татар мәдәниятенең баш коралы камилләнү юлына төште.

---

[1] *Мефистофель* (Mephistopheles, Mephostophilis, Mephistophilus, «яктылыкны яратмаучы, күрәлмаучы» мәгънәсендәге грек сүзе булуы ихтимал, mē – юк, pōs – яктылык һәм phílos – яратучы; башка версияләр буенча, борынгы яһүди чыгышлы – мефиц – җимерүче һәм тофель – ялганчы) – явыз рухларның, шайтаннарның, Иблиснең, сөрелгән фәрештәләрнең берсенең атамасы.

[2] *Насыйри* – Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров (1825–1902), күренекле мәгърифәтче, галим.

Ләкин руслашу моменты монда да үзен күрсәтеп үтте. Әмма аңа каршы татар әдәби активы үзенең дөрес принципларын куеп, татар телен дөрес юлда саклап калды. Бу юлдагы ачык нәзари көрәш шул ук 1924 нче елның Мәскәүдәге татар-башкорт мәгарифчеләр съездына бәйләнадыр. Монда әдәби тел һәм атамалар мәсьәләсе куелган иде. Өч агым көрәште. Берәүләр иске гарәпне саклау юлында булдылар, берәүләр, гарәпне бөтенләй чыгарып бетереп, аның урынына урыс сүзләренә капканы бөтенләй киң ачып куярга тәкъдим кылдылар. Күпчелек боларның берсен дә кабул итмәде, башлап шул съезд киңәшендә, аннан соң 1921 нче елның 16 сентябрьдә Казан киңәшендә тикшерелеп сызылган юл, соңра Гыйльми үзәк тарафыннан (1925 ел, 6 ноябрь) рәсми кулланма тезислар булып чыгарылдылар. Монда татар теленең гарәпләшүме, руслашумы яки татарлашумы кебек агымнардан каюсын тотачагы, ягъни милли мәдәният мәсьәләсендәге принциплардан ниндиен алга куячагы ачык күрелде. Бу кулланма тезисның төп моментлары болар:

1 – Татар әдәби теленең иң төп материалы үзебезнең ана телебездән алынырга тиешле татарча сүзләр була торып, болар урынына башка телдән һич сүз алынмас.

2 – Гарәп сүзләреннән, рус сүзләреннән татар телен тазартырга кирәк.

(Кулланмада күрсәтелгән билгеле шартлар, билгеле чикләр буенча гына бу гарәп, рус сүзләрен кулланырга мөмкин булыр).

3 – Татардан сүз табылмаса, мәдәни милләтләрдә уртак йөргән бәйнәлмиләл сүзләр һәм атамалар безнең матбугатыбызда кулланырлар, ләкин болар татар калыбына, татар теле төзелешенә салынырлар[1].

Күрәсез, татар теле үзенең төзелешендә беренче нигез кылып – үз ана элементларын ала. Икенче нигез бәйнәлмиләл сүзләр (революция, трактор, интернационал, пролетариат, математика һәм башкалар). Менә монда да татар теле үзенең руслашу ягында бармавын, иске гарәпчелек нигезендә калырга да теләмәвен күрсәтте. Менә ничә ел инде шул югарыгы нигезләрдә тел үсеп, эшләнеп, баеп килә. Руслашу тенденциясе бөтенләй җиңелде. Шул татарлашу нигезендә хәзер безнең әлифбаларыбыз, уку китапларыбыз, тел сабаклары, имлялар, сарыф-нәхү – татар грамматикалары, әдәбият кануннары һәм әдәбият тарихлары

[1] Бу хакта Татарстан Мәгариф комиссариаты басып чыгарган «Имля, әлифба, тел, халык әдәбияты турында инструкцияләр мәҗмугасы». *Авт. иск.*

тәмам эшләнеп чыгып юлга салынды. Хәзер инде татар теленең тулы сүзлеге эшләтелмәктәдер.

Хәзер әнә шул нигез буенча атамалар эшләнә, шуның буенча халык өчен гыйльми, сәяси әсәрләр таратыла. Хәзер шул аз вакыт эчендә татар теле бик нык күренер дәрәҗәдә баеды. Татар телендә бу соңгы 3–4 ел эчендә чыккан китаплар, дәреслекләр, гыйльми әсәрләр үзләренең мөндәриҗәләре буенча да, эшләнүләре буенча да элеккеләреннән бик күп алдалар. Хәзер без инде электә исеме дә булмаган сәяси әсәрләр өстенә урта мәктәпләрдә дәреслек булырлык бик күп гыйльми китаплар басып чыгардык. Мәйдандагы биология, физика, кимия, математика, һәндәсә, җәбер, өчпочмаклылар, гигиена, Русия тарихы, революция тарихы, татар әдәбияты тарихы, ботаника, зоология һәм башка күп китапларыбыз да хәзер татар мәдәниятенең бу тармагында да үсү, күтәрелү, тирәнәю барганын күрсәтәләр. Без югарыдагы форма буенча милли мөндәриҗәсе белән пролетариатча булачак дигән идек. Әдәбият, матбугат дөньясында без менә моның ачык мисалын очратабыз. Һәммә китаплар татар өчен, татар телендә, татар аңына каратып басылалар. Ләкин мөндәриҗәләре һәм методлары буенча һәммәсе материализм нигезендә баралар. Һич булмаса, шуңар омтылалар. Әдәби әсәрләрдә, яңа әдәби талантларда бу момент тагын да ачык күренәчәк. Бу соңгы 4–5 ел безгә байтак яңа талантлар бирде. Болар әдәбиятка үз сүзләре, үз мәгънәләре, үз формалары белән килделәр. Милли әдәбиятка байлык арттыралар.

Дөрес, боларда байтак кимчелекләр бар. Боларда акыллы баш Мефистофльләр өчен көләргә урын юк түгел, ләкин төп бер нәрсә факт – татар теле, татар әдәбияты югалуга түгел, руслашуга түгел, үзенең татарлык нигезендә пролетариат рухы белән сугарылган хәлдә үсеп, тирәнәеп, күтәрелеп бара. Моны вакытлы бизгәк дип атарга урын юк, бу тормышның түбәннән килгән тарихи хәрәкәт, монда йотылу галәмәте түгел, адәм саен үсү, көчәю билгесе күренеп бара.

Дөрес, кайбер заманнарда әсәрләрдә, ашыгычлык, игътибарсызлык аркасында төп дөрес нигездән читкә тайпылу, рус сүзләренә кирәксез урын бирү күренергә мөмкин.

Ләкин бу иттифакый[1] моментлар. Әмма хәзер әдәби телнең әдәби әсәрләрнең тенденцияләрен – барышларын караганда, без гарәпчәдән дә, урысчадан да мөмкин кадәрле котылырга

[1] *Иттифакый* – очраклы.

таба юнәлгәнлеген күрәбез. Матур әдәбият бу юлда беренче булып бара. Анда сафлык зурырак, яңа татар сүзләре арта тора. Тарихи-иҗтимагый әсәрләрдә дә шул ук юнәлеш хөкем сөрә. Әгәр моннан 7–8 ел элекке белән хәзергене чагыштырсак, без югаргы фикернең дөрестлеген күрербез (ләкин шуны хәтердән чыгармагыз: әлбәттә, бер кешенең әсәрләрен тикшерү кирәк, юкса язучының башкалыгыннан, урысча яки татарча булуыннан бер үк замандагы әсәрләрдә бер-береннән аерылырга мөмкин. Шелтәгә, рәнҗүгә төшмәс өчен үз китапларымдагы үзем аңламастан килгән үзгәрешләрне алам).

| **Китапның исеме** | **Язылган чыккан елы** | **Бит** | **Татарча, гарәпчә, урысча һәм бәйнәлмиләлчәдән кергән сүзләрнең проценты** | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **Татарча** | **гарәпчә** | **бәйнәлмиләлчә** | **урысча** |
[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (199 ф., 1 тасв., 1007 эш, 28 кәг.). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 265). Текст төп нөсхәдән алынды.

## Прошение ротмистра Стерлитамакского уезда Стерлитамакскому уездному исправнику о проверке и об уведомлении его об Г. Г. Ибрагимове[1]

26 августа 1914 г.

Секретно

№ 6574
26 августа 1914 г[ода]

Из имеющихся во вверенном мне управлении сведений усматривается, что упомянутый в записке моей от 26 августа 1913 года за № 1634 кр[естьянин] дер[евни] Султанмуратовой Уршакминской вол[ости] Галимджан Гирфанович Ибрагимов выбыл из гор[ода] Казани на родину.

Сообщая об изложенном, прошу о проверке означенных сведения и о последующем меня уведомить.

Подп[ись] верно: ротмитср (*подпись неразборчива*)

Стерлитамакскому уездному исправнику

---

[1] Төп нөсхә (кулдан язылган) Башкортстан Республикасы Милли архивында саклана (187 ф., 1 тасв., 504 эш, 41 кәг.). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 265). Текст төп нөсхәдән алынды.

## Сообщение Стерлитамакского уездного исправника Уфимской губернии начальнику Уфимского губернского жандармского управления о прибытии Г. Г. Ибрагимова из Казани к себе на родину[1]

10 сентября 1914 г.

Секретно

10 сентября 1914 г[ода]
№ 666.

Начальнику Уфимского губернского жандармского управления

На Ваше отношение от 26 августа, дело № 6574, сообщаю Вашему Превосходительству, что крестьянин деревни Султанмуратовой Уршакминской волости Галимчан Гирфанович Ибрагимов прибыл из г[орода] Казани на родину, и об учреждении за ним, согласно отношения от 26 августа 1913 г[ода], негласное наблюдение, одновременно с сем поручено приставу 1 стана.

Уездный исправник: (*подпись неразборчива*)

[1] Төп нөсхә (кулдан язылган) Башкортстан Республикасы Милли архивында саклана (187 ф., 1 тасв., 504 эш, 41 кәг.). Стәрлетамак өяз исправнигының рәсми кәгазенә язылган. Адресат штемпленнән күренгәнчә, 1914 елның 15 сентябрендә Уфада кабул ителгән (керү № 7785). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 266). Текст төп нөсхәдән алынды.

## Сообщение начальника Уфимского губернского жандармского управления начальнику Казанского губернского жандармского управления о пребывании Г. Ибрагимова в деревню Султанмуратово[1]

18 сентября 1914 г.

Секретно

18 сентября 1914 г[ода]
№ 7306.
На № 9963.

Галимджан Ибрагимов проживает ныне в деревне Султанмуратово, где за ним наблюдение установлено.

Генерал-майор (*подпись Устинова*)

Начальнику Казанского губернского
жандармского управления

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (199 ф., 1 тасв., 1007 эш, 35 кәг.). Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгының рәсми кәгазенә язылган. Адресат штемпеленнән күренгәнчә, 1914 елның 23 сентябрендә Казанда кабул ителгән (керү № 13746 һәм эш № 43). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 266). Текст төп нөсхәдән алынды.

## Сообщение Стерлитамакского уездного исправника Уфимской губернии начальнику Уфимского жандармского управления о выбытии Г. Ибрагимова из деревни Султанмуратово в город Казань[1]

9 октября 1914 г.

Секретно

Октября 9 дня 1914 г[ода]

Начальнику Уфимского губернского жандармского управления

В дополнение к отношению от 10 сентября сего года и за № 616, сообщаю Вашему Превосходительству, что башкир дер[евни] Султанмуратовой Галимджан Ибрагимов 2 сего октября выбыл на жительство в г[ород] Казань.

За уездного исправника: Угли Магумуридзе

---

[1] Төп нөсхә (кулдан язылган) Башкортстан Республикасы Милли архивында саклана (187 ф., 1 тасв., 504 эш, 44 кәг.). Стәрлетамак өяз исправнигының рәсми кәгазенә язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 266). Текст төп нөсхәдән алынды.

## Сообщение начальника Уфимского губернского жандармского управления начальнику Казанского губернского жандармского управления о выезде Г. Ибрагимова на жительство в город Казань[1]

15 октября 1914 г.

Секретно

15 октября 1914 г[ода]
№ 8067

В дополнение записки моей от 18 сентября сего года за № 7306 сообщаю, что упоминаемый в таковой Галимджан Ибрагимов 2-го сего октября выбыл на жительство в город Казань.

Генерал-майор (*подпись Устинова*)

Начальнику Казанского губернского
жандармского управления

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (199 ф., 1 тасв., 1007 эш, 36 кәг.). Уфа губерна жандарм идарәсе башлыгының рәсми кәгазенә язылган. Адресат штемпеленнән күренгәнчә, 1914 елның 21 октябрьдә Казанда кабул ителгән (керү № 15261 һәм эш № 43). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 267). Текст төп нөсхәдән алынды.

## 1915
## Сообщение Казанского губернского жандармского управления начальнику Уфимского губернского жандармского управления о выезде Г. Г. Ибрагимова из Казани в город Уфу[1]

17 февраля 1915 г.

Совершенно секретно

17 февраля 1915 г[ода]
№ 88.

Во вверенное мне управление поступили непроверенным формальным порядком сведения о том, что известный Вам (записки Ваши от 18 сентября и 15 октября 1914 г., за №№ 7306 и 8067) Галимджан Ибрагимов 10 сего февраля выехал в Уфу для проводов брата на войну.

Сообщая об изложенном на распоряжение, о последующем прошу меня уведомить.

Полковник: (*Подпись неразборчива*)

Начальнику Уфимского губернского жандармского управления

[1] Төп нөсхә Башкортстан Республикасы Милли архивында саклана (187 ф., 1 тасв. 504 эш, 54 кәг.). Казан губерна жандарм идарәсе башлыгының рәсми кәгазенә язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 269). Текст төп нөсхәдән алынды.

## Справка из адресного стола города Уфы[1]

19 февраля 1915 г.

Место жительство

Прежнее с обозначением участка, улицы и № дома или в другом месте – Выбыл с Б[ольшой] Успен[ской] ул[ицы] д[ома] № 50 2 уч[астка] 19 февраля с[его] г[ода] выбыл Стерлитамак.

Время объявления в участке – *19 февраля 1915 г.*

Фамилия – *Ибрагимов*.

Имя – *Галимжан*. Отчество

Звание или сословие и поименование совместно живущих членов семейства – *Журналист, д[еревни] Султанмуратовой Уршакминской вол[ости] Стерлитамакского уезда*.

Лета – *28.*

Какого вероисповедания – *Магометанского*.

## Сообщение Уфимского губернского жандармского управления начальнику Казанского губернского жандармского управления о выезде Г. Ибрагимова из Уфы на родину[2]

26 февраля 1915 г.

Совершенно секретно

№ 1253.

26 февраля 1915.

На № 88.

Имею честь сообщить Вашему Высокоблагородию, что Галимжан Ибрагимов проживал в гор[оде] Уфе до 19 сего февраля, какового числа как видно из справки адресного стола, выбыл из гор[ода] Уфы на родину в Стерлитамакский уезд.

Подлин[но] подписал: генерал-майор Устинов

Верно: ротмистр (*подпись неразборчива*)

Начальнику Казанского губернского
жандармского управления

---

[1] Төп нөсхә Башкорстан Республикасы Милли архивында саклана (187 ф., 1 тасв., 504 эш, 57 кәг.). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 270). Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Шунда ук (187 ф. 1 тасв., 504 эш, 56 кәг.).

## Агентурные сведения начальнику Казанского губернского жандармского управления[1]

26 августа 1915 г.

Совершенно секретно

№ 529.
26 августа 1915 г[ода]
гор[од] Казань.

Партия панисламистов и пантюркистов
Запись № 26
Сведения начальника Казанского губернского жандармского управления
Агентура – «Жителя»

Сведения поступали: 23 августа.

Кто принял сведения от агентуры: подполковник Прогнаевский.

Сущность сведения:

...В других местностях замечается тоже самое за исключением только Уфы, где чувствуется солидарность всех слоев татарского населения. Видимо это обстоятельство и заставило таких людей, как Гаяз Исхаков, Галимджан Ибрагимов обратить внимание на Уфу. Там, по дошедшим сведениям, Исхаков, Ибрагимов, Гумер Терегулов и Сагид Рамеев затевают сорганизовать тайную мусульманскую революционную партию.

Что сделано:

Сообщено начальнику Уфимского губернского жандармского управления сего числа за № 531. Гаяз Исхаков упоминается в записке за № 19; Галимджан Ибрагимов – за № 7; Гумер Терегулов в записке «по разным сведениям» от 21 сентября 1913 года за № 667, препровожденной в район (начальнику Саратовского губернского жандармского управления).

---

[1] Төп нөсхә элекке СССР Октябрь революциясе архивында саклана (ЮИ-ОО ф., 1915 тасв., 74г28аБ эш, 57 (икенче ягы) кәг.). Адресат штемпеленнән күренгәнчә, 1915 елның 1 сентябрендә кабул ителгән (керү № 14547). Текст Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивындагы фотокүчермәдән алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## Уведомление унтера-офицера дополнительного штата Уфимского губернского жандармского управления начальнику сего управления о прибытии Г. Ибрагимова из деревни Султанмуратово в город Уфу. Пункт Стерлитамак[1]

26 декабря 1915 г.

Секретно

26 декабря 1915 г[ода]
№ 78.

Доношу, что состоящий под негласным наблюдением студент Галимджан Ибрагимов в ноябре месяце сего года из родины деревни Султанмуратовой Стерлитамакского уезда выбыл в г[ород] Уфу, где состоит якобы преподавателем в каком-то магометанском училище.

Унтер-офицер: Ермин Каширин

Начальнику сего управления

---

[1] Төп нөсхә (кулдан язылган) Башкортстан Республикасы Милли архивында саклана (187 ф., 1 тасв., 504 эш, 77 кәг.). Уфа губерна жандарм идарәсе өстәмә унтер-офицер штатының рәсми кәгазенә язылган. Адресат штемпеленнән күренгәнчә, 1915 елның 28 декаберендә Уфада кабул ителгән (керү № 10205). Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 271). Текст төп нөсхәдән алынды.

## б)
## Уфада укытучылык эшенә бәйле документ

## 1917
## Уфада мөгаллимәләре өчен ачылган ике айлык җәйге курсны тәмамлау хакында шәһадәтнамә[1]

1917 ел

Уфада 1917 нче ел мөселман «Ханымнар җәмгыяте» мөгаллимәләр өчен ачкан ике айлык җәйге курсларның һәйәте тәгълимиясе тарафыннан бирелгән

Шәһадәтнамә

Самара губернасы Бөгелмә өязе Урсалов[2] волосте Яңа Кәшер[3] авылының Әкрәмә Әбубәкер кызы Даишева курсның 4 нче сыйныфында булып, түбәндәге дәресләргә дәвам итте.

Укыган фәннәр:

1) Татар теле (сарыф, нәхү методикасы, бераз нәзарияте әдәбия)

2) Хисап (кәррә гади әгъшарга гамәл әрбәгасе)

3) Ысулы тәгълим вә тәрбия (дидактика)

4) Табигыять (хикмәте табигыя)

5) Җәгърәфия (гомуми мәгълүмат)

6) Тарих (татар тарихыннан гомуми мәгълүмат)

7) Дин (гомуми мәгълүмат)

8) Гарәпчә –

9) Русча –

Һәйәте тәгълимия әгъзалары: ахунд Җиһанша Абызгилдин[4] (*имза*), Г. Ибраһимов (*имза*), Ф. Сәйфи (*имза*), имза (*танылмый*), имза (*танылмый*), Әхмәт Хәбиб (*имза*).

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (ДВХ-8/501). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Урсалов* – Урсалы, хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Әлмәт районындагы авыл.

[3] *Яңа Кәшер* – хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Әлмәт районындагы авыл.

[4] *Җиһангир Абызгилдин* – Җиһангир Талха улы Абызгилдин (1873–1938), дин һәм җәмәгать эшлеклесе. 1907 елдан «Госмания» мәдрәсәсе мөдире, 1912 елдан Уфа шәһәре ахуны. 4 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтаенда (1914 ел, 15–25 июнь, С.-Петербург) катнаша. 1917 елда Эчке Россия һәм Себер мөселманнары

## в)

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены документлары

### «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[1]

9 март 1917 ел, Уфа

1 – Җәмгыятьне ачу-ачмау мәсьәләсе байтак сүзләргә сәбәп булды. Чөнки килгән партиядән ким иде. Күпчелек хәзер эш вакыты булганын игътибарга алып кворум көтмичә эшләргә булды, килгән кадәр чын кворум дип таныды.

2 – Мәҗлестә әгъза азлык сәбәпле башта митинг көнен билгеләү мәсьәләсе каралды. Митинг якшәмбе көн 12 нче мартка билгеләнде. Моның өчен хәзердән хәзерләү мәсьәләсе Исмәгыйль Субаевка тапшырылды.

3 – Митингның программасы түбәндәгечә билгеләнде:

1) Үзгәрешләр тугрысында кыскача мәгълүмат бирү.

2) Яңа хөкүмәтнең бу көнгә кадәр эшләгән эшләрен санау.

3) Шурамызның эшләгән эшләренә хисап бирү.

4) Яңа җәмгыятьнең Уставы белән таныштыру.

5) Бюроның эш программасын хәбәр итү.

6) Мәүзугъ[2] хакында берничә сүз.

7) Җәмәгать мөәссәсләре[3] хакында мәгълүмат бирү.

8) Җәмгыятькә әгъзалар кабул итү.

---

Диния нәзарәтендә казый урынбасары һәм Уфа губернасыннан Учредительное собраниегә делегатлыкка кандидат итеп сайлана. 1920 елдан Диния нәзарәтендә: Голәмаләр шурасы сәркятибе; имамнар һәм мөәзиннәр белән эшләү программасын төзи; дини әдәбият нәшер итү белән шөгыльләнә. Мәдрәсәләр өчен фәлсәфә, астрономия, гигиена буенча дәреслекләр авторы. Шәхес культы корбаннарының берсе.

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 114, 114 (икенче ягы) кәг.). Беренче мәртәбә «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З. С. Миннуллин; науч. ред.: Р. Р. Фахрутдинов, Р. Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2017.– Т. 1.– С. 21» дигән җыентыкта бастырыла. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Мәүзугъ* – тема, эчтәлек.

[3] *Мөәссәс* – корылган, төзелгән, нигезләнгән.

4 – Устав карала башлады (инде әгъзалар кабул [итү] күбәйтелгән иде). Ул аз-маз тасхих[1] белән кабул ителде вә ахырына берничә маддә арттырылды.

5 – Бюроның гарыз кылдыгы[2] эш програмы җәмгыять әгъзаларына хәбәр ителде. Ул тугрыда моназарә[3] ачмыйча сайлаулар башларга вә яңа әгъзалар кабул итәргә карар бирелде.

6 – Бүген янә 12 әгъза кабул ителде. Болар барысы 27 сум яздырдылар. Шуннан бер сумы алынмаган. Элек язылганнардан Госман Терегулов[4] өч сум, Һидаятулладан 3 сум, Зариф Җиһаншин 10 сум (сигезендә язылган берәүнең бер сумы шуңа кушылды. Барлыгы 44 сум акча янә Гомдә Хәбировка тапшырылды).

7 – Соңра сайлаулар башланып, нәтиҗәдә түбәндәге кешеләр сайланды:

Гомәр Терегулов 44 тавыш белән, Закир әл-Кадыйри[5] – 40, Галимҗан Ибраһимов – 38, Фатыйх Сәйфи – 36, Гомдә Хәбиров – 36, Вагыйз Нәүрузов[6], Сәгыйть Рәмиев – 36, Исмәгыйль Субаев – 34, Һидаятулла Еникеев – 31, Хәбибулла Әхтәмов[7] – 25,

[1] *Тасхих* – төзәтү, дөресләү; редакцияләү.

[2] *Гарыз кылдыгы* – тәкъдим иткән.

[3] *Моназарә* – фикер алышу, бәхәсләшү.

[4] *Госман Терегулов* – Госман Нигъмәтулла улы Терегулов (1894–1976), Башкорт милли азатлык хәрәкәте эшлеклесе, ватандашлар сугышында катнашкан, 1918–1919 елларда Башкорт гаскәрендә поручик, 1919–1920 елларда кызыл Армиядә Башкорт хәрби шурасы әгъзасы. 1918 елның июнь аеннан Тамьян-Катай ирекчеләр отряды башлыгы һәм бер үк вакытта Верхнеурал башкорт көчләре белән идарә итә, 1919 елның гыйнвар азагыннан Башкорт корпусының 6 нчы укчылар полкы командиры, май аеннан – Аерым Башкорт кавалерия дивизиясенең 1 нче кавалерия полкы командиры. Шәхес культы корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[5] *Закир әл-Кадыйри (1877–1955)* – журналист, 1913–1918 елларда Уфада нәшер ителгән «Тормыш» газетасының мөхәррире, 1919 елда чит илгә китә.

[6] *Вагыйз Нәүрузов* – Вәгыйз (Мөхәммәтвагыйз) Нәүрузов (?–?), журналист, патша охранкасы агенты, 1917 елдан соң Колчак армиясе офицеры. Хатыны Фатыймаи-Фәридә Нәүрузова (1889–1914) белән наширлектә һәм мөхәррирлектә 1912 елның 18 февраленнән 1913 елның 31 сентябренә кадәр Томски шәһәрендә татар телендә сәяси, иҗтимагый, икътисади һәм әдәби «Сибирия» газетасы чыгаралар. Бу басма 1913 елда Уфа шәһәренә күчерелеп, «Тормыш» исеме белән 18 октябрьдән 1918 елның 12 апреленә кадәр сәүдәгәр Гыйбадулла Госманов (?–?) наширлегендә һәм Мөхәммәтвагыйз Нәүрузов, Закир Кадыйри (1878–1954), Гыймадетелислам Хәбиров (?–?) мөхәррирлегендә нәшер ителә.

[7] *Хәбибулла Әхтәмов* – Хәбибулла Габделхак улы Әхтәмов (1883–1938), дин эшлеклесе, ахун (1917), 1918 елның ахырына кадәр Уфа губернасы һәм өязе Сынташ авылы мәчетендә, Уфаның 6 нчы җамигъ мәчетендә имам-хатыйп һәм Эчке

Әхмәтсолтан Терегулов[1] – 24, Закир Шакиров[2] – 21, Габдулла Шенаси – 19, Исхак Касмасов – 19, Салих Хәбиров – 18.

Кандидатлар: Сәгыйть Сүнчәләй[3] – 16, Самат Шәрәфетдинов – 14, Һаҗәр Еникеева – 13, Шәйхулла Еникеев – 12, Госман Терегулов – 11, Хәнифә Сәйфуллина – 10.

Тәфтиш[4] комиссиясенә: Гариф Хәмитов – 12, Кәшшафетдин Шәмсетдинов – 8, Закир Субиев –6.

Кандидатлар: Җиһанша Габдүшев – 4, Шаһбазгәрәй Еникеев – 4.

---

Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте әгъзасы. Ачыктан-ачык диннән баш тартуы һәм Диния нәзарәте составыннан чыгуы хакында белдергәч (1927), Уфа педагогия техникумында укытучы булып эшли. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[1] *Әхмәтсолтан Терегулов* – Әхмәтсолтан Гали улы Терегулов (1880–1952), 1915 елда Уфа губернаторы янында аеруча мөһим эшләр буенча чиновник, Уфа шәһәр Думасында гласный, 1918 елда Уфа Вакытлы мөселман шәһәр халык комитеты әгъзасы.

[2] *Закир Шакиров* – Закир Шакир улы Шакиров (1881–1968), педагог, тел галиме, Хезмәт Батыры (1928).

[3] *Сәгыйть Сүнчәләй* – Сәгыйть Сүнчәләй (Сәгыйть Хәмидулла улы Сүнчәләев) (1889–1937), шагыйрь, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[4] *Тәфтиш* – тикшерү, эзләү.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[5]

11 март 1917 ел, Уфа

1—12 нче мартта, якшәмбе көн, Новый клуб залында гомуми мөселманнар митингы ясалырга карар кылынды. Митинг вакыты сәгать 2 дә билгеләнде.

2—11 мартта мөселман солдатларының митингысында нотык сөйләргә Галиәсгар әфәнде Гафури[6] җибәрелде һәм Закир әфәнде Шакиров та үтенелде.

3 – Солдатларга митинг ясау эшләрен (вакытын, урынын) белер өчен, тиешле кешеләре белән күрешеп аңлашырга Әхмәтсолтан Терегуловтан үтенелде.

4 – Тәрҗемә һәм язу-тәхәррир өчен биш кешедән гыйбарәт бер комиссия сайларга булынды.

5 – Тәхәррир комиссиясенә[7]: Сәгыйть Рәмиев, Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи, Самад Шәрәфетдинов, Сәгыйть Сүнчәләйләр сайланды.

6 – Төрле урында лекция укыр өчен Закир әфәнде, Вагыйз, Гомәр Терегулов, Галиәсгар әфәнде, Хәбибулла Әхтәмовлар билгеләнде.

7 – Шәкертләр арасыннан лекция һәм тәхрир комиссиясенә берәр вәкил чакырылырга бирелде.

8 – Комиссиянең малия ягын тәэмин итәр өчен: Әхмәтсолтан, Фәтхулла Баһаветдин, Нургали Алмаев, Гариф Хәмидов, Салих Хәбиров, Кәшфулла Шәмсетдинов, Исхак Касмасов, Мәкарим Әүлияровлардан иганә җыярга дип үтенелде. Шулар өстенә: Исмәгыйль Субаев, Гыйсмәтулла Маҗар Әгерҗиләр арттырылды.

9 – Канцелярия өчен кирәкле нәрсәләрне алырга Гомдә һәм Фатыйх Сәйфигә тапшырырга.

---

[5] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 112 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[6] *Галиәсгар әфәнде Гафури* – Галиәсгар Могыйн улы Гафуров-Чыгътай (1867–1942), язучы, журналист.

[7] *Тәхрир комиссиясенә* – рәсми язып бару (беркетмә) комиссиясенә.

## «Русия мөселманнары арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» төзелү хакында[1]

12 март 1917 ел, Уфа

Хөррият игълан кылынгач Уфаның зыялы мөселманнары тарафыннан төзелгән Бюро[2] хәзер «Русия мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» исемле бер оешмага әверелде. 6 нчы марттан бирле үзенә әгъзалар кабул итә. Әгъзалык акчасы бер сум. Әгъзалары көн саен бик күпләп арталар. Хәзер инде Уставы ясалып, 9 нчы март җыенында тәсдыйк ителде. Шул көнге җыенда Комитетка идарә вә тәфтиш комиссиясенә сайлаулар булып, яшерен тавыш белән түбәндәге кешеләр үттеләр: идарә әгъзалыгына: Гомәр Терегулов, Закир әл-Кадыйри, Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи, Гомдә Хәбиров, Вагыйз Нәүрузов, Сәгыйть Рәмиев, Исмәгыйль Субаев, Һидаятулла Еникеев, Хәбибулла Әхтәмов, Әхмәтсолтан Терегулов, Закир Шакиров, Габдулла Шенаси, Исхак Касмасов, Салих Хәбиров; аларга кандидатлыкка: Сәгыйть Сүнчәләй, Самат Шәрәфетдинов, Һаҗәр ханым Еникеева, Шәйхулла Кинзикеев, Госман Терегулов, Хәнифә туташ Сәйфуллина; тәфтиш комиссиясенә: Гариф Хәмитов, Кәшфулла Шәмсетдинов, Закир Субиев; аларга кандидатлар: Җиһанша Габдүшев, Шаһбазгәрәй Еникеевләр сайланды...

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[3]

17 март 1917 ел, Уфа

...Бу мәҗлестә иштиракь иттеләр[4]: Вагыйз Нәүрузов, Фатыйх Сәйфи, Гомдә Хәбиров, Галимҗан Ибраһимов, Закир Шакиров, Салих Хәбиров, Исхак Касмасов, Гомәр Терегулов.

---

[1] «Тормыш» газетасының 1917 елгы 12 нче март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Бюро* – «Русия Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты» башта шулай атала һәм ул 1917 елның 5 нче мартында оештырыла.

[3] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 107 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[4] *Иштиракь иттеләр* – катнаштылар.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[1]

20 март 1917 ел, Уфа

1 – Авылдан килгән Галимҗан әфәнде Ибраһимовның гарызы белән халыкны хәзерге хәл белән таныштыру өчен бүгеннән башлап кичекмичә таныштыручылар йибәрергә карар бирелде.

2 – Өязләргә хәзердән чыгып китәр өчен Галиәсгар әфәнде Гафуров белән Мөбарәкшаһ хәзрәт Хәнәфидән үтенелде. Алар кабул ителде.

Вагыйз Нәүрузов имзасы, (танылмый), Гомдә Хәбиров имзасы, Фатыйх Сәйфи имзасы, Закир әл-Кадыйри имзасы, Галимҗан Ибраһимов имзасы.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[2]

21 март 1917 ел, Уфа

1 – Галимҗан әфәнде лекторларга биреләчәк вәкаләтнамә рәвешен гарыз кылды. Кабул ителде.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 106 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 106 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[1]

22 март 1917 ел, Уфа

1 – Комитетка махсус орган чыгару мәсьәләсе.

Башта органның сметасын караучы комиссия исеменнән Галимҗан әфәнде доклад ясады. Сары кәгазьгә басканда киләчәк 9 айга газетаның барлык чыгуы 19216 сум фараз кылына. Комиссия газетаның 4 аен гына комитетка күтәртеп, калганын ачык калдырырга гарыз кылды. Ул вакыт 8832 сум комитет өстенә төшә. Аның үз килерен чыгарганда 3832 сум чыгым комитет өстендә кала.

Бик озак вә кызу мөзакәрәләр[2] соңында комитет үзеннән мөстәкыйль газета чыгармый дигән карарга килде. Иҗаби[3] 5, сәлби[4] 9 тавыш. Берсе тавыш бирми.

2 – Гомуми җыен мәсьәләсе иртәгә калды.

3 – Әхмәтсолтан әфәнде Терегулов үзенең башка җәмәгать мөәссәсләрендә эше гаять күп булып мәҗлесләрне даими зиярәт итә алмаганлыгын вә эш белән яхшы танышып барырга мөмкинлек таба алмаганлыгын күрсәтеп, рәис могавинлыгыннан[5] истигъфадә[6] итә вә шуны кабул итүне сорый. Истигъфадәсе кабул ителде.

Рәис: Гомәр Терегулов, Фатыйх Сәйфи.

Әхмәтсолтан Терегулов имзасы.

Исмәгыйль Субаев имзасы.

(Танылмый)

Галимҗан Ибраһимов имзасы. Хәбибулла Әхтәмов имзасы.

*Абруй Сәйфи*[7] *имзасы.* Гомдә Хәбиров имзасы.

Салих Хәбиров имзасы. Закир Шакиров имзасы.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 105 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Мөзакәрә* – фикер алышу.

[3] *Иҗаби* – уңай.

[4] *Сәлби* – кире.

[5] *Могавин* – урынбасар.

[6] *Истигъфа* – хезмәттән азат ителү.

[7] *Абруй Сәйфи* – Абруй Сәлах кызы Сәйфи (1890–1960), журналист, педагог, җәмәгать эшлеклесе, тәрҗемәче.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[1]

23 март 1917 ел, Уфа

Мәҗлестә хазир булдылар[2]: рәис Гомәр Терегулов, секретарьлар Фатыйх Сәйфи, Гомдә Хәбиров, әгъзалар хаҗи Гыйсмәтулла Әгерҗи, Нәҗип Хәкимов, Галимҗан Ибраһимов, Салих Хәбиров, Закир Шакиров, Закир әл-Кадыйри, Абруй Сәйфи, Вагыйз Нәүрузов.

Түбәндәге мәсьәләләр каралды:

1 – Нәшер ителгән әсәрләрне тарату ысулы. Гомәр әфәнде нәшер ителгән нәрсәләрне Земствога сатып бирергә, берегеп эшләү мөссәсләрен буш бирергә. «Тормыш»[3] адресы белән таратырга, шөгъбәләремезгә[4] буш йибәрергә гарыз кылды (каралып торганда Әхмәтсолтан әфәнде Терегулов, Һидаять Еникеев әфәнде килделәр).

а) Нәшер ителгән китапларга Земстводанмы, башка мөәссәсләрдәнме барыбер, кайсы вилаятьтә килере барыбер.

б) Чит вилаятьләрдә хәзерге хәл мөнәсәбәтилә туган мөәссәсләрнең һәркайсына берничәшәр данә китап буш бирелә.

т) Уфа вилаятендәге мөәссәсләрнең барысына да күпләп буш бирелер.

х) Комитет почта белән берәмләп китап йибәрми.

д) Сибириянең бөтен мәхәлләләренең адресын Мәхкәмәи шәргыядән алып, барысына да басылган рисаләләр йибәрелер.

р) Һәр мөәссәскә күпмешәр китап йибәрү мәсьәләсе адреслар билгеләнгәннән соң һәр мөәссәснең үзенә карап билгеләнер.

с) Китаплар комитетның үзенә төшкән хакына сатыла.

2 – Моннан соң идарә җыеннары атнага өч мәртәбә була.

Мәҗлес көндез сәгать 5 тә башлана. Көннәре җәмегъ, якшәмбе, чәршәмбе көннәргә билгеләнде. Билгеле көннәр булдыгыннан идарә әгъзаларына чакыру йибәрелми.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 104, 104 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Хазир булдылар* – катнаштылар.

[3] *«Тормыш»* – кара: Вагыйз Нәүрузов.

[4] *Шөгъбәләремезгә* – бүлекләребезгә.

3 – Һидаять әфәнде Еникеев рәис могавинлыгына сайлана.

4 – Гомуми җыен ясау мәсьәләсе. Гомуми җыен ясарга карар бирелде. Көне 30 нчы мартка, пәнҗешәмбе көн кич сәгать 7 гә билгеләнде (Хәбибулла Әхтәмов килде).

5 – Малия[1] комиссиясеннән бер үтенеч: малия комиссиясе моннан соң да комитетның малиясе яхшырту юлында ныклап иҗтиһад[2] итүләре үтенелде.

6 – Салихҗан хәзрәт доклады

Аңлы имам вә ахундларны Уфага алдырып шулар аркылы авылларны хәзерге хәл белән таныштыру мәсьәләсе әсасан[3] кабул ителде.

Чакырылачак муллаларның вилаять съездына да катнашулары да матлуб[4] булдыгыннан аларга 10 нчы апрельгә чакырылырга булды. Юхса тәфсилле доклад ясау Салихҗан хәзрәткә тапшырылды.

7 – Петроградка барачак вәкил Гомәр әфәндегә 500 сум билгеләнде.

8 – Акчаны кая кую мәсьәләсе. Бу мәсьәлә комитетны рәсмиләштерү мәсьәләсенә гаид[5] булганга, бу хакта сөйләшү-аңлашу Һидаятулла әфәнде Еникеевкә тапшырылды.

9 – Язучыга ярдәм итүче яки йомышка йөрү өчен малай алу мәсьәләсе.

Йомышка йөрү өчен бер малай алырга карар бирелде. Алу Хәбибулла әфәнде Әхтәмовка тапшырылды. Язучыга ярдәм кирәк вакытта ярдәмче бирү секретариат карамагына калдырылды.

10 – Вагыйз әфәнде солдатларга лекция укыганнан хәбәр бирде. Аңа ярдәмгә тагын бер лектор билгеләнде Хәбибулла Әхтәмов.

11 – Ахырында Исмәгыйль Госмановның телеграмы. Аны Минзәлә өязенә лектор итеп йибәрергә карар бирелде. Ярты ай өчен хәзер 15 көнгә 150 сум йибәрелә. Калганы хакында хат белән мөзакәрә кылыначак.

Бер дә кичекмичә өяз комитетыннан удостоверения алып калулар урынына чыгарга кушып телеграм бирелде. Акча йибә-

---

[1] *Малия* – акча эшләре.

[2] *Иҗтиһад* – тырышу.

[3] *Әсасан* – нигездә.

[4] *Матлуб* – соралган.

[5] *Гаид* – бәйләнешле.

релгәнлеге хакында аерым телеграм белән хәбәр итәргә карар кылынды.

12 – Баембитов[1] телеграмы. Гыйлемдар Баембитовны әсасан чакырырга күпчелек белән карар бирелде. Иртәгәдән чакырып телеграм бирергә булды. Рәис Гомәр әфәнде: «Мин тиз көннән Мәскәүгә барачакмын. Шул сәбәпле мин чакыруны, үзем барып аның хакында аңлашканга кадәр, кичектереп торуны гарыз кылам»,– ди. Шул сүзенә бинаән[2] ул хәзердән чакырырга каршы тавыш бирә һәм шуны протоколга кертүне гарыз кыла.

13 – Имам Гыйзетдин Исәнбирдин гаризасы. Аны лектор итеп чыгарырга карар бирелде. Аның белән сөйләшеп тәгълимат бирү[3] мосахәбәләр[4] Гомдә Хәбировка тапшырылды.

[1] *Баембитов* – Гыйлемдар Солтан улы Баембитов (1886–1933), журналист, сул эсер. Башкорт Мөселман Комиссариатында комиссар. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[2] *Бинаән* – нигезләп, таянып

[3] *Тәгълимат бирү* – өйрәтү.

[4] *Мосахәбәләр* – утырышулар.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[1]

24 март 1917 ел, Уфа

1 – Гыйзетдин әфәнде Исәнбирдингә комитет бер вакытта йөз илле сум бирергә карар бирде.

Фатыйх Сәйфи имзасы.

2 – Архангельский сәүдәгәрләреннән Мирхәйдәр Баһаветдиновка Уфа комитеты белән әтрафлы рәвештә танышыр өчен Вагыйз әфәнде Нәүрузовка тапшырылды.

Фатыйх Сәйфи имзасы, Вагыйз Нәүрузов имзасы, Закир Шакиров имзасы, Галимҗан Ибраһимов имзасы, Һидаятулла Еникеев имзасы, Әкрам Мөхетдинов имзасы.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[2]

2 апрель 1917 ел, Уфа

Идарә җыены. Мәҗлескә рәис могавины[3] Һидаятулла Еникеев, секретарьлар Гомдә Хәбиров, Фатыйх Сәйфи, әгъзалар: Закир Шакиров, Вагыйз Нәүрузов, Закир әл-Кадыйри, Сабирҗан Шәмгулов, Галимҗан Ибраһимовлар килде.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 103 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 101 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[3] *Рәис могавины* – рәис урынбасары.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[1]

2 апрель 1917 ел, Уфа

2 апрельдә фәүкылгадә[2] гомуми комитет әгъзаларының җыелышы протоколы.

Рәислеккә Галимҗан әфәнде Ибраһимов сайланды. Секретарь Хәбибулла әфәнде Әхтәмов.

Мәсьәлә съездга вәкилләр сайлау тугрында иде. Сайлау яшерен ысул белән булды. Җәмәгать тарафыннан ошбу кешеләр кандидатурасы куелды: Һидаятулла Еникеев, Ибраһимов, Кадыйри, Әхтәмов, Зыяэддин хәзрәт әл-Кәмали[3], Нәүрузов, Мөстакыймов, Әхмәтханов, Сабир хәзрәт, Сәргаскәр Бухармитов, Дәүләтшаһ Гобәйдуллин, Нәҗип Хәкимов, Сабирҗан Шәмгулов, Шаһәхмәтов, Һаҗәр ханым, Фатыйма Алкина, Зөһрә Әхтәмова, Фатыйх Сәйфи, Гыйлемдар Баембитов.

Болар эченнән: Фатыйх Сәйфи, Һаҗәр ханым, Нәҗип Хәкимов үзләренең кандидатураларын куймауны үтенделәр. Баембитов та үз кандидатурасын алды. Бирелгән записькаларны санау өчен җыелышның үзе тарафыннан унике кешедән гыйбарәт комиссия сайланды.

Комиссия нәтиҗәнең ошбу рәвештә булуын игълан итте:

Кандидатлар: Алган тавышлары:

1) Галимҗан Ибраһимов 216
2) Зыяэддин хәзрәт әл-Кәмали 189
3) Дауд Мөстәкыймов 162
5) Вагыйз Нәүрузов 165
6) Хәбибулла Әхтәмов 119
7) Галләм Мостафин 77
8) Сабир хәзрәт 84
9) Закир әл-Кадыйри 76

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 126, 126 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Фәүкылгадә* – гадәттән тыш.

[3] *Зыяэддин хәзрәт әл-Кәмали* – Пәрвәзетдин Камалетдин улы Зыятдинов (1873–1942), педагог, дин белгече, җәмәгать эшлеклесе. 1906 елда Уфада «Мәдрәсәи Галия»не нигезли һәм 1919 елга кадәр аның мөдәррисе була. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

10) Фатыйма Алкина 55

11) Шәрифҗан Әхмәтханов 60

12) Һидаятулла Еникеев 62

13) Сабирҗан Шәмгулов 68

Мәҗлеснең карары буенча күп тавыш алган кешеләр вәкил булып сайланачак булганга алты кеше Мәскәүдә булачак Гомумроссия мөселманнары съезды гражданлык комитеты тарафыннан вәкил булып тасдыйк ителделәр[1].

Тәнбия[2]: Сабир хәзрәт урынына яңлыш әүвәл уларак Галләм Мостафин язылган. Дөресте Сабир хәзрәт күп тавыш алганлыктан, әүвәл язылырга тиеш.

Мәҗлеснең рәисе: Галимҗан Ибраһимов.

Секретаре: Хәбибулла Әхтәмов.

---

[1] *Тасдыйк ителделәр* – расландылар.

[2] *Тәнбия* – кисәтү (искәрмә).

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[1]

3 апрель 1917 ел, Уфа

1917 нче елның апрель 3 ндә гражданлык тарату комитетының гомуми җыелышы булды. Рәис: Вагыйз Нәүрузов, сәркятип: Галимҗан Ибраһимов.

Куелган мәсьәләләр:

1) Айлык хисап, 2) малия хисабы, 3) Бәләбәйдән кайткан вәкил Вагыйзь әфәнде доклады, 4) Кәшфулла Шәмсетдинов доклады.

Карарлар:

1) Булачак вилаять җыелышына кибетләреннән илле вәкил чакырылырга тиеш.

2) Комитетның гомуми җыелышы унбиш көндә бер мәртәбә булыр.

Галимҗан.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[2]

5 апрель 1917 ел, Уфа

Мәҗлестә Һидаятулла Еникеев, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Шенаси, Гомдә Хәбиров, Хәбибулла Әхтәмов, Закир Шакиров, Вагыйз Нәүрузов, Салих Хәбиров, Фатыйх Сәйфиләр бар иде. Агрызский да килде. Нәҗип Хәкимов, Әхмәтсолтан Терегулов.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 127 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 100 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[1]

7 апрель 1917 ел, Уфа

Җыен мәдрәсә «Госмания»дә[2] булды. Мәҗлес ачылганда әгъзалардан Сабирҗан Шәмгулов, Габдулла Шенаси, Салих Хәбиров, Закир әл-Кадыйри, Хәбибулла Әхтәмов, рәис Һидаятулла Еникеев, Секретарь Гомдә Хәбиров хазир иделәр.

...х) Гомуми мөселман съездының Мәскәүдә булачагы хакында Гомәр Терегуловтан һәм мәркәз бюродан телеграмнар килгән. Алар тыңланды (Фатыйх Сәйфи вә Галимҗан Ибраһимов та килделәр).

...3 – Авылларда йирле оешмалар төзеп, халык гел шул оешмалар аркылы гына эшләсен...

а) Йир мәсьәләсен хәл кылу Учредительный собраниегә калдырыла.

б) Әгәр йир хакында низаг чыкса, һичбер кеше башбаштаклык кылмаска, бәлки йирле оешмаларда гына хәл кылырга тиешле.

Бу мәсьәләнең соңгы шәккы[3] тавышка куелганчы Фатыйх Сәйфи вә Галимҗан Ибраһимов чыгып киттеләр.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 98, 98 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Мәдрәсәи «Госмания»* – дин эшлеклесе, имам, ахун Хәйрулла Госманов (1848–1907) тарафыннан Уфада 1887 елда нигезләнеп, XX йөз башларында әйдәп баручы мәдрәсәләрнең берсе. 1905 елгы буржуаз инкыйлабтан соң анда укыту методлары яңартыла, берникадәр дөньяви фәннәр укытыла башлый. 1918 елда татар милли гимназиясе итеп үзгәртелә. Хәзерге вакытта Тукай урамындагы 39 санлы йорт, анда 14 санлы гомуми урта белем бирү мәктәбе урнашкан.

[3] *Шәккы* – аерым.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[1]

9 апрель 1917 ел, Уфа

Мәҗлестә рәис могавины Һидаятулла Еникеев, секретарьлар Гомдә Хәбиров, Фатыйх Сәйфи, әгъзалардан Салих Хәбиров, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Шенаси, Хәбибулла Әхтәмов, Закир Шакиров хазир иде.

...

Рәис: *Һидаятулла Еникеев имзасы.*

Галимҗан Ибраһимов имзасы, Фатыйх Сәйфи имзасы... Закир Шакиров имзасы.

Секретарь: *Гомдә Хәбиров имзасы.*

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[2]

13 апрель 1917 ел, Уфа

Мәҗлестә рәис Гомәр Терегулов, әгъзалардан Сабир хәзрәт, Вагыйз Нәүрузов, Галимҗан Ибраһимов, Фәтхулла Баһаветдин, секретарьлардан Гомдә һәм Фатыйх Сәйфи хазир иделәр.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 97, 97 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 96 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[1]

19 апрель 1917 ел, Уфа

Мәҗлестә Гомәр, Һидаят, Сабирҗан хәзрәт, Хәбибулла, Вагыйз, Гомдә, Нәҗип әфәнделәр, Сабир хәзрәт хазир иделәр. Закир Шакиров килде.

...

Закир әл-Кадыйри, Гомәр Галәви әфәнделәр килде. Фатыйх Сәйфи килде. Галимҗан Ибраһимов килде...

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[2]

20 апрель 1917 ел, Уфа

20 нче апрель җыены. Төрле мәсьәләләр куелган гомуми мәҗлес.

Мәҗлестә катнаштылар: Галимҗан Ибраһимов, Закир әл-Кадыйри, Зыяэддин әл-Кәмали, Хәбибулла Әхтәмов, Гыйсмәтулла хаҗи, Вагыйз Нәүрузов, Нәҗип Хәкимов, Әхмәтсолтан Терегулов, Фәтхулла Баһаветдинов, Мәкарим Әүлияров, Гыйндулла Ишмаев, Алмаев, Фатыйх Сәйфи.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[3]

22 апрель 1917 ел, Уфа

Комитет җыенына рәис Һидаятулла Еникеев, секретарьлар Гомдә Хәбиров, Фатыйх Сәйфи, әгъзалар Сабирҗан Шәмгулов, Закир Шакиров, Галимҗан Ибраһимов, Фәтхулла Баһаветдинов, Гомәр Галәви, Хәбибулла Әхтәмов, Сабир хәзрәт, Әхмәтсолтан Терегулов, Нәҗип Хәкимовлар хазир булды.

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 95 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Шунда ук (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 94 (икенче ягы) кәг.).

[3] Шунда ук (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 94 кәг.).

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[1]

19 май 1917 ел, Уфа

Мәҗлескә килүчеләрдән Сабир Хәсәни, Галимҗан Ибраһимов, Абруй Сәйфи, Мәгъдән Кәримов, Самат Шәрәфетдинов, Фатыйх Сәйфи, Мәкарим Әүлияров, Гыйндулла Ишмаев, Габдулла Шенаси.

Комитетның рәисе булмаганга вакытлы рәвештә Сабирҗан Хәсәни билгеләнде.

*Фатыйх Сәйфи имзасы... Галимҗан Ибраһимов имзасы, Абруй Сәйфи имзасы, Мәкарим Әүлияров имзасы, Гыйндулла Ишмаев имзасы, Самат Шәрәфетдинов имзасы.*

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[2]

24 май 1917 ел, Уфа

Исмәгыйль әфәнде Җәгъфәровка 25 нче майдан беренче июньгә кадәр авылга кайтып килергә мөсагадә[3] бирелде.

Фатыйх Сәйфи имзасы, Әхмәтсолтан Терегулов имзасы, Абруй Сәйфи имзасы, Самат Шәрәфетдинов имзасы, Галимҗан Ибраһимов имзасы.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 89 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 88 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[3] *Мөсагадә* – мөмкинлек.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[1]

26 май 1917 ел, Уфа

Комитетның алдагы көннәрендә җитди эшләр булса да комитет әгъзаларының күбесе бүген Уфада булмаганга, эш тәртибенчә барсын өчен эш комитетына читтән тавышка хуҗа булырлык хак белән чын кешеләрне чакырырга булды. Бу чакырылган кешеләрне алдагы гомуми җыенда тәсдыйк кылдырырга. Эшләшү өчен муафыйк табылган кешеләр: Галләм Мостафин, Шәрифҗан Әхмәтҗанов, Нургали Агаев, Шәриф Сүнчәләй, Мәкарим Әүлияров, Галәэтдин Ходаяров[2], Нурлыгаян Гали, Уразаев, Җиһангир хәзрәт Абызгилдин, Зыя хәзрәт, Галимҗан Нигъмәтуллин, Хаҗи Вәлиев, Кәшшафетдин хәлфә, Бәхтизин, Сөләйман Асанович, Дауд Мөстәкыймов, Җиһанша...... 3 эшләрлек, Габделкави Сәйфуллин, Нурмөхәммәт Бикмөхәммәтов... Бухармитов, Уталиев, Галиәсгар Гафуров, Кудашев, Сәлимҗан Урманов, Госман әфәнде Терегулов.

Шәһәр идарәсенә сайлау эше якшәмбе көндәге мәҗлескә калдырылды.

Комитет идарә әгъзалары әгәр дә комитет дәвам итүдән тукталса яисә читкә ял итәргә китсә, бу хакта комитетка, идарә әгъзасынамы калдырырга тиеш. Бәйрәм мәсьәләсен карау киләчәктәге комитет идарә мәҗлесенә калдырды.

Рәис өчен: *Әхмәтсолтан Терегулов имзасы. Фатыйх Сәйфи имзасы, Хәбибулла Әхтәмов имзасы, Галимҗан Ибраһимов имзасы, Гыйндулла Ишмаев имзасы.*

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 88 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Галәэтдин Ходаяров* – Галәэтдин Гайнетдин улы Ходаяров (1891–1966), журналист, партия-совет эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[1]

28 май 1917 ел, Уфа

Һидаятулла Еникеевтән авыру сәбәпле комитет мәҗлесенә йөри алмавы хакында игъламнамә күренде (вакыты күрсәтелмәгән).

2 июньдә җомга көн сәгать 3 тә Новый клуб залында комитетның гомуми җыены ясалырга карар бирелде.

Гомуми җыенга сайлауның техник ягын хәзерләр өчен Әхмәтсолтан Терегулов, Госман Терегулов, Сөләйман Асанович, Фатыйх Сәйфиләр билгеләнде.

28 нче майдан башлап берничә көнгә Сөләйман әфәнде Асановичтан үтенелде. Лотфән[2] кабул итте.

Вакытлы уларак көненә дүрт сәгать эшләү шарты белән секретарь урынында 5 сум билгеләнде.

Әхмәтсолтан Терегулов имзасы, Фатыйх Сәйфи имзасы, Галимҗан Ибраһимов имзасы, Хәбибулла Әхтәмов имзасы, Гыйндулла Ишмаев имзасы, Кәшшафетдин Шәмсетдинов имзасы.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 87 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Лотфән* – рәхим итеп.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыелышы беркетмәсе[1]

2 июнь 1917 ел, Уфа

Галимҗан Ибраһимов рәис, Әхмәтсолтан Терегулов могавин рәис, Хәбибулла әфәнде секретарь итеп сайландылар.

1) Бер айлык эшләнгән эшләр хакында Фатыйх Сәйфи кыскача хисап бирде.

Җәмгыятьтә нәшрият эшенең артта булуына сәбәп итеп комитетның үзенә махсус матбагасы булмавын күрсәттеләр.

Сөальләр: Карибов: Авыл халкының лекторларга ихтыяҗы зур булдыгыны бәян кылып, ирләр вә ханымнардан берничә кешеләр чыгарырга тиеш диде.

Нурулла Ханов: Талчук шикелле демократияләрдән дә кеше кертергә тиеш ди.

Сонра комитетка түбәндәге кешеләр кооптировать итәргә карар бирелде: Имаметдин Бәхтизин, Галләм Мостафин, Нургали Алмаев, Шәриф Сүнчәләй, Госман Терегулов, Мәкәрим Әүлияров, Хаҗимөхәммәт Уразаев, Җиһангир Абызгилдин, Зыяэддин әл-Кәмали, Хаҗиәхмәт хәзрәт Вәлиев, Галимҗан Нигъмәтуллин, Кәшфулла Шәмсетдинов, Сөләйман Асанович, Гыймадетдин Шаһәхмәтов, Җиһанша Биктаһиров, Нурмөхәммәт Бикмөхәммәтов, Әкълимә Таһирова, Галиәсгар Гафуров, Зөләйха Урманова, Шәрифҗан Әхмәтханов, Гатаулла Гомәров, Мәгъдән Мәһдиев, Зәфи Фирузов, Баһаветдин Нуриманов[2], Җомадил Вәлиев, Низаметдин Баһаветдинов, Нуретдин Галиев, Нурулла Салиховлар.

Залдагылардан берсе: «Безнең гаскәриләрне хакрак игътибарга алыңыз!» – ди.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 124 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Баһаветдин Нуриманов* – Баһаветдин Җәлалетдин улы Нуриманов (1893–1918), инкыйлап хәрәкәте эшлеклесе. 1917 елдан РСДРАП(б) әгъзасы. Уфа эшче һәм солдатлар советы депутаты, РСДРАП(б) Уфа губерна комитеты Татар-башкорт бюросы рәисе. 1918 елның февраленнән Оренбург мөселман хәрби-революцион комитеты әгъзасы. Март аеннан Оренбург губерна мөселман комиссариаты рәисе, июль аеннан Орскида Кызыл армиядә сәяси хезмәткәр. Август (сентябрь) аенда аклар тарафыннан кулга алына һәм атып үтерелә.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[1]

4 июнь 1917 ел, Уфа

...2) Галимҗан әфәнде Ибраһимов илә Фатыйх әфәнде Сәйфи җәнапләренең истифга таләп кылып биргән гаризалары каралып, протоколга кертергә карар бирелде.

...3) Гомәр әфәнде Терегулов илә Галимҗан Ибраһимов вилаять игенчеләр (крәстияннәр) съездына вәкил уларак тәгъйинләнделәр.

Идарә серетарьлык кылучы: (*Хәбибулла Әхтәмов имзасы*).

Җыелыш рәисе: (*Габдулла Шенаси имзасы*).

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[2]

6 июнь 1917 ел, Уфа

Комитет әгъзаларының гомуми җыены.

Мәсьәлә: Гомәр Терегуловның Мәскәү җыелышы хакында доклады. Докладтан соң бераз сөальләр булды.

Гомуми мәҗлеснең рәисе: Галимҗан Ибраһимов.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[3]

18 июнь 1917 ел, Уфа

1917, 18 июнь. Якшәмбе.

Хазир булган әгъзалар: Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи, Сөләйман Асанович, Абруй, Җомадил Вәлиев, Моратгалим.

Президиум әгъзаларыннан законный состав җыелмаганга, һичбер эш эшләргә мөмкин булмады.

*Моратгалим Мөхәммәтов имзасы*.

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 86, 86 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Шунда ук (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 122 (икенче ягы) кәг.).

[3] Шунда ук (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 83 (икенче ягы) кәг.).

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[1]

21 июнь 1917 ел, Уфа

Мәҗлестә хазир булган әгъзалар: Гомәр Терегулов, Галимҗан Ибраһимов, Нурмөхәммәт Бикмөхәммәтов Нурулла Халиков, Җомадил Вәлиев, Хаҗиәхмәт Яфаев, Госман Терегулов, Гомдә Хәбиров, Моратгалим Мөхәммәтов, Галимҗан Нигъмәтуллин, Һидаятулла Еникеев, Гыйндулла Ишмаев, Җиһанша Биктаһиров, Кәшфулла Шәмсетдинов, Низаметдин Баһаветдинов, Галиәсгар Гафуров, Галәэтдин Ходаяров.

...

Рәис: *Гомәр Терегулов имзасы.*

Һидаятулла Еникеев имзасы, Галиәсгар Гафуров имзасы, Җомадил Вәлиев имзасы, Нурулла Габделхаликов имзасы, Гомдә Хәбиролв имзасы, Сөләйман Асанович имзасы.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 82, 82 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[1]

23 июнь 1917 ел, Уфа

Хәбибулла әфәнде Әхтәмов гражданский комитетның җыенын ачып, рәис сайларга гарыз кыла.

Галимҗан Ибраһимов рәис, Хәбибулла Әхтәмов секретарь [итеп] сайлана.

1) Социалистический партияләр илә таныштыру, 2) шәһәр Думасында гласный булачак кешеләрнең кандидатурасын күрсәтү.

Элек сүз алып Гомәр әфәнде Терегулов без аерым платформа төзи торырга тиеш түгел, бәлки социалистический партияләр белән барырлык (трудовиклардан да уң булмаган партияләр белән барырлык) кешеләр булса йитә.

Моратгалим Мөхәммәтов: Платформа мәсьәләсен мөзакәрә кылып[2] торсак, бүген кандидатура куеп өлгерә алмамыз. Шуңар күрә кандидатура хакында гына сөйлик.

Фатыйх Сәйфи: Бу җыелышта без бүгенгә кадәр сукырча баруны аңламаенча йөредек, ләкин бондан соңра күзләремезне ачып аңлап барырга тиеш. Бонда әйтәләр, трудовиклардан да уң булмаган партия кешеләре белән барырлык кешеләр йитә диләр. Бонда күрсәтеләчәк спискадан иң мәгълүм бер эшкә вәгъдә бирсеннәр. Аннан сайлармыз.

Гыйлемдар Баембитов: Бу көнгәчә аш-чәй мәҗлесләренә йөреп һәрбер эшемез янә кичектерә итеп килгән муллалар, байлар юк. Болар кая? Һич шөбһәсез йортлы, йирле кешеләр үзләренә башка берләшеп киңәшеп яталар булырга кирәк. Без монда, алар анда җыелышымыздан күренә. Безнең алдымызда бер көрәш тора. Киләчәктә шәһәр Думасы бер аерым мәмләкәт шикелле булып бетүдә, шәһәр эшен идарә мөстәкыйль автономия хәрәкәт итә тора. Шундай киң хокуклы шәһәр Думасына сайланган кешеләрнең мәсләге, сәяси йөзе ачык мәгълүм булган кешеләр генә сайланырга тиеш. Бәгъзылар әйтәләр: мөселманнар аз булачак. Безнең ихтыяҗымыз үтәлер микән диеп. Ләкин мин әйтәм: Дума демократлардан гыйбарәт булса, һич шөбһәсез, үтәләчәк.

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 119, 119 (икенче ягы), 120 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Мозакәрә кылып* – фикер алышып.

Мин күптән социалист-революционер һәм шундай сул партия кешеләрен сайларга тәкъдим кылам.

Гомәр әфәнде: Монда мәсьәләне икенче төрле куясыз. Сез бит үткән җыелышта карар биргән идеңез мөселманнар аерым хәрәкәт итәргә дип. Мин шуңа карап сөйлим. Без әйтмимез: бөтен мөселманнарның интересларын сөйләмәсәк тә мәгълүм. Монда әгәр бер партиядән генә кандидатура куелса, уңгайсыз булыр. Мәсәлән, социалист-революционерлар партиясеннән булган кешеләрнең кандидатураларын гына куйсак. Социалист-демократ партиясеннән булган кешеләр отказаться итәргә тиеш. Без мөселманнар аерыла башласак көчемез кими. Мин шуңар күрә әйтәм: трудовиклардан да уң булмаган кешеләрне сайларга ярый диеп.

Мансур: Бик куркам, аерылышырмыз да көч кимер диеп. Көч булмаса тиешле кешеләремезне кертә алмамыз. Рус кадетлары сайланырга тырышып йөриләр, китаплар тараталар.

Фатыйх Сәйфи: Гомуми мөселман съездында эшләнмәгән эшләрне социалист-революционерлар эшләде диеп социалист-революционерларны мактый, Гомәргә бәйләнеп китә.

Галиәсгар Гафуров: Бу җыелышка килгән кешеләрнең бары да мөселманнар. Нинди генә партиядән булса да мөселманнарның хосусый файдалары булдыгыннан иң элек үзара берләшергә тиешмез. Шулай да мөселманнар уң булыр диеп уйлый алмыймыз.

Батыршин: Бонда җыелган кешеләр бары да социалист диеп беләм. Озак тартышып тормыйк, максудка кайтыйк.

Низаметдин Баһаветдинов: Хосусый милекләр хакында бераз сөйләп, иттифакка чакыра.

Кәшшафетдин Шәмсетдинов: Вәгътәсыйму җәмил Аллаһ җәмилан, ягъни мөселманнар берләшеп аларның җебенә тотынырга, ди.

Хәбибулла Әхтәмов: Гомуми мөселманнар съездында кабул ителгән трудовиклардан да уң булмаган партияләр белән блок ясарга карар бирелгәнлектә вә ул карар безнең өчен шул карар мөкатдәс[1] саналырга тиешлеген дә сөйләп, мәсьәләне кыска тотарга, кандидатуралар күрсәтергә кайтырга өнди.

Гомәр әфәнде Галәви: Ислам мондый соңгы елда аерылышып аз зарар күрмә диләр. Хәзердә аерылачак булсак, ифрат зур яңа зарарлар күрәчәкмез. Әфәнделәр, аерылышмыйк, берләшеп яхшы эшләрлек кешеләр сайлыйк.

---

[1] *Мөкатдәс* – изге.

Гомәр әфәнде Терегулов: Платформа мәсьәләсе ифрат зур, хәтта Гомумроссия мөселманнарының съезды да платформа ясый алмады. Без монда бер акыллы халык җыелып ясый алачак түгелмез. Юк-бар мәсьәлә белән вакыт әрәм итәргә ярамый, максудка кайтыйк та, шәһәр Думасына гласный булып сайланачак кешеләр хакында фикер алышыйк та, кандидатуралар күрсәтик.

Нурулла Халиков: Безнең күп кирәкмәс табылган партия булса – социал-демократик партиясе.

Фатыйх Сәйфи: Гаяз Исхаковның съездан соң социалист-революционер партия кушылганын сөйләп, «Социалист-революционерлар партиясеннән булган кешеләрне сайларга тиеш» ди.

Карарлар:

1) Платформа билгеләмәскә, бәлки Гомәр әфәнденең элекке гомуми җыелышта карар күрсәткән тәкъдиме (заявлениесе) буенча үткән карар буенча хәрәкәт итәргә күп тавыш белән үтте (шул арада председатель отказать иткән сәбәпле бераз тавыш чыгып ала). Тавышка кандидатуралары куелып үткән кешеләр: Гомәр әфәнде Терегулов, Һидаятулла Еникеев, Шәрифҗан Әхмәтханов, Хәбибулла Әхтәмов (Галимҗан Ибраһимов кандидатурасын ала), Имаметдин Бәхтизин, Җомадил Вәлиев, Моратгалим Мөхәммәтов, Хаҗиәхмәт Яфаев, Низаметдин Баһаветдинов, Кәшфулла Шәмсетдинов, Галләм Мостафин, Минсорур Зарипова, Абруй ханым Сәйфи (Сабирҗан Басимов кадет диеп күпчелек кертми калды), Дауд Мөстәкыймов (Мәкарим Уляров төшерелде), Исмәгыйль Субаев, Зыяэддин әл-Кәмали, Җиһанша Биктаһиров (Әхмәтсолтан төшеп калды) (Мөхтәрәм Еникеев калды), Гомдә Хәбиров, Закир, Сәет Мөсләхов, Гыйлемдар Баембитов, Харис Исхаков (Миңлевәли Улимаев төшерелде), Госман Мөхәммәт угылы Терегулов (Сәмигулла Батырбаев төшерелде), Закир Шакиров.

Бу кандидатуралары күрсәтелмеш кешеләрнең спискасын төзеп Управага кертергә (Фатыйх Сәйфи кандидатурасын алды).

3) Гласный булып сайланган кешеләр социалистический партияләр белән барырга вәгъдә бирдекләреннән социалист-демократ вә социалист-революционерлар белән барырга тиешләр. Әгәр дә мәзкүр[1] партияләрнең программаларына хилафгам мөселманнар зарарына хәрәкәт иткән гласныйларны чыгарырга хакымыз булыр.

Мәҗлестә секретарьлык итүче: Хәбибулла Әхтәмов.

Мәҗлес рәисе: Галимҗан Ибраһимов.

[1] *Мәзкүр* – күрсәтелгән.

## «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены беркетмәсе[1]

27 июнь 1917 ел, Уфа

Мәҗлестә хазир булган әгъзалар: Гомәр Терегулов, Галимҗан Ибраһимов, Моратгалим Мөхәммәтов, Хаҗиәхмәт Яфаев, Мәкарим Әүлияров, Низаметдин Баһаветдинов, Нурулла Халиков, Кәшфулла Шәмсетдинов, Гыйндулла Ишмаев, Җиһанша Бикташиров, Имаметдин Бәхтизин, Галимҗан Нигъмәтуллин, Самат Шәрәфетдинов, Гомдә Хәбиров, Мәгъдән Мәһдиев, Хаҗиәхмәт Вәлиев, Җомадил Вәлиев, Габдулла Кәримов, Дауд Мөстәкыймов, Фатыйх Сәйфи, Абруй Сәйфи, Әкълимә Таһирова, Гомәр Галәви, Нурмөхәммәт Бикмөхәммәтов.

Рәис: *Гомәр Терегулов имзасы.*

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 81 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## г)
## Учредительный собраниегә сайлау документлары

## 1917
## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

21 сентябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 1

21 нче сентябрь 1917 нче ел.

Уфа вилаять Милли шурасының сул канат әгъзалары, Уфа мөселман гаскәри шурасы, Уфа вилаять авыл халкы шурасының мөселман әгъзалары һәм татар социалист-революционер оешмасы тарафыннан төзелгән «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясенең җыелышы.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Сүнчәләй[2], Гомәр Әлмөхәммәтов[3], Галимҗан Әминов[4] һәм Муса Йосыпов[5].

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Беренче мәртәбә «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2017.– Т. 1.– С. 376–377» дигән җыентыкта бастырыла. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Шәриф Сүнчәләй* – Шәриф Хәмидулла улы Сүнчәләй (1885–1959), педагог, журналист, җәмәгать эшлеклесе.

[3] *Галимҗан Әминов (?–?)* – сәяси эшлекле, Уфада мөселамн солдатлары оешмасы бюросын төзүчеләрнең берсе. Башкорт Мөселман Комиссариатында хәрби бүлек әгъзасы.

[4] *Гомәр Әлмөхәммәтов* – Гомәр Әлмөхәммәтов (1895–1939), җәмәгать эшлеклесе, журналист.

[5] *Муса Йосыпов* – Муса Рахман улы Йосыпов (1896–1937), партия һәм дәүләт эшлеклесе, журналист, Казанда Татар педагогия институты директоры (1933–1935 еллар) һәм Татар дәүләт академия театры (1935–1937 еллар) директоры, Уфада татар телендә нәшер ителгән «Башкортстан» (хәзерге «Кызыл таң») газетасының баш мөхәррире (1922–1929 еллар) булып эшләгән. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

Мәҗлес көндез сәгать 1 дә ачылып, түбәндәге карарларга килende:

1 – Комиссиягә рәис һәм сәркятип сайлау мәсьәләсе каралып, рәислеккә Галимҗан Әминев, сәркятиплеккә һәм рәис могавины итеп Гомәр Әлмөхәммәтов сайланды.

2 – Авыл халкы шурасыннан йибәрелгән Муса Йосыпов белән татар с[оциалист] р[еволюционер]лар комитетыннан йибәрелгән Галимҗан Әминов комиссия әгъзалыгына тәсдыйк ителәләр.

3 – Бәләбәй өяз вә Милли шурасы җыелышыннан кайткан Галимҗан Әминов доклад укый. Бәләбәй Милли шурасының Башкару комитеты, Бәләбәй авыл халкы шурасының Башкару комитеты Бәләбәй өязеннән күрсәтелгән вәкилгә беренче урын бирелүдән катгый рәвештә сорыйлар һәм соң чиктә һич беренче, икенче урында булса да ярый, шуннан түбән урынга разый түгелләр, ди һәм шулар ук с[оциалист] р[еволюционер] Гомәр Еникеевнең кандидатурасын куярга сорыйлар, ди.

Мәсьәлә мөзакәрә ителгәннән соң:

1 – Әсасан Гомәр Еникеевне спискәгә керттерергә карар бирелде.

2 – Аны 2 нче урынга кертергә дә каршы киленмәде.

4 – Спискәне түбәндәге рәвешчә төзәргә карар бирелде:

1 – Галимҗан Ибраһимов.

2 – Гомәр Еникеев.

3 – Шәриф Сүнчәләй.

4 – Әхмәдетдин Мөхәммәтдинев.

5 – Мөхетдин Әхмәрев.

6 – Шәехгаттар Солтанов.

7 – Ильяс Алкин[1].

8 – Һади Сәгъди.

9 – Фатыйх Сәйфи.

10 – Шәфыйк Салихҗанов.

11 – Миңлебай Кудашев.

12 – Зәки Вәлиди.

13 – Габделхәй Дәүкәев.

14 – Фуад Туктаров.

---

[1] *Ильяс Алкин* – Ильяс Сәетгәрәй улы Алкин (1895–1937), хәрби-сәяси эшлекле, географ, Бөтенрусия мөселман «Хәрби шура»сы рәисе, 1922–1937 елларда Мәскәүдә Төрки халыклар коммунистик университеты укытучысы, доценты, профессоры. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

5 – Комиссиянең кулында шул югарыда кандидатуралары күрсәтелгән кешеләрдән бәгъзыларының кулларыннан разыйлык кәгазе булмау сәбәпле телеграммалар белән разыйлык кәгазе алырга Шәриф Сүнчәләйгә тапшырырга.

6 – «Авыл халкы спискәсе»нә плакат төзергә карар бирелеп, Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Әлмөхәммәтов һәм Галимҗан Әминовларга шуны төзү эшен тапшырырга.

7 – Башкортлар белән блок мәсьәләсен хәзергә ачык калдырырга.

8 – Комиссиянең киләчәк җыелышын 23 нче сентябрьдә көндез сәгать 1 дә ясарга.

Рәис: (*Галимҗан Әминов имзасы*).

Әгъзалар: (*Муса Йосыпов имзасы*)..., (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: Гомәр Әлмөхәммәтов.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

23 сентябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 2

23 нче сентябрь 1917 нче ел.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Сүнчәләй, Гомәр Әлмөхәммәтов, Галимҗан Әминов һәм Муса Йосыпов.

Мәҗлес көндез сәгать 2 дә ачылып, түбәндәге карарлар бирелде:

1 – Шәриф Сүнчәләй Шәехгаттар Солтановка, Фуад Туктаровка, Әхмәдетдин Мөхәммәтдиневкә, Һади Сәгъдигә, Гомәр Еникеевкә һәм Миңлебай Кудашевларга телеграмнар биреп алардан разыйлыкларын сораганлыгы хакында доклад ясап, Шәриф Сүнчәләйнең эшләгән эшләре комиссия тарафыннан тәсдыйк ителә.

2 – Галимҗан Әминев спискәне ни рәвештә бирергә тиеш икәнлеге хакында комиссиядән белешкәнлеге һәм комиссиядән Вакытлы хөкүмәт тарафыннан төзелгән «Положение о выборах в Учредит[ельное] собрание» дигән брошюрканы алганлыгы, шул брошюркадан аңлашылмаган нәрсә булса, комиссиядән сорарга тиеш була икәнлеге хакында доклад ясый. Спискәгә кул куючылар өчен булган листны нинди рәвештә төзергә кирәк икәнлеген һәм брошюркадагы аңлашылмаган нәрсәләрне комиссиядән белешергә Әминевкә тапшырырга.

3 – «Авыл халкы спискәсе» өчен плакат ясау комиссиясе тарафыннан төзелгән ляихә[2] каралып, бераз төзәтелгәннән соң, шул плакатны бөтенләй эшләп бетерүне шул ук комиссиягә тапшырырга. Комиссия мәзкүр ляихәне төзеп бетергәннән соң комиссиянең җыелыш карамагына тапшырыр.

4 – «Авыл халкы спискәсе» хакында кызыл комачтан плакат ясап, Уфадан Эстәрлетамак ягына һәм Бирский ягына чыга тор-

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Ляихә* – проект.

ган Идел күперләренә аркылы асып куярга, шул плакатлар өчен кызыл комач табу хәзерлеген бүгеннән үк күрә башларга.

5 – Комиссиянең алдагы җыелышын 24 нче сентябрьдә кичке сәгать 5 тә ясарга.

Рәис: (*Галимҗан Әминев имзасы*).

Әгъзалар: (*Муса Йосыпов имзасы*)..., (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: Гомәр Әлмөхәммәтов.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

24 сентябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 3

24 нче сентябрь 1917 нче ел.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Әминев, Гомәр Әлмөхәммәтов, Шәриф Сүнчәләй һәм Муса Йосыпов.

Мәҗлес көндез сәгать 5 тә ачылып, түбәндәге карарлар бирелде:

1 – Галимҗан Әминев үзенә тапшырылган эшләр хакында доклад ясый.

2 – «Авыл халкы спискәсе»н төзеп, астына тарафдарларыннан кул куйдыра башларга.

Рәис: (*Галимҗан Әминев имзасы*).

Әгъзалар:... (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: Гомәр Әлмөхәммәтов.

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

29 сентябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 4

9 нчы сентябрь 1917 нче ел.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Әминев, Гомәр Әлмөхәммәтов, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Сүнчәләй һәм Муса Йосыпов.

Мәҗлес көндез сәгать 12 дә ачылып, түбәндәге карарлар бирелде:

1 – Ильяс Алкиннан: «Нинди спискә һәм кайсы урынга куясыз?» – дип телеграм килү сәбәпле, шуңа җавап Ильяс Алкинга түбәндәге телеграм бирелде: «Дүрт оешма тарафыннан чыгарылган мөселман с[оциалист] р[еволюционер]лар спискәсе, урын дүртенче. Әгәр дә Казаннан үтәчәк булсаңыз, урынны үзебезнең кешебезгә калдырырсыз. Аннан үтә алмасаңыз Уфадан үткәрербез. Атаңыз, исем вә фамилияңез белән подписыңызны удостоверять иттереп телеграм биреңез».

Рәис: (*Галимҗан Әминев имзасы*).

Әгъзалар:... (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: Гомәр Әлмөхәммәтов.

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

30 сентябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 5

30 нчы сентябрь 1917 нче ел.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Әминев, Гомәр Әлмөхәммәтов, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Сүнчәләй һәм Муса Йосыпов.

Мәҗлес көндез сәгать 3 тә ачылып, түбәндәге карарлар бирелде:

1 – «Башкортлар спискәсе» белән блок ясау мәсьәләсе каралып, «Авыл халкы спискәсе» белән «Башкорт спискәсе»н берләштерү (технический блок) әсасан кабул ителде.

2 – Ильяс Алкиннан: «Нинди урынга, кемнәр спискәсенә?» – дип телеграм килү сәбәпле, Алкинга түбәндәге рәвештә телеграм бирергә карар бирелде: «Дүрт мөселман оешмасы тарафыннан чыгарылган С[оциалист] Р[еволюционер]лар спискәсе, урын дүртенче, әгәр дә Казаннан үтсәңез, бездәге урынны үзебезнең кешегә калдырырсыз, аннан үтмәсәңез, моннан үткәрербез, исем, атаңыз һәм фамилияңез белән подписыңызны удостоверять иттереп телеграм биреңез».

Рәис: (*Галимҗан Әминев имзасы*).

Әгъзалар:... (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: Гомәр Әлмөхәммәтов.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

2 октябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 6

2 нче октябрь 1917 нче ел.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Әминев, Гомәр Әлмөхәммәтов, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Сүнчәләй һәм Муса Йосыпов.

Мәҗлес көндез сәгать 2 дә ачылып, түбәндәге карарлар бирелде:

1 – Ибнеямин Әхтәмовның[2] «Тормыш» газетасында басылган Гомәр Еникеев хакындагы мәкаләсе мөнәсәбәте белән мөзакәрә булганнан соң, Гомәр Еникеевнең «Авыл халкы спискәсе»ндә калу мөселман халкын зур шөбһәгә төшереп спискәнең абруен югалту ихтималы зур булганга күрә, Гомәр Еникеевне «Авыл халкы спискәсе»ннән чыгарырга вә шул мөнәсәбәт белән Бәләбәй Милли шурасы белән ныклап сөйләшеп аңлашыр өчен бер вәкил йибәрергә карар бирелеп, Галимҗан Әминевне йибәрергә.

2 – Самара Милли шурасының гомуми җыелышына киткән Мөхетдин Әхмәревкә: «Әгәр дә Ильяс Алкин беренче урынга куелса, срочно телеграм бир!» – дип телеграм сугарга.

Рәис: (*Галимҗан Әминев имзасы*).

Әгъзалар:... (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: Гомәр Әлмөхәммәтов.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Ибнеямин Әхтәмов* – Ибнеямин Әбусогуд улы Әхтәмов (1877–1941), хокук белгече, милли сәясәт эшлеклесе.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

7 октябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 7

7 нче октябрь 1917 нче ел.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Әминев, Гомәр Әлмөхәмматов, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Сүнчәләй һәм Муса Йосыпов.

Мәҗлес көндез сәгать 1 дә ачылып, түбәндәге карарлар бирелә:

1 – Спискәдән Гомәр Еникеевне чыгару хакында Бәләбәй Милли шурасы белән аңлашып кайтыр өчен Бәләбәйгә вәкил булып барып кайткан Галимҗан Әминев түбәндәге мәүзугъда доклад укый:

«Авылда Гомәр Еникеев: «Мине халык куйган, халык үзе алсын»,– дип кандидатурасын алырга разый булмыйча торды, соңыннан Гомәр Еникеевне спискәдән чыгару тугрысында чыгарган карардан игътибар иткәч, үз кандидатурасын алырга Г. Еникеев разый булды. Шулвакыт Миңлебай Кудашев: «Г. Еникеев спискәдән чыгарылса, мин дә үземнең кандидатурамны алам»,– дип заявление кертте. Бәләбәй Милли шурасының буңа карашы бу рәвешчә: спискәдән Бәләбәй өязе куйган кешеләр чыксалар да, Бәләбәй Милли шурасы үз юлы белән барачак һәм «Авыл халкы спискәсе»н яклаячак, һәрхәлдә, Казан платформасы ягын яклаячак түгел. Бу хакта Бәләбәй Милли шурасының әгъзалары, шул җөмләдән Гомәр Еникеев белән Миңлебай Кудашев, берәм, берәм чыгып үз фикерләрен сөйләделәр. Шуңа бинаән, Бәләбәй Милли шурасы безнең белән булачак дип ышанам».

Әминевнең доклады тыңланганнан соң комиссия сәгать кичке 9 да җыелырга карар биреп тарала.

Рәис: (*Галимҗан Әминев имзасы*).

Әгъзалар:... (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: Гомәр Әлмөхәмматов.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

7 октябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 8

7 нче октябрь 1917 нче ел.

Мәҗлес сәгать кичке 9 да ачылып, түбәндәге карарлар бирелә:

1 – Гомәр Еникеевнең комиссия исеменә: «Уңайсызлыклар чыгудан саклану өчен, «Авыл халкы спискәсе»ннән кандидатурамны алам»,– дип биргән заявлениесе каралып, аның спискәдән чыгуын кабул итәргә.

2 – Спискәдән кандидатурасын алган Гомәр Еникеевнең урынына Бәләбәйдән радъездыннан күрсәтелгән кешеләрдән берәүне спискәгә кертергә тиешле табылганлыктан, кемне вә нинди урынга кую мәсьәләсе мөзакәрә ителә һәм Гыйззәтулла Ильясовны куярга карар бирелә вә аны нинди урынга кую мәсьәләсе мөзакәрәгә куелып, 2 нче урынга Шәриф Сүнчәләйне, 3 нче урынга Гыйззәтулла Ильясовны куярга кабул ителә. Комиссиянең рәисе Галимҗан Әминев мәсьәләнең бу рәвешчә хәл кылынуы тугрысында битараф кала.

Рәис: (*Галимҗан Әминев имзасы*).

Әгъзалар:... (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: (*Гомәр Әлмөхәммәтов имзасы*).

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

8 октябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 9

8 нче октябрь 1917 нче ел.

Башкорт федералистлары спискәсе комиссиясенең әгъзалары белән катнаш мәҗлес.

Мәҗлес кичке сәгать 9 да ачыла.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Әлмөхәммәтов, Шәриф Сүнчәләй һәм Муса Йосыпов, башкорт вәкилләреннән – Сәлах Атнагулов[2] һәм Фәтхулла Әхмәдуллин.

1 – Ике спискәне бергә кушу мәсьәләсе мөзакәрә ителеп, әсасан икесен берләштерү кабул ителә.

2 – Блок ясаганда ни рәвештә ясарга вә кайсы урынга кемне кую мәсьәләсе озак мөзакәрә ителгәннән соң, башкорт вәкилләренең таләпләре кабул ителерлек булмаганлыктан, мәсьәлә бу мәҗлестә хәл кылынмый, һәр як үзләре мөзакәрә кылганнан соң 9 нчы октябрьдә көндез сәгать 3 тән икенче мәҗлес ясарга карар бирелә.

Рәис өчен:

Әгъзалар: (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: (*Гомәр Әлмөхәммәтов имзасы*).

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Сәлах Атнагулов* – Сәлах (Сәлахетдин) Садри улы Атнагулов (1893–1937), сәяси эшлекле, публицист, язучы. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

9 октябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 10

9 нчы октябрь 1917 нче ел.

Башкорт федералистлары белән катнаш мәҗлес.

Көндез сәгать 3.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Әлмөхәммәтов, Шәриф Сүнчәләй һәм Муса Йосыпов.

1 – «Башкортлар спискәсе» белән «Авыл халкы спискәсе»н берләштерү мәсьәләсе яңадан мөзакәрә ителеп, башкортларның шартлары кабул ителмәслек булу сәбәпле, берләштермичә, «Авыл халкы спискәсе»н аерым чыгарырга карар бирелә.

Рәис өчен:

Әгъзалар:... (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: (*Гомәр Әлмөхәммәтов имзасы*).

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

9 октябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 11

9 нчы октябрь 1917 нче ел.
6 да.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Сүнчәләй, Гомәр Әлмөхәммәтов һәм Муса Йосыпов.

1 – Спискәгә Миңлебай Кудашевны кую мәсьәләсе мөзакәрәгә куелып, Бәләбәйгә барган вәкилнең әйтүе буенча, Миңлебай Кудашев: «Гомәр Еникеевнең кандидатурасы спискәдән алынгач (Гомәр Еникеев кандидатурасын үзе ала), мин дә «Авыл халкы спискәсе»ндә кала алмыйм, кандидатурамны алам»,– дигән икән, шул сәбәпле Кудашевның кандидатурасын спискәдән алырга карар бирелә.

2 – Спискәне окончательный формада түбәндәге рәвешчә төзергә булды:

1 – Галимҗан Ибраһимов.
2 – Шәриф Сүнчәләй.
3 – Гыйззәтулла Ильясов.
4 – Әхмәдетдин Мөхәмәтдинев.
5 – Мөхетдин Әхмәрев.
6 – Шәехгаттар Солтанов.
7 – Һади Сәгъди.
8 – Шәфыйк Салихҗанов.
9 – Хәйрелвәри Гыйсмәтуллин.

Әүвәлдә күрсәтелгән кешеләрдән:

Гомәр Еникеев үзе заявление биреп кандидатурасын ала. Ильяс Алкиннан разыйлык телеграмы килмичә кала. Фатыйх Сәйфи кандидатурасын алуы хакында заявление бирә. Миңлебай Кудашев заявление биреп кандидатурасын ала. Зәки Вәлиди «Башкортлар спискәсе»нә куелу сәбәпле, кала. Габделхәй

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

Дәүкәев заявление биреп кандидатурасын ала. Фуад Туктаровтан разыйлык телеграмы килеп йитми.

Югарыда күрсәтелгән сәбәпләргә бинаән, бу кешеләр спискәдән чыгарылалар.

Рәис өчен:

Әгъзалар:... (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: (*Гомәр Әлмөхәммәтов имзасы*).

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

19 октябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 12

19 нчы октябрь 1917 нче ел.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Әлмөхәммәтов, Шәриф Сүнчәләй һәм Галимҗан Әминев.

1 – Спискәләргә бирелгән тавышларын кешеләрдән кайсы спискәләр белән берләштерү мәсьәләсе мөзакәрәгә куелып, күп мөзакәрәләрдән соң, 9 нчы номерлы (рус социалист революционерлар) спискәсе һәм 10 нчы номерлы (большевиклар) спискәсе белән берләштерергә карар бирелә.

2 – Бирский шәһәрендә 1 нче сентябрьдә булган Милли шураның 3 нче гомуми җыелышында Милли шураның гомуми җыелышын ташлап чыккан сул канат әгъзаларның: «Әгәр дә Милли шура тарафыннан чыгарылган спискә файдасына Милли шура хәзинәсеннән акча тотылачак булса, сул канат әгъзалар тарафыннан чыгарылган спискә файдасына да Милли шура хәзинәсеннән акча тотылыр» дигән карарына бинаән, Милли шураның сул канат әгъзаларының санына мөтәнасыйп[2] рәвештә тиешле булачак акчаны Милли шурадан таләп итәргә карар бирелә.

Рәис өчен: (*Галимҗан Әминев имзасы*).

Әгъзалар:... (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: (*Гомәр Әлмөхәмматов имзасы*).

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Мөтәнасыйп* – тигез, туры килгән.

## Г. Ибраһимовның Эчке Русия вә Сибирия мөселманнарының беренче Милләт Мәҗлесендә әгъза булып катнашуы хакында[1]

1917 ел

| ...Гадәд | Исем, фамилияләре | Вилаяте |
|---|---|---|
| 2. | Галимҗан Ибраһимов | Уфа |

[1] Беренче мәртәбә «Мохтарият» журналының 1917 елгы 4 нче санында (б. 14–15) бастырыла. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2017.– Т. 1.– С. 417» дигән җыентыкта китерелә. Текст соңгы чыганактан алынды.

## «Авыл халкы спискәсе»нең Учредительный собраниегә сайлау эшләрен башкару комиссиясе»нең беркетмәсе[1]

8 ноябрь 1917 ел, Уфа

Протокол № 13

8 нче ноябрь 1917 нче ел.

Мәҗлестә хазир булдылар: Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Әлмөхәммәтов, Шәриф Сүнчәләй һәм Галимҗан Әминев.

1 – Уфа вилаятендә булган өяз шәһәрләрендәге Учредительный собраниегә сайлау комиссияләренә 3 нче номерлы спискәдән вәкилләр тәгаенләү мәсьәләсе каралып, түбәндәге рәвештә тәгаенләргә карар бирелә:

1 – Бәләбәй шәһәрендәге өяз сайлау комиссиясенә – Газыйм Касыймов[2].

2 – Эстәрлетамак шәһәрендәге өяз сайлау комиссиясенә – Гыйлаҗетдин Миңлебаев.

3 – Минзәлә шәһәрендәге өяз сайлау комиссиясенә – Шакирҗан әл-Хәмиди.

4 – Бирский шәһәрендәге өяз сайлау комиссиясенә – Фатыйх Вәлидов.

5 – Златоуст шәһәрендәге өяз сайлау комиссиясенә – Мирсәет Габделкауров.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 106 эш, 129 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Газыйм Касыймов* – Газыйм Касыйм улы Касыймов (1891–1938), журналист, партия һәм җәмәгать эшлеклесе. 1918–1919 елларда Бәләбәй шәһәрендә татар телендә нәшер ителгән «Ярлы тавышы» газетасының мөхәррире була. 1921 елның җәеннән алып, 1922 елның беренче августына – Зур Башкортстан оешканга һәм аның башкаласы Стәрлетамактан Уфага күчкәнгә кадәр, РКП(б)ның Уфа губкомы органы булып татар телендә Уфада чыккан «Урал» газетасының мөхәррире. 1923 елда ул М. Гафуриның иҗат эшчәнлегенә 20 ел тулу юбилеен һәм аңа «Башкортстан халык шагыйре» исемен бирүне оештыручыларның берсе. Шулай 1923 елда әдип турында татар телендә беренче китапны (Касыймов Г. Атаклы халык шагыйре Мәҗит Гафури (әдәбият юлында егерме еллык хезмәте шәрәфенә язылган бөек бәйрәм – юбилей мөнәсәбәте белән).– Нашире: Башкортстан нәшрият һәм китап сәүдәсе ширкәте.– Уфа: Типо-лит. Башпрома «Октярьский натиск», 1923.– 87 б.) яза. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

6 – Уфа өязе сайлау комиссиясенә вәкил итеп – Галимҗан Әминов.

7 – Югарыда тәгаенләнгән вәкилләргә Уфа округ комиссиясендә 3 нче номерлы спискәнең вәкиле Гомәр Әлмөхәммәтовка үз исеменнән телеграмнар йибәрергә тапшырырга карар бирелә.

Рәис өчен: (*Галимҗан Әминев имзасы*).

Әгъзалар:... (*Галимҗан Ибраһимов имзасы*).

Сәркятип: (*Гомәр Әлмөхәммәтов имзасы*).

## Г. Ибраһимовның Эчке Русия вә Сибирия мөселманнарының беренче Милләт Мәҗлесендә яңа канун ляихәләре комиссиясенә сайлануы хакында[1]

26 ноябрь 1917 ел

Мәҗлес сәгать 11 дә ачыла.

Садри әфәнде Максуди рәислек итә. Сайлау нәтиҗәләре игълан ителә.

Сайлауларның нәтиҗәләре шулай чыкты:

...Яңа канун ляихәләре комиссиясенә:

Беренчедән Ибнеямин Әхтәмов, Нәҗип Корбангалиев, Гаяз Исхакый, Госман Дивиев, Габдулла Сөләймани, Һади Атласи;

Икенчедән Сәгыйть Янгалычев, Галимҗан Ибраһимов, Ильс Алкин, Гани Абызов, Фәтхи Әхмәдуллин, Фатыйх Сәйфи.

Комиссиянең риясәтләре: комиссияләргә риясәтләр сайланып бетте. Мәгариф комиссиясе[ндә]: рәис – Гомәр Терегулов, иптәше Ибраһим Бикколов, сәркатип Шәһит Әхмәдиев, иптәше Хәлил Бакиев.

Дәстүр комиссиясендә: рәис Нәҗип Корбангалиев, сәркатип Исмәгыйль Габди.

Яңа канун ляихәләре комиссиясендә: Ибнеямин Әхтәмов. Иптәше Янгалычев, сәркатип Гани Абызов.

Диния комиссиясе[ндә]: рәис Салихҗан Урманов, иптәше Зыяэтдин әл-Камали, сәркатип Хәнәфи Мортазин, иптәше Мөбарәкшаһ Хәнәфи.

Сөаль вә истифарда: рәис Г. Баттал.

[1] Беренче мәртәбә «Мохтарият» журналының 1917 елгы 4 нче санында (б. 1–15) бастырыла. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2017.– Т. 1.– С. 435» дигән җыентыкта китерелә. Текст соңгы чыганактан алынды.

## Г. Ибраһимовның Эчке Русия вә Сибирия мөселманнарының Милләт Мәҗлесеннән башкортлар съездына китүе хакында[1]

27 декабрь 1917 ел

...Тупракчылар фракциясе. Милләт Мәҗлесенең башында көчле бер фракциядә, соңгы вакытта фракциянең зәгыйфьләнүе күрелә. Башта фракция җыела торган бүлмә Галимҗан Шәрәф эшләгән хариталар[2] белән бизәнгән вә һәрвакыт җанлы эш белән кайный иде. Ләкин тупракчылар җыелып бер рәсемгә төшү белән, бу бүлмәнең кешеләре тарала, көч аерыла башлады. Кайбер әгъзалар күп эшле тупраклы мохтарият комиссиясенә керделәр, кайберләре (Галимҗан Ибраһимов башкорт съездына[3], Ильяс Алкин Хәрби Шурага) Милләт Мәҗлесеннән киттеләр. Соңгы көннәрдә кайбер мәсьүл[4] әгъзалар урыннарыннан истигъфа[5] итеп, кайберләрне с[оциал] – р[еволюционер] максималист дип, аерым гөруһ[6] тәшкил иттеләр. Тупракчылар эчендә бу хәлгә тәәссеф[7] итеп, фракцияне табигый халәтенә кайтарырга теләүчеләр күренә...

---

[1] Беренче мәртәбә «Безнең тавыш» газетасының 1917 елгы 27 декабрь санында «Мөхбир» имзалы авторның «Милләт Мәҗлесе хәбәрләре» дигән мәкаләсендә бастырыла. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2017.– Т. 1.– С. 459» дигән җыентыкта кителә. Текст соңгы чыганактан алынды.

[2] *Харита* – географик карта.

[3] *Галимҗан Ибраһимов башкорт съездына...* – сүз 1917 елның 8–20 декабрендә Оренбургта үткәрелгән өченче Бөтенбашкорт корылтае хакында бара. Бу корылтайда Башкорт хөкүмәте оештырыла.

[4] *Мәсьүл* – җаваплы.

[5] *Истигъфа* – хезмәттән азат итү, эштән чыгу.

[6] *Гөруһ* – төркем.

[7] *Тәәссеф* – кайгыру, ачыну.

# ХАТЛАР

## 1912
## Письмо Г. Ибрагимова из Киева Ханафию Кайбышеву[1]

13 декабря 1912 г.

Уважаемый господин Ханафи. Недавно Вам писал письмо. После того, как господин Халил (или Халиулла) имел намерение отправиться в Казань и Вас там увидеть у меня есть еще несколько слов, которые хотелось бы вам сообщить. Однако я и сам не знаю с чего начать. Наверное все написал уже в последнем письме (строчка непонятна) господину Халилу воздух Киева пришелся по душе. Там он начал Бог весть как беситься. Он поехал в Казань с этой же миссией, т.е. (как будто бы) побеситься. Не знаю будет ли там почва или нет. Взятая им на себя должность поверенного в делах очеь важна с точки зрения и идеи. Как Вы смотрите на этот вопрос, т.е. поддерживаете его или отвергаете. (Слово непонятно) конечно будет многозначительным. От меня благословение... Если однако коснутьтся самой крупной из нужд, в крайнем случае одна партия, думается, молодежи не смотрит на это холодно. Во всяком случае имеет большое значение в деле характеристики нашей молодежи как ответить Казань на голос сынов, могучего своей природой Кавказа. Многие вещи ясно понимаются. Кончаю слово (приветствие) Галимджан. Киев 1912 г[од] 13 декабря.

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (199 ф., 1 тасв., 914 эш, 29, 29 (икенче ягы) кәг.). Беренче мәртәбә «Язучы биографиясенә яңа чыганаклар» дигән җыентыкта (Казан, 1989, б. 48–49), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында татар теленә тәрҗемә итеп бастырылган (Казан, 2000, б. 68–69). Текст төп нөсхәдән алынды.

Хат аерым жандармнар корпусы тарафыннан студент Мөхәммәтханәфи Кайбышевны 1913 елның 3 маенда тентү буенча төзелгән 16 санлы беркетмәдә урнаштырылган. Беркетмә полковник М.В. Прогнаевский тарафыннан имзаланган. Тәрҗемәче – 15 нче Татар Улан полкы штабс-ротмистры фон-Трентовиус. Пүнәтәйләрнең имзалары аңлашылмый.

## Письмо Х. Кайбышева из Казани Г. Ибрагимову[1]

28 декабря 1912 г.

Халиуллу (т.е. Еникеева) проводили, сам расскажет, когда увидитесь, но и я расскажу в 2-х словах. Я исполнил, что мог, но не интересуюсь его идеей, а для оказания помощи Халиулле и для того, чтобы пыл его не остыл (буквально – ходил лишь для того, чтобы не погась огонь в его мысли и на сердце) Вы можете быть скажете: «Почему Вы так сделали?» Вот почему. Объединение молодежи, объединение татарской молодежи чересчур хорошее дело, это одно из моих самых больших (буквально – высоких) мечтаний. Поэтому я говорю, что это невозможно. Я не могу верить, чтобы в жизни наших татар свершились чересчур хорошие дела. Об осуществлении «высоких мечтаний» я не буду даже говорить. Словом – я впол[не] знаю казанскую молодежь. Чувствуя, что будет легче вить веревку из песка, чем их, т.е. молодежь собрать в одну точку. И в прочих городах молодежь та же. Кавказских молодцев я не люблю. Их мысли узки, как узки ущеллия межде их горами... нет полета мысли... Халиулла приехал с целью объединить студентов, мы воспротивились. Должно быть (т.е. его прибытие) имело целью объединить вообще молодежь. Для студентов существуют землячества. Поручать дела студентам, собрав их для проведения дел цивилизации – было бы созданием на свете одной самой интересной монополии. Хотя и так: мол когда был здесь Халиулла, молодежь собралась и обсуждала (беседовала), написано в скобках и я тут был. Придя к решению сделать какое либо дело, выбрали комиссию. Когда Халиулла уезжал, он очень ругался. Свидания с казанской молодежью послужило для него больших уроков.

Перевод сделан штабс-ротм. фон-Трентовиусом

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (199 ф., 1 тасв., 63, 63 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды.

Хат Киевтә 1913 елның 17 апрелендә Г. Ибраһимовны тентү вакытында алынып, рус теленә тәрҗемә иттерелгән.

# 1913
# Г. Ибраһимовның Киевтән Хәнәфи Кайбышевка язган хаты[1]

3 гыйнвар 1913 ел

Мөхтәрәм Хәнәфи әфәнде!

Хәзер генә хатыңызны китереп бирделәр. Менә укып чыгу белән җавапка да керештем. Бәлки, тиздән озын ук хатым булыр, бу юлы тик әллә нинди бер минутлык тәэсирдән генә шулай ашыгылды да, шуңа күрә уйларга җай калмады.

Хәлилдән мин бер хат алган идем. Сез дә, ул да асыл мәсьәләне тәфсыйл итмәгәнсез. Аның хатында да Казан яшьләреннән тәмам разочарование аңкый иде, Сезнең бәяныңыз да шул күрелдә. Мин Хәлил әфәнде илә очрашканда, һәрвакыт Сезнең хакта сүз чыга иде. Ул минем Сезне тасвирыма каршы: «Ышанмыйм, син аны аңлап җиткермәгәнсеңдер», – ди иде. Хатыңызны алгач, мин Сезне яхшы ук аңлаганлыгымны сизеп, бераз киберем[2] дә кузгалды.

Сез әүвәлге хатыңызда да татарның киләчәгендә бик караңгы бер каберстаннан башка нәрсә күрергә мөмкин түгеллеген сөйләгән идеңез, бусында да шуңа якын мәфһүм[3] күрәм. Гомумән, Сезнең хатыңыздан, Хода белсен, ниндидер бер авыр, үтергеч салкын исә.

Мин шуларны укыйм, бер түгел, кат-кат укыйм, башта, әлбәттә, дөньяда Сезнең кебек адәмнәрнең булуына йөрәк ачый, гүя Сезнең шул шөбһәләреңез астында әллә ни чаклы яшь иманнар берәм-берәм егылырлар, җимерелер кебек тоям. Гүя Сез иң зарарлы гонсырлар[4] күренәрсез... Ләкин бу бер минутлык тәэсир була... Менә мин яңадан үзгәрәм дә Сезнең хәзерге халәтеңезне әллә нинди вакытлы кебек күрәм. Гүя менә бервакыт Сезне бөек

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (199 ф., 1 тасв., 52 г-52 д (икенче ягы) кәг.) Беренче мәртәбә «Язучы биографиясенә яңа чыганаклар» дигән җыентыкта (Казан, 1989, б. 49–50), аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бер үк хат ике итеп, шактый хәреф хаталары һәм кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 69–71). Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Киберем* – тәкәбберлегем.

[3] *Мәфһүм* – эчтәлек.

[4] *Гонсырлар* – элементлар.

нәфсеңез аны күтәрә алмыйча, берьюлы бөтен рухын үзгәртеп, Сез бер күтәрелү белән әллә кемнәрнең әллә кайчаннан бирле корып килгән хәлсез биналарын бер минутта кырып, җимереп ташларсыз, татар тормышының әллә кайсы явызлыкларын берәм-берәм җимереп, яңа хәят вә яңа идеалның җимерелмәс нигезләрен җирләштерерсез кебек хис итәм.

Ышанырсызмы, «Аң»ны күргәнем юк. Мин «Гасыр»да ничә елдан бирле эшлим[1]. Бу – бер. Икенче, Киевкә киткәндә, Фатыйх «Аң» исеменнән мине язышырга рәсми рәвештә чакырды. Монда килгәч, Гәрәй, үзе хат язып, яңадан «Аң»га язышуны үтенде. Шулардан соң, бер этлек булмаганда, журналның беренче номерын йибәрергә анлар тиешле иде. Мин моны болай анларның мәгънәсезлеген күрсәтү өчен генә язам.

Гәзитәләр дә Сезнең «Айсылу»ның «Аң»да басылганын хәбәр бирде[2]. Артык шатмын. Һәр номерда Сезнең исемнең очравын телим.

Беләсезме, Сезнең теге айга менгән Зөһрәнең Фатыйх тарафыннан алынганын ишеткәч, бик ачуым кабарган иде. Аның «Халык кызлары»н[3] күргәч, бик озаклап көлдем һәм бар ачуым таралды. Андый бер Зөһрә түгел, мең Зөһрә язылса да, Сезнекенә бер инә чаклы зарар бирмәячәк. «Халык кызлары»ндагы Зөлхәбирәне үткән ел башка бер мөхәррир эшләп, «Гасыр»га саткан иде[4]. Мин ул бичараның да эшләре әрәмгә калды дип уйлаган идем. Карасам, аныкы илә Фатыйхныкы арасында дәхи йир-күк бар. Минем башымда күптән, бик күптән әллә ни

---

[1] *Мин «Гасыр»да ничә елдан бирле эшлим* – Г. Ибраһимов «Гасыр» нәшриятында рәсми рәвештә эшләми. Бәлки, ул хезмәттәшлеген белдергәндер. Чөнки 1911 елда аның «Татар нәхүе», «Татар сарыфы» дәреслекләре, «Сөю-сәгадәт» әсәре шушы нәшриятта бастырыла.

[2] *Гәзитәләр дә Сезнең «Айсылу»ның «Аң»да басылганын хәбәр бирде* – Хәнәфи. Айсылу. Халык әкиятеннән алып язылган / Хәнәфи // Аң.– 1913.– № 2.– Б. 5–7. М. Хәнәфинең (Мөхәммәтхәнәфи Кайбышевның) иҗат эшчәнлеге хакында тулырак: Мирсияпова Т.И. Экзистенциальные мотивы в творчестве М. Ханафи: Автореф. дис… канд. филол. наук / Т.И. Мирсияпова; ГОУ ВПО «Казанский государственный университет им. В.И. Ульянова-Ленина».– Казань, 2009.– 26 с.

[3] Әмирхан Ф. Халык кызлары. Ай өстендәге Зөһрә. «Юл» китапханәсеннән 64 нче китап.– Казань: Электро-тип. «Умид», 1913.– 31 б.

[4] *«Халык кызлары»ндагы Зөлхәбирәне үткән ел башка бер мөхәррир эшләп, «Гасыр»га саткан иде* – сүз шушы басма хакында бара: Бәшири З. Картада оттырылган кыз хикәясе. Халык телендә сөйләнелә торган Зөлхәбирә хакында. Нашире: Г. Гобәйдулла.– Казань: Электро-тип. «Умид», 1912.– 40 б.

чаклы һәм матур, һәм фаҗигый картиналары белән Сөембикә йөри иде. Фатыйх аны яза дигәч, афәрин, эшем бетте дип уйлаган идем. «Халык кызлары»н күргәч, яңадан өмидем артты гына түгел, инде Сөембикә хакында музам үз малы кебек эшли башлады. Фатыйх минем Сөембикәмә якын да килмәгән, нитәк ул якын килмәгән иде Сезнең айга менгән туташларга.

«Халык кызлары»н укыгач, мин Фатыйхны кызгандым.

Сез яңа тормышка кергәнсез. Хәерле булсын. Мондагы дөнья беркөе ага. Бәйрәм үтте инде. Сездә дә беренче гыйнвар белән тәбрикләшү тәкәллефе юк бугай.

Хатым бер минутлык тәэсир астында, гайре табигый халәттә язылa. Эчендә җүләрлекләре булса, шул халдән күрерсез. Тиз дәхи хат язарга тырышырмын. Дога вә фатыйха: Галимҗан – 1913, гыйнвар – 3, Киев.

## Х. Кайбышевның Казаннан Г. Ибраһимовка язган хаты[1]

27 гыйнвар 1913 ел

Мөхтәрәм Галимҗан әфәнде! Бу көннәрдә Сезгә хат язаем диеп йөри идем, бер көнне кич булып килгәндә Сезнең «Яшь йөрәкләр»еңез[2] килеп төштеләр. Бу бүләгеңез өчен меңмең рәхмәтле. Мин тегеләй дә алып укымакчы булып йөри идем, анысы мөмкин түгел бит. Чөнки зурлыгы берлән бу – бездә беренче роман (зурлыгы тугрысында гына сөйлим – чөнки укып чыга алмадым әле). Бигрәк тә минем өчен кызыклы мәсьәлә: ниләр шул тикле күп иттереп татар тормышы хакында әйтә алдыңыз икән, дим. Чөнки художественный роман улганда анда (ягъни «Яшь йөрәкләр»дә) ахыр ун ел тормышымыз улса кирәк, үзенә күрә бер отчет... Хәер, белмим әле, укып карамый сүз йөртүе кыен, тик бу эш Сезнең каләмеңез берлән язылганга күңелемдә йәринчә өмидләр уйганып тора...

Хәлиулланың бунда килеп китүе тугрында языган җирләрем Сезне канәгатьләндерә алмаган икән. Хәзер инде боларны язуда файда юк. Хәлиулла әфәнде Киевтәдер – баштан-аяк сөйләп бирер.

Минем «Айсылу»ны Сез күтәрәсез күтәрүен дә, хәзер укып чыккач, фикереңез, бәлкем, йәринчә үзгәргәндер дә. Чөнки Сез аны бер мәртәбә ишеттеңез генә, үзеңез дә укымадыңыз, бары ишеттеңез генә... Өченче номерда тагы минем бер нимәмне баскан иделәр, анысын үзем телгә алырлык диеп әйтә алмыйм.

Сезгә «Аң» бара башлагандыр инде. Беренче номеры чыккач, мин Хәсәнидән сораганымда ул йибәрдек дигән иде. Әле соңыннан шуны исенә төшердем дә, ул магазинындагы әфәнделәреннән сорый: «Йибәрелдеме?» – диеп. Теге әфәнде: «Юк, йибәрелмәгән иде», – дия куйды. Шулай итеп Сезне мәхрүм тотканнар икән. Фатыйх «Аң»да бик киңәя алмый, чөнки «Кояш»тан бушамый да. Аннан башка да «Аң»да романистлар йитәрлек булачак. Бигрәк хәзер «Мөрәббия»не баса башлагач...[3] Хәсәни

[1] Төп нөсхә Украина Үзәк дәүләт тарих архивында саклана (ф. 274, 3 тасв., 238 эш). Текст Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивындагы ксерокүчермәдән алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Яшь йөрәкләр»еңез* – Ибраһимов Г. Яшь йөрәкләр. Нашире: Әхмәд әл-Исхакый «Шәрык» көтепханәсе / Г. Ибраһимов.– Казань: Электро-тип. «Умид», 1912.– 416 б.

[3] *Бигрәк хәзер «Мөрәббия»не баса башлагач...* – Мөрәббия. Роман. Мөхәррире:

фәнни нәрсәләр сорый, язарга кеше юк. Журналның яхшы булуын теләгәннән мин тырышып карар идем – бер дә вакытым юк, имтихан тотудан бушап булмый.

Бигрәк фәнни нәрсәләр язу – минем өчен бу эшкә өйрәнер өчен яхшы улыр. Чөнки киләчәктә (хәзер дә шулай ук) минем каршымда дошманнардан, төрле «фәлсәфә»ләрдән фән алда булачак. Шунлыктан миңа фәнни фикерләрне юл-юл итеп тезәргә өйрәнү – бик кирәкле эш булыр. Мәгәр Элиге әйтте: «Вакыт булмагач, аны сатып алып булмый».

Хәлиулла барда без комиссия сайлаган идек. Ул Устав төзер өчен сайланган булса да, хәзергәчә Уставка тотынганы юк әле. Мәгәр аның урынына комиссиямез хәзерлегендә зур бер вечер ясарга йөри булса кирәк... Ходай ярдәм бирсен! Шулай ук Хәлиулла монда чакта Киев студентларына акча җыеп йибәрмәкче идек, мәгәр хәзер ул мәсьәлә һичбер кузгалмый. Шулвакыт халык: «Соңыннан йибәрәмез», – ди башлагач, мин: «Иптәшләр, тимерне кызуында сугу яхшы булыр иде, соңыннан бу эшне онытырмыз», – дигән идем, әлбәттә, минем сүзләремә бары да каршы төштеләр. Мәгәр хәзер дә шул хәлләрне Хәлиуллага сөйләңез. Боларны сөйләп, гомумән, эчен яндырыңыз әле (әлбәттә, әгәр шул эшеннән суынып өлгермәгән улса).

Сездә ни хәлләр бар? Ни берлән тугрылыйсыз? Ниләр йимерәсез? Казанны сагынмайсызмы? Ни язасыз? Качан мәшгуль яза торган нәрсәңез дөнья күрәчәк?

Вакыт салыңыз! Татар копирациянең кадерен белергә әйтә башлаган кеби тоела. Фикереңезчә татар тормышында хәзердә ниндәен агымнар сизелә, күренә? Уйлап карасаңыз языңыз әле. Рәхмәт әйтермен...

Хушыңыз. Языңыз. Язарга вакытым булмаса да – укырга вакытым бар.

Адрес – иске.

Хәнәфи

27/I. 13 г.

P. S. Хәлиуллага сәлам. Хат язсын.

---

Хөсәен Рәхми. Мөтәрҗиме: Г. Авыргазый // Аң.– 1913.– № 3.– Б. 34–38; – № 4.– Б. 52–57; – № 6.– Б. 91–94; – № 7.– Б. 111–114; – № 8.– Б. 128–131; – № 9.– Б. 155–158; – № 10.– Б. 162–167; – № 11.– Б. 183–184; – № 12.– Б. 198–203; – № 13.– Б. 219–224; – № 14.– Б. 234–239; – № 15.– Б. 251–154; – № 16.– Б. 278–281; – № 17.– Б. 290–294; – № 18.– Б. 307–310; – № 19.– Б. 329–332; – № 20.– Б. 342–345.

## Письмо Х. Кайбышева из Казани Г. Ибрагимову[1]

27 января 1913 г.

Когда был здесь Халиулла мы было выбрали одну комиссию. Хотя эта комиссия и была выбрана для выработки Устава, но до настоящего времени она еще не принялась за устав. Однако, вместо этого, наша комиссия в настоящее время кажется думает организовать один большой вечер. Дай Бог помощи. А также, когда Халиулла был здесь, мы хотели собрать деньги и послать Киевским студентам, однако в настоящее время этот вопрос не возбуждается... В то время публика стала говорить: «Товарищи, хорошо было бы ковать железо, когда оно горячо, после забудем». Конечно моим словам все воспротивились. Но сейчас расскажите это обстоятельство Халиулле. Если он недостаточно верит тому, что я знаю казанцев, не будет лишним, чтоб он поверил. Расскажите ему все это и вообще, буквально – жгите его внутренность (это я думаю в смысле надосадить ему). В скобках: конечно, если он не успел еще остыть к этому делу.

Перевод сделан штабс-ротм[истром] фон-Трентовиусом

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (199 ф., 1 тасв., 63 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды.

Хат Киевтә 1913 елның 17 апрелендә Г. Ибраһимовны тентү вакытында алынып, рус теленә тәрҗемә иттерелгән.

## Письмо Халиуллы Еникеева из Казани Г. Ибрагимову[1]

17 апреля 1913 г.

Здравствуй Галимджан эфенди. Привет тебе из Казани. 17 декабря я приехал в Казань и до 21 декабря обделывал дела. Результаты скверны. Виноват в этом ты, ибо твоя аттестация меня погубила все дело. Казанская молодежь оставила самое невыгодное впечатление. Во-первых, ты будешь за это наказан, во-вторых, принужден будешь поставить бутылку водки. Познакомился со всей казанской молодежью. Идея моя нашла всеобщее сочувствие, но личные интересы выше общественных дел. Могу пока сказать, что здесь столько партий, сколько людей. Но обо всем после, когда я приеду. Предупреждаю, во избежении недоразумений на запросы из Казани воздерживаться, ибо самая идея мною несколько переиначена. Это я сделал на свой риск. Мне опять придется после Рождества с ними воевать. Постарайся познакомиться с студентом Талышинским и проводи свои взгляды на дело. Этим ты много можешь служить самой идее... Постарайся записаться в число членов зе[мляче]ства. Между прочим, по тактическим соображениям я говорил, что ты в этой работе принимаешь деятельное участие. Имей в виду и не прозевай. В случае если будет запрос, говори, что имеешь в виду объединение не только студенчества, а всей мусульманской молодежи. Это тоже по тактическим соображениям. Могу только пока сказать, что здесь образовалась ячейка. Это успех. Рисуй киевское землячество в более или менее идеальном освещении. Пока всего хорошего. Через пять минут уезжаю в Уфу.

ХаЕникеев[2]... 21-го декабря.

С подписанном верно: Отдельного корпуса жандармов подполковник (*подпись Прогнаевского*)

---

[1] Төп нөсхә (машинкада язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (199 ф., 1 тасв., 914 эш, 49, 49 (икенче ягы) кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

Хат Киевтә 1913 елның 17 апрелендә Г. Ибраһимовны тентү вакытында алынып, рус теленә тәрҗемә иттерелгән.

[2] *ХаЕникеев* – Халиулла Еникеев.

## Письмо Г. Ибрагимова из Киева Шагиту Ахмадиеву и Загиту Нуркину[1]

24 апреля 1913 г.

Шагит и Захид[2]!

Шлю Вам свой первый привет из Киевской тюрьмы. Вам, наверное, известно, что я арестован. Но, думаю, не мешал бы Вам кое-что слышать и лично от меня самого.

Все вышло очень просто. 17 го апр[еля] 12 ч[аса] ночи в моей комнате был обыск, по постановлению Киевского жандар[мского] упр[авления].

Взята масса книг, как татарских, так и русских и турецких. Также взят все письма, картины, даже альбом. И, главное, все мои рукописи[3], среди которых было кроме планов заметков, схем, несколько готовых статьи для газеты, маленьких рассказов и, главное, то злосчастная «Киргизская дочка»[4], над которой я работал всю целую зиму. Я думаю теперь только о рукописях: если их мне возвратят, то все остальное – второстепенно!

Как уже сказал, взяли мои вещи, вместе с ними арестовали и себя.

---

[1] Төп нөсхә Украина Дәүләт архивында саклана (274 ф., 3 тасв., 236 эш, 1–2 кәг.) Татар теленә тәрҗемәсе «Кызыл таң» газетасының 1967 елгы 19 февраль, «Казан утлары» журналының 1972 елгы 8 нче, «Социалистик Татарстан» газетасының 1977 елгы 14 март саннарында, Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында урнаштырылган (Казан, 2000, б. 75–76). Текст Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивындагы фотокүчермәдән алынды һәм оригиналда беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Захид* – Заһидулла Садретдин улы Нуркин (1888–1966), журналист, тәрҗемәче. 1922–1927 елларда Гыйльми үзәкнең редакция коллегиясендә сәркятип булып эшли.

[3] *… все мои рукописи* – Г. Ибраһимовны тентү вакытында алынган барлык кульязмалары, Киев губерна жандарм идарәсендә тәрҗемәче булмау сәбәпле, Казан губерна жандарм идарәсенә җибәрелә. Анда аларны штабс-ротмистр А.Ф. фон-Трентовиус рус теленә тәрҗемә иткәннән соң, кире Киевкә җибәрелә. Аларның бер өлеше Г. Ибраһимовка кире кайтарыла, икенче өлеше югала.

[4] *… то злосчастная «Киргизская дочка»* – Г. Ибраһимовның 1909 елда язылабашлап 1911 елда тәмамлаган бу әсәре Оренбургта «Вакыт» нәшрияты тарафыннан бастырыла башлагач, типографиядә тентү булып, кульязма жандарм идарәсенә эләгә һәм кире кайтарылмый. Автор үзендә калган каралама нигезендә әсәрне яңадан яза. Киевтәге тентүләр вакытында бу кульязма да алынып, җитмеш бите югала. Шуңа язучы ул әсәрне «злосчастная» дип атый.

Когда меня привели в участок, я был ужасно порожен тем, что там сидят 12 мусульманск[их] ст[удентов] и, еще в добавок, в другой камере две курсистки – одна из Уфы, Ахтямова, другая из Кавказа, Сона ханым[1].

А среди студен[тов] были представители мусуль[манского] студен[чества] из Казани, Петербурга, Москвы (брат Каримова[2]) и др[угих] универ[ситетских] гор[одов].

Там мы все вместе переночевали, а утром меня в тюрьму, их незнаю куда.

Вот уже прошла неделя как я день и ночь шагаю зад-перед в своей одиноко заключенной комнате, т.е. камере. Рядом со мной сидит ст[удент] кав[казец] Рустамбеков. Он тоже с нами вместе арестован. Как я сидит в положение одиночного заключения.

Шагит (если его в Казани нет) или ты Захид: вы немедленно сообщите моему брату по адр[есу] Уф[имская] губ[ерна] Стерлитамак[ский] у[езд] Уршакминск[ая] вол[ость] д[еревня] Султанмуратово. Шакирджан...

Потом, и это главное, Шагит, я тебе даю поручение: насчет второго издания этимологии[3] поговори с «Гаср»ом. Сделай условие как сам находишь выгодным. Пожалуйста не оплашай.

Пишите обо всем подробно, кланяйтесь всем.

Пока досвидания: Галимзан.

---

[1] *Сона ханым* – Сона Абделхак кызы Ахундова (1893–?), Киевтә хатын-кызларның югары курсларында табигать белеме факультетында укыган.

[2] ... *брат Каримова* – сүз язучы, нашир, җәмәгать эшлеклесе Фатыйх (Мөхәммәтфатыйх) Кәриминең (1870–1937) бертуган энесе, ул вакытта Мәскәү сәүдә институты студенты Мөхәммәтгариф Кәримов (1887–1935) хакында бара.

[3] ...*насчет второго издания этимологии* – сүз шушы китап хакында бара: Ибраһимов Г. Татар сарыфы. Икенче кәррә басылуы. Наширләре: Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе, Казан / Г. Ибраһимов.– Казань: Лито-тип. И.Н. Харитонова, 1913.– 78 б.

## Г. Ибраһимовның Солтанморат авылыннан Әхмәтгәрәй Хәсәнигә язган хаты[1]

8 сентябрь 1913 ел

Мөхтәрәм Әхмәтгәрәй әфәнде!

Мәктүбеңне алдым. «Аң» кебек куәт вә тәрәккыен чыннан арзу[2] иттегем бер журналның портфелен тәкъдим итүеңезгә – шундый мөһимioктада мине зурлавыңызга рәхмәт.

Беләсез, мин хәяте мотлака[3] кешесе. Шуның өчен дә күпләрнең тәгаҗҗебенә каршы моңарчы «Вакыт» вә «Йолдыз» кебек зур вә карт газеталарның дәгъвәтен иҗабәт итми[4] килә идем.

Ләкин Сезнең дәгъвәтеңезне алгач, кырт кисеп рәд[5] җавабы бирәсем килмәде. Озакламый Казанга барам. Шунда тәфсыйлләп сөйләшербез.

Шартларда килешсәк, уйлаган мәртәбәдә тәрәккый бирә алучөн лязем[6] улган әсбап вә мәваднең[7] табылуында әминиять[8] ала алсак, бәлки, бергә эшләп тә китәрбез.

Һәрнә күрешкәч мәгълүм улыр.

Хәзергә хөрмәт вә сәлам: Галимҗан – Солтанморат.
1913 – сентябрь 8

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (121400). Беренче мәртәбә «Безнең мирас» журналының 2017 елгы 6 санында бастырыла (б. 28–30). Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Арзу* – теләк.

[3] *Хәяте мотлака* – ирекле тормыш.

[4] *Иҗабәт итми* – кабул итми.

[5] *Рәд (рәдд)* – кире кайтару, кабул итмәү.

[6] *Лязем* – тиешле.

[7] *Мәвад* – матдә.

[8] *Әминиять* – ышаныч.

## Г. Ибраһимовның Казаннан Хөсни Кәримгә язган хаты[1]

26 октябрь [1913 ел]

Хөсни[2] иптәш!

Төрмәдән чыкканлы бирле[3] сиңа хат яза алганым юк. Ачуланган булсаң, кичерә күр. Үзеңдә дә шундый эшләре булгалый торгандыр эле.

«Аң»ның секретарьлыгын алдым[4]. Буны, бәлки, ишеткәнсеңдер дә. Яшь фикер, яшь куәт «Аң» тирәсенә җыелсын иде. Чын мәгънәсе илә әдәби вә мәдәни бер мәҗмуга шәкеленә керсен иде, дим. Синең «Волга» хакындагы мәкаләң[5] миндә. Бәйрәм номерына кертә алмадым. Чөнки Шәһит теге шигыреңне бирде[6], аны баскач, «Волга» калды. Чөнки бер номерда ике имза килешеп бетми.

«Волга»ңда хиссият зур. Ләкин эшләнүе җитми. Бик ашыккансың. Мин сине беләм, син башыңда түгел, кәгазьдә эшлисең. Мин үзем дә шулай. Шуңа күрә иптәшлектән әйтәм, син һәрбер мәкаләңне, һич булмаса, өч мәртәбә язып чык. Беренчесе алган мәүзугың[7] хакында башыңа ни килсә, тәртибенә-фәләненә ри-

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (120006–6[а]). Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 3 нче санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер хаталар белән бастырылган (Казан, 2000, б. 78–79). Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Хөсни* – Хөсни Кәрим (Хөснетдин Минһаҗетдин улы Кәримов, 1887–1965), язучы, педагог, җәмәгать эшлеклесе. Г. Ибраһимовның «Галия» мәдрәсәсе буенча сабакташы, якын дусларыннан берсе. Ул 1912–1915 елларда Әстерханда рус-татар мәктәбендә мөгаллим булып эшли.

[3] *Төрмәдән чыкканлы бирле* – сүз, гаебе табылмау сәбәпле, 1913 елның 13 июнендә Киев төрмәсеннән чыгарылуы хакында бара.

[4] *«Аң»ның секретарьлыгын алдым* – Г. Ибраһимовның бу журнал идарәсендә сәркятип булып эшли башлавы хакында басманың 1913 елгы 20 нче санында хәбәр дә бастырыла: «Идарәдән: «Аң»ның сәркятиплек (секретарьлык) ләвазимене мөхәррирләремездән Галимҗан Ибраһимов әфәнде кабул итте. Журнал киләчәк санында игътибар аның каравында чыгачактыр» (б. 353). Ул әлеге вазифаны 1914 елның 13 февраленә кадәр башкара.

[5] *Синең «Волга» хакындагы мәкаләң* – «Аң» журналында Х. Кәримнең андый мәкаләсе билгеле түгел.

[6] *Шәһит теге шигыреңне бирде* – сүз Х. Кәримнең «Былбылга» исемле шигыре хакында бара. «Аң» журналының 1913 елгы 21 нче санында бастырылган (б. 353).

[7] *Мәүзугъ* – тема; эчтәлек.

гая[1] кылмыйча, тутырасың да чыгасың. Икенчесендә шул әүвәлге мәүзугъны табигый тәртипкә, һәр фикер вә картинаны тиешле урынына куеп чыгасың. Өченчесе инде актык эшләү була. Менә шулай эшләгәндә, синең мәкаләләр бик шәп чыгачак. Чөнки синдә фикер бар, хис бар, каләм дә бар. Тик шуларның ачык картинада табигый тәртип белән төзелүе җитми.

«Волга» бераз үзгәрсә, гаҗәпләнмә. Синең иптәшчә мөгамәләңә таянып, мин аны төзәткәләрмен.

«Аң»га тукталмый яз. Яхшы итеп эшләсәң, һәр номерга керә барыр. Гонорар иң азы өч тиен[2]. Мәкаләсенә күрә арттырырга да мөмкин булыр.

Әдәбият хакында, шигырь хакында язгаларсың дип уйлыйм. Ул хакта тәрҗемәләр дә матлуб[3]. Шигырең булса йибәр. Ләкин басармын дип алдан сүз бирә алмыйм. Иптәшчә мокавәлә[4] булсын, кире кайтарсам, үпкәләмәссең.

Сине авыру дип ишетәм. Кыен көннәрең үтеп, матди тәэминнән соң андый хәлгә төшүеңә бик кайгырам. Сәламәтләнүеңне телим.

Язуларыңны конверт тышына: «Галимҗан Ибраһимовка махсус»,– дип куйсаң, тагы аруырак булыр.

Озын хат яз әле.

«Аң»ның анкетына, әлбәттә, җавап язарсың[5]. Дәхи бернәрсә: «Идел»дә «Аң»ның үзгәреше хакында бернәрсә үткәрә алмассыңмы?[6] Андагы белешләргә сәлам сөйлә. Сәгыйть әфәнде[7] ни хәлдә?

Бакый дустлык вә иптәшлек илә Галимҗан Ибраһимов.

Казан, октябрь 26

---

[1] *Ригая* – игътибар итү.

[2] *Гонорар иң азы өч тиен* – сүз «Аң» журналында бастырылган текстның һәр юлына түләнгән каләм хакы турында бара.

[3] *Матлуб* – таләп ителгән.

[4] *Мокавәлә* – килешү.

[5] *«Аң»ның анкетына, әлбәттә, җавап язарсың* – Х. Кәримнең ул анкетага җавабы билгеле түгел.

[6] *«Идел»дә «Аң»ның үзгәреше хакында бернәрсә үткәрә алмассыңмы?* – анда Г. Ибраһимов сораган эчтәлекле мәкалә юк.

[7] *Сәгыйть әфәнде* – сүз Сәгыйть Рәмиев хакында бара. Хат язылган вакытта ул «Идел» газетасы идарәсендә эшли.

Иртәгә бәйрәм[1]. Ләкин тәбрик итәсем килми. Чөнки йөрәгемдә андый бер хис юк, ә ригаяләнергә теләмим. Рәсемеңне алдым. Зур рәхмәт. Алдыргач, үзем дә йибәрермен.

Хөсни, «Аң»да татар ысулының тәрәкъкыйсе[2] вә кичерелгән дәверләре хакында бернәрсә кирәк иде[3]. Моны «Бәдәвам»[4] вә «Фәзаил әш-шөһүр»ләрдән[5], Каюм Насыйри, Заһир Бигиләрдән[6] башлап хәзерге минутка терәргә лязем булыр. Һәм һәрбер дәвергә аерым мисал вә нәмүнәләр китерергә тиеш. Шуны уйлап карамыймсың? Син дә фикереңнең факттан күбрәк чыгуы бар. Бу хезмәттә исә фикердән артык факт вә нәмүнәләр[7] кирәк булыр.

---

[1] *Иртәгә бәйрәм* – сүз Корбан гаете хакында бара. «Аң» журналының 1913 елгы 21 нче санында басманың нашире һәм мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәни (1883–1934) белән Г. Ибраһимов тарафыннан «Аң»ның барлык язучыларын, мөхәррирләрен, мөштәриләрен һәм укучыларын әлеге бәйрәм белән тәбрикләре бастырылган.

[2] *Ысулының тәрәкъкыйсе* – ысулының алга китеше.

[3] *«Аң»да татар ысулының тәрәкъкыйсе вә кичерелгән дәверләре хакында бернәрсә кирәк иде* – журналда Х. Кәримнең андый эчтәлекле мәкаләсе юк.

[4] *«Бәдәвам»* – XVIII йөз урталарында иҗат ителгән, авторы билгеле булмаган дини эчтәлекле әдәби шигъри әсәр. Беренче мәртәбә Казан университеты типографиясендә 1846 елда нәшер ителә. Аннан соң күп тапкырлар бастырылып, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку китабы буларак файдаланылган.

[5] *«Фәзаил әш-шөһүр»* – «Айларның хасиятләре» дип тәрҗемә ителгән, мөселман календаре айлары хакындагы дини-әхлакый эчтәлекле бу китап Җәмалетдин Бикташи исемле кеше тарафыннан язылып, беренче мәртәбә 1854 елда Казанда нәшер ителгән. Аннан соң ул 1917 елга кадәр тагын берничә тапкыр бастырылган.

[6] *Заһир Биги* – Заһир Ярулла улы Бигиев (1870–1902), татар әдәбиятында роман жанрын нигезләгән мәгърифәтче әдип.

[7] *Нәмүнә* – үрнәк.

## 1914
## Г. Ибраһимовның Сухумнан Хөсни Кәримгә язган хаты[1]

12 апрель 1914 ел, Сухум

Хөсни иптәш!

Хатыңны алдым. Мин сиңа берничә мәртәбә язарга уйладым, ләкин адресың булмады. Элек андый вакытта «Идел» аркылы мөмкин иде. Хәзер ул туктаган дип ишеттем[2]. Үзеңнең башлап искә алуың бик ярады.

Казаннан зарарсыз гына жалунья, мәсьүлиятле[3] эшне ташлап китү халыкка ят күренде. Моны күпләр төрлегә хәмел иттеләр[4]. Син дә «Аң»нан китү дигән шикелле карыйсың. Юк, алай түгел, мин «Аң»нан китмәдем[5], Казаннан киттем. «Аң»ны Кавказда, Киевтә, Мәскәүдә, һич булмый икән, Әстерхан, Уфада чыгарырга булса иде, мин аны ташламас идем. Мин Казанда шул мәгълүм мохиттә тора алмыйм, Казан үзенең Печән базары, Болагы, Балык базары белән, аннан бигрәк тә эшсез, имансыз, фасыйк[6] яшьләре, баштанаяк мәгънәсез интригалар[7] эченә чорналып

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (120006–6[б]). Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1957 елгы 3 нче, рус теленә тәрҗемәсе «Дружба народов» журналының 1957 елгы 5 нче саннарында бераз кыскартылып, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 81–83). Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *«Идел»... туктаган дип ишеттем* – Әстерханда татар телендә нәшер ителә торган «Идел» газетасы 1914 елның 27 гыйнварында чыгудан туктый.

[3] *Мәсьүлиятле* – җаваплы.

[4] *Хәмел иттеләр* – юрадылар.

[5] ...*«Аң»нан китмәдем* – Г. Ибраһимов Казаннан китсә дә, «Аң» журналы нашире һәм мөхәррире, «Гасыр» көтепханәсе хуҗасы Ә. Хәсәни белән бәйләнешен өзми, мәкаләләрен, әсәрләрен җибәреп тора. Ул шулай ук башка көндәлек матбугатлар белән дә элемтәдә тора.

[6] *Фасыйк* – азгын, бозык.

[7] ...*мәгънәсез интригалар* – Г. Ибраһимов «Вакыт» газетасының 1911 елгы 1 октябрь санында «Габди» имзасы белән «Казан китапчылары» дигән мәкалә бастыра. Моңа каршы Ш. Әхмәров «Йолдыз» газетасының шул елгы 29 ноябрь санында «Сөйләү ансат, эшләү читен» дигән мәкалә белән чыга. Ул Габдине шәкерт дип атап, Л. Толстой әсәрләрен урлап язуда гаепли. Плагиатлыкта гаепләгәннәре өчен Шиһабетдин Әхмәровны, Әхмәт Урманчиевны, Гыйльметдин Шәрәфне (1885–1942) третийский суд хөкеменә дәгъва итә. Суд 1912 елның 11 февралендә юрист Ибнеәмин Әхтәмов (1877–1941) рәислегендә, хакимнәр Фуат Туктаров, Ф. Әмирхан, Ф. Агиев, Тимерша Соловьев (1875–1947) булып, Ф. Әмирхан өен-

беткән «хадиме милләт»ләре[1] белән мине гаҗәп туйдырды. Теге елны, гаҗиз булгач, Киевкә киткән идем. Бер ел үтте, Казанның биргән начар тәэсире йөрәктән чыкты — Гәрәйнең[2] «Аң»га чакыруын кабул итә бирдем. Ләкин Казан һаман шул Казан, яшел хадимнәр һаман шул иде. «Аң»ны ташлауны мин кызгандым, ләкин Казанда торуның имкяне[3] калмагач һәм кеше чишәлмәс төсле күренгән хисне өздем дә — вәссәлам.

Мин хәзер һәйбәт йирдә яшим. Килешли Киевтә өч атна булдым[4]. Одесса аша дүрт көн диңгез. Сухум да зарарсыз гына шәһәр. Тетарга бай түгел, көтепханәләре ярлы — бу ягы бераз мөшкел, ләкин аның урынына табигате бик бай. Шәһәр диңгез буенда. Нәкъ ярда әйбәт бульвар бакчасы бар. Шәһәрнең бер кырые тауга терәлә — җәнүб чәчәкләре илә тулган зур бакчалар бар. Гомумән, монда шәһәр икәне аз хис кылына: урамнар киң, йортлар карсак, сирәк, урамнар, өй буйлары агачлар белән тулы, бер як диңгез, бер як тау. Менә бу шәһәрлекне, шәһәрнең йөрәкне баса торган явыз сыйфатын бетерә. Миңа һәм шул ягы охшады да. Мөмкин булса, бераздан тирә-якка йөреп килергә дә дәртем бар. Моннан бер утыз чакрымда, диңгез буенда Яңа Афон[5] дигән монастырь бар. Гаҗәп мактыйлар. Шуны күрергә өмидем. Гомумән, монда килүдән шатмын. Күңел күтәрелә, рух тула. Җәй көне үтә эсселәр хәлдән екмаса, көзгәчә торырга исәбем бар.

Эшләргә кәефем тә табыла, вакыт та күп. Тик бераз кыйммәт, ләкин нишлисең, шуңа күрә Кавказ бит! Сиңа язмадым

---

дә үткәрелә. Нәтиҗәдә Г. Ибраһимов аклана. Бу вакыйга хакында тулырак кара: Ибраһимов Г. Казан китапчыларының рәддиясе / Г. Ибраһимов // Йолдыз.– 1911.– 4 дек.; Әхмәров Ш. Габди әфәндегә / Ш. Әхмәров // Йолдыз.– 1911.– 8 дек.; Габди. Дәгъвәт // Йолдыз.– 1911.– 15 дек.; Әхмәров Ш., Урманчиев Ә. Идарәгә мәктүп / Ш. Әхмәров, Ә. Урманчиев // Йолдыз.– 1911.– 19 дек.; Хөкем хөкеме Йолдыз.– 1912.– 26 февр.

[1] *«Хадиме милләт»* – «милләт хадиме» – биредә милләтне сүздә генә кайгыртып йөрүчеләргә кинаяле ишарә.

[2] *Гәрәйнең* – сүз «Аң» журналының нашире һәм мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәни хакында бара.

[3] *Имкяне* – мөмкинлеге.

[4] *Килешли Киевтә өч атна булдым* – Г. Ибраһимов Казаннан 1914 елның 13 февралендә китә һәм Киевкә 15 февральдә килеп җитә. Киевтән 11 мартта Одессага китә.

[5] *Яңа Афон* – Афон тавы итәгендә 1875 елда салынган зур монастырь һәм кальга.

бугай, мин бит «Безнең көннәр» язам[1]. Бу «Хәят дулкыннары» атлы трилогиянең беренче җөзьэ була. Хәзердә чамаларда өч йөз биттән артмас кебек. Ахырга таба арта торган да булса, ничек булыр. Моны Гәрәйләргә бирәм. Килештек. Мин май ахырларына матбагага бирергә булыр дигән нияттәмен. Шул вакытка тәмам кулымнан йибәрергә тырышам.

Синең теләкләргә рәхмәт, иптәш. Башта хыял, йөрәктә хис бар – эшләргә форсатлар, настроениеләр булсын. Ләкин, газиз, алкоголизм белән күп нәрсәне әрәм итә яздым. Казаннан киткәнле бирле эчкәнем юк. Үземне яхшы хис кылам. Гомеремдә берничә мәртәбә ташладым. Зыянда башка һичнәрсә белән тутырылмаган бушлыклар сизелә дә тагы эчәргә тотынасың. Мин бу кебек, эчкече халык иде. Мин быел Казанда ваклап түгел, тәүлекләп эчкәләдем. Шундый компанияләр туры килде. Сиңа язмадыммы, анда минем Зоя дигән бер һәйбәт кенә яшь хатын белән бераз роман булды. Шуның ире студент һәм иптәшләре компаниясе һәрбер рус яшьләре кебек эчкече халык иде. Шуларда тәүлекләп яткан хәлләр булды, табигый, болар бик изделәр. Менә монда гына бераз хәл алып киләм.

«Татар шагыйрьләре» китабының күп тәнкыйтькә очравы[2] шулай син дигәнчә. Ләкин, иптәш, шуны онытма, китапның төрле яктан, яманнан да булсын, каралуы зарарлы эш түгел. Аннан соң татарның зәүкы белән бу туры да килешеп бетүне мин үземә бервакытта да шарт итмим. Тукай хакында «Йолдыз»ның

---

[1] *«Безнең көннәр» язам* – өч кисәктән торырга тиешле бу романның беренче кисәген Г. Ибраһимов 1914 елның июнь урталарында тәмамлаган, әсәрне бастыру өчен «Гасыр» нәшриятына биргән. Әмма сиксән бите типографиядә җыелып, ике табагы басылгач, цензура нәшер итүне туктата. «Ирек» газетасы үзенең 1917 елгы 18 август санында тиздән бу әсәрнең бастырыла башланачагы хакында белдерү урнаштыра. Ләкин ул 1919 елда гына дөнья күрә: Ибраһимов Г. Безнең көннәр: Роман / Г. Ибраһимов.– Казань: Лито-тип. т-ва «Умид», 1919.– 442 б.

[2] *«Татар шагыйрьләре» китабының күп тәнкыйтькә очравы* – бу китап 1913 елда нәшер ителгән: Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре. Беренче бүлем. Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Габдулла Тукаев / Г. Ибраһимов.– Оренбургта «Вакыт» матбагасы, 1913.– 103 б. Икенче кисәге исә дөнья күрмәгән. Китапта «Тукай – шагыйрьме?» дип куелган сорау киң җәмәгатьчелектә зур ризасызлык, шау-шу чыгаруга сәбәп була. Шуңа күрә Г. Ибраһимов исеменә гаепләүләр ташлаган мәкаләләр көндәлек матбугатта еллар дәвамында басылып килә. Кара: Җәләй. Әдәби мосахәбәләр. «Татар шагыйрьләре» / Җәләй // Йолдыз.– 1913.– 24 июль; Уйгур. Яңа әсәрләр. «Татар шагыйрьләре» / Уйгур // Йолдыз.– 1913.– 4 авг.; Вәлиди Ә. Шәрекъка гаид яңа әсәрләр / Ә. Вәлиди // Шура.– 1915.– № 6.– Б. 175.

икенче апрелендә тагын бер мәкаләм булды[1]. Күрдеңме? Ни дисең?

«Идел көлә»не мин бераз төзәттем[2]. Тиз кирәчәк материал эченә төреп калдырдым. «Китапчы» хакындагы тәнкыйтең кермәстер. Әмма теге, исеме хәтеремнән чыкты, яшь тормыш хакындагысы тиздән керәчәк иде. Мин киткәч, бутап, югалтып бетермәсәләр ярар иде! Мин бик ашыгыч киттем, күп рәтләп булмады.

Үз хакында бер дә язмагансың. Сине былтыр ул өйләнә, диләр иде, юкмы әле?[3] Гыйшык-мыйшыклар барамы?

«Яшь йөрәкләр»дән[4] соң байтак гыйбрәтләр булды, хәзерге романым «Безнең көннәр»дә байтак яңа кешеләр чыгар кебек. Арада үзеңне күрсәң, гаҗәпләнмә![5] Ләкин шул бар, иптәш, татар тормышы, бигрәк тә яшьләр галәме тар, тәмам эшләнеп, булып җиткән характерлар юк диярлек аз.

Син «Феня»не[6] һаман язмыйсың. Иптәш, никтер мин синең сәламәтлегеңне урта кебек күрәм. Быел Шәһит бик куркытып сөйләгән иде, ахры, шуннан калгандыр. Ләкин, иптәш, вак-төяк самолюбиене ташлап, җәй бер тыныч йиргә китеп эшләми-нитми, хәтта укымый-язмый, бүре кебек тазарырга иде. Мин кайчан гына уйласам да, сине көл кебек ап-ак йөзле хәтерлим дә күңелгә начар уйлар төшә. Мин сиңа «Феня»не язу белән башлаган идем

[1] *Тукай хакында «Йолдыз»ның икенче апрелендә тагын бер мәкаләм булды* – Ибраһимов Г. Талант трагедиясе / Г. Ибраһимов // Йолдыз. – 1914. – 2 апр.

[2] *«Идел көлә»не мин бераз төзәттем* – Х. Кәримнең бу әсәре «Аң» журналында бастырылмаган.

[3] *Сине былтыр ул өйләнә, диләр иде, юкмы әле?* – Зәйнәп Кәримова истәлекләреннән күренгәнчә, Хөсни Кәрим белән аларның туйлары Уфада 1916 елның май аенда Сәгыйть Рәмиев өендә була. Анда Г. Ибраһимов та катнаша һәм Х. Кәримнең атасы вазифасын үти: Кәримова З. Ул безнең якын дустыбыз иде / З. Кәримова // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төзүчесе Рөстәм Акъегет. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Б. 176.

[4] *«Яшь йөрәкләр»* – Ибраһимов Г. Яшь йөрәкләр. Нашире: Әхмәд әл-Исхакый «Шәрык» көтепханәсе / Г. Ибраһимов. – Казань: Электро-тип. «Умид», 1912. – 416 б.

[5] *Арада үзеңне күрсәң, гаҗәпләнмә!* – «Хатта сүз «Безнең көннәр» романындагы нечкә күңелле Сәхип образы турында бара, аның бирелешендә Х. Кәримнең балачагы, яшьлек елларына бәйле вакыйгалар ачык төсмерләнә. «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре арасында аның көйләрне бик тиз отып алу сәләте, татар-башкорт җырларын оста башкаруы да билгеле»: Сабиров С. Кызыл чәчәкләрнең берсе (Хөсни Кәримнең тууына 100 ел) / С. Сабиров // Соц. Татарстан. – 1987. – 15 дек.

[6] *«Феня»* – Х. Кәримнең язылмый калган хикәясенең исеме.

дә сүзем икенчегә борылды, вакыйган, язудан, укудан кан мөһимрәк бит. Чын дустлыкка хәмел кыл[1] – мин синең хәят хакында никтер кайбер вакыт авыр уйлыйм, ягъни тән сәламәтлеге хакында. Чөнки шундый кыен үткәрелгән шәкертлек, аннан соң учительлеккә хәзерләнү – әллә болар бары да хата – син үгез кебек таза, синең битләрең кып-кызылмы? Альбомнан рәсемеңне алып карадым. Син анда ябыксың.

Хәтеремдә юк, сиңа мокабилән[2] рәсм йибәрдемме, юкмы – менә хат эченә рәсем салам. Бу – минем гомеремдә ару чыккан нәрсәм. Ләкин мине алай дип уйлама. Бу – былтыр, Киев зинданыннан чыгып, төрле йирдә ханымнардан чәчәкләр, букетлар алгач, Ак Идел буенда пароходта кайтып, Уфада иң матур берничә шат көннәр уздырган чакта, ягъни гомеремнең иң надир мәсгуд[3] вакытында, шуңа күрә биш-алты яшь яшәргән чагымда, Уфада алынган иде. Кешеләр аны мин түгелдер, диләр. Чөнки хәзер яңаклар эчкә суырылды, күзләр бераз төпкә баттылар. Җан, йөрәк яшь, гаюр, ләкин тән картая, иптәш!

Иптәш, бик озын хат яз. Ниләр уйлыйсың, ниләр бетерәсең? Барын да тәфсыйл ит. Барыннан да бигрәк тазар! Тамырларда кан тулып кайнап аксын – шунсыз бер эш тә чыкмый ахры. Анда иптәшләр булса, мине сорасалар, фатиха вә сәлам диген.

Кулларыңны кысам: Галимҗан.
1914, апрель 12, Сухум.

---

[1] *Хәмел кыл* – юра.
[2] *Мокабилән* – каршы.
[3] *Надир мәсгуд* – сирәк бәхетле.

## Г. Ибраһимовның Сухумнан Хөсни Кәримгә язган хаты[1]

13 май 1914 ел, Сухум.

Хөсни иптәш,

хатыңны берничә көн элек алган идем, җавабым бу көнгә кадәр кичекте. Син май ахырына кадәр Әстерханда булам дигәнсең[2], барып сиңа ирешә әле.

Сине күрмәгәнгә берничә ел булды. Син башта «Мәдрәсәи Галия»гә килгәндә[3] нык кына, таза гына булсаң да, «Галия», бигрәк тә учительлеккә хәзерләнү сине ябыктырды[4]. Мин ахыр күргәндә, син, минемчә, безнең кебек ябык, арыган, ватылган, истирахәткә[5] мохтаҗ идең. Аннан соң тагы күп ватылдың. Шәһит сине үткән ел бик авыр[у] дип тә сөйләде, инде быел тагы, айлык алтмыш-йитмешне табу өчен, 11—12 сәгать эшләргә мәҗбүр булгач, син тагы арыйсың, ватыласың. Шуңа күрә авылга китү дәртең бик-бик муафыйк[6]. Ләкин авылның авылы бар. Халык бик каршы булмаса, бала артык күп җыелмаса, шул вакытта гына сиңа хәл җыярга мөмкин булыр. Һәрхәлдә, Әстерхандагыдан авыл муафыйк чыгар. Без синең белән яшерешүне ташладык, арадагы рия[7] бетте — мин дә уйлаганымны ачык әйтим: син, иптәш, учительлек юлында күп тырыштың, күп эшләп, ач яшәдең, бу сине җисмани ватты. Ләкин сине арыткан нәрсә бу гына түгел,

---

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (120006–6). Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер хаталар белән бастырылган (Казан, 2000, б. 84–87). Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Син май ахырына кадәр Әстерханда булам дигәнсең* – Х. Кәрим Әстерханнан 1914 елның җәендә китә. Туган ягына кайтып, Бөре өязе Байкыбаш авылы (хәзерге Башкортстан Республикасы Караидел районында) мәдрәсәсендә мөгаллим булып эшли башлый.

[3] *Син башта «Мәдрәсәи Галия»гә килгәндә* – Х. Кәрим «Галия» мәдрәсәсенә укырга 1906 елның көзендә килә, 1912 елда аны тәмамлый.

[4] *… бигрәк тә учительлеккә хәзерләнү сине ябыктырды* – Х. Кәрим «Галия» мәдрәсәсен тәмамлагач, Царицын реаль училищесында укытучылыкка (учительлеккә) имтихан тапшыра, аннары Әстерханда рус-татар мәктәбендә укытучы булып эшли.

[5] *Истирахәткә* – ял итүгә.

[6] *Муафыйк* – урынлы.

[7] *Рия* – икейөзлелек.

синдә зур самолюбие бар. Син һичбер йирдә гади, илтифатка алынмаган бер адәм булып калырга риза түгелсең, шуңа күрә һәр йирдә һәркайчан син үзеңнең инструментың кылларын актык дәрәҗәгә кадәрле көчләп тартасың, ягъни син һәр йирдә тән белән генә түгел, тел белән, баш белән, нерв белән, гакыл белән – хасил[1], җан вә тән белән гелән-гелән артык үзеңне көчлисең, һәрвакыт напряжениедә, һәрвакыт кирәгеннән артык көч сарыф итүдәсең (мин боларны әүвәлге хәлеңә карап әйтәм). Менә шулар сине тән ягыннан ару өстенә, җан белән дә, нерв, гакыл вә йөрәк белән дә арыткан. Сиңа, чын мәгънәсендә җан һәм тән илә свежий шат егет булу өчен, бераз заманнар үзеңне һичбер турыда көчләмичә, мотлак, табигый хәлдә простата, покой һәм свободно яшәргә кирәк. Шундый хәят булсын ки, өең җылы, тамагың тук, эшең артык ватмый, башың тыныч, халык алдында могътәбәр булыйм, шәп күреним дип тә үзеңне ватмыйсың, бераз гына шулай «наплевать на все» дигәндәй тәмама-тәмам истирахәткә биреләсең. Авыл йирендә учитель булсаң, урыныңнан кудыртмас кадәр генә тырышып, ягъни күп укыту илә ватылмасаң, башка турыда да үзеңне бер дә көчләмәсәң, тәкәллефләнмәсәң[2], шөбһәсез, сиңа теге «Галия»гә килгән елың, ачык, шат хәят, дәртле фәлән-фәлән Хөсни кайтыр иде.

Мин үзем табган[3] зәгыйфьмен. Мантыйк[4], ачлык, аракы мине тагы ваттылар. Сиңа язган нәрсәләр миндә дә бар. Мин менә Кавказга килгәч, дөньяда чын истирахәтне татыдым. Аерым бүлмә, зур, һавалы, якты. Аерым ход. Теләсәң көн буе идәндә ятып, ыштансыз ауна. Бай түгелмен, ләкин мәгълүм микъдар килә[5]. Түшәккә карап аяк сузам, ватылмыйм, үземне һичбер турыда көчләмим. Байтак эшлим. Ләкин үземне истирахәт хис итәм. Тәнемнән бигрәк, җаным, нерваларым хәл җыя. Хәзер мин шундый халәттәмен ки, гүя күп еллар дәвам итеп, бөтен организмны актык дәрәҗәдә бетергән бер авырудан акрын-акрын терелеп киләм кеби.

---

[1] *Хасил* – кыскасы.

[2] *Тәкәллефләнмәү* – ясалма кыланмау.

[3] *Табган* – табигый.

[4] *Мантыйк* – биредә схоластика.мәгънәсендә

[5] *…мәгълүм микъдар килә* – язган мәкаләләре өчен һәм «Гасыр» матбагасында бастырган әсәрләре өчен Ә. Хәсәни каләм хакы түләп тора. Сүз шул гонорарлар хакында бара.

Бу миңа файдасыз булмас. Күзгә кадәр торсам, тәэсире күрелер. Тагы хис итәм ки, күзгә генә аз. Миңа ел да шулай кирәк иде. Ләкин монда гел торып булмый, кайтыла, тагы ватыласың. Синең кәсебең башка. Учитель булдың. Авылга бер-ике гәзит алдырдың, сирәк-сирәк иптәшләр белән хат языштың – рәхәт, мандолинны сыздырдың да истирахәт кыл; янында бер кара каш та булса, артык ни кирәк. Кара каш дигәннән, өстеңә авыр йөк булыр булмаса, өйләнгәндә зарар юк, хосусан, авылда матур, яшь хатының булса, артык һичнәрсә кирәге калмый. Эчүдән туктадым, дисең, тәбрик итәм, Казаннан чыкканнан бирле мин дә эчмим. Тагы ни булыр алда.

Син, һәрхәлдә, шәрик[1], һич булмаса, бөтен бер ел шундый полный истирахәт, полный простота, полный свободный, көчләнми, көчәнми, тәкәллефләнми хәят кара. Бу арада язуны да ташлау ярый. Мин ышанам, табигать сиңа бернәрсә биргән. Гомерең, вафа итсәң[2], син әдәбият галәменә бер әйбер, бик табигый вә мөмтаз[3] бер әйбер бирергә тиешлесең, мин моны хис кылам, ләкин хәзерге ватылган хәлдә улса, чыкмый, җан-тән хәл алсын, куәт үзе бәреп чыгар. Бу хакта синең үзеңә дә сөйли идем. «Яшь куәтләр»[4] исеме илә язып та, бастырмаган бер тәнкыйди нәрсәмдә дә мин моны яздым. Ләкин хәзер син язмыйсың һәм үзеңне беразга ватма, шуңа күрә мин ул нәрсәмне чыгармыйм әле. Тагы әйтәм: җан-тән, нерв вә калеб[5] хәл алсын – куәт үзе бәреп чыгар. Ул куәт нинди булыр, син даими язучы булып, күп язып китерәсеңме, әллә табигатьнең сиңа куйганы – тик бернәрсә бирерлекме, мин аны белә алмыйм. Ләкин шул бернәрсә бирүеңә, шул бернәрсәнең әдәбиятта лязем бер мөһим әсәр булып калуына мин никтер катгыян[6] ышанам. Еллар буена язмасаң да, бу ышануым кимеми.

---

[1] *Шәрик* – сабакташ.

[2] Вафа итсәң – багышласаң.

[3] *Мөмтаз* – башкалардан аерылып тора торган.

[4] *«Яшь куәтләр»* – 1912 елда язылып, Г. Ибраһимов аны «Шура» журналына җибәрсә дә, үз вакытында дөньяга чыкмаган. Язучы 1913 елның 17 апрелендә Киевтә кулга алынгач, тентү вакытында әлеге мәкалә дә табыла. Казан жандарм идарәсенә җибәреп тикшерткәннән соң, ул сәяси яктан куркынычсыз һәм зарарсыз дип табыла. Мәкалә «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр» исеме белән «Йолдыз» газетасының 1915 елгы 6 февраль, 29 апрель саннарында бастырыла.

[5] *Калеб* – күңел.

[6] *Катгыян* – нык.

Син, авылга барып батып калырмын, дип уйлама. Мине кунакка чакырырсың, безгә үзең килерсең, мөнәсәбәт өзелмәс, бер тазаргач, шәһәргә урнашырга мотлак-мотлак мөмкин улыр. Мин моны өмит итәм.

Яшь көннең матур сәгатьләре бергә кичкән. Ахрысы, шуларны онытырга адәмнең тәкате йитмидер. Мин Казанда, фәләндә әллә кемнәр белән, үзләре янында вакыт, гаҗәп дуст мөгамәләдә булдым, ләкин киттең, аерылдың – бетә, онытыла, әһәмиятләре югала. Ахрысы, яшьлек иптәшләре генә йөрәктә мәңге калалардыр. Безгә, насыйп булса, гомернең алдагы көннәрендә бергә булырга күп тугры килер дип уйлыйм.

Шакир[1] белән хатлашмыйсызмы? Ул өйләнде. Карамалыдан[2] бер ару гына кыз алган. Июньдә төшерә бугай. Мине чакыра. Ләкин кайта алмам, ахры. Кавказ аяк асты түгел, ел саен килеп булмый. Бер килгәч торасы иде ич. Ул да гомергә бер килгән нәрсә. Кайту кирәк иде, ләкин әле сүз бирмәдем.

Син, диңгез күрергә дисең. Чынын әйткәндә, үзеңне ватма, акчаңны әрәм итмәү кирәк иде. Әгәр бик телисең икән, анда хәер инде.

Сухумга килеп чыксаң, кызык булыр иде. Бунда ике юл бар: 1) Каспий, Баку. Аннан поезд белән Тифлис аша Батумга, Батумнан пароход белән сухумга. 2) Петровскийдан, Яңа Царицыннан Новороссийскийга поезд, аннан Сухумга пароход.

Боларга күпме расход дип тәгаен әйтә алмыйм. Ләкин бик кысканда да бару-кайту илледән ким булу ихтималы юк. Хат яз әле. Фатыйх Сәйфине анда күрәсеңме? Тагы ниләр бар?

Кулыңны кысып: Галимҗан.

Сухум, 1914, май 13.

---

[1] *Шакир* – бу кешенең шәхесе турында әлегә дәлилле мәгълүматыбыз юк.

[2] *Карамалы* – хәзерге Башкортстан Республикасының Авыргазы районы Яңа Кәлчир җирле үзидарәсенә караган Олы Карамалы авылы булса кирәк.

## 1915
## Г. Ибраһимовның Солтанморат авылыннан Әхмәтгәрәй Хәсәнигә язган хаты[1]

6 март 1915 ел

Гәрәй иптәш, сиңа Уфадан бер ачык хат язган идем, алдыңмы, юкмы, белмим. Берничә нәрсә бар, менә тагын язам. Февраль чыкты. «Альбомны» һаман күреп булмый әле[2]. Шуны, иптәш, тизрәк күрергә иде. Чыгу белән миңа бик әгълаләреннән[3] өч нөсхә (авылга) җибәрергә куш.

Мин Уфада булдым. Анда, Карс мөселманнары файдасына театр куячак булып, үзара киңәш мәҗлесе ясадылар. Шунда мине дә чакырдылар. Мәсьәлә нинди әсәр уйнау турында килгәч, мин Казанга телеграм биреп, «Тигезсезләр»не[4] сорату фикерен гарыз иткән идем. Мәсьәләне әсасән кабул итсәләр дә, унынчан кичектерми кую лязем булганга, «Тигезсезләр»не өлгертеп булмас, диелде. Шуның белән бәрабәр, артист вә любительләр миннән, шул әсәр тиз басылып чыкмаса, кулъязмасын җибәртә алырмы дип, мөхәррирдән яки наширдән сорарга үтенделәр. Син, Гәрәй, шул хакта миңа бер хәбәр язсаң иде. Монда аны озаклатмый куярга уйлыйлар, ягъни мәсьәлә бер кузгалгач, унынчы марттан соң булачак театрга шуны өлгертергә исәплиләр.

Мин тиздән (ягъни бер ун көннән) Уфага китәм. Шуңарчы бер хәбәр кирәк.

«Хикәяләр» басыла башладымы?[5] Тизләвеңне үтенәм. «Тигезсезләр» чыкса, җибәртә күр, мин ул хакта һәйбәтләп, киңләп язарга ният итәмен. Сиңа, бу хатка кушып, бер кәгазь җибәрдем.

[1] Төп нөсхә Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана (119759–18). Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1962 елгы 3 нче санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 89–90). Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *«Альбомны» һаман күреп булмый әле* – Альбом (Санаигы нәфисә мәҗмугасы). Санаигы нәфисә сөючеләргә. «Аң» нәшере.– Казань: Тип. И. Н. Харитонова, 1915.– 32 б. Аны Г. Ибраһимов үзе төзегән.

[3] *Әгълаларенннән* – яхшыларыннан.

[4] *«Тигезсезләр»* – Әмирхан Ф. Тигезсезләр (Яңа кешеләр). Өч пәрдәдә пьеса. Наширләре: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе. Казан.– Казань: Электро-тип. «Мариф», 1915.– 72 б.

[5] *«Хикәяләр» басыла башладымы?* – «Гасыр» нәшриятына бастырырга бирелеп тә, чыкмый калган.

Анда «Хикәяләр»нең тышкы, алгы битләре хакында сүз бар. Шуңа дикъкать итеп, үзем язганча куйдырырга оныта күрмә.

Хәзергә башка юк. Минем агай больницада ята[1]. Аның аягын ярдылар. Аның иптәшләре сугышка китте, бу авыру сәбәпле калды. Котылуына бик нык өмет бар. Хода ни бирер. Мин, аның мәсьәләсе бер яклы булганчы, Уфадан китә алмам. Буңа, шаять, бер унбиш көн, ихтимал, өч атна вакыт кирәк булыр. Шунсыз Казанга юл алу мөмкин түгел.

«Аң»ны күрдем. Җәләйнең[2] мәкаләсенә «Әдәби хәрәкәт»[3] исеме биргәнсең икән. «Язгы чәчәкләр» дигәннән бусы мәгънәлерәк булыр. Хәнәфинең «Истәлеге»[4] матур чыккан дияргә ярый, тик бик аз гына төчерәк. Дәхи «Истәлек» сүзе, яңа булу өстенә, ярап бетәрме икән, ул әдәбиятка кереп китәрме икән дигән шөбһә дә бар. Һәрнә, хәерле булсын. Сәгыйть Рәмиев «Аң»га үзенең «Яңа шигырь һәм әүвәлгеләр»[5] дигән яңа басылган шигырь мәҗмугасын җибәрәм диде. Син аны яратасың бугай. Шул хакта «Аң»да берәр нәрсә язылса, яки һичбулмаса, аның мәҗмугасыннан берәр кыйтга кертелсә, күңелле булыр иде[6].

Син, мәкаләләреңә бераз перерыв бирәм, дигәнгә, «Аң»га язу җибәрмәдем әле. Авылда берничә көнем-атнам бар. Шул арада бернәрсә оештырсам кирәк. «Тормыш»ка «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән бернәрсә бирдем – ике

---

[1] *Минем агай больницада ята* – сүз Г. Ибраһимовның агасы Шакирҗан хакында бара. Аның Беренче Бөтендөнья сугышында катнашканлыгы мәгълүм, күрәсең, больницада терелеп чыккач алынган.

[2] *Җәләй* – сүз Җамал Вәлиди хакында бара.

[3] *«Әдәби хәрәкәт»* – кара: Вәлидов Җ. Әдәби хәрәкәт (Тәнкыйть) / Җ. Вәлидов // Аң.– 1913.– № 3; – Б. 59–63; – № 4.– Б. 83–85; – № 6.– Б. 122–126; – № 7.– Б. 145–148.

[4] *Хәнәфинең «Истәлеге»* – сүз Х. Кайбышевның «Аң» журналының 1915 елгы 3 нче санында (б. 63–65) «М. Хәнәфи» имзасы белән бастырган «Вакытсыз сүнгән «Яшьлек» (Яшь мөхәррирләремездән Сәетгәрәй Еникеев хакында истәлек)» дигән некрологы хакында бара. Анда өметле бу шагыйрьнең (1893 елда туган) иртә вафат булуына кайгы белдерелә.

[5] *«Яңа шигырь һәм әүвәлгеләр»* – Сәгыйть Рәмиевнең яңа шигырьләре һәм әүвәлгеләре.– Уфа: «Шәрык» матбагасы борадәран Кәримовларның, 1915.– 36 б.

[6] *Шул хакта «Аң»да берәр нәрсә язылса, яки һичбулмаса, аның мәҗмугасыннан берәр кыйтга кертелсә, күңелле булыр иде* – С. Рәмиевнең ул мәҗмугасы хакында «Аң» журналында бернинди дә мәгълүмат һәм аннан шигырьләр дә бастырылмаган. Басманың 1916 елгы саннарында шагыйрьнең шундый әсәрләре дөнья күргән: № 2 «Ул йоклый» (б. 22), № 5 «Киң иман» (б. 78), № 9 «Ул торды» (б. 146), № 22 «Дога» (б. 343).

фельетон[1]. «Аң»дагы Әминә мәкаләсе дә шунда хәтергә алынды[2], шаять, күргәнсеңдер.

Авылга бер хат язар идең. Казанда нинди яңа гайбәтләр бар?

Казанда чакта аннан китәсе килә. Китсәң, сагына башлыйсың. Ялкауланмый бер хат яз әле. «Гасыр» вә «Аң» әһеленә, гомумән, сәлам.

Мәсьәләнең иң мөһим ягы кала язган икән: син, иптәш, март кырыгын, бу хатны алгач, кичектерми җибәрергә әйтә күр![3] Бу хатым дүрт көн бара, перевод дүрт көн килә. Шул исәптән мин мартның унбишенә синнән акча килгәндер дип, атым җигеп, кесәмә паспортымны салып, пучтага – унбиш чакрым авылга үзем барачакмын.

Дога вә сәлам!

Аллага тапшырып: Галимҗан – Солтанморат, 1915 – март 6.

---

[1] *«Тормыш»ка «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән бернәрсә бирдем – ике фельетон* – кара: Г. Ибраһимов. «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән / Г. Ибраһимов // «Тормыш».– 1915.– 26, 27 авг.

[2] *«Аң»дагы Әминә мәкаләсе дә шунда хәтергә алынды* – сүз «Аң» журналының 1914 елгы 23 нче санында (б. 417–420) Әминә Мөхетдиния (1893–1944) тарафыннан бастырылган «Кем ул мөгаллимә Фатыйма? («Мөгаллимә» пьесасындагы мөгаллимә тибын тәнкыйть)» дигән мәкалә хакында бара. Ә. Мөхетдиния: «Драмада тереклеккә якын булу мөһим мәсьәләләрдән саналмыйча, бәлки драмадан күңел, йөрәк хәятына якын булу көтелә», – ди. Г. Ибраһимов үзенең мәкаләсендә әйтелгән фикергә каршы төшеп, драманы кискен тәнкыйтьләп чыга, драма авторын реализмнан читкә тайпылуда гаепли. Дөрес, аның карашларын кире кагып язылган язма да дөнья күрә: Бикташев А. Тәнкыйть тирәсендә / А. Бикташев // Кояш.– 1915.– 13, 14 авг.

[3] *…март кырыгын, бу хатны алгач, кичектерми җибәрергә әйтә күр!* – сүз Г. Ибраһимовның журналда басылган материаллары өчен март аенда алырга тиешле 40 сум гонорар хакында бара булса кирәк.

## Г. Ибраһимовның Уфадан Әхмәтгәрәй Хәсәнигә язган хаты[1]

16 декабрь [1915] ел

Гәрәй иптәш,

Йибәргән китапларыңны алдым. Ләкин «Аң» һаман килми. Син бу хатны алгач та, миңа бу елгы «Аң»нарны беренче номерыннан ук башлап йибәрергә куша күр әле. Әдәбият дәресләрендә кирәкләре булгалый[2].

Дәхи түбәндәге әсәрләрне йибәрсеннәр иде:

1) Альманах[3], альбом[4],

2) Шәриф Камалның[5] хикәяләр төркеме[6],

3) Галимҗан Ибраһимовның моңарчы чыккан барлык әсәрләре[7],

4) Галиәсгар Камалның[8] «Дәҗҗал»ы[9],

5) «Мөстәфад әл-әхбар»ның беренче җилде[10],

---

[1] Төп нөсхә Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә «Казан утлары» журналының 1966 елгы 12 нче санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 90–93) бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Б*илгеле булганча, Г. Ибраһимов 1915 елның 28 октябреннән алып «Галия» мәдрәсәсендә татар теле һәм әдәбияты дәресләре укыта башлый.

[3] Альманах (Хикәя вә шигырьләр мәҗмугасы). «Аң» нәшере Казан. Казанда «Мәгариф» матбагасы.– Казань: Электро-тип. «Маариф», 1915.– 120 б.

[4] Альбом (Санаигы нәфисә мәҗмугасы). Санаигы нәфисә сөючеләргә. «Аң» нәшере.– Казань: Тип. И. Н. Харитонова, 1915.– 32 б.

[5] *Шәриф Камал* – Шәриф Камалетдин улы Камал (Байгилдиев) (1884–1942), язучы, җәмәгать эшлеклесе.

[6] Камал Ш. Хикәяләр төркеме. Беренче төп. Вак хикәя вә тасвирлардан гыйбарәттер / Ш. Камал.– Оренбургта «Вакыт» матбагасы, 1914.– 195+II б.

[7] Г. Ибраһимовның 1916 елга кадәр нәшер ителгән әсәрләрен библиографиядән кара.

[8] *Галиәсгар Камал* – Галиәсгар Камал (Галиәсгар Галиәкбар улы Камалетдинов) (1879–1933), драматург, театр һәм җәмәгать эшлеклесе, татар драматургиясенә һәм театрына нигез салучыларның берсе.

[9] Камал Г. Дәҗҗал. Драма 4 пәрдәдә, 5 картинада. Нашире: Сабах көтепханәсе / Г. Камал. Наширләре: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе Казан.– Казань: Электро-тип. «Умид», 1912.– 59 б.

[10] Әл-кыйсме әл-әүвәл мин Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Басма улынмыштыр Казанда Домбровскийның табыгханәсендә Мөхәммәтҗан бине Минһаҗетдин beширкәт әхъяи Шәрифҗан әл-Кәриминең хәраҗәте илән 1897 нче

6) Риза казыйның «Әсма» белән «Сәлимә»се[1],

7) Акъегетзадә Мусаның[2] «Хисаметдин менла»сы[3],

8) Заһир Бигиевнең «Мәварә эн-нәһердә сәяхәт»е[4],

9) Укмасыйның «Алданма кызыл алмага»сы[5] һәм халык җырлары вә көйләре хакындагы беренче бәйләм китаплары,

10) Газиз Гобәйдуллинның «Олуг кешеләр һәм аларның әсәрләре»[6],

11) Хәсәнгата казыйнның «Төрек тарихы»[7],

12) Һади Атласиның[8] «Казан ханлыгы»[9], «Сибирия тарихы»[10], «Сөембикә»[11] дигән өч китабы,

---

елда. – 264 б.

[1] *Риза казыйның «Әсма» вә «Сәлимә»се* – Гафил бине Габдулла. Әсма яки Гамәл вә җәза. Оренбург: М. Г. Кәримов матбагасы, 1903. – 130 б.; Сәлимә, яки Гыйффәт. – Казан: Б. Л. Домбровский басмаханәсе, 1899. – 80 б.

[2] *Акъегетзадә Муса* – Муса Мөхәммәтҗан угылы Акъегетзадә (1864–1923), мәгърифәтче язучы.

[3] Хисаметдин менла. Милли роман яки хикәя. Әсәре Муса Акҗегет. Бу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмыштыр 1886 нчы елда. – 70 б.

[4] Бигиев М. – З. Мавәраэннәһердә сәяхәт (Трансоксанияйә сәфәр) / М. – З. Бигиев. – Казань: Типо-лит. И. В. Ермолаевой, 1908. – 108 б.

[5] Алданма кызыл алмага. Әсәр – Миргазиз әл-Укмасый. Нашире: Мөхәммәтҗан Сәйдәшев. – Матбагаи Кәримия Казанда, 1907 сәнә. – 18 б.

[6] Олуг кешеләр һәм аларның әсәрләре. 1 нче китап. 1. Гаяз әфәнде. «Ике йөз елдан соң инкыйраз». Г. Газиз. 2. Йосыф Акчура. «Мөкауфият хатирәләре». Н. Хәлфин. – Казанда әүвәлдә «Үрнәк», хәзер В. И. Казаков матбагасы, 1911. – 32 б.

[7] Мөфассал тарих кауме төрки. Мөхәррире: Казан мозафаты имамнарыннан ахун вә казый Хәсәнгата Габәши мулла Мөхәммәд угылы әл-Габәши. – Уфа: «Шәрык» матбагасы, 1909. – 316 б., яки Мохтасар тарих кауме төрки. Җөзэ әүвәл. Нашире: Идрисов, Галиев вә шөрякәләре тиҗарәтханәсе. Мөәллифе: Казан мозафаты имамнарыннан ахун вә казый Хәсәнгата Габәши мулла Мөхәммәд угылы әл-Габәши. – Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1907. – 56 б.

[8] *Һади Атласи* – Һади (Әхмәтһади) Мифтахетдин улы Атласов (1876–1938), тарихчы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[9] Атласов Һ. Казан тарихы. 1 нче җилд / Һ. Атласи. – Казань: Электро-тип. «Умид», 1914. – 344 б.

[10] Атласов Һ. Себер тарихы. Беренче җөзэ. Һәркем аңларлык саф татар телендә язылган милли тарихымыздан бер әсәрдер / Һ. Атласи. – Казань: Электро-тип. «Умид», 1911. – 176 б.

[11] Атласов Һ. Сөен-Бикә / Һ. Атласов. – Казань: Электро-тип. «Умид», 1914. – 62 б.

13) Гайнетдин Әхмәровның «Казан тарихы»[1] һәм «Сөембикә»се[2],

14) Галиәсгарның «Уйнаш»ы[3],

15) Солтан тәрҗемәсе: «Борис Годунов»[4], «Алеко (Чегәннәр)»[5],

16) Толстойның[6] «Хаҗи Морат»[7], «Тере мәет»[8], «Сурат каһвәханәсе»[9],

17) Андреевтан[10] тәрҗемә: «Асылган йиде кешеләр»[11],

---

[1] Казан тарихы (Казан дарелфөнүнендә тарих, асәре гатыйка вә голүме ән-нәсаб җәмгыяте әгъзасы Гайнетдин Әхмәровның 1909 нче сәнә февраль 12 сендә Шәрык клубында халыкка укыган дәресе). Нашире: «Бәянелхак» идарәсе Казанда.– «Бәянелхак» матбагасы, 1909 ел.– 112 б.

[2] Г. Әхмәровның бу китабы аерым басылмаган.

[3] Уйнаш. Театру мәҗмугасы. Драма 3 пәрдәдә. Җилд II. Китап – 11. Галиәсгар Камал. Наширләре: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе Казан.– Казань: Лито-тип. И.Н. Харитонова, 1911.– 51 б.

[4] Борис Годунов. Мөхәррире: А.С. Пушкин. Мөтәрҗиме: С. Рахманколый. Беренче табгы. Наширләре: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе Казан.– Казань: Литотип. И.Н. Харитонова, 1912.– 79 б.

[5] Алеко яки Чегәннәр. Хикәя. Мөхәррире: А.С. Пушкин. Мөтәрҗиме: Солтан Рахманколый.– Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1909.– 22 б.

[6] *Толстой* – Лев Николаевич Толстой (1828–1910), граф, рус язучысы.

[7] Хаҗи Морат. Тарихи хикәя. Мөхәррире: граф Лев Толстой. Мөтәрҗиме: Мәхмүд Мәрҗани. Нашире: «Белек» көтепханәсе, Оренбург.– Казань: Электро-тип. «Умид», 1913.– 163 б.

[8] Л.Н. Толстойның бу әсәре татар телендә аерым китап булып басылмаган. Ул «Идел» газетасының 1911 елгы саннарында С. Рәмиев тәрҗемәсендә дөнья күргән: Живой труп. Тере мәет. Драма 6 пәрдәдә, 12 манзарада. Лев Николаевич Толстой әсәре. Мөтәрҗиме – Сәгыйть Рәмиев // Идел.– 1911.– 30 сент., 4, 7, 11, 14, 19, 21, 25, 28 окт., 1, 4 нояб.

[9] Мөхәррире: Л.Н. Толстой. Сурат каһвәханәсе. «Суратская кофейня». Соч. Л.Н. Толстого. Издание в память 80 летнего юбилея маститого русского писателя Льва Н. Толстого. Мөтәрҗиме вә нашире: Хөсәен Әбүзәров. Перевел Х. Абузяров.– Казань: Тип. газеты «Баянуль-хак», 1908.– 16 б.

[10] *Андреев* – Леонид Николаевич Андреев (1871–1919), рус язучысы.

[11] Леонид Андреев әсәре. Асылган йиде кешеләр хикәясе / Фатыйх Әмирхан тәрҗемәсе.– Казанда «Үрнәк» матбагасында басылды, 1908.– 104 б.

18) Гаязның «Остазбикә»се[1], «Мөгаллимә»се[2], «Зиндан»[3].

«Аң»ның 1915 нче елда чыккан номерларының һәммәсен йибәрүне тәкрар үтенәм. Болар миңа бик матлуб. Бу хатны берничә көн элек башлап та бетерә алмый куйган идем, хатыңны алгач, яңадан тотындым.

Башлыйк матбугат юбилееннән[4] һәм «Аң»ның дәвамыннан. Казанда вакытта үзең белән сөйләшкәндә, «Аң»ның тукталу ихтималыннан бик тәәссеф итүемне[5] әйткән идем. Дәвами хәбәре хакыйкатән дә шатландырды. «Аң» тукталса, әдәбият белән мәдәни фикер хакыйкатьтә бер органсыз калачак, яшь истигъдадлар[6] өчен дә зур мәхрүмият булачак иде. Дәвам иттерергә карарында фәүкылгадә[7] исбат иткәнсең.

Бу – бер минем түгел, күпләрнең фикередер.

Насыйп булса, һәр номерга булмаса да, еш-еш язарга тырышачакмын һәм башкаларны да димләячәкмен, һәрхәлдә, башланган эшеңдә дәвам вә сәбатыңны[8] ихлас күңелдән тәбрик итәм.

Матбугат юбилее бик тиеш нәрсә. Мин ул хакта, әлбәттә, язарга тиешле күрәм[9]. Ләкин Уфа шундый бер каһәрле кала ки, монда кирәк материалны вакытында табарга кыен. Иске газитләр, иске журналлар кирәк. Боларны Уфада табып булырмы – белмим. Көтепханәдә дә, хосусый кулда да күренмиләр, һәрхәлдә, тырышачакмын һәм иң соңга калганда да декабрь 27 ләреннән калмаска ижтиһад итәрмен.

Болар шулай.

---

[1] Мөхәммәтгаяз әл-Исхакыйның мәҗмугаи асаре. Остазбикә. 28 нче декабрь, 24 нче гыйнвар 1915 сәнә, Мәскәү. Сигезенче җилд. Беренче табгы. Нашире: Мөхәммәтгаяз әл-Исхакый.– Мәскәү, [е.к.].– 79 б.

[2] Мөхәммәтгаяз әл-Исхакыйның мәҗмугаи асаре. Мөгаллимә. Язылды 6–8 декабрь 1913 ел. Финляндия. Драма өч пәрдәдә. Өченче җилд. 2 нче китап. Мөхәммәтгаяз әл-Исхакый.– Петербург, [е. к.].– 190 б.

[3] Зиндан. Мөхәррире: Мөхәммәтгаяз әл-Исхакый.– Казань: Типо-литогр. И. В. Ермолаевой, преемн. Ключникова, 1907.– 80 б.

[4] *Башлыйк матбугат юбилееннан* – 1917 елга кадәр татарларда көндәлек матбугат барлыкка килү вакыты «Казан мөхбире» газетасының беренче саны чыгу көне – 1905 елның 29 октябре исәпләнелә.

[5] *Тәәссеф итүемне* – үкенүемне.

[6] *Истигъдадлар* – сәләтлеләр.

[7] *Фәүкылгадә* – гадәттән тыш.

[8] *Сәбатыңны* – ныклыгыңны.

[9] *Мин ул хакта, әлбәттә, язарга тиешле күрәм* – матбугат юбилее уңае белән Г. Ибраһимов мәкалә язмаган булса кирәк, газета-журналларда табылмады.

Бар яңа бер мәсьәлә. Мин тео[рия] словес[тности]ны «Галия»дә укытып, тәҗрибә кылып, күп төзәттем.

Дәхи шундагы дәресләр тәҗрибәсендә (татар теленең методикасы) методика родного языка эшләнеп барыла. Мин бу нәрсәләрне быел кышта бастырырга тиешле идем.

Сиңа сүз ачуым түбәндәге сәбәптән: моңарчы синең белән эшләп килдек, сиңа бурычлар да бар. Әсәрләремнең бер наширда булуын күңелем бик тели. «Гасыр»ның матур басуы да күңелемә бик охшый. Шунлыктан мин ул ике дәреслегем хакында да «Гасыр» белән киңәшеп үтми торып, мондагы наширларга бирергә йөрәгем тартмый. Сез ничек уйлыйсыз? «Гасыр» шул ике нәрсәне басарга быел имкян табамы, юкмы?[10]

Минем дәреслекләрем моңарчы да чыкканы бер мәктәпләргә керә барды. Боларда тәҗрибә дә кушыла. Боларның мәктәп вә мәдрәсәгә керүе хакында сөйләргә дә хаҗәт юк. Әгәр дә быел кыш бастыра алабыз дисәгез, гыйнварда сезгә ул әсәрләрне җибәрә алам. Шартлары хакында сөйләшә башларга ярый.

Кәгазь юкмы, башка манигъ[11] бармы, ни дә булса, бастыра алмасагыз да, миңа бер хәбәр яз. Чөнки мин, бәлки, мондагы наширләр белән сөйләшмәмме дигән бер фикердәмен. Әле катгый түгел, шулай да сез баса алмасагыз, йә үзем бастыру, йә болар белән сөйләшеп карау ниятендәмен. Миңа аларның быел дөньяга чыгуы күп җәһәттән бик матлуб[12]. Шул хакта кичекми бер хәбәреңне көтәм.

«Аң»да быел барлыгы биш мәкалә булды[13]:

---

[10] Г. Ибраһимовның бу хезмәтләре «Гасыр» нәшриятында түгел, ә «Сабах»та нәшер ителгәннәр: Ибраһимов Г. Тел сабаклары. Икенче китап (Гамәли имля – Иншага, сарыф, нәхүгә хәзерлек). Нашире: «Сабах» көтепханәсе, Казан / Г. Ибраһимов.– Казань: Лито-тип. т-ва «Умид», 1918.– 47 б.; Ибраһимов Г. Татар телен ничек укытырга? (Телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә). Нашире: «Сабах» ширкәте Казанда / Г. Ибраһимов.– Казань: Тип. т-ва «Умид», 1918.– 76 б.

[11] *Манигъ* – каршылык.

[12] *Матлуб* – сорала.

[13] «Аң» журналының 1915 елгы саннарында Г. Ибраһимовның басылган мәкаләләре биш кенә түгел. Алда күрсәтелгәннәрдән башка янә илаһият галиме, тарихчы, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) тууына 100 ел тулу уңаеннан ике мәкаләсе бастырылган: Ибраһимов Г. Бөек остазның кайбер тәэлифләре. Юбилей мөнәсәбәтилә тәнкыйть / Г. Ибраһимов // Аң.– 1915.– № 1.– Б. 5–19; Ибраһимов Г. Бөек остазымызның тарихи бер тәнкыйте. Тәнкыйть / Г. Ибраһимов // Аң.– 1915.– № 2.– Б. 39–47.

1) «Уфа мәҗлесе карарлары»[1],

2) «Хезмәт һәм әдәби җинаять» (Шакирның китабы хакында тәнкыйть)[2],

3) «Татар имлясында яңа агымнар»[3],

4) «Мәдрәсәи Галия» хакында»[4],

5) «Татар сарыфлары»[5].

Син шуларның һәммәсен хисаплатып, тиешле акчасын йибәртсәң иде. Болар хисабына илле сум алынган. Тагын шул чамадан артыграк тияргә тиеш. Үтенәм. Хисапларын дөрес карасыннар иде. Кайбер вакытта мөсаһәлә[6] була. «Гасыр»дан китаплар алдырдым. Югарыдагы китапларны йибәрергә куша күр. Үтенәм, ул китапларны минем «Гасыр»га булган бурычларым хисабына кушсыннар. «Аң»дагы мәкаләләр гонорарына аны катнаштырма әле. Әгәр алай мөмкин булмаса, китапларны җибәрмәвең үк матлуб.

Уфада хәят күңелле генә үтә. Күп эшлим бугай. «Мәдрәсәи Галия» дә бераз вакытны ала. Анда кайсы көндә ике, кайсы көндә өч сәгать дәрестә булам.

Казанда ни хәбәрләр? Аны бер дә язмагансың. Матбугат юбилеенә гәзитәләрдә ник язмыйлар? Аңа бит башка якларның да кушылуы матлуб.

Сораганнарга сәлам сөйлә.

Хәзергә башка хәбәр юк. Хат, перевод вә китаплар көтеп калам: Галимҗан.

Декабрь 16 – Уфа

Адресым әүвәлгечә.

---

[1] *«Уфа мәҗлесе карарлары»* – И.Г. Уфада дәрес китаплары хакындагы киңәш мәҗлесенең карарлары / Г. И. // Аң.– 1915.– № 15–16.– Б. 284–286.

[2] *«Хезмәт һәм әдәби җинаять» (Шакирның китабы хакында тәнкыйть)* – Ибраһимов Г. Хезмәт һәм әдәби җинаять. Тәнкыйть (Юрист Шакир Мөхәммәдъяровның «Суд законнары») / Г. Ибраһимов // Аң.– 1915.– № 14.– Б. 253–256.

[3] *«Татар имлясында яңа агымнар»* – Ибраһимов Г. Татар имлясында яңа агымнар (Уфада мәктәп китаплары хакында ясалган киңәш мәҗлесендә укылган мәгърузәнең холясасы) / Г. Ибраһимов // Аң.– 1915.– № 18.– Б. 327–336.

[4] *«Мәдрәсәи Галия» хакында»* – Ибраһимов Г. «Мәдрәсәи Галия вакыйгасы» хакында берничә сүз (Муса әфәнденең «Вакыт»та басылган мәкаләсен укыгач язылды) / Г. Ибраһимов // Аң.– 1915.– № 20.– Б. 354–359.

[5] Ибраһимов Г. Татар сарыфлары (Фатыйх Сәйфи, Җәмалетдин Вәлиди һәм Г. Сәгъди әфәнделәрнең яңа чыккан сарыф вә нәхү китаплары мөнәсәбәте белән) / Г. Ибраһимов // Аң.– 1915.– № 21–22.– Б. 378–390.

[6] *Мөсаһәлә* – игътибар җитмәү.

## 1916
## Г. Ибраһимовның «Тормыш» газетасы идарәсенә язган хаты[7]

27 апрель 1916 ел

Идарәгә мәктүб

«Тормыш»та бу ел көзгә чыгуы матлуб булган тел вә әдәбият дәреслекләреннән берничә әсәремне басу хакында кулында кәгазе булган наширләргә мөрәҗәгатем басылган иде.

Шул көннәрдә Казаннан килгән Шиһабетдин әфәнде Әхмәров[8] белән сөйләшеп, бу әсәрләрне көзгә бастырып чыгару шарты белән, «Сабах» көтепханәсенә бирдем.

Нәшер итәргә теләүчеләр булып та, хәбәрләшеп мәшәкатьләнмәсеннәр өчен бу мәктүбемә газетаңызда урын бирүеңезне үтенәм.

Ихтирам белән: Галимҗан Ибраһимов.

---

[7] «Тормыш» газетасының 1916 елгы 27 апрель санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 94) бастырылган. Текст газетадан алынды.

[8] *Шиһабетдин әфәнде Әхмәров* – Шиһабетдин Шәрәфетдин улы Әхмәров (1882–1966), педагог, журналист, нашир.

## Г. Ибраһимовның «Тормыш» газетасы редакциясенә язган хаты[1]

22 декабрь 1916 ел

Идарәгә мәктүб

Мин Уфа земствосы тарафыннан ачылган тәгълим-тәрбия[2] курсларыннан һәм Гыйбадулла Госмановның[3] кызлар мәдрәсәсендә татар теле мөгаллимлегеннән истигъфа иттем[4].

Бу хезмәтне алуым гәзитәңездә язылып үткәнлектән, алардан истигъфамны да «Уфа хәбәрләре» кыйсемендә[5] әйтүеңезне рәҗа итәм[6].

Ихтирам илә: Галимҗан Ибраһимов

«Тормыш»: Галимҗан әфәнденең бу истигъфасенә бик тәәссеф итәмез[7].

---

[1] «Тормыш» газетасының 1916 елгы 22 декабрь санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 96) бастырылган. Текст газетадан алынды.

[2] *Гыйбадулла Госманов* – Гыйбадулла Галиулла улы Госманов (?–?), Уфа сәүдәгәре, «Тормыш» газетасының нашире. Ул 1916 елның октябрендә Уфада кызлар укыту өчен мәдрәсә ача.

[3] *Тәгълим вә тәрбия* – өйрәтү һәм тәрбия.

[4] *Истигъфа иттем* – киттем.

[5] *Кыйсемендә* – бүлегендә.

[6] *Рәҗа итәм* – үтенәм.

[7] *Тәәссеф итәмез* – үкенәбез.

## 1917
## Г. Ибраһимовның «Безнең юл» газетасына язган хаты[1]

19 октябрь 1917 ел

Галимҗан Ибраһимов мәктүбе
(Мәсләкме, дипломмы)

Гыйбадулла Госманов газитәсе 734 нче номерында йир федерация хакында Мәскәү карары белән барачак авыл халкы спискәсенә вилаять һәм өяз мөселманнары тарафыннан кертелгән кандидатлар, шул җөмләдән аеруча минем хакта байтак нәрсәләр яза[2].

Иң элек шуны әйтәм: Спискәләр буенча сайлау көрәше шәхесләр түгел, бәлки сыйныфлар, мәсләк вә программалар көрәшедер. Йир вә федерация теләүче безнең авыл халкы спискәсен – № 3[не] яклаучы иптәшләргә, фикердәшләргә дә хәтерләтеп үтү, агитация вакытында иң беренче планга шәхесләрне алмаңыз, каршы як кандидатларының шәхесләренә кагылмаңыз, бәлки, сәяси мәсләкләрен, дөрестрәге мәсләксезлекләрен тикшереңез; мәсьәлә шәхесләрдә түгел, мәсләктә, сәяси юлларындадыр.

Хосусый үземә ташланган тәнкыйтькә каршы шуны әйтәм: мин яшермим, чыннан да мин Милюковлар[3] кебек шаккатырырлык шәп иттереп, русча сөйли алмамдыр. Шулай була торып та Стәрлетамак өяз мөселманнары һәм вилаять Милли шурасының сул канат әгъзаларының теләген кабул кыйлып, мин үземнең кандидатурамны куярга риза булдым.

Учредительный собраниегә үтә алырмынмы, юкмы? Анысы башка мәсьәлә. Әмма ризалык бирдем.

---

[1] «Безнең юл» газетасының 1917 елгы 19 октябрь санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 98–102) бастырылган. Текст газетадан алынды.

[2] «Тормыш» газетасының 1917 елгы 24 октябрь санында имзасыз «Учредительный собраниегә сайлау хәзерлекләре мөнәсәбәтилә. Мәсләк тә кирәк, тәрбия дә» дигән мәкалә дөнья күрә. Анда 3 нче список буенча кандидатлар гомумән, Г. Ибраһимов аерым алганда, эшләре белән танылмаган, югары тәрбия алмаган кеше буларак тәнкыйтьләнелә.

[3] *Милюков* – Павел Николаевич Милюков (1859–1943), дәүләт эшлеклесе, тарихчы һәм публицист, 1920 елдан эмиграциядә.

Ни өчен?

Моның сәбәбе үз кашымда бик изге, бик газиз саналган эшләрдер.

Унике елдан бирле минем башымны катырган, күп вакыт халкымызның язмышы хакында өметсезлекләргә төшергән бер иҗтимагый начарлык бар – ул да безнең төрек-татар халкында мәсләк булмау, мәсләктә сәбат итмәүдер.

Электән мин моны күп яздым, күп сөйләдем. Романнарымда, хикәя вә мәкаләләремдә бу фаҗигане ачарга тырыштым.

Инде бу ел, революция соңында, халкымызның хәятендәге бу фаҗига шул дәрәҗәдә коточкыч булып ачылды, эш башындагыларымыз шул дәрәҗәдә мәсләксезлек күрсәттеләр ки, мин шаша калдым.

Һәр көн, һәр атлаган саен күрә килгән, җанны әрнетә килгән мәсләксезлекләрне, сәбатсызлыкларны[1] саный тормыйм, алар безгә тарихи яки бер романчыга тыныч вакытта язарга ничә җилдлек бер материал булачаклар, мин фәкать һәркемнең күз алдында булган зур «фаҗигаләр»нең берничәсен генә күрсәтим.

Май аенда утыз миллион мөселманның 900 вәкиле Мәскәүгә җыела да: «Федерация булсын, йиргә социализация булсын», – дип карар чыгара. Бөтен халык, бөтен матбугат буны тарихи җыелышның, тарихи корылтайның тарихи карарлары дип зур тантана белән каршы ала.

Шул «тарихи» көннән ике ай үтә. Тагы Казанга җыелалар да әүвәлге тарихи карарларны себереп ташлап, адәм көлкесе, чыннан да тарихи материал булырлык платформа кабул кылалар. Социализация дә, федерация дә утка ягылып, көлләре күккә очырыла.

Госманов газитәсе әле һаман бер яктан федерация булсын дип кычкыра. Икенче яктан федерациянең иң зур дошманнары белән тулган бер спискәне халыкка мактап кабул кыйлдырырга көчәнә.

Бу мәсләкме? Бу мәсләккә хезмәтме? Бу сәбатмы? Мәдәни галәмдә бундый эшне йә ахмаклар, йә сатлыклар гына эшли ала. Мактансам, хакым бар, менә шул мәсләксезлекләр, шул ахмаклыклар эчендә, хөррият хәрәкәтләренең башыннан бирле билгеле бер юлдан барамын. Аерым спискә чыгарулар, шуңа исемем куелырга ризалык бирүем – йир вә федерация юлында яздан бирле туктамый көрәшеп килүчеләр сафына бер мәсләк арттыру,

[1] *Сәбатсызлыкларны* – тотнаксызлыкларны.

азмы-күпме көч кушу өмете беләндер. Әгәр дә ярлы халыкның байтак теләген эченә алган Мәскәү карары җимерелмәгән булса, мөселманнан сайланган һәммә вәкилләр федерация һәм йиргә социализация буенча барырга мәҗбүри булсалар, Әхмәтбәкләр[1], Әхтәмовлар[2] бу карарга буйсынсалар, безнең теләк табылган булыр, аерым спискә чыгарырга хаҗәт калмас иде. Чөнки безнең кашымызда мәсьәләнең әһәмияте – Габдулламы, Сәйфулламы үтүдә түгел, бәлки, мәсләкнең үтүендәдер. Ләкин эш алай булмый. Казан платформасы дигән бер-бер каһәр чыгар, диләр. Вилаять Шурасының уң канаты шуны кабул кыйлды, җыен федерация дошманнарын тутырып спискә чыгарды.

Инде йир вә федерация теләүчеләргә куәтле көрәш мәйданына чыгу мәсләге бер бурыч булды.

Беләсез, мин язу кешесе. Хәзерге көндә ашыгыч рәвештә тәмамлау лязем булган күп нәрсәләрем бар. Укучылар, укытучылар минем ул әйберләремне телеграм белән дә, хат белән дә ашыктырып сорыйлар. Шулай булса да, хосусый үземә бик күп матди зарар килсә дә, мин ихтыярсыз сәяси көрәшкә чумдым.

Һәркем белә, тарихта бер генә тавыш артык булу сәбәбеннән җөмһүрият урынына монархия урнашып киткән йирләр булды (Франция). Йиргә социализация белән федерация куркыныч хәлгә килгәч, дөнья вә башка эшләр икенче планга төште, ничек мөмкин, шулай үз мәсләгемез кешеләрен үткәрергә тырышу лязем булды. Шунлыктан ризалык бирелде.

Үтсәм – бик яхшы. Йир вә федерация ягына бер тавыш арткан була. Андагы беренче эш – Учр[едительное] собр[ание]гә барган йөзләп мөселман вәкиле арасында мәсләк рухын алга сөрүдер. Икенче бер өметем башка милләтләр белән аңлашу, комиссияләрдә эшләү... Учредительный собрание рус милләтенең парламенты гына түгел, Русиядәге һәммә халыкларның уртак мәҗлесе. Анда иң азында илле телдә сөйләү булачак. Һәрбер милләтнең вәкиле русчаны Милюков кебек яхшы белмәгәне хәлдә һич булмаса, бер мәртәбә үз ана телендә касыйдә сөйләп үтәчәк булыр – табигый, хәзергә бер хыял, бер өмет әле.

Әйтергә телгәнем – үтәрменме, юкмы? – аңа тыныч карыйм. Үтсәм – югарыда әйтелгән мәсләксезлеккә каршы мәсләк намына бер эш кыйла алу өметем бар димәктер.

---

[1] *Әхмәтбәк* – сүз Әхмәтбәк Салихов (Цаликов) хакында бара.

[2] *Әхтәмов* – сүз Ибнеямин Әхтәмов хакында бара.

Айлар, еллар үтәр. Халык уяныр. Бездә дә диплом белән мәсләкнең ике нәрсә икәнен аера башларлар. Шулвакыт социалистларга мәйдан килер.

Без еракка, ерак киләчәккә карыймыз. Алдагы мәйдан өчен яшимез. Федерация белән социализация үтсә, зур шатлык, үтмәсә, Русиядә яңадан бер канлы революция булуы лязем димәктер. Ул вакыт без яңадан сызганып, шул алдагы революция өчен эшләргә – халыкны шуңа хәзерләргә тотыначакмыз. Һәрхәлдә, диплом мәсьәләсе безгә төкереп ташлый торган бер мәсьәлә. Безгә мәсләк кирәк. Дипломы булып та, мәсләге халыкка зарарлы икән, безнең каштa ул чүп, бәлки, зарарлы чүптер.

Менә шуның өчен дә суллар надан халыкны диплом белән алдап булыр әле дигән юлны тотмады. Дипломсыз булса да, мәсләге юлында көрәшкә хәзер булган иманлы, сәбатлы халык вәкилләрен спискәгә керттеләр.

Тәңре киләчәктә халыкларны мәсләксезләрдән, мәсләк дошманнарыннан коткарсын!!

Стәрлетамак өяз мөселманнары һәм вилаять Милли шурасының сул канат әгъзалары тарафыннан авыл халкы спискәсенә кандидатурасы куелган:

Галимҗан Ибраһимов.

Ахырдан:

Мәсьәлә тәмам булгач, шуны да әйтим: Госманов газитәсе минем «Галия»дә, земство курсларында һәм Госманов мәктәбендә укытуларыма да кара тап ташларга көчәнә. Булмый инде, чыннан да Госманов газитәсенең баш мөхәрриренең үзенә төшә торган чукмардыр.

Югарыда әйтелгән мәктәпләрдән «Галия» мәсьәләсе Госманов мөхәррире өчен күңелле булмаса кирәк. «Галия»нең архивасын актарсаң, Госманов мөхәрриренәме, әллә Ибраһимовка кара тап чыгар. Ибраһимовны әле шәкертләр таләп итә. Ә Кадыйри аннан ничек чыкты? Госманов мәктәбендә Уфадан китүем сәбәпле ук[ыт]уны ташлагач, бөтен мәктәп шәкертләре һәм Госманов гаиләсе күз яше белән ташламавымны үтенделәр. Земство курсындагы шәкертләрнең мөрәҗәгатен «Тормыш»та үзеңез бастырдыңыз. Ул мәктүбнең ахырында менә нинди сүзләр бар иде: Без Галимҗан әфәнденең укытуыннан мәмнүн булу гына түгел, чын күңелдән шатлана, ул укытканда без һәрбер сәгатьтә яңа бер гыйлем ала идек. Хәзер аңардан ятим калдык. Аның урынына китаплардан гына ярдәм көтә торган икенче

бер кеше тәгъйин кыйлынып, кадерле минутларымызның бушка үтүе безне соң дәрәҗәдә куркыта. Галимҗан әфәндедән безне мәхрүм итмәвен үтенәмез.

Мөхтәрәм Галимҗан әфәнде, без Сезне көтәмез. Башка кешенең күрүен башымызга да китермимез». 23 имза («Тормыш», 574). Мин бу фактларны Госманов газитәсенең Галимҗан Ибраһимов рәтләп укытмады дигәненә каршы мәҗбүр иттем. Сәяси көрәш дөньяда бар эш. Ләкин ачыктан-ачык ялганлау бу көрәш түгел, шарлатанлык була.

Г. И.

# ТЕЛЕГРАММАЛАР

## 1917
## Г. Ибраһимовның Казаннан «Ирек» газетасына җибәргән телеграммасы[1]

7 август 1917 ел

Казаннан телеграмма

Русия мөселманнарының 2 нче җыелышының карарлары бөтенләй байлар файдасын күзәтә. 1 нче съездда кабул кылынган җир, хатын-кызларның хокукы һәм федерация хакындагы карарларын бозды, авыл кешеләре разый түгелләр...

Ибраһимов.

[1] «Ирек» газетасының 1917 елгы 7 август санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 98) бастырылган. Текст газетадан алынды.

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## 1911

## Г. Ибраһимовның Шиһабетдин Әхмәров һәм аның фикердәшләренә карата белдерүе[1]

15 декабрь 1911 ел

Дәгъвәт

Ш. Әхмәров һәм аның илә фикердәш булуларын игълам иткән әфәнделәр! 567 нумер «Йолдыз»дагы нәрсәңезне укыдым. Бик мәмнүнмен. Бу мәсьәләләрне кузгатудан минем төп максатым: сезнең чын физиономияңезне мәйданга чыгару иде. Ул булды: чөнки сез минем «Вакыт»та һәм «Йолдыз»да язган дәгъва һәм фактларымнан һичберенә җавап бирмәгәнсез, димәк, анлар «ачы хакыйкатьләр». Укучы буңа, әлбәттә, дикъкать итәр.

Бу мәкаләңезне укыгач, Бохара шәриф урамында күргән бер вакыйга хәтеремә килде: анда бер хайванны ахмаклыгы өчен үткен камчы илә сырт буеннан яралар. Ә ул хәрэф[2] артык хиссезлегеннән шуны тоймый, рәхәтләнеп койрыгын селкеп тора.

Сез дә «хозурланып торам» дигән сүзеңез илә шуңа тәмам охшап чыктыңыз.

Мондый затлар илә бер мәсьәлә хакында моназарә кыйлышып, сүз аңлату мөшкел булганга, сез минем тарафтан зикер кыйлынган вә күзеңезне ярып күрерлек мәртәбәдә һәркемгә мәгълүм булган фактларга тугры җавап бирмичә гел мәгънә сезчә лыгырдап кына торганга, китапчылык моназарәсен хәзергә калдырып, сезгә түбәндәге карарымны белдерәм:

Сезнең әүвәлге мәкаләңездә минем әсәрләрем хакында хаксыз бер дәгъва – плагиат – мәсьәләсе аңлашылган иде. Мин сездән бу дәгъване кайтарып алырга яки маддә-маддә исбат кыйлырга сорадым. Сез дәгъвадә әсрар итүеңезне белдереп бик күп шаһитләр алдында шуны яңадан икърар иттеңез һәм «Йолдыз»ның 765 нче нумерында[3] яңадан шуны тәсдыйк итеп, «Әйткән сүз – аткан ук, без кайтарып алмыйбыз, җавапка чакыр, исбат-

[1] «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 15 декабрь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Хәрэф* – гакылсыз.

[3] *«Йолдыз»ның 765 нче нумерында* – сүз шушы мәкалә хакында бара: Әхмәров Ш. Габди әфәндегә / Ш. Әхмәров // Йолдыз.– 1911.– 8 дек.

ка хәзермез», – диденез. Хәзер булсаңыз, бик яхшы: мин сезне шул дәгъваны исбат иттерү өчен Третейский суд «хөкемнәр хөкеменә» дәгъвәт итәм вә шуны мона хәзер игълам итәм. Минем тарафтан «хәким» булуны әдип мөхтәрәм Фатыйх Әмирхан әфәнде илә зыялыларымыздан Фәхрелислам Агиев җәнапләре кабул кыйлдылар.

Бу әфәнделәр судка рәис улмак өчен юрист Бинямин әфәнде Әхтәмов җәнапләреннән үтенүне мәгъкуль күрәләр.

Мона карарым шушы. Боны игълам иттем, үз тарафыңыздан ике «хәким» сайлап, Фатыйх Әмирхан әфәндегә мөрәҗәгать итәсез[1].

Габди.

---

[1] *Фатыйх Әмирхан әфәндегә мөрәҗәгать итәсез* – каршы якның җавабын кара: Әхмәров Ш., Урманчиев Ә. Идарәгә мәктүб. Иҗабәт вә дәгъвәт / Ш. Әхмәров, Ә. Урманчиев // Йолдыз. – 1911. – 19 дек.

Ике арадагы дәгъваларны нәтиҗәсе хакында кара: Хөкем хөкеме // Йолдыз. – 1912. – 26 февр.

## 1912
## Г. Ибраһимовның «Карак мулла» һәм «Сөю-сәгадәт» хикәяләре нәшер ителү хакында[1]

28 февраль 1912 ел

«Карак мулла» һәм «Сөю-сәгадәт».

Бу ике китап икесе дә «Гасыр» нәшрияты улып, Галимҗан әфәнде Ибраһимов каләмилә язылган хикәяләрдер. Матур һәм назик[2] кенә хикәяләр булып чыкканнар. Бәһаләре берсе 10 тиен, берсе 7 тиен генәдер.

## 1913
## Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы нәшер ителү хакында[3]

10, 13, 15, 17, 20 гыйнвар 1913 ел

Яңа гына «Өмид» матбагасында басылып чыкты 416 сәхифәле татарча роман «Яшь йөрәкләр» Галимҗан әфәнде Ибраһимов әсәре («Шәрык» көтепханәсе нәшере). Бу әсәр бу көнгә кадәр татар матбугатына чыккан романнарның иң зурысы. Бәһасе 1 сум 30 тиен, пучта илә 1 сум 50 тиен. Күпләп һәм азлап «Сабах» көтепханәсендә сатыла.

Адрес: Казань, Уфа т-ву «Сабах».

---

[1] «Идел» газетасының 1912 елгы 28 февраль санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Назик* – матур, нәфис.

[3] «Йолдыз» газетасының 1913 елгы 10, 13, 15, 17, 20 гыйнвар саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## «Яшь йөрәкләр». Мөһим әсәр. Бөек роман[1]

22, 24, 27 гыйнвар 1913 ел

Мөхәррирләремездән Галимҗан әфәнде Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» исемендәге бөек романы «Шәрык» көтепханәсе мәсрафы[2] илә басылып чыкты.

Әдәбиятымызда моңарчы мисле[3] күрелмәгән бөек романны җөзэәләргә[4] бүлмәенчә бөтен шәкелендә бастыру шәрәфе беренче «Шәрык» көтепханәсенә төште. «Яшь йөрәкләр» хакында фәкать шуны гына әйтәмез: «Яшь йөрәкләр» сөйләми, сүз илә туктамый, бәлки, тарихы әхвал агымыннан килеп чыккан авыр, караңгы хәятны, аның бөтен эчке вә тышкы кыяфәте, тудырган сәбәпләре, биргән нәтиҗәләре, барлык тармаклары илә җанлы рәвештә укучының күз алдына китерә дә куя. «Яшь йөрәкләр»дә иске тормыш илә «яшь куәт» бәрелешәләр. Китә көрәш. Башлана авыр көннәр, туа тарихи нәтиҗәләр. «Яшь йөрәкләр»дә бик күп төрле типлар гаять мөкәммәл рәвештә тасвир ителмештер. Әсәрнең тел вә тәртип ягындагы кәмаләте[5] хакында сөйләп торырга да лөзүм юктыр[6].

«Яшь йөрәкләр»не укыңыз. Җитди сурәттә тәүсыя[7] итәмез. Һәркем аңларлык йиңгел телдә. Роман вә әдәбият һәвәсләләрендә мотлакан бер данәсе булынырга тиешледер. «Яшь йөрәкләр» 416 бит үзерендә[8] бик нәфис рәвештә басылды. Хакы: 1 сум 30 тиен. Пучта илә 1 сум 50 тиен. Заказной булса, пучта хакы 27 тиен. Күпләп алучыларга күп тәнзил[9]. Мәшһүр китапчыларның һәркайсында сатыла.

---

[1] «Йолдыз» газетасының 1913 елгы 22, 24, 27 гыйнвар саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Мәсраф* – чыгым.

[3] *Мисле* – кебек.

[4] *Җөзэә* – бүлек.

[5] *Кәмаләт* – җитешкәнлек.

[6] *Лөзүм юктыр* – кирәк түгелдер.

[7] *Тәүсыя* – киңәш.

[8] *Үзерендә* – биредә: күләмендә.

[9] *Тәнзил* – ташлама.

Ихтар[1]: «Шәрык» көтепханәсе спрош вә заказларны һәрвакытта көне илә йибәрә. Истанбул, Мисыр матбугаты Русиядә басылган һәрбер әсәр клитле суръттә «Шәрык» көтепханәсендә мәүҗүдтер[2].

Теләгән китапларыңызны «Шәрык» көтепханәсеннән табарсыз.

---

[1] *Ихтар* – искәрмә.

[2] *Мәүҗүд* – бар, бар булган.

## Яңа басылып чыкты! «Яшь йөрәкләр»[1]

29, 31 гыйнвар; 3, 5, 7, 10, 12 февраль 1913 ел

Яшь мөхәрриремездән Галимҗан әфәнде Ибраһимовның иң соңгы әсәре. 416 битле бу бөек романның бәһасе 1 сум 30 тиен. Пучта илә 1 сум 50 тиен.

Мөрәҗәгать өчен адрес: Казань, книгоиздательству «Гаср» № 2.

## Яңа гына басылып чыккан китаплар[2]

14 февраль 1913 ел

...«Яшь йөрәкләр» 1 сум 30 тиен.

Адрес: Казань, т-ву «Маариф».

---

[1] «Йолдыз» газетасының 1913 елгы 29, 31 гыйнвар; 3, 5, 7, 10, 12 февраль саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] «Йолдыз» газетасының 1913 елгы 14 февраль саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Объявление об издании повести Г. Ибрагимова «Карак мулла» (Мулла разбойник)[1]

1913 г.

Мухаммеданская неповременная печать на татарском языке в приволжском и оренбургском крае за 1912-й год

В повестях Галимджана Ибрагимова «Карак мулла»[2] (Мулла разбойник), Казань. Тип. Харитонова, $16^0$. 30 стр. 1000 экз... и Бикмулова Касима[3] «Ат караклары»[4] (Конокрады), Казань, тип. Умид. $16^0$. 32 стр. 3000 экз., в крайне непривлекательном свете рисуется сословие мулл старого направления: в числе их встречаются даже люди, занимающиеся кроем прямых своих обязанностей разбоем и кражею лошадей.

---

[1] «Православный собеседник» журналының 1913 елгы июнь санына кушымта булган «Инородческое обозрение»нең 3 нче китабында А. Емельяновның «Мухаммеданская неповременная печать на татарском языке в Приволжском и Оренбургском крае за 1912-й год» дигән мәкаләсендә (б. 229) бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *«Карак мулла»* – Карак мулла: Хикәя. Мөхәррире: Галимҗан Ибраһимов. Беренче басылуы.– Казань: Лито-тип. И.Н. Харитонова, 1912.– 30 б.

[3] *Бикмулов Касим* – Касыйм Җәмалетдин улы Бикколов (1868–1937), тарихчы, язучы, педагог.

[4] *«Ат караклары»* – Мулла Касыйм Бикколов. Ат караклары.– Казань: Электро-тип. «Умид», 1912.– 32 б.

## Объявление об издании книги Г. Ибрагимова «Мазлума хатын, яхуд кюргян джафаларым» («Угнетенная женщина, или страдания, перенесенные мною»)[1]

1913 г.

Мухаммеданская неповременная печать на татарском языке в приволжском и оренбургском крае за 1912-й год

Вопросу о положении мухаммеданской женщины посвящен был целый ряд специальных произведений, главным образом, беллетрического содержания. Вот перечень некоторых из них: Ибрагимов. «Мазлума хатын, яхуд кюргян джафаларым»[2] (Угнетенная женщина, или страдания, перенесенные мною), Уфа, тип. Каримова, Хусайнова и К$^0$–16$^0$. 24 стр. 1000 экз...

## Г. Ибраһимовның Киевтән Казанга кайтуы хакында[3]

23 июнь 1913 ел

Галимҗан Ибраһимов – мөхәррирләремездән Галимҗан Ибраһимов җәнапләре Киевтән бу көннәрдә Казанга кайтты.

[1] «Православный собеседник» журналының 1913 елгы июнь санына кушымта булган «Инородческое обозрение»нең 3 нче китабында А. Емельяновның «Мухаммеданская неповременная печать на татарском языке в Приволжском и Оренбургском крае за 1912-й год» дигән мәкаләсендә (б. 230) бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *«Мазлума хатын, яхуд кюргян джафаларым»* – Мәзлумә хатын яхуд күргән җәфаларым. Нашир вә мөхәррир Г. Ибраһимов. Уфа «Шәрык» матбагасы.– Уфа: Электро-тип. т-ва «Каримов, Хусаинов и К$^o$», 1912.– 23 б.

[3] «Йолдыз» газетасының 1913 елгы 23 июнь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Г. Ибраһимовның туган авылы Солтанмораттан Казанга килүе хакында[1]

19 сентябрь 1913 ел

Галимҗан Ибраһимов – мөхәррирләремездән Галимҗан әфәнде Ибраһимов 16 нчы сентябрьдә Эстәрлетамак өязендәге үз авылыннан Казанга килде. Әгәр Казанда калмаса, бу ел Петербургта кышламакчы[2].

## Объявление об издании романа Г. Ибрагимова «Яшь йөрәкләр»[3]

1913 г.

Критика и библиография

«Яшъ юрякляръ»[4] – Этот большой роман – сочинение нашего молодого писателя Галимзяна Ибрагимова, изданный книгоиздательством «Шарк» (в Троицке Оренбург. губ.), поступил в продажу только в течение последних месяцев. Книга напечатана в типографии «Умид» (в Казани), цена 1 р. 30 к.

---

[1] «Йолдыз» газетасының 1913 елгы 19 сентябрь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә басты- рыла.

[2] *Әгәр Казанда калмаса, бу ел Петербургта кышламакчы* – Г. Ибраһимов Петербургка бармый, Казанда кала.

[3] «Православный собеседник» журналының 1913 елгы сентябрь санына кушымта булган «Инородческое обозрение»нең 4 нче китабында «Критика и библиография» дигән бүлекчәдә (б. 229) бастырылган. Текст шуннан алынды.

[4] *«Яшъ юрякляръ»* – Ибраһимов Г. Яшь йөрәкләр. Нашире: Әхмәд әл-Исхакый «Шәрык» көтепханәсе / Г. Ибраһимов.– Казань: Электро-тип. «Умид», 1912.– 416 б.

## Г. Ибраһимовның «Аң» журналының җаваплы сәркятибе булып эшли башлавы хакында[1]

20 октябрь 1913 ел

Идарәдән: «Аң»ның сәркятиплек (секретарьлык) ләвазимене[2] мөхәррирләремездән Галимҗан Ибраһимов әфәнде кабул итте. Журнал киләчәк саннан игътибар аның каравында чыгачактыр.

## Г. Ибраһимовның «Аң» журналында Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре хакында[3]

27 октябрь 1913 ел

Юлдашларыбыз

Матбугатымыз дөньясында мөмтаз[4] урын тотарга тиешле булган «Ак юл» журналының соңгы нумеры идарәмезгә килде...

Мөндәриҗәсе:... Г. Ибраһимов. Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре...

---

[1] «Аң» журналының 1913 елгы 20 нче санында (б. 352) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Ләвазимене* – дәрәҗәсен.

[3] «Аң» журналының 1913 елгы 21 нче санында (б. 376) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[4] *Мөмтаз* – аерылып торган.

## Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәте бастырылу хакында[1]

25, 26, 28, 29, 30, 31 май; 1, 2, 6, 7, 8, 9, 12, 13, 14, 15, 16, 17, 19, 20, 21, 22 июнь 1913 ел

Галимҗан Ибраһимов әсәре.

«Татар шагыйрьләре» эчендә әсәрләре иң мәкъбүл[2] булган Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Габдулла Тукаев шигырьләрене сүтеп күрсәткән бер әсәрдер. Нәзым[3] булган әсәрләр барысы да шигырь булмаганыны вә шигырьләрне нә рәвештә тәкъдир итәргә тиешлекне белергә теләгән әдәбият һәвәслеләренә тәүсыя[4] ителәдер. Китап «Вакыт» матбагасында яхшы кәгазьдә нәфис рәвештә басылды. Хакы 35 тиен, пучта илә 43 тиен. Баш ысклады «Вакыт» идарәсе. Шөгъбәләре[5] Казанда «Мәгариф», Уфада «Чулпан» көтепханәләредер.

---

[1] «Вакыт» газетасының 1913 елгы 25, 26, 28, 29, 30, 31 май, 1, 2, 6, 7, 8, 9, 12, 13, 14, 15, 16, 17, 19, 20, 21, 22 июнь саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Мәкъбүл* – яхшы күрелгән.

[3] *Нәзым* – тезмә.

[4] *Тәүсыя* – киңәш.

[5] *Шөгъбәләре* – бүлекләре.

## 1914
## Г. Ибраһимовның «Борынгы ислам мәдәнияте» дигән хезмәте бастырылу хакында[1]

22 февраль; 14 март; 11, 18 апрель 1914 ел

Үткен каләме илә гомумгә танылган яшь язучыларымыздан Галимҗан Ибраһимов әсәредер. Хакы берәмләп 35 тиен, пучта илә 43 тиен.

Әүвәлге мөселманнар – гарәпләрнең һәр хәлләре берлә якыннан танышлык кылырга теләгән затлар өчен иң бөек бер моталәга[2] китабыдыр. Бу китапның мәктәп программаларына кабул ителүе, гомуми вә хосусый көтепханәләрдә, тарих һәвәсләреләремез кулында берәр данәсе булмак, әлбәттә, ляземдер[3]. Зирә[4], бөтен Аврупа мәдәниятенең остазы булган борынгы ислам мәдәниятеннән хәбәрсез тору бу көндә бигрәк безләр өчен беренче хурлыктыр.

Мөндәриҗәсе[5]: дибаҗә[6], Гарәбстан ярыматаусы, гарәпләрдә нәсел-нәсәп, тел вә кабилә, җаһилият заманында[7] гарәпләрнең тарихы, гыймран мәдәниятләре, тормышлары, хөкүмәт вә истикълялы[8], дин, гыйбадәт, әхлак вә гадәтләре, шигырь вә хитабәтләре[9], уку белүләре, заманы җаһилиятенең ниһаяте, гарәпләрдә исламият, тарихы әһле ислам, голүме хасса, голүме гамма, буның өчен баш хәрәкәт, мөтәрҗимнәр[10], юнан теленнән фәлсәфә вә әдәбиятка гаид[11] тәрҗемә ителмеш Әфлә-

[1] «Вакыт» газетасының 1914 елгы 22 февраль; 14 март; 11, 18 апрель саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.
[2] *Моталәга* – өйрәнү.
[3] *Лязим* – тиешле.
[4] *Зирә* – чөнки.
[5] *Мөндәриҗәсе* – эчтәлеге.
[6] *Дибаҗә* – кереш.
[7] *Җаһилият заманында* – наданлык заманында (Ислам диненә кадәрге чорда).
[8] *Истикъляль* – бәйсезлек; ирек.
[9] *Хитабәт* – ораторлык.
[10] *Мөтәрҗимнәр* – тәрҗемәчеләр.
[11] *Гаид* – бәйләнешле.

тун[1] вә Аристаталис[2], Җалинус әсәрләре, тыйб вә аның фәргусы[3] хакындагы әсәрләр, һинд, кыбтый теленнән тәрҗемә ителмеш китаплар мөселманнарның гыйлемгә нисбәтләре, тәэлифат[4] һәм мөәллифләр, мөселманнарда голүм вә мәгариф, ислам фәйләсуфлары, рәсадханәләр[5], голүме[6] тыйббыя, ислам табибләре, галәме исламда маристаннар, гыйльме кимия[7], голүме табигыя, җәгъръфия, җәгъръфиәи гомуми китаплары, тарих әдәбият, музыка, гыйльми җәмгыятьләр, мәктәп-мәдрәсәләр, көтепханә вә кыйраәтханәләр[8], гыйлемнең мөселманнарга тәэсире вә аларга биргән мөкяфате[9], диңгез флоты вә башкалар, ислам шәһәрләре, ислам асәре гатыйкасы[10], асәре мәнкулә[11], борынгы мөселманнар хакында фәйләсуф Дарпар ни ди? Хатимә.

---

[1] *Әфләтун* – Платон (Plátōn) (б.э.к. 428 яки 427–348 яки 347), борынгы юнан философы.

[2] *Аристаталис* – Аристотель (Aritotélēs) (б.э.к. 384–322), борынгы юнан философы һәм галиме.

[3] *Фәргъ* – тармак.

[4] *Тәэлифат* – биредә: китаплар.

[5] *Рәсадханәләр* – обсерваторияләр.

[6] *Голүм* – гыйлемнәр.

[7] *Гыйльме кимия* – химия фәне.

[8] *Кыйраәтханә* – уку залы.

[9] *Мөкяфәт* – бүләк.

[10] *Асаре гатыйк* – археология.

[11] *Асаре мәнкулә* – риваятьләр.

## Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» дигән хезмәте бастырылу хакында[1]

9 март; 22 апрель 1914 ел

Галимҗан Ибраһимов әсәре

«Татар шагыйрьләре» эчендә әсәрләре иң мәкъбүл булган[2] Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Габдулла Тукаев шигырьләрене сүтеп күрсәткән бер әсәрдер. Нәзым[3] булган әсәрләр барысы да шигырь булмаганыны вә шигырьләрне нә рәвештә тәкъдир итәргә тиешлекне белергә теләгән әдәбият һәвәслеләренә тәүсыя ителәдер. Китап «Вакыт» матбагасында яхшы кәгазьдә нәфис рәвештә басылды. Хакы 35 тиен, пучта илә 43 тиен. Баш ыскладаы «Вакыт» идарәсе. Шөгъбәләре Казанда «Мәгариф», Уфада «Чулпан» көтепханәләредер.

## Г. Ибраһимовның Сухум шәһәренә сәфәре хакында[4]

11 март 1914 ел

Галимҗан Ибраһимов – гәзитәмезнең язышучыларыннан вә мәгъруф мөхәррирләремездән[5] Галимҗан әфәнде Ибраһимов күптән түгел Киевтән Кара диңгез буендагы курортларның берсе булган Сухумга сәфәр кылмыштыр. Мөхәррир хәзерендә «Безнең көннәр» атлы зур роман эшләү белән мәшгуль.

Адресы: Сухум, до востребования Г. Ибрагимову.

[1] «Вакыт» газетасының 1914 елгы 9 март, 22 апрель саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Мәкъбүл булган* – яхшы күрелгән.

[3] *Нәзым* – тезмә.

[4] «Йолдыз» газетасының 1914 елгы 11 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[5] *Мәгъруф мөхәррирләремездән* – танылган язучыларыбыздан.

## Г. Ибраһимовның «Диңгездә» дигән әсәре бастырылу хакында[1]

5 август 1914 ел

(«Шура»да басылганнан соң[2] рисалә шәкелендә басылды.)

Мөхәррире Галимҗан Ибраһимов. Диңгез пароходында барган бер картка очрап, аның сүзләренә караганда халкымызның бик күп хыялый әкиятләргә чын күз илә караганнарыннан фикер җәһәтенчә нә кадәр түбән икәнлекләрене ачык бәян итү илә бергә диңгез күренешләре тәрсим[3] ителмеш кызык бер хикәядер.

Хакы 8 тиен. Пучта илә 10 тиен.

Адрес: Оренбург, редакция газ. «Вакыт».

---

[1] «Вакыт» газетасының 1914 елгы 5 август санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Шура»да басылганнан соң* – Ибраһимов Г. Диңгездә / Г. Ибраһимов // Шура.– 1911.– № 6.– Б. 171–175; – № 7.– Б. 205–208.

[3] *Тәрсим* – рәсемен (сурәтен) ясау.

## Г. Ибраһимов һәм Габделбари Батталның «Яңа әдәбият» дигән дәреслеге бастырылу хакында[1]

2, 23 сентябрь 1914 ел

Мөгаллим вә мөдәррис әфәнделәр дикъкатенә!

Мөһим дәреслек «Яңа әдәбият», мөһим дәреслек. Тәҗрибәле мөгаллим вә мөдәррисләремездән Галимҗан Ибраһимов вә Г. Баттал әфәнделәр тарафыннан «Яңа әдәбият» исемле хыялый зур вә рәсемле бу хрестоматия тәртип ителеп, татар әдәбияты дәресләре укыту юлында һәм мөгаллимнәргә һәм дә таләбәләргә хәкыйкать бик зур йиңеллек ясадылар. Бу надир[2] дәреслектә атаклы мөхәррир вә шагыйрьләремезнең иң яхшы вә мөнтәхәб[3] әсәрләреннән фикърәләр[4], хикәяләр, шигырьләр дәреҗ ителүе[5] һәм дә рәсемле булуы вә шуның илә бәрабәр тәгълим[6] бабында яхшы тәҗрибә сахибе[7] булган мөгаллимнәр тарафыннан тәртип ителүе аның һәр җәһәттән мөкәммәл булачагына ачык дәлилдер. Мөгаллим әфәнделәрнең дикъкатьләрен җәлеп итәмез: зур форматта, яхшы кәгазьдә 270 сәхифәләр чамасындагы бу мөһим дәреслекнең бәһасе 1 сум, пучта илә 1 сум 18 тиен. Күпләп алучыларга бөек скидкә.

Мөрәҗәгать өчен адрес: Казань, «Гаср» № 5.

---

[1] «Вакыт» газетасының 1914 елгы 2, 23 сентябрь саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Надир* – сирәк.

[3] *Мөнтәхәб* – сайлап алынган.

[4] *Фикърә* – өзек, өземтә.

[5] *Дәреҗ ителү* – теркәлү.

[6] *Тәгълим* – өйрәтү.

[7] *Сахиб* – ия, хуҗа.

## Г. Ибраһимов һәм Габделбари Батталның «Яңа әдәбият» дигән дәреслеге бастырылу хакында[1]

5, 6, 9, 10, 11, 12, 13 ноябрь 1914 ел

«Гасыр» матбагасы. Казанда Мәскәуский урамда Казаков йортында, «Болгар» номерлары[2] астында.

Мөгаллим вә мөдәррис әфәнделәр!

Яңа гына басылып чыгып сатыла башлады «Яңа әдәбият». Мөрәттибләре[3]: Галимҗан Ибраһимов вә Габделбарый Баттал. Бу надир дәреслектә атаклы мөхәррир вә шагыйрьләремезнең иң яхшы вә мөнтәхәб әсәрләреннән фикърәләр, хикәяләр, шигырьләр дәреҗ ителгән. Рәсемле булуы вә шуның илә бәрабәр тәгълим бабында яхшы тәҗрибә сахибе булган мөгаллимнәр тарафыннан тәртип ителүе аның һәр җәһәттән мөкәммәл булачагына ачык дәлилдер. Бу китап басылып чыгу илә бик күп атаклы мәдрәсәләремезнең рөшди[4] сыйныфларына дәрес китабы ителеп кабул ителде. Зур форматта вә бик яхшы кәгазьдә, бик күп рәсемнәр илә басылган 240 сәхифәлек бу мөһим дәреслекнең бәһасе 1 сум, пучта илә 1 сум 18 тиен. Күпләп алучыларга бөек скидкә.

Мөрәҗәгать өчен адрес: г. Казань, «Гаср» № 4.

---

[1] «Кояш» газетасының 1914 елгы 5, 6, 9, 10, 11, 12, 13 ноябрь саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Болгар» номерлары* – Казанда Евангелистлар һәм Мәскәү (хәзерге Татарстан һәм Мәскәү) урамнары чатында кунакханә (№ 17/59). П. П. Романов проекты буенча 1866 елда беренче гильдия сәүдәгәре, нәселдән шәрәфле гражданин Ибраһим Исхак улы Аппаков (1821–1885) табыш китерү йорты буларак төзеттерә. Аны 1897 елда Әхмәт Мөхәммәтгали улы Хөсәенов (1837–1906) И. Аппаковның кызы Бибимәрьямбанудан (1866–?) сатып ала. 1906 елда сәүдәгәр Фәтхулла Әхмәдуллин (?–?), аның бер өлешен арендалап, кунакханә ача. 1907 елда Мөхәммәтрәхим Мөхәммәтшакир улы Казаков (1874–1937) аңардан кунакханәне сатып ала. 1910 елның 1 декабреннән «Болгар» номерлары бертуган Мөхәммәтша (?–?) һәм Гарәпша (?–?) Рамазановлар идарәсенә күчә. Г. Тукай анда (төрле бүлмәләрдә, соңгысы 40 нчы), башка урыннарда торып алгалаганын исәпләмәгәндә, 1907 елның көзеннән 1912 елның 12 декабренә кадәр яши. Бина 2008 елның 28 сентябрендә тулысынча сүттерелеп, урынына шуңа охшашлы бина корылды.

[3] *Мөрәттибләре* – тәртип итүчеләре, төзүчеләре.

[4] *Рөшди* – башлангычтан югары, урта.

## Г. Ибраһимовның «Йөз ел элек» дигән әсәре бастырылу хакында[1]

10 декабрь 1914 ел

«Шура»да дәреҗ ителгәннән соң[2] рисалә итеп басылды.

Мөхәррире Галимҗан Ибраһимов.

Буннан йөз ел элек бер авыл мулласының мәгыйшәтене[3], ул заманда халкымызның фикер вә истигъдады[4], бер беренә ихтирамән тартынмауларыны һәм бер-берсе алдында нә кадәр хәйрәтләр[5] сачеп, аз гына каһрилык[6] килерене төсле булдисә шундук куян кебек посканларыны [...] бу хикәядә бик гүзәл күрсәтмештер. Хакы 10 т., пучта илә 12 т.

---

[1] «Вакыт» газетасының 1914 елгы 10 декабрь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Шура»да дәреҗ ителгәннән соң* – Ибраһимов Г. Йөз ел элек / Г. Ибраһимов // Шура.– 1911.– № 12.– Б. 379–382; – № 13.– Б. 411–413; – № 14.– Б. 440–443.

[3] *Мәгыйшәтене* – тормышын, көнкүрешен.

[4] *Истигъдады* – сәләтлелеге.

[5] *Хәйрәтләр* – аптыраулар, хәйран калулар.

[6] *Каһрилык* – җәберләү.

## 1915
## Объявление об издании учебного пособия «Яңа адабият» («Новая литература»), составленного Г. Ибрагимовым и Габделбари Батталом[1]

1915 г.

Краткий обзор татарско-мухаммеданской неповременной печати за 1914-й г.

Среди учебников и учебных руководств следует отметить: «Янга адабият»[2] (Новая литература) Галимджана Ибрагимова и Баттала, Казань, тип. Харитонова, 1/8 д.л. 240 стр. 21 рис. 5000 экз. 1 р. 18 к. Это произведение представляет школьную хрестоматию, роскошно изданную, с прекрасными рисунками, но с тенденциями национализма и без достаточной сообразованности с природой детей и их пониманием.

---

[1] «Православный собеседник» журналының 1915 елгы сентябрь санына кушымта булган «Инородческое обозрение»нең 12 нче китабында А. Емельяновның «Краткий обзор татарско-мухаммеданской неповременной печати за 1914-й г.» дигән мәкаләсендә (б. 1017) китерелә. Текст шуннан алынды.

[2] *«Янга адабият»* – Ибраһимов Г. вә Баттал Г. Яңа әдәбият: Дәреслек. Беренче басма. Наширләре: Әхмәдгәрәй Хәсәни вә шөрякәсе, Казан / Г. Ибраһимов вә Г. Баттал. – Казань: Лито-тип. И. Н. Харитонова, 1914. – 240 б.

## 1916
## Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романы басылып чыгуы хакында[1]

21 февраль 1916 ел

Йеңи китаплар

Каләмең гүзәллеге вә ифадәсенең[2] ачыклыгы илә Русиядәге төрек әдәбияты мөхибләре[3] арасында юксәк[4] бер мәүкыйг[5] казаныш мөхәррирләремездән Галимҗан әфәнде Ибраһимов «Яшь йөрәкләр» намында[6] милли бер роман нәшер итмешде[7].

Табгының нәфасәте[8] мөндәрижәтенә[9] бер кат даһа[10] гүзәллек вирмешдер. 400 сәхифәдән гыйбарәт буйлә бер роман язып нәшер итдермәк бу заманда бөек муаффәкыятьтер[11]. «Яшь йөрәкләр» мәваденә[12] даир[13] моталәгамезе[14] бер арада язарыз. Кыйммәте 1 рублә 30 капик улан бу роман бөтен мөселман көтепханәләрендә сатылмактадыр.

---

[1] «Тәрҗеман» газетасының 1916 елгы 21 февраль санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Ифадә* – аңлату.

[3] *Мөхиб* – дус, яратучы, сөюче.

[4] *Юксәк* – югары, бөек.

[5] *Мәүкыйг* – урын.

[6] *Нам* – исем.

[7] … *«Яшь йөрәкләр» намында милли бер роман нәшер итмешде* – Ибраһимов Г. Яшь йөрәкләр. Нашире: Әхмәд әл-Исхакый «Шәрык» көтепханәсе / Г. Ибраһимов.– Казань: Электро-тип. «Умид», 1912.– 416 б.

[8] *Табгының нәфасәте* – нәшер ителүнең гүзәллеге.

[9] *Мөндәриҗә* – эчтәлек.

[10] *Даһа* – тагын да.

[11] *Муаффәкыять* – уңыш.

[12] *Мәвад* – бүлекләр.

[13] *Даир* – бәйле, каралган.

[14] *Моталәга* – уку, өйрәнү, берәр мәсьәләне төрле яктан тикшереп хөкем чыгару.

## 1917

## Уфада 1917 елның беренче апреленнән чыга башлаячак «Ирек» газетасына абунә дәфтәре ачылу хакында[1]

29 март 1917 ел

Уфада беренче апрельдән чыга башлаячак «Ирек» газитәсенә абунә дәфтәре ачылды.

Газитә хәзергә атнага өч мәртәбә чыга. Бәһасе: беренче апрельдән ел ахырына кадәр – тукыз айга – 4 сум, алты айга 2 сум 50 тиен, өч айга 1 сум 50 тиен, бер айга 60 тиен. Гәзитәнең һәйяте тәхририясе: Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи, Габдерахман Фәхретдинов[2], Вагыйз Нәүрузов, Чыгтай, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Сүнчәләй әфәнделәрдән гыйбарәт.

Газитәнең мөхәррире: Галимҗан Ибраһимов.

Нашире: Фатыйх Сәйфи (Казанлы).

Идарәханә: «Сарай» номерларында[3]. Телефон № 373.

## Г. Ибраһимовның Эчке Русия һәм Сибирия мөселманнарының беренче Милләт мәҗлесенә әгъза булып килүе хакында[4]

1917 ел

Эчке Русия вә Сибирия мөселманнарыны
беренче Милләт мәҗлесенә килгән әгъзалар
...2. Галимҗан Ибраһимов.

---

[1] «Тормыш» газетасының 1917 елгы 29 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Габдерахман Фәхретдинов* – Габдерахман Ризаэтдин улы Фәхретдинов (1887–1937), журналист, тәрҗемәче. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң аклана.

[3] *«Сарай» номерларында* – хәзерге вакытта Уфада күз авырулары фәнни-тикшеренү институты биналарының берсе: Пушкин урамы, 90 йорт.

[4] «Мохтарият» журналының 1917 елгы 4 нче санында урнаштырылгын (б. 14–15). Анда Уфа, Казан, Самара, Сембер, Сарытау, Тамбов, Әстерхан, Пермь, Уральский, Акмулла-Тургай, Мәскәү, Касыйм, Вятка, Пенза, Нижгород вилаять-төбәкләреннән, 1, 2, 3, 4, 5, 8, 12, 18 нче армия, Кавказ, Җәнүби гарби фронттан барлыгы 83 әгъза теркәлгән. Г. Ибраһимов исемлектә 2 нче сан белән күрсәтелгән. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

# МӨРӘҖӘГАТЬЛӘР

## 1916
## Г. Ибраһимовның дүрт хезмәтен бастыру өчен наширләргә мөрәҗәгате[1]

22 март 1916 ел

Кәгазе бар наширләр дикъкатенә

Әүвәлге өчесе тел вә әдәбият дәреслекләреннән, соңгысы әдәби тәнкыйтьләрдән гыйбарәт булган түбәндәге дүрт әсәремне кулында кәгазе бар яки кирәк кадәрле кәгазь табып җиткерергә ышана алган наширләр дикъкатенә гарыз итәм[2]:

1) «Әдәбият кануннары»[3] (уникe табак булачак). Мөндәриҗә: татар теленең бәлягате[4], гаруз[5] һәм фәнни әдәбият – теория словесности.

2) «Татар телен ничек укытырга?»[6] (дүрт табаклар чамасында). Мөндәриҗә: мәктәп вә мәдрәсәләремездә тел вә әдәбиятны ничек вә нинди ысул белән укыту хакында методика фәненең үз телемезгә татбикъ ителгән[7] төп нәзарияләре[8] һәм гыйльми нәмүнәләр[9].

---

[1] «Тормыш» газетасының 1916 елгы 22 март санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 93–94) бастырылган. Текст газетадан алынды.

[2] *Гарыз итәм* – мөрәҗәгать итәм.

[3] *«Әдәбият кануннары»* – Ибраһимов Г. Әдәбият кануннары. Икенче басма. Нашире: «Сабах» ширкәте Казанда / Г. Ибраһимов.– Казань: Тип. т-ва «Умид», 1918.– 120 б.

[4] *Бәлягать* – матур сөйләм сәнгате.

[5] *Гаруз* – шигырь төзелеше системасы.

[6] *«Татар телен ничек укытырга?»* – Ибраһимов Г. Татар телен ничек укытырга? (Телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә). Нашире: «Сабах» ширкәте. Казан, Уфа / Г. Ибраһимов.– Казань: Типо-лит. т-ва «Умид», 1916.– 90 б.

[7] *Татбикъ ителгән* – яраклаштырылган.

[8] *Нәзарияләре* – теорияләре.

[9] *Нәмүнәләр* – үрнәкләре.

3) «Ибтидаи татар сарыфы»[1] (өч табак булачак). Бу әсәр «Татар сарыфы» вә «Татар нәхүе»нең әсаси маддәләрен[2] ибтидаи сыйныфларга махсус рәвештә бер китапка җыеп садәләштерү[3] вә гомумиләштерүдән гыйбарәттер.

4) «Татар шагыйрьләре»[4] – Икенче бүлем. Мөндәриҗәсе: мөкаддимә[5], «Яңа татар нәзымының[6] атасы», «Гомер заигъ чәчәкләре»[7] «Мөтәрҗим шагыйрь»[8], хатимә[9].

Бу әсәрләрдән әүвәлге өчесенең, бигрәк тә «Әдәбият кануннары»ның алдагы көзгә басылып чыгуы матлуб[10] булганлыктан, кәгазь мәсьәләсендә бер җай табуына ышана алган наширләр булса, түбәндәге адрес белән хәбәрләшүләрен үтенәм.

Галимҗан Ибраһимов.

Адрес: Уфа, «Мәдрәсәи Галия»

---

[1] *«Ибтидаи татар сарыфы»* – бу исемдә китап чыгуы билгеле түгел. Аның шушы китабы басылуы мәгълүм: Ибраһимов Г. Татар сарыфы. Бөтенләй яңадан эшләнгән бишенче басмасы. Нашире: «Сабах» көтебханәсе, Казан / Г. Ибраһимов.– Казань: Типо-лит. «Умид», 1917.– 52 б.

[2] *Әсаси маддәләре* – нигез кагыйдәләре.

[3] *Садәләштерү* – гадиләштерү.

[4] *«Татар шагыйрьләре» – Икенче бүлем* – Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре. Беренче бүлем. Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Габдулла Тукаев / Г. Ибраһимов.– Оренбургта «Вакыт» матбагасы, 1913.– 103 б. (Икенче кисәге исә дөнья күрмәгән).

[5] *Мөкаддимә* – кереш.

[6] *Нәзым* – тезмә әсәр.

[7] *«Гомер заигъ чәчәкләре»* – «Умырзая чәчәкләре».

[8] *«Мөтәрҗим шагыйрь»* – «Тәрҗемәче шагыйрь».

[9] *Хатимә* – бетем.

[10] *Матлуб* – соралган, теләнгән.

## Г. Ибраһимовның үзләрендә әдәби әсәрләр булган кешеләргә үтенече[1]

28 октябрь 1916 ел

Әдәбият дусларыннан бер үтенеч

Түбәндәге исемнәре аталган әсәрләрнең нөсхәләрен китапчылардан табып булмады. Хальбуки, тел вә әдәбият дәресләре укыганда, болар һәр көн диярлек шәкертләргә кирәк булмактадыр.

Һичбулмаса, һәр сыйныфка берничә нөсхә табылмасмы дип, мин һәр чыккан әсәрне җыя килгән әдәбият дусларына мөрәҗәгать итеп, кулларында шул түбәндәге әсәрләр булса, минем исемгә йибәрүләрен үтенәм.

Боларның нөсхәсен кулларыннан бөтенләй йибәрергә теләмәгән әфәнделәргә яз көне, дәресләр беткәч кайтарып йибәрүне өстемә алам, әгәр дә сатып бирергә теләсәләр, күпмешәр нөсхәдән булса да, түбәндәге бәһа бәрабәренә налож кылуларын рәҗа итәм.

Кирәк булган әсәрләр, түләнәчәк бәһа:

Каюм Насыйриның «Фәвакиһел-җөләса»[2] ун сум,

Салих Күкләшевнең[3] «Диване хикәят татар»ы[4] ике сум,

---

[1] «Тормыш» газетасының 1916 елгы 28 октябрь санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 95–96) бастырылган. Текст газетадан алынды.

Билгеле булганча, Г. Ибраһимов 1915–1917 елларда Уфада «Галия» мәдрәсәсендә тел-әдәбият дәресләре укыта. Аның бу үтенече шул вакытларга туры килә.

[2] *«Фәвакиһел-җөләса»* – Фәвакиһәл-җөләса фил-әдәбият. Мостатраф вә рузеләхйар китапларыннан интихаби тәэлиф кыйлынып кырык руза үзеренә мөрәттиб мордәдәлларның калебләрен әхйа кыйлыр бер китаптыр вә Габделкаюм мелла Габденнасыйр угылының каләм фәкыйранәсеннән җәрәян итмеш бер әсәрдер. Ошбу китап Казан университетының табыгханәсендә басма улынмышдыр 1884 нче елда.– Б. 615 б.

[3] *Салих Күкләшев* – Салихҗан Күкләшев (1811–1864), Оренбургтагы Неплюев хәрби мәктәбендә гарәп, фарсы һәм татар телләрен укытучы.

[4] *«Диване хикәят татар»* – Татарская хрестоматия, составленная Салих Джаном Кукляшевым.– Казань, в университетской типографии, 1859.– III+123 б.

Радловның[1] «Белек» мәҗмугасе[2] ике сум,

Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла»сы бер сум,

Заһир Бигиевнең «Гүзәл Хәдичә»[3] белән «Мавәраэннәһердә сәяхәт»еннән башка һәммә әсәрләр. Һәрберсенә иллешәр тиен.

Гафил ибне Габдулла (Риза казый)ның «Әсма» вә «Сәлимә»-се. Нөсхә башына иллешәр тиен.

Исмәгыйль Гаспринскийның[4] «Дарер-рәхәт»е. Нөсхәсенә илле тиеннән.

Кулында шул әсәрләрнең нөсхәләре булган затлардан минем исемемә түбәндәге адрес белән налож кылып җибәрүләрен тәкрар үтенәм.

Ихтирам илә: Галимҗан Ибраһимов

Адрес: Уфа, Электрическ[ий] переу[лок]., д. № 3.

---

[1] *Радлов* – Василий Васильевич (Фридрих Вильгельм) Радлов (1837–1918), шәркыятьче, тюрколог, тел галиме, этнограф, археолог, Петербург Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1884).

[2] *«Белек» мәҗмугасе* – Белек. Балаларга укыр өчен чыгарылган китап.– Казан университет типографиясендә басылды, 1872.– 232 б.

[3] *Заһир Бигиевнең «Гүзәл Хәдичә»* – Өлүф яки Гүзәл кыз Хәдичә: Роман. Әсәре Мөхәммәдзаһир ибне ахунд мулла Җарулла Бигиев (Басмасына рөхсәт бирелде Петербурхта 6 нчы июльдә 1887 нче елда). Басма улынмыштыр Казанда Вячеславның табыгханәсендә 1887 нче елда.– 77 б.

[4] *Исмәгыйль Гаспринский* – Исмәгыйль Мостафа улы Гаспринский (Гаспралы) (1851–1914), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, мәгърифәтче, педагог, нашир.

# ХӘБӘРЛӘР

## 1916

## Г. Ибраһимовның «Галия» мәдрәсәсендә мөгаллим булып эшләве хакында[1]

6 ноябрь 1916 ел

Уфадагы мәктәп вә мәдрәсәләрдә укучы һәм укытучыларның саны.

«Мәдрәсәи Галия»дә укучылар 120.

Мөгаллим вә мөдәррисләре Зыяэтдин әл-Камали, Хөҗҗәт әл-Хәким[2], Мөхәммәтов, Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи, Ибраһим Юманкулов[3], Багданов[4], рус теленнән Җиһанша Габдүшев.

---

[1] «Тормыш» газетасының 1916 елгы 6 ноябрь санында урнаштырылган. Анда Уфа шәһәрендәге 1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче, 6 нчы мәхәлләләрдә, «Мәдрәсәи Госмания»да, «Мәдрәсәи Галия»дә укучы шәкертләрнең санын һәм аларда кемнәр мөгаллим һәм мөдәррис булганлыгы хакында мәгълүмат китерелә. Аннан күренгәнчә, Уфада барлыгы 905 укучы укыган. Текст газетадан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Хөҗҗәтелхәким* – Хөҗҗәтелхәким Мәхмүдов (?–?), публицист, тәнкыйтьче, тәрҗемәче, шагыйрь.

[3] *Ибраһим Юманкулов* – Ибраһим Юманкулов (?–?), шагыйрь.

[4] *Багданов* – Гариф Багданов (1889–1955), педагог, тәрҗемәче.

## 1917
## Г. Ибраһимовның Госмановларның кызлар мәдрәсәсендә укытмаячагы һәм «Мәдрәсәи Галия»дә дә отпуска алуы хакында[1]

10 февраль 1917 ел

Галимҗан әфәнде Ибраһимовның истигъфа[2] һәм отпускасы

Галимҗан әфәнде бер ел «Мәдрәсәи Галия»дә дәрес укытуы өстенә Госмановлар тәрбиясендәге кызлар мәдрәсәсендә һәм земство курсларында милли тел вә әдәбият дәресләрен укытмакта иде. Яңа ел тәгътилендә[3] ул үзенең земство кызлар мәдрәсәсеннән истигъфа иткәнен газетамызда игълан иткән иде. Моннан соң кызларның үтенүләре буенча мәзкүр[4] мәдрәсәдәге укытуын дәвам иттерәчәге дә язылып үткән иде. Инде Галимҗан әфәнденең бу мәдрәсәдәге дәресләрне укытмаячагы ачык мәгълүм булды. Ул «Мәдрәсәи Галия»дән дә февраль ахырларына кадәрле отпуска алган. Госмановлар кызлар мәдрәсәсенә аның урынына тел вә әдәбият мөгаллиме бик зур тырышлыктан соң табылды. Ләкин земство курсларында бу дәресләрне укыту өчен мөгаллим табылганы юк. Бу ел анда тел вә әдәбият дәресләре укытылмый калу ихтималы бар.

Халыкның ана телен вә әдәбиятын белгән учитель һәм учительницалар чыгару максатилә ачылган курслар өчен бу хәл бик тәәссефтер[5].

---

[1] «Тормыш» газетасының 1917 елгы 10 февраль санында урнаштырылган. Моны газета үкенечле хәл дип бәяли. Текст төп нөсхәдән алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Истигъфа* – хезмәттән азат ителү, эштән китү.

[3] *Тәгътилендә* – ял вакытында (каникулда).

[4] *Мәзкүр* – күрсәтелгән, әйтелгән.

[5] *Тәәссефтер* – кызганычтыр.

## Уфада «Ирек» газетасы чыга башлаячагы хакында[1]

31 март 1917 ел

Уфада яңа гәзитә

Уфада бер кыйсым каләмнәре белән танылган мөхәррир вә җәмәгать хадимнәре тарафыннан «Ирек» исемендә яңа гәзитә чыгарырга уйлана икән[2]. Идарәмезгә алынган бер мәктүбтә бәян ителдегенә күрә, бу гәзитә хәзергә атнада өч мәртәбә чыгып торачак. Беренче нумеры апрель башларында чыгачак Мәсьүл[3] мөхәррире Галимҗан әфәнде Ибраһимов, нашире Фатыйх Сәйфи әфәндедер. Һәйәте тәхририя эчендә Габдерахман Фәхретдинов, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Гафуров әфәнделәрнең исемнәре дә зикер ителә. Һәйәте тәхририя әгъзалары үткен вә җитди каләмнәре илә танылган затлар булганлыктан, бу гәзитәнең халкымыз өчен файдалы булып җитди хезмәтләр кыйлуын өмид итәмез.

---

[1] «Вакыт» газетасының 1917 елгы 31 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] …«*Ирек» исемендә яңа гәзитә чыгарырга уйлана икән* – халык, 16 нчы саннан татар социалист-революционерлар газетасы Уфада 1917 елның 30 мартыннан 11 сентябренә кадәр нәшер ителә. Барлыгы 35 саны дөнья күрә. Аннары «Ирек», «Солдат теләге», «Авыл халкы» берләшеп, «Безнең юл» исеме белән 21 сентябрьдә беренче саны дөнья күрә. Аның мөхәррире булып Г. Ибраһимов кала.

[3] Мәсьүл – җаваплы.

## Уфа тугрысында[1]

3 май 1917 ел

«Ил» газетасы Галимҗан Ибраһимов вә Фатыйх Сәйфи әфәнделәрнең Вагыйз Нәүрузовны «Ирек» идарәсеннән чыгарганлыклары хакындагы мәктүпне басканнан соң, провокаторларның халык арасына кереп оешып барган эшләрне туздырышып йөргәнлекләрен бәян итә. Мисаллар китерә, ниһаять, Вагыйз Нәүрузовка күчеп, түбәндәге сүзләрне яза:

Вагыйз Нәүрузи хөррият вакытындагы «хезмәтне» Уфага күчергәндә анда төзелгән бер оешмага очрады. Бу оешма бөтен милли, сәяси мәсьәләләрдә Уфаның күпчелеге тарафыннан кабул ителгән һәрбер карарга хилаф хәрәкәт итә. Һәрбер эштә үзеннән бер «мөгез» чыгарырга маташа иде. Оешмага шәхси интриганы сөя торган, мания величия хасталыгы белән авырый торган һәркем кергән иде. Оешманың үзәгендә сабикъ[2] мөфти Баязитовның[3] секретарьлары Фатыйх Сәйфи, Габдерахман Фәхретдинев, военный цензор писаре Гыйлемдар Баембитов, мөхәррир Галимҗан Ибраһимовлар иде [...].

---

[1] «Тормыш» газетасының 1917 елгы 3 май санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Сабикъ* – элекке, үткәндәге.

[3] …*мөфти Баязитовның* – сүз Мөхәммәтсафа Гатаулла улы Баязитов (1885–1937) хакында бара. Ул 1915 елның 28 июлендә Оренбург мөселманнар Диния нәзарәте мөфтие итеп билгеләнә һәм 1917 елның 22 мартында Вакытлы хөкүмәт аны бу вазифадан азат итә. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе.

## Г. Ибраһимовның Бөтенрусия мөселманнарының икенче съездын тәбрикләү хакында[1]

25 июль 1917 ел

...Һади Максуди – «Йолдыз» исеменнән, Галләм Сөендеков – казачий мөселманнар исеменнән, Хәбибрахман Зәбири – «Милли фонд» исеменнән, Зиннәтулла әфәнде – Дон хузасындагы[2] эшчеләр исеменнән, Хафиз Янгулатов – Төркестан татарлары исеменнән, [Г.] Баттал – «Корылтай» исеменнән, Хәсәнгата хәзрәт Габәши – голәма исеменнән, Галимҗан Ибраһимов – татар социалист матбугаты исеменнән, Фуад Туктаров – Мөселман комитеты исеменнән, Мулланур Вахитов – социалистлар исеменнән, Йосыпов – бохаралылар исеменнән, Рауза ханым Солтангалиева – мөслимәләр вәкиле исеменнән, Гомәр Галәви – мәркәзи укытучылар бюросы исеменнән, Зәкәрия Садретдинов – җәмгыяте хәйрия в «Кояш» газетасы исеменнән, Әхмәтҗан Мостафин – Казан укытучылары исеменнән корылтайны тәбрик итәләр...

---

[1] «Кояш» газетасының 1917 елгы 25 июль санында урнаштырылган. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2017.– Т. 1.– С. 278» дигән җыентыкта бастырыла. Текст соңгы чыганактан алынды.

[2] *Дон хузасындагы* – Донбасс бассейнындагы.

## Г. Ибраһимовның Бөтенрусия мөселманнарының икенче съездында революционный комиссиягә сайлануы хакында[1]

2 август 1917 ел

...Корылтайда каралачак мәсьәләләр 8 маддә булып,ниләрдән гыйбарәт идеке Беренче мәҗлес хакында язылган мәкаләдә зикер ителгән иде. Менә шул мәсьәләләр хакында төрле урыннардан килгән докладларны тикшереп, гомуми мәҗлескә гарыз кылыр өчен биш шөгъбә (секция) ясалды:

1. Милли мохтарият шөгъбәсе.
2. Нәшрият шөгъбәсе.
3. Малия[2] шөгъбәсе.
4. Милли тәшкиләт шөгъбәсе.
5. Хат-хәрәкәт, ягъни Учредительный собраниегә хәзерлек шөгъбәсе.

Бу шөгъбәләргә язылган кешеләр һәркөн өйләдән соң сәгать 4 тән 10 га кадәр махсус урыннарга җыелып эшләргә булдылар. Буннан башка янә революционный, финансовый, ревизионный исмилә өчәр комиссия ясалырга карар бирелде: революционный комиссиягә: Биньямин Әхтәмов, Гомәр Терегулов, Фуад Туктаров, Г. Ибраһимов; малия комиссиясенә: Исмәгыйль Рәмиев, Гали Әсәдуллаев, Заһид Шамуил, Янбулатов, Таҗетдинов әфәнделәр сайланды; тәфтиш[3] комиссиясенә әгъзалар сайлау хәзергә ачык калдырылды...

---

[1] Беренче мәртәбә Х. Әхтәмов тарафыннан «Вакыт» газетасының 1917 елгы 2 август санында бастырылган «Русия мөселманнарының гомуми съезды» исемле мәкаләсендә китерелә. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2017.– Т. 1.– С. 280–281» дигән җыентыкта бастырыла. Текст соңгы чыганактан алынды.

[2] Малия – финанс.

[3] *Тәфтиш – тикшерү, ревизия.*

## Г. Ибраһимовның Бөтенрусия мөселманнарының икенче съездына вәкил булып катнашуы хакында[1]

8 август 1917 ел

Бөтенрусия мөселманнарының икенче съездына[2] катнашкан вәкилләр

Бөтенрусия мөселманнарының Казанда булган икенче съездына түбәндәге шәһәр вә губерналардан ошбу вәкилләр килгәннәр иде... Уфа губернасыннан вә шәһәреннән:... Ибраһимов Галимҗан...

## Г. Ибраһимовның Татар социалист-революционерлар оешмасының Вакытлы мәркәз комитетына әгъза итеп сайлануы хакында[3]

11 август 1917 ел

...Вакытлы бу комитетка әгъза итеп түбәндәге җиде кеше сайланды:

1. Галимҗан Ибраһимов.
2. Шәриф Сүнчәләй.
3. Фатыйх Сәйфи [Казанлы].
4. Гаскәри шура рәисе Исмәгыйль Рәмиев.
5. Прапорщик Мөхетдин Әхмәрев.
6. Крестьяннар шурасының башкаручы комитетында әгъза Дәүкәев һәм Галимҗан Әминев...

---

[1] «Корылтай» газетасының 1917 елгы 8 август санында урнаштырылган. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2017.– Т. 1.– С. 254–256» дигән җыентыкта бастырыла. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Бөтенрусия мөселманнарының икенче съезды 1917 елның июль-август айларында Казанда үткәрелә. Анда Уфа губернасыннан сайланган 29 делегат арасында Г. Ибраһимов та була.

[3] Беренче мәртәбә «Ирек» газетасының 1917 елгы 11 август санында бастырылган «Татар социалист-революционерлар оешмасының Вакытлы мәркәз комитеты төзелде» исемле мәкаләдә китерелә. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2017.– Т. 1.– С. 254–256» дигән җыентыкта бастырыла. Текст соңгы чыганактан алынды.

## Вилаять мәҗлесе. Карар[1]

1 ноябрь 1917 ел

Блок тарафыннан төзелгән спискәдән[2]:
... Галимҗан Ибраһимов...

## Вилаять мәҗлесе хисабы[3]

5 ноябрь 1917 ел

Уфада октябрь 8 дән 30 га кадәрле Бөтенвилаять мөселман вәкилләренең гомуми җыелышы булды.

Октябрь 30.

Иртәнге мәҗлес Художество театрында сәгать 11 дә Галимҗан Ибраһимов риясәтендә ачыла.

...32 әгъза сайлау мәсьәләсе мөзакәрә ителеп, тәнасыйб ысулынча, ягъни спискәләр буенча сайлау кабул кылына...

...Икенче номерга тавыш күп бирелгән. Алардан Милләт мәҗлесенә әгъза булып түбәндәге 17 (унҗиде) кеше үтә.

...2. Галимҗан Ибраһимов.

---

[1] «Тормыш» газетасының 1917 елгы 1 ноябрь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Блок тарафыннан төзелгән спискәдән* – 1917 елның 30 октябрендә ачылган икенче мәҗлестә блок тарафыннан төзелгән исемлектә 16 депутат сайланган.

[3] «Безнең юл» газетасының 1917 елгы 5 ноябрь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Г. Ибраһимовның Учредительный собраниегә Русиядәге мөселманнар тарафыннан кандидат итеп күрсәтелүе хакында[1]

16 ноябрь 1917 ел

Хәзер инде һәр йирдә Учредительный собраниегә сайлау өчен кандидат фиһристләре[2] күрсәтү тәмам булып бетте. Ләкин бу араларда төрле урыннарда булган чуалулар һәм почта эшләмәү сәбәпле, кай йирдәге мөселманнарның кемнәрне кандидат итеп күрсәткәнлекләре мәгълүм түгел иде. Хәзер газеталар килә башлаганнан соң, күп урыннарның игълан иткән фиһристләре мәгълүм булды.

Казан шәһәрендә мөселманнарның кемнәрне кандидат итеп күрсәткәнлекләре мәгълүмдер.

Башка йирләрдәге мөселманнардан күрсәтелгән кандидатларның безгә мәгълүм булганнар хәзергә ошбулардыр:

...Уфадагы социалистлар тарафыннан: 1) Галимҗан Ибраһимов, 2) Шәриф Сүнчәләй, 3) Гыйззәтулла Ильясов, 4) Әхмәтдин Мөхетдинов, 5) Мөхетдин Әхмәров, 6) Шәехгаттар Солтанов, 7) Һади Сәгъдиев, 8) Әхмәтшәфикъ Сәлимҗанов, 9) Хәйревәри Гыйсмәтуллин...

---

[1] Беренче мәртәбә «Йолдыз» газетасының 1917 елгы 16 ноябрь санында бастырыла. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З. С. Миннуллин; науч. ред.: Р. Р. Фахрутдинов, Р. Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2017.– Т. 1.– С. 420–421» дигән җыентыкта кителә. Текст соңгы чыганактан алынды.

[2] *Фиһристләре* – исемлекләре; Уфа мөселман социалистларыннан барлыгы 9 кеше теркәлгән.

# АВТОГРАФЛАР
## 1910
### Әнисе Бибихәсәнәгә[1]

Октябрь 1910 ел

Хөрмәтле анама гаҗизанә бер ядкяр уларак тәкъдим итәм: Галимҗан.

1910 – октябрь.

## 1912
### Гыйбадулла Алпаровка[2]

23 февраль 1912 ел

Иптәшем Гыйбадулла Алпаров әфәндегә ядкяр ителде.
Галимҗан.
1912 – февраль 23. Казан

### Әхмәтгәрәй Хәсәнигә[3]

Декабрь 1912 ел

Иптәшем Әхмәтгәрәй Хәсәни әфәндегә ядкяр.
Галимҗан.
1912 – декабрь.
Казан

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимов, абыйсы Шакирҗан Ибраһимов (1884–1961) һәм дусты Шәһит Әхмәдиев (1888–1930) белән бергә төшкән фотоның икенче ягына язылган. Латин хәрефләре белән язылган мондый язулар да бар: «1910 – ел үктәбердә Казанда алынган рәсем». Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән (Казан, 2000, б. 68), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Төп нөсхә кайда икәнлеге мәгълүм түгел. Фотокүчермәсе Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның «Сөю-сәгадәт (Карт шагыйрьнең тәэсораты)» (Казан, 1912) хикәясе китабының титул битенә язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 68), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст фотокүчермәдән алынды.

[3] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның Васита ширкәте почта открыткасы итеп эшләткән фотосының икенче ягына язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 81), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

## 1913
## Абзыйсы Шакирҗан Ибраһимовка[1]

Март 1913 ел

Борадәр газизем Шакирҗан әфәнде җәнабләренә ядкяр итәм: Галимҗан.

1913 – Киев – март

## Шәһит Әхмәдиевкә[2]

Декабрь 1913 ел

Иптәшем Шәһит Әхмәдиевкә ядкяр итәм.

Галимҗан. Казан – декабрь – 1913.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның яшь вакытта алдырган фотосының икенче ягына язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 73), аннан соң «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, аннан соң «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] Төп нөсхә Татарстан Республикасының Милли музеенда саклана (122214–20). Ак эшләпә, плащ-накидка киеп төшкән фотосыннан ясатылган почта открыткасының икенче ягына гарәп хәрефләре белән язылган. Аның нәкъ бу сурәте үзе төзеп бастырган «Санаигы нәфисә мәҗмугасы»ндагы күмәк фотода да бар: Альбом (Санаигы нәфисә мәҗмугасы). Санаигы нәфисә сөючеләргә. «Аң» нәшере.– Казань: Тип. И. Н. Харитонова, 1915.– Б. 32: (уңнан сулга) Гаяз Исхакый (1878–1954), Сәгыйть Рәмиев (1880–1926), Шәриф Манатов (1887–1936), Галимҗан Ибраһимов. Рәсемнең 1913 елның җәй аенда алдырылуы язылган. Текст төп нөсхәдән алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## 1914
## Туганы Мохтар Ибраһимовка[1]

Август 1914 ел

Мохтар[2] иптәш,

Дәүләкәндә[3] хозур үткәрелгән берничә көн хатирәсе итеп моны һәдия итәм. Ләкин бер шарты бар: син яхшы рәсемнәреңнән берсен миңа бирергә тиеш.

Галимҗан. –

1914 – август.

Дәүләкән

## 1916
## Туганы Мотаһар Ибраһимовка[4]

20 декабрь 1916 ел

Кадерле дустым Мотаһар Ибраһимовка[5] ядкяр: Галимҗан.

1916 – декабрь 20 – Уфа.

---

[1] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның почта открыткасы итеп эшләтелгән фотосының икенче ягына язылган. Беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының 1963 елгы 1 нче санында, аннан соң «Г. Ибраһимов турында истәлекләр»дә (Казан, 1966, б. 17), Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 88), «Галимҗан Ибраһимов: Мәкаләләр, истәлек-хатирәләр»дә (Казан, 2007, б. 56), «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[2] *Мохтар Вилдан улы Ибраһимов (1885–1969)* – Г. Ибраһимовның туганнан туган кардәше (Вилдан Гыйрфанның бертуган энесе). Ул әлеге автограф тарихы турында үзенең «Туганым турында» дигән истәлегендә этрафлы аңлата (Совет әдәбияты.– 1963.– № 1.– Б. 119–120).

[3] *Дәүләкән* – хәзерге Башкортстан Республикасындагы шәһәр.

[4] Төп нөсхә Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Автограф Г. Ибраһимовның Уфада яшәгән вакытында алдырылган фотосының икенче ягына язылган. Беренче мәртәбә «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, аннан соң «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

[5] *Мотаһар Ибраһимов* – Мотаһар Вилдан улы Ибраһимов (1893–1975), педагог, әдипнең туганнан туган кардәше.

## Г. Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи-Казанлы Уфада Зыяэтдин әл-Кәмалига[1]

[26] декабрь 1916 ел

Хөрмәтле мөфәссир Зыяэддин әл-Кәмали хәзрәтләре.

Русия мөселманнары арасында Коръәннең саф һәм дөрест рухын аңлату юлында кылган хезмәтләреңезгә унъеллык бәйрәм мөнәсәбәте белән бу олуг китапны җәнабеңезгә һәдия итәмез[2].

Мәдрәсәи галиәи диниәнең һәйәте тәгълимиә әгъзаларыннан: Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи (*Имзалар*). 1916, декабрь. Уфа.

---

[1] Төп нөсхә, чыганакларда хәбәр ителгәнчә, Башкортстанның халык шагыйре (1964) Сәйфи Кудашның (Сәйфетдин Фәттахетдин улы Кудашевның) (1894–1993) шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 97), аннан соң «Тулпар» журналының 2013 елгы 1 нче (б. 69), «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивындагы фотокүчермәдән алынды.

Мәгълүм ки, 1916 елның 26 декабрендә Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенең унъеллык юбилее билгеләп үтелә. Бу уңай белән әлеге уку йортын нигезләгән һәм гамәлгә куйган Зыяэтдин әл-Кәмалиның (Пәрвәзетдин Кәмалетдин улы Зыятдиновның, 1873–1942) эшчәнлеге югары бәяләнеп, аңа бирелгән бүләкләр арасында әлеге автографлар язылган Коръән дә бар.

[2] *Һәдия итәмез* – бүләк итәбез.

## Г. Ибраһимов, Гыйниятулла Терегулов, Фатыйх Сәйфи, Закуан Богданов, Ибраһим Юманкулов Уфада Зыяэтдин әл-Кәмалига[1]

26 декабрь 1916 ел

Русия мөселман агарту юлында олуг хезмәтләр кылган мөхтәрәм Зыяэддин әл-Кәмали җәнабләренә Мәдрәсәи галиәнең һәйәте тәгълимиәсе тарафыннан:

Мөхтәрәм мөдәррис!

Бөтен ислам дөньясын каплап алган авыр кара төн үтеп, һәр тарафта, шул җөмләдән Русия мөселманнары эчендә дә, яңы якты мәдәни бер хәят эзләнү башланган, халкымызның һәр сыйныфы, бигрәк тә яшьләр, борынгы мәдрәсәләрне ташлап, сахрада адашкан юлчылар кеби кая барырга, йөрәкләрендәге гыйлемгә сусауны ни белән кандырырга гаҗиз булган бер дәвердә Сез үзегезнең бетмәс-төкәнмәс иҗтиһадыңыз, мисалы булмаган тәвәккәллегеңез белән һич юктан Мәдрәсәи галиәи диниә кебек олуг бер гыйлем йорты вөҗүдкә китереп, гыйлемгә, тәрбиягә сусаган яшьләргә зур нәдәмәт иттеңез. Борынгы ысул белән гакыллары богауланган, фикерләре туңган татар яшьләренә киң уй бирдеңез, шәхсыятьләрен кысынкы җир астыннан чыгардыңыз һәм шул яшьләргә халкымызның иң караңгы почмакларына таралган киләчәк хәятнең хуҗалары, булачак меңнәрчә балаларның аң вә тәрбияләренә билвасыйт[2] хезмәт иттеңез. Тәңренең бик бәхетле колларына гына насыйп була торган бу олуг хезмә-

[1] Төп нөсхә, чыганакларда хәбәр ителгәнчә, Башкортстанның халык шагыйре (1964) Сәйфи Кудашның (Сәйфетдин Фәттахетдин улы Кудашевның) (1894–1993) шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 96–97), аннан соң «Тулпар» журналының 2013 елгы 1 нче (б. 69), «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивындагы фотокүчермәдән алынды.

Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенең унъеллык юбилее уңаеннан Зыяэтдин әл-Кәмалига бирелгән бүләкләр арасында янә әлеге автографлар язылган тәбрикнамә дә бар. Бу хакта Самад (Самад Шәрәфетдинов) исемле авторның «Тормыш» газетасының 1917 елгы 3 гыйнвар санында бастырган «Мәдрәсәи галиә»нең ачылуына ун ел тулу мөнәсәбәте белән булган мәҗлес» дигән мәкаләсендә болай хәбәр ителә: «Галимҗан әфәнде сүзен Зыяэтдин әл-Кәмали хәзрәтне тәбрик итү белән тәмам итте вә аңар һәйәте тәгълимия исеменнән адрес тәкъдим итте вә бер Коръән һәдия кылды».

[2] *Билвасыйт* – арадашлык белән.

теңез белән Сезне тәбрик итәбез һәм авыр язмышлы, кайгылы халкымызның алдагы бәхет бинасын төзү өчен тагы күп еллар хезмәт итүеңезне бер Аллаһыдан телибез.

Мәдрәсәи галиәи диниәнең һәйәте тәгълимиәсе әгъзаларыннан: Галимҗан Ибраһимов, Гыйниятулла Терегулов[1], Фатыйх Сәйфи, Закуан Богданов, Ибраһим Юманкулов (*Имзалар*). 1916 нчы сәнә, 26 нчы декабрь.

---

[1] *Гыйниятулла Терегулов* – Гыйниятулла Нигъмәтулла улы Терегулов (1891–1984), терапевт, медицина фәннәре докторы (1940), профессор (1940), Башкорт АССРның атказанган фән эшлеклесе (1944).

## 1917
## Вәсфи Гыйльмияровка[1]

Август 1917 ел

1) Кем ыңгырашса, шуңа ярдәм кулын суз!
2) «Мин үзем өчен яшәмәдем һәм яшәмәм!»
3) Хәзерге көнлек теләгемез – федерация, йиргә социализация[2] һәм барча инсаннарның innirекле, тигез, бәхетле булуларыдыр.
Галимҗан
(Галимҗан Ибраһимовтан)

## «Тугры, гомуми, тигез, яшерен һәм мөтәнасыйп сайлауга нигезләнгән Учредительный собрание» дигән китапта[3]

Татар әдәбияты җәмгыяте рәисе: (*имза танылмый*)
Татар әдәбияты хадимнәренең Үзәк союзының председателе: (*Галимҗан Ибраһимовның имзасы*)
Секретарь: (*имза танылмый*)
Эш йөртүче: (*имза танылмый*)

---

[1] Төп нөсхә хәзерге вакытта кайда икәнлеге мәгълүм түгел. Фотокүчермәсе Ә. А. Шамованың шәхси архивында саклана. Беренче мәртәбә факсимилесе «Кызыл таң» газетасының 1967 елгы 11 март, аннан соң тексты төп нөсхәнең фотокүчермәсе буенча «Казан утлары» журналының 1987 елгы 3 нче саннарында, Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 98), «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырылган. Текст фотокүчермәдән алынды.

Бу автографның хакында А. Шамов «Казан утлары» журналында шундый тарих китерә: «1917 елның августында укытучы Вәсфи Гыйльмияров, Г. Ибраһимовны Бирск шәһәренә бара торган Агыйдел пароходында очратып, аңардан хатирә итеп бер-ике сүз язып бирүен үтенә һәм аңа кулындагы блокнотын суза. Әдип шундук аңа күңелендәге өч фикерне язып бирә».

«Кызыл таң» газетасында дата 1918 ел дип күрсәтелгән.

[2] *...йиргә социализация...* – бу эсерлар фиркасе лозунгысы, чөнки ул вакытта Г. Ибраһимов большевиклар фиркасе әгъзасы булмый.

[3] Төп нөсхә Казанда тарих фәннәре кандидаты, доцент Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллинның (1953–2019) шәхси архивында саклана (Казан, 1917, б. 29). Беренче мәртәбә «Кызыл таң» газетасының 2017 елгы 9 февраль, аннан соң «Мәдәни җомга» газетасының 2017 елгы 17 февраль саннарында бастырыла. Текст төп нөсхәдән алынды.

# КОТЛАУЛАР

## 1913

## Әхмәтгәрәй Хәсәни һәм Г. Ибраһимовның «Аң» журналына язышучыларны, язучыларны, басманы алдыручыларны һәм барлык укучыларны Корбан бәйрәме уңае белән котлавы[1]

27 октябрь 1913 ел

Зур Корбан бәйрәме белән «Аң»ның барлык язучыларыны, мөхәррирләрене, мөштәриләрене[2] вә бөтен укучыларыны чын күңелдән котлыйм.

Әхмәтгәрәй Хәсәни.

Юлдашымызны бәйрәм белән тәбрик итәм: Галимҗан Ибраһимов.

---

[1] «Аң» журналының 1913 елгы 21 нче санында (алгы тышлыкта) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Мөштәриләрне* – матбугатны яздырып алучыларны.

# V

# СОВЕТ ЧОРЫ ДОКУМЕНТЛАРЫ

## ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ДОКУМЕНТЛАР

### 1918

### Делегатский билет Г. Г. Ибрагимова на 3-й Всероссийский съезд Советов рабочих и солдатских депутатов[1]

[10 января] 1918 г.

Делегатский билет № 846

Предъявитель сего тов[арищ] Ибрагимов Галимжан Гирфанович делегат от Уфимской губ[ернии], член Учредит[ельного] собрания действительно состоит членом 3-го Всероссийского съезда Советов р[абочих] и с[олдатских] д[епутатов].

Подписали: предс[едатель] манд[атной] комиссии (*подпись неразборчива*).

Член Организац[ионной] комиссии (*подпись неразборчива*)

Секретарь ЦИК: В. Аванесов[2].

*Печать ВЦИК*

---

[1] Күчермә (машинкада язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (292 ф., 2 тасв., 1987 эш, 31 кәг.). «Г. Ибрагимов № партбилета 34827. 1923 года Казань. В Казанский городской районный комитете РКП(б). Копии с документов (для автобиографии. По требованию райкома» дип язылган тупланмада. Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 271). Текст күчермәдән алынды.

[2] *В. Аванесов* – Варлаам Александрович Аванесов (1884–1930), совет дәүләт эшлеклесе, 1917–1919 елларда БҮБК Президиумы әгъзасы һәм сәркятибе.

## Соглашение между Национальным собранием (Миллят-Меджлиси) и башкирами[1]

14 января 1918 г.

Вслед за тем, как Национальное собрание, приняв постановление об образовании «Волго-Уральского штата», избрало комиссию территориальной автономии, Галимджан эфенде Ибрагимов был отправлен в Оренбург на башкирский курултай. Того следствие: избрав комиссию из 10-ти человек, курултай решил направить ее в Уфу для переговоров с комиссией Национального собрания [по вопросам] территориального самоуправления...

[1] Беренче мәртәбә «Тормыш» газетасының 1918 елгы 14 гыйнвар санында дөнья күрә. Аннан соң рус телендә тәрҗемәсе «Национально-государственное устройство Башкортостана (1917–1925 гг.). Документы и материалы: в 4 т.– Уфа: Китап, 2002.– Т. 1.– С. 255–257» дигән җыентыкта, «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин, Р.Д. Шарафиева; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2019.– Т. 2.– С. 23–25» исемле китапта бастырыла. Текст соңгы чыганактан алынды.

## Выписка из газеты «Шуро» № 10 от 14 января 1918 г. стр. 4[1]

В день открытия Учредительного Собрания присутствовало девять депутатов мусульман, образовавших социалистическую фракцию. Народные комиссары предложили в первую очередь декларацию советской власти о земле, мире и другие внесенные от центрального комитета вопросы. Эсеры предложили вопросы о мире, земле, форме государственного управления, мирной делегации. Прошло предложение эсеров. Это вызвало требование большевиков и левых эсеров выяснить отношение к советской власти. Отклонение немедленного обсуждения вопроса вызвало протест и уход большевиков и левых эсеров, в отсутствие которых собрание провозгласило федеративную республику, приняло социализацию земли, постановило немедленно приступить к ведению мирных переговоров, приняло перемирие. Мусульманская делегация осталась в зале заседания. Присоединился к ушедшим большевикам, левым эсерам Галимджан Ибрагимов. Фракция огласила свою декларацию. Сегодня Учредительное Собрание распущено. Члены фракции Ахмед Цаликов, Сюнчелеев, Ибрагимов, Туктаров, Мухамедиаров, Мухаметдинов, Ильясов, Ахмеров, Салехов.

[1] Күчермә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (36 ф., 1 тасв., 232 эш, 15 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә тәкъдим ителә.

## Членский билет ВЦИК Г. Г. Ибрагимова[1]

[15 января] 1918 г.

Членский билет ВЦИК № 118

Всероссийский Центральный Исполнительный Комитет Советов рабочих, крестьянских, солдатских и казачьих депутатов.

Предъявитель сего тов[арищ] Ибрагимов Галимжан Гирфанович избран III Всероссийским съездом Советом в члены Центрального Исполнительного Комитета Советов рабочих, солдатских, крестьянских и казачьих депутатов сроком от 15 января по 18-е апреля 1918 г[ода].

Подписали: председатель: Я. Свердлов[2].

Секретарь Аванесов.

Печать ВЦИК и фотограф[ическая] карт[очка] с подписью Г. Ибрагимова.

---

[1] Күчермә (машинкада язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (292 ф., 2 тасв., 1987 эш, 31 кәг.). «Г. Ибрагимов № партбилета 34827. 1923 года Казань. В Казанский городской районный комитете РКП(б). Копии с документов (для автобиографии. По требованию райкома» дип язылган тупланмада. Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 271–272). Текст күчермәдән алынды.

[2] *Я. Свердлов* – Яков (Янкель) Михайлович Свердлов (партия тәхәллүсе – Андрей, Макс һ.б.), Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте эшлеклесе, 1918 елның 8 (21) ноябрендә БҮБК рәисе итеп сайлана.

## Декрет
## Совета Народных Комиссаров[1]

17 (30) января 1918 г.

Учреждается Комиссариат по делам мусульман внутренней России при Народном комиссариате по национальным делам.

Комиссаром по делам мусульман назначается член бывшего Учредительного собрания от Казанской губернии Мулла-Нур Вахитов, товарищами его – члены бывшего Учредительного собрания от Уфимской губ[ернии] – Галимзян Ибрагимов и от Оренбургской губ[ернии] – Шариф Манатов.

Председатель Совета Народных Комиссаров
В. И. Ульянов (Ленин)
Народный комиссар по делам национальностей
Джугашвили-Сталин
Управляющий делами правительства Вл. Бонч-Бруевич[2]
Секретарь Совета Народных Комиссаров
Н. Горбунов[3]

---

[1] Беренче мәртәбә «Сборник узаконий»ның 1918 елгы 17 нче санында, аннан соң «Газета Временного Рабочего и Крестьянского правительства»ның 1918 елгы 19 гыйнвар санында, «Известия» газетасының 1918 елгы 21 гыйнвар санында, «Знамя революции» газетасының 1918 елгы 27 гыйнвар санында, «Вестник Научного общества Татароведения»нең 1925 елгы 3 нче санында (б. 29), «Декреты Советской власти»ның 1957 елгы 1 нче томында (б. 367), «Образование Башкирской Автономной Советской Социалистической Республики. Сборник документов и материалов»та (Уфа, 1959, с. 85–86), «В. И. Ленин и Татария: Сборник документов, материалов и воспоминаний»ның төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басмасында (Казан, 1970, б. 49–50), шул ук китапның 1990 елгы басмасында (б. 94–95), «В. И. Ленин в Башкирии. Документы, материалы, воспоминания» китабында (Уфа, 1974, б. 98) бастырылган. Текст «В. И. Ленин и Татария: Сборник документов, материалов и воспоминаний»ның төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басмасыннан алынды (Казан, 1970).

[2] *Вл. Бонч-Бруевич* – Владимир Дмитриевич Бонч-Бруевич (1873–1955), дәүләт һәм партия эшлеклесе, тарих фәннәре докторы.

[3] *Н. Горбунов* – Николай Петрович Горбунов (1892–1937), дәүләт эшлеклесе, совет чоры фәнен оештыручыларның берсе, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1935).

## Пропуск Г. Ибрагимова для прохода в помещение Временного рабоче-крестьянского правительства в Смольном институте[1]

20 января 1918 г.

Управление делами Временного рабо[че]-крест[ьянского] правительства

Петроград, 20 января 1918, Смольный институт

Пропуск № 231

Выдан Ибрагимову, товарищу Комиссара по делам мусульман сроком на 1-е марта 1918 г[ода] на право свободного прохода в помещение Временного рабоче-крест[ьянского] правительства в Смольном институте.

Управ[ляющий] делами правит[ельства]: Вл. Бонч-Бруевич.

Секретарь Совнаркома (*подпись неразборчива*).

Печать Управ[ляющего] делами.

## Указание комиссару-матросу при главном телеграфе о допуске к аппарату Г. Ибрагимова[2]

1 февраля 1918 г.

Председатель народных комиссаров

1-го февраля 1918 г[ода], Петроград

Комиссару-матросу при главн[ом] телеграфе.

Прошу Вас, товарищ Комиссар, допустить к аппарату товарища Ибрагимова для разговора с Казанью и Уфой.

Нарком Сталин.

---

[1] Күчермә (машинкада язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (292 ф., 2 тасв., 1987 эш, 31 (икенче ягы) кәг.). «Г. Ибрагимов № партбилета 34827. 1923 года Казань. В Казанский городской районный комитете РКП(б). Копии с документов (для автобиографии. По требованию райкома» дип язылган тупланмада. Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 272). Текст күчермәдән алынды.

[2] Күчермә (машинкада язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (292 ф., 2 тасв., 1987 эш, 31 (икенче ягы) кәг.). «Г. Ибрагимов № партбилета 34827. 1923 года Казань. В Казанский городской районный комитете РКП(б). Копии с документов (для автобиографии. По требованию райкома» дип язылган тупланмада. Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 272). Текст күчермәдән алынды.

## Казанда уздырылган Икенче Бөтенроссия мөселман хәрбиләре съездында фракциялар турында «Безнең тавыш» газетасында мәгълүмат[1]

19 февраль 1918 ел

...Мәзкүр фракциянең башында Нигъмәтулла Еникиев, Исмәгыйль Рәмиев, Атнагулов, Ягъкуб Байков әфәнделәр торадыр ки, боларның икесе Галимҗан әфәнде Ибраһимовка, калган икесе Беренче Сибирский армейский корпусның военный революционный комитетында һәм мөселманнар тарафыннан сайланган әгъзалар булганга, кемнәр идеге ап-ачык беленсә кирәк. Бу фракциянең башында Ильяс Алкин тора дию чеп-чи ялган һәм ифтирадыр[2]. Ильяс Алкинга әүвәлән андый былчыракларны ыргыту хаксыз, икенчеләй ул фракциядә Ильяс Алкин юктыр. Ул фракцияне белми, фракция аны белмидер. Бу фракциядә уңнар һәм тылдан килгән берничә генә вәкилләр дию дәхи хакыйкатьтән чыгып әйтелгән бер сүздер ки, фракциянең 127 кешесе улып, күбесе фронттан килгән вәкилләрдән гыйбарәттер...

---

[1] Беренче мәртәбә мәгълүмат «Безнең тавыш» газетасының 1918 елгы 19 февраль санында «Бәләбәй солдаты «Ни» псевдонимлы авторның «Хаклык кирәк» дигән мәкаләсендә дөнья күрә. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин, Р.Д. Шарафиева; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2019.– Т. 2.– С. 117–119» исемле китапта бастырыла. Текст соңгы чыганактан алынды.

[2] *Ифтира* – яла ягу.

## Протокол заседания Главной коллегии Комиссариата по делам мусульман Внутренней России[1]

7-го марта 1918 г. в городе Петрограде

Председательствовал тов. Мулланур Вахитов. Присутствовали члены Коллегии: Галимджан Ибрагимов, тов. Гали Кильдибяков[2].

Слушали:

1. О Казанских событиях.

Постановили:

3. Отклонить предложение тов. Галимджана Ибрагимова о командировании его в Казань с информационной целью и принять предложение тов. Вахитова и тов. Кильдибякова о командировании в Казань тов. Каспранского в качестве курьера со специальными поручениями.

Председатель: Вахитов.
Члены: Кильдибяков, Ибрагимов.

[1] Беренче мәртәбә «Первый год пролетарской диктатуры в Татарии (Сборник документов и материалов по истории парторганизации и гражданской войны в 1918 г.).– Казань: Татаргосиздат, 1933.– С. 45» дигән җыентыкта, аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин, Р.Д. Шарафиева; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2019.– Т. 2.– С. 152–153» исемле китапта бастырыла. Текст соңгы чыганактан алынды.

[2] *Гали Кильдебяков* – Мөхәммәтгали Нурмөхәммәт улы Килдебәков (1881–1949) – журналист, язучы, 1918–1919 елларда – Эчке Россия мөселманнары эшләре буенча комиссариатның матбугат бүлеге мөдире.

## Пропуск Г. Ибрагимова для прохода в помещение Временного рабоче-крестьянского правительства[1]

22 марта 1918 г.

Управ[ление] делами рабо[че]-крест[ьянского] правит[ельства]

Москва, 22 марта 1918 г[ода]

Пропуск № 141

Выдан т[оварищу] Ибрагимову, тов[арищу] Комиссару по делам мусульман сроком на 1-е июня 1918 г[ода] на право свободного прохода в помещение рабоч[е]-крест[ьянского] правительства.

Управ[ляющий] делами правит[ельства]: Вл. Бонч-Бруевич.

За секретаря Совнаркома: Озеревская.

---

[1] Күчермә (машинкада язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (292 ф., 2 тасв., 1987 эш, 31 (икенче ягы) кәг.). «Г. Ибрагимов № партбилета 34827. 1923 года Казань. В Казанский городской районный комитете РКП(б). Копии с документов (для автобиографии. По требованию райкома» дип язылган тупланмада. Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 273). Текст күчермәдән алынды.

# Положение
# о Татаро-Башкирской Советской Республике
# Российской Советской Федерации[1]

22 марта 1918 г.

Исходя из принципа национального самоопределения трудовых масс, утвержденного III Всероссийским съездом Советов, Народный Комиссариат по делам национальностей, в согласии с Комиссариатом по делам мусульман Средней Азии России, выработал следующее положение о Татаро-Башкирской Советской республике.

1. Территория Южного Урала и Среднего Поволжья объявляется Татаро-Башкирской Советской республикой Российской Советской Федерации.

2. При определении границ в основу кладется проект, разработанной башкирскими и татарскими революционными организациями (вся Уфимская губ[ерна], башкирская часть Оренбургской губернии, Казанской губ., за исключением чувашско-черемесской части, и прилегающие мусульманские части Пермской, Вятской, Симбирской и Самарской губерний). Окончательное установление границ республики предоставляется Учредительному съезду Советов этой республики.

---

[1] Беренче мәртәбә «Сборник узаконий»ның 1918 елгы 30 нчы санында (б. 394), аннан соң «Известия Всероссийского Центрального Исполнительного Комитета Советов»ның 1918 елгы 24 (11) санында, «Чулпан» газетасының 1918 елгы 30 мартында (татар һәм рус телләрендә), «Образование Башкирской Автономной Советской Социалистической Республики. Сборник документов и материалов» (Уфа, 1959, с. 138), «Образование и государственно-правовое положение Татарской АССР» (Казань, 1960, ч. 1 (1917–1925 гг.), с. 23–24), «Мулланур Вахитов: Жизнь и деятельность пламенного революционера-ленинца» (1985, с. 52–53), Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 273–274) дигән китап-җыентыкларда бастырылган. Текст соңгы чыганактан алынды.

Татар-Башкорт җөмһүрияте Милләт мәҗлесенең Идел-Урал Штатын төзүгә каршы РСФСР составында татар һәм башкорт милли дәүләтчелегенең фаразланган формасы. Оештыру съездын ачу Уфа шәһәрендә 1918 елның 13 сентябренә билгеләнә, ләкин ул булмый кала. 1919 елның 23 мартында мөстәкыйль Башкорт Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү сәбәпле, РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросының 1919 ел 13 декабрь карары белән ТБССР төзү хакындагы фәрман гамәлдән чыгарыла.

3. Политическое и экономическое взаимоотношение западной части Республики и Башкортостана определяется учредительным съездом Советов Татаро-Башкирской республики.

4. Организация комиссии по созыву учредительного съезда Советов поручается Комиссару по делам мусульман Средней России.

Народный комиссар по делам национальностей
И. Джугашвили-Сталин
Комиссар по делам мусульман Средней России
Мулланур Вахитов
Члены комиссариата Шариф Манатов,
Галимджан Ибрагимов
Секретарь Народного Комиссара
по делам национальностей
С. Диманштейн[1]

P. S. Публикуя это положение, считаю нужным сообщить, что аналогичные положения вырабатываются Народным комиссариатом по делам национальностей для азербайджанских татар Грузии, армян, киргизов, старо-текинцев и других народов России, революционные организации которых прошу сообщить свои конкретные планы Федерации.

Нарком Джугашвили-Сталин
22 (9) марта 1918 г.

---

[1] *С. Диманштейн* – Семён (Шимен) Маркович Диманштейн (1886–1938), революционер, совет-партия эшлеклесе.

## Татар-Башкорт Шуралар Җөмһүрияте[1]

1918 ел

Бөтенрусия эшче, солдат һәм авыл халкы шуралары вәкилләренең өченче корылтае тарафыннан, үз көче белән көн итүче халыкларның милли мохтариятьләре хакында кабул ителгән әсасларга[2] таянып, милли эшләрне карый торган халык комиссариаты, эчке Русия Мөселман эшләре комиссариатының муаффәкате[3] илә, Татар-Башкорт Шуралар Җөмһүрияте хакында түбәндәге карарларны чыгарды:

1) Җәнүби Урал һәм Урта Идел тупрагы Русия шуралары федерациясенең Татар-Башкорт шуралар Җөмһүрияте итеп игълан кылынды.

2) Бу җөмһүриятнең чикләрен билгеләүдә татар-башкорт революционный оешмалары тарафыннан эшләнгән ляихәләр[4] әсас итеп тотыла.

(Бу ляихә буенча җөмһүрияткә түбәндәге җирләр керә: Уфа вилаяте бөтенләй, Оренбург вилаятенең башкортлар яши торган өлеше, Казан вилаятенең чуаш вә чирмеш күпчелек булып утырган җирләреннән башкасы һәм Пермь, Вятка, Самара вә Сембер вилаятьләренең югарыдан әйтелгән җирләргә күрше булып та мөселманнар күпчелек булып утырган җирләре). Чикләрне тәмам өзек рәвештә билгеләү Татар-Башкорт Җөмһүриятенең эшче вә авыл халкы шуралары вәкилләренең Учредительный корылтаена тапшырыладыр.

3) Татар-Башкорт Җөмһүриятенең гареб ягы белән (шәрыкта булган) Башкортстан кыйсеме арасында сәяси вә икътисади мөнәсәбәтне билгеләү мәсьәләсе Җөмһүриятнең Учредительный корылтаена тапшырыладыр.

4) Татар-Башкорт Җөмһүриятенең эшче вә авыл халкы вәкилләреннән гыйбарәт Учредительный корылтаена җыю өчен

---

[1] Газыйм Касыймов төзеп, Г. Ибраһимовның «Бер-ике сүз» исемле кереш мәкаләсе (б. IV–XVI) белән 1918 елда Мәскәүдә «Шәрык» басмаханәсендә нәшер ителгән «Татар-Башкорт Шуралар Җөмһүрияте (Беренче китап)» дигән китапта бастырылган (М., 1918, б. 2–3). Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Әсасларга* – нигезләргә.

[3] *Муаффәкате* – көче.

[4] *Ляихәләр* – проектлар.

комиссия төзү эше эчке Русия Мөселман эшләре комиссариатына йөкләтеләдер.

Милли эшләрне карый торган халык комиссары:
Жугашвили-Сталин.
Эчке Русия мөселман эшләре комиссары:
Мулланур Вахитов.
Эчке Русия мөселман эшләре комиссариаты әгъзалары:
Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Манатов.
Милли эшләрне карый торган халык комиссариатының
секретаре: Диманштейн.
Мәскәү, 1918 сәнә, март.

## О переименовании Комиссариата по делам мусульман внутренней России[1]

Москва, 6 апреля 1918 г.

Постановления, принятые единогласно на совместном заседании членов Центрального комиссариата и башкирских представителей:

1) Комиссариат по делам мусульман внутренней России реогранизуется в «Татаро-Башкирский центральный комиссариат» и впредь официально будет именоваться так.

2) В губерниях и уездах, где живут татары и башкиры, при Советах должны образоваться также совместные татаро-башкирские комиссариаты.

3) Татаро-башкирский центральный комиссариат будет состоять из множества отделов, как-то: просвещения, военного, труда, агитации, статистики, земельного, печати; каждый из них будет возглавляться отдельным комиссариатом. В качестве одного из отделов будет существовать башкирский отдел, занимающийся вопросами особо касающимися башкир; во главе его будет поставлен башкирский комиссар.

4) Новые члены Центрального комиссариата и представители башкир целиком и полностью принимают Положение о Татаро-Башкирской республике, состоящее из четырех статей, которое объявлено и утверждено 22 марта [1918 г.]: они будут совместно трудиться над его осуществлением.

Подписали: с одной стороны, члены Татаро-Башкирского центрального комиссариата: Мулланур Вахитов, Галимджан Ибрагимов, Шариф Манатов, Хади Килдебеков, Махмут Алеев, Юсуф Ибрагимов; с другой стороны, представители башкирского народа: Тагир Имаков, Галиахмет Аитбаев, Гибадуллов, Ирназаров и член Временного башкирского совета Шафиев.

---

[1] Беренче мәртәбә «Чулпан» газетасының 1918 елгы 17 апрель санында дөнья күрә. Аннан соң русчага тәрҗемәдә «Образование Башкирской Автономной Советской Социалистической Республики. Сборник документов и материалов» (Уфа, 1959, с. 148) дигән китапта бастырылган. Текст соңгы чыганактан алынды.

## В Центральном Комиссариате Татаро-Башкирской республики

## Комиссия по созыву съезда Татаро-Башкирской республики[1]

17 апреля 1918 г.

...Первое заседание совещания было открыто 13 апреля товарищем Муллануром Вахитовым.

На первом заседании присутствовали следующие члены: председатель Казанского комиссариата Мирсаид Султан-Галиев, приглашенный в качестве специалиста Галимджан Шараф и казанский профессор Покровский; из членов Урало-Волжской коллегии – Саляхетдин Атнагулов, от оренбургского Башкирского совета – Султанбеков, от имени бюро, избранного [съездом] представителей одиннадцати губерний в Казани для разработки вопросов штата– товарищ Зиновьев, из центральной организации чуваш – Яким Максимов и Даниил Ельменев, от марийцев – Николай Алексеев, из членов Центрального татаро-башкирского комиссариата – Мулланур Вахитов, Галимджан Ибрагимов, Шариф Манатов, Хади Кильдибеков, Галиахмет Аитбаев, Махмуд Алеев, Шафик Рахматуллин, Ирназаров...

---

[1] Беренче мәртәбә «Чулпан» газетасының 1918 елгы 17 апрель санында дөнья күрә. Аннан соң русчага тәрҗемәдә «Национально-государственное устройство Башкортостана (1917–1925 гг.). Документы и материалы: в 4 т.– Уфа: Китап, 2002.– Т. 1.– С. 483–485» дигән җыентыкта, аннары «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин, Р.Д. Шарафиева; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2019.– Т. 2.– С. 407–408» исемле китапта бастырыла. Текст соңгы чыганактан алынды.

## Габделбари Батталның «Алтай» газетасында «Милләт мәҗлесе» дигән мәкаләсеннән[1]

18 апрель 1918 ел

...Милләт Мәҗлесенең беренче җыелышы ачылган чакта Октябрь инкыйлабы күптән түгел генә мәйданга килгән, большевик[лар] хөкүмәте яңа гына төзелгән иде. Әмма Милләт Мәҗлесе таралган вакытта большевик[лар] хөкүмәте үзенең көчен Учредит[ельное] собраниене тарату белән бик ачы күрсәтте. Милләт Мәҗлесенең беренче җыелышының ябылуы Учредит[ельное] собраниенең таратылу мизгеленә тугры килде. Учредит[ельное] собрание таратылу белән, аның татар әгъзаларыннан Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов вә Шәриф Манатов, сул социалистлар белән чыгып китеп, шул вакытта Петербургта дәвам иткән 3 нче Советлар съездына барып ялгандылар, бераздан Эчке Русия мөселманнары комиссариаты төзеделәр. Вилаятьләрдә[2] дә боларның моктәдиләре[3] табылды; төрле мөселман мәркәзләрендә мөселман комиссариатлары төзелү, большевизмны мөселманнар арасында да гамәлгә куярга тырышыла башлады...

---

[1] Беренче мәртәбә «Алтай» газетасының 1918 елгы 18 апрель санында дөнья күрә. Аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З. С. Миннуллин, Р. Д. Шарафиева; науч. ред.: Р. Р. Фахрутдинов, Р. Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2019.– Т. 2.– С 48–50» дигән китапта бастырылган. Текст соңгы чыганактан алынды.

[2] *Вилаять* – өлкә.

[3] *Моктәдил* – уртача.

## Выписка из протокола № 6 заседания Коллегии Народного Комиссариата по делам национальностей от 21 апреля 1918 г.[1]

Присутствовали:
1. И. Сталин – Народный Комиссар по делам национальностей.
2. С. Пестковский от Народного Комисс. по делам национ.
3. Ф. Розин (Азис) от Латышского Комиссариата.
4. В. Авнесов от Армянского Комиссариата.
5. С. Бобинский от Польского Комиссариата.
6. К. Бродский –//– (Ликвидац. Комис.).
7. В. Скорынко от Беларусского –//–
8. Л. Червяков –//–
9. С. Матулайтис от Литовского –//–
10. Г. Г. Ибрагимов от Татаро-Башкирского Комиссариата.
11. И. Товсуха – Секретарь Коллегии.
Председательствовал т. Сталин.
Секретарствовал т. Товстуха.
8. О Татаро-Башкирском Комиссариате.

Резолюции

Постановлено: Народному Комиссариату по делам национальностей совместно с Татаро-Башкирским Комиссариатом созвать в 2-х недельный срок совещание по созыву Учредительного Съезда Татаро-Башкирской республики.

В состав этого совещания привлечь представителей всех заинтересованных в автономии Татаро-Башкирии губернских и городских Совдепов и соответствующих Мусульманских Комиссариатов из местностей, расположенных в границах Татаро-Башкирии, и смежных с ними. На совещание делегировать также представителей Народного Комиссариата по делам национальностей.

---

[1] Төп нөсхә Россия Федерациясе Дәүләт архивында саклана (1333 ф., 2 тасв., 2 эш, 13 кәг.). Беренче мәртәбә «Первый год пролетарской диктатуры в Татарии (Сборник документов и материалов по истории парторганизации и гражданской войны в 1918 г.).– Казань: Татаргосиздат, 1933.– С. 53» дигән җыентыкта, аннан соң «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин, Р.Д. Шарафиева; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов.– Казань: Заман, 2019.– Т. 2.– С. 409» исемле китапта бастырыла. Текст соңгы чыганактан алынды.

## Собрания и их резолюции по поводу образования Татаро-Башкирской республики[1]

28 апреля 1918 г.

Собрание уфимских рабочих татаро-башкир [, состоявшееся] 28 апреля, прослушав доклад товарища Галимджана Ибрагимова, единогласно постановило:

1. Уфимский Совет рабочих-татар выражает Центральному татаро-башкирскому комиссариату полное доверие и, вполне надеясь, что Центральный комиссариат поведет рабочих татаро-башкир к светлому будущему, во всякое время будет стоять на страже революционного комиссариата.

2. Татаро-башкирские рабочие всеми силами поддерживают осуществление Татаро-Башкирской советской республики.

3. Собрание находит необходимым организовать татаро-башкирскую Рабоче-крестьянскую красную армию.

Председатель собрания Сунчелей[2]

---

[1] Төп нөсхә телеграф бланкасында, Россия Федерациясе Дәүләт архивында (130 ф., 2 тасв., 69 эш, 110–111 кәг.) саклана. Беренче мәртәбә «Образование Башкирской Автономной Советской Социалистической Республики. Сборник документов и материалов» (Уфа, 1959, с. 149–150) дигән китапта бастырылган. Аннан күренгәнчә, карар телеграф аша Халык Совет комиссариатына, Милләтләр эше буенча комиссариатка һәм Татар-башкорт Үзәк комиссариатына тапшырылган. Аннары «100-летие образования Татарской АССР. Сборник документов и материалов: в 3 т. / авт.-сост. З.С. Миннуллин, Р.Д. Шарафиева; науч. ред.: Р.Р. Фахрутдинов, Р.Р. Хайрутдинов. – Казань: Заман, 2019. – Т. 2. – С. 412» исемле китапта бастырыла. Текст соңгы чыганактан алынды.

Текст күрсәтелгән китаптан алынды.

[2] *Сунчелей* – Бирeдә Сәгыйть яки Шәриф Сүнчәләйләрнең кайсы икәнлеге төгәл күрсәтелмәгән. Аларның беренчесе Уфага 1915 елда, икенчесе 1917 елда килә. Шулай да Шәриф Сүнчәләй булу ихтималы күбрәк.

## Из протокола объединенного собрания представителей татарских и башкирских организаций в г. Уфе о слиянии Мусульманского и Башкирского комиссариатов при Губсовнаркоме в Татаро-Башкирский комиссариат[1]

29 апреля 1918 г.

Председательствует на собрании Галимжан Ибрагимов.

На обсуждение ставится вопрос об объединении Башкирского комиссариата с Мусульманским комиссариатом при Уфимском губернском совете народных комиссаров в Татаро-Башкирский комиссариат и о таком его наименовании.

Заслушивается доклад Галимжана Ибрагимова об изменениях в центре, где [Комиссариат по делам мусульман] уже реорганизован в Центральный татаро-бащкирский комиссариат, [о том, что] и здесь необходимо объединить два комиссариата в один Уфимский губернский татаро-башкирский [комиссариат] и так его именовать.

После доклада состоялось длительное обсуждение. Единогласно принято нижеследующее постановление:

1) Комиссариат по делам мусульман при Уфимском губернском совете народных[2] комиссаров объединяется с Башкирским комиссариатом и реорганизуется в Татаро-Башкирский комиссариат и [впредь] именуется таким образом.

2) Уфимский губернский татаро-башкирский комиссариат будет состоять из нижеследующих отделов: а)[3] агитационного и организационного, б) образования, в) военного, г) литературы и печати, д) статистического, е) труда, ж) земельных дел. Если Татаро-Башкирский комиссариат сочтет необходимым, то имеет право открывать и дополнительные отделы.

---

[1] Беренче мәртәбә «Көрәш» газетасының 1918 елгы 7 май санында дөнья күрә. Аннан соң русчага тәрҗемәдә «Образование Башкирской Автономной Советской Социалистической Республики. Сборник документов и материалов» (Уфа, 1959, с. 148) дигән китапта бастырылган. Текст соңгы чыганактан алынды.

[2] *В документе* крестьянских. *Примеч. в источнике. – Р. И.*

[3] В документе обозначение пунктов дано буквами арабского алфавита. *Примеч. в источнике. – Р. И.*

*«Көрәш»* – Уфа вилаяте Халык комиссарлары шурасының нашире әфкяре. Көндәлек сәяси, иҗтимагый сул социалистлар газетасы. 1918 елда барлыгы 68 сан нәшер ителә.

3) Гилемдар Баимбетов, избранный Уфимским губернским съездом крестьян и рабочих комиссаром по мусульманским делам, остается главным комиссаром в Татаро-Башкирском комиссариате.

4) Для руководства отделами в коллегию Уфимского губернского татаро-башкирского комиссариата избираются следующие товарищи: 1) Тагир Имаков – заведующий отделом агитации и организации, 2) Исмагил Рамеев – его товарищ, 3) Шариф Сунчелей – заведующий отделом просвещения, 4) Салахетдин Атнагулов, Габдрахман Рахимкулов – его товарищи, 5) Галимжан Аминев – заведующий военным отделом, 6) Шагит Худайбердин – его товарищ, 7) отделом литературы и печати руководит Гилемдар Баимбетов, 8) Гумер Альмухаметов избирается общим секретарем Татаро-Башкирского комиссариата.

(Собрание закрывается в 3 часа дня)

Подписи в подлиннике протокола:

Председатель объединенного собрания
Галимжан Ибрагимов
Уфимский комиссар по мусульманским делам
Гилемдар Баимбетов
Члены Уфимского мусульманского комиссариата:
Галимжан Аминев, Шариф Сунчелей, Исмагил Рамеев
Представители Уфимского башкирского комиссариата:
Шанит Худайбердин, Гали Гайнуллин, Габразаков,
Ахмедуллин
От представителей Уфимской секции крестьян:
Сагит Улямов, Муса Юсупов, Габдульхай Даукаев
От имени Татар-Башкирского комиссариата:
Салахетдин Атнагулов, Ибрагим Асикаев
Секретарь объединенного собрания
Гумер Альмухаметов

## О прочтении доклада Г. Ибрагимовым перед рабочими-татар[1]

7 мая 1918 г.

1. Издать книгу тов[арища] Саади «Язык, литература и письменность в человеческом мире и их историческое развитие»[2], по плану руководств и пособий немедленно по выпуске в свет первоочередных учебников.

Председатель Акадцентра *(подпись Г. Ибрагимова)*

Ученый секретарь *(подпись З. Норкина)*

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (Р-3682 ф., 1 тасв., 694 эш, 40 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Издать книгу тов[арища] Саади «Язык, литература и письменность в человеческом мире и их историческое развитие»* – 1926 елда нәшер ителә: Сәгъди Г. Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре (гомумән тел-әдәбият тарихыннан) / Г. Сәгъди.– Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926.– 246 б.

## Протокол № 28
## заседания Татарской редакционной коллегии Акадцентра Татнаркомпроса от 3/VII – 1925 года[1]

Присутствовали: Ибрагимов, Максудов, Курбангалеев, Чигтай, Норкин, Каримов, Г. Рахим и Хуснуллин.

Председатель – Ибрагимов. Секретарь – Норкин.

Слушали:

...16. Рецензия (устная) тов[арища] Ибрагимова о труде тов[арища] Алпарова «Основы татарск[ой] грамматики».

Постановили:

...16. Включить в план 1925 / 26 года, с добавлением введения с разработкой тюркск[ой]-татарск[ой] грамматики[2].

Председатель *(подпись Г. Ибрагимова)*

Секретарь *(подпись З. Норкина)*

## 1926
## Корылтай[3]

1926 ел, Баку

1 нче мартта гомуми имля нигезләре турында профессор Щерба[4] белән Жирковның[5], аннан соң «Төрк телләренең имлясы турында» Галимҗан Ибраһимов, Шакирҗан Рәхими[6] (соңыннан өстәлгән докладчы) һәм Фәрһад Агазадәләрнең[7] докладлары тыңланып, фикер алышулардан соң мәҗлес ябылды.

---

[1] Төп нөсхә дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (Р-3682 ф., 1 тасв., 694 эш, 42 (икенче ягы), 43 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Нәшер ителә:* Алпаров Г. Шәкли нигездә татар грамматикасы (Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә). Татарстан Гыйльми үзәк каравында басылды (төзәтелгән икенче басмасы) / Г. Алпаров.– Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926.– 164 б.

[3] «Беренче тюркология корылтае һәм аның тикшергән мәсьәләләре / Төзүчесе Гали Рәхим» дигән җыентыкта (Казан, 1926, б. 26) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[4] *Щерба* – Лев Владимирович Щерба (1880–1944) – тел галиме, СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы.

[5] *Жирков* – Лев Иванович Жирков (1885–1963), тел галиме.

[6] *Шакирҗан Рәхими* – Шакирҗан Рәхимҗан улы Рәхими (1893–1938), үзбәк мәгърифәтчесе, педагог. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[7] *Фәрһад Агазадә* – Фәрһад Рәхим оглы Агазадә (1880–1931), әзәрбәйҗан тел галиме, педагог, журналист.

## В Академцентр Башкирнаркомпроса[1]

6 апреля 1926 г[ода], г. Казань

Уфа
Башкирская ССР

В Акадцентр Башкирнаркомпроса

6 апреля 1926 г[ода]
№ 7244.

Согласно п.п. 1, 2 и 8 резолюции I-го туркологического съезда по вопросу о научной терминологии при выработке последней на различных тюрко-татарских наречиях, должно быть обращено усиленное внимание на групповое сродство наречий и возможную однородность терминологии в учебниках. Это вызывает необходимость более тесного контакта между терминологическими комиссиями различных тюрко-татар республик.

Принимая во внимание это обстоятельство, Академцентр Наркомпроса ТССР просит Вас выслать выработанные до сих пор Вами терминологические материалы, обещая взамен выслать свои по окончании их подготовки.

Председатель Акадцентра: (*подпись Г. Ибрагимова*)
Уч[еный] секретарь: (*подпись З. Нуркина*)

---

[1] Төп нөсхә Башкортстан Республикасының Милли архивында саклана (798 ф., 1 тасв., 1513 эш, 44 кәг.). ТССР Мәгариф халык комиссариатының Гыйльми үзәге грифле рәсми кәгазенә машинкада язылган. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 312–313) кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган. Текст төп нөсхәдән алынды.

# ХӘБӘРЛӘР

## 1925
## Гыйльми үзәк янындагы татар һәм рус коллегияләренең составларын билгеләү хакында[1]

1925 ел

Гыйльми үзәктә

Гыйльми үзәк коллегиясе – Татарстан Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе 1925 елның 4 нче февралендәге җыелышында Гыйльми үзәк янындагы татар һәм рус коллегияләренең составларын түбәндәгечә кабул итте:

1. Татар коллегиясе – рәисе Галимҗан Ибраһимов. Әгъзалар: Шәһит Әхмәдиев, Исхак Рәхмәтуллин, Фатыйх Сәйфи, Гаяз Максуд, Латыйф Гомәров, Мөхәммәт Парсин, Габдулла Толымбайский[2], Мөхетдин Корбангалиев, Гали Рәхим[3].

---

[1] «Безнең юл» журналының 1925 елгы 1–2 нче кушма санында (б. 171) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Габдулла Толымбайский* – Гомәр Толымбай (Толымбайский) (Габделхак Җәлалетдин улы Шаһиәхмәтов (1900–1938), язучы, фольклорчы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган (журналда исеме ялгыш язылган. – *Р. И.*).

[3] *Гали Рәхим* – Гали Рәхим (Гали Мөхәммәтшакир улы Рәхимов) (1892–1943), язучы, әдәбият белгече. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе, үлгәннән соң акланган.

## «Безнең юл» журналына Казаннан язышучылар хакында[1]

1925 ел

Журналда язышучылар

Казанда – Галимҗан Ибраһимов, Зәки Гыймранов, Фатыйх Сәйфи, Мөхәммәт Парсин, Исхак Рәхмәтуллин, Шәһит Әхмәдиев, Толымбайский, Г. Ходаяров, М. Сәгыйдуллин[2], Вәли Шәфигуллин[3], Х. Кәримов, Г. Галиев[4], Әминә Мөхитдиния[5], Ф. Бурнаш[6], Кәрим Әмири, Кави Нәҗми[7], Кутуй[8], Шамил Госманов[9], Латыйф Гомәров, Гаяз Максудов, Абруй Сәйфи, Ш. Измайлов, Лотфи Хөснуллин, Калчурин, Сарим Фәхри, Садри Җәлал[10], Һади Такташ, Г. Газиз[11], Корбангалиев, Кулиев, Ә. Гаффаров[12] һәм башкалар.

---

[1] «Безнең юл» журналының 1925 елгы 1–2 нче кушма санында (б. 190) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *М. Сәгыйдуллин* – Миңлегәрәй Сәгыйдулла улы Сәгыйдуллин (1900–1938), сәясәт эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[3] *Вәли Шәфигуллин* – Вәли Сәлим улы Шәфигуллин (1894–1939), сәясәт эшлеклесе, журналист. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[4] *Г. Галиев* – Гомәр Билал улы Галиев (1900–1954), әдәбият галиме, тәнкыйтьче, язучы-прозаик. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[5] *Әминә Мөхитдиния* – Әминә Фәсах кызы Мөхетдинова (1893–1944), хокук белгече, сәясәт эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[6] *Ф. Бурнаш* – Фәтхи Бурнаш (Фәтхелислам Закир улы Бурнашев) (1898–1942), драматург, шагыйрь, публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[7] *Кави Нәҗми* – Габделкави Һибәтулла улы Нәҗметдинов (1901–1957), язучы, шагыйрь, тәнкыйтьче-публицист, җәмәгать эшлеклесе.

[8] *Кутуй* – Гадел Кутуй (Гаделша Нурмөхәммәт улы Кутуев) (1903–1945), язучы.

[9] *Шамил Госманов* – Шамил Хәйрулла улы Госманов (1898–1937), язучы, җәмәгать эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[10] *Садри Җәлал* – Садрислам Хәйретдин улы Вәлидов (1891–1943), язучы. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[11] *Г. Газиз* – Газиз (Габделгазиз) Салих улы Гобәйдуллин (1887–1938), тарихчы, җәмәгать эшлеклесе. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[12] *Ә. Гаффаров* – Әхәт Гаффаров (?–?), үткән гасырның егерменче елларындагы журналист.

## Гыйльми үзәк тарафыннан Каюм Насыйриның тууына йөз ел тулу билгеләнеп үтелүе хакында[1]

1925 ел

Каюм Насыйриның туганына йөз ел тулу

Гыйльми үзәккә Ширданнан алынган соңгы дөрест материал буенча Каюм Насыйриның моңарча язылып килгәнчә 1824 нче елда түгел, бәлки 1825 елның искечә 2 нче (яңача 15 нче) февралендә туганлыгы беленде. Шуның уңае белән Татарстан Гыйльми үзәге татар теле, имлясы һәм әдәбиятына байтак хезмәтләр күрсәткән Каюм Насыйриның йөз еллык бәйрәмен үткәрү чарасына керешеп, февральнең 15 ндә Дәүләт татар театрында зур гыйльми җыелыш ясады. Җыелышта Татарстан исеменнән Шәһит иптәш Әхмәдиев сөйләгәннең соңында гыйльми җыелышны ясаучы комиссиягә Татарстан хөкүмәте тарафыннан җибәрелгән хатны укыды (бу хат түбәндә китерелә). Соңра Насыйриның тарихи урыны (Галимҗан Ибраһимов), Насыйриның тормышы (Мөхәммәт Парсин), Насыйриның гыйльми хезмәтләре (Гали Рәхим), Насыйриның татар теленә хезмәте (Мөхетдин Корбангалиев) турында докладлар укылды. Докладлар беткәч, Насыйрины искә төшерү булып, Һади Максуди, Фатыйх Әмирхан һәм Х. Вәлиевләр үзләренең Насыйри турында истә калганнарын сөйләделәр. Җыелышның ахырында Галимҗан иптәш Ибраһимов үзенең соңгы сүзендә Насыйрины җентекләп тикшереп өйрәнү, аның кулъязмаларын һәм басылган китапларын җыю юлында булышлык күрсәтүне җыелышта булган бөтен иптәшләрдән үтенде. Насыйриның каберен таратмас өчен Татарстан хөкүмәтенең таш яздырып куярга һәм Насыйри почмагын ачарга тиешле чаралар күрәчәген шулай ук Насыйри турында бер мәҗмуга чыгару өчен Гыйльми үзәк янында коллектив төзелүе турында сөйләп, Насыйри баба хөрмәтенә булган бу

[1] «Мәгариф» журналының 1925 елгы 1–2 нче кушма санында (б. 171–173) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә бастырыла.

Хөкүмәт хаты журналист Гариф Латыйфның (1886–1962) «Каюм Насыйрины искә төшерү турында зур җыелыш» дигән мәкаләсендә беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1925 елгы 18 февраль санында, аннан соң «Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре. Мәҗмуга» (Казан, 1926) дигән җыентыкта бастырылган.

җыелышны япты. Насыйрины истә калдыру өчен Шәһит Әхмәдиев иптәш Татарстан хөкүмәте исеменнән түбәндәге карарны игълан итте:

1. Мәскәүдәге журналистлар институтында Насыйри исеменә стипендия билгеләргә;

2. Казандагы Евангелистовский һәм Яңа бистәдә Большой Симбирский урамнарны Насыйри исеме белән атарга;

3. Казан татар педтехникумын «Насыйри педтехникумы» дип атарга.

4. Насыйри әсәрләрен сайлап бастырырга һәм аның турында мәҗмуга чыгарырга[1].

Татарстан хөкүмәтенең хаты

Кадерле иптәшләр!

Кичектерү мөмкин булмаган эшләр булу сәбәпле, утырышка бара алмадык. Моның өчен җыелыштан гафу үтенәбез. Шуның белән бергә Татарстан Җөмһүрияте хөкүмәте исеменнән җыелышка түбәндәге сүзләребезне әйтүне сезгә тапшырабыз:

Пролетариат яңа, якты, азат көннәр өчен булган авыр көрәшләрдә үткәннең һәммә тәҗрибәләреннән файдалануны үзенең бурычы дип саный. Үткән тәҗрибәләр, үткән хезмәтләр безнең хәзерге төзү эшебездә ярдәмче корал булу белән бергә, ул тәҗрибәләр, ул көрәшләр үткән тарихның иске, караңгы хәлләрен җимереп, кешелек дөньясының бер адым булса да алга – яктылыкка таба атлавына хезмәт иттеләр. Менә шул нигездән чыгып, хәзерге көндә иҗтимагый азатлыклар, общий бәхетләр өчен көрәштә булган аңлы эшче-крәстияннәр, тарихның ул билгеле бер баскычында гыйльми, әдәби, мәдәни хезмәтләр кылып, үткән көрәшчеләрне тәкъдир итәләр, аларны хөрмәт белән искә төшерәләр. Йөз еллыгы уңае белән бәйрәм ителгән Каюм бабабыз үзенең гыйльми-әдәби хезмәтләре белән татар тарихының менә шундый кадерле эшчеләренең берсе, бәлки, беренчесе. Шуңар күрә дә Татарстан Җөмһүрияте хөкүмәте ул өлкән бабаның туганына йөз ел тулган көнне олылап үткәрүне тиешле санады һәм башка берничә төрле сагынмалык-ядкяр эшләү белән

---

[1] *…аның турында мәҗмуга чыгарырга* – ул мәҗмуга икенче елда ук нәшер ителә: Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм йөз еллык бәйрәм материаллары. Мәҗмуга. Гали Рәхим карамагында.– Казан: Татарстан дәүләт нәшр., басмасы, 1926.– 135 б.

бергә аның әсәрләреннән, һич булмаса, кайберләрен бастыру, аның тормышы, хезмәте турында тулы материал, мәгълүмат бирерлек мәҗмуга чыгарту чараларын күрәчәк.

Сезгә сәлам белән:

Татарстан Җөмһүрияте Үзәк Башкарма председетале: Шаһимәрдәнов.

Татарстан Җөмһүрияте халык комиссарлары Советы председателе: Хаҗи Габидуллин[1].

---

[1] *Хаҗи Габидуллин* – Хаҗи Заһидулла улы Габидуллин (1897–1940), дәүләт эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты (1933), профессор (1934). 1924–1927 елларда Татарстан Җөмһүрияте халык комиссарлары Советы рәисе булып эшли. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

## Гыйльми үзәк янында тел комиссиясе төзелү хакында[1]

1925 ел

Гыйльми үзәктә

Тел комиссиясе – татар телендә бик күп атамаларны кайбер кешеләр гарәпчә, кайберәүләр урысча йөртәләр. Шушы тел анархиясенә чик кую максаты белән, Гыйльми үзәк катында тел комиссиясе төзелде. Комиссиянең составы:

1) Г. Ибраһимов, 2) Корбангалиев, 3) М. Парсин, 4) Г. Рәхим, 5) Толымбайский һәм 7) татар телен гамәлгә кую комиссиясеннән ике вәкил.

---

[1] «Мәгариф» журналының 1925 елгы 3 нче санында (б. 125), «Безнең юл» журналының 1925 елгы 5 нче (б. 218) саннарында урнаштырылган. Текст «Мәгариф» журналыннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә басыла.

## Гыйльми үзәктә К. Насыйри мәҗмугасын төзү хәзерлеге эше хакында[1]

1925 ел

Гыйльми үзәктә

Каюм Насыйри мәҗмугасы – Татарстан Җөмһүрияте Халык комиссарлары Советы татар теле реформаторы Каюм Насыйриның исемен мәңгеләштерү юлында күреләчәк чаралары эчендә аның исеменә бер мәҗмуга чыгаруны алдында тотып, бу мәҗмуганы хәзерләү эшен Гыйльми үзәккә тапшырган иде. Гыйльми үзәк бу мәҗмуганы хәзерләү эшен Галимҗан иптәш Ибраһимовка тапшырды. Мәҗмуга 10 табак күләмендә булачак.

Каюм Насыйриның матбугатка чыкмый калган әсәрләре – Гыйльми үзәк, Казан университеты көтепханәсеннән цензор Готвальд[2] кулъязмалары арасында сакланып матбугатка чыкмый калган Каюм Насыйриның кулъязма әсәрләрен вакытлы рәвештә алып торды.

Ул кулъязмалар шулар:

1. Археология материаллары.
2. Зөя өязендәге зуррак авылларның тарихлары.
3. Аксак Каратун яки Лука Канашевич[3] турында.
4. Мәшһүр голәмалар.

Каюм Насыйри үзенең бу әсәрләрен янгын куркынычыннан саклау өчен Готвальдка тапшырган булса кирәк. Чөнки кулъязмаларның кырыйлары азрак яна башлаган кебек күренә.

Тарихи материаллар – Газиз Гобәйдуллин Гыйльми үзәккә үзендә сакланып килгән шушы тарихи материалларны тапшырды:

1) Купчи (купчая) Хәлфин имзасы белән.

2) Екатерина II нең Пугачёв хәрәкәтен бетерү эшендә катнашкан өчен Ибраһимовка биргән мәкяфәт[4] кәгазе.

3) Мәрҗанинең кайбер кулъязмалары.

---

[1] «Мәгариф» журналының 1925 елгы 3 нче санында (б. 125–126), кыскартылган өлеше «Безнең юл» журналының 1925 елгы 5 нче (б. 218) саннарында урнаштырылган. Текст «Мәгариф»тән алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Готвальд* – Иосиф Фёдорович Готвальд (1813–1897), шәркыятьче.

[3] *Аксак Каратун яки Лука Канашевич* – Лаврентий Канашевич Лука (? – 1758), дин эшлеклесе, миссионер. Мөселманнарны җәберләгәне өчен халык телендә Аксак Каратун буларак та билгеле.

[4] *Мәкяфәт (мөкяфәт)* – мактау.

## Гыйльми үзәк президиумы утырышында тел һәм атамалар хакында инструкция кабул ителүе хакында[1]

1925 ел

Тел һәм атамалар турысында инструкция
(Бу инструкция Гыйльми үзәк президиумының 1925 нче ел, 6 нчы ноябрьдә булган утырышында кабул ителде)

1924 нче ел февраль аенда Мәскәүдә җыелган татар мәгариф эшчеләре съездындагы аерым киңәшмәдә һәм шул ук ел 16 нчы синтәбердә Казандагы матбугат-әдәбият хезмәтчәннәренең җыелышында кабул ителгән тезисларны, шуннан соң Гыйльми үзәкнең үзе тарафыннан 1924 нче ел декабрь аенда кабул ителгән тезисларны һәм соңрадан алынган тәҗрибәләрне күз алдында тотып, телне җиңеләйтү һәм атамалар ясау өчен Гыйльми үзәк хәзер түбәндәге инструкцияне кабул итә:

1 – Татар әдәби теленең иң төп нигез материалы үзебезнең ана телебездән алынырга тиеш. Татарча сүзләр була торып, болар урынына һичбер башка телдән һичбер сүз алынмас.

2 – Татарча сүзләр табылмаган урыннарда мәгънәнең теләве ана теленең сөреше буенча:

а) Татарча тамырларыннан яңа ясалма сүзләр төзелерләр (монда гыйльми дөрестлек һәм халыкка аңлаешлы булу ягына аеруча тукталырга кирәк).

б) Борынгы онытылган сүзләрдән яки Россиядәге төрки кабиләләрнең безгә җиңел аңланырлык сүзләреннән алыныр.

3 – Гарәп сүзләреннән телне, әлбәттә, тазартырга кирәк.

Бу төп кагыйдәдән тик түбәндәге өч урында гына чигенергә туры килә:

а) Гарәпчәдән кереп тә, халык эчендә үз теле кебек үзләшкән сүзләр элеккедәй үз урыннарын сакларлар (каләм, һава, китап, дөнья, дин, мәктәп, кабер, хикәя кебекләр).

б) Әдәбиятыбызда киң рәвештә таралып, гражданлык алып үз сүзләребез дәрәҗәсендә үзләшкән атамалар, сүзләр гарәпчәдән булсалар да һаман да матбугатта кулланылалар (әсәр, шигырь, әдәбият, мәгариф, сәясәт, дәүләт, җәмәгать, мәдәният, милләт,

[1] «Мәгариф» журналының 1925 елгы 10–11 нче кушма санында (б. 176–178) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

тарих, фәлсәфә, әхлак, хезмәт, карар, мәсьәлә, хәреф... кебекләр).

т) Исламның үзендә генә булып, татарчада, башка телләрдә сүзе булмаган мәгънәләрнең атамалары шул гарәпчә яки фарсыча рәвешендә йөртелер (боларның кирәк урыннары дингә каршы әсәрләрдер. Гает, хаҗ, хәлифә, хәрам, пәйгамбәр, сәхаба, иман... кебек).

4 – Мәдәни милләтләр арасында уртак йөргән сүзләр һәм атамалар шул көенчә әдәбиятыбызда кулланырга тиешле (буржуазия, пролетариат, интернационал, техника, факультет, анатомия, психология, азот, фосфор, электрик, атом, агроном, калори, термометр... кебекләр).

5 – Матбугатта, әдәбиятта урынсыз рус сүзләре куллануга каршы кискен чара күрергә тиешле.

Бу кагыйдәдән тик түбәндәге урыннарда гына чигенергә туры килә:

а) Татарчасы булмаган яки дә ясалма рәвештә төзелә алмаган, гарәпчәсе халыкка аңлашылмаган урыннарда рус сүзләре кулланылыр (завуд, пристан, парахуд, пуезд, самавар... кебекләр).

б) Рус идарәсенә, рус тарихына, рус иҗтимагыятенә каратылган рус сүзләре кулланылырлар (өяз, земство, вулыс, кенәз, бояр, крәстиян, дума, савит... кебек).

6 – Гарәпчәдән, русчадан һәм дә башка чит телләрдән сүзләр алганда, татар әйтүенчә алырга һәм язарга (һава, хайван, сарык, палитсә, капиратиф, Мәскәү... кебекләр).

7 – Телнең, әдәбиятның үз тарбигый нигезендә үсүенә иркенлек кую өчен матбугат дөньябызга чит сүзләрне керткәндә сыйфатларның, фигыльләрнең, ясалма сүзләрнең рәвешләре (фурмалары) татарча нигезендә сакланырлар.

Ялганмалар, кушымталар, әлбәттә, татар теленең үз асылындагыча кулланырлар (мәсәлән, русчадагы -ский, -чкий, -чество-ны... кебек ялганмалар кулланылмас).

Бу кагыйдәдән түбәндәге урыннарда чигенүләр булыр:

а) Гарәпчәдән кергән нисбәт рәвеше (гыйльми, әдәби, сәяси... кебек),

б) Яурупадан кергән кайбер ялганмалар [«ист» – реалист, материалист, коммунист; «атсийа» – сатсиализатсийа, иликтруфикатсийа; «изм» – мунизм, футуризм, марксизм, ленинизм... кебекләр. Шулай ук сирәгрәк сүзләрдә «ик» һәм «ал» ялганмалары – аргинал, лирик, сатсийал, прафиссианал... кебек].

8 – Халык эчендә йөргән русча сүзләрне әдәбиятка керткәндә тагын түбәндәге мамент күз алдында тотылыр: бер кабиләдә яки төбәктә генә (Пензада, Сергачта, Саратовта) русча әйтелеп тә башкалар да моның татарчасы булса, матбугатка, әлбәттә, ул төякнең яки кабиләнең русчасы түгел, бәлки татарның башка җирләрендә йөртелгән үз сүзләре алыныр (сидилчә түгел – ыңгырчак, тез чәшкәсе түгел – тез капкачы, валинка түгел – пима).

9–5 нче маддәдәге (а) һәм (б) пунктлары буенча аталма сүзләрнең безнең әдәбиятка керергә ярап-ярамаганлыгы Гыйльми үзәк янындагы атамалар комиссиясендә билгеләнер.

10 – Татарстандагы бөтен матбугатта бу инструкциянең эшкә ашырылуы мәҗбүридер.

Татарстан Мәгариф комиссариаты Гыйльми үзәге рәисе:
Галимҗан Ибраһимов.
Секретаре: Заһид Нуркин.

## Татар әлифбасы турында Гыйльми үзәк карары хакында[1]

1925 ел

Татар әлифбасының тәртибе турында

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатының Гыйльми Үзәге түбәндәге карарны чыгарды:

I. Әлифба тәртибенең төрле кешеләр тарафыннан төрлечә йөртелеп, нык урынлашкан бер тәртип булмавы, лөгать китаплары төзүдә, канун һәм карарларның пунктларын санауда төрлелек кертkәнлектән, Татарстандагы бөтен совет учреждениеләрендә, мәгариф эшләрендә һәм матбугатта куллану өчен рәсми итеп татар хәрефләренең әлифба тәртибе түбәндәгечә билгеләнә:

1) ئـ, 2) ا, 3) بـ, 4) پـ, 5) تـ, 6) جـ, 7) چـ, 8) حـ, 9) د, 10) ر, 11) ز, 12) ژ, 13) سـ, 14) شـ, 15) عـ, 16) فـ, 17) قـ, 18) کـ, 19) گـ, 20) ڭـ, 21) لـ, 22) مـ, 23) نـ, 24) و, 25) ۋ, 26) ۇ, 27) هـ, 28) ه, 29) یـ, 30) ئـ, 31) ˏ (калынлык билгесе).

Искәрмә: 1) канун һәм карарларда хәреф белән әйберләр тәртибен күрсәткәндә, хәрефләрнең шәкелләре ( ئـ ا, بـ, پـ, تـ, جـ, چـ…) рәвешендә йөртелеп, (ع, ئا, ب, پ, ت, ج, چ) рәвешләрендә йөртелмәс.

1. «Сүз, суз, бүлде, булды, үлем, улым» кебек бер-береннән башка хәрефләре белән аерылмый, тик калынлык тамгасы белән генә аерылган сүзләрнең нечкәләре лөгать һәм исемлекләрдә калынлыклардан (калынлык тамгасы булганнарыннан) алда куелыр. Сүз тәртипләрен билгеләүдә калынлык тамгасы аерым бер хәреф итеп каралмас.

I. Әлегә чаклы хәрефләрнең исемнәре иҗек өйрәнгән заманнар гадәте буенча, «әлиф, би, ти, җим, хы, дал, ра, зый, син, шин...» дип йөртелә иде. Бу исемнәрнең мәгънәсез, күп вакытта хәрефләрнең төп авазлары белән бәйләнешсез һәм укучы балалар бикләп укылуы файдасыз, буталдыргыч булганлыктан, аларның күбесе үзгәртелеп һәм хәрефләрнең күрсәткән авазына якынайтылып, югарыда күрсәтелгән хәрефләргә түбәндәге исемнәр билгеләнә: ئـ (әмзә), ا (а), بـ (бе), پـ (пе), تـ (те), جـ (җе), چـ (че), حـ (хе), د (де), ر (ре), ز (зе), سـ (се), شـ (ше), عـ (гы), فـ (фе), قـ (кы), کـ (ке), گـ (ге), ڭـ (ңе), لـ (ле), مـ (ме), نـ (не), ئو (о), ۋ (ве), ئۇ (у), هـ (һе), ه (ә), یـ (йе), ئی (ы), ˏ (калынлык билгесе).

[1] «Мәгариф» журналының 1925 елгы 10–11 нче кушма санында (б. 178–179) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

I. Бу карар Татарстандагы барлык савит учреждениеләрендә, барлык татар матбугатында һәм мәктәпләрендә, матбугат аркылы игълан кылынган көннән башлап гамәлгә куелуы мәҗбүридер.

Татарстан Гыйльми Үзәге рәисе: Галимҗан Ибраһимов.

Секретаре: Заһид Нуркин.

1925 – нуябер.

## 1925–[19]26 нче ел өчен Татарстан Җөмһүриятенең нәшрият планы

Башлангыч[1]

1925 ел

1 – Бу план Татарстан Халык мәгариф комиссариаты Гыйльми Үзәге тарафыннан, Татарстан дәүләт нәшрияты, Өлкә Комитеты матбугат бүлегенең һәм башка оешмаларның катнашы белән төзелде. Монда Мәгариф Комиссариатының гына түгел, бәлки Татарстандагы нәшрият учреждениеләренең һәммәсенең алдагы эш елында чыгарырга уйланган барлык нәрсәләре керде. Шул як белән бу пландагы материал өчкә бүленде:

а) Мәгариф комиссариаты буенча басылачак әсәрләр, татар телендә 1531 табак, рус телендә 322 табак.

ә) Өлкә Комитетының матбугат бүлеге буенча басылачаклар 919 табак ярым.

б) Төрле учреждениеләр тарафыннан басылачак нәрсәләр (Совнарком, Наркомзем кебек) 579 табак ярым.

Барлыгы: 3352 табак.

2 – Бу планны төзегәндә тик Татарстан Җөмһүрияте генә түгел, бәлки СССРдагы барлык татар халкының ихтыяҗы күз алдында тотылып, башка шәһәрләрдәге татарча нәшрият оешмалары белән параллелизмга төшмәү моменты хәтергә алынды. Моның өчен алар белән аерым киңәш ясап, кайбер нәрсәләрне кайда кем тарафыннан бастыру мәсьәләсе аеруча килешүгә калдырылды.

3 – Планга «Кизүдәге мәсьәләләр буенча» дигән бер тармак кертелеп, алдан күреп билгеләү мөмкин булмаган мәүзугъләр турында чыгарырга тиеш булыначак әсәрләр менә шуңар керәчәкләр. Әгәр дә тормыш ихтыяҗы мәҗбүр итсә, планда күрсәтелгән кайбер әсәрне икенчеләр белән алмаштыру мөмкин булачак. Бу план, үткән елларныкына караганда бик күп дәрәҗәдә киң, зур булганга, моны төзегәндә Татарстан Җөмһүриятенең полиграф куәте хәзерге хәленнән үсәргә-көчәергә

---

[1] «Мәгариф» журналының 1925 елгы 9 нчы санында урнаштырылган (б. II–III). Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

тиешлеге күз алдында тотылды. Юкса, бу планны үтәү авырга киләчәк.

4 – Әсәрләрнең кайберләренең язучылары күрсәтелсә дә, бик күпләр әле кем тарафыннан язылачагы билгеләнмәгән. Оригиналь, тәрҗемә уларак язарга теләүчеләр бу хакта Гыйльми үзәккә мөрәҗәгать итәрләр. Әсәрләрнең вакытында чыгуларын тәэмин өчен без ноябрь аенда планның төп бүлекләрен тапшырып бетәргә уйлыйбыз. Мөрәҗәгатьләр менә шуны игътибарга алып хәзердән бирелсеннәр.

Татар Мәгариф комиссариаты Гыйльми үзәге рәисе: Галимҗан Ибраһимов.

Секретаре: Заһид Нуркин.

Гыйльми редакторы: Г. Шенаси.

Татарстан дәүләт нәшрияты директоры: Вәли Шәфигуллин.

## 1928
## Сообщение об избрании Г. Ибрагимова членом в Государственную Академию Художественных наук[1]

25 января 1928 г.

Наркомпрос
Главнаука
Государственная Академия
Художественных наук
Москва, ул[ица] Кропоткина, 32
№ 108

Об избрании в Государственную Академию художественных наук (ГАХН)

Сообщение

Москва 25-го января 1928 года.
Казань, Народный Комиссариат по просвещеню тов[арищу] Г. Ибрагимову.

Государственная Академия Художественных наук извещая Вас об избрании Вас членом Академии, настоящим обращается к Вам с просьбой не отказать приехать в течении текущего академического года в Москву для прочтения доклада.

Ученый секретарь ГАХН: А. А. Сидоров[2].
Ученый секретарь ОИН: Ю. Самарин.

Примечание: 1. Об этом имеются сообщения в печати: а) в газ[ете] «Кзыл Татарстан» (орган Татобкома, 1928 г[од]).

---

[1] Күчермә (машинкада язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (292 ф., 2 тасв., 1987 эш, 91 кәг.). Беренче мәртәбә татар теленә тәрҗемәсе «Татарстан» журналының 1997 елгы 3 нче санында (б. 28), оригиналда Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында текст кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган (Казан, 2000, б. 323). Текст күчермәдән алынды.

[2] *А. А. Сидоров* – Алексей Алексевич Сидоров (1891–1978), сәнгать тарихчысы, китап белгече һәм библиофил, СССР ФА мөхбир әгъзасы (1946).

## 1927
## Г. Ибраһимовның басылган әсәрләре хакында[1]

1927 ел

Галимҗан Ибраһимовның зурырак әсәрләре[2]

I – 1918 нче елга чаклы язган әдәби әсәрләре.

1 – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы». 1907 нче елда «Әлислах» гәзитендә басылган. 1910 нчы елны китап буларак басылган, 64 бит.

2 – «Татар хатыныниләр күрми». 1909 нчы елда Эстәрлетамакта «Каләм» нәшрияты тарафыннан бастырылган. 1911 нче елны кабат басылган. 148 бит.

3 – «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә». 1910 нчы елда Казандагы «Гасыр» нәшрияты тарафыннан бастырылган.

4 – «Йөз ел элек». Оренбургтагы «Вакыт» нәшрияты тарафыннан бастырылган (башта «Шура» журналында басылган). 35 бит.

5 – «Диңгездә». 1910 нчы елда шул ук «Вакыт» нәшрияты тарафыннан бастырылган (бусы да элек «Шура»да чыккан). 24 бит.

6 – «Карт ялчы». Шул ук «Вакыт» нәшрияты тарафыннан 1911 нче елда бастырылган. 26 бит. Бу әсәр хәзергә кадәр барысы 4 тапкыр басылды.

7 – «Карак мулла». 1912 нче елда «Гасыр» нәшрияты тарафыннан бастырылган. 30 бит.

8 – «Көтүчеләр». 1913 нче елда «Аң» журналында басылган. Соңыннан берничә тапкыр китап булып чыкты.

9 – «Габдрахман Салихов». «Аң»да 1913 нче елны басылды.

10 – «Уты сүнгән җәһәннәм». 1912 нче елда «Вакыт» тарафыннан бастырылган.

11 – «Яшь йөрәкләр». Оренбургтагы «Шәрык» нәшрияты тарафыннан 1912 нче елны бастырылган. 416 бит.

12 – «Яз башы». 1912 нче елда «Шәрык» тарафыннан бастырылган.

13 – «Табигать балалары». 1914 нче елда «Аң» тарафыннан бастырылган. 24 бит. Берничә тапкыр басылды.

---

[1] «Безнең юл» журналының 1927 елгы 12 нче санында (б. 34–35) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар графикасында беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Болар Г. Мөхәммәдиева иптәш тарафыннан русча төзелгән библиографиядән тәрҗемә итеп алындылар. *Редакция.*

II – 1918 нче елдан соңгы әдәби әсәрләре

14 – «Безнең көннәр». 1919 нчы елда Казандагы «Сабах» ширкәте тарафыннан бастырылган. 454 бит (бу әсәр 1914 нче елда басыла башласа да, цензор тарафыннан туктатылган булган).

15 – «Яңа кешеләр». 1921 нче елда Татгиз тарафыннан бастырылган.

16 – «Алмачуар». 1922 нче елда Татгиз тарафыннан бастырылган. 24 бит.

17 – «Кызыл чәчәкләр». 1922 нче елда Татгиз тарафыннан бастырылган. 147 бит.

18 – «Адәмнәр». 1923 нче елда Татгиз тарафыннан бастырылган. 54 бит.

19 – «Казакъ кызы». 1924 нче елда Мәскәүдәге Үзәк нәшрият тарафыннан бастырылган.

III –[19] 18 нче елга чаклы тел, әдәбият турындагы әсәрләре

20 – «Татар сарыфы». 1911 нче елда «Гасыр» нәшрияты тарафыннан бастырылган. 82 бит. Бу әсәр 1918 нче елда төзәтелеп 5 нче тапкыр басылды.

21 – «Татар нәхүе». Шул ук 1911 нче елда, шул ук «Гасыр» тарафыннан бастырылган. 74 бит. 1916 нчы елда 5 нче тапкыр басылды.

22 – «Татар имлясы». 1912 нче елда «Гасыр» тарафыннан бастырылган. 28 бит.

23 – «Татар телен ничек укытырга?» Шул ук елларны Казандагы «Сабах» тарафыннан бастырылган. 78 бит.

24 – «Әдәбият кануннары». 1916 нчы елда «Сабах» тарафыннан бастырылган. 78 бит. 1919 нчы елда «Вакыт» нәшрияты тарафыннан бастырылган.

25 – «Татар шагыйрьләре». 1913 нче елда «Вакыт» нәшрияты тарафыннан бастырылган.

26 – «Тел сабаклары». 1918 нче елда «Сабах» тарафыннан бастырылган. 179 бит.

IV – [19] 18 нче елдан соң язылган тел,
әдәбият турындагы әсәрләре

27 – «Иҗтимагый әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы». «Безнең юл», 1 нче сан.

28 – «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре». Комбинат басмасы. 1927 нче ел (төрле гыйльми мәкаләләр, докладлар мәҗмугасы). 143 бит.

29 – «Кара маяклар». 1924 нче елда Мәскәүнең «Нәшрият» кооперативы тарафыннан бастырылган. 70 бит. (Бу исә үзбәк һәм әзәрбәйҗан төрекчәләренә дә тәрҗемә ителеп басылган).

30 – «Пролетариат әдәбияты турында». 1924 нче елда шул ук нәшрият тарафыннан бастырылган. 74 бит.

31 – «Төрек телләренең имлясы». Беренче тюркология съездында укылган доклад (19126 нчы елда, Бакуда). Тюркология съезды материаллары белән басыла.

Татарлар арасындагы иҗтимагый һәм революция хәрәкәтләре турындагы әсәрләр. ([19]21 нче елдан соң язылганнар)

32 – «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы». 1921 нче елда Татгиз тарафыннан бастырылган. 145 бит.

33 – «Татар студентлары хәрәкәтеннән». 1922 нче елда Татобласкомол тарафыннан бастырылган. 42 бит.

34 – «1905 нче елда татарлар». Комбинат тарафыннан 1925 нче елда бастырылган. 235 бит (бу китап русчага да тәрҗемә кылынды).

35 – «Урал һәм уралчылар». 1927 нче елда Татиздат тарафыннан бастырылды. 42 бит.

36 – «Татар мәдәнияты кая бара». 1928 нче елда шул ук Татиздат тарафыннан бастырылды. 46 бит.

VI – Галимҗан Ибраһимов редакциясендә
һәм юлбашчылыгы астында чыккан әсәрләр

37 – «Мулланур Вахитов». 1919 нчы елда Хәрби коллегия тарафыннан чыгарылган.

38 – «Каюм Насыйри». 1923 нче елда Комбинат тарафыннан чыгарылган.

39 – «Бабич шигырьләре». 1922 нче елда Татгиз тарафыннан чыгарылган.

40 – «Ярдәм I». 1922 нче ел, Татгиз басмасы.

41 – «Ярдәм II». 1922 нче ел, Татгиз басмасы.

42 – «Биш ел эчендә». 1925 нче елда Татарстан Үзәк Башкармасы тарафыннан чыгарылган.

43 – «Татарстанны өйрәнү материаллары» (урыс телендә). 1925 нче елда Мәгариф халык комиссариаты тарафыннан чыгарылган.

44 – «Ленин исемендәге мәҗмуга». 1920 нче елда Үзәк Бюро тарафыннан Ленинградта чыгарылган.

45 – «Троцкизмга каршы». Комбинат басмасы, 25 нче ел.

46 – «Альманах». 1914 нче елда «Аң» тарафыннан чыгарылган.

## Г. Ибраһимовның авыруы хакында «Кызыл Татарстан» газетасында[1]

22 март 1927 ел

Галимҗан иптәш Ибраһимовның хәле

Татарның мәшһүр карт язучысы Галимҗан иптәш Ибраһимов күптәннән бирле туберкулез авыруы белән авырый һәм аның бу авыруы 22–23 нче елларда тукталган иде. Аның бу авыруы үткән елның август аенда яңадан башланып, авызыннан кан килүләр булды. Шуннан соң профессор һәм врачлар аңар Сухумга барырга киңәш бирделәр.

Сухумда башта Ибраһимов иптәшнең авыруында яхшыру булса ла, һаваларның начарлану сәбәпле соңга таба хәле авырлашты һәм Сухумнан шул авыру килеш кайткач эшендә дәвам итте.

Моннан ике атналар элек иптәш Ибраһимовта җиңелчәрәк грипп авыруы булып, шуның белән бергә кан килү куркынычы сизелде.

Иптәш Ибраһимов Татарстан Советлары 7 нче съездының[2] 17 нче март иртәнге утырышында үзенең хәле авырлашканын сизде һәм аннан шушы көндә байтагук кан китте. Шушы көндә профессор Чебоксаров, профессор Лурия, профессор Терегулов һәм доктор Еналиевлардан[3] гыйбарәт беренче консилиум булды. 18 нче март көнендәге икенче консилиумда доктор Салих Корбангалиев[4] тә бар иде.

Иптәш Ибраһимовның температурасы 18 нче март көндез 39, 5, кич белән 40, 1, 20 нче мартта 39 ярым булып, кичә иртәнге

---

[1] Беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 22 март санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләре»нең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 315) кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган. Текст газетадан алынды.

[2] *Татарстан Советлары 7 нче съездыны* – Татарстан Советларының 7 нче съезды 1927 елның 15–21 март көннәрендә Казанда була.

[3] *Еналиев* – Сөләйман Бикмөхәммәт улы Еналиев (1894–1938), күз табибе, сәламәтлек саклау эшен оештыручы. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[4] *Салих Корбангалиев* – Салих Мөхетдин улы Корбангалиев (1901–2001), сәламәтлек саклау эшлеклесе, хирург, медицина фәннәре докторы (1955), профессор (1956), мактаулы уйлап табучы. 1927 елда Казан университетының хирургия клиникасында эшли.

температурасы 38,5 иде. Кичә көндез сәгать 12 дәге температурасы 37,8, пульсы 90 булды. Иптәш Ибраһимовтан кан китү 17 нче мартның төнендә булып, 18 нче мартта катырак рәвештә кан китте. Ул кичә көндез сәгать 12 ләрдә Казанның Иске клиникасына күчерелде. Аның янында төнләрдә татар докторларыннан Локманов һәм Мамишов иптәшләр дежурлык кылдылар. Ә хәзер клиникага күчерелгәч, профессорлардан Чебоксаров, Лурия, Терегулов һәм доктор Корбангалиевлар карыйлар.

Иптәш Ибраһимовта соңгы көннәрдә кан төкереге күренә. Анда туберкулез авыруы өстенә уң як үпкәсенең югаргы һәм урта өлешендә үпкә шеше авыруы да бар.

Профессорларның әйтүләренә караганда иптәш Ибраһимовның кичә көндез сәгать 12 дәге хәле түбәндәгечә:

Йөрәкнең эшләве яхшы, хәле җитди, пульсы яхшы. Хәзерге көннәрдә аерым куркыныч күренми.

## Г. Ибраһимовның авыруы хакында «Кызыл Татарстан» газетасында[1]

24 март 1927 ел

Галимҗан иптәш Ибраһимовның хәле

Иптәш Ибраһимовның 23 нче март көндез сәгать 2 дә хәле түбәндәгечә:

Үпкә шеше авыруы көчәйми, йөрәге яхшы эшли. Кан китүе юк. Температурасы – 38. Пульсы – 90. Хәле беркадәр яхшырак.

## Г. Ибраһимовның авыруы хакында «Кызыл Татарстан» газетасында[2]

25 март 1927 ел

Галимҗан иптәш Ибраһимовның хәле

Иптәш Ибраһимовның 24 нче март, көндез сәгать бердәге хәле түбәндәгечә:

Йөрәге яхшы эшли. Кан китү юк. Үпкә шеше авыруы көчәйми. Температурасы – 38. Пульсы – 90. Хәле канәгатьләнерлек дияргә ярый.

---

[1] Беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1927 елгы 24 март санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 316) кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган. Текст газетадан алынды.

[2] Беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1927 елгы 25 март санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 316) кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган. Язучының фотосурәте дә бар. Текст газетадан алынды.

## Г. Ибраһимовның авыруы хакында «Кызыл Татарстан» газетасында[1]

26 март 1927 ел

Галимҗан иптәш Ибраһимовның хәле

Иптәш Ибраһимовның 25 нче март көндез сәгать 2 дәге хәле түбәндәгечә:

Йөрәге яхшы эшли. Кан китү юк. Температурасы – 38,3. Пульсы – 90. Гомумән, хәлендә әйтерлек зур үзгәреш күренми.

## Г. Ибраһимовның авыруы хакында «Кызыл Татарстан» газетасында[2]

27 март 1927 ел

Галимҗан иптәш Ибраһимовның хәле

Иптәш Ибраһимовның 26 нчы марттагы көндезге хәле турында профессор Чебоксаров түбәндәге сүзләрне сөйләде:

Турыдан-туры куркыныч беткән шикелле күренә, кан китү артык тәкрарланмый. Уң як үпкәдәге шеш авыруы тагын да акыръная. Шеш үпкәнең сул ягына эләкмәгән. Йөрәгенең эшләве яхшы. Пульсы – 84. Температурасы – 38,2. Гомуми хәле – канәгатьләнерлек.

[1] Беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1927 елгы 25 март санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан. 2000, б. 316) кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган. Текст газетадан алынды.

[2] Беренче мәртәбә «Кызыл Татарстан» газетасының 1927 елгы 27 март санында, аннан соң Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында (Казан, 2000, б. 317) кайбер төгәлсезлекләр белән бастырылган. Текст газетадан алынды.

## 1928

## Акт освидетельствования для установления наличия, степени и характера инвалидности Г. Г. Ибрагимова[1]

4 января 1928 г.

Фам. *Ибрагимов.*

Имя *Галимжан.*

Отч[ество] *Гирфанович.*

Год рожд. *40.*

Пол. *Муж[ской].*

Место рождения: *Быв[шей] Уфимской губ[ернии] в Татреспублике*[2].

Грамотен.

Предприятие, учреждение, хозяйство, в котором был занят до наступления инвалидности:

а) Наименование: *Академич[еский] Центр.*

в) Адрес (местонахождение): *Татреспублика.*

д) Должность: *Председатель.*

Сколько лет (месяцев) работал в данном пред.: *4-й год.*

В каком возрасте начал работать по найму: *с 18 лет.*

Причины инвалидности:

В. *Общие заболевания.*

Медицинская часть.

Субъективные жалобы исследуемого: *Слабость, кашель, одышка. Сильно нервничает.*

Анамнез: *Заболевание туберкулезом обнаружено 15 лет назад. С 1914 года страдает малярией. В 1920–1921 г[одах] болел воспалением почечных лоханок. Последн[ие] 3–4 года болеет колитом. Не работает с 17 марта 1927 года.*

Данные предварительных исследований (химич[еских], микрокоп[ических], рентгенск[опических] и проч[их]) и больничных наблюдений:

Справка д[окто]ра Керцмова от 30/XII с указанием на заболевание туберкулезом легких продуктивно-эксудативн[ой] формы с каверном. Ст.– III. По поводу частого кровохарк[ания] ему с

[1] Төп нөсхә элекке СССР Үзәк дәүләт Октябрь революциясе архивында саклана (1235 ф., 136 тасв., 819 эш, 16, 16 (икенче ягы), 17, 17 (икенче ягы) кәг.). Текст Казанда яшәүче Ә. А. Шамованың шәхси архивындагы фотокүчермәдән алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *…в Татреспублике* – бу хата, дөресе:… в Башреспублике.

I /XII-27 года накладывется правосторонний пневмоторакс, 10 мес[яцев] лежит в постели.

Данные объективного исследования:

1 / Общий вид, состояние питания, кожа: *Кожные покровы и видимые... оболочки норм.– окраски. Подкожный жировой слой тонок.*

2 / Костно-мышечная система: *без заметных изменений.*

3 / Внутренние органы:

а) органы кровообращения: *левая граница сердца на 3 пальца кисти руки от левой сосковой линии. Правая по левому краю грудины. Дыхание слабое. Пульс 100 в 1.*

б) дыхание: *Справа вследествие наложения пневмоторакса ослабление дыхание, сзади по всей поверхности легкого. Спереди субкренитирующие храпы сверху до низу. Под соском и к наружи от него омфорическое дыхание. Слева предосженный жесткий выдох отбирахитирующ[ий]. Храпы по передней подмышечной линии внизу.*

в) пищеварение:

Болежиорность по ходу толстых кишек.

г) мочеотделение: *без заметных изменений.*

4) Нервная система: *Красн. дермограф. новым. сухожил. красн. рефлексор, легко волнуется без всяких достаточных оснований.*

5) Зрение: *нормальное.*

6) Слух: *нормальный.*

Диагноз:

а) заболевания, констатированные у исследуемого (точный перечень): *Туберкулез легких Ст.– III с каверном, невростения резко выраж[енная].*

б) Основное заболевание, являющееся причиной стойкой утраты трудоспособности: *Туберкулез легких Ст.– III с каверном.*

Заключение бюро врачебной экспертизы.

I. Имеется ли стойкая утрата трудоспособности: *Имеется.*

II. Группа инвалидности: *Первая.*

1) Нет ли состояния беспомощности: *Нет.*

2) Не потеряна ли способность ко всякому труду: *Потеряна.*

I. Подлежит переосвидетельствованию через 12 месяцев 4 января 1929 года.

4 января 1928 г.

(От руки): Медицинск[ая] часть истории болезни с подлинным верно.

Д[окто]р (*подпись врача Р. Х. Тагировой*)

*Печать*

Верно: (*подпись неразборчива*)

## Г. Ибраһимовның Дәүләт сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы булып сайлануы хакында[1]

29 гыйнвар 1928 ел

Галимҗан Ибраһимов – Дәүләт сәнгать фәннәре академиясенең члены.

Бөек татар әдибе Галимҗан Ибраһимовның егерме еллык хезмәт бәйрәме уңае белән Дәүләт сәнгать фәннәре академиясенең Галимҗан Ибраһимовның әдәби, иҗади, шулай ук гыйльми хезмәтләрен тәкъдир итеп аны шушы академиянең члены итеп бертавыштан сайлавы турында Татарстан Мәгариф халык комиссариатына Мәскәүдән рәсми кәгазь алынды.

Галимҗан Ибраһимов – татарлардан академия члены дәрәҗәсен алган беренче гыйлем эшчесе.

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 29 гыйнвар санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Г. Ибраһимовның XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт юбилее уңае белән нәшер ителгән гыйльми-тәнкыйди җыентык хакында[1]

1928 ел

«Галимҗан Ибраһимов»[2]

Бөек татар әдибе Галимҗан Ибраһимовның XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт юбилее уңае белән Мөхәммәт Таһиров, Габдрахман Сәгъди, Сафа Борһан[3], Г. Нигъмәти[4] иптәшләр редакциясендә Татиздат чыгарган гыйльми-тәнкыйди җыентык, 196 бит. Бәясе 1 сум 75 тиен.

Галимҗан Ибраһимовның әдәби, гыйльми-иҗади хезмәтләре белән татар хезмәт массасын киң рәвештә таныштыру өчен мондый җыентыкның кирәклеге, мөһимлеге турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Җыентык чыннан да шул зур мәсьәләгә җавап бирерлек булып чыккан. Җыентык Исхак иптәш Рәхмәтуллин тарафыннан язылган сүз башы белән башланып, калган материаллар түбәндәгечә ике бүлеккә бүленгәннәр:

1 – Галимҗан Ибраһимовның әдәби-иҗтимагый хезмәте; 2 – Галимҗан Ибраһимовның гыйльми-иҗади хезмәте.

Беренче бүлектәге мәкаләләр

«Азатлык һәм матурлык шагыйре» – Сәнгать фәннәре академиясе президенты профессор П. Коган[5] мәкаләсе; «Галим-

---

[1] «Безнең юл» журналының 1928 елгы 1 нче санында (б. 32), «Мәгариф» журналының 1928 елгы 2 нче санында (б.104) урнаштырылган. Текст соңгы чыганактан алынды һәм гамәлдәге татар графикасында беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Галимҗан Ибраһимов»* – Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык) // Җыентык Мөхәммәт Таһиров, Габдрахман Сәгъди, Сафа Борһан, Галимҗан Нигъмәти иптәшләрдән гыйбарәт комиссия редакциясендә чыга.– Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1928 ел.– 196 б.

[3] *Сафа Борһан* – Сафа Вафа улы Борһан (1899–1937), журналист. 1926–1928 елларда Татар китап нәшриятында мөхәррире булып эшли. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[4] *Г. Нигъмәти* – Галимҗан Нигъмәти (Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәтуллин) (1897–1941), әдәбият галиме, тәнкыйтьче. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[5] *П. Коган* – Петр Семенович Коган (1872–1932), әдәбият галиме, тәнкыйтьче, тәрҗемәче.

җан Ибраһимовның әдәби иҗатлары» – Габдрахман Сәгъди; «Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә революция мотивлары» – Г. Нигъмәти; «Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә тематика һәм өслүб яклары» – Г. Толымбайский; «Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә татар хатын-кызлары тормышы һәм хатын-кыз типлар» – Әминә Халит.

Икенче бүлектәге мәкаләләр:

«Әдәбиятыбызда марксизм тәнкыйте һәм Галимҗан Ибраһимов» – Кави Нәҗми; «Галимҗан Ибраһимов һәм бездә әдәбият белеме» – Гомәр Галиев; «Галимҗан Ибраһимовның тел мәйданындагы хезмәтләре» – Җәмал Вәлиди; «Галимҗан Ибраһимов татарны өйрәнүче» – профессор А. Самойлович[1]; «Татар грамматикасының эшләнүе һәм Галимҗан Ибраһимов» – Нигъмәт Хәким[2]; «Галимҗан – методист, педагог» – Мөхетдин Корбангалиев; «Революция хәрәкәтләре тарихы һәм Галимҗан Ибраһимов» – М. Сәгыйдуллин; «Тарихчы-сәясәтче булу ягыннан Галимҗан Ибраһимов» – профессор Н. Фирсов[3]; «Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең библиографиясе» – Рифгать Таһиров[4], Г. Мөхәммәдова.

Җыентык яхшы техникада басылып, Галимҗан Ибраһимовның төрле вакыттагы бик күп төрле рәсемнәре һәм иң соңгы кульъязмасы белән бизәлгән.

Җыентыкның юбилейнең рәсми тантана көненнән бер айлап алдан чыгуы бигрәк яхшы булган. Бөтен татар мәктәпләре, гыйльми-әдәби оешмалар һәм җәмгыятьләр, гомумән тиешле җәмәгать учреждениеләре, әлбәттә, бу җыентыкны кулда итәргә тиешләр.

Ф.

[1] *А. Самойлович* – Александр Николаевич Самойлович (1880–1938), шәркыятьче, СССР Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1929).

[2] *Нигъмәт Хәким* – Нигъмәтулла Гыйният улы Хәкимов (1889–1937), тел, әдәбият белгече. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[3] *Н. Фирсов* – Николай Николаевич Фирсов (1864–1933), тарихчы.

[4] *Рифгать Таһиров* – Рифгать Шакирҗан улы Таһиров (1903–1977), тарихчы.

## Г. Ибраһимовның 20 еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт юбилее уңае белән Мәскәүдә үткәрелгән кичә хакында[1]

2 март 1928 ел

Мәскәүдә Галимҗан Ибраһимов иптәшнең юбилее
Коммунистический академиядә Галимҗан Ибраһимов кичәсе.

25 нче февраль, кич сәгать сигездә Коммунистический академия бинасында татарның зур әдибе, коммунист иптәш Ибраһимов Галимҗанның әдәби, гыйльми, иҗтимагый хезмәтләренә 20 ел тулу уңае белән аны тантаналы рәвештә олылау өчен багышланган кичә үткәрелде.

Бу кичәне СССР халыкларының әдәбиятын өйрәнү комиссиясе белән берлектә Коммунистический академия оештырган иде. Кичәдә Мәскәүдәге татар-башкортларның, башка төрек халыкларының гыйльми көчләре һәм Шәрык әдәбияты белән кызыксынучы, аны өйрәнүче гыйльми көчләр, партия һәм совет оешмаларының вәкилләре бар иде. РСФСР Халык мәгариф комиссариаты коллегиясе әгъзасы иптәш Гасыйм Мансуров[2] кичәне рәсми рәвештә ачып, кыскача нотык сөйләде. Ул үзенең нотыгында: «Без бүген партиябезнең әгъзасы иптәш Галимҗан Ибраһимовны егерме еллык әдәби, мәдәни хезмәте өчен тантаналы рәвештә зурлыйбыз. Ул татарның әдәби, иҗтимагый, сәяси тормышында бик сирәк очрый торган хезмәтчеләренең берсе. Аның татар эшчәннәре өчен күрсәткән хезмәтләре бик күп тармаклы булып, татар эшчәннәренең мәдәни тормышында күтәрелгән мәсьәләләрнең бөтенесендә актив рәвештә катнашты. Ул егерме ел буена төрле әдәби һәм фәнни әсәрләр, татар телен өйрәнү турында китаплар һәм мәкаләләр язды. Шуның белән бергә татарның общественный эшенә активный катнашып, күп көчләр салды.

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 2 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Гасыйм Мансуров* – Гасыйм Гата улы Мансуров (1894–1955), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог.

1910–1911 нче елларда Волга буе татарларын өйрәнгәндә ул зур гыйльми хезмәтләр күрсәтте.

Татарлармы, төрекләрме мәсьәләсе кузгалгач, бу мәсьәлә Ибраһимов иптәшнең активный катнашуы һәм инициативасы белән татарлар төрек милләтенең бер тармагы дигән рәвештә хәл ителде. Җыеп әйткәндә, ул общественный тормышта кузгалган мәсьәләләрне ачык аңлап, дөрес чишә белеп, туры агымга төшерүчеләрдән иде. Кайбер мәсьәләләрдә аның аерым хаталары булгалады, ләкин ул хаталар аның общественный тормышта һәм художество дөньясында булган урынын югалтмый», – ди.

Аннан соң Максудов Мәхмүт иптәш сөйли. Максудов иптәш үзенең докладында Ибраһимовның әдәби әсәрләрен ике чорга – Октябрь революциясенә кадәр һәм Октябрь революциясеннән соңгы чорларга бүлеп анализ ясый һәм аның аерым әсәрләреннән парчалар укып, язучының ничек үсүен, нинди баскычлар үтүен бик матур итеп гәүдәләндерә.

Профессор Бороздин[1] доклады

– Мин Галимҗан Ибраһимов иптәш белән беренче мәртәбә Фәннәр академиясенең юбилее вакытында очраштым. Чит илләрнең фән галимнәре аның белән танышып, аңа зур игътибар һәм зурлау белән карадылар. Өченче мәртәбә Тюркология съездында очраштым. Ләкин бу мәртәбәдә ул тюркология эше белән бик нык мәшгуль булганга, аның белән күп сөйләшергә туры килмәде.

Мин Татарстан Җөмһүриятенең 5 еллык юбилеендә булдым. Ибраһимов иптәш ул юбилейгә багышлатып язылган китапларны юбилей көненә бастырып өлгертә алган иде.

Беренче татар операсы «Сания»гә башлангыч сүзне ул язды. Казанда «Сания» беренче мәртәбә сәхнәгә куелганда миңа аның белән бергә карарга туры килде. Ул башта бик дулкынланып, борчылып утырды. «Сания»не куюдан яхшы нәтиҗә чыккач, ул бик канәгатьләнде.

Активный һәм янып торган энергияле хезмәтчене авыру безнең арабыздан аерды. Ул хәзер эшли алмый, эшли алмауга хафаланадыр. Шуңа күрә аңа бу кичә исеменнән тәбрик телеграмы җибәреп, аның сәламәтләнүендә теләктәш булуны тәкъдим итәм, дип сүзен бетерде.

[1] *Бороздин* – Бороздин Илья Николаевич (1883–1959), тарихчы-шәркыятьче, этнограф, педагог, әдәбият тәнкыйтьчесе.

Түрәколов иптәш яңа төрек әлифбасы Үзәк комитеты исеменнән тәбрик әйтеп, Галимҗан Ибраһимов иптәшнең иҗтимагый эшендәге кайбер хаталарына тукталып китә.

Үзәк комитет матбугат бүлеге вәкиле Аршаровни[1] иптәш үзенең сүзендә Ибраһимов иптәшнең коммунист булуы ягыннан карап бәя бирде.

Кичә Г. Мансуров иптәшнең соңгы сүзе белән тәмам була.

Мәскәү татар эшчеләре клубында җыелыш

Татар әдәбияты һәвәскәрләре җыелышында 26 нчы февральдә Галимҗан Ибраһимовның художник булуы турында Мәскәүнең татар эшчеләр клубында Мәхмүт Максудов иптәшнең доклады булды. Бу җыелышка югары мәктәпләрдә укучы студентлар, яшь язучылар килгән иде. Максудов иптәшнең докладының мөндәриҗәсе Коммунистический академиядә ясаган доклады белән бер иде. Докладтан соң фикер алышулар булып, унга якын иптәшләр фикер алышуга катнаштылар. Фикер алышу вакытында төп мәсьәлә Галимҗан Ибраһимов иптәш нинди әдип, вак буржуа язучысымы, әллә пролетариат язучысымы дигән формада куелды.

Шамов иптәш Галимҗан Ибраһимовны пролетариат язучысы, марксист дип танырга мөмкин дигән караш белән чыгып, аны русларның Максим Горькиенә ошатты. Максим Горький кебек реакция чорларында Галимҗан рух күтәренкелеге биреп торган оптимис[т] әсәрләр бирде, ди. Шулай ук Галимҗанның классик булып-булмавы турында фикер алышынды.

Г. Ишмаев.

[1] *Аршаровни* – Аршалуис Михайлович Аршаруни (1896–1985), әрмән әдәбият галиме, публицист, тәнкыйтьче.

## Г. Ибраһимовның 20 еллык юбилее уңае белән Татар мәдәният йортында ачылган күргәзмә хакында[1]

8 апрель 1928 ел

Татар хезмәт халкының бөек әдибе Г. Ибраһимов иптәшкә культура дөньясы тиешле бәяне бирде.

Рәсемдә: Г. Ибраһимовның 20 еллык юбилее уңае белән Татар мәдәният йортында ачылган күргәзмәнең тәбрикләр бүлеге күренә.

## Ялтада дәваланучы Г. Ибраһимовның сәламәтлеге хакында[2]

1928 ел

Карт әдип Галимҗан Ибраһимов терелә

Карт әдибебез Галимҗан Ибраһимовның XX еллык тантаналары үткәч, Татарстан Мәгариф халык комиссариаты юбилейнең тиешле материалларын тапшыру һәм Галимҗан Ибраһимовның хәлен белү өчен аның янына Татарстан Гыйльми үзәк рәисе иптәш Таһировны[3] җибәргән иде. Без бу урында Галимҗан Ибраһимовның юбилей уңае белән Татарстан Мәгариф Халык Комиссариатына җибәргән хатын һәм Галимҗан Ибраһимовның Таһиров иптәш белән утырышканда яңалиф турында сөйләгән кайбер фикерләрен басабыз[4].

Редакция

---

[1] «Татарстан» газетасының 1928 елгы 8 апрель санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] «Безнең юл» журналының 1928 елгы 5 нче санында (б. 29) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[3] *Таһиров* – Мөхәммәт Хәмзә улы Таһиров (1895–1929), сәясәт эшлеклесе. 1924–1929 елларда ТАССР Мәгариф халык комиссары урынбасары, Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәк рәисе.

[4] *…яңалиф турында сөйләгән кайбер фикерләрен басабыз* – кара: Яңалиф турында Г. Ибраһимов // Безнең юл.– 1928.– № 5.– Б. 30.

## 1933
## Г. Ибраһимовның Ялтадан Казанга кайтышлый Мәскәүдә тукталуы хакында[1]

30 сентябрь 1933 ел

Галимҗан Ибраһимов Мәскәүдә

Кичә 29 сентябрьдә татар әдәбиятының карт һәм бөек талантлы язучысы Галимҗан Ибраһимов иптәш Татарстан колхозчыларының II-нче съездына[2] делегат булып барышлый Мәскәүгә тукталды. Ул 20 сентябрьдә үк кайтып җитәргә тиеш булса да, соңгы көннәрдә һаваларның кискен рәвештә сәламәтлегенә зарар китерерлек булып, үзгәрүе аркасында кичегеп кайтырга мәҗбүр булган.

Ул Мәскәү совет язучылары белән булган очрашу әңгәмәсендә соңгы вакытларда үзенең сәламәтлеге яхшыру ягына күчеп китүен, тик август айларында гына һавалар үзгәрү аркасында тагы да көчәя төшкәнен белдерде. Ул бүген генә Мәскәүгә килеп, поездда тынычсызлануына карамастан, Татарстан колхозчыларының съездына үзеннән булмаган сәбәпләр белән ачылу вакытына кичегеп баруына зур үкенеч белдереп, кичке поезд белән Татарстанга, съездның ябылу кичәсенә булса да өлгерергә ашыга.

– Съездның ябылу кичәсен генә булса да күрмәү минем кайту мәшәкатьләренең яртысын юкка чыгара. Татарстан колхозчыларының бу съездына көрәшчеләр тупланачак. Мин аларны үз күзем белән күрәсем килгән иде,– ди.

Ә әдәби мохит белән артык кызыксынганын, соңгы вакытларда әдәбият тирәсендә булган яңалыклар белән танышасы килгәнен, моның өчен аз вакытка гына кайткан арада тирәнтен танышу мөмкинлеге аз булуын аңлатты.

– Кышкы һавалар минем сәламәтлегем өчен яхшырак. Шуңар күрә дә кыш көне озаграк вакытка кайтып, Мәскәү, Казан язучылары тирәсендә булган яңалыклар белән тирәнрәк таны-

[1] «Коммунист» газетасының 1933 елгы 30 сентябрь санында урнаштырылган. Авторы күрсәтелмәгән. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *…Татарстан колхозчыларының II-нче съездына* – ударник колхозчыларның Бөтентатар икенче съезды Казанда 1933 елның 27 сентябрь – 4 октябрь көннәрендә уздырыла.

шырга телим. Шулай ук алдынгы колхозларның байтагын йөреп чыгарга һәм мин киткәч туган яңа гигантлар белән танышырга. Аларны өйрәнергә теләгем зур, – ди.

Ул үзенең ашыгыч беседасында Мәскәү язучыларының яңалыклары белән кызыксынып, аларның съездга ничек хәзерлек алып барулары һәм нәрсәләр өстендә эшләүләре турында сорашты.

– Тавышыгыз аз чыга, матбугатта үзегезнең барлыгыгызны аз белдерәсез, – дип Мәскәү язучыларының оешкан рәвештә ничек эш алып барулары гәзет битләрендә сыек яктыртылуы турында бик урынлы күрсәтмә ясады.

Ул 29 нчы сентябрьдә кичке поезд белән Татарстанга китте.

## Г. Ибраһимовның Мәскәүдән Казанга китүе хакында[1]

2 октябрь 1933 ел

Галимҗан ага Ибраһимов Казанга китте

29 нчы сентябрь кич сәгать $9^{45}$ минутта 12 нче номерлы поезд белән Галимҗан Ибраһимов Казанга китте. Галимҗан ага Ибраһимовны озатырга татар язучыларыннан Шамил Госман, Толымбайский, Әхмәт Фәизләр катнаштылар. Вагонда Г. Ибраһимов белән язучылар арасында җанлы рәвештә фикер алышулар булды. Г. Ибраһимов Казаннан Кырымга кайтканда яңадан Мәскәүгә тукталырга булды. Ул – «Мәскәү предприятиеләренә барып, эшчеләр тормышы белән танышырга теләгем зур, сәламәтлегем мөмкинлек бирсә, бу максатымны тормышка ашырырга тырышырмын», ди.

Г. Ибраһимов Магнитогорскийдагы рекордчы Галиуллинчылар мәсьәләсе белән кызыксына. Үзен озатырга килүчеләргә,– алар хәзер нинди эштә эшлиләр, дип сөаль куя. Аны озатырга катнашучы язучылар һәм матбугат вәкилләре: «Галиуллин үзе прораб ярдәмчесе булып эшли, ә бригадасында эшләүчеләр мартен цехына эксплуатациягә күчтеләр», дип җавап бирәләр. Галимҗан Ибраһимов Магнитогорскийдагы аерым эшчеләр белән язышуы турында сөйләп уза.

$9^{45}$ та 12 нче номерлы поезд кузгала. Озатырга килүчеләр Казаннан кайтканда Мәскәүгә тукталуын сорап саубуллаштылар.

---

[1] «Коммунист» газетасының 1933 елгы 2 октябрь санында урнаштырылган. Авторы күрсәтелмәгән. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Г. Ибраһимовның Ялтадан Казанга кайтышлый Мәскәүдә журналистлар белән очрашуы хакында[1]

3 октябрь 1933 ел

Галимҗан Ибраһимов белән очрашу кичәсе

29 нчы сентябрьдә татарның атаклы язучысы Галимҗан ага Ибраһимовның Мәскәүгә килү уңае белән «Коммунист» гәзете[2] редакциясе язучы, журналистлар белән очрашу кичәсе ясады. Очрашу кичәсенә Мәскәү татар язучылары, журналистлар, хәбәрчеләр һәм берникадәр татар эшчеләре активлары җыелган иде.

Кечкенә сөйләшү утырышы шактый зур кичәгә әйләнде. Карт язучыны бөтенесе сагынганнар. Бөтен иптәшләр Галимҗан аганы каршы алу өчен, күрер өчен, сөйләшер өчен килгәннәр.

Галимҗан ага Ибраһимов үзенең кыска гына речендә татар совет язучылары алдында торган конкрет бурычларны санап үтә.

– Хәзергә иң мөһим мәсьәлә, – ди ип[тәш] Ибраһимов, – совет язучыларының беренче Бөтенсоюз съездына хәзерләнү. Бу эшкә бөтен язучылар, бигрәк тә коммунист язучылар бик нык катнашырга тиешләр. Съездның көн тәртибенә бик күп, бик мөһим мәсьәләләр куелды. Шул җөмләдән, татар әдәбияты турындагы докладны күрсәтеп үтәргә була. Тик татар язучылары үзләре, үзләрен читтә тотмыйча, эшкә бик нык катнашырга тиешләр.

Мәскәү язучылары өчен теория белеме ягыннан үсү өчен зәмин зур. Тик аны файдалана белергә кирәк. Тәнкыйтьчеләр өчен, драматурглар, прозачылар, шагыйрьләр өчен үсәргә, эшләргә мөмкинлек зур. Агишев, Толымбай, Усманов, М. Максут иптәшләр тәнкыйть, проза, драматургия өлкәсендә рус язучылары белән аралышып, съездга хәзерләнү тәртибендә эш алып ба-

[1] «Коммунист» газетасының 1933 елгы 3 октябрь санында бастырылган. Автор үзен «Әй» дип кенә күрсәткән. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Коммунист» гәзете* – СССР ҮБК милләтләр Советы басма органы, 1932 елның 9 гыйнварыннан 1934 елның 30 декабренә кадәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси газета. Барлыгы 845 саны дөнья күрә. «Эшче», «Игенчеләр» газеталарын берләштерү нигезендә барлыкка килә. Мөхәррире И. Агишев була.

рырга тиешләр. Шулай ук шагыйрьләрдән Ә. Яркәй[1], М. Крыймов[2], Ә. Фәиз[3] һәм М. Җәлил[4] иптәшләр, Фадеев[5] җитәкчелеге астында төзелгән поэзия комиссиясендә эшләсәләр, үзләренә зур теоретик һәм практик белем алачаклар, ди.

Ип[тәш] Ибраһимов язучылар алдында торган әһәмиятле бурычларның берсе итеп социалистик реализм методын куллану, аны ныклап үзләштерү кирәклекне әйтә. Шулай ук организацион эшләр турында. Яшь язучылар арасында эшләү һәм башка күп кенә эшләр хакында конкрет һәм мәгънәле киңәшләр бирә.

Беседага «Коммунист» гәзетәсенең җаваплы редакторы И. Агишев, язучылардан Ш. Усманов, Г. Толымбай, Ә. Яркәй һ.б. иптәшләр катнашчылык иттеләр. Язучылар татар әдәбиятының соңгы елларда шактый үсүен күрсәтү белән бергә, социализм төзелеше темпларыннан артта калып баруын сөйләделәр. Толымбай татар язучылары арасыннан профессиональ язучылар үстерү өчен шартлар тудырырга кирәклекне сөйләде. Башка иптәшләр татар телендә матур әдәбиятны күбрәк чыгару мөмкинлекләрен арттырырга кирәклеккә туктадылар. Хәзерге барышында бу эш канәгатьләнерлек түгел, шуның аркасында яшь язучылар кадрын хәзерләү эшенең артта баруын күрсәттеләр.

Чуаш язучылары исеменнән Галимҗан ага Ибраһимовны ип. Моластовкин[6] котлады. Урта Иделдәге әдәбият түгәрәге исеменнән карт язучыны Сәет Таепов тәбрикләде.

Ип[тәш] Галимҗан Ибраһимов үзенең җавап речендә матур әдәбият мәйданының киң күләмдә җәелеп баруын, аның социализм төзелешенә конкрет ярдәм итәргә тиешлеген сөйләде.

Алдыбызда торган бурычларны үтәр өчен социализм төзелеше эшендә нык катнашып, аның һәрбер катлаулы тармагын нык үзләштерергә кирәклекне, яшь язучыларның теоретик сәяси белемнәрен арттыру өстендә бик нык эшләргә кирәклекне күрсәтте.

---

[1] *Ә. Яркәй* – Әхмәт Ерикәй (Әхмәт Фазыл улы Ерикиев) (1902–1967), шагыйрь.

[2] *М. Крыймов* – Мансур Кәрим улы Крыймов (1898–1938), шагыйрь.

[3] *Ә. Фәиз* – Әхмәт Әхмәтсафа улы Фәйзи (Фәйзуллин) (1903–1958), язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе, ТАССР, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1953, 1957).

[4] *М. Җәлил* – Муса Мостафа улы Җәлилов (1906–1944), шагыйрь, Советлар Берлеге Каһарманы (1956, һәлак булганнан соң).

[5] *Фадеев* – Александр Александрович Фадеев (1901–1956), рус язучысы.

[6] *Моластовкин* – Гаврил Александрович Молостовкин (1900–1958), журналист, тәрҗемәче.

Галимҗан ага Ибраһимовның күрсәтүләре бик урынлы һәм вакытлы. Язучылар арасында тәрбия эшләрен съездга хәзерләнү уңае белән җәеп җибәрергә кирәк.

Очрашу кичәсенә катнашкан иптәшләр Галимҗан аганың Казаннан кайтышлый Мәскәүдә озаккарак вакытка тукталуын сорадылар.

## 1934
## Г. Ибраһимовның Совет Язучылары союзына кабул ителүе хакында[1]

15 июнь 1934 ел

Совет язучылары Союзы

Татарстан Совет Язучылары Союзының Оештыру Комитетының президиумы Союзга член итеп алу турында бирелгән гаризаларын караганда гомумән уставтан һәм бигрәк тә аның югарыдагы пунктыннан[2] чыгып эш итте. Гаризалар бирү әле дәвам итә. Ләкин беренче нәүбәттә каралган 50 гаризага йомгак ясаганда түбәндәге хәл күренә: каралган 50 гаризадан 24 кеше Союзга член итеп билгеләнә. Болар арасында Г. Ибраһимов, Ш. Камал[3], Ф. Сәйфи, К. Нәҗми, Г. Нигъмәти, Г. Гали, К. Тинчурин[4], И. Газый[5], Ф. Кәрим[6], М. Буберно[7], Б. Зернит[8] һәм совет язучылары уставының сорауларына җавап бирүче башка язучы һәм тәнкыйтьчеләр бар.

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1934 елгы 5 июнь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла, стиле сакланды.

[2] *...югарыдагы пунктыннан чыгып эш итә* – ул пункт газетада китерелгән һәм шулай: «СССР Совет Язучылары Союзы уставының 3 нче бүлек, 2 нче параграфында нинди язучы һәм тәнкыйтьчеләр Союзга член булып керә алулары турында түбәндәгеләр әйтелә: «Совет язучыларының Союзында член булып, Совет власы платформасында торучылар һәм социалистик төзелештә катнашучылар, әдәби хезмәт белән системалы рәвештә шөгыльләнүчеләр,– аерым китап рәвешендә яки әдәби художество һәм тәнкыйть журналларында басылган (шулай ук профессионал һәм клуб сәхнәләрендә куела торган) һәм художество яки гыйльми (тәнкыйть хезмәтләре) әһәмият тоткан художество яки тәнкыйть әсәрләре булган язучылар (әдипләр, шагыйрьләр, драматурглар, тәнкыйтьчеләр) тора алалар».

[3] *Ш. Камал* – сүз Шәриф Камал хакында бара.

[4] *К. Тинчурин* – Кәрим Гали улы Тинчурин (1887–1938), драматург, актёр, режиссёр, педагог, ТАССРның атказанган артисты (1926). Шәхес культы чоры корбаннарының берсе, үлгәннән соң акланган.

[5] *И. Газый* – Ибраһим Газый (Ибраһим Зарифулла улы Мингазиев) (1907–1971), язучы, тәрҗемәче, җәмәгать эшлеклесе.

[6] *Ф. Кәрим* – Фатыйх Кәрим (Фатыйх Әхмәтвәли улы Кәримов) (1909–1945), шагыйрь.

[7] *М. Буберно* – Михаил Семёнович Бубеннов (1909–1983), язучы. 1931–1941 елларда Татарстанда яшәгән.

[8] *Б. Зернит* – Бруно Иванович Зернит (1914–1960), шагыйрь.

## 1935
## Г. Ибраһимов әсәрләренең рус һәм таҗик телләрендә басылып чыгуы хакында[1]

1935 ел

Галимҗан Ибраһимов әсәрләре СССР халыклары телләрендә

Соңгы еллар эчендә атаклы татар совет язучысы Галимҗан Ибраһимов иптәшнең «Тирән тамырлар» романы һәм башка әсәрләре рус[2], казакъ, үзбәк[3], чуаш һәм башкорт телләренә тәрҗемә ителеп чыгарылганнар иде.

Бу елны Гослитиздат (Мәскәү) Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» исемле романын да рус теленә тәрҗемә итеп чыгарды. Роман Г. Шәрипова тарафыннан тәрҗемә ителгән һәм русча исеме «Дочь степи»[4] дип куелган.

Шушы ук елны Таҗикстан дәүләт нәшриятында, Х. Шукуруллаев тәрҗемәсендә, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» («Решанойи чукуррафта») романының таҗикча тәрҗемәсе басылып чыкты. Роман зур кулда, пөхтә техникада чыккан.

---

[1] «Совет әдәбияты» журналының 1935 елгы 4–5 нче кушма санында урнаштырылган (б. 123). Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] Ибрагимов Г. Утро в степи. Перевод с татарского Гайши Шариповой // Альманах художественной литературы тюркских народов СССР. Под редакцией И. Н. Бороздина, Али Назима, Н. Васильева-Шубоссини, Уйгура, А. Чачикова и Гайши Шариповой. Вступительная статья И. Н. Бороздина.– Л.: Изд-е «Красной газеты», [1930].– С. 16–18; Ибрагимов Г. Глубокие корни: Роман / Перевод с татарского и комментарии Гайши Шариповой, вступительная статья И. Бороздина / Г. Ибрагимов.– М.: ГИХЛ, 1931.– 205 с.; Ибрагимов Г. Дети природы (Авторизированный перевод) / Г. Ибрагимов // Сборник татарской литературы (дореволюционный) / Под ред. П. Радимова, с предисловием П. Когана.– М.– Л.: Гос. изд-во худож. лит-ры, 1931.– С. 78–92; Ибрагимов Г. Старый батрак (авторизированный перевод) / Г. Ибрагимов // Сборник татарской литературы (дореволюционный) / Под ред. П. Радимова, с предисловием П. Когана.– М.– Л.: Гос. изд-во худож. лит-ры, 1931.– С. 92–107.

[3] Ƅbrahƅmof A. Qƅzƅl cecəklər hikəjəse (Biz pastadan kutarildik) / A. Ƅbrahƅmof.– Toşkent-Samarkand: Өznəşr, 1932.– 106 b.; Ƅbrahƅmof A. Teran tomirlar / A. Ƅbrahƅmof.– Toşkent-Samarkand: Өzdəvnəşr, 1933.– 204 b.

[4] *«Дочь степи»* – Ибрагимов Г. Дочь степи: Роман / Перевод с татарского и комментарии Гайши Шариповой / Г. Ибрагимов.– М.: ГИХЛ, 1934.– 130 с.

## 1957
## Саннар һәм фактлар[1]

12 март 1957 ел

Ибраһимовның беренче әсәре – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе 1907 елны «Әльислах» газетасында басыла; 1909 елны «Татар хатыны ниләр күрми» исемле зур хикәясе беренче тапкыр аерым китап булып чыга.

***

«Безнең көннәр» романының беренче вариантын Г. Ибраһимов 1914 елны язып бетерә, ләкин патша цензурасы ул китапны инде басыла башлагач конфискацияли.

***

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң Галимҗан Ибраһимовның әсәрләре зур тиражлар белән төрле шәһәрләрдә, төрле телләрдә басыла башлыйлар. Берничә ел эчендә аның «Карт ялчы» хикәясе өч тапкыр, «Яз башы» хикәясе дүрт тапкыр, балалар өчен язылган «Алмачуар» хикәясе дүрт тапкыр, «Табигать балалары» ике тапкыр аерым китап булып чыга.

***

1928 елны Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы беренче тапкыр басыла.

***

30 елларда Галимҗан Ибраһимовның алты томнан торган әдәби әсәрләр җыентыгы дөньяга чыга. Шушы ук елларда аның ике томлык һәм өч томлык сайланма әсәрләре дә басыла. Болардан башка аның төрле аерым хикәяләре – «Көтүчеләр», «Сәнәкчеләр», «Казакъ кызы», «Диңгездә» кебек әсәрләре китап булып басыла; аларның кайберләре икешәр-өчәр басмада чыга.

***

Галимҗан Ибраһимовның совет чорында йөзгә якын исемдә әдәби һәм фәнни китаплары басыла; аның татар телендә чыккан әсәрләренең генә дә тиражы 400 мең данәгә җитә.

---

[1] «Совет Татарстаны» газетасының 1957 елгы 12 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

***

1931 елны Москвада Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар», 1935 елны «Татар хатыны ниләр күрми» романнары рус телендә басыла. Рус телендә Г. Ибраһимовның тагын байтак әдәби һәм фәнни китаплары чыга.

***

Г. Ибраһимовның әсәрләре СССР халыклары телләрендә һәм чит телләрдә дә күп басыла. Аның әсәрләре казакъ, азербайҗан, үзбәк журналларында да, аерым китаплар булып та чыга.

***

1956 елны Г. Ибраһимовның Таткнигоиздатта өч томлык сайланма әсәрләр җыентыгы чыкты. Тиздән рус телендә бер томлык сайланма әсәрләре чыгачак.

## 1962
## Тантаналы җыелыш[1]

15 март 1962 ел

Кичә, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, татар әдәбиятының классигы, тарихчы һәм тел галиме Галимҗан Ибраһимовның тууына 75 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды. Анда язучының үлемсез әсәрләрен яратып укучы йөзләрчә кешеләр – Казан заводларында, фабрикаларында һәм төзелеш предприятиеләрендә эшләүчеләр, язучылар, журналистлар, галимнәр, укытучылар, студентлар һәм башка профессия вәкилләре – киң җәмәгатьчелек катнашты. Кичәне Г. Ибраһимовны күреп белгән язучы Афзал Шамов ачты. «Г. Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлы» турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Мансур Хәсәнов ясады.

Президиумда язучының Уфадан килгән туганнары Мотаһар һәм Габделхак Ибраһимовларның күренүен залда утыручылар кайнар тәбрикләп каршыладылар.

Художество бүлегендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары «Татар хатыны ниләр күрми» спектакленнән өзек күрсәттеләр. ТАССРның халык артисты Х. Сәлимҗанов[2] «Кызыл чәчәкләр» повестеннан, РСФСРның халык артисты Г. Шамуков[3] «Табигать балалары» хикәясеннән өзекләр укыдылар. Концертта ук РСФСРның һәм ТАССРның атказанган артисткасы З. Хисмәтуллина[4], РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Ф. Насретдинов[5], ТАССРның атказанган артисты

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1962 елгы 15 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *Х. Сәлимҗанов* – Хәким Йосыф улы Сәлимҗанов (1903–1981), драма актёры, режиссёр, ТАССРның халык артисты (1957).

[3] *Г. Шамуков* – Габдулла Рухулла улы Шамуков (1909–1981), драма актёры, педагог, язучы, Башкорт АССРның атказанган артисты (1943), ТАССРның, ТСФСРның, СССРның халык артисты (1950, 1957, 1980).

[4] *З. Хисмәтуллина* – Зөләйха Гатаулла кызы Хисмәтуллина (1922–1994), җырчы, педагог, РСФСРның, Татарстан Республикасының халык артисткасы (1966, 1992), профессор (1983).

[5] *Ф. Насретдинов* – Фәхри Хөсәен улы Насретдинов (1911–1986), җырчы, ТАССРның, РСФСРның халык артисты (1950, 1957).

Р. Ваһапов[1], опера һәм балет театры солисткасы Л. Бәширова чыгыш ясадылар.

Фойеда Г. Ибраһимовның моңарчы билгеле булмаган фоторәсемнәреннән, 1909 елдан башлап гомеренең соңгы елларына кадәр басылган әсәрләреннән һәм шушы елларда басылган китаплардан күргәзмә оештырылган иде. Тамашачылар аны кызыксынып карадылар.

Язучыга 75 яшь тулу уңае белән күп кенә телеграммалар алынды. Алар арасында Кыргызстан, Төркмәнстан, Чувашия, Мордовия АССР һәм башка тугандаш республикалардан килгән телеграммалар бар.

---

[1] *Р. Ваһапов* – Рәшит Ваһап улы Ваһапов (1908–1962), җырчы, ТАССРның халык артисты (1957).

## 1968
## Олы әдип истәлегенә[1]

8 март 1968 ел

Син борчылма, әдип, син башкарган эшләр
Һич калмады юлда тукталып.
Без эшләрбез еллар үткән саен
Хезмәтеңә күбрәк сокланып.

Әйе, күренекле әдибебез Галимҗан Ибраһимовны без әнә шулай истә тотабыз һәм чын күңелдән хөрмәтлибез. Шәһәребезнең Ленин районындагы Галимҗан Ибраһимов исемендәге проспект, аның исемен йөртүче СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институты...

Ә бит без Галимҗан Ибраһимовны педагог буларак та яхшы беләбез. Ул олы тормыш юлын казах далаларында балалар укытып башлаган. Шунысы күңелле, Г. Ибраһимов әле моннан ярты гасыр элек үк бала тәрбияләүдә бүген дә актуаль булып калучы проблемаларны күтәреп чыккан. Аның: «Мәктәп баланың зиһенен эшләтергә, эзләнергә өйрәтергә тиеш», – дигән сүзләре совет укытучылары өчен бүген дә укыту-тәрбия эшендә девиз булып тора.

Танылган язучы, галим, революционер һәм педагогның шушы хезмәтләрен искә алып, Галимҗан Ибраһимовның тууына 80 ел тулган көннәрдә республика мәктәпләре арасында бөек әдип исеменә лаек булу өчен конкурс игълан ителгән иде. Бу конкурста йөзләрчә коллектив катнашты. Анда Казанның 89 нчы мәктәбе җиңүче дип табылды.

Тик бу мәктәп комсомоллары, укытучылар коллективы Галимҗан Ибраһимов исемен алу белән генә чикләнмәделәр. Уку елы башлануга алар бөек әдипкә музей ачарга һәм һәйкәл куярга сүз биргәннәр иде. Аларга мәктәпнең шефлары – В. В. Куйбышев исемендәге химия заводы эшчеләре дә ярдәм итте. Югары класс укучылары һәйкәлнең постаментын үз көчләре белән төзеделәр. Ә язучының образын скульптор Виктор Рогожин[2] иҗат итте.

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1968 елгы 8 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *Виктор Рогожин* – Виктор Иванович Рогожин (1927), сынчы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1996).

Мәктәпнең язучылар бүлмәсендә Галимҗан Ибраһимовка багышланган стендларны әзерләү өчен дә зур көч куярга туры килде. Язучының революцион эшчәнлегенә, иҗатына һәм тормышына багышланган йөзләрчә документлар, аның хәзер сирәк очрый торган китапларының фоторәсемнәре булдырылды. Алай гына да түгел, мәктәп тынгысызлары күп кенә документларның төп нөсхәләрен дә таба алдылар. Алар арасыннан Галимҗан Ибраһимовның укытучы Әминәгә бүләк иткән фоторәсеме бик кызыклы. Язучының профессор Гыйбадулла Алпаровка автограф белән бүләк иткән «Безнең көннәр» романы да стендны бизәп тора.

...6 март көнне мәктәп алдындагы бакчадан ишетелгән музыка күпләрне җәлеп итте.

Бөек әдибебезгә әлегә беренче һәйкәлне ачуга багышланган тантаналы митингны мәктәп директоры В. Г. Надриев ача. Тынлы оркестр башкаруында Советлар Союзы Гимны яңгырый. Һәйкәлне каплап торган ак җәймә акрын гына шуып төшә. Тантанада катнашучылар алдында мәгърур карашын социалистик Казанга төбәгән әдип образы калка.

КПССның Ленин районы секретаре И. М. Әхметова митингта беренче булып сүз ала. Ул партия, совет органнары һәм җәмәгатьчелек исеменнән мәктәп коллективын зур тантана белән котлый һәм аңа алда да зур уңышлар тели. Митингта сүз алган Афзал Шамов, Сибгат Хәким[1], РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Г. Шамуков иптәшләрнең чыгышлары тантанада катнашучыларда зур тәэсир калдырды. Татарстан АССРның мәгариф министры урынбасары Р. Галиәхметов[2] конкурста җиңгән мәктәп коллективын зур бәйрәм белән котлады. Ә бу репортаж башында китерелгән дүрт юл шигырьне мәктәп музеен төзүгә зур көч куйган ТАССРның атказанган укытучысы Ф. Җәләлиева әйтте.

...Митинг тәмам. Пионерлар һәйкәл постаментын үзләре үстергән чәчәкләр белән бизәделәр.

Ф. Нуриәхметов

---

[1] *Сибгат Хәким* – Сибгат Таҗи улы Хәкимов (1911–1986), шагыйрь, публицист, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның халык шагыйре (1986).

[2] *Р. Галиәхмәтов* – Равил Әлми улы Галиәхмәтов (1924–1991), халык мәгарифе эшлеклесе, РСФСРның атказанган мәктәп укытучысы (1966).

## 1977
## Саннар һәм фактлар[1]

13 март 1977 ел

Галимҗан Ибраһимов әдәбият мәйданына «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән хикәясе белән 1907 елда килеп керә, ул «Әльислах» газетасында басылып чыга. Шуннан соң бер-бер артлы аның башка хикәяләре, повестьлары, романнары дөнья күрә. 1909 елны «Татар хатыныниләр күрми» исемле зур хикәясе беренче тапкыр аерым китап булып чыга. Шушы ук елда чыккан «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» китабы, 1911 елда дөнья күргән «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Карак мулла» хикәяләре һәм 1912 елда басылып чыккан, татар әдәбияты тарихында асылда беренче зур психологик роман булган «Яшь йөрәкләр» романы Г. Ибраһимовны талантлы, оста әдип итеп танытты.

***

Әдипнең күпкырлы иҗаты совет чорында тагын да киң колач ала, һәм ул үзенең иң яхшы зур полотнолы әсәрләрен иҗат итә. Аның Октябрьдән соңгы чорда язылган беренче әдәби «Яңа кешеләр» драмасы була. Ул 1920 елда тәмамлана һәм Октябрь революциясенең өч еллыгын билгеләп үткән көннәрдә татар театры сәхнәсендә куела. Аерым китап булып ул 1921 елда чыга.

***

Аның 1920 елда басылган «Безнең көннәр» романының беренче варианты, 1934 елдагы икенче варианты, «Кызыл чәчәкләр» повесте (1922 ел), «Казах кызы» (1924 ел), «Татар хатыны ниләр күрми» хикәясенең роман итеп эшләнгән икенче варианты (1929 ел) һәм «Тирән тамырлар» (1928 ел) укучыларның иң яраткан әсәрләренә әверелделәр һәм берничә мәртәбә аерым китап булып зур тиражлар белән төрле шәһәрләрдә, төрле телләрдә басылып чыктылар. 1929–1936 елларда аның Сайланма әсәрләренең 6 томлыгы, 1956–1957 елларда 3 томлыгы басылып чыга, ә 1976 елда Татарстан китап нәшрияты Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең 8 томлыгын чыгара башлады.

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1977 елгы 13 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

***

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң да Г. Ибраһимов фәнни-тикшеренү эшен дәвам итә. Аның «Татарлар арасында революцион хәрәкәт» дигән зур хезмәте 1925 елда басылып чыга, һәм ул хәзерге көндә дә әһәмиятен югалтмаган. Татар әдәбиятын һәм телен үстерү өлкәсендә дә ул зур көч куеп эшләвен дәвам итә. 1924 елда аның «Пролетариат әдәбияты турында», «Имля, тел һәм әдәбият мәсьәләләре» китаплары (2 нче басмасы 1927 елда), 1927 елда «Татар мәдәнияты нинди юл белән барачак» исемле хезмәте дөнья күрә.

***

1923 елда беренче тапкыр аның «Адәмнәр» хикәясе рус телендә чыга һәм шуннан соң бер-бер артлы аның әсәрләре тугандаш халыклар телендә басылып чыга башлый; рус телендә «Тирән тамырлар» (1931, 1957, 1964, 1966, 1976 елларда), «Казах кызы» (1934, 1957, 1966, 1976 елларда), «Татар хатыны ниләр күрми» (1935, 1957 елларда), «Безнең көннәр» (1962 елда) һ.б. әсәрләре; азербайҗан телендә «Адәмнәр» (1927 ел), «Кызыл чәчәкләр» (1928 ел), «Безнең көннәр» (1935 ел); үзбәк телендә «Табигать балалары» (1930 ел), «Казах кызы», «Кызыл чәчәкләр» (1932 ел), «Тирән тамырлар» (1961 ел), «Казах кызы» (1964 ел); казах телендә «Тирән тамырлар» (1936 ел), «Казах кызы» (1960 ел), «Алмачуар» (1961 ел), «Безнең көннәр» (1971 ел) һ.б. әсәрләре басылып чыга. Безнең китапханә һәм Бөтенсоюз китап палатасы мәгълүматларына караганда, Галимҗан Ибраһимов китаплары барлыгы 11 телдә басылып чыккан, шул исәптән 13 китабы рус телендә 579 мең данә тираж белән басылган.

Н. Нуруллина,
В. И. Ленин исемендәге республика
фәнни китапханәсе хезмәткәре

## Фәнни конференция[1]

16 март 1977 ел

Кичә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында татар совет әдәбияты классигы, революционер, галим, зур җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 90 ел тулуга багышланган фәнни конференция булды.

Конференцияне кереш сүз белән тарих фәннәре докторы М. Мөхәррәмов[2] ачты.

Татар совет культурасы үсешендә Г. Ибраһимовның күпьяклы роле турында фән докторлары М. Хәсәнов, К. Фасеев[3], Г. Халитов, Л. Климович[4] (Мәскәү), А. Гаджиев (Баку); фән кандидатлары Ш. Турдыев[5] (Ташкент), Р. Баимов[6] (Уфа), Г. Хантимерова[7] (Мәскәү), Я. Абдуллин[8], С. Алишев[9], Р. Нуруллина[10],

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1977 елгы 16 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *М. Мөхәррәмов* – Мидхәт Кәрим улы Мөхәррәмов (1922–1993), тарихчы, тарих фәннәре докторы (1964), профессор (1967), ТАССР, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1972, 1982). 1977 елда СССР ФА Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры.

[3] *К. Фасеев* – Камил Фатыйх улы Фәсиев (1919–2005), дәүләт эшлеклесе, философия фәннәре докторы (1972), профессор (1973), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1979).

[4] *Л. Климович* – Люциан Ипполитович Климович (1907–1989), шәркыятьче, әдәбият галиме.

[5] *Ш. Турдыев* – Ширали Турдыев (1933–2011), үзбәк әдәбияты галиме, филология фәннәре кандидаты.

[6] *Р. Баимов* – Роберт Нурмөхәммәт улы Баимов (1937–2010), башкорт әдәбияты галиме, язучы, филология фәннәре докторы (1983), профессор (1984), БР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), БАССРның атказанган фән эшлеклесе (1986).

[7] *Г. Хантимерова* – Галия (Көбра) Закир кызы Хантемирова (1921–2012), тәрҗемәче, әдәбият тәнкыйтьчесе, филология фәннәре кандидаты (1972).

[8] *Я. Абдуллин* – Яхъя Габдулла улы Абдуллин (1920–2006), философия фәннәре докторы (1979), профессор (1982), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1996).

[9] *С. Алишев* – Сәлам Хатыйп улы Алишев (1929–2015), тарихчы, тарих фәннәре докторы (1990), ТРның атказанган фән эшлеклесе (1996).

[10] *Р. Нуруллина* – Розалина Мәрдан кызы Нуруллина (1929–2012), журналистика белгече, журналистика, филология фәннәре кандидаты (1966), ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1990).

Н. Гыйззәтуллин[1], Ф. Фасеев[2], Ф. Хатыйпов[3], Ф. Сафиуллина[4], язучы Г. Мөхәммәдова иптәшләр докладлар һәм белдермәләр белән чыктылар.

Конференция эшендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев[5] катнашты.

---

[1] *Н. Гыйззәтуллин* – Нур Габделхәй улы Гыйззәтуллин (1928–2004), әдәбият галиме, филология фәннәре кандидаты (1953).

[2] *Ф. Фасеев* – Фазыл Салих улы Фәсиев (1925–2016), тел галиме, филология фәннәре кандидаты (1962).

[3] *Ф. Хатыйпов* – Фәрит Миргалим улы Хатыйпов (1930), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1986), профессор (1987), Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (2000).

[4] *Ф. Сафиуллина* – Флёра Садри кызы Сафиуллина (1938–2011), тел галимәсе, филология фәннәре докторы (2001), профессор (1997), Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы (1993), Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (2004).

[5] *М. Ф. Вәлиев* – Морзаһит Фәтхи улы Вәлиев (1922–1993), партия эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты (1961).

## 1987
## Урам бәйрәме[1]

10 март 1987 ел

Татар әдәбияты классигы, даһи юлбашчыбыз В. И. Ленинның көрәштәше Галимҗан Ибраһимов исемен йөрткән урам башкалабызның ике күрше районын бергә тоташтыра. Урамның бер ягы – Ленин районына, ә икенче ягы Мәскәү районына керә. Шуңа күрә 7 мартта үткәрелгән урам бәйрәмен оештыруда һәр ике районның да культура-спорт комплекслары катнашуы, бу көнне һәр ике районның да хезмәт ияләре бәйрәм итүе гаҗәп түгел.

Шушы урамда гомер итүче, 1920 елдан партия члены булган Сөләйман ага Казбекның сүзләре искә төшә.

– Күз алдымда үсте Казан,– дигән иде ул.– Элек сазлык, әрәмәлек иде бит бу урында. Ә бүген иң матур проспектлардан санала ул.

– Урам бәйрәменең Бөек Октябрьгә 70 ел тулган чорда, классикның тууына 100 ел тулган көннәрдә үткәрелүе аны тагын да ямьлерәк, күңеллерәк, эчтәлеклерәк итә,– диде Татарстан Язучылар союзы председателе Туфан Миңнуллин[2] үзенең чыгышында.– Шуңа күрә бу урам бәйрәме генә түгел, ә бөтен шәһәр хезмәт ияләре бәйрәме, әдәбиятыбыз бәйрәме дә.

...Шул сүзләрне раслагандай, урамның күркен тәшкил иткән «Синтез» физкультура йортында һәм Химиклар культура сарае янындагы бакчада спорт ярышлары, кечкенә сабантуй, чәй-шашлык, китап сәүдәсе башланып китте, ике районның үзешчән сәнгать осталары концерты булды.

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1987 елгы 10 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *Туфан Миңнуллин* – Туфан Габдулла улы Миңнуллин (1935–2012), драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе, ТАССР, РСФСР, Башкортстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1978, 1984, 1995), Татарстан Республикасының халык язучысы (2005).

## «Тирән тамырлар» мәктәп сәхнәсендә[1]

11 март 1987 ел

Галимҗан Ибраһимов бәйрәме... Аңа хәзерлек безнең мәктәптә күптән башланды. Без язучының тормыш юлын һәм иҗатын өйрәндек, рефератлар яздык, аның әсәрләренә рәсемнәр ясадык, стена газетасы чыгардык. Мәктәп күләмендә зур кичә үткәрдек. Үзебезгә кунакка Г. Камал исемендәге Татар академия театры артистларын чакырдык. Укучылар үзләре яраткан сәхнә осталарын – СССРның халык артисты, СССР Верховный Советы депутаты Шәүкәт Биктимеров[2], РСФСРның халык артисткалары Вера Минкина[3], Гәүһәр Камалова[4], Шәхсәнәм Әсфәндиярова[5], ТАССРның халык артисты Наил Әюпов[6], ТАССРның атказанган артисткасы Фирдәвес Әхтәмова[7] һәм курайчы Ринат Гыйләҗевны алкышлап каршы алдылар.

Без башта Г. Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлына багышланган әдәби-музыкаль монтаж күрсәттек.

Аннары сәхнәгә артистлар чыкты. Алар Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәреннән өзекләр күрсәттеләр. Бу артистлар шушы әсәрне сәхнәдә 1959 елда ук уйнаганнар. Ә бүген алар үзләренең яшьлекләрен искә төшереп, тагын да рухланып уйнадылар. Шулай ук «Татар хатыны ниләр күрми» әсәреннән өзек күрсәтелде.

---

[1] «Яшь ленинчы» газетасының 1987 елгы 11 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *Шәүкәт Биктимеров* – Шәүкәт Хәсән улы Биктимеров (1928–2012), артист, Татарстанның халык артисты (1968), РСФСРның халык артисты (1970), СССРның халык артисты (1977), Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (2012), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы (2007).

[3] *Вера Минкина* – Вера Егоровна Минкина (1918–2011), актриса, ТАССРның, РСФСРның халык артисткасы (1968, 1977).

[4] *Гәүһәр Камалова* – Гәүһәр Габдулла кызы Камалова (1922–1990), актриса, ТАССРның халык (1976), РСФСРның атказанган артисткасы (1983).

[5] *Шәхсәнәм Әсфәндиярова* – Шаһсәнәм Ибраһимбәк кызы Әсфәндиярова (1926–1996), драма актрисасы, педагог, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты (1970, 1977).

[6] *Наил Әюпов* – Наил Галиулла улы Әюпов (1936–2008), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1987), РФнең атказанган артисты (1999).

[7] *Фирдәвес Әхтәмова* – Фирдәвес Каюм кызы Әхтәмова (1939–2012), драма актрисасы, ТРның халык артисткасы (1996).

Курайчы Ринат Гыйләҗевның чыгышы да истә калды.

Галимҗан кечкенә чагыннан ук курайга гашыйк булган. Курай моңын тыңлаганда бөек язучының бала вакытын, аның урманда ат саклап йөрүләрен күз алдына китердек.

Кичәдә 2 нче музыка мәктәбе укучылары да чыгыш ясадылар.

Без әнә шулай итеп Галимҗан Ибраһимовның иҗаты һәм тормышы белән якыннан таныштык. Ә инде артистлар белән очрашу ялкынлы язучы турында белемнәребезне, ана телебезгә мәхәббәтебезне тагын да арттырды.

Эльза Хаҗиева,
Казандагы 73 нче мәктәпнең X класс укучысы

## Үлемсез хәзинә[1]

12 март 1987 ел

Галимҗан Ибраһимовның беренче әсәре — «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе 1907 елда Фатих Әмирхан тарафыннан редакцияләнгән «Әльислах» газетасында басыла. 1909 елны «Татар хатыны ниләр күрми» исемле зур хикәясе беренче тапкыр аерым китап булып чыга.

Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр әдипнең 15 китабы чыкканы билгеле. Алар арасыннан «Яз башы» (1910), «Диңгездә» (1911), «Карак мулла», «Карт ялчы», «Яшь йөрәкләр» (1912) әсәрләрен санап китәргә була.

«Безнең көннәр» романының беренче вариантын Г. Ибраһимов 1914 елда язып бетереп нәшриятка тапшыра, ләкин патша цензурасы ул китапны инде басыла башлагач конфискацияли.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң Г. Ибраһимовның әсәрләре зур тиражлар белән төрле шәһәрләрдә, төрле телләрдә басыла башлый.

1907 елдан 1987 елга кадәрге чорда аның татар телендә 97 китабы дөнья күргән. Шулардан 61 е — матур әдәбият әсәрләре. 1921 елга кадәр татар телендә чыккан китапларының тиражы билгесез, ә күрсәтелгәннәренең тиражы 460 меңнән артып китә. Рус телендә әдипнең 1927 елдан 1987 елга кадәр 16 китабы басылган. Аларның тиражы 750 мең данә тирәсе. СССР халыклары телләрендә 20 ләп китабы чыккан, аларның якынча тиражы 120 мең данә.

Совет власте елларында Г. Ибраһимов әсәрләре күптомлыклар булып 6 тапкыр басылган. 1927 елда җиде томнан чыгару өчен әзерләнгән җыентыкларның 2, 5 һәм 6 нчы томнары чыккан, ә 1, 2, 3, 4, 7 томнары чыкмый калган. 1933–1934 елларда чыккан 5 китаптан торган «Сайланма әсәрләр»енә «Тирән тамырлар», «Казакъ кызы», «Безнең көннәр» романнары һәм хикәяләре тупланган.

1974 елда чыга башлаган сигез томнан торган «Әсәрләр» җыелмасы Г. Ибраһимовның үлемсез әсәрләрен тулы итеп күзалларга мөмкинлек бирә. Монда аның әдәби әсәрләре дә, фәнни-публицистик хезмәтләре дә шактый киң чагылыш тапкан.

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1987 елгы 12 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

Болардан тыш, әдипнең аерым китап булып басылган әсәрләре арасыннан «Безнең көннәр» романын (1919), «Карт ялчы» (1922, 1925), «Алмачуар» (1922, 1927), «Казакъ кызы» (1924, 1933), «Кызыл чәчәкләр» (1922, 1935) һәм башка әсәрләрен күрсәтергә мөмкин. Бу әсәрләр һәм 1928 елда беренче мәртәбә аерым китап булып басылып чыккан «Тирән тамырлар» романы әдипнең укучылар тарафыннан иң яратып укыла торган популяр әсәрләре булып саналалар. Ул әсәрләр рус теленә һәм СССРда яшәүче башка тугандаш халыклар теленә дә тәрҗемә ителгәннәр.

Рус телендә Г. Ибраһимовның «1905 елгы революциядә татарлар» дигән зур күләмле тарихи хезмәте 1926 елда 4.000 данә тираж белән Казанда басыла.

«Тирән тамырлар» романы рус телендә Казанда һәм Мәскәү нәшриятларында 4 мәртәбә басылган, аларның гомуми тиражы – 230 мең данә. Бу роман казах, таҗик, үзбәк, кыргыз телләрендә дә чыккан.

«Безнең көннәр» романы 4 тапкыр рус телендә чыккан, аның тиражы 325 мең данә тәшкил итә. Ул 1935 һәм 1971 елда казах телендә дә басылган.

1927 һәм 1928 елларда ук «Адәмнәр», «Картлык көннәрендә», «Кызыл чәчәкләр» хикәяләре икешәр тапкыр азербайҗан телендә Бакуда чыккан, 1935 елда шунда ук «Безнең көннәр» романы дөнья күргән.

«Казакъ кызы» романы 1923 елда рус телендә Мәскәүдә дөнья күрә, аннан соң ул 1934, 1957, 1966 елларда Казан һәм Мәскәү нәшриятларында басыла. Бу китап казах һәм үзбәк телләрендә дә чыккан.

«Алмачуар» хикәясе дә әдипнең иң популяр әсәрләреннән санала. Ул ике тапкыр күп тиражлар белән рус телендә, 1961 елда казах телендә дөньяга чыгарылган.

Ә. Хисамова,
Татарстан китап палатасы директоры

## Г. Ибраһимов юбилее хөрмәтенә[1]

13 март 1987 ел

Бу көннәрдә республикабыз җәмәгатьчелеге күренекле татар совет язучысы, галим, ялкынлы революционер-интернационалист, зур җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуны киң билгеләп үтә. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан Язучылар союзы белән берлектә, бу юбилейга багышлап фәнни конференция үткәрде. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында студентларның Бөтенсоюз фәнни конференциясе булды. Г. Ибраһимовка багышлап, әдип исемен йөрткән тел, әдәбият һәм тарих институтында музей-бүлмә, ТАССР сынлы сәнгать музеенда күргәзмә ачылды. Казан шәһәренең Ленин районында Г. Ибраһимов исемендәге урам бәйрәме, республикабыз шәһәрләрендә һәм авылларында укучылар конференцияләре, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелде.

12 мартта М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды.

Президиумда – КПСС өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов[2], КПСС өлкә комитеты бюросы членнары һәм членлыкка кандидатлар, республиканың партия, совет, профсоюз оешмалары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре, хезмәт коллективлары вәкилләре, илебез башкаласы Мәскәүдән, тугандаш республикалардан килгән кунаклар.

Тантаналы җыелышны кереш сүз белән КПСС өлкә комитетының икенче секретаре А. А. Родыгин[3] ачты.

Галимҗан Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, Г. Ибраһимов юбилеен үткәрү буенча республика комиссиясе председателе М. Х. Хәсәнов чыкты.

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1987 елгы 13 март, аннан соң «Татарстан яшьләре» газетасының 1987 елгы 14 март санында «Әдип хөрмәтенә» исеме белән бастырылган. Текст «Социалистик Татарстан»нан алынды.

[2] *Г. И. Усманов* – Гомәр Исмәгыйль улы Усманов (1932–2015), партия, дәүләт эшлеклесе.

[3] *А. А. Родыгин* – Аркадий Андреевич Родыгин (1931–2006), партия эшлеклесе.

Җыелышта чыгыш ясадылар: Г. Ибраһимовның юбилеен үткәрү буенча Бөтенсоюз комиссиясе председателе, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев[1], язучы М. С. Мәһдиев[2], «Органик синтез» производство берләшмәсе машинисты Н. П. Никишин, «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары Р. С. Мөхәммәдиев[3], Балтач урта мәктәбе укытучы-методисты В. Г. Фазлыева, Казахстан Язучылар союзы идарәсе секретаре Ш. Мортазаев[4], Үзбәкстан Язучылар союзы идарәсе секретаре М. Әгъзамов, Башкортстан Язучылар союзы идарәсе председателе Ә. М. Мирзаһитов, Казан педагогия институты студенты Г. Фәйзуллина.

Аннары Татарстан сәнгать осталары концерты булды.

---

[1] *Ю. И. Суровцев* – Юрий Иванович Суровцев (1931–2001), әдәбият тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче.

[2] *М. С. Мәһдиев* – Мөхәммәт Сөнгать улы Мәһдиев (1930–1995), язучы, әдәбият галиме, филология фәннәре кандидаты (1964), Татарстан Республикасының халык язучысы (1993).

[3] *Р. С. Мөхәммәдиев* – Ринат Сафа улы Мөхәммәдиев (1948), язучы. Әдәбият галиме, әдәбият тәнкыйтьчесе, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1986).

[4] *Ш. Мортазаев* – Шерхан Мортаза улы Мортазаев (1932), казакъ язучысы.

# СССР Язучылар союзында[1]

13 март 1987 ел

СССР Язучылар союзы идарәсе күренекле язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуны үткәрү буенча Бөтенсоюз юбилей комиссиясе төзеде. Комиссиянең председателе итеп – СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев, председатель урынбасары итеп – ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, комиссиянең җаваплы секретаре итеп шагыйрь Гәрәй Рәхим[2] расланды. Юбилей комиссиясе составына КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев[3], танылган язучылар Ч. Т. Айтматов[4], Әсхәт Мохтар[5], Ю. В. Бондарев[6], Ю. Н. Верченко[7], Р. Г. Гамзатов[8], Ә. Н. Еники, В. В. Карпов[9], Д. Н. Көгелтинов[10], Т. А. Миң-

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1987 елгы 13 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *Гәрәй Рәхим* – Григорий Васильевич Родионов (1941), шагыйрь, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1984), Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1985), Татарстан Республикасы халык язучысы (2011).

[3] *Р. К. Беляев* – Рәис Кыям улы Беляев (1935–1996), партия һәм хәкимият хезмәткәре, профессор (1992).

[4] *Ч. Т. Айтматов* – Чыңгыз Төрәкол улы Айтматов (1928–2008), язучы, Кыргызстан ССРның халык язучысы (1968), Кыргызстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1974).

[5] Әсхәт Мохтар (1920–1997), язучы һәм шагыйрь, тәрҗемәче, Үзбәкстан ССРның халык язучысы (1980).

[6] *Ю. В. Бондарев* – Юрий Васильевич Бондарев (1924), язучы, Социалистик Хезмәт Герое (1984), Ленин премиясе лауреаты (1972), ике мәртәбә СССР Дәүләт премиясе лауреаты (1977, 1983).

[7] *Ю. Н. Верченко* – Юрий Николаевич Верченко (1930–1994), рус язучысы.

[8] *Р. Г. Гамзатов* – Рәсүл Гамзат улы Гамзатов (1923–2003), авар шагыйре, язучы, тәрҗемәче.

[9] *В. В. Карпов* – Владимир Васильевич Карпов (1922–2010), рус язучысы.

[10] *Д. Н. Көгелтинов* – Давид Никитич Көгелтинов (1922–2006), шагыйрь, журналист, Калмык АССРның халык шагыйре (1969), СССР Дәүләт премиясе лауреаты (1976), Социалистик Хезмәт Герое (1990).

нуллин, П. Л. Проскурин[1], әдәбият галиме Г. И. Ломидзе[2] һәм башкалар кертелде.

Апрель аенда Мәскәүдә, әдәбиятчыларның үзәк А. А. Фадеев исемендәге йортында, Г. Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булачак.

[1] *П. Л. Проскурин* – Пётр Лукич Проскурин (1928–2001), рус язучысы, Социалистик Хезмәт Герое (1988), СССР Дәүләт премиясе лауреаты (1979).

[2] *Г. И. Ломидзе* – Георгий Иосифович Ломидзе (1914–1999), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1960), профессор (1965), СССР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (1972), Россия Федерациясе Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы (1991).

## Әдип хөрмәтенә[1]

14 март 1987 ел

Бу көннәрдә республикабыз җәмәгатьчелеге күренекле татар совет язучысы, галим, ялкынлы революционер-интернационалист, зур җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуны киң билгеләп үтә. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан Язучылар союзы белән берлектә, бу юбилейга багышлап фәнни конференция үткәрде. В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында студентларның Бөтенсоюз фәнни конференциясе булды. Г. Ибраһимовка багышлап, әдип исемен йөрткән тел, әдәбият һәм тарих институтында музей-бүлмә, ТАССР сынлы сәнгать музеенда күргәзмә ачылды. Казан шәһәренең Ленин районында Г. Ибраһимов исемендәге урам бәйрәме, республикабыз шәһәрләрендә һәм авылларында укучылар конференцияләре, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелде.

12 мартта М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында Галимҗан Ибраһимовның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды.

Президиумда – КПСС өлкә комитеты беренче секретаре Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитеты бюросы членнары, республиканың партия, совет, профсоюз оешмалары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре, хезмәт коллективлары вәкилләре, илебез башкаласы Мәскәүдән, тугандаш республикалардан килгән кунаклар.

Тантаналы җыелышны кереш сүз белән КПСС өлкә комитетының икенче секретаре А. А. Родыгин ачты.

Галимҗан Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлы турында доклад белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары, Г. Ибраһимов юбилеен үткәрү буенча республика комиссиясе председателе М. Х. Хәсәнов чыкты.

Җыелышта чыгыш ясадылар: Г. Ибраһимовның юбилеен үткәрү буенча Бөтенсоюз комиссиясе председателе, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Ю. И. Суровцев, язучы М. С. Мәһ-

---

[1] «Татарстан яшьләре» газетасының 1987 елгы 14 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

диев, «Органик синтез» производство берләшмәсе машинисты Н. П. Никишин, «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары Р. С. Мөхәммәдиев, Балтач урта мәктәбе укытучы-методисты В. Г. Фазлыева, Казахстан Язучылар союзы идарәсе секретаре Ш. Мортазаев, Үзбәкстан Язучылар союзы идарәсе секретаре М. Әгъзамов, Башкорстан Язучылар союзы идарәсе председателе Ә. М. Мирзаһитов[1], Казан педагогия институты студенты Г. Фәйзуллина.

Аннары Татарстан сәнгать осталары концерты булды.

[1] *Ә. М. Мирзаһитов* – Әсгать Мәсгут улы Мирзаһитов (1928–1989), драматург. 1973–1988 елларда Башкортстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе.

## Классикка багышлап[1]

15 март 1987 ел

Уфа шәһәренең 65 нче гимназия-мәктәбендә татар әдибе классик милли прозасына нигез салучы, XX гасыр татар прозасының юлбашчысы, тәнкыйтьче, әдәбият галиме, тарихчы-педагог һәм җәмгыять эшлеклесе, якташыбыз Галимҗан Ибраһимовның тууына 90 ел тулуга багышланган зур бәйрәм үткәрелде. Анда республика һәм Уфа шәһәре укытучылары, галимнәр, мәгариф эшлеклеләре, журналистлар, студентлар катнашты. Башлап кунакларны гимназия директоры Рәшидә Харитонова тәбрикләде. Кунаклар әдип иҗатына багышланган әдәби-музыкаль композиция карадылар. Аннан 1 нче, 3 нче, 6 нчы, 7 нче сыйныфларда ачык дәресләр булды. Тантана халкыбызның күркәм бәйрәме, сабантуй белән тәмамланды. Соңыннан уку-укыту мәсьәләләренә багышланган эшлекле сөйләшү булды. Анда профессор Суфиян Поварисов[2], БДУ доцентлары – Б. Сәлимгәрәева[3], Р. Идрисов[4], БГПИ доценты Ә. Әпсәләмова, Башкортстанның мәгарифне үстерү институтыннан Илсөяр Локманова, Уфа шәһәре мэриясенең мәгариф идарәлегеннән Г. Сәлимова, Ф. Гарифуллина һ.б. катнашты.

Татар гимназиясе үзенең асыл исеменә җаваплы имтиханны лаеклы үтте дип билгеләделәр юбилей кичәсендә катнашучылар бертавыштан һәм педагогик коллективка уңышлар теләделәр.

---

[1] «Өмет» газетасының 1987 елгы 15 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *Суфиян Поварисов* – Суфиян Шәмсетдин улы Поварисов (1924–2016), тел галиме, язучы, филология фәннәре докторы (1992), профессор (1992), Башкортстан Республикасының һәм Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (1992, 2005), Россия Федерациясенең мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (1997), Башкортстан Республикасының халык язучысы (2012), Бөек Ватан сугышы ветераны. 1960 елдан Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты (хәзерге татар филологиясе һәм мәдәнияте) кафедрасында эшли.

[3] *Б. Сәлимгәрәева* – Бәйнә Салихҗан кызы Сәлимгәрәева (1933), филология фәннәре кандидаты, тел галимәсе, 1962–2000 елларда Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты (хәзерге татар филологиясе һәм мәдәнияте) кафедрасында эшли.

[4] *Р. Идрисов* – Рәүф Рифгать улы Идрисов (1954), филология фәннәре кандидаты, әдәбият галиме, Башкорт дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты (хәзерге татар филологиясе һәм мәдәнияте) кафедрасында эшли.

Уфа шәһәре мэры Фидус Ямалетдинов[1], аның урынбасары Мидхәт Мәмбәтов[2], Уфа шәһәренең мәгариф бүлеге башлыгы Гөлнур Мөхәммәтҗанова шәһәребезнең 140 нчы, 136 нчы һәм 65 нче милли мәктәпләрендә булдылар. Алар уку йортларының материаль-техник базасы һәм уку-тәрбия мәсьәләләре белән таныштылар.

Р. Бакиров.

---

[1] *Фидус Ямалетдинов* – Фидус Әгъләм улы Ямалетдинов (1953), 1995–2000 елларда Уфа шәһәре хакимияте башлыгы, Уфа шәһәр Советы рәисе булып эшли.

[2] *Мидхәт Мәмбәтов* – Мидхәт Әхмәтхан улы Мәмбәтов (1941), филология фәннәре кандидаты, 1999–2005 елларда Уфа шәһәре хакимияте башлыгы урынбасары вазифаларын башкара.

## Әдипнең музей-бүлмәсе[1]

3 апрель 1987 ел

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты татар әдәбиятының күренекле язучысы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов исемен йөртә. 1967 елда әдипнең 80 еллык юбилее уңае белән бирелгән бу олы исем институтка зур бурычлар йөкли. Бу чынлыкта да шулай. Әдип әсәрләренең сигез томлы җыелмасын институт хезмәткәрләре әзерләде. Иҗатына багышланган фәнни конференцияләр шушы бинада үтте. Быел да әдипнең 100 еллык олы юбилее көннәрендә институтта ике көн дәвамында фәнни конференция эшләде. Конференциядә Казан галимнәре белән бергә Мәскәү, Алма-Ата, Баку, Махачкала, Уфа, Йошкар-Ола һ.б. шәһәр галимнәре Г. Ибраһимовның күпкырлы иҗатын төрле яклап яктырттылар.

Конференция башланган көнне, 11 мартта, республика юбилей комиссиясенең карары белән, институтта Г. Ибраһимовның музей-бүлмәсе ачылды[2]. Татарстан дәүләт эшлеклеләре, конференция кунаклары бу тантананың беренче шаһитлары булды.

Мәгълүм нәрсә, Г. Ибраһимовның шәхси әйберләре сакланмаган, югалган. Музей-бүлмә әдипнең фото-рәсемнәре, биографик документлары, эш кәгазьләре, автографлары, хатларының ксерокопияләреннән оештырылды. Язучының тормыш һәм иҗат юлын, иҗтимагый-революцион эшчәнлеген яктыртучы бу документларның копияләре Татарстан дәүләт музееннан, Татарстан Үзәк дәүләт архивыннан, КПССның Татарстан өлкә партия архивыннан алынды. Берникадәр материал үз архивыннан күчте.

Г. Ибраһимов 1933 елның 30 сентябрендә Татарстан колхозчы ударникларының икенче съездына чакырыла. Аның Казан циркы бинасында съезд делегатлары алдында ясаган чыгышы вакытында алынган рәсеме, «Галия» мәдрәсәсе, әдип «Галия»

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1987 елгы 3 апрель санында басылган. Текст шуннан алынды.

[2] *...института Г. Ибраһимовның музей-бүлмәсе ачылды* – изге ният белән корылган бу музей-бүлмәдә әлеге гасыр башларында Россия Фәннәр академиясе Казан гыйльми үзәге белән уртак файдалану максатында төзекләндерү эшләре башкарылды. Шунысы аянычлы, эш барышында андагы барлык әйберләр дә чыгарып түгелде. 2016 елның көзендә Институт үзе дә башка урындагы бинага күчерелде. – *Р. И.*

мәдрәсәсе шәкертләре һәм укытучылары арасында, Г. Ибраһимов һәм Һ. Такташ, ул яшәгән йортлар – музей-бүлмәдә шундый күпсанлы фото-рәсемнәр урын алды.

Г. Ибраһимов Киевтә яшәгәндә Киев мөселман студентлары хәрәкәтенә катнашканы өчен кулга алына (1913 ел, 17 апрель), бүлмәсенә тентү ясала, бөтен әйберләре Киев губерна жандарм идарәсе карамагына күчә. Киев жандарм идарәсендә татар тәрҗемәчесе булмаганлыктан, ул әйберләр, дүрт төргәккә төрелеп, Казан губерна жандарм идарәсенә җибәрелә. Әйберләр сакланмаган, кая киткән – язмышлары билгесез. Архивта Г. Ибраһимов китапханәсендәге китаплар исемлеге сакланган. Әлеге исемлекне укыгач, әдипнең кызыксыну даирәсе киң булуына хәйран каласың. Анда көнбатыш Европа, рус, татар, төрек әдәбиятының яхшы үрнәкләре җыелган, тарих, тел, педагогика, методика һ.б. фән өлкәләреннән бай әдәбият тупланган. 26 яшьлек егет шулкадәр күп китапны ничек җыеп өлгергән!

Киев вакыйгаларыннан соң жандарм идарәсе Г. Ибраһимов артыннан күзәтү оештыра. Бу эшкә Казан, Киев, Одесса, Сухуми һ.б. шәһәрләрдәге жандарм идарәләре тартыла. Шул турыда сөйләүче документларның копияләре дә музей-бүлмәгә куелды. Музей-бүлмәдә Г. Ибраһимовның Киев жандарм идарәсенә үз кулы белән язып биргән аңлатма язуы да бар.

Татарстан партия архивыннан әдипнең гаять тулы һәм җентекләп эшләнгән автобиографиясенең, күпсанлы шәхси документлар копиясенең, төрле елларда тутырылган анкеталарының копияләре алынды. Һәрхәлдә, институт фәнни учреждение булгач, Г. Ибраһимов бүлмәсе фәннилеккә тарта.

Афзал ага Шамов Г. Ибраһимовның әдәби мирасын туплау буенча күптәннән эшләп килә. Г. Ибраһимовка 1928 елда иҗатының 20 еллык бәйрәме уңае белән «Хезмәт каһарманы» дигән мактаулы исем бирелә. Әлеге мактаулы исем грамотасының, Дәүләт художество фәннәре академиясенә член итеп сайлану (1928 ел) уңае белән әдипнең Академиягә җибәргән язмасының, автографларының, күп кенә хатларының копияләрен музей-бүлмәгә ул тапшырды.

Музей-бүлмәне тулыландыру дәвам итә. Гомумән, институт Г. Ибраһимов мирасының туплану урыны булырга тиеш, дип карала.

Г. Ибраһимов белән безне аерган ара әллә ни ерак түгел. Аерым кешеләрдә аңа караган материалларның саклануы бик мөм-

кин. Без алардан үзләрендә сакланган материалларны институтка китерүләрен үтенәбез.

Ф. Ибраһимова,
филология фәннәре кандидаты

## Свет далекого пламени[1]

4 апреля 1987 г.

Вчера в Москве, в Центральном Доме литераторов, состоялся вечер, посвященный 100-летию со дня рождения выдающегося татарского писателя и государственного деятеля Галимджана Ибрагимова.

Вечер вел секретарь правления Союза писателей СССР Ю. И. Суровцев. Во вступительном слове он сказал: «Сегодня – литературный вечер, посвященный писателю, но советская литература всегда была связана с революцией, именно в революционной народности – ее сокровенная суть. И по справедливости называя Ибрагимова одним из основоположников советской многонациональной литературы, мы не забываем, что он был прежде всего политическим писателем, ученым и общественным деятелем. «Новые люди» – это не просто название пьесы Ибрагимова, это – пафос его жизни, его служения революционной новизне. Он и сам был новым человеком, сыном Великой Революции.

«Я – солдат пролетарской революции. Если я сумел создать произведения, нужные рабочим и крестьянам, то причина этому не мой талант, а связь с моим народом». Эти слова Ибрагимова привел в своем докладе первый заместитель Председателя Совета Министров ТАССР М. Х. Хасанов. Он сказал далее:

– Возьмите любую область татарской советской литературы и вы обнаружите там знак качества – могучее духовное влияние писателя-коммуниста. Уже одно перечисление основных направлений творческой деятельности Ибрагимова вызывает в нашем воображении титанический образ. Оригинальный мыслитель, смелый революционер и государственный деятель, классик татарской литературы, открывший широкий путь к методу социалистического реализма, писатель-интернационалист, проницательный критик, яркий публицист, эрудированный ученый-теоретик, педагог... По широте интересов и систематической целеустремленной научно-творческой деятельности он был в подлинном смысле слова энциклопедистом.

---

[1] «Вечерняя Казань» газетасының 1987 елгы 4 апрель санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

Историческая заслуга Ибрагимова состоит в том. Что он расширил горизонты татарской литературы, соединил ее с опытом русской, европейской литературы, с философскими корнями Востока.

Огромный интерес юбилейный вечер вызвал не только у москвичей. В переполненном зале ЦДЛ – партийные и советские работники, литераторы, ученые журналисты – гости из многих республик, представительная делегация из Татарии.

О чем говорили выступавшие?

Секретарь правления Союза писателей РСФСР, главный редактор еженедельника «Литературная Россия» М. М. Колосов[1]:

– Если разделить жизнь замечательного сына богатого талантами татарского народа на пять, даже на десять биографий, то каждый из этих десяти был бы не просто незаурядным человеком, но величиной, знаменитостью. До сих пор творчество Ибрагимова во всех областях – это источник радости и эстетического наслаждения.

Прозаик, лауреат Государственной премии Узбекистана имени Хамзы П. К. Кадыров[2]:

– Как между планетами Галактики, между народами, культурами Востока и Запада всегда существовали силы взаимного притяжения. Прогрессивные люди Татарии с давних дней наводили, образно говоря, духовный мост между Востоком и Западом, были послами передовой мысли. Творчество Ибрагимова послужило импульсом для пробуждения национального самосознания и в нашем, узбекском народе. Для всех поколений его книги – питательный, целебный родник.

Прозаик, секретарь правления Союза писателей Казахстана К. К. Турсункулов[3]:

– Он жил в казахских аулах, был мугаллимом, обучал детей, прекрасно знал нравы, культуру, язык моего народа. Мы, казахи, признательны ему навсегда за его «Дочь степи» – и считаем Ибрагимова своим, казахским писателем.

---

[1] *М. М. Колосов* – Михаил Маркович Колосов (1923–2001), әдәбият тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче.

[2] *П. К. Кадыров* – Пиримкул Кадыров (1928–2010), язучы, Үзбәкстан ССРның халык язучысы, Үзбәкстан ССРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

[3] *К. К. Турсункулов* – Калаубек Кудайбергенулы Турсункулов (1934–2009), казакъ язучысы, җәмәгать эшлеклесе.

Драматург, Секретарь правления Союза писателей СССР, председатель правления Союза писателей Башкирии А. М. Мирзагитов:

– Глубоко символично, что классик татарской литературы родился и вырос на нашей, башкирской земле, был посланцем Башкирии во ВЦИК, где слышал В. И. Ленина, общался с ним. Известна народная мудрость: учитель не тот, кто учит, а тот, у кого учатся. Ибрагимов и сегодня учит нас интернационализму, духовности, революционной гражданственности.

Украинский писатель и переводчик В. Г. Гримич[1]:

– Юбилеи наших великих предшественников – не только торжественное чествование. В дни 100-летия Тукая мы выпустили книгу его стихов и поэм в новых переводах, к 80-летию М. Джалиля вышел 34-тысячным тиражом и разошелся в две недели его стихотворный сборник на татарском и украинском языках. Готовятся к изданию переводы прозы и публицистики Г. Ибрагимова. Он знал Украину не понаслышке, восторженно писал о Тарасе Шевченко[2], называл его поэтом-героем. «Чувство семьи единой», о котором писал мой земляк Павло Тычина[3], было и для Ибрагимова жизненным, творческим девизом.

Драматург, руководитель писательской организации Татарии, председатель правления Союза писателей ТАССР Т. А. Миннуллин:

Тукай, Амирхан, Габдулла Кариев, Ибрагимов... Они родились в одно время и очень рано сформировались как мыслители. Если честно, наше поколение проигрывает им в гражданской зрелости. Время революционной перестройки требует от нас смелых поступков, а мы еще порой предпочитаем личное благополучие борьбе. Нам уютно в тени гигантов. Жизнь пламени недолговечна. Но они предпочитали сгорать, а не тлеть. И вот парадокс: след от короткого пламени долог, а дым рассеивается временем...

---

[1] *В. Г. Гримич* – Вилль Григорович Гримич (1925–2016), украин әдәбият тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче.

[2] *Тарас Шевченко* – Тарас Григорьевич Шевченко (1814–1861), украин шагыйре, рәссам, фикер иясе.

[3] *Павло Тычина* – Павло (Павел) Григорьевич Тычина (1891–1967), украин шагыйре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, УССР Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1929), Социалистик Хезмәт Герое (1967).

Классики напоминают нам, пишущим, о долге перед народом и Родиной: светить, освещать. Нет важнее задачи – передать эту традицию следующим поколениям.

Вечер закончился большим концертом мастеров искусств Татарии.

На вечере присутствовали: заместитель заведующего Отделом культуры ЦК КПСС Е. В. Зайцев, заведующий сектором художественной литературы Отдела культуры ЦК КПСС В. А. Степанов[1], инструктор Отдела культуры ЦК КПСС Н. Н. Митрофанов, инструктор Отдела организационно-партийной работы ЦК КПСС В. П. Пичугин, инструктор Отдела пропаганды ЦК КПСС В. М. Леонов, заведующий отделом культуры, искусства и печати Совета Министров РСФСР А. П. Беляков, академик К. А. Валиев[2], заведующая отделом культуры Татарского обкома КПСС Д. Х. Зарипова.

Н. Жданова,
Б. Вахнюк

---

[1] *В. А. Степанов* – Виктор Александрович Степанов (1934–1988).

[2] *К. А. Валиев* – Камил Әхмәт улы Вәлиев (1931–2010), физик, физика-математика фәннәре докторы (1964), РФАнең хакыйкый әгъзасы (1991; 1972 елдан СССР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, 1984 тән хакыйкый әгъзасы), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1992), Казан университетының шәрәфле докторы (2006).

## 1997
## Яҙыусы, йәмәғәт эшмәкәре[1]

19 март 1997 йыл

Кисә Башҡорт дәүләт педагогия институтында күренекле татар яҙыусыһы, яҡташыбыҙ, йәмәғәт эшмәкәре Ғәлимйән Ибраһимовтың тыуыуына 110 йыл тулыуга арналған ғилми конференция уҙғарылды.

Профессор Р. Әмиров[2], педагогия институтының татар филологияһы кафедраһы мөдире, доцент С. Сафуанов[3], Тарих, тел һәм әҙәбиәт институтының бүлек мөдире, тарих фәндәре докторы С. Ҡасимов[4], Башкорт дәүләт университетының татар филологияһы кафедраһы мөдире, профессор Р. Сибәғәтов[5] йөкмәткеле докладтар менән сыгыш яһаны.

А. Байсурин

---

[1] «Башҡортостан» газетасының 1997 елгы 19 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *Р. Әмиров* – Рәиф Кадим улы Әмиров (1941), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1986), профессор (1987), Башкортстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (1992).

[3] *С. Сафуанов* – Суфиян Гаяз улы Сафуанов (1931–2009), филология фәннәре кандидаты, әдәбият галиме, тәнкыйтьче.

[4] *С. Ҡасимов* – Салават Фитрәт улы Касыймов (1934), тарихчы, тарих фәннәре докторы (1995), профессор (1998), Башкортстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (1998).

[5] *Р. Сибәғәтов* – Радик Гали улы Сибәгатов (1934–2005), тел галиме, филология фәннәре докторы (1988), профессор (1989), Башкортстан һәм Татарстан Республикаларының атказанган фән эшлеклесе (1993, 2004).

## 2001
## Г. Ибраһимовның яңа томы[1]

2001 ел

100 еллык юбилее уңае белән Г. Ибраһимовның «Әсәрләр»е җыелмасының сигез томы басылып чыккан иде. Әмма аның бай мирасы ул томнарга гына сыеп бетә алмады. Ниһаять, тугызынчы томы[2] дөнья күрде. Бу җыелмага әдипнең элекке «Әсәрләр»енә кермәгән автобиографик язмалары, хатлары, автографлары, телеграммалары, гаризалары тупланган. Язмалар төрле газета-журналлардан, Киев, Мәскәү, Казан, Уфа архивларыннан җыелган.

Бу томлык нигезендә Г. Ибраһимов – иҗтимагый мәнфәгатьләр белән янып яшәүче зур дәүләт эшлеклесе, киң белемле галим, талантлы язучы, көчле рухлы, трагик язмышлы шәхес итеп күз алдына килә.

---

[1] «Казан утлары» журналының 2001 елгы 5 нче санында бастырылган (б. 191). Текст шуннан алынды.

[2] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Тугыз томда / Җыентыкны төзүче, текст һәм аңлатмаларны әзерләүче Ибраһимова Ф. И. / Г. Ибраһимов.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.– 9 т.: Хатлар һәм документлар.– 464 б.

## 2007
## Бөек әдипкә багышлана[1]

16 март 2007 ел

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар әдәбияты классигы, күренекле галим, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 120 ел тулуга багышланган «түгәрәк өстәл» булып үтте. Анда әлеге институтының танылган галимнәре, телевидение-радио, матбугат вәкилләре катнашты.

«Түгәрәк өстәл» утырышын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы К. Миңнуллин алып барды. Ул әүвәл кыскача гына олуг юбилей уңаеннан планлаштырылган эшләр һәм алда торган мәсьәләләр белән таныштырды. 1967 елдан бирле Г. Ибраһимов исемен йөрткән бу институт галимнәренең олуг әдибебез исемен һәм иҗатын мәңгеләштерүдә турыдан-туры катнашы барлыгын билгеләп үтте. Казанның Декабристлар урамы һәм Ибраһимов проспекты тоташкан урында Г. Ибраһимовка һәйкәл кую турында хөкүмәткә тәкъдим кертелүе, апрель аенда әдипкә багышланган зур фәнни-гамәли конференция узачагы һәм башка күп төрле чаралар турында хәбәр итте. «Түгәрәк өстәл» утырышында институт галимнәре тарафыннан әзерләнгән, «Мәгариф» нәшриятында басылып чыккан «Галимҗан Ибраһимов. Милләт-тел-әдәбият» дигән китапның, Г. Ибраһимовның төрле елларда язылган фәнни һәм тәнкыйть мәкаләләре тупланган җыентыкның беренче әзер нөсхәләре күрсәтелде.

Утырышта шулай ук Г. Ибраһимовның барлык әсәрләрен дә колачлаган яңа күптомлык һәм әдипнең энциклопедик басмасын әзерләү хакында да сүз барды.

«Түгәрәк өстәл»дә катнашкан галимнәр Ф. Урманчиев, М. Әхмәтҗанов, Х. Мәхмүтов, Н. Хисамов, Р. Исламов, З. Рәмиев, Г. Арсланов, М. Зәкиев һ.б. Г. Ибраһимовның катлаулы язмышы хакында искәртеп, аның татар әдәбияты тарихында зур роль уйнаган шәхес булуын әйтеп, әдипнең фәнни-гыйльми эшчәнлегенә дә югары бәя бирде.

---

[1] «Мәдәни җомга» газетасының 2007 елгы 16 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

Утырышта катнашучылар соңыннан Казанның 17 нче гимназиясенә юл тотты, Г. Ибраһимовның гимназия каршында куелган бюстына чәчәкләр салды, гимназиянең укучылары һәм укытучылар коллективы белән очрашты.

Нияз Акмал

## Бөек әдипкә багышлана[1]

16 март 2007 ел

Татарстанда Г. Ибраһимовны олылау көннәре үткән атна башында Яр Чаллы дәүләт педагогия институтында башлап җибәрделәр. Биредә «Галимҗан Ибраһимов мирасы һәм хәзерге заман» исеме астында фәнни-гамәли конференция узды. Әлеге чарада Казан, Уфа, Яр Чаллы, Алабуга, Минзәлә кебек шәһәрләрдән әдәбият галимнәре, 120 ләп мәктәп укытучысы, филология белгечлеге буенча белем алучы студентлар һәм аспирантлар катнашты.

Конференцияне ачу тантанасында институтның ректоры Фәйрүзә Мостафина барлык килгән кунакларны тәбрикләп, «Биредә халкыбыз киләчәген уйлап, армый-талмый эшләүче галимнәребез җыелган» дип ассызыклап узды. Ул шулай ук кунакларга Г. Ибраһимов иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнгән зур галимебез Мансур Хәсәновның котлавын һәм фатихасын да җиткерде.

Конференциянең пленар утырышын КДУ профессоры, тәнкыйтьче һәм язучы Тәлгат Галиуллин алып барды. Аның сүзләренә караганда, идеология һзм заманалар үзгәрсә дә, Г. Ибраһимовның гасыр башында һәм 20–30 нчы елларда әйтелгән фикерләре һаман да актуаль кала бирә, әсәрләре яңа күзлектән чыгып өйрәнелә һәм аны һич кенә дә совет җырын гына җырлаган большевик буларак кабул итәргә кирәкми.

Язучының иҗатын заман таләпләрен истә тотып өйрәнү кирәклеген шулай ук пленар утырышта чыгыш ясаган галимнәребез Хатыйп Миңнегулов, Фоат Галимуллин, Дания Заһидуллина, Мирфатыйх Зәкиев тә искәртеп үтте. Галимнең исемен йөрткән Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары Рамил Исламов белдергәнчә, бүгенге көндә Г. Ибраһимов иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнү буенча зур эшләр башкару сорала, аның әлегәчә өйрәнелмәгән язмалары да шактый, хәзергә кадәр хәтта җәсәденең кайда күмелгәнлеге дә төгаен билгеле түгел.

Конференция үз эшен өч секциягә бүленеп алып барды. Секцияләрдә ясалган чыгышлар Галимҗан Ибраһимовның иҗатын,

[1] «Мәдәни җомга» газетасының 2007 елгы 16 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

татар әдәбияты, тел гыйлеме, тәнкыйте, публицистикасы үсешенә керткән өлешен төрле яклап өйрәнүгә багышланды. Институт ректоры сүзләренә караганда, конференция материаллары буенча аерым җыентык та чыгарылачак. Эш нәтиҗәсе буенча кабул ителгән резолюциядә исә иң мөһиме булып ТР Мәдәният министрлыгына Галимҗан Ибраһимовның Казанда һәйкәлен булдыру турында тәкъдиме тора.

Радик Сабиров

## Якты рухы шат булсын![1]

17 март 2007 ел

Әдәбиятыбыз классигы, күренекле педагог, мәгърифәтче, публицист, тарихчы, галим, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 120 ел тулды.

Хөкүмәтебез бу олуг шәхеснең исемен мәңгеләштерү юлында кайбер чаралар күрде. Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына, башкалабызның зур бер урамына һәм Казандагы 17 нче гимназиягә аның исеме бирелгән.

Юбилей уңаеннан, әдип исемендәге шушы урамда киләчәктә аның һәйкәле куелачак һәм язучы турында бай мәгълүмат тупланган энциклопедия дөнья күрәчәк. Бу турыда шушы көннәрдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында үткәрелгән «түгәрәк өстәл»дә әйтелде. Институт директоры, профессор Ким Миңнуллин алып барган бу очрашуда язучылар, галимнәр, журналистлар һәм җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Аннары алар, 17 нче гимназиядә булып, әдипнең мондагы һәйкәленә чәчәкләр салды һәм аның музеен карады. Укучылар һәм укытучылар белән очрашу да бик җанлы һәм кызыклы булды.

С. Әхәтов

[1] «Мәгърифәт» газетасының 2007 елгы 17 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

## Җиңүчеләр билгеле[1]

31 март 2007 ел

Г. Ибраһимовның 120 еллыгына багышланган газетабызның 17 февраль санында басылган викторинага нәтиҗә ясар чак җитте. Иң сөендергәне – җавапларның һәрберсе дөрес иде. Бүтән чакта мондый викторина-конкурсларда кызлар гына катнаша, ә бу юлы малайларның активлыгына сокландык. Редакциягә килгән 105 җавапның нәкъ яртысы – аларныкы.

Татарстанның барлык районнарыннан да килде җаваплар. Кайбер укучылар озаклап китапханәләрдә утырып, укытучылары ярдәме белән чын фәнни хезмәт язганнар. Үз укучыларында әдәбиятка шундый тирән мәхәббәт уята алганы өчен Апас районы Ындырчы мәктәбе, Мамадыш районы, Урта Кирмән урта мәктәбе укытучыларына да зур рәхмәтле без.

Ә хәзер җиңүчеләрне атыйбыз. Менә алар:

I урын Фаил Сафиуллин (Апас, Югары Ындырчы), Разия Бәдретдинова (Сарман, Мортыштамак).

II урын Айназ Галиев (Лениногорск, Урмышлы), Балтач районы Салавыч урта мәктәбеннән «Туган якны өйрәнү» музее әгъзалары.

III урын Чистай районы Мөслим урта мәктәбенең V сыйныф укучылары (җитәкчеләре Гүзәлия Фәйзрахманова), Арча районы Шурабаш мәктәбе укучылары.

Тагын Яшел Үзән районы Олы Шырдан мәктәбеннән Гөлия һәм Гөлназ Талиповалар, Тәтеш районы Келәш мәктәбеннән Чулпан Камалетдинова, Сарман районы Зур Нөркәй мәктәбеннән Наилә Вәлиуллина, Мамадыш районы Вахит авылыннан Ильмир Низамиевның эшләре билгеләп үтелде.

Фамилияләре газетада күренгән җиңүче укучыларыбыз Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының истәлекле китаплары белән бүләкләнә.

Котлыйбыз!

---

[1] «Сабантуй» газетасының 2007 елгы 31 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

## Mənalı ömrün akkordları…[1]

5 may 2007

Bu günərdə Tatarıstan Respublikasının paytaxtı Kazan şəhərində tatar ədəbiyyatının klassiki, görkəmli alim, tanınmış dövlət və ictimai xadim Əlimcan Ibrahimovun anadan olmasının 120 illiyin həsr olunmuş «Əlimcan Ibraimov və XXI əsr» mövzusunda beynəlxalq elmi-praktik konfrans keçirilib. Azərbaycan MEA Nizami adına ədəbiyyat Institutunun «Xarici ölkələr ədəbiyyatı və ədəbi əlaqələr» şöbəsinin müdiri, filologiya doktoru, professor Vaqif Arzumanlı həmin tədbirdə iştirak edib. Professorun tədbirlə bağlı yazısını təqdim edirik.

...Ə. Ibraimova həsr edilmiş beynəlxalq konfrans ayrı-ayrı bölmələrdəki məruzələrlə öz işinə başladı. Üç bölmədə – «Ə. Ibraimov və tatar ədəbiyyatı», «Ə. Ibraimov və tatar dili», «Ə. Ibraimov və tatar tarixi və mədəniyyəti» – 60-dan artıq məruzə dinlndi.

Günün ikinci yarısında isə plenar iclası keçirildi. Mənim «Əlimcan Ibraimov və Azərbaycan ədəbiyyatı» mövzusundakı məruzəm məhz plenar iclasa salınmışdı. Bu iclada programa əsasən cəmi dörd məruzə dinlənildi.

Bütün qonaqların, dövlət və hökümət üzvlərinin, Tatarıstan Elmlər Akademiyası rəhbərliyinin iştirk etdiyi plenar iclasdakı məruzəm maraqla qarşılandı və Təşkilat Komitəsi tərəfindən xüsusi olaraq yüksək qiymətləndirildi.

Mən öz məruzəmdə əsasən Ə. Ibraimovun Azərbaycan ədəbiyyatı ilə bağılıqlarını əhatə etməyə çalışdım. Daha doğrusu, məruzəm «Ə. Ibraimov və Yusif Vəzir Çəmənzəminli», «Ə. Ibraimovun 1926-cı ildə Bakıda keçirilən I türkoloji quqrultayda iştirakı», «Ə. Ibraimovun bədii əsərləri Azərbaycan dilində», «Ə. Ibraimovun nəşri ilə XX əsrin 20–30-cu illrində Azərbaycan nəsri arasında tipoloji oxşarlıqlar», «Azərbaycan yazıçıları Ə. Ibraimovun yaradıçılığı haqqında», «Ə. Ibraimov klassik Azərbaycan ədəbiyyatı haqqında», «Ə. Ibraimov Nəriman Nərimanov haqqında», «Azərbaycan ədəbiyyatşünaslğı Ə. Ibraimov haqqında» məsələlərini əhatə edidi. Əlbəttə, bu məsələlərin hərəsinin ayrıca bir məruzənin mövzusu olmasına baxmayaraq, ayrılan vaxt çərçivəsində məruzəmin əsas tezislrini

[1] Баку шәһәрендә нәшер ителүче «Xəzər» газетасының 2007 елгы 5 май санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

konfrans iştirakçılarına çatdıra bildim və ətbii ki, bu da həmkarlarım tərəfindən yüksək səviyyədə təqdir olundu.

Maraqlıdır ki, elə oradaca həm Tatrıstan EA Ə. Ibraimov adına Dil, ədəbiyyat və incəsənət Institunun, həm Kazan Dövlət Universitetinin, həm də bir il əvvəl fəaliyyət başlamış Tatrıstan Humanitar-Pedaqoji Universitetindən olan həmkarlarımız məruzənin surətlərini istədilər ki, onu öz elmi toplularında çap etdirsinlər. Hətta mənim bu mövzuda ayrıca kitabımın hazırlanmasının vacibliyini vurğuladılar.

Beynəlxalq konfrans Kazandakı Q. Kamal adına Tatar Dövlət Akademik Teatrında Ə. Ibraimovun anadan olunmasının 120 illiyinə həsr edilmiş ədəbi-musiqili gecə ilə başa çatdı. Daha sonra Tatarıstan hököməti və konfransın Təşkilat Komitəsi qonaqların şərəfinə ziyaft verdi.

Kazanda olarkən fürsətdən istifadə edib Ə. Ibraimov adına Dil, ədəbiyyat və incəsənət Institutu ilə Nizami adına ədbiyyat Institutu arasında əməkdaşlığın da gücləndirilməsi istiqamətində görüləcək işlər barədə söhbətlər apardım. Razılaşdıq ki, yaxın illrdə birlikdə «Azərbaycan-tatar ədəbi əlaqələri» mövzusunda araşdırmalardan ibarət monografiya hazırlayaq və bu kitabın tatar və Azərbaycan dillrində Kazanda və Bakıda nəşrinə nail olaq.

Ə. Ibraimov adına Dil, ədəbiyyat və incəsənət Institunun direktoru, filologiya elmləri doktoru, proftssor Kim Minnullin və Institutun elmi işlər üzrə direktor müavini, filologiya elmləri doktoru Ramil Islamov ilə söhbətlərim zamanı onların Azərbaycana olan dərin rəğbətini, çox isti münasibətlərini hiss etdim və bu da məndə inam yaratdı ki, həqiqətən iki elm ocağı arasında yaından əməkdaşlıq üçün xeyli imkanlar mövcuddur...

Kazanda keçirilən beynəlxalq konfrans iştirakçılarının coğraffiyası geniş idi. Bu mötəbər tədbirdə Türkiyə, Ukraina, Mərkəzi Asiya respulikaları, eləcə də Rusiyanın bütün türk respublika və vilayətlərindən dəvət olunmuş qonaqlar iştirak edirdilr.

Kazanda keçirilən konfrans işində qonaq səfəri ilə Tatrıstan Respublikasının Azərbaycandakı daimi nümayndliyinin rəhbəri, akademik Nail Şamiloviç Zaripov[1] da iştirak edirdi. Konfransda məruzə etməsə də, Nail Zaripov bu mötəbər məclisə əliboş gəlməmişdi. Onun təşbbüsü iəl 1926-ci ildə Bakıda keçiriln I türkoloji qurultayın kinolentləri, xüsusilə Ə. Ibraimovun və o tarixi tədbirdə

[1] *Nail Şamiloviç Zaripov* – Наил Шамил улы Зарипов (1955), 2005–2013 елларда Татарстан Республикасының Әзәрбәйҗан Республикасындагы Даими вәкиле.

görkəmli ədibin və alimin rəhbərliyi ilə iştirak edən Tatarıstan nümayəndə heyətinin fəaliyyəti ilə bağlı Bakıda çəkilən kinokadrların konfransda nümayiş etdirməsi çox əlamətdar hadisə oldu. Bu vaxta qədər həmin tarixi kinolentlr Tatarıstan ictimaiyyətinə demok olar ki, molum deyildi.

Vaqif Arzumanlı,
filolojiya elmləri doktoru, professor

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## 1917
## Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы нәшер ителәчәге хакында[1]

18 август 1917 ел

Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр» исемендә булган бөек романы моннан өч ел элек басыла башлап та цензор рөхсәт итмәү сәбәбеннән туктатылган иде. «Гасыр» көтебханәсе тиздән бу әсәрне басарга керешәчәк[2]. «Безнең көннәр» биш йөз сәхифәләр чамасында булып, 1905 нче елдагы бөек революцияне тасвир итәдер.

## 1919

### Әдәбият дөньясында[3]

12 октябрь 1919 ел

Бөек революционерымыз Мулланур Вахитов иптәш хакында Галимҗан Ибраһимов карамагында Мәркәз мөселман хәрби һәйәте тарафыннан «Шәрыкның бөек революционеры Муллануp иптәш Вахитов» дигән исемдә дүрт-биш табаклы бер мәҗмуга тәртип ителеп, басарга бирелде[4]. Мәҗмуга Октябрь революциясенең ике еллык бәйрәменә багышлана. Вахитовның тәрҗемәи хәле, рәсемнәре, кульязмалары, аның эшләре, характеристикасы хакында пролетариат мөхәррирләренең мәкаләләре, хатирәләре, шигырьләре булачактыр.

---

[1] «Ирек» газетасының 1917 елгы 18 август санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Гасыр» көтебханәсе тиздән бу әсәрне басарга керешәчәк* – Ибраһимов Г. Безнең көннәр: Роман / Г. Ибраһимов.– Казань: Лито-тип. т-ва «Умид», 1919.– 442 б.

[3] «Кызыл Армия» газетасының 1919 елгы 12 октябрь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[4] *Басылып чыга:* Шәрыкның бөек революционеры Мулланур Вахитов. Мәҗмуга Октябрь революциясенең ике еллык бәйрәменә багышлана. Галимҗан Ибраһимов карамагында. Мәркәз мөселман хәрби һәйәт нәшере.– Казань: Тип. т-ва «Умид», 1919.– 100 б.

## 1920

### Матбугат дөньясында[1]

18 октябрь 1920 ел

«Яңа кешеләр»[2]
Өч пәрдәлек драма
(1918–19 нчы елларда Идел-Урал тупрагындагы
вакыйгалардан алынган)

Галимҗан Ибраһимовның югарыдагы әсәре әдипләр, журналистлар, артистлар кулында язма хәлендә укылды. Якын арада Казан сәхнәсендә кую чарасына керешәләр.

Октябрь революциясенә өч ел тулу бәйрәменә өлгертергә тырышылачак.

---

[1] «Эшче» газетасының 1920 елгы 18 октябрь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Яңа кешеләр»* – Ибраһимов Г. Яңа кешеләр: Драма өч пәрдәдә (Вакыйга 1918–1919 нчы елларда Идел-Урал тупрагында) / Г. Ибраһимов.– Казанда «Өмид» матбагасы, 1920.– 60 б.

Әлеге пьесасы өчен Г. Ибраһимов ел буена авторлык гонорары бирелмәү шарты белән 150 мең сум акчалата бүләкләнә (Татарстан Республикасы Милли архивы: Р-3682 ф., 1 тасв., 7 эш, 5 кәг. Төп нөсхә).

## 1922

### Галимҗан Ибраһимов тарафыннан төзелгән әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының беренче китабы нәшер ителү хакында[1]

31 гыйнвар 1922

Мөһим әдәби әсәр. Бөтен килере ачларга багышланган. Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасы (альманах) басылып тәмам булды.

Мөндәриҗә:
«Ил көтә». Ф. Бурнаш.
«Вакытсыз һәлак булды». Галимҗан Ибраһимов.
Шигырь. Шәехзадә Бабич.
«Соңгы минутта». Мәҗит Гафури.
«Ачлык көннәрендә». Кәрим Әмири.
«Шәмсия». Фәтхи Бурнаш.
«Беренче ашкыну». Фатыйх Әмирхан.
«Идел» хикәясеннән. Гали Рәхим.
«Күмгән иде». Г. Газиз.
«Яңгырсыз елларда». М. Гали[2].
«Крушниклар». Фатыйх Сәйфи-Казанлы.
«Барыбер». Садри Җәлал.
«Без түбәннән күтәрелдек». Галимҗан Ибраһимов.
Көйле парчалар. Сүнчәләй, Бабич, Эшче.

Мәҗмуга Галимҗан Ибраһимов редакциясендә чыга. 135 бит, хакы 40 мең сум.

Хәзердән күпләп алу өчен адрес:
Казань, «Помгол».

---

[1] «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 31 гыйнвар санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *М. Гали* – Мөхәммәт Вәли улы Галиев (1893–1952), язучы, журналист, әдәбият галиме.

## Галимҗан Ибраһимов тарафыннан төзелгән әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының беренче китабы нәшер ителү хакында[1]

2, 3, 7, 10, 14, 15 февраль, 10 март 1922

Яңа гына басылып чыкты һәм сатыла башлады.

Әдип һәм шагыйрьләребездән Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш, Шәехзадә Бабич, Фатыйх Әмирхан, Гали Рәхим, Г. Газиз, М. Гали, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Садри Җәлал, Мәҗит Гафури, Кәрим Әмири, Сәгыйть Сүнчәләй һәм башкаларның катнашы белән язылган әдәби «Ярдәм» мәҗмугасы «Васита» көтепханәсендә[2] берәмләп һәм күпләп сатыла башлады[3].

Берәмләп хакы: 55 мең сум.

Адрес:

Казань, Сенная, Т-во «Васита».

## Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр» һәм «Яңа кешеләр» драмасы сатылуы хакында[4]

17, 20 февраль 1922

Дәүләт нәшриятының мөселманча китап складында түбәндә мәзкүр китаплар һәркемгә күпләп һәм берәмләп сатыла.

«Безнең көннәр» 456 битле бөек революционный роман. Мөхәррире: Галимҗан Ибраһимов, бәһасе 45, 000 сум.

«Яңа кешеләр» драма өч пәрдәдә. Мөхәррире: Галимҗан Ибраһимов. 8, 000 сум [...].

Мөрәҗәгать өчен адрес:

г. Казань, Тукаевская ул[ица], д. № 31. Мусульман[ский] книж[ный] п/отдел Татгосиздат.

---

[1] «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 2, 3, 7, 10, 14, 15 февраль, 10 март саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Васита»* – Казанда 1910 елларда оешкан китап сату ширкәте, 1917 елда шул җирлектә ачылган нәшрият.

[3] Әдәби ярдәм мәҗмугасы.– Казан: Т. С. Ш. Җ. 2 нче номерлы дәүләт басмаханәсендә эшләнде, 1922.– 130 б.

[4] «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 17, 20 февраль саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Галимҗан Ибраһимовның «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан (Кечкенә хатирә)» дигән хезмәте нәшер ителү хакында[1]

1922 ел, № 3

Казанда яшь коммунистлар союзы тарафыннан яңа гына басылып чыкты «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан (Кечкенә хатирә)»[2]. Мөхәррире: Галимҗан Ибраһимов.

Революция тарихына материаллар җыючылар өчен мотлак алып укылырга тиешле мөһим бер әсәрдер.

Мөндәриҗәсе:

Башлангыч – Реакция көннәре – Мөртәтләр – Үз дөньябызда – «Лена» фаҗигасе – Яңадан дулкын – Доктор Кайбышев Хәнәфи – «Хәллә» – Лиза – Петька – Коля – Агаш – Грузин большевик – Киевтә мөселман землячествосы – Беренче яңлыш адым – Яшерен оешма һәйәтенең эш планы – Әгъзалары – Көрәш маддәсе – Яңадан Кайбышев – 17 нче апрельгә вәкилләр җыелды – Ике каһарман – Жандармерия – Гуля – Участка – Жандарм ата яки палач – Иректә калганнар – Оешманың рәисе Ханталышский җылы – Бер мәктүпнең язмышы – Вакыйганы ни өчен кабартмыйлар – Мәсьәлә туктала – Зинданда үзгәрүчеләр – Шлисельбург каһарманнарын каршы алалармыни? «Ишек күрсәтүләр» ни белән бетте? – «Каһарманнар»ганиләр булды – Хатимә.

---

[1] «Кызыл Шәрык яшьләре» журналының 1922 елгы 3–4 нче кушма санында урнаштырылган (б. 48). Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Казанда яшь коммунистлар союзы тарафыннан яңа гына басылып чыкты «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан (Кечкенә хатирә)»* – Ибраһимов Г. Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан кечкенә бер хатирә. Татарстан өлкә комитеты коммунист яшьләр союзы нәшере / Г. Ибраһимов.– Казан: «Татарстан» матбагасы, 1922.– 42 б.

## «Кызыл чәчәкләр» хикәясе[1]

18 июнь 1922 ел

Шушы көннәрдә Татарстан дәүләт нәшрияты тарафыннан Галимҗан иптәш Ибраһимовның соңгы әсәрләреннән булган «Кызыл чәчәкләр» исемендәге хикәясе басылып чыкты[2]. Хикәя урта кулда 148 бит зурлыкта булып, соң дәрәҗә яхшы кәгазьгә басылган һәм нәфис итеп эшләнгән әсәрнең мөндәриҗәсе хакында язуны икенче вакытка калдырабыз.

[1] «Татарстан» газетасының 1922 елгы 18 июнь санында бастырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Кызыл чәчәкләр» исемендәге хикәясе басылып чыкты* – Ибраһимов Г. Кызыл чәчәкләр хикәясе (Без түбәннән күтәрелдек) / Г. Ибраһимов.– Казан: Социал Советлар Җөмһүриятенең дәүләт нәшрияты, 1922.– 148 б.

## Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының икенче кисәге нәшер ителүе хакында[1]

20 июнь 1922 ел

Бөтен килере ач балаларга багышланган әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының икенче кисәге басылып бетеп сатыла башлады[2].

Мөндәриҗәсе түбәндәгечә:

1) «Ярдәм юлында» – Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш; 2) «Көзге җилләр» (шигырь) – Г. Тукай; 3) «Алмачуар» (хикәя) – Галимҗан Ибраһимов; 4) «Мөхәммәтҗан» (көйле парча) – Фәйз әл-Ба; 5) «Бай һәм ярлы», «Җан», «Көрәшеп үткән кыска гомереңне!!», «Бәнем фәрештәм», «Дөньяга» (шигырьләр) – Шәехзадә Бабич; 6) «Чукынган мәхдүм белән урыс зиратында күмелгән хаҗи» (хикәя) – М. Гали; 7) «Дошман ягында тоткынлыкта илне сагыну» (шигырь) – Миргазиз Укмасый; 8) «Зимагур» (хикәя) – Фатыйх Сәйфи-Казанлы; 9) «Сихерләде мине кызыл гөл» (шигырь) – Кәрим Әмири; 10) «Таштугай», «Давылбай», «Бану» (башкорт җырлары) – җыючысы: Мәхмүт Бөдәйли[3]; 11) «Эшче кызы Нина» (хикәя) – Шамил Госманов; 12) «Җәйге көннәр» (шигырь) – Г. Харис[4]; 13) «Җылыйлар» (шигырь) – М. Гафури; 14) «Азатлык юлында» (хикәя) – С. А. Азаматов; 15) «Изел-йорт» (башкорт такмагы) – җыючысы: Хуҗа Бәдигый[5]; 16) «Ярдәм!!», «Ил үлә» (шигырьләр) – Мирзаяр Мөхәммәт; 17) «Журналист» (хикәя) – Садри Җәлал; 18) «Язгы җил» (шигырь) – Зәйнәп Бәширова[6]; 19) «Тырнак сугу» (хикәя) – Гали Хәбиб; 20) «Ачлык җәһәннәме», «Саф чәчәкләр»

---

[1] «Татарстан» газетасының 1922 елгы 20 июнь санында бастырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *...әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының икенче кисәге басылып бетеп сатыла башлады* – Әдәби ярдәм мәҗмугасы. Икенче китап. Татар җөмһүриятендәге әдипләр, шагыйрьләр һәм нашир, матбагачыларның бер коллектив уларак хезмәт-ярдәмнәре белән чыга.– Казан: «Татарстан матбагасы», 1922.– 240 б.

[3] *Мәхмүт Бөдәйли* – Мәхмүт Кәшфелһади улы Бөдәйли (1895–1975), журналист, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

[4] *Г. Харис* – Габдулла (Габдуллаҗан) Харис улы Харисов (1893–1931), шагыйрь.

[5] *Хуҗа Бәдигый* – Хуҗа Габделбәдигъ улы Бәдигов (1887–1940), тел галиме, фольклорчы.

[6] *Зәйнәп Бәширова* – Зәйнәп Хуҗихан кызы Бәширова (1903–1984), шагыйрә.

(шигырьләр) – Нәҗип Думави; 21) «Тәгъзия» (хикәя) – Фатыйх Әмирхан; 22) «Эскрипкәче Хөсәен» – Г. Газиз; 23) «Күл өстендә көймәдә» (шигырь) – Сәмави[1]; 24) «Сандугач ник соры булган?» (хикәя) – Гали Рәхим; 25) «Язмышка каршы» (нәсер) – М. Максут; 26) «Кызыл каһарманнарга» (шигырь) – Сәгыйть Сүнчәләй; 27) «Ярдәм» мәҗмугалары идарәсеннән.

Мәҗмуга урта кулда, 240 битлек зурлыкта булып, беренче кисәге бик яхшы кәгазьгә басылган һәм нәфис итеп эшләнгән.

Сәнаигы нәфисә вә әдәбият мөхибләре һәм күңелләрендә ачларга ярдәм хисе булган затлар әдәби «Ярдәм» мәҗмугаларының беренче һәм икенче кисәкләрен сатып беткәнгә кадәр алып калырга тиешләр!!

Әдәби «Ярдәм» мәҗмугасының беренче кисәгенең бәһасе берәмләп (1922 нче елда чыгарган акча белән) 42 сум. Икенче кисәк 105 сум. Икесе бергә 145 сум.

Күпләп һәм берәмләп Тукайский урамда 31 нче номерлы йортта дәүләт нәшриятының мөселманча китап складында саклана.

Читтән соратучыларга мөрәҗәгать өчен адрес:

Казань: Тукаевская ул., д. № 31. Мусульманский книжный склад.

---

[1] *Сәмави* – Төхфәтулла Ченәкәев.

## 1924

## Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» хикәясе нәшер ителү хакында[1]

10, 13, 15, 16 гыйнвар 1924 ел

Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты тарафыннан яңа басылып сатыла башлады «Адәмнәр» Галимҗан Ибраһимов әсәре[2]. Хикәя. Бәһасе 45 тиен.

(1921–22 нче елларның кышкы көннәрендә Идел-Урал буе).

Бу китапта 1921–22 нче елда булган ачлыкның фаҗигасе тасвир ителә. Бу ачлыкта үлүчеләр, бер кадак икмәк өчен кеше үтерү, бер кадак икмәккә тән сату, авыл бае, кулакның ачлыктан файдалану өчен ачлар белән тарткалашуы, адәм ите ашау, адәм итен шәһәр базарына сату кеби гаять куркыныч манзараларны эченә алган бу хикәяне уку узган ачлыкны искә алдыру өчен җитәрлек гыйбрәт була ала.

Сорату өчен адрес:

Казань, Угол Московской и Евангелистовской ул под №№ Болгар, книжн[ый] магазин Комбината издательства и печати АТССР.

## Г. Ибраһимовның «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» дигән хезмәте нәшер ителү хакында[3]

17 июль 1924 ел

Галимҗан иптәш Ибраһимовның соңгы әсәре: «Кара маяклар» матбугат галәменә чыкты[4].

Төрек-татар контрреволюционерлары, кара әдипләр: Г. Исхаков, Муса Бигиев, Рәсүлзадә Әминнәрнең Советка каршы чыгарган китаплары, агитацияләре турында җиңгел телдә язылган яңа әсәр.

---

[1] «Татарстан» газетасының 1924 елгы 10, 13, 15, 16 гыйнвар саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *…яңа басылып сатыла башлады «Адәмнәр» Галимҗан Ибраһимов әсәре* – Ибраһимов Г. Адәмнәр: Хикәя / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты нәшере, 1923.– 50 б.

[3] «Азат Себер» газетасының 1924 елгы 17 июль санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[4] *«Кара маяклар» матбугат галәменә чыкты* – Ибраһимов Г. Кара маяклар яки ак әдәбиятлар / Г. Ибраһимов.– Мәскәү: «Нәшрият» кооперативы, 1924.– 70 б.

## 1925

### Каюм Насыйриның тууына йөз ел тулу уңае белән зур җыелыш![1]

15 февраль 1925 ел

1925 нче ел февраль 15, якшәмбе кич сәгать 7 дә Дәүләт татар театрында Каюм Насыйриның туганына йөз ел тулу уңае белән Гыйльми үзәк тарафыннан зур җыелыш ясала. Җыелышның программасы:

1) Каюм Насыйриның тарихи урыны – Галимҗан Ибраһимов.

2) Насыйриның биографиясе – Мөхәммәт Парсин.

3) Насыйриның имля, әдәби тел турында хезмәтләре – Мөхетдин Корбангалиев.

4) Насыйриның гыйльми-фәнни хезмәтләре – Г. Рәхим.

5) Истәлекләр, аерым төшенчәләр.

6) Җыелышта Каюм Насыйриның йөз еллык көнен Татарстан Җөмһүрияте хөкүмәтенең ничек олылау турындагы эшләре.

Җыелышка керү һәркемгә буш, билетлар таратылмый.

Йөз еллыкны үткәрү комиссиясе

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1925 елгы 15 февраль санында урнаштырылган. Текст төп нөсхәдән алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Гыйльми үзәктә[1]

1925 ел, № 1–2

Гыйльми үзәк коллегиясе – Татарстан Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе 1925 елның 4 нче февралендәге җыелышында Гыйльми үзәк янындагы татар һәм рус коллегияләренең составларын түбәндәгечә кабул итте:

1. Татар коллегиясе – рәис Галимҗан Ибраһимов. Әгъзалар: Шәһит Әхмәдиев, Исхак Рәхмәтуллин, Фатыйх Сәйфи, Гаяз Максудов, Латыйф Гомәров, Мөхәммәт Парсин, Габдулла Толымбайский, Мөхетдин Корбангалиев, Гали Рәхим.

2. Рус коллегиясе – рәис Галимҗан Ибраһимов. Әгъзалар: Кочкарин, М. К. Корбут[2], Дикавецкий[3] һәм Гермаидзе.

## Яңа чыккан китаплар[4]

1925 ел, № 10–11

«1905 нче ел революциясендә татарлар»[5] – Галимҗан Ибраһимов әсәре, 235 бит, бәясе 2 сум.

---

[1] «Мәгариф» журналының 1925 елгы 1–2 нче кушма санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *М. К. Корбут* – Михаил Ксаверьевич Корбут (1899–1937), тарихчы, Казан университеты профессоры. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[3] *Дикавецкий* – Александр Антонович Диковецкий (1902–1967), врач, галим, язучы, Казан университеты укытучысы.

[4] «Мәгариф» журналының 1925 елгы 10–11 нче кушма санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар графикасында беренче мәртәбә бастырыла.

[5] *«1905 нче ел революциясендә татарлар»* – Ибраһимов Г. Татарлар арасында революция хәрәкәтләре. Беренче бүлек (1905) / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1925.– 235 б.

## Тюркология съезды турында доклад
## Гомум халык өчен[1]

5 апрель 1926 ел

Дүшәмбе көн 5 нче апрельдә Татар театры бинасында кич сәгать 6 да Бакуда булып үткән беренче Тюркология съезды хакында вәкилләр тарафыннан хисап доклад булачак. Керү һәркемгә буш.

Докладчылар: Г. Ибраһимов, Г. Максудов, Г. Сәгъди, Н. Хәким, Г. Шәрәф...

Гыйльми үзәк

[1] Төп нөсхә (кулдан язылган) дәүләт бюджет учреждениесе «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»нда саклана (Р-3682 ф., 1 тасв., 950 эш, 19 кәг.). Текст шуннан алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

## 1927
## Яңа чыккан китаплар[1]

1927 ел, № 1

«Урал» һәм «уралчылар»[2]

Галимҗан Ибраһимов әсәре. Татарстан Дәүләт нәшрияты басмасы. 44 бит. 40 тиен. Галимҗан Ибраһимовның бу китабы махсус рәвештә «Урал»[3] һәм «уралчылар» гәзитенең XX еллыгына[4] каратып язылган. Хәзергә чаклы без «Урал» һәм «уралчылар» турында күбесенчә Г. Ибраһимовның «5 нче ел революциясендә татарлар» дигән китабыннан, бу турыдагы мәкалә һәм тезисларыннан файдалана идек. Бу китап инде «Урал» һәм «уралчылар» мәсьәләсенең, безнең тарихта большевизм хәрәкәте башлануның аерым рәвештә тикшерелеп бербөтен хәленә китерелгәнне күрәбез. Китап шушы мөндәриҗәдә[5] җыелган: I – Бездә гәзитәчелек тарихы һәм «Урал»; II – «Урал»ның заманы; III – уралчылык тарихы; IV – «Урал»ның тоткан юлы; V – Ахыргы сүз.

---

[1] «Безнең юл» журналының 1927 елгы 1 нче санында урнаштырылган (б. 40). Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә басыла.

[2] *«Урал» һәм «уралчылар»* – Ибраһимов Г. «Урал» һәм «уралчылар» («Урал» гәзитәсенең 20 еллык бәйрәмен үткәрү комиссиясе карамагында басыла) / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1927.– 44 б.

[3] *«Урал»* – атнасына 2–3 мәртәбә чыга торган татар телендәге беренче социал-демократик газета. Нашир, язучы, журналист Тимерша Салаватулла улы Соловьёв (1875–1947), сәясәт эшлеклесе Гомәр Хәбибрахман улы Терегулов (1887–1938) наширлегендә һәм Хәдичә Зариф кызы Ямашева (Таначева) (1883–1952) мөхәррирлегендә Оренбургта 1907 елның 4 гыйнварыннан шул ук елның 27 апрельгә кадәр нәшер ителә. Барлыгы 31 саны дөнья күргән.

[4] …*«Урал» һәм «уралчылар» гәзитенең XX еллыгына* – бу хакта тулырак кара: Мөхәммәт Гөлсем. «Урал» кичәсе // Безнең юл.– 1927.– № 1.– Б. 34–35; «Урал» газетасы хакында өстәмә кара: Səjfi-Qazannь F. «Ural» gəzete / F. Səjfi-Qazannь // Janalif.– 1932.– № 3.– B. 60–70.

[5] *Мөндәриҗә* – эчтәлек.

## Барлык редакция һәм нәшриятларга[1]

22 декабрь 1927 ел

Карт марксист татар әдибе Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык әдәби, гыйльми, иҗтимагый хезмәт юбилеен үткәрү Үзәк комиссиясе С.С.С.Р.дагы бөтен төрек-татар телләрендә чыга торган гәзит-журналларның редакцияләренә, төрле нәшриятларга, шулай ук гыйльми-әдәби оешмаларга түбәндәге үтенеч белән мөрәҗәгать итә:

Төрек-татар хезмәт ияләренең мәдәни барышларында иҗтимагый-мәдәни әһәмияте зур булган бер эшкә – татарның бөек әдибе Галимҗан Ибраһимовның XX еллык хезмәт юбилеен үткәрү эшенә кереште. Әлбәттә, бу зур мәдәни эш төрле урыннарның һәм юбилейне үткәрүдә төп эшне үз өстенә йөкләгән Үзәк комиссиянең һәрвакытта багланышта булуларын, юбилейгә хәзерлек вакытында кирәк булган бөтен материалларны уртаклашуларын сорый. Менә шуңар күрә дә Үзәк комиссия югарыда күрсәтелгән оешмаларның хәзер үк үзләрендә юбилей хәзерлегенең ничек баруын белдерүләре һәм үзләрендә гәзит-журналларда юбилейгә багланышлы булган һәрбер мәкалә һәм башкаларны даими рәвештә Үзәк комиссиягә җибәреп торуларын үтенә. Шулай ук Үзәк комиссия дә үз тарафыннан төрле урыннарга төрле аңлатмалар һәм материаллар җибәреп торачак.

Юбилейне үткәрү вакыты 15 нче февральдән мартның беренче яртысына кичектерелде. Материаллар һәм төрле кәгазьләр түбәндәге адрес белән җибәрелергә тиешләр:

Казань, Кремль, Наркомпрос, Акцентр, Юбил[ейной] Комиссии.

Үзәк комиссия рәисе өчен М. Таһиров.
Секретарь: Гомәр Галиев

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1927 елгы 22 декабрь, «Безнең юл» журналының 1927 елгы 12 нче саннарында (алгы тышлыкның эчке ягында) урнаштырылган. Текст газетадан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Яңа чыккан китаплар[1]

1927, № 2

«Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?»[2]

Галимҗан Ибраһимов әсәре. Татарстан Дәүләт нәшрияты басмасы. 1927.

Бу әсәрнең мөндәриҗәсе түбәндәгечә: Мөхәррирдән; 1 – Мәсьәләнең куелышы; 2 – Яңа һәм иске тип мирзалар карашы; 3 – Иске һәм яңа тип милләтчеләр; 4 – Пролетариат юлы; 5 – Сталин формуласы; 6 – Безнең өчен кайсы юл; 7 – Нәтиҗәләр.

Татар эшче-крәстиәннәрнең мәдәни барышларындагы төп моментларга тукталган, бу юлда киләчәк өчен нинди сызык булырга тиешлеген ачып биргән – милли мәдәниятләр мәсьәләсендә партия сәясәтенең төп моментларын күрсәтеп үткән бу әсәр, әлбәттә, бездә соңгы вакытта матбугатка чыккан әсәрләрнең зур әһәмиятле мәүзугълыларыннан берсе. Бәясе 25 тиен.

---

[1] «Безнең юл» журналының 1927 елгы 2 нче санында урнаштырылган (б. 38). Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар графикасында беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?»* – Ибраһимов Г. Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1927.– 40 б.

## 1928
## «Галимҗан Ибраһимов» җыентыгы нәшер ителәчәге хакында[1]

22 гыйнвар 1928 ел

Тиздән басылып чыга – Татиздат – тиздән басылып чыга

«Галимҗан Ибраһимов» (XX еллык әдәби, гыйльми, иҗтимагый хезмәт бәйрәме уңае белән чыгарыла торган гыйльми-тәнкыйди җыентык).

Җыентык эчендә.

1) Кереш урынында Исхак Рәхмәтуллин.

1 бүлем. Әдәби иҗади хезмәте.

2) Матурлык һәм азатлык шагыйре.

Сәнгать фәннәре академиясе президенты П. С. Коган.

3) Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары.

Габдрахман Сәгъди.

4) Галимҗан Ираһимов әсәрләрендә революция мотивлары.

Галимҗан Нигъмәти.

5) Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең өслүб һәм тематика яклары.

Г. Толымбайский.

6) Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә хатын-кызлар тормышы һәм хатын-кыз типлары.

Әминә Халид.

2 бүлем. Гыйльми хезмәте.

7) Татарда марксизм тәнкыйте һәм Галимҗан Ибраһимов.

Кави Нәҗми.

8) Татарда әдәбият белеме һәм Галимҗан Ибраһимов. Г. Галиев.

9) Галимҗан Ибраһимовның татар теленә хезмәте. Җәмал Вәлиди.

10) Галимҗан Ибраһимов – укытучы һәм методист.

Мөхетдин Корбангалиев.

11) Галимҗан Ибраһимов – татарны өйрәнүче.

Профессор А. Самойлович.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 22 гыйнвар санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

12) Революция хәрәкәтләре тарихы һәм Галимҗан Ибраһимов.

М. Сәгыйдуллин.

13) Тарихчы-сәясәтче булу ягыннан Галимҗан Ибраһимов.

Профессор Н. Н. Фирсов.

14) Галимҗан Ибраһимов әсәрләренең библиографиясе.

Рифгать Таһиров, Г. Мөхәммәдова.

Китап 15 басма табаклар (250 битләр) зурлыкта булып, яхшы кәгазь һәм рәсемнәр, һәм кулъязмалар белән бизәлеп басыла.

Хәзердән заказлар кабул ителә бер сум задатка җибәрүчеләргә. Калганы налож белән җибәрелә.

Күпләп алдыручыларга скидкә. Адрес:

Казань, Чернышевская 21. «Татиздата».

## Галимҗан Ибраһимовның художник П. П. Беньков тарафыннан ясалган рәсеме бастырылып чыгарылуы хакында[1]

29 гыйнвар, 1 февраль 1928 ел

XX еллык әдәби хезмәт бәйрәменә каратып Галимҗан Ибраһимовның Сәнгать фәннәре академиясе әгъзасы карт художник П. П. Беньков[2] тарафыннан ясалган рәсемен бастырып чыгарды.

Рәсем яхшы кәгазьдә, литография юлы белән эшләнгән булып, зурлыгы 72х58 сантиметр, хакы бары 50 тиен генә.

Саны аз булганлыктан заказларны алдан бирергә кирәк. Күпләп алучыларга скидка ясала.

Адресы: Казань, «Татиздат».

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 29 гыйнвар, 1 февраль саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *П. П. Беньков* – Павел Петрович Беньков (1872–1949), рәссам, педагог.

## «Безнең юл»ның бу саны[1]

Февраль 1928 ел

Татар массасының мәдәни үсешенә зур хезмәт иткән, татар әдәбияты-сәнгате дөньясына бик күп кыйммәтле иҗатлар бүләк иткән, классик әдәби әсәрләр тудырган, татар матбугатына марксизм нигезендә күпләп гыйльми-тарихи әсәрләр биргән, татар теленең гыйльми эшләнүе, татар әдәбиятының гыйльми тикшеренелүе юлында зур эш күрсәткән, зур көч түккән, пролетариат революциясенең актив көрәшчесе булып, шул юлда эшче-крәстияннәр интересы өчен, үзенең әдәби, гыйльми эшләре белән бергә үзен практик эшләрдә дә атаклы җәмәгать эшчесе итеп танытырлык зур хезмәтләргә ия булган бөек әдипкә, галимгә, җәмәгать эшчесенә, революционерга – Галимҗан Ибраһимовка багышлыйбыз.

Редакция

[1] «Безнең юл» журналының 1928 елгы 2 нче санында (б. 1) урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## «Мәгариф» журналының 2 нче саны Г. Ибраһимовның 20 еллык хезмәт бәйрәменә багышлап чыгарылуы хакында[1]

Февраль 1928 ел

«Мәгариф»нең бу номеры журналыбызның элекке редколлегия әгъзасы һәм җитәкчеләреннән булган Галимҗан иптәш Ибраһимовның XX еллык әдәби, гыйльми һәм иҗтимагый хезмәт бәйрәменә багышлап чыгарыла.

[1] «Мәгариф» журналының 1928 елгы 2 нче санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Г. Ибраһимовның 20 еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт юбилее хакында Үзәк юбилей комиссиясе белдерүе[1]

1928 ел

XX. Галимҗан Ибраһимовның егерме еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәте юбилее (1907–1928). Юбилей үзәк комиссиясе.

1927 елның октябрендә атаклы татар язучысы Галимҗан Ибраһимовның әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт башлавына 20 ел тулды.

Шушы 20 ел эчендә Галимҗан Ибраһимов гомумән татар мәдәни тормышына, бигрәк тә татар матур әдәбиятына үзенең кыйммәтле әдәби иҗатлары, шулай ук гыйльми, тәнкыйди әсәрләре һәм турыдан-туры үзенең катнашы белән чиксез күп хезмәтләр күрсәтте һәм шул өлкәләрдә югары урын тотып килде.

Татарстан Социал Советлар Җөмһүриятенең дәүләт органнары, җәмәгать оешмалары һәм гыйльми-әдәби җәмгыятьләре Галимҗан Ибраһимовның татар әдәбиятына һәм татарның гыйльми-мәдәни үсешенә күрсәткән кыйммәтле хезмәтләрен тәкъдир итеп, аның 20 еллык хезмәт юбилеен үткәрергә карар бирделәр.

Юбилей үткәрү эшләрен алып бару өчен Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршында махсус Үзәк комиссия төзелде.

Татарстан дәүләт органнары һәм юбилей Үзәк комиссиясе Г. Ибраһимовның 20 еллык юбилеен татар хезмәт ияләре арасында гына түгел, СССРдагы башка төрк халыклары арасында да мәдәни-тарихи әһәмияте зур булган бер вакыйга иттереп саныйлар.

Юбилей Үзәк комиссиясе сезгә югарыда әйтелгәннәрне белдерү белән бергә, сез бу зур мәдәни эшкә тиешенчә игътибар итәрсез һәм үз тарафыгыздан юбилейгә мөмкин чаклы тулы рәвештә катнашырсыз дип ышанып кала.

Юбилей тантанасы 1928 нче елның 10 нчы март көненә билгеләнә.

Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт юбилеенә катнашырга теләгән җәмәгать оешмала-

[1] Төп нөсхә Россия Федерациясе Үзәк дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивында саклана (941 ф., 10 тасв., 250 эш, 5–6 (икенче ягы) кәг.). Типография ысулы белән эшләнгән. Текст Казанда Ә. А. Шамованың шәхси архивындагы фотокүчермәдән алынды һәм беренче мәртәбә бастырыла.

рының, шулай ук аерым иптәшләрнең үзләренең катнашуларын түбәндәге адрес буенча Үзәк комиссиягә белдерүләрен үтенелә.

Казан, Кремль, Наркомпрос, Гыйльми үзәк, Үзәк юбилей комиссиясенә.

Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык хезмәт юбилеен үткәрү Үзәк комиссиясенең рәисе: Мөхетдинов.

Юбилей Үзәк комиссиясенең секретаре: Гомәр Галиев.

Юбилей Үзәк комиссиясенең членнары:

Баһаветдинов[1], М. Таһиров, И. Рәхмәтуллин, М. Корбангалиев, профессор Н. Н. Фирсов (Казан), профессор И. Н. Бороздин (Мәскәү), доцент Г. Сәгъди, доцент Г. Ф. Линсцер, доцент Н. З. Векслин[2], К. Мәһди, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Г. Нигъмәти, Сафа Борһан, Шәриф Камал, М. Фазлуллин, Ф. Бурнаш, Г. Толымбайский, М. Сәгыйдуллин, М. Давыдов, Ф. Хәсәнов.

XX. Двадцатилетний юбилей литературно-художественной и научной деятельности Галимджана Ибрагимова (1907—1928). Центральная юбилейная комиссия.

В октябре месяце 1927 года исполнилось 20 лет литературно-художественной и научно-общественной деятельности крупнейшего татарского писателя Галимджана Ибрагимова.

За этот 20-ти летний период времени Г. Ибрагимов неустанной своей работой занял одно из крупных мест в культурной жизни татар вообще и литературно-художественной, научно-общественной жизни в особенности, дав ценные свои творения как татарской литературе, так и науке.

Правительственные органы и научно-общественные организации Автономной Татарской Соц[иалистической] Сов[етской] Республики во внимание к литературно-художественным и научно-общественным заслугам Г. Ибрагимова решили ознаменовать и провести юбилей 20-ти летия его деятельности.

Для проведения этого юбилея при Татнаркомпросе создана специальная Центральная комиссия.

[1] *Баһаветдинов* – Гыймаз Баһаветдин улы Баһаветдинов (1897–1938), сәясәт эшлеклесе. 1928–1930 елларда ТАССР Халык комиссарлары советы рәисе урынбасары, Эчке эшләр халык комиссары. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

[2] *Н. З. Векслин* – Носон-Бер Залманович Векслин (1897–1942), географ-икътисадчы. 1926–1929 елларда ТАССРның Мәгариф халык комиссары урынбасары. Шәхес культы чоры корбаннарының берсе; үлгәннән соң акланган.

Правительственные органы и Центральная комиссия по проведению юбилея Г. Ибрагимова полагают, что этот юбилей является культурно-историческим актом крупного общественного значения не только для трудящихся татар, но и для родственных тюрко-татарских народов всего СССР.

Центральная Юбилейная комиссия, осведомляя вас о вышеизложенном, надеется, что вы тоже обратите надлежащее внимание и примете возможное участие в проведении этого юбилея, который состоится 10-го марта текущего года.

Организации и лица, желающие отметить юбилей 20-ти летней литературно-художественной и научно-общественной деятельности Г. Ибрагимова своими поздравлениями и приветствиями, благоволят направлять таковые Юбилейной комиссии по следующему адресу:

г. Казань, Кремль, Татнаркомпрос, Акадцентр, Юбил[ейной] комиссии.

Председатель Центральной юбилейной комиссии: Н. Мухитдинов.

Секретарь Центральной комиссии: Гумер Галеев.

Члены Центральной юбилейной комиссии:

Багаутдинов, М. Тагиров, И. Рахматуллин, М. Курбангалеев, проф. Н. Н. Фирсов, проф. И. Н. Бороздин, доцент А. Саади, доцент Н. З. Векслин, доцент Г. Ф. Линсцер, К. Магдиев, Ф. Сайфи, Г. Нигмати, Сафа Бурганов, Ш. Камал, М. Фазлуллин, М. Сагидуллин, Ф. Бурнаш, Г. Тулумбайский, М. Давыдов, Ф. Хасанов.

## Галимҗан Ибраһимовның юбилей җыентыгы нәшер ителү хакында[1]

10 февраль 1928 ел

Татарстан дәүләт нәшрияты. «Татиздат» тарафыннан басылып чыкты: Галимҗан Ибраһимов (20 еллык юбилейга каратылган җыентык)[2].

Бәясе 1 сум 75 тиен.

Заказлар кабул ителә.

Казань, «Татиздат» Торгсектор.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 10 февраль санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Галимҗан Ибраһимов (20 еллык юбилейга каратылган җыентык)* – Галимҗан Ибраһимов (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык) / Җыентык Мөхәммәт Таһиров, Габдрахман Сәгъди, Сафа Борһан, Галимҗан Нигъмәти иптәшләрдән гыйбарәт комиссия редакциясендә чыга.– Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1928 ел.– 196 б.

## Галимҗан Ибраһимовның юбилей җыентыгы һәм башка китаплары сатуда булуы хакында[1]

10 февраль 1928 ел

Татарның карт әдибе Галимҗан иптәш Ибраһимовның түбәндә исемнәре күрсәтелгән китапларын әдәбият сөюче һәркем кулында булдырырга тиеш.

XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык.

Бу җыентыкка әдипнең соңгы кулъязмасы һәм төрле вакыттагы рәсемнәре урнаштырылган. М. Таһиров, Г. Сәгъди, С. Борһан, Г. Нигъмәти редакциясендә. Бәясе 1 сум 75 тиен.

Зурайтылган рәсеме / – / – / – / 50 / – /

Безнең көннәр (роман, зур кулда) / – / – / 2 / – / – / – /

Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак / – / – / – / – / 25 / – /

Карт ялчы (хикәя) / – / – / – / – / 15 / – /

Алмачуар / – / – / – / – / 03 / – /

Дингездә / – / – / – / – / 03 / – /

Пролетариат әдәбияты мәсьәләләре / – / – / – / – / 50 / – /

Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре / – / – / – / – / 85 / – /

Задаткасыз заказлар кабул ителми.

Баш складның адресы:

Казань, Чернышевская, 21, Торг Сектор Татиздата.

## Галимҗан Ибраһимовның юбилей җыентыгы нәшер ителү хакында[2]

15 февраль 1928 ел

Татарстан дәүләт нәшрияты. «Татиздат». Басылып чыкты, заказлар кабул ителә. Галимҗан Ибраһимов (20 еллык юбилейга каратылган җыентык). Бәясе 1 сум 75 тиен.

Казань, «Татиздат» Торгсектор.

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 10 февраль санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 15 февраль санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Галимҗан Ибраһимовның 20 еллыгын үткәрү турында[1]

16 февраль 1928 ел

1927 елның октябрендә атаклы татар язучысы Галимҗан Ибраһимовның әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт башлавына 20 ел тулды. Шул мөнәсәбәт белән 1928 нче ел 10 нчы мартта аның юбилее уздырыла. Бу юбилейне уздыру мәктәпләргә һәм уку өйләренә тапшырыла. Бу учреждениеләр юбилейне үткәрергә алдан ук хәзерлекләр күреп, ул кичәгә авыл халкын да тартырга тиешләр. Юбилей кичәсендә башта Галимҗан Ибраһимовның хезмәтләре һәм тормышы турында доклад куеп, аннан соң аның әсәрләреннән кисәкләр укырга һәм әдәбият-концерт бүлеге ясарга киңәш ителә.

Галимҗан Ибраһимов турында доклад өчен материаллар: 1) «Мәгариф»[2] журналының 12 нче нумеры; 2) «Бзнең юл»[3] журналының 12 нче нумеры; 3) «Сабанчы»да[4], «Крестьян журналы»нда[5] чыккан һәм чыгачак мәкаләләр; 4) Галимҗан Ибраһимов турында «Татиздат» бастырып чыгарган мәҗмуга. Бу мәҗмуганың хакы бер сум 75 тиен булып, анда бөтен материаллар тулы рәвештә кертелгән. Шул «Татиздат»тан ук 50 тиенгә Галимҗан Ибраһимовның зур күләмдәге рәсемен алдырырга була.

Адрес: Казань, «Татиздат».

Губерна юбилей комиссиясе.

Губерна мәгариф бүлеге инспекторы: Чарышов.

---

[1] ВКП(б)ның Пенза губкомы һәм губерна Башкарма комитетының атналык крестьян «Сабанчы» газетасының 1928 елгы 16 февраль санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Мәгариф»* – ТССР Мәгариф халык комиссариаты наширлегендә Казанда 1921–1936 елларда нәшер ителгән гыйльми педагогия журналы.

[3] *«Безнең юл»* – Казанда 1922–1930 елларда нәшер ителгән гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый айлык журнал.

[4] *«Сабанчы»* – ВКП(б)ның Пенза губерна комитеты һәм губерна Башкарма комитетының атналык крестьян газетасы, 1922–1928 елларда чыккан.

[5] *«Крестьян журналы»* – андый исемдә журнал билгеле түгел, ВКП(б) өлкә комитеты һәм Татарстан Үзәк Башкарма комитетының басма органы булган, 1924–1929 елларда чыккан «Крестьян гәзите» булса кирәк.

## Галимҗан Ибраһимовның «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» дигән китабы нәшер ителү хакында[1]

9 март 1928 ел

Яңа басылып чыкты.
Татиздат дәүләт нәшрияты.

... «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре»[2].
Галимҗан Ибраһимов. Бәясе 85 тиен.

## Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәтенә багышланган тантаналы җыелыш хакында[3]

10 март 1928 ел

Бүген 10 нчы март, кич сәгать 6 да элекке Опера театрында (Галактионов урамы, 51 нче йорт) Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә багышлап тантаналы җыелыш ясала. Җыелышның көн тәртибе:

1) Галимҗан Ибраһимовның әдәби-иҗади һәм гыйльми-иҗтимагый хезмәтләре турында докладлар.

2) Спектакль, концерт.

Тантаналы җыелышның рәсми бүлегенә тәбрикләр белән башкача катнашырга теләгән оешмалар, шулай ук аерым кешеләр бу турыда юбилей үзәк комиссиясенә алдан белдереп куярга тиешләр.

Тантаналы җыелышка керү – махсус билетлар буенча.

Юбилей үзәк комиссиясе.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 9 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә басыла.

[2] ... *«Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре»* – Ибраһимов Г. Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре (1924–1911) / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты нәшере, 1927.– 143 б.

[3] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 10 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә басыла.

## Галимҗан Ибраһимов юбилее[1]

14 март 1928 ел

Казан, 12 март (РОСТА) Галимҗан Ибраһимовның әдәби хезмәтенә 20 ел тулу уңае белән тантаналы утырыш үткәрелде. Бу уңай белән юбилей иясенә бик күп котлаулар килде. Фәннәр академиясе, академик Ольденбург[2], Бартольд[3], Когоннардан, СССР милли җөмһүриятләренең Мәгариф комиссарлыкларыннан, партия һәм җәмәгать оешмаларыннан котлаулар алынды.

---

[1] «Яңа авыл» газетасының 1928 елгы 14 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Ольденбург* – Сергей Фёдорович Ольденбург (1863–1934), шәркыятьче, рус индология мәктәбенә нигез салучыларның берсе.

[3] *Бартольд* – Василий Владимирович Бартольд (1869–1930), шәркыятьче.

## Башкорт дәүләт труппасы тарафыннан Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» пьесасы сәхнәгә куелуы хакында[1]

14 март 1928 ел

Профсоюз әгъзалары һәм укучылар өчен очсыз хак белән Башкорт дәүләт труппасы тарафыннан тамаша куела.

Әдәби хезмәте белән танылган атаклы әдип Галимҗан Ибраһимов әсәре. «Яңы кешеләр»[2] 3 пәрдәдә. Кассада билетлар хәзердән үк сатыла.

Театр мөдире Бухарский[3].

---

[1] «Яңа авыл» газетасының 1928 елгы 14 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

Бу спектакльнең афишасы да сакланып калган. Аннан күренгәнчә, ул 16 март (җомга) көнне куелган. Афишада шундый сүзләрне дә укырга мөмкин: «Уфа сәхнәсендә беренче мәртәбә әдәби хезмәте белән танылган атаклы әдип Галимҗан Ибраһимовның әсәре».

[2] *«Яңа кешеләр»* – бу әсәр 1920 елда нәшер ителә: Ибраһимов Г. Яңа кешеләр: Драма өч пәрдәдә (Вакыйга 1918–1919 нчы елларда Идел-Урал тупрагында) / Г. Ибраһимов.– Казанда «Өмид» матбагасы, 1920.– 60 б.

[3] *Бухарский* – Хаҗиәхмәт Гыйрфанетдин улы Бухарский (1899–1974), актёр, режиссёр.

## Галимҗан Ибраһимов белдерүе[1]

13 май 1928 ел

Беләсез, һәрвакыт мин үзем юбилейга каршы идем. Ләкин татар хезмәт ияләре, алар белән бергә башка халыкларның да алдынгы катлавы арасында минем аз вакыт эчендәге эшләремне тәкъдир итү белән бәйләп, мәдәни бер бәйрәм ясарга зур теләк барлыгы[н] күп төрле оешма һәм учреждениеләр миңа төшендергәч, риза булдым. Юбилейның бу кадәр зур бер масштабта үтүе, аның зур бер мәдәни бәйрәм рәвешендә узуы хезмәт ияләренең мәдәни үсүләрен, никадәр зур адымнар белән алга китешне күрсәтә. Табигый, бу хәлгә шатланмый мөмкин түгел...

---

[1] Шушы чыганакта урнаштырылган: Таһиров М. Кырым истәлекләре / М. Таһиров // Кызыл Татарстан.– 1928.– 13 май. Беренче мәртәбә Г. Ибраһимов «Әсәрләр»енең 9 нчы томында бастырылган (Казан, 2000, б. 145). Текст газетадан алынды.

## О присвоении Г. Ибрагимову звания Героя Труда[1]

16 августа 1928 г.

Галимджан Ибрагимов, проф. Гордягин – герои труда.

Москва, 14. (Роста)... за ряд научных заслуг президиум ВЦИК присвоил звание героя труда члену Государственной Академии Художественных Наук Ибрагимову.

[1] «Красная Татария» газетасының 1928 елгы 16 август санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

## «Кызыл Татарстан» газетасы 1929 елда бер еллык язылучыларына Дәрдемәнднең академик тулы мәҗмугасы белән Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» исемле романын бүләк итәчәге хакында[1]

14, 28 декабрь 1928 ел

«Кызыл Татарстан» гәзите 1929 нчы елда бер еллык подписчикларына татар классикларыннан Дәрдемәнднең[2] беренче мәртәбә басыла торган академик тулы мәҗмугасы[3] белән Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар»[4] исемле 15 табаклы яңа романы, иң соңгы әсәрен бүләк итә.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 14, 28 декабрь саннарында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Дәрдемәнд* – Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев (1859–1921), шагыйрь, алтынчы, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче.

[3] …*академик тулы мәҗмугасы* – Dərdmənd əsərləre / Təzycese: İ. Rəmi.– Qazan: Jaŋalif, 1929.– 108 b.

[4] … *«Тирән тамырлар»* – Ибраһимов Г. Тирән тамырлар (Тугры сүз): Хикәя / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты, 1928.– 198 б.

## Карт әдип Галимҗан Ибраһимов терелә[1]

1928, № 5

Карт әдибебез Галимҗан Ибраһимов XX еллык юбилей тантаналары үткәч Татарстан Мәгариф халык комиссариаты юбилейнең тиешле материалларын тапшыру һәм Галимҗан Ибраһимовның хәлен белү өчен аның янына Татарстан Гыйльми үзәге рәисе иптәш Таһировны җибәргән иде. Без бу урында Галимҗан Ибраһимовның юбилей уңае белән Татарстан Мәгариф халык комиссариатына җибәргән хатын һәм Галимҗан Ибраһимовның Таһиров иптәш белән утырышканда яңалиф турында сөйләгән кайбер фикерләрен басабыз.

Редакция.

[1] «Безнең юл» журналының 1928 елгы 5 нче санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды.

## Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» исемле әсәре басылып чыгуы хакында[1]

27 декабрь 1928 ел

Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» исемле әсәре басылып чыкты[2]; бәясе 1 сум 50 тиен. Сорарга «Татиздат»тан.

## Комиссия по изучению литератур народов Советского Востока[3]

1928, № 2

...Комиссия устроила совместно с Научной Ассоциацией Востоковедения два открытых заседания: 1) Вечер, посвященный 20-летию литературной деятельности Галимджана Ибрагимова (докладчики: Максудов, проф. Бороздин, Мансуров, Аршаруни).

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 27 декабрь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» исемле әсәре басылып чыкты* – Ибраһимов Г. Тирән тамырлар (Тугры сүз): Хикәя / Г. Ибраһимов.– Казан: Татарстан дәүләт нәшр., 1928.– 198 б.

[3] «Новый Восток» журналының 1928 елгы 22 нче санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

## 1929
## Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы нәшер ителүе хакында[1]

Февраль 1929 ел

«Тирән тамырлар».

Атаклы карт язучы Галимҗан Ибраһимовның иң соңгы әсәре.

Бу китап бөтен татар китап магазиннарында сатыла. «Тирән тамырлар» үзенең зурлыгына һәм яхшы техникада басылуына карамастан бәясе бары бер сум 50 тиен.

Соратыр өчен адрес: Казан: Татиздат.

[1] «Безнең юл» журналының 1929 елгы 2 нче санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы сатылуы хакында[1]

Февраль 1929 ел

Ибраһимов Галимҗан (XX еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый бәйрәменә каратылып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык). Җыентык: Мөхәммәт Таһиров, Габдрахман Сәгъди, Сафа Борһан, Галимҗан Нигъмәти иптәшләрдән гыйбарәт комиссия редакциясендә чыга.

Казан. Тат[арстан] дәү[ләт] нәшр[ияты]. 1928. $8^0$. 194 бит. Тиражы 3000. Бәясе 1 с[ум] 75 т[иен].

[1] «Безнең юл» журналының 1929 елгы 2 нче санында арткы тышлыкның эчке ягында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## «Кызыл Татарстан» газетасы 1929 елда бер еллык язылучыларына Дәрдемәнднең академик тулы мәҗмугасы белән Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» исемле романын бүләк итәчәге хакында[1]

22 декабрь 1928 ел

«Кызыл Татарстан» гәзите 1929 нчы елда бер еллык подписчикларына татар классикларыннан Дәрдемәнднең беренче мәртәбә басыла торган академик тулы мәҗмугасы белән Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» исемле 15 табаклы яңа романы, иң соңгы әсәрен бүләк итә.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1928 елгы 22 декабрь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

## 1931
## Хроника[1]

1931, № 4

ГИХЛдә татар әдәбияты сериясеннән Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» повестеның русчага тәрҗемәсе чыга[2].

[1] «Яңалиф» журналының 1931 елгы 4 нче санында урнаштырылган (б. 44). Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла.

[2] *«Тирән тамырлар» повестеның русчага тәрҗемәсе чыга* – Әсәрнең рус телендә тәрҗемәсе озак еллардан соң гына бастырыла: Ибрагимов Г. Глубокие корни: Роман / Перев. с татарского Р. Фаизовой / Г. Ибрагимов.– М.: Худож. лит, 1964.– 226 с.

## 1933

### Председатель Ялтинского оргкомитета ССП Г. Г. Ибрагимов награжден ВЦИК званием героя труда[1]

5 января 1933 г.

Текст грамоты: президиум Всероссийского Центрального Исполнительного Комитета, отмечая Вашу выдающуюся и исключительно полезную деятельность в области социально-культурного развития татарских трудящихся масс, выразившуюся в создании классических произведений татарской художественной литературы, в издании специальных трудов по изучению классовой борьбы и революционного движения среди татар, а также учитывая Вашу активную общественную работу,– награждает Вас званием героя труда.

Председатель Всероссийского Центрального Исполнительного Комитета М. Калинин.

И[сполняющий] о[бязанности] секретаря Всероссийского Центрального Исполнительного Комитета Новиков.

[1] «Литературная газета»ның 1933 елгы 5 гыйнвар санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

## Әдип Галимҗан Ибраһимов Хезмәт Батыры[1]

18 апрель 1933 ел

Совет язучылары Союзының Ялта (Кырым) оештыру комитеты председателе әдип Галимҗан Ибраһимов СССР ҮБК тарафыннан Хезмәт Батыры исеме белән бүләкләнде. Аңа бирелгән грамотаның тексты:

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты президиумы Сезнең татар хезмәт ияләре күпчелегенең социаль культура өлкәсендә алга китүләре юлындагы бик күренекле һәм аеруча файдалы хезмәтләрегезне – татар матур әдәбияты классик әсәрләрен тудыру, татарлар арасында сыйнфый көрәш һәм революцион хәрәкәтне өйрәнүгә багышланган хезмәтләр бастыруыгызны шулай ук актив җәмәгать эшләрегезне искә алып,– Сезне хезмәт батыры исеме белән бүләкли.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты председателе: М. Калинин.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты секретаре эшен башкаручы: Новиков.

[1] «Коммуна» газетасының 1933 елгы 18 апрель санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

## В крупнейшем издательстве художественной литературы[1]

29 ноября 1933 г.

К съезду выйдут также: большой роман башкирского писателя С. Тагирова «Солдаты»[2], роман татарского писателя Ибрагимова «Дочь казака»...

---

[1] «Литературная газета»ның 1933 елгы 29 ноябрь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды.

[2] Сүз язучы Афзал Таһиров (1890–1937) һәм аның Беренче Бөтендөнья сугышы вакыйгаларын яктырткан әсәре турында бара: Солдаты. Авториз. обработка по подстрочному с башкир. Вступ. статья от редакции.– М.: ГИХЛ, 1934.– 207 с. Аннан соң әсәр рус телендә тагын ике мәртәбә нәшер ителә: Солдаты. Авториз. пер. Изд. 2-е.– М.: Гослитиздат, 1935.– 384 с.; Солдаты. Подстрочный пер. с башкирского Н. Газизова и Галиева. Изд. 2-е испр.– М.: Гослитиздат, 1936.– 296 с.

## 1934

### Совет Язучылары союзы[1]

5 июнь 1934 ел

Татарстан Совет язучылары Союзының Оештыру комитетының Президиумы Союзга член итеп алу турында бирелгән гаризаларын караганда гомумән Уставтан һәм бигрәк тә аның югарыдагы пунктыннан чыгып эш итте. Гаризалар бирү әле дәвам итә. Ләкин беренче нәүбәттә каралган 50 гаризага йомгак ясаганда түбәндәге хәл күренә: каралган 50 гаризадан 24 кеше Союзга член итеп билгеләнә. Болар арасында Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Сәйфи, К. Нәҗми, Г. Нигъмәти, Г. Гали, К. Тинчурин, И. Гази, Ф. Кәрим, М. Буберно, Б. Зернит һәм совет язучылары Уставының сорауларына җавап бирүче башка язучы һәм тәнкыйтьчеләр бар.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының 1934 елгы 5 июнь санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды һәм гамәлдәге татар хәрефләрендә беренче мәртәбә бастырыла, стиле сакланды.

## Об учреждении Всесоюзного Пушкинского Комитета в связи со столетием со дня смерти А. С. Пушкина Постановление Центрального Исполнительного Комитета Союза ССР[1]

16 декабря 1935 г.

В связи с предстоящим празднованием столетнего юбилея со дня смерти великого русского поэта, создателя русского литературного языка и родоначальника новой русской литературы – Александра Сергеевича Пушкина, обогатившего человечество бессмертными произведениями художественного слова,– Центральный исполнительный Комитет Союза ССР постановляет:

1. Учредить Всесоюзный Пушкинский Комитет в следующем составе:

Председатель – А. М. Горький.

Заместители председателя – А. С. Бубнов[2] и А. С. Щербаков[3].

Члены Комитета:

...45. Ибрагимов Г.

2. Поручить Пушкинскому Комитету выработать ряд мероприятий, имеющих целью увековечить память А. С. Пушкина среди народов Союза ССР и содействовать широкой популяризации его творчества среди трудящихся.

3. Выработанные Комитетом меры внести на утверждение ЦИК Союза ССР и осуществлять соответствующим накоматам с тем, чтобы все подготовительные работы были закончены за три месяца до дня годовщины смерти поэта – 10 февраля 1937 года.

Председатель Центрального
Исполнительного Комитета Союза ССР
М. Калинин.

Секретарь Центрального
Исполнительного Комитета Союза ССР
И. Акулов[4].

Москва, Кремль. 16 декабря 1935 г.

---

[1] «Правда» газетасының 1935 елгы 17 декабрь санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

[2] *А. С. Бубнов* – Андрей Сергеевич Бубнов (1883–1940), дәүләт һәм партия эшлеклесе, тарихчы-публицист.

[3] *А. С. Щербаков* – Александр Сергеевич Щербаков (1901–1945), дәүләт һәм партия эшлеклесе, 1934–1936 елларда СССР Язучылар берлегендә оештыручы секретарь була.

[4] *И. Акулов* – Иван Алексеевич Акулов (1888–1939), партия һәм дәүләт эшлеклесе.

## 1957

## Тантаналы кичә[1]

12 март 1957 ел

Татарстан язучылар союзы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты һәм СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты университетның актовый залында бүген, кич 7 сәгатьтә татар әдәбиятының классигы – язучы Галимҗан Ибраһимовның тууына 70 ел тулуга багышланган тантаналы кичә үткәрәләр. Кичәдә язучының әдәби һәм җәмәгать эшчәнлеге турында доклад белән филология фәннәре кандидаты Г. Халит чыгачак.

Докладтан соң шәһәр сәнгать көчләре һәм университет үзешчән сәнгать коллективы катнашы белән художество бүлеге булачак.

[1] «Совет Татарстаны» газетасының 1957 елгы 12 март санында бастырылган. Текст шуннан алынды.

# 1997

## Г. Ибраһимовның тууына 110 ел тулу уңаеннан Башкортстан дәүләт педагогия институтында фәнни конференция уздырылу хакында[1]

15 март 1997 ел

17 мартта Башкортстан дәүләт педагогия институтының 3 нче бинасында (Октябрь революциясе урамы, 3/1, 409 бүлмә) атаклы татар язучысы, якташыбыз, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 110 ел тулуга багышланган республика гыйльми конференциясе үткәрелә.

Конференция 12 сәг. 30 минутта башлана.

---

[1] «Өмет» (Уфа) газетасының 1997 елгы 15 март санында урнаштырылган. Текст шуннан алынды.

## Эчтәлек

*Р. Исламов.* Галимҗан Ибраһимов – документларда: өйрәнелү тарихы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

I. АВТОБИОГРАФИЯЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
II. КАЙБЕР ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРЕННӘН ҮРНӘКЛӘР . . . . . . . . . . . 59
Алмачуар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Табигать балалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86

III. КАЙБЕР ГЫЙЛЬМИ ХЕЗМӘТЛӘРЕННӘН ҮРНӘКЛӘР. . . .101
Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? . . . . . . . . . . . . . . . . . .101
Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Мәсьәләнең куелышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Яңа һәм иске тип мирзалар карашы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Пролетариат юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .111
Сталин формуласы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .117
Волбашкармаларда аппаратның миллиләшүе . . . . . . . . . . . . . . . 129
Нәтиҗәләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134

IV. СОВЕТ ЧОРЫНА КАДӘРГЕ ДОКУМЕНТЛАР. . . . . . . . . . . . . .138
Иҗтимагый-сәяси документлар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .138
а) Жандармерия документлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .138
б) Уфада укытучылык эшенә бәйле документ . . . . . . . . . . . . . . . 267
в) «Мөселманнар арасында гражданлык идеясе тарату комитеты»ның гомуми җыены документлары . . . . . . . . . . . . . . . 268
г) Учредительный собраниегә сайлау документлары . . . . . . . . . . . 295
Хатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .316
Телеграммалар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 356
Белдерүләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 357
Мөрәҗәгатьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 378
Хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 382
Автографлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 391
Котлаулар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 398

V. СОВЕТ ЧОРЫ ДОКУМЕНТЛАРЫ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 399
Иҗтимагый-сәяси документлар. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 399
Татарстан Мәгариф халык комиссариаты документлары . . . . . . . 504
Гыйльми үзәк документлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 522
Хәбәрләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 561
Белдерүләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 642

*Китапта файдаланылган иллюстратив материаллар түбәндәге чыганаклардан алынды:*

*Татарстан Республикасы Дәүләт архивы;*

*Башкортстан Республикасы Милли архивы;*

*Татарстан Республикасының Милли китапханәсе;*

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге;*

*Казанда яшәүче Әлфия Шамова, Рамил Миңнуллин, Рәмил Исламовның шәхси архивлары;*

*төрле телләрдәге хәзерге көндәлек матбугат, ачык интернет ресурслар.*

16+ Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. №436–ФЗ

Фәнни басма

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ –
ДОКУМЕНТЛАРДА

I том

Автобиографияләре, әдәби әсәрләреннән, гыйльми хезмәтләреннән үрнәкләр, совет чорына кадәрге һәм совет чоры документлары

*(на татарском языке)*

Ответственный за выпуск: *Фуат Рафиков*
Дизайн обложки: *Григорий Эйдинов*
Художественное оформление: *Рамиль Миннуллин*
Компьютерная вёрска: *Йолдыз Нуриева*
Корректор: *Ландыш Авхадиева*

Формат 84х108 1/32. Усл. печ. листов 36,12
Бумага офсетная. Тираж 1000 экз. Заказ №

Отпечатано в полном соответствии с качеством
предоставленного электронного оригинал-макета в типографии филиала
ОАО «ТАТМЕДИА» ПИК «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2. e-mail: idelpress@mail.ru